Амирхан Еники
СОЧИНЕНИЯ
в пяти томах

1 том

*Рассказы*
Казань
Татарское книжное издательство
2000

Әмирхан Еники
Казань
Татарское книжное издательство
2000

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2000

ББК 84 Тат.7–4
Е 56

Редколлегия:
*И.К.Хәйруллин, Р.М.Миңнуллин, Ф.Г.Галимуллин, Д.С.Шакиров, Х.Г.Әюпов, Т.А.Миңнуллин, Н.С.Фәттах, М.Х.Вәлиев, Н.Т.Ильясова*

**Еники Әмирхан**

Әсәрләр, 5 томда. 1 том.— Казан: Татар. кит.нәшр., 2000, 447 бит, рәсеме белән.

ISBN 5–298–00984–0

© Төзү, кереш сүз, 2000
© Татарстан китап нәшрияты, 2000

# Татар әдәбиятының морзасы

Мин һәрвакыт Әмирхан Еникидән бераз шүрләбрәк яшәдем.

Үземне әллә кемгә санап, түш киереп йөргәндә туктатыр да: «Син нәрсә әле бик кылтаеп йөрисең? Кем булдың ул чаклы?» — дип оялтыр төсле тоела иде. Бүтән берәү ул сүзләрне әйтсә, җавабын да табар идем, телләшеп алырга да күп сорамас идем. Әмма Еники... Кыскасы, аңарга бик якын килергә, янәшәсендә җәелеп утырырга базмадым.

Әдәбиятта остазлыкны кабул итмәсәм дә, Әмирхан абыйга мөнәсәбәтем башлангыч сыйныф баласының үз укытучысына булган мөнәсәбәте сыман иде.

Аның сине тыңлаганда башын аска иебрәк утыруы, күзлек өстеннән генә сөзеп карап алуы, ара-тирә «әйе, эһем, әйе» дип әйткәләп куюы күпләрне каушата иде. Синең белән килешкәнен, килешмәгәнен дә белеп булмый иде. Күңеленә ошамаган сүз ишетсә дә, җиң сызганып бәхәсләшергә керешми иде. Һәр сүзе, һәр хәрәкәте уйланган иде аның, беркем дә какшата алмаслык үз уе, үз фикере бар иде.

Көнкүрештәге үз-үзен тотышы Әмирхан абыйның иҗатына да хас. Мин ул язганнарның барысын да укып бардым шикелле. Көтеп алып укыдым. Гаҗәпләнеп, сокланып, тәмләп укыдым һәм укыйм.

Әле менә китабына сүз башы язу уңаеннан хикәяләре җыентыгын кулыма алган идем. Караштыргалап, хәтеремне генә яңартырга җыенган идем, онытылып китеп укып чыктым. Кирәк бит шундый осталык — махсус бәйләнеп тә, бер генә дә житешмәгән ягын табып булмый. Һәр хикәядә фикер тирәнлеге һәм төгәллеге, һәрбер җөмлә камил һәм тәэсирле, һәрбер сүз үз урынында. Уңган, зәвыклы хуҗабикәнең табыны шикелле: карап торырга да матур, ризыкларын авыз итсәң, телең йотарлык. Югыйсә анда әллә кайлардан китерелгән үтә кыйммәтле деликатеслар да юк.

Әмирхан аганы укыгач, «һи, болай гына мин дә яза алам» дип, ялгышуың да ихтимал. Наданнарны алдый торган гадилек. Ләкин бөек гадилек. Андый гадилеккә өйрәнеп кенә ирешеп булмыйдыр. Ходай биргән сәләттер ул.

Әмирхан абыйның кулъязмаларын карап чыгасым килә минем. Анда сызылган-бозылган урыннар юктыр сыман. Күктән аңа кемдер әйтеп тора да, шуны әдип кәгазьгә генә төшереп барадыр кебек. Ул укучыны шаккатырырга теләми. Ул бары тик сөйли генә.

Татарда «Яхшы сүз — җан азыгы, яман сүз — баш казыгы» дигән гыйбарә бар. Әмирхан абый, әлбәттә, аны белә. Ләкин белгәнен берәүгә дә белгертми. Аның «Бер сүз» дигән кыска гына хикәясен иплап кенә, ләззәтләнеп йотып барганда, кинәт шул бер сүзне укыйсың да тетрәнеп куясың. Ходаем, мин дә шундыйрак сүз әйтеп берәрсенең җанын рәнҗетмәдем микән, дип уйланасың.

Мәхәббәт турында инде күпме язылган, без дә язып торабыз — «Нәрсә соң ул мәхәббәт?» дигән мәңгелек сорауга җавап эзлибез. Әмирхан Еники дә эзли. «Гөләндәм туташ хатирәсе»ндә дә, «Төнге тамчылар»да да эзли. Аларны укыгач, берәү дә җавап таба алмаган сорауга җавап тапкан кебек буласың. Мәхәббәт дигән могҗиза, күк капусы ачылгандай, үзенең серләрен безгә сөйләп бирә сыман. Шул серләр сине әсир итә, сихерле һәм җаныңның сафлана баруын тоясың.

Без, авыл малайлары, авылны яхшы ук беләбез. Табигатьнең гүзәллегенә соклanудан да бизмәгәнбез әле. Әмма «Җиз кыңгырау»ны укыганда, Нигъмәтулла абзый тарантасына утырып, Каракош авылы белән Абзан авылы арасын үтәсе, Түрәш болынындагы биек үлән арасына чалкан ятып күккә карап ятасы килә. Күңел, җан шунда тартыла. Табигатьтән аерылып үзебезнең ничаклы ярлыланганыбызны күреп, йөрәк әрни, сагыш баса. Үзеңдә «Әйтелмәгән васыять»тәге Акъәби балалары чалымын сизеп, оялып куясың. Чистарынасы килә.

Без бүген үзебез яшәгән көннәрне болгавыр еллар дип атыйбыз. Күпләребездә өметсезлек чире. Аның сәбәпләрен бүген власть башында утыручылардан күрәбез. Бактың исә, илдәге башбаштаклыкның тамыры тирәндә икән. Ата улын, ана кызын белмәү бу илдә күптәннән башланган икән. Кеше кадере булмаган җәмгыятьтә кешегә кешечә яшәргә шартлар юк икән. Аның шулай икәнен төшенү өчен Әмирхан аганың «Тынычлану»ын укырга кирәк икән.

Мин Еники турында язганда аның әсәрләренең эчтәлеген сөйләмәскә дип сүз куйган идем. Ләкин тыела алмыйм. «Курай»ны, «Матурлык»ны укымаганнарга шуны укып күрсәтәсем килә, кинорежиссер булып «Шаяру»дан фильм эшлисем килә. Зәңгәр яулыкның Идел өстендәге караңгылыкка кереп югалуын Әмирханча сурәтләсәң генә дә гаҗәеп кадр булыр иде.

Уйлап утырам — татар кешесенең холык-фигылен, яшәү рәвешен, кием-салымын, төс-кыяфәтен, осталык-маһирлыгын, уңган-үҗәтлеген Еники кебек төгәл сурәтләп биргән язучылардан кемнәр бар икән? Гаяз Исхакый, Гомәр Бәширов, Мөхәммәт Мәһдиев, Аяз Гыйләҗев... Юк, санамыйм. Ялгышып, кемнедер онытып калдыруым ихтимал.

Әмирхан Еникидә нинди генә татарлар юк. Сөйкемлеләре, сөйкемсезләре, киң күңеллеләре, икейөзлеләре, акыллылары, ахмаклары, зыялылары, наданнары — барысы да бар. Әмма мине иң сокландырганы — «Чикерткә»дәге татарлар. Ишан кыяфәтендәге шәкерт һәм аның мөриде булып кыланган хәлфә турында әкият итеп кенә сөйләнгән хикәядә үземнең татарымны таныйм мин. Утта янмас, суда батмас татарымны күрәм. Бу әкәмәт дөньяда чарасызлыктан аптырап калганда, инде бетте дигәндә дә җаен тапкан татарымны очратып куанам. «Моңарчы эшли белгән татар башы бу юлы да берәр әмәлен табар әле, боерган булса»,— ди язучы. Мең кат гафу үтенәм, Әмирхан абый җөмләсенә «татар» дигән сүзне үзем өстәдем. Өстәмичә булдыра алмадым. Хәйләкәр әдип ул сүзне юри язмаган, укыган кеше үзе төшенер дигәндер. Мин түзә алмадым, өстәдем.

Чын татар иде Әмирхан агабыз. Милләтебезнең иң затлы сыйфатларын күңелендә кадерләп саклаган зыялы татар иде. Мине иң куандырганы һәм сокландырганы —аңарда мокытлыкның эзе дә юк иде. Буйсынырга мәҗбүр булган очракларда да дәрәҗәсен төшермәде. Шуңадыр, ахры, аның үлемен ишеткәч, көндәлегемә «Әмирхан Еники үлгән, диделәр. Татар әдәбиятының соңгы морзасы бездән китте. Мужиклар гына җыелып калдык» дип язып куйганмын.

Каләмдәшләрем гафу итсеннәр, бу сүзләр озак уйлап йөргәннән соң, үзебезне кимсетү өчен язылган сүзләр түгел. Кинәт кенә башка килгән беренче уй. Уйга килгән, димәк, уйланырга җирлек бар, үз кадеребезне үзебез белсәк иде.

Сүземне кечкенә генә бер вакыйга белән тәмамлыйм.

Беркөнне минем унбиш яшьлек оныгым Диләрә китапханәмдәге Әмирхан Еники китапларын күтәреп йөри. «Нишлисең,— мин әйтәм,— алар белән?» «Татар әдәбияты буенча реферат язам»,— ди. «Ни өчен Әмирхан Еники?» — дим. «Чөнки мин аның «Кем җырлады?» дигән хикәясен укып чыккан идем, бик ошады. Калганнарын да укыйм да язам»,— ди.

Бу бик мәгънәле вакыйга. Диләрә бүгенге шылдыр-былдыр заманның шәһәрдә туган баласы. Әгәр Әмирхан абый андыйлар игътибарын җәлеп итәрлек әсәрләр калдырган икән, димәк, аның иҗат гомере бик озын. Амин, шулай булсын!

**Туфан Миңнуллин,**
**6 март, 2000 ел**

# Бала

*Сөекле кызым Резедага*
*багышлыйм*

Лейтенант Иванов ротасы урман эче буйлап зур саклык белән алгы позициягә таба китеп бара. Дошман самолеты күренә калса, тизрәк агачлар арасына яшеренергә уңай булсын дип, кызылармеецлар юлның ике ягыннан пар-пар тезелешеп баралар.

Юл ат, арба, машина эзләре белән тулы. Җәяүлеләр дә күп үткән булса кирәк: дымлы комда солдат итекләреннән, хатын-кыз ботинкаларыннан калган эзләр дә ярылып ята. Бу юл — бүгенге мәхшәрнең бердәнбер телсез шаһиты. Ике туганның бер үк эзгә басканын бары ул гына белә. Ә шулай да ул бу сәгатьтә нинди мәкерле тыныч һәм нинди буш.

Урман, үз-үзен тыңлагандай, хәрәкәтсез һәм тып-тын. Кояш чыккан вакыт. Мәһабәт төз наратларның очлары җылы нурга манчылып, рәхәт бер талгынлыкка бирелгәндәй, шылт та итмичә, тик кенә торалар... Берәм-сәрәм очраган усакларның көмеш яфраклары, таң сулышыннан уянышып, сөенә-сөенә уйнаган шикелле, җилфердәшәләр... Ачык урыннарда, җиргә таба сыгыла төшеп, хәрәкәтсез ак томан ята. Үлән эченнән узсаң, шунда ук итекләрнең йөзләре ялтырап чыга һәм эзләр, яшькелт-кара тасмадай, артта сузылып кала. Үсемлекләрнең исле пары борынны кытыклый һәм үпкәләргә сыланган кебек була. Озак килүгә дә, йөкнең авырлыгына да карамастан, тән нициндер бер җиңеллек, күңел исә шул җиңеллектән гамьсез бер рәхәтлек тоя...

Ротаның арткы рәтендә кызылармеец Зариф, алдан баручы иптәшләренең тигез генә тирбәлгән аркаларына карап, салмак кына атлап бара. Аның йөзендә тыныч ваемсызлык. Бары тик кысыла төшкән күзләре генә аның эчке уйларына йотылып баруын күрсәтә.

Бу иртәнең җылы тынлыгы, урманның өлкән гамьсезлеге каядыр якында гына мәрхәмәтсез сугыш, кан һәм үлем барлыгын онытып торырга мәҗбүр итә, гүя сөттәй ак томан ул дәһшәтләрне үз эченә яшерә һәм кешедән ераклаштыра. Бу тыныч һәм сөенечле хисләр белән сулый торган табигатьтә кеше ничектер, үзе дә теләмәстән, алданучан була.

Чыннан да, Зариф кая барганын һич онытмаса да, хәзерге минутта иң гади, шул ук вакытта күңеленең һәркайчан сагынып теләгән уйларына йотылган иде: менә киң кырлары, зәңгәр урманнары белән гел хыялында яшәгән туган иле, һәр читән казыгына кадәр таныш авылы, сәке йөзлегендәге киртләчләренә кадәр күзе алдыннан китми торган өе, исенә төшергән саен тавышы ишетелгәндәй тоелган хатыны, ниндидер сөйкемле гадәтләре белән йөрәгендә сакланган баласы... Урам күпере... басу юлы... иген кыры... Тулы, тыгыз башакларын күтәрә алмыйча җиргә иелгән бодайлар... Быел нинди мул уңыш иде!.. Хәзер инде көн-төн ашлык сугалардыр.

Менә Зарифның колагына кайдадыр якында гына ашлык суккыч машинаның гөрләве, эре көлтәләрне тартып алып йоткан чакта үкереп куюы ишетелгән кебек булды.

Ул: «Кайда сугалар икән?» — дип уйларга өлгерә алмады, командирның:

— Һава! — дип кычкырганы ишетелде. Рота минут эчендә юлның ике ягына, агачлар арасына яшеренде.

— Менә сиңа молотилка! — диде Зариф, бер агач төбенә ятып, һәм алдануына башын селкеп куйды.

Самолет ераклашты. Лейтенант команда бирде булса кирәк, алда яткан кызылармеецлар ашыгып тора башладылар. Зариф та урыныннан кузгалды. Ләкин ул бер адым да атларга өлгермәде, үзеннән биш-алты метр гына читтә өч-дүрт яшьлек кыз баланың басып торганын күреп, ихтыярсыз тукталды. Баланың берәр якын кешесен күрергә теләп, тирә-ягына каранды, ләкин якында һичкем барлыгы сизелми иде. Зариф бик гаҗәпләнеп янә балага карады; бала чыннан да ялгыз иде. Ул үзе биеклек кенә бер куак янына баскан, кечкенә кулына берничә бөртек каен җиләге учлаган, шуны кабарга хәзерләнгән җиреннән туктап, зур соры күзләре белән Зарифка исе китеп карап тора. Озак елаудан аның күз төпләре шешенгән, түгәрәк битендә яшь юллары калган... Ләкин хәзер тынычланган, нинди хәлдә булуын онытkan, ахрысы — аяк астындагы җиләкләрне җыярга керешкән. Аның өстендә зәңгәр сукнодан җәйге пальто, башында фетрдан тегелгән кара шапочка, аны кызыл тасма белән ияк астыннан китереп бәйләгән; аякларында озын сары оеклар белән сары ботинкалар һәм бер аягында галошы бар, икенчесен төшереп калдырган, ахрысы.

Зариф бу баланың дошман явыннан качып баручылардан югалып торып калганын бик тиз төшенә, һәм аңарда кузгалган беренче теләк — баланы тизрәк күтәреп аласы килү булды. Шул ук вакытта ул ротадан аерылып калырга һич ярамаганлыгын да уйлап алды. Беренче хәрәкәте аның ротасы артыннан китү өчен юлга таба борылу булды. Ләкин ул, бер адым да атламастан, кинәт балага таба кире борылды, ашыгып аның янына барды да җитез генә күтәреп алды.

Бала куркуыннан:

— Әни! — дип кычкырып җибәрде һәм, җиләген йомарлаган кулы белән Зарифның битеннән этәреп, аякларын селкеп еларга кереште.

Зариф, баланы кысып тоткан килеш, аяк астында аунаган чыбыкларга, агач төпләренә абынмас өчен сикерә-атлый, ашыгып юлга чыкты. Шундый кыска вакыт үтүгә карамастан, рота шактый ераклашкан иде инде. Зариф, сыңар кулы белән иңендәге мылтыгын уңайлый төшеп, кызу-кызу атлый башлады.

Бала елап арыган, күрәсең; тиз арада аның елавы тавышсыз үксүгә әйләнде. Зариф кесәсеннән бер шикәр кисәге чыгарып, тузанын өргәләп, балага тоттырды. Бала башта башын селкегән булды, аннары шикләнеп кенә буш кулы белән шикәрне алды һәм йомарлап күкрәгенә кысты.

Зариф йомшак тавыш белән:

— Аша, аша! — диде һәм баланың аркасыннан сыйпап, сөеп куйды. Балага шул җитә калды: ул үксүеннән туктады, тынычланган кебек булды һәм, Зарифның кулында акрын гына селкенеп, тирә-ягына каранып бара башлады. Зариф баланың юка киеме аша йомшак тәнен, җылысын, тәмле исен тоя иде. Ниндидер бер ләззәтле сагыну белән шул йомшак тәнне, шул тәмле бала исен тагы да ныграк тоярга, ничектер үзенә сеңдерергә теләгәндәй, ул баланы акрын гына кыса, аркасыннан сыйпый... Һәм аның йөрәге төбеннән әйтеп биреп булмый торган сөенечле бер ярату хисе җылы дулкын булып күтәрелә бара иде. Зарифның да бит өч яшьлек Фәридәсе бар. Зариф та бит әти, һәм, бәлки, шушы минутта ул үз баласы белән бу бала арасында аерма тоймыйдыр, киресенчә, бу балага биргән мәхәббәтен һәм назын үз Фәридәсенә биргән кебек тоядыр. Ул, баланың йомарлаган кулын тотып, кипкән иреннәренә тидереп алды. Акрын, назлы гына:

— Әтиең, әниең бармы? — дип сорады, һәм аның тамак төбе кытыкланып, күзләре дымланып китте.

Бала ачык тавыш белән җавап кайтарды:

— Әнием дә бар, әтием дә бар... безнең әле тагын кәҗәбез дә бар. Бәтиләре ап-ак.

Зариф елмаеп, балага күтәрелеп карады:

— Шулаймыни? Кара син, ап-аклар икән... Ә әтиең кайда соң?

— Китте.

— Кая китте?

— Белмисеңмени? Фронтка,— диде бала һәм аз гына тынып торганнан соң исенә төшкәндәй,— ул лейтенант,—дип куйды.

— Шулаймыни? Менә син нинди акыллы, әтиеңнең кем икәнен дә беләсең. Ә...

— Зариф кинәт сүзен бүлде. Ул: «Әниең кайда?»—дип сорамакчы булган иде, ләкин баланың исенә төшермәс өчен, тыелып калды.

Бала Зарифка тәмам ияләшеп өлгерде, күрәсең. Ул, тарсынмыйча, әүвәл бер кулындагы ике бөртек җиләгән капты, соңра икенче кулындагы шикәрен суыра башлады.

Кинәт бөтен урман эчен дәһшәтле гөрселдәү каплап алды. Җир буйлап тетрәү йөгерде һәм һава дулкынынынан агачларның башлары селкенешеп куйдылар. Кайдадыр якында гына артиллерия атышы башланды. Зариф та, бала да бераз вакытка сүзсез калдылар. Ниндидер бер шомлы тынлык аларның эчләренә урнашкан кебек булды... Бала куркуыннан акрын гына калтырана башлады. Зариф аны үзенә кыса төште, һәм аңа икесенең дә йөрәкләре бергә типкән кебек тоелды.

Бераздан, бала елаган тавыш белән:

— Әни! — дип куйды.

Зариф акрын, сабыр тавыш белән:

— Елама, кызым, хәзер әниең янына барып җитәбез,—диде һәм үз тавышы үзенә баз эченнән килгәндәй тонык, саңгырау булып ишетелде.

Бала, Зарифка сыена төшеп, бер кулы белән аның муеныннан урап алды. Зариф, белмим баланы юатыр өчен, белмим үзенең эчке бер уеннан:

— Без кая барабыз? — дип сорап куйды.

— Әбиләргә кунакка,— диде бала җитди генә.

Зариф ихтыярсыз елмайды.

Шул арада алар юлның икегә аерылган җиренә килеп җиттеләр. Уңга аерылган юл белән рота китеп бара, сулдагысы исә якындагы станциягә илтергә тиеш. Биек һәм сирәк үскән наратлар арасыннан станция янындагы йортларның түбәләре дә күренә иде... Зариф хәзер чыннан да аптырашта калды. Нишләргә? Дөресен әйткәндә, ул һич туктамастан ротасын куып җитәргә тиеш. Ләкин кулында сыенып утырган бала аны ике юл чатында тукталырга мәҗбүр итте. Баланы ут эченә кадәр алып барырга мөмкин түгел. Ул соңгы өмет белән, хәтта чакырып, тирә-ягына каранды. Ләкин һичберкемнең килгәне яки китеп барганы күренми иде. Берничә секунд ул бөтен акылын җигеп уйланды. Хәтере ялгышмаса, аңа рота китеп барган юлдан бер тапкыр үтәргә дә туры килгән иде, һәм бу юл будка яныннан тимер юлны кисеп үтәргә тиеш кебек иде. Ул станция белән будка арасын эченнән исәпләп алды һәм балага күтәрелеп карады. Бала, Зарифның нәрсә уйлаганын сизенгән шикелле, зур булып ачылган күзләре белән аңа бик җитди карап тора. Бу караш Зарифның икеләнүен өзде; ул үз-үзенә катгый рәвештә: «Өлгерермен!» — диде һәм, баланы кулында ипли төшеп, йөгерә-йөгерә станциягә таба китеп барды.

Менә станциянең платформасы күренде. Аның алдында кызыл эшелон тора, ул хәзер кузгала булса кирәк —кешеләрнең ашыгып вагоннарга менүләре күренә.

Зариф станциягә килеп җитте, йөгереп платформага чыкты һәм тирә-ягына карарга өлгерә алмады, кара киемле ябык бер рус хатыны:

— Балам! — дип кычкырып, Зарифка ташланды.

Бала:

— Әнием! — дип, бөтен гәүдәсе белән хатынга сузылды, һәм Зариф баланың үз кулыннан киткәнен сизми дә калды.

Төнлә белән олы юлны немец бомбага тоткан вакытта баласын югалтып, соңыннан аны эзләп-эзләп тә таба алмаган ананың шушы минуттагы хәлен аңлатып бирү мөмкин булмас иде. Ул йөрәгенә сыеша алмаган шатлыгыннан сүзсез, бары ыңгырашып баласының кулларыннан, битеннән, чәченнән, күзләреннән үбәргә кереште.

Баланың кулыннан шикәре төшеп китте. Кемнәрдер алар янына җыела башлады.

Зариф баланы тапшыруга тирән итеп бер сулады, тирдән елтыраган маңгаен кулының сырты белән сыпырып куйды һәм ана белән баланың кавышу күренешенә бары соклану тулы караш кына ташлый алды. Бәлкем, шул секундта аның ана белән балага назлау сүзе әйтәсе, үзенең исә мактау һәм рәхмәт сүзе ишетәсе килгәндер. Ләкин ана беренче тетрәнүеннән айнырга өлгермәс борын ук, Зариф тимер юл буйлап йөгерә-йөгерә китеп тә барды.

Хатын, баласын күтәргән килеш, аның артыннан омтылып нәрсәдер кычкырды. Зариф артына карап бары кулын гына селкеде. Хәзер аның башында бер генә уй иде: ничек итеп ротаны тизрәк куып җитәргә, ничек итеп командиры алдына барып басарга һәм нәрсә дип әйтергә?

Менә алда тимер юл аша үтеп барган рота күренде. Зариф, мылтыгын иңеннән кулына алып, тагы да кызурак йөгерә башлады. Бәхеткә каршы, рота тимер юлдан ерак түгел бер агачлык ышыгына барып туктаган иде.

Ниһаять, Зариф килеп җитте. Аз гына читтәрәк папирос тартып торган, озын буйлы, чандыр гәүдәле командиры алдына барып басты, һәм кулын чигәсенә куеп:

— Иптәш лейтенант!..— диде дә, тынын ала алмыйча, туктап калды.

Командир, Зарифның тирләп кызарган йөзенә текәлеп карап:

— Иң элек тынычланыгыз! — диде.

Бу сабыр тавыш Зарифны чынлап та тынычландырган кебек булды. Ул тирән генә итеп бер сулап алганнан соң, сүзләрен артык бутамыйча, кайда һәм ни өчен юк булып торуын әйтеп бирде.

Командир шактый дәшми торды. Зариф менә хәзер каты шелтә алам дип селкенергә дә куркып тора иде. Ниһаять, командир, папиросын җиргә ташлап, итегенең очы белән аны озак кына изгәләде, аннан акрын тавыш белән сорап куйды:

— Баланы кемгә тапшырдыгыз?

— Әнисенә...

Шул минутта ротадан бер-ике йөз метр уңга, агачлар арасына, снаряд төшеп шартлады. Һавага төтен, туфрак, агач ботаклары күтәрелде. Командир икенче папирос чыгарып ашыкмыйча гына кабызды, соңра алдында һич кузгалмыйча басып торган Зарифка:

— Сез зур изгелек эшләгәнсез,— диде.— Моның өчен мин сезгә рәхмәт белдерәм!

Зариф гаҗәпләнүдән күзләрен йомгалап алды. Командир моны күрде булса кирәк, аның җитди чырае, таң шәүләсе төшкәндәй, яктырып, йомшарып киткән кебек булды.

— Мин әйткәнне аңладыгызмы?

Зариф, дулкынлануыннан иреннәрен кысып, башын гына селекте.

— Инде хәзер урыныгызга барыгыз! Ярты сәгатьтән соң рота, агачлыкны үтеп, ачык җиргә чыкты һәм, цепька таралып, алдагы ут позициясенә таба юнәлде.

Бу — чын сугыш кыры иде. Биредә үлем никадәр әрсез, рәхимсез булса, тереклек шулкадәр үз-үзенә ышанучан, бирешмәс, мәгърур була белә. Биредә кеше бер алмаз бөртегенә әйләнә. Ул, күзгә күренмәс дәрәҗәдә кечкенә булуына карамастан, олы алмазның бөтен сыйфатларын үзендә саклый. Ул каты... Һәм ул нурлар чагылдыра.

Зариф снаряд шартлавыннан йөгергән һава дулкынының йөзенә бәрелүен сизә. Ул колагы төбеннән чинап, сызгырып үткән һәр пуля турында уйлана; гүя, ул пуля тисә, бары тик чеметеп кенә алыр кебек.

Чыннан да, Зариф, беренче мәртәбә сугышка керүенә карамастан, үзендә аңлавы читен булган бер тынычлык тоя иде. Күңелендә аның кояшлы иртә тынычлыгы, хыялы исә шул иртәнең нурлы матурлыгы белән тулы. Менә ул ирексездән муенын сыпырып куйды. Гүя шунда баланың кул җылысы йогып калган иде.

1941

## Ана һәм кыз

Җәй башының шифалы яңгыры, тузанлы юллар өстеннән тыпырдап, җитез генә явып үтте... Иртәнге яшь кояш та таулар шикелле күкнең түренә сузылган кара-зәңгәр болытлар өстеннән ялтырап килеп чыкты. Аның яктылыгы шундый мул, нурларының түгелүе шундый дәртле, җитез иде, хәтта кояш үзе дә бу юмартлыгыннан тынычлыгын җуеп, урынында тик тора алмыйча тибрәнә һәм бер кечерәйгәндәй, бер

зурайгандай булып күренә иде. Аның әйләнәсендәге аксыл якты күк, алтын тузанында аунаган үтә күренмәле юка ефәкне кемнәрдер йөгерә-йөгерә җәйгән шикелле, һаман ачыла бара, һәм ераклашкан болытларның күкрәве аның өстен сыйпап, тигезләп үткәндәй тоела иде... Яңгырның соңгы тамчылары җиргә төшеп бетәргә өлгермәс борын, салават күпере дә калыкты. Аның бер башы тау итәгендәге сыек ак томанга төренгән иген кырына терәлгән, икенче башы, киң тугай аша дугаланып, Сакмар өстенә төшкән иде.

Рәхилә, ашыкмыйча гына килеп, урамга караган кечкенә тәрәзәне ачты. Өйнең бүрәнәләренә терәлеп үскән миләш агачының яфракларыннан берничә эре тамчы тәрәзә төбендәге гөлләр өстенә коелды. Бәбкә үләннәре өстендәге, энҗе бөртекләре шикелле, нур чәчрәтеп уйнаган тамчыларның яктылыгы, яңгыр исе белән аралашып, өй эченә иңгәндәй булды... Кинәт кергән һавадан өй түрендәге агач караватның ак чыбылдыгы җилфердәп куйды һәм аның эченнән хәлсез бер тавыш ишетелде:

— Кызым...

Рәхилә, тәрәзәдән борылып, агач караватянына килде һәм акрын тавыш белән:

— Нәрсә, әни? — диде.

— Чыбылдыкны күтәр... Менә шулай...

Чыбылдык эчендә, ике мендәр өстендә, үтә ябык авыру ана ята.

Ул кансыз юка иреннәре белән көчәнеп елмаерга тырышты, яртылаш ачык күзләрендә, әйтерсең кояшның бер бөртек нуры төште, аз гына җылылык белән елтыраган кебек булдылар. Ул, көрсенеп:

— Менә Алланың рәхмәтле яңгыры,— диде, һәм аның авыру күкрәгеннән сәламәт вакытындагы тавышы чыгып куйды.

Ана күптәннән каты авыру һәм ул бу урынга инде яңадан тормаска ятканлыгын яхшы белә. Ләкин тыныч җан белән үлемне көткән бу авыру анада соңгы сулышыннан аерылу минутын кичектерү теләге бик көчле: ул улын көтә. Бердәнбер улының фронттан кайтуын, менә шул кечкенә ишектән иелә төшеп керүен, елмаеп янына килүен, «Әни!» дип дәшүен күрергә тели иде. Бу гади сагыну гына түгел, бу — үзеннән соң каласы тормышның дәвамын күрергә тырышу, һәр тамчы каны белән йөрәге аша үткән ана мәхәббәтен соңгы тапкыр актыгына кадәр улына бирү теләге иде. Ул белә: ана белән ир бала арасындагы мәхәббәт бервакытта да андый ачыклык һәм юмартлык белән тышка чыга алмый. Әгәр менә ир булып җитешкән улы һәрвакыттагыча буйсынып башын игән, тартынып сүзсез торган оялчан кыяфәте белән каршында басып торса, ул бары бер сүз — «балам» дип үрелеп, аның маңгаеннан үбәр иде...

Ананың күңеленә шик киләме?.. Каты сугышның күп корбаннар алуын, кемнәрнеңдер газиз уллары, сөйгән ирләре, кадерле якыннары сугыш кырында торып калуын ул белә. Ләкин аңарда улын күрү ышанычы шундый көчле ки, һичбер нинди шик аның күңеленә кереп урын ала алмый иде. Гүя аның улы нинди генә хәтәр хәлләрдә калмасын, күпме генә ут эчендә йөрмәсен, барыбер исән-сау кайтачак. Бу — шулай, бу — көннең якты, төннең караңгы булуы кебек бәхәссез... Һичшиксез, аның газизе кайтыр, кайтырга тиеш!

Андагы бу ышаныч аның якыннарына да күчкән иде. Кызы Рәхилә, туганы белән төрле хәл булуын исендә тотса да, күңеле төбендә шактый тынычлык тоя. Бигрәк тә ана белән һәр көн туганы турында сөйләшү аның исән-сау кайтуын ничектер уйланусыз, пошынусыз көтәргә гадәтләндерде. Гүя ул фронттан, ут эченнән түгел, ә елдагы гадәте буенча күрше шәһәрдән, институттан каникулга кайтырга тиеш. Шулай да Рәхилә, уйланган минутларында бу гамьсезлекне сизеп, үз-үзеннән риза булмыйча, ихтыярсыздан тынычсызлана башлый иде.

Бүген июньнең егерме сигезенче көне... Туганы аның һәр елны шушы числоларда яки июль башларында институттан кайта торган иде. Әнисенең, туганнарының сөеп, сокланып карауларына каршы ул һаман бер сүз белән,—гүя аңардан шуны гына сорыйлар,— җавап кайтара иде:

— Әни, зачетларымны башкалардан элек биреп бетердем, сезнең янга кайтырга ашыктым.

Былтыр исә ул институтны тәмам бетереп кайтырга тиеш иде. Ләкин өйгә, туганнары янына шундый зур шатлыкның бәйрәмен бергәләп үткәрер өчен кайтасы вакытта, фронтка китеп барды. Ә өйдә аның бу кайтуын көтү әле һаман аларның йөрәкләрендә саклана. Һәрхәлдә, ана бүген, моны исенә төшереп, сүз кузгатмыйча калмас.

Кечкенә өй эче яңгыр белән юылып яшәргән көннең җылы яктылыгыннан киңәйгән кебек... Миләш агачының яфраклары аша төшкән кояш нурлары, өйнең идән-стеналарын эре-эре челтәрле бизәкләр белән чуарлап, тибрәнеп уйныйлар. Өстәлдәге графинның түгәрәк бөкесе, ачык шкафның тар шүрлегендәге киртләчләренә кыстырган балкашык башлары бу шаян, йөгерешкән нурларны үзләренә җыялар, һәм үзләре дә кечкенә кояшчык шикелле тирә-юньнәренә күз камаштыргыч яктылык чәчеп балкыйлар... Куе-җиңел, хуш исле һава, өй эченә берьюлы мул булып керергә теләгәндәй, тәрәзәнең читләренә җыелган ак пәрдәне күтәреп-күтәреп куя һәм һәрнәрсәне иркәләп, сыйпап йөргән кебек тоела.

Ананың бүген кәефе яхшы. Бу шифалы һаваны сулавы аңа җиңел, рәхәт; зәгыйфь тәнендә, никадәр хәлсезләнгәнен сиздереп, ниндидер бер җылымса талгынлык йөри.

Рәхилә, кул эшен алып, тәрәзә янына утырды. Ул авыру анасы белән үзе башлап сөйләшүдән тыела. Ул шулай әнисеннән читтәрәк, аерым бер нәрсә турында да артык уйланмыйча, сүзсез утырырга гадәтләнгән иде. Аның уйлары, аяз күктә өзек-өзек аккан вак болытлар шикелле, акрын, сиздермичә, шәүләсез агалар.

Өй эчендә нурлы тынлык... Ачык тәрәзәдән батыр шаулап зур кара корт килеп керде. Өй эче бер минутка аның көчле бызылдавы белән тулды. Ләкин кортка урын тар, кызыксыз күренде булса кирәк, өй эчен бер әйләнде дә кире ачык, иркен һавага чыгып очты. Өйдә янә тынлык урнашты.

Ниһаять, ана башлап дәште:

— Кызым!

— Нәрсә, әни?

— Хәсәнемнең соңгы хаты килгәнгә күпме булды инде?

Рәхилә аз гына уйланды:

— Хәзер, әни... Унында алган идек... ике атна тулып узды.

Ана көрсенеп куйды:

— Озак... нигә язмый икән?

— Ул яза булыр, тик хәзер бит почта озак йөри.

Ана дәшмәде. Ул сәламәт вакытындагыча айнык тере булып ачылган күзләре белән көн яктысына карап ята. Тәрәзәдән төшкән яктылыктан аеруча сары булып күренгән йөзендә аның җитди тынычлык һәм нәрсәдер хакында уйлануы сизелә. Гүя кәефе яхшы, акылы ачык вакытта таркау уйларын җыярга, әйтәсе сүзләрен хәтеренә төшерергә тырыша.

Менә ул кызына текәлеп карап алды һәм янә сабыр гына сүз башлады:

— Кызым, сиңа сүзем бар.

— Тыңлыйм, әни...

— Хәсәнемне күргәч, мин күп тормам.

— Әни, нигә алай дисең?.. Хәсән кайтуга син терелерсең...

— Юк, кызым... Хәсәнем кайтканчы торсам, бик шөкер инде. Тик менә куанычымнан әйтәсе сүзләремне онытырмын дип куркам.

— Әни, ул кайткач, без бергә-бергә бик озак торырбыз әле.

Ана хәлсез-ялкау гына елмаеп куйды. Бу елмаюда гүя яшь баланың уйланмыйча сөйләнүенә соклану һәм ул сүзләрнең чынлыктан никадәр ерак икәнен ачык белү сизелә иде. Ләкин кызының ихлас күңелдән юатуы аңа ошады булса кирәк — ул, җиңел генә көрсенеп:

— Кем белә, Ходай кушып, бәлкем, терелеп тә куярмын әле,— диде.— Шулай да, кызым, исемә төшкәндә кайбер сүзләремне әйтеп каласым килә.

— Тыңлыйм, әни.

Ана бер генә секунд дәшми торды. Кипкән иреннәре өстеннән теленең очын йөртеп алды. Соңра акрын гына, сүз араларында кыска-кыска гына тыныш ясап, сөйләргә кереште:

— Алты кыз баладан соң мин бер ир бала күрдем... Ул бик яшь иде әле, без өй эчебез белән ятим калдык. Әтиең, мәрхүм, аны күз алмасы кебек саклап үстерергә васыять әйтеп калдырды. Менә без аны барыбыз да бергәләп үстердек... Тәрбияләдек... Укыттык. Син, ул укысын, кеше булсын дип, йортның бөтен мәшәкатен үз өстеңә алдың, мине карар өчен шушы яшеңә кадәр иргә чыкмый тордың... Инде минем беренче васыятем шул, кызым: Хәсән балам бервакытта да апаларын-сеңелләрен онытмасын, мине якын күргән кебек, аларны якын итсен... Кулыннан килгән ярдәменнән ташламасын. Бигрәк тә сине туган анасы кебек күрсен, синең күрсәткән хезмәтләреңне бервакытта да онытмасын...

— Хәсән туган җанлы бала, әни... Ул тарафтан тыныч бул. Үзең беләсең, ул безнең өчен үлеп тора иде бит.

— Әйе, Хәсәнем әтисе мәрхүмгә охшаган. Әтиең мәрхүм бик ипле, бик йомшак күңелле кеше иде. Бервакытта да беркемгә дә авыр сүз әйтмәде. Беркем белән дә сүзгә килеп, бозылышып тормады. Әйтәсе юк, мәрхүм бик сабыр холыклы, чыдам кеше иде... Хәсәнемнең әле үз башына дөнья көтә башлаганы юк. Менә исән-сау кайтыр... эшли башлар...

Шушы минутта Рәхилә почта таратучы Маһирәнең тәрәзә каршысыннан үткәнен күреп калды. Әнисенең нәрсә сөйләгәнен онытып, үз-үзенә һич исәп бирмәстән, урыныннан торып, ашыга-ашыга ишеккә таба юнәлде. Гадәттә, тирләгән сипкел битле Маһирә, бу йортта бик көтелгән, килгән саен бик якты йөз белән каршы алынган кеше булганга күрә, туп-туры өйгә кереп, кычкырып исәнләшә һәм:

— Менә, Хәмидә җиңги, улыңның үз кулыннан алып китердем,— дип, алып килгән хатын ананың күкрәге өстенә куя иде.

Аның һәр килүе бу сагышлы моңсуга, авыру тынлыкка төренгән кечкенә өй өчен чын бәйрәм була иде. Һәм Рәхилә, Маһирәнең килгәнен күреп, бервакытта да каршы чыкмый, алдан ук дусларча елмаю белән, ишектән күзләрен алмыйча, кергәнен көтеп тора иде.

Бүген ул ни өчендер каршы чыкты.

Капкадан кереп өлгергән Маһирә Рәхиләне күрү белән:

— Әһә, Рәхилә апа, күңеле сизеп, көтеп торган икән,—дип, көр тавыш белән кычкырып куйды. Иске күн букчасыннан бер бәйләм хатлар чыгарды һәм алдан ук билгеләп куйган бер ак конвертны җитез генә алып Рәхиләгә сузды.

Рәхилә ак конвертны кулына алды, ләкин шунда ук кире бирәсе килеп куйды. Адресны язган кул һич таныш түгел һәм конверт бик юка иде. Ләкин шик юк: конверт аның исеменә иде. Ул, эчендә хаты барын белергә теләгәндәй, бармаклары белән капшап карады. Соңра ниндидер бер шомлы шикләнү белән ашыгып конвертны ачты. Конверт эченнән урталай бөкләгән кечкенә саргылт кәгазь чыкты. Аның сул почмагында бик үк ачык төшмәгән штамп иде.

Рәхилә бик тизлек белән — хәтта шундый тизлек белән, әйтерсең йөрәге тибүеннән туктап тора иде — кәгазьне укырга кереште:

«...нчы танковый полк штабы шушының белән сезгә хәбәр итә ки, танк йөртүче сержант Хәсән Гыйльметдин улы Ишаев 1942 елның бишенче июнендә Ватаныбыз өчен немец-фашистларга каршы каты сугышта батырларча һәлак булды. Күмелгән урыны Курск өлкәсе, Рельски районы Костровка авылы янында, туганнар каберендә...»

Рәхилә кәгазьне ахырына кадәр укый алмады, каты итеп сул кулына йомарлады һәм, кинәт кенә борылып, өй ишегенә таба китте. Куанычлы хәбәр килү шатлыгын уртаклашуны көтеп торган Маһирә Рәхиләнең болай кинәт борылып китүеннән аптырап калды һәм, артыннан кычкырып:

— Рәхилә апа, бәй, нигә бер сүз дә әйтмәдең, кемнән соң, Хәсәннәнме? — диде.

Рәхилә китеп барышлый, гүя Маһирәгә түгел, һавага ташлагандай, бары:

— Әйе,— дип кенә куйды.

Ул кемнәндер кача кебек иде. Маһирәнең: «Йә, нәрсәләр язган соң, тукта әле?» диюеннән котылыр өчен, тиз генә өйалдына кереп югалды. Инде өй ишегенең тоткасына тотынгач, ул ирексездән туктады. Өйгә, ана янына керү аның өчен шундый шомлы, шундый авыр, газаплы иде, әйтерсең ул хәзер менә баштүбән тирән бер бушлыкка егылырга тиеш. Ничектер кинәт бөтен тәне хәлсезләнгән, күз аллары караңгыланган кебек булды... Ләкин ул бернәрсә дә уйлый алмый иде әле, һәм аның кулы, «керергә кирәк» дигән карардан түгел, ә үзлегеннән ишекне ачты. Өйгә керүгә ул, ананың карашы белән очрашмас өчен туп-туры алдына карап, тәрәзә янына узды. Кызының кергәнен көтеп яткан ана тиз үк:

— Кем бар иде анда? — дип сорады.

— Мәрфуга җиңги. Иләк сорап кергән.

Ни өчен Рәхилә болай дип җавап бирде — ул һичбер вакытта да әйтеп бирә алмас. Әнисен алдау уе аның башына һич килгәне юк иде; бу шулкадәр көтелмәстән, уйламастан һәм шулкадәр табигый әйтелде ки, Рәхилә ихтыярсыз янә эченнән әле генә әйткән сүзләрен кабатлап куйды. Ана исә, хуҗа булып:

— Үткән бер алуларында ертып керткәннәр иде, әйтеп бирер идең,— диде.

Рәхилә дәшмәде. Әнисенең бу ялганны чынга алуы аны бер минутка ниндидер һәлакәттән коткарган кебек булды. Ләкин ул үзен һаман ялангач хәлдәге кеше сыман тоя, йөрәге аша өшү, калтырау йөри, һәм ана бер дикъкать белән караса, бөтенесен аңлар төсле... Чыннан да, Рәхилә баскан урыныннан кузгалырга курка, ул үз хәлен аңларга көчәнә, каядыр югалган уйлау куәтен табарга тырыша. Бәхетсезлек үзенең бөтен мәрхәмәтсез чынлыгы белән аның аңына барып җитмәгән кебек... Ул иң гади сорауларга җавап биреп маташа: «Хәсән үлгәнме?» — «Әйе, үлгән».— «Хәсән инде кайтмасмы?» —«Юк, кайтмас».— «Чынмы бу?.. Чынмы бу?..»

Сүзе бүленгән ана:

— Кызым, син мине тыңлыйсыңмы? — ди.

Бәлкем, бу аның икенче дәшүедер. Рәхилә күзләрен йома:

— Әйе, әни...

— Менә, кызым... Нәрсә әйтмәкче идем соң? Хәтерләрем бик таркау шул... Әйе, менә, Алла боерса, кайтыр... Эшкә керер... Укуын бетергәннән соң аның беренче башлап эшләве генә бит әле... Яшь, тәҗрибәсез... Кемнәр белән очрашмас, кемнәр белән бергә булмас... Кешенең төрлесе — яхшысы, яманы була... Шуңар күрә, кызым, ныгытып әйтеп каласым килә: берүк эшендә гадел була күрсен...

Һәм ана ашыкмыйча гына улының эштә, тормышта ничек булырга, үзен ничек тотарга тиешлеген сөйли. Рәхилә исә, кыймылдарга куркып, анасына кырын басып тора һәм күзләрен ачарга көче җитми. Менә Хәсән аның сул кулында... Юк! Хәсән үзе биредә шикелле... Рәхиләнең аңын бер секундка томан каплады һәм аның йомык күзләре алдына бик ачык булып туганы Хәсән килде: гүя ул шушы ак конвертны тотып ишектән килеп керде. Рәхиләнең колагына аяк тавышы, ишекнең ачылганы ишетелгән кебек булды... Туганы ни өчендер яланбаш... Ләкин ник бер үзгәрсен... нәкъ әүвәлгечә, ябык, нечкә озын буйлы... Тик йөзе генә, студент вакытына караганда, шактый олыгайган... киң маңгаена салгаланып кара чәче төшкән... Кечкенә күзләре куаныч белән елтырыйлар, ул тарсынып елмая, гүя кинәт, көтмәгәндә килеп керүеннән уңайсызлана төсле (ул шулай һәркайчан кызлар кебек оялчан иде)... Иреннәре аның кыймылдыйлар, ул нәрсәдер әйтә шикелле, тик тавышы ишетелми... Һәм менә кулындагы ак конвертны әнисенә суза...

Рәхилә куркынып күзләрен ачты, башын селкеп куйды, һәм аңына кайту белән башына килгән беренче уй «Ник элек әни үлеп, соңыннан бу хәбәр килмәде? Ни өчен бу гаделсезлек?» дигән уй булды.

Ул инде хәзер ананың сүзләрен тыңлый алмый, ул сүзләрнең һәртөрле мәгънәсе югалды, тик утлы күмергә акрын гына өргән җил шикелле, йөрәгенең чыдамаслык әрнүен генә үстерә, көчәйтә... Һәм Рәхилә зур булып ачылган күзләре белән тирә-юненә хәлсез ялварып карана. Ана исә һаман сүзен дәвам иттерә:

— Инде миннән соң, кызым, аның белән син каласың. Син аны карап үстердең, үзең аның белән бергә үстең. Сез бик дус идегез. Хәтереңдәме, ул, «Рәхилә апай!» дип, артыңнан калмыйча ияреп йөри иде... Инде, кызым, сиңа васыятем шул: бервакытта да аның белән араң бозылмасын, исемегез кешеләр теленә гайбәт булып кермәсен. Син олы була бел. Минем урынга каласың... Ана бул... Бервакытта да ярдәмеңнән, акыллы киңәшеңнән ташлама... Ул бик яшь бит әле... Син инде аңардан күзләреңне алма... Кызым, ник дәшмисең?

Рәхилә әнисенә таба атлады. Кинәт ул үзендә шундый хәлсезлек — әйтерсең тәненнән бөтен канын суырганнар — шундый бер хәлсезлек тойды... Тезләре акрын гына сыгыла кебек... Менә хәзер әнисенең аяклары өстенә ава, күкрәгеннән ярсу ычкына: «Ах, әни!» — ди, ләкин яшьләренә буыла һәм сүзсез генә, бөтен тәне белән калтыранып елый, елый да елый... «Ах, аңа үзе һәм әнисе шундый кызганыч, алар шундый бәхетсезләр, шундый ялгыз-бәхетсезләр...

Юк, Рәхилә аумады. Бу — берничә секунд башының томан эчендә йөзүе иде, бу — тау кебек газапның бик төптән күтәрелеп бугазга килүе иде. Рәхилә аны кире йота алды, ул турайды, ул тирән-тигез генә сулады, акрын-тыныч кына:

— Ярый, әни! — диде.

Һәм ана үз нәүбәтендә кызына ихтирам тулы күзләре белән карап:

— Рәхмәт, кызым, мин сиңа ышанам! — диде.

Алар арасында тынлык урнашты. Рәхилә, бу сүз бүленүдән файдаланып, тышка чыгарга ашыкты. Ул ананың Хәсән турында яңадан сөйли башлавыннан котылырга, аз гына вакыт ялгыз булырга, ичмасам, бер тулы итеп һава суларга кирәклекне тоя иде. Ләкин ул туп-туры чыгып китәсе урынга, әүвәл өстәл янына килеп, ни өчендер буш стаканны кулына алды, китә башлагач, яңадан борылып, аны кире урынына куйды, соңра ишеккә таба китте.

Ишектән чыгуга, ул чак кына апасы Хәлимә белән бәрелешмәде. Аның алдында җирдән калыккан шикелле, ашыгып килүдән кызарган, еш сулыш алудан күкрәкләре бер күтәрелеп, бер төшеп һәм бөтен тәненнән эссе бәреп торган апасы Хәлимә басып тора иде. Рәхилә, аның борчылулы сорау белән текәлгән күзләрен күрүгә, кулыннан тотып, үзеннән калдырмыйча, тизрәк йорт алдына алып чыкты.

— Син нәрсә, берәр нәрсә ишетеп килдеңме?

— Маһирә, хат бар, диде.

— Йә?

— Син хатны уку белән бик үзгәргәнсең. Маһирәгә бер сүз әйтмичә өйгә кереп киткәнсең...

Рәхилә каты итеп иреннәрен кысты.

Хәлимә аның кулын кинәт кенә тартып куйды:

— Йә, әллә миннән дә яшерер идегезме?

— Акрын, синнән беркем дә яшерми.

— Нигә әйтмисең соң, хат кемнән?

— Хат... фронттан.

— Хәсәннәнме?

— Апа, сабыр бул... Хәсән үлгән...

Хәлимә, чак ишетерлек итеп:

— Үлгән? — диде, артка таба ава башлаган кебек булды, ләкин кинәт әче кычкырып, бөтен гәүдәсе белән алга, ишеккә таба ташланды:

— Әнием, әнием...

Рәхилә стена булып Хәлимәнең алдына басты, кулы белән каты итеп иңбашыннан тотып алды һәм көч белән җиргә таба иде.

— Тукта...

Бу минутта Рәхиләнең туры гәүдәсе тагы да үсә төшкәндәй булды. Менә ул күкрәген алга таба чыгарып басып тора, һәм моңарчы күренмәгән ниндидер бер көч, мәрхәмәтсез усаллык булып, аның йөзенә калка. Йомыла төшкән күзләрендә хәтәр бер коры чаткы кабына... Ләкин бу һич таныш булмаган кыргый көчнең кинәт шундый олы булып тууы апасын бик үк куркытмасын өчен (бу хәле аның үзенә дә шомлы булып тоела), ул тыелырга тырыша, тик тыелу аңа зур авырлык белән бирелә. Ачулы тавышында эчке калтырану сизелә, ул акрын сөйләргә тырыша.

— Нишлисең син? Бер кайгы җитмәгәнме сиңа? Берьюлы ике кайгы булсын дисеңме, аз гына уйлыйсыңмы син? Әйтүең белән үтерер идең бит. Белмисеңмени, ул ишектән күзләрен алмыйча аны көтә? Юк, әни моны белергә тиеш түгел. Ишетәсеңме?..

Хәлимә Рәхиләнең кискен кушуына чарасыз буйсынды. Ул хәлсезләнеп бөгелде, башын кулларына салды, ничектер кечерәеп калды... Һәм, тәмам ихтыярын югалткан бала шикелле, үксеп-үксеп еларга кереште.

— Апа, җитәр дим, ишетәсеңме, җитәр дим.

Хәлимә тыела алмый, елавы һаман көчәя бара. Рәхилә, борчылып, тирә-юненә карана. Читән буйлап күрше хатынның чишмәдән менеп килгәнен күрә, тиз генә Хәлимәне иңбашыннан тотып, селкеп ала:

— Тукта дим. Әнә Сабира җиңги безгә таба килә. Яхшы түгел, тыела бел. Бала түгелсең бит.

Хәлимә тыелырга тырыша, йомарлаган кулын авызына куя, үксүен чыгармас өчен, бармакларын тешли... Алар икесе дә күрше хатынга аркалары белән борылып торалар. Тыныч, үзара сөйләшеп торалар кебек... Һәм күрше хатын, бу ике туганның шушы минутта башларыннан нәрсә кичергәннәрен һич белмәстән, акрын гына алар янынннан үтеп китә. Рәхилә белән Хәлимәгә исә аның якынлашуы, узуы һәм ераклашуы бер гомер булып тоела.

Күрше хатын ераклашуга, Рәхилә йомшак кына дәшә:

— Апа, бәгырем, бар, кайт.

Хәлимә, суларга һава җитмәгәндәй, башын күтәреп:

— Хәсән туганым, Хәсән туганым, син кайда? — ди һәм янә үкси башлый.

Рәхилә Хәлимәнең чәчләреннән сыйпый:

— Апа, бәгырем, чыдыйк, бик авыр булса да чыдыйк. Бер безнең башка гына төшкән хәсрәт түгел бу... Апа, бәгырем, тыңла мине, бар кайт, балаларың белән бул, аларны сөй, тынычлан.

Һәм, култыгыннан алып, ашыкмыйча, сакланып кына капкага таба илтә. Хәлимә буйсынып атлый, хәлсез башын Рәхиләнең иңбашына сала, елавыннан туктый.

Рәхилә Хәлимәне тынычландырыр өчен уйлап, ләкин үз-үзенә әйткәндәй:

— Сугыш бу...— ди.

Хәлимәне капкадан озату белән Рәхилә өйгә, әнисе янына ашыга... Өйдә тынлык. Өйдә җан иясе юк шикелле... Тик ачык тәрәзәләрнең ак пәрдәләре генә салмак җилфердәшә. Рәхилә сакланып кына агач караватянына килеп әнисенә карый. Ана йоклый. Ялгыз калган сабый бала шулай иркә, йомшак һаваның назлап сөюеннән йоклап китүчән була... Әйе, авыру ана бала тынычлыгы белән йоклый. Саргаеп кипкән кечкенә йөзендә аның —әйтерсең уйларын, газапларын ниндидер сихерле кул сыпырып алган — тыныч гамьсезлек.

Рәхилә, чебен кунып борчымасын өчен, акрын гына ак чыбылдыкны төшерә һәм аяк очы белән генә басып кире өйдән тышка чыга. Ишегалдының түренә узып, бакча рәшәткәсе буендагы яшел чирәмгә утыра.

Гаҗәп, Рәхилә үзендә елыйсы килү тоймый. Ә ул ялгыз калгач тыела алмам, елармын дип уйлаган иде. Бәлки кайчан да булса бер елар, һичшиксез елар... Ә хәзер... Юк, бик тырышып караса да елый алмас иде. Яшьләре аның эчендә кибеп бетте һәм күңелендә тыныч бушлык, аз гына моңсу тыныч бушлык урнашып калды. Әмма моңсу бушлык төбендә, кайдадыр бик тирәндә, кагылырга хәтәр сызлавыклы бер төер ята. Рәхимсез ачу-нәфрәт төере бу! Һич шик юк ки, Рәхилә менә шушы минутта бәдбәхет дошманны үз кулы белән рәхәтләнеп буар иде, буар иде һәм... җиңеләеп калыр иде. Сугыш бит бу, үлем өчен түгел, тормыш өчен сугыш!

Хәсән!.. Әйе, Рәхилә аны карап үстергән иде. Янә үстермәсмени? Әгәр үз баласы булмаса, апаларының, сеңелләренең балаларын карап үстерер. Бер Хәсән урынына ун Хәсән үстерер!

Юк, бу минутта кайгысы бик зур булса да, Рәхилә елый алмый... Кулы тойган җир, аркасыннан сөйгән кояш, күзләренә караган чәчәкләр тыныч булырга кушалар, сүзсез, бары үзләренең шушында, аның әйләнәсендә булулары белән юаталар. Чыннан да, Рәхилә салкын-тыныч. Тик чигәсендә аның әле үзе күреп өлгермәгән ике бөртек чал чәче елтырый...

1942

## Бер генә сәгатькә

Авылдан ике километр ераклыкта сөзәк сырт буйлап тимер юл үтә. Авыл очындагы Галимҗан абзый йортының тәрәзәсеннән карасаң, нәкъ каршыда карт юкә агачлары ышыгына яшеренгән кечкенә кызыл кирпеч станция бинасы һәм сарыга буяган кызыл түбәле җыйнак каралтылар күренә. Станциядән ике якка сузылган берничә рәт юллар кайчан буш була; тик теге яки бу тупиктагы ялгыз вагон, онытылып калган шикелле, моңаеп тора... Кайчак исә ул юлларга озын-озын эшелоннар килеп туктый. Күп вакытта вагоннарның ишекләре ачык була, һәм аннан кешеләр сикерешеп төшеп, арлы-бирле йөри башлыйлар. Кайвакытта исә, вагоннар ябык була һәм алар җепкә тезгән уенчык вагоннар төсле булып күренәләр: гүя, аларның кара тәгәрмәчләре бик юка, җиңел һәм чак җиргә тиеп, хәзер тәгәрәшеп китәргә торалар. Кара паровоз ерактан, чабыш айгыры шикелле, бик сылу, дәртле, кыю булып күренә һәм, пошкырган саен, һавага бер-бер артлы тезелешеп киткән кечкенә ак болытлар тарата.

Галимҗан абзыйның хатыны Мәрьям абыстай өйнең кечкенә тәрәзәсеннән шул күренешкә — карт юкәләр ышыгындагы тәбәнәк кызыл станциягә һәм аңардан ике якка сырт буйлап «көмеш дилбегә» төсле сузылып киткән юлга карап торырга ярата иде. Элек аның мондый гадәте юк иде. Ул ара-тирә авылның башка хатын-кызлары белән бергәләшеп станция каршысына йомырка, сөт, май алып бара, пассажирларга алып килгән нәрсәләрен татарча мактап-мактап сатарга тырыша һәм, тубалы, шешәләре бушап калса, күтәренке кәеф белән тизрәк өйгә, карты янына кайтырга ашыга иде. Кыскасы, станциягә, поездларга күптән ияләшкәнгә күрә, аларны бар дип тә белми һәм тәрәзәдән карап тору теләге бервакытта да күңеленә килми иде.

Инде сугыш башлангач, өч улы шул кечкенә станциядән, кызыл вагоннарга утырып, кояш батышына таба фронтка киттеләр. Мәрьям абыстайның исәбенчә, алар кайчан да булса шул ук юл белән, шундый ук вагоннарга утырып, шушы кечкенә станциягә кире кайтып төшәргә тиешләр иде. Һәм менә ул күңеле моңсу сагыш белән тулган яки бер дә сәбәпсез эче пошкан минутларда тәрәзәдән тимер юл буена карап торырга гадәтләнде. Күп вакыт станция буш була, бер яктан да поезд килгәне күренми. Мәрьям абыстай йөрәге төбеннән күтәрелергә маташкан өметсезләнүне басарга тырышып, акрын гына сулап, тәрәзәдән китә. Кайвакыт исә ул сырт буйлап станциягә таба килгән озын эшелонны күрә. Сырт өстеннән караган кояштан кечкенә кызыл вагоннарның зур кыек күләгәләре авыл ягына таба төшкән, һәм бу бер-берсеннән тигез яктылык белән аерылган кыек күләгәләр яшел чирәм өстеннән бик кызу куып баралар, ә рельслар буйлап җиңел кара тәгәрмәчләрдән калышмыйча чуар яктылык йөгерә. Менә күкрәген киерә төшеп барган паровозның кечкенә җиз трубасыннан кинәт ап-ак пар ишелеп-ишелеп һавага күтәрелә, аннан артка таба кызу гына йөзеп китә, поезд өстендә һавада чак сизелерлек вак кына якты дулкыннар тирбәнеп кала... Ә бераздан Мәрьям абыстайның колагына сузып кычкырткан гудок тавышы килеп ишетелә. Бу тавышны ул салкын кан белән тыңлый алмый, бу тавыш аның йөрәгенә төшә, һәм ул, сихерләнгән кеше шикелле, поездан күзләрен аера алмый. Ул аның станциягә килеп җитүен, вагоннарның тавышсыз, салмак кына бәрелешеп туктауларын, поездан кешеләрнең төшүен һәм авыл юлына кемнең дә булса килергә чыгуын көтеп, күзләренә җәелгән яшь томаны аша озак карап тора. Өч улының кайсысы булса да, кайчан да булса бер, килгән поездан төшеп, авыл юлына чыгар бит! Ул бит, шушы тәрәзәдән карап тора торгач, авылдашларыннан берничә кешенең фронттан кайтуларын беренче булып күргән дә иде.

Бүген исә Мәрьям абыстайның кәефе бигүк әйбәт түгел иде. Аның бөтен тәне авыраеп, башы томаланып тора һәм кул-аяклары хәлсез яналар. Ләкин ул, кәефе ничек булуына карамастан, иртә торырга гадәтләнгән. Карты белән килене Камилә кыр эшенә йөргәнгә күрә, ул һәр көн, алардан иртәрәк торып, үзләрен ашатып-эчертеп озату хәстәренә керешә. Камилә торып, су китереп, сыер савып кергәнче, аның казан асты ягылып, бәрәңгесе пешеп, самовары куелып өлгергән була. Бүген дә шулай, кәефе начар булуга карамастан, килене белән картының тышкы эшләрне бетереп керүләренә чәй урынын хәзерләп куйды. Өстәлдә җиз самовар үзалдына, бары үзе өчен генә моңланган шикелле, акрын гына шаулап утыра, олы табак белән китереп куйган бәрәңгедән, ашыйсы килүне котыртып, җылы бу күтәрелеп тора.

Менә Галимҗан абзый, кулларын угалап, өстәл артына кереп утырды. Бер олы кайнар бәрәңгене алып, мул итеп тозлап, авызын тутырып капты. Соңра кәефләнеп кысылган күзләре белән Мәрьям абыстайга карап:

— Карчык, нигә болай бик боексың? — диде.

Мәрьям абыстай икеләнеп җавап бирде:

— Әллә тагы, үзем дә белмим, башым авырта.

Галимҗан абзый карчыгының сүзләренә артык игътибар итмәде. Ул бары:

— Бирешәсең, карчык, бирешәсең! — дип кенә куйды.

Мәрьям абыстай картына дәшмәде. Ул үзендә картаеп өлгергән кешеләрдә еш була торган, сөлек шикелле бөтен хәлен суырган авыр бер бушлык тоя иде. Уй юк, бернинди сизү юк, тик күз кабакларын авырайткан гәүдәне һаман урынга сөйрәгән хәлсезлек кенә бар. Бу саңгырау хәлсезлек аның бөтен әгъзаларына, нindидер бер чирнең ашыкмыйча килүе төсле, акрын гына җәелә бара һәм колаклары эчпошыргыч бер тоныклык белән туктаусыз шаулап тора иде.

Карты белән киленен эшкә озаткач, Мәрьям абыстай иренеп кенә чәй урынын җыештырырга кереште. Килененең ун яшьлек кызы Зәйнәп кызу-кызу гына идәнне себерде дә каядыр чыгып йөгерде. Мәрьям абыстай ялгыз калды, һәм бу ялгызлык аңардагы авыр бушлыкны тагын да тирәнрәк, тагын да саңгыраурак иткән кебек булды. Аның бары урынга гына ятасы килә иде. Ул хәтта, гадәте буенча, тәрәзәгә барып, тимер юл буена карарга да иренде. Чәй урынын җыештырып бетүгә, мич буендагы сандык өстенә менеп, аркасын мичкә терәп, бөрешеп кенә ятты. Күпме-азмы ятканнан соң, ул йокыга талган кебек булды. Ләкин бу таза йокы түгел иде. Аның йомык күзләре алдында нindидер танырга мөмкин булмаган күренешләр һәм кешеләр томан эчендә, еракта йөзәләр, ә колакларында, бик ерактан ишетелгән буа тавышы шикелле, тонык кына гөжләү шаулый. Ләкин аның акылы тәмам оеган һәм сизгерлеге тәмам сүнгән иде.

Менә бервакытны аның колагына:

— Әни! — дигән тавыш ишетелде, ләкин аңына барып җитмәде, тик гәүдәсе генә сискәнеп куйды. Күпмедер вакыттан соң бу тавыш якында гына, нәкъ колагының төбендә, бик ачык булып ишетелде:

— Әни!

Мәрьям абыстайның бөтен тәне буйлап кискен калтырау йөгерде, нindидер бер саташулы төштән котылырга теләгәндәй, ихтыярсыз башын чайкап куйды һәм авырайган күз кабакларын ачты.

Аның өстенә иелеп, кече улы Гомәр елмаеп карап тора иде. Мәрьям абыстайның күзләрендә бер секундка саташулы курку кабынган кебек булды. Гомәр, һаман елмайган килеш, тыныч кына:

— Әни, курыкма, бу мин,— диде.

Мәрьям абыстай, терсәкләренә таянып, урыныннан күтәрелергә тырышты. Аның иреннәре кызу-кызу кыймылдый башлады: әллә ул шатлык авазы белән кычкырырга тели иде, әллә кызу гына пышылдап, берәр дога укымакчы иде. Тик ул чак ишетелерлек хәлсез тавыш белән бары:

— Улым, йа Алла, Гомәрем, синме бу?! — дип кенә әйтә алды.

Гомәр, әнисенең ике кулыннан йомшак кына алып, аны урыныннан торгызды:

— Мин инде, әни, мин. Әллә күзләрең начар күрәме?

Мәрьям абыстай, хәлсезлектәнме, әллә сүз таба алмау җәфасыннанмы, улына сыенып, акрын гына елый башлады.

Шул арада ишек бусагасында Зәйнәп күренде. Ул бер генә секундка тукталды һәм өй эчен яңгыратып:

— Абый! — дип бер кычкырды да яшен тизлеге белән ишектән кире тышка атылды.

Тын өйдә көтмәгәндә кыска гына яңгырап куйган Зәйнәп тавышы Мәрьям абыстайны, ниһаять, йокылы-уяулы хәлдән тәмам чыгарды. Аның бөтен авыру хәлсезлеге кинәт өстеннән коелып төшкән кебек булды. Ул, күзләрен сөртә-сөртә, берьюлы кайткан җан терелеге белән сөйләнә башлады:

— Менә рәхмәт яугыры! Төшемме бу дип торам. Поезд кычкырганын да ишетми калганмын лабаса.

Соңра ул нәрсәдер эшләргә кирәклекне кинәт исенә төшергән, ләкин тәгаен нинди эш икәнен ачык кына белмәгән кеше шикелле ашыгып ишеккә таба китте, кире борылып янә улына килде.

— Балам, утырыр идең, аякларың арыгандыр... Ходаем, этиең дә китеп өлгерде. Булмаса, артыннан барыйм әле. Колхоз ихатасында түгел микән.

Ул янә ишеккә таба китә башлады, ләкин Гомәр аны туктатты.

— Әни, син йөрмә. Зәйнәп мине күрде бит. Ул әти артыннан йөгерде булса кирәк.

— Шулаймы?! Ходаем, зиһеннәрем таралып китте. Төшемме дип торам. Үзем көтә идем бит, көтә идем, йөрәгем сизә иде. Йа Раббем, догаларымны бушка куймадың, инде Шакир белән Фатихымны гына күрәселәрем калды.

Шул арада тыштан кызу атлаган аяк тавышлары ишетелде һәм, ишек ачылып, Галимҗан абзый белән килене Камилә һәм Зәйнәп килеп керделәр.

Галимҗан абзыйның йөзе җыеп ала алмаслык тоташ бер елмаюга әйләнгән; ничек кенә тыныч булырга тырышмасын, аның да иреннәре агарган һәм акрын гына калтыраналар...

Ул, ике кулын сузып, каршысына күтәрелгән улына таба атлады.

— Улым, Гомәр!

— Саумы, әти!

— Бәрәкалла, бәрәкалла. Куаныч белән күрешер көннәр бар икән.

Камилә дә каенесе белән ике куллап күреште. Ул чак ишетелерлек итеп:

— Гомәр! — диде дә соңра: — Исән кешеләр бер кайталар! — дип үксеп елап та җибәрде.

Зәйнәп исә, янә: «Абыем!» — дип кычкырып, Гомәрнең муенына ташланды. Галимҗан абзый, артында торган урындыкка утырыр-утырмас кулларын күтәреп, битен сыйпагандай итте дә килененә карап йомшак кына:

— Килен, балам, елама! — диде.— Менә берсе кайтты, синеке дә кайтыр. Хәбәре юк-югын, ләкин бит әле еларга да сәбәбе юк. Сабыр бул! Улым, бөтенләйгәме?

— Юк, әти, вакытлы гына...

— Алай, бөтенләй үк түгел икән, ә! Һем-м, күпмегә соң?

— Мин бик азга.

— Шулай да ике айгамы, бер айгамы, күпмегә?

— Юк, әти... мин бик аз вакытка, бары бер генә сәгатькә!

Бу хәбәрнең тәэсире барысына да шундый булды ки, гүя ул Гомәрнең авызыннан чыкмады, ә кайдандыр, стена аша килгән ят, ямьсез бер тавыш булып ишетелде, һәм алар бу тавыштан ничектер барысы берьюлы кинәт катып калдылар. Галимҗан абзый улына кызганыч елмаю белән, ышанмыйча карый, Мәрьям абыстай исә, бөтенләй таңга калып, бернәрсә аңламаган кыяфәт белән, күзләрен зур ачып, улына текәлгән иде.

Гомәр хәлне төшендерергә ашыкты:

— Безнең эшелон станциядә, әти... Без госпитальдән фронтка китеп барабыз. Поезд бераз торасы булганга, мине менә сезнең белән күрешеп чыгар өчен бер генә сәгатькә җибәрделәр.

Галимҗан абзый, әйтергә сүз таба алмаган шикелле:

— Азрак, улым, азрак, азрак,— дип мыгырданып куйды. Соңра исенә төшкәндәй: — Син, Гомәр, булмаса, иртәгә икенче поезд белән китәрсең,— диде.

— Һич булмый, эти, мин үзебезнең поездга өлгерергә тиешмен!

Бу катгый сүзләрдән соң барысы да бераз вакыт нәрсә әйтергә дә белмичә аптырап тордылар. Алар шундый көтмәгәндә очрашу шатлыгы белән шундый тиз, кинәт аерылышу авырлыгын бер үк вакытта аңлау, тоюдан гаҗиз иделәр. Алар бу бер-берсе белән сыеша алмый торган ике капма-каршы хиснең кайсын чынга алырга, кайсына ышанырга, кайсысы белән бу минутта яшәргә кирәклекне белмиләр иде. Камилә үзе дә сизмәстән елавыннан туктады. Мәрьям абыстай яңадан хәлсезләнде, әлеге бушлык аны янә үз эченә йота башлады. Тик бары Зәйнәп кенә, бернинди китүне белергә дә, ишетергә дә теләмичә, үзенең яңгыравыклы тавышы белән:

— Юк, юк... Китмисең, абый, китмисең! — дип кычкырып, Гомәргә тагын да ныграк сыена төште, аның муенына нечкә беләкләре белән тагын да ныграк уралды.

Галимҗан абзый алдына, бер ноктага төбәлеп карап торганнан соң башын күтәрде, карчыгы белән килененә карап алды һәм тавышын күтәрә төшеп:

— Йә, нәрсә мәрткә киткән шикелле катып калдыгыз? — диде.— Кешенең минутлары санаулы... Килен, самоварыңны тизрәк өлгерт! Анасы, нәрсәң бар, хәзерлә!

Камилә каенатасының сүзеннән төртеп уяткандай сискәнеп куйды һәм уңган килен өлгерлеге белән, ике кулы түгел, дүрт кулы бар төсле, өй эчен бер итеп эшләргә кереште. Ул иң элек Зәйнәпне читкә чакырып алып, колагына нәрсәдер әйтеп, каядыр йөгертте. Соңра самоварны җилтерәтеп алып идәнгә куйды, су өстәп, коры чыралар белән ут салып җибәрде. Учак алдына кечкенә тимер таган белән таба куеп, аның астына ут якты. Чоланнан өч-дүрт савытны берьюлы күтәреп, май, күкәй, сөт алып керде. Кечкенә сандыгын ачып актарына, аннан ниндидер төеннәр, чүпрәкләр чыгара башлады.

Мәрьям абыстай да үзенчә нәрсәдер эшләргә тырыша иде. Ләкин ул, улыннан ерак китәргә курыккан шикелле, һаман өстәл тирәсендә әйләнә, яки кулына алган әйбере белән баскан урынында туктап кала, нәрсә эшләргә кирәклеген оныткан кебек, уйланып тора һәм, бер улына, бер картына карап, акрын тавыш белән:

— Ходаем, мунча да кереп өлгермәс микәнни! — ди.

Галимҗан абзый, башын селкеп:

— Эх, карчык, карчык! — ди һәм үзе торып чәй урынын хәзерләргә керешә.

Гомәргә әнисенең бу гаҗизлегенә карау бик авыр иде. Аның йөрәге әнисен кызганудан сызлана башлады һәм күңеленә ихтыярсыз: «Юкка үзләренә күрендем»,— дигән уй да килеп куйды. Ләкин ул күптән түгел генә нинди ашкыну, дулкынлану белән үзләренең станциясенә якынлашкан иде, ничек үтенеп командирыннан бер генә сәгатькә булса да авылга җибәрүен сораган иде, ничек ашыгып, тирләп-пешеп, йөгерә-атлый кайткан иде һәм хыялы кадерле күрешү минутларын уйлау белән тулы, йөрәге күпме шатлыклы хисләр татуны сизү белән бәхетле иде. Ул, әтиемне, әниемне, бөтен туганнарымны шатландырырмын, бәхетле итәрмен, дип уйлады. Хәзер исә бу шатлык уйный башларга өлгермәгән музыканың кинәт өзелеп ыңгырашуы кебек, бу бәхет елмаерга өлгермәгән кояшның кара болыт артына яшеренүе кебек иде. Бигрәк тә әнисенең зәгыйфь йөрәген шундый капма-каршы тойгылар утына салуда үзен гаепле дип белү аның өчен авыр иде. Шуңа күрә ул күңелендә булган янә бер кадерле теләген — яратып йөргән кызы Заһидәне күрәсе килүен этисе белән әнисенә сиздерүдән куркып утыра. «Заһидәне телгә алсам, бары аның өчен генә кайткан булып күренермен»,— дип уйлый иде ул. Тик җиңгәсенең Зәйнәпне чакырып алып, каядыр йөгертүе аңарда бер өметле сизенү тудырды. Уңган җиңгәсе яратышып йөргән егет белән кызны күрештерү чарасын, әлбәттә, күрергә тиеш иде.

Менә төрле хәбәрне һәркемнән элек ишетеп, һәр урында бөтенесеннән алда килеп өлгерүче авыл малайлары һәм кызлары ишек төбенә җыела башладылар. Кыюрак малайлар түргә узып:

— Исәнме, Гомәр абый! — дип кул биреп күрешәләр һәм, башка әйтер сүз тапмыйча, кире ишек төбенә китәләр. Анда алар арасында кызу бәхәс бара.

— Күрдегезме? Гомәр абыйның медале бар!

— Медаль түгел, орден ул.

— Орден сиңа, медаль! Медаль әнә шундый түгәрәк, ак була.

— Ә минем түгәрәк орден да күргәнем бар.

— Бар, пычагым.

— Ышанмасаң, Гомәр абыйның үзеннән сора.

— Кая тыгыласың, аякка бастың ич.

Мәрьям абыстай Гомәрнең кесәсеннән өстәлгә бушаткан шикәрен балаларга:

— Менә, балам, Гомәр абыегызның күчтәнәче! — дип өләшә башлады. Балалар сөенешеп елмаялар, ләкин шикәрне, оялган сыман, тартынып алалар, кыюсыз гына:

— Рәхмәт, түти! — дигән булалар һәм тизрәк учларына йомалар. Арттарак торган балалар кысылышып алга чыгарга тырышалар.

Мәрьям абыстайның шулай улым кайтты дип балаларны сөендерергә тырышуыннан Гомәр әнисенең үзенә булган мәхәббәтен аеруча бер тирәнлек белән сизеп алды һәм ана мәхәббәтен мондый тулылык белән сизү аның өчен кинәт бик авыр булды. Кайтып кергәч, беренче тапкыр диярлек ул күңеле нечкәрүен тойды һәм күзләренә килмәкче булган яшьләрен тыяр өчен, ашыгып, маңгаен ышкырга тотынды.

Менә Камилә кайнап чыккан самоварны җитез генә өстәлгә алып куйды. Өстәл өсте, кунак табыны шикелле, май, каймак, тәбә, Мәрьям абыстайның саклап тоткан балы, Камиләнең сандык төбеннән чыгарган прәннекләре, тәлинкә тутырып телгән икмәк һәм эреле-ваклы чынаяклар белән тулы иде. Гомәр, тансык аш итеп, катык та сорап алды.

Мәрьям абыстай һаман сыеның ярлы булуына өзгәләнә:

— Ичмасам, тавык та суеп өлгертә алмадык! — ди.

Галимҗан абзый шаяртып:

— Борчылма, карчык, хәзергә менә йомыркасын ашый торсын, икенче кайтып, боерган булса, тавыгыңны да ашап китәр,— дигән була һәм Гомәргә карап күз кысып куя.

Ахырда барысы да чәй эчәргә утырдылар. Гомәрне кыстау, аның ашау-эчүе турында сорашу белән җанлы сөйләшү башланды. Бу сөйләшү менә хәзер алда торган аерылышуны оныттырган кебек булды. Аларның табыны бәхетле гаиләнең кайчандыр менә шулай барысы бергәләп, гөрләшеп утырган чакларын хәтерләтеп җибәрде.

Гомәр фронтта башыннан кичергәннәрне кыска гына сөйләп алды. Мәрьям абыстай сугыш хикмәтләрен, улының күргәннәрен таңга калып, тагын да хәтәррәк нәрсәләр ишетеп куркырга торган кыяфәт белән тыңлый иде. Гомәр сакланып кына ничек, нинди шартларда яралануын сөйли башлагач, ул берничә тапкыр, үзалдына гына: «Йа Раббем, йа Раббем»,— дип куйды. Ахырда чыдамады, калтыранган тавыш белән:

— Әй улым, улым, ничек исән калгансың! — диде.

Гомәр, тыныч елмаеп, гади генә:

— Әни, менә үзең күрәсең ич, тап-тазамын! — ди. Галимҗан абзый да улының ашыкмыйча, сабыр гына сөйләвен, сүзләренә искитәрдәй төс бирмәвен һәм, һәрнәрсәнең асылын белгәндәй, һәркемгә туры карап, тыныч елмаюын күргәч: «Малай башка-а!» — дип уйлап куйды. Аның улы белән җитдирәк мәсьәлә турында сөйләшәсе килде һәм, сакалының очын бармаклары белән тибрәткәләп, салмак кына:

— Соң, улым, англичаннарның фронтта эшләре ничек бара? — диде.

Мәрьям абыстай картының бу сүзләрен ишетүгә кабынып китте:

— Тапкансың сорашыр нәрсә, әгелчәннәр, имеш. Нигә кирәк ул сиңа... Башка әйтеп калыр сүзең юкмыни?

— Тик кенә утыр әле син!

— Гомәр бит айлап торырга кайтмаган, ата кеше син, файдалы киңәшләреңне бирер идең.

— Мишәйт итмә дим мин сиңа! Гомәрнең безнең киңәш белән йөрисе калмаган.

Мәрьям абыстай рәнҗеп еламсырый башлый:

— Гомерем буена шул кирәксез сүзләре белән миңа аркылы төшеп җанымны кыйнады. Миңа улларым кадерле, минем җаным бары алар өчен генә көя. Фатихымның ике елдан бирле хәбәре юк. Шакирым хәзер кайда, исән-саумы? Шулар турында сораштырырга иде. Ә син, карт тиле, әгелчәннәр кайгысын кайгыртып утырасың.

Галимҗан абзый улына карап: «Менә аңламаган кеше белән нишлисең инде!» — дигәндәй, берничә тапкыр башын селкеп куйды.

Гомәргә әтисе белән әнисенең болай бәрелешеп алулары бик таныш иде. Галимҗан абзый, газета укыштыргалаганга күрә, халыкара хәлләр һәм тышкы сәясәт турында үзенчә фикер йөртергә, җай чыкканда шул хакта сөйләшеп алырга ярата. Мәрьям абыстай исә, чын ана буларак, гаиләнең эчке сәясәте турында гына уйланудан һәм балалары кайгысын гына кайгыртудан уза алмый. Элек укудан кайткан вакытларында да әтисе халыкара хәлләр турында, әнисе аның шәһәрдә ничек торуы, ашау-эчүе турында бер-берсен бүлгәләп сорашырга керешәләр һәм ахырда бер-берсе белән бәрелешмичә калмыйлар иде. Мондый вакытта Гомәргә һәр икесен дә канәгатьләндерерлек һәм килештерерлек сүз табарга кирәк була иде.

Хәзер дә ул шулай булырга тырышты:

— Әни, син юкка безнең өчен артык борчыласың. Мин менә исән-сау, бик азга булса да, сезне кайтып күрдем. Озакламый бөтенләй дә кайтырмын. Әти бит кайчан сугыш бетәр дә, кайчан барыбыз да җиңү шатлыгы белән өйләребезгә кайтырбыз дип сорамакчы була.

— Хак сүз, хак сүз!

— Союзниклардан рәт чыкмады, әти. Карга карганың күзен чукымый инде ул... Әле менә безнең армия немецларны пыр туздырып куарга тотынгач, күз буяр өчен генә дигәндәй, кыймылдый башлаган булдылар. Хәер, алардан башка да инде без Гитлерның муенына петляның тазасын салдык. Үзең беләсең, бу петля хәзер көннән-көн буыла бара!

— Шулаймы, бирсен Алла! Халык шул петляның тизрәк буылып бетүен көтә, улым, бик көтә. Аягына яңа баскан баланың да телендә хәзер бер генә сүз: кайчан сугыш бетәр икән, ди.

— Инде озак көтәсе калмагандыр, эти, менә күңел үзе озакламый бетәсен сизеп тора кебек... Әйе...

Гомәр кул сәгатенә карап ала.

— Миңа кузгалырга вакыт җиткән икән, эти, рөхсәт итегез...

Мәрьям абыстай сискәнеп куя:

— Ходаем, шулай бик тизмени?

Камилә ашыгып:

— Гомәр, тагын берне генә ясыйм әле,— ди һәм Гомәрнең чәшкәсенә үрелә.

Галимҗан абзый үзалдына әйткәндәй:

— Әйе, санаулы минутлар тиз үтә,— ди.

Гомәр урыныннан кузгала. Ул бу минутның барысы өчен дә никадәр газаплы, авыр булуын ачык күрә һәм юатыр өчен нәрсә генә әйтсә дә ясалма булып тоеласын яхшы сизә, ләкин әйтмичә булдыра алмый: тыштан ничек тә тынычлыгын сакларга тырышып, тик үзе дә сизмәстән тавышын күтәрә төшеп, әйтә:

— Бик зур рәхмәт сый-хөрмәтегезгә, әйе... Сезне бик сагынган идем, бик яхшы булып калды. Инде тиздән бөтенләй кайтуымны көтегез!

Мәрьям абыстай елый башлый:

— Газиз йөзләреңне күргән кебек тә булмадым.

— Әни, бәгырем, юкка...

Галимҗан абзыйның да йөзе караңгылана:

— Карчык, сабыр бул!

Нәкъ шушы минутта ишекне киң ачып, Мәрьям абыстайның агасының улы, былтыр фронттан агач аяк белән кайткан Шәрифулла килеп керә. Ул, кочагын ачып, туры Гомәргә таба бара:

— Һо, Гомәр, туганым! Кая, җанкисәгем, бер әп итеп күрешик әле! — Һәм Гомәрне кочаклап, ике яңагыннан да үбеп ала.— Молодец, молодец! Менә исән-сау кайткансың. Рәхмәт, туган! Ә миңа хәбәр итми торалар. Юк, мин әйтәм, каным коелган җирләрдән кайткан туганымны, төшкән килен шикелле, каршы алырга тиешмен. Шулай бит! Мәрьям түти, бәгырем, нигә елыйсың? Шатлык бит бу, бәйрәм бит бу!..

Мәрьям абыстайның яшьләре мөлдерәп коела. Ул сүзен чак әйтә ала:

— Әй Шәрифуллам, китә бит, китә!

Шәрифулла аптырап, ышанмыйча, Гомәргә карый.

Гомәр ни өчендер көчәнеп елмайган була.

— Шулай, Шәрифулла абый, безнең эшелон станциядә тора. Азрак булды, нишлисең...

Шәрифулла катгый рәвештә:

— Не смеешь, брат, не смеешь! — ди, чалбар кесәсеннән ярты баш аракы чыгарып, шап иттереп өстәлгә куя. Ул үзе, бераз эчеп алганга күрә, кызмача. — Без болай шаяруны яратмыйбыз. Кайткансың икән, торырга тиешсең. Точка!

— Шәрифулла абый...

— Юк, юк, ишетәсем дә килми. Әйдә, утыр! Син, брат, минем команданы тыңларга тиешсең! — Һәм чәшкәне тутырып аракы куя.

— Шәрифулла абый, син бит үзең армиядән кайткан кеше. Приказны үтәмәскә ярыймы?.. Менә миңа бер сәгать вакыт бирделәр. Бер сәгатьтән мин барып җитәргә тиеш. Бу минем өчен приказ.

Алар берничә секунд бер-берсенең күзләренә туры карап торалар. Ахырда Шәрифулла, уң кулын күтәреп:

— Да,— ди,— приказ — закон! Җизни, син аңлыйсыңмы, приказ — закон! Старшина Сәлимов дөрес әйтә. Ул китәргә тиеш! Ну, Гомәр, аякларың җиңел булсын! Яңадан әйләнеп кайтырга...

Чәшкә белән аракыны суза. Гомәр аракыны ала.

— Мин дә шулай дим, Шәрифулла абзый. Сугышкан кадәр сугышасы калмады. Менә күп тә үтмәс, әйләнеп чыккан кояш шикелле, яңадан кайтып килербез.

— Әйе, әйе, кайтасың, обязательно кайтасың! Мәрьям түти, бәгырем, мәрҗән яшьләреңне юкка түкмә! Кайтам, ди, ишетәсеңме, кайтам, ди.

Мәрьям абыстай сүзсез, акрын гына елавыннан тәмам кечерәеп кала. Яшьләре аның, ана йөрәгендә изге бер чишмә ачылган шикелле, туктаусыз агалар. Бу яшьләрдә газаплы хәсрәт ачысы юк, бу энҗедәй саф яшьләрдә тик ана мәхәббәтенең мәңге суынмас җылысы гына бар. Ашыгып Гомәрнең юл капчыгына оекбашлар, сөлге, яулыклар һәм азык-төлекләр салып йөргән Камилә дә үкси башлый, эшеннән бер генә минутка да туктамыйча йөри-йөри үкси. Галимҗан абзый, ихтыярын җигеп, тыныч-сабыр булырга тырыша, тик карлыга төшкән тавыш белән:

— Амин, Шәрифулла, амин! — ди.

Гомәр аракыны беткәнче эчеп куя.

— Әти, әни бәгырем, сез минем өчен артык янып көймәгез! Шәрифулла абый менә бик тиз аңлады. Сез дә аңларга тиеш. Мине фронт көтә. Гитлерның эшен бетерәсе бар.

Гитлер дигән сүзне ишетүгә Шәрифулланың күзләрендә хәтәр бер ут кабына:

— А, мин ул Гитлерны! Мин аны җан җиреннән кысып, бөтен дөньяга акыртыр идем! — Һәм алга сузган кулын, тешләрен шыкырдатып, шундый көч белән кыса ки, бу минутта кайдадыр Берлинда утырган Гитлер тынычлыгын җуеп, урындыгы өстендә шуышып куярга тиеш иде кебек.

Ишек төбендә балалар күбәя. Күрше хатын-кызлар җыела башлый. Күрешүчеләр, сорашучылар, Мәрьям абыстайны кызганып кайгыручылар һаман арта бара. Бу хәл Гомәрне шактый уңайсыз хәлгә куя. Ул соңга калудан чынлап курка башлый һәм тизрәк китәргә ашыга:

— Әти, сез мине озата барырсыз бит?

— Әйе, улым.

— Ә син, әни...

Мәрьям абыстай улының әйтеп бетергәнен көтмичә, балалар шикелле:

— Мин дә, мин дә,— ди һәм кинәт туган җанлану белән ашыгып киенә башлый.

Гомәр исә: «Ә син, әни, борчылып йөрмә инде»,— димәкче булган иде, дәшмәде.

Ахырда алар: юл капчыгын иңбашына асып Гомәр, иске эшләпәсен кырпу бүрегенә алыштырып кигән Галимҗан абзый, кара сатин тышлы билле бишмәтен киеп, кечкенә мамык шәлен беләгенә салып Мәрьям абыстай, Камилә килен, Шәрифулла тышка чыгалар.

Гомәрне бала-чагалар, хатын-кызлар һәм кайбер авыл агайлары урап алалар. Барысы белән дә бер үк вакытта исәнләшү һәм саубуллашу башлана. Гомәр хатын-кызларның уллары яки ирләре турында «очратмадыңмы?», «ишетмәдеңме?» кебек сорауларына кыска гына булса да тынычландырырлык җавап бирергә тырыша. Агайларның төрле яхшы теләкләрен, мактап әйткән сүзләрен игътибарсыз калдырмыйча тыңлый. Шул ук вакытта ул кешеләрнең башлары өстеннән тирә-ягына каранып кемнедер эзли. Ләкин ул юк, ул күренми...

Гомәр беренче тапкыр җиңгәсенә сорау белән карады. Камилә өзгәләнеп:

— Зәйнәпне йөгерткән идем бит. Нишләп һаман юк икән? Кырга ук китеп бардымы икәнни?! — диде.

Гомәргә җиңгәсенең бу кадәр аның өчен өзгәләнүе кызганыч иде. Ул, күрешер өчен ике кулын сузып, акрын гына:

— Җиңги, борчылма,— диде.— Бик зур рәхмәт сиңа... Күп итеп сәлам әйтерсең!

Соңра Шәрифулла абыйсы белән үбешеп күрешә һәм кискен генә борылып, иңбашындагы капчыгын рәтли-рәтли юлга таба атлый. Аның артыннан Галимҗан абзый һәм вак-вак кына кызу атлап Мәрьям абыстай, янә бала-чагалар иярәләр.

Авылдан чыгуга, алар артыннан колхоз председателе җибәргән җиңел тарантаска җигелгән туры ат килеп җитте. Кузлага председательнең ундүрт яшьлек улы Әдһәм утырган. Ул кызу юыртып килгән атны кинәт туктатып:

— Галимҗан абзый, утырыгыз! — диде.

Соңга калудан куркып, ләкин хәлсез әнисен кызганып, акрын барырга мәҗбүр булган Гомәр өчен бу атның көтмәгәндә куып җитүе бик урынлы булды. Ул әтисе белән әнисен тарантас түренә утыртып, үзе кузлага менеп артка карап утырды. Менә хәзер генә аның алдында туган авылы тоташы белән ачылды. Бер караш ташлау белән ул авылның бөтен тыкрыкларын, таныш өй түбәләрен, авыл каршындагы сөзәк тауны, тау астындагы вак куаклыклар арасыннан боргаланып, яшеренеп аккан кечкенә елгачыкны, аның чәчәкле тар тугаен һәм авылның ике очыннан башланып киткән тигез, киң иген кырын күреп алды. Аның өчен туган җирнең бу күренеше — йөргән юлларында күп очраткан, күреп күнегелгән гадәти генә бер күренеш иде. Ләкин җәй башының яшь, тансык, сөйкемле матурлыгы белән балкыган шушы тау битләре, шушы кырлар аңа атасы йорты кебек үк үтә таныш, аеруча якын иде. Ул бу җирләргә карау белән кайда нинди юл үткәнен, нинди сукмакларның кая алып баруын, кайда нинди чокыр, нинди куаклык, ничек дип аталган басу, печәнлек барлыгын бик ачык хәтеренә төшерде, күпме генә читтә йөрсә дә, аларны бервакытта да онытмаячагын аңлады, һәм аның күңеленә кешенең торып киткән җирләренә кайтып, йөргән эзләренә яңадан басып йөрүе үз гомерендә кабатлана торган нәрсә икән дигән уй килде. Янә үткәннең бер кадерле хатирәсе аның исенә төшмичә кала алмады. Әнә шул тау итәгендәге куаклар арасында, печән чапкан вакытларда, ул һәм Заһидә ничек бер-берсе белән очрашырга теләп йөриләр иде. Кызык, алар аулакта очрашкач бер-берсенә сер сынатмаска тырышалар, әйтергә дип күңелләрендә саклап йөрткән сүзләрен әйтә алмыйча, һич кирәге булмаган нәрсәләр турында сөйләшеп маташалар, инде Гомәр үзен тыя алмыйча кинәт Заһидәне ирексезләп үбәргә тырышса, бер-берсенә үпкәләшеп аерылыша торганнар иде. Ул вакытта алар, берсе икенчесенең йөрәгендә нәрсә ятканын бик яхшы сизеп торсалар да, бер-берсенә «сөям» дигән сүзне әйтә алмыйча калдылар. Тик Гомәр фронтка китеп, хат язышa башлагач кына, алар үзеннән-үзе туган кыюлык белән мәхәббәтләрен бер-берсенә ачканнар иде. Шуңа күрә дә «сөям» диюен язган хатларыннан гына укып белгән, ләкин ничек итеп, нинди караш, нинди тавыш белән бу сихри сүзне әйтүен ишетмәгән, инде минеке дип йөрәге белән тойган, ләкин үзенеке булуына күзләре

белән күреп ышанмаган Заһидәсен аның гаять күрәсе килә иде. Хәзер дә ул ераклаша барган авыл очына, Заһидә күренмәсме дип, һаман карый бара, ләкин юл буш, авылдан ашыгып килүче күренми иде.

Кызу юыртып барган туры ат тиз арада аларны станциягә китереп тә җиткерде. Тарантастан төшеп, алар платформага чыктылар. Станция каршында озын эшелон тора һәм аның алдында бик күп хәрби кешеләр арлы-бирле йөриләр.

Гомәр этисен-энисен ияртеп үз вагонына якынлашуга, аларны солдатлар сырып алдылар. Гомәрнең иптәшләре, Гомәр белән бик үз булуларын күрсәтергә тырышып, куштанланып, шул ук вакытта бераз көнләшкәндәй дә булып, сөйләнә башладылар:

— Черт возьми, Сәлимовка нинди бәхет чыкты!

— Безнең Сәлимов молодец ул! Бер уңайдан да файдаланмыйча калмый.

— Ничә әйтсәң дә — старшина! Уңган халык!

Бу сүзләрне алар, башлыча, үзләре дә уйламастан, Гомәрне этисе белән энисе күз алдында күтәрер өчен әйтәләр һәм халык уртасында бераз каушап, югалып калган карт белән карчыкка да шундый ук куштанлык күрсәтеп, якын итеп, ләкин ниндидер бер сөйкемле балаларча тәкәллеф белән кул биреп күрешәләр:

— Исәнмесез, дядька!

— Исәнмесез, бабушка!

— Улыгызны күреп бик шатлангансыздыр?

— Хәзер инде исән-сау бөтенләй кайтуын көтегез!

Гомумән, киң илнең төрле якларыннан җыелган һәм кайсыдыр шәһәрләрдә, авылларда шундый ук карт эти-әниләре калган бу солдатлар чал кергән түгәрәк кара сакаллы, таза бәдәнле Галимҗан абзый белән ак йөзле, кечкенә буйлы Мәрьям абыстайга олы кызыксыну һәм эчке уйчанлык белән карыйлар иде. Гүя алар да менә шулай эти-әниләре белән бәхетле күрешү минутларына ирешүне өмет итәләр һәм хәзерге минутта шул күрешүне күз алларына китереп, шуның сагынычлы куанычын тоеп торалар кебек. Гомәрне әйләндереп алган түгәрәк эченә, көтмәгәндә, юан гәүдәле, кыска муенлы, бик шома итеп кырынган түгәрәк битле бер майор килеп керде. Гомәр аны күрү белән корыч чыбык шикелле җитез тураеп, үкчәләрен бер-берсенә бәреп честь бирде. Майор көр тавыш белән русча:

— А, старшина Салимов, килеп җиткәнсез икән! —диде.

— Так точно, товарищ майор!

— Бик вакытлы... Ә, кадерле папаша белән мамаша да озата килгән икән! — Ул карт белән карчыкка ихтирам йөзеннән, ләкин тигез дәрәҗәле үз кеше булырга тырышып, кул биреп күрешә. Гади генә итеп: — Здравствуйте, папаша! Ну, как поживаем? — ди.

Галимҗан абзый дәрәҗәле кешенең бу игътибарына каршы тиешле ихтирам белән җавап бирә:

— Слау бух, товарищ!

Майор янә, улларын күрү куанычын уртаклашып, берничә җылы сүз әйтә, күрешүнең бик кыска вакытлы булуына тәәссеф белдерә.

— Ничава, товарищ, ничава,— ди моңа каршы Галимҗан абзый, сабыр гына.— Вайна бит, знаем!

Бу сүзләрне ишеткәч, майор, кашларын күтәрә биреп, чын соклану белән Галимҗан абзыйга беравык карап тора, аннан, дәртләнеп, сугышның тиздән бетәчәген, Совет Армиясенең дошманны һичшиксез тар-мар итәчәген сөйләп китә, бер уңайдан армиягә, Гомәр кебек, менә дигән егетләр үстереп биргән ата-аналарга рәхмәт тә әйтә һәм иң ахырда, бер авыз русча сүз белмәгән Мәрьям абыстай өчен генә булса кирәк, Гомәрнең аркасыннан кагып, үзенчә татарчалап:

— Улан якши, улан якши! — дип куя.

Мәрьям абыстайның күңеленә бу сүзләр аеруча ошады. Аның ана йөрәге улы турындагы һәрбер сүзне, улына булган һәрбер карашны ычкындырмыйча аулап тора иде. Сүзләр аның өчен аңлаешлы булмаса да, ул бу кешеләрнең нинди тавыш белән сөйләүләреннән, аларның күз карашларыннан Гомәргә булган дуслык, якынлыкны ачык сизә, күңеле аның бу кешеләргә карата рәхмәт белән тула, эченнән: «Иптәшләре, Ходайга шөкер, әйбәт кешеләр икән!» — ди һәм улының киләчәк гомере, саулыгы өчен тынычлану тоя.

Ахырда алар яныннан кызыл фуражкалы станция начальнигы үтеп китә. Бераздан паровоз, нечкә трубасыннан еш-еш ак пар чыгарып, дәртләнеп шаулый башлый. Менә эшелон буенча төрле урыннан: «Вагоннарга!» — дигән команда ишетелә. Гомәрләр тирәсенә җыелган солдатлар, ашыгып, вагоннарына таралалар. Поезд кузгалыр алдыннан аерылышуның иң соңгы минутлары, гадәттә, кешеләр өчен аеруча авыр була. Бу вакытта кешеләр сүзсез калалар һәм, аерылышуның никадәр газаплы булуын бөтен йөрәкләре белән сизсәләр дә, паровозның тизрәк кычкыртуын көтәләр. Гүя кеше, үз-үзенә исәп бирмәстән, тизрәк шул аерылышу газабыннан котылырга тели. Гомәр дә, Галимҗан абзый да, Мәрьям абыстай да, бер сихерле көч тарткан шикелле, алга, эшелон очына сүзсез карап торалар. Ниһаять, паровоз озын итеп кычкырта һәм, көч җыйгандай, бераз бик куәтле шаулап тора. Соңра поездны акрын гына урыныннан кузгата... Бирешмәскә тырышкан вагоннар сыкранышып рельслар өстеннән тәгәри башлыйлар. Кемдер вагон ишегеннән:

— Сәлимов, без киттек! — дип кычкыра.

Гомәр бу очрашу дәвамында беренче тапкыр бик җитди чырай белән:

— Йә, эти! — ди һәм этисенә ике кулын суза. Галимҗан абзый улының кулларын тота төшә.

— Хуш, улым! Алла хәтәр-хәвефләрдән үзеңне сакласын. Яңадан исән-сау күрешергә язсын! Хатларыңны еш яза тор.

Соңра Гомәр әнкәсенә карый. Ул, татар улларына хас тыйнаклык белән, бары күрешмәкче генә булган иде. Ләкин әнисенең шундый бер тирән газаплы мәхәббәт белән сүзсез караган яшь тулы күзләрен очраткач, ирексездән алга омтылып, аның кечкенә, җиңел гәүдәсен күкрәгенә кыса. Берничә секунд дәвамында ул нәкъ йөрәге турында әнисенең җылы сулышын тоя, аның хәлсез тавыш белән пышылдап күкрәге эченә әйткәндәй: «Улым, улым!» — диюен ишетеп кала, ләкин поезд тавышыннан башка сүзләрен аера алмый... Ниһаять, ул, әнисеннән сак кына аерылып, ераклашып барган вагон артыннан йөгерә. Иптәшләре, кул биреп, аны вагон эченә тартып алалар. Инде вагон ишегенең кырыена бөтен гәүдәсе белән туры басып артына караганда, аның йөзе гаепле сыман, кичерү сорагандай, елмая, кысылып караган күзләре дымланып ялтырыйлар төсле.

Поезд кызулый. Вагон тәгәрмәчләре рельс ялгаулары өстеннән тигез тавыш белән сугып үтүләрен ешлата баралар.

Мәрьям абыстай улының бөтен сыны күренеп барган вагон ишегенә йотлыгып карый. Ләкин аның күз аллары томанлана. Вагоннар, бер-берсе белән кушылып, бик кызу алга шуган тоташ бер кызыл стена булып күренә башлыйлар. Гомәр шул тоташ кызыллык эчендә югала. Ахырда бу кызыллык, сыегаеп, чуар бер шәүләгә әйләнә, һәм поезд кире артка таба чапкан шикелле була.

Авылдан станциягә таба йөгерә-йөгерә Заһидә белән Зәйнәп киләләр. Заһидә өстендәге җәйге пальтосының югары төймәләрен ычкындырган, башындагы ак яулыгын кулына алган... Аның кыска калын толымнары сүтелә төшеп, чәч бөртекләре җилдә очкалыйлар, кыр җиленнән һәм кояштан янып каралган киң маңгаена, борын очына тир бөртекләре чыккан.

Ул поездның киткәнен белә. Ул аның тавышын ишетте. Кызыл эшелонның сырт артына яшеренүен күрде. Гомәрне алып киткән поездның ак төтеннәре, вак болытлар булып, станция өстеннән акрын гына йөзеп үтәләр —ул шуларны да күреп бара. Ләкин бара, Гомәрнең китүен, аны күрми калуын бик яхшы белсә дә, юри тукталырга теләмичә, тыеласы килмәгән бер ярсу белән аскы иренен тешләп һаман бара. Бу баруда үз-үзенә хисап бирмичә, чынлык белән килешергә теләмәү тискәрелеге сизелә иде. Чыннан да, аның Гомәре шундый көтмәгәндә кайткан иде, аның Гомәре шундый тиз китеп тә барды. Ул, Заһидә, аны күрми дә калды. Болар бар да дөрес бит! Ләкин ни өчен дөрес?.. Ни өчен дөрес?

Менә аларга станциядән кайтып килгән туры ат очрады. Галимҗан абзый, кызларны күрүгә, атны туктатырга кушты. Зәйнәп йөгереп әбисе янына килде. Заһидә тарантастан шактый читтә туктады. Галимҗан абзый аңа карау белән кызның йөрәгендәниләр кайнаганын бик яхшы сизеп алды. Ул, йомшак тавыш белән ата булып, бары:

— Кызым, Заһидә, утыр безнең янга! — диде.

Заһидә әүвәл башын селкеп куйды, соңра кискен генә бары бер сүз ташлады:

— Кайтмыйм!

Галимҗан абзый артык сүз әйтүнең урынсыз икәнен белә иде. Ул кузладагы малайның аркасына акрын гына төртеп куйды:

— Әйдә, балам, кузгал!

Алар кузгалып киткәч, Заһидә янә бераз бара төшеп, юл буена чирәмгә утырды. Ул беркемгә үпкәләми дә, беркемгә ачуланмый да иде. Хәтта сөйгәне Гомәрне күрми калуның никадәр үкенечле булуы турында да юньләп уйламый иде. Ул бары йөрәге төбеннән күтәрелгән, бөтен тәне буйлап йөргән тиле ярсуны баса алмыйча газаплана. Ул янындагы үләннәрне йолкып-йолкып ала, аларны тешли яки калтыранган бармаклары белән бик вак итеп өзгәли. Янә ул һаман бугазына күтәрелгән төерне кире йота алмаудан гаҗиз иде. Ул тырыша, ачу белән башын селкеп куя, аскы иренен тешләп тора, ләкин юк — төер һаман бугазына килә. Ахырда ул башын кинәт тезләре өстенә сала һәм һичбер нинди тыелусыз, юка пальтосы аша түгәрәкләнеп, тыгызланып торган иңбашларын калтырата-калтырата, елап җибәрә.

Икенче көнне Галимҗан абзыйның йортында гадәттәге тормыш, үз ярлары эченә кайткан елга кебек, акрын гына ага башлады. Ләкин бу тыштан гына шулай иде. Асылда өй эче Гомәрнең күзгә күренмәс рухы белән тулы кебек, һәм кешеләр, көндәлек эшләрен эшләп, тыштан бернәрсә хакында уйланмыйча тыныч кына йөргән төсле күренсәләр дә, шул рухның әсирлегеннән чыкканнары юк иде. Аларның күңел күзләре алдында Гомәрнең җанлы кыяфәте һаман басып тора, башларыннан аның турында уйлау чыкмый, өйнең җиһазлары, Гомәрнең эзен үзләрендә саклаган кебек, аның булуын, аның кайда утыруын, нәрсәгә тотынуын искә төшереп торалар. Инде Гомәрнең өстәл өстендә онытылып калган портсигары барысына да, бигрәк тә Мәрьям абыстайга, бик серле мәгънәгә ия булган хикмәтле бер нәрсә булып күренә. Портсигар турында сүзләр күп була һәм аның онытылып калуын бөтен күрше-тирә белән Гомәрнең исән-сау әйләнеп кайтуына юрыйлар. Мәрьям абыстай һәркемгә бер тапкыр күрсәтеп чыкканнан соң, бу зат нәрсәне каядыр, һич кеше күзе төшмәслек җиргә яшереп куя.

Галимҗан абзыйның гадәтендә хыяллану булмаса да, ул да улы турында уйланудан туктамый иде. Гомәр аңарда, ике елдан артык вакыт эчендә бары бер генә сәгатькә күренеп китүенә карамастан, бик яхшы тәэсир калдырган иде. Ул аңа буе-сыны белән өлгереп җиткән, акылга утырган, холкы күркәм булып камилләшкән чын ир-егет булып күренде. Исән-сау кайтса, үзенә тиң торырлык, гаиләсенең яхшы исемен сакларлык, бәхетле тормыш төзи алырлык кеше булуына ышанасы килде. Шул уңай белән ул Заһидә турында да уйланып куйды.

Камилә килендә Гомәрнең кайтып күренүе сүнеп барган өметләрен яңадан тергезде. Ике елдан бирле хәбәре булмаган ире Фатих исән-саудыр төсле булып тоелды. Аның да шулай көтмәгәндә кайтып керүенә ышанасы килде, һәм Камилә ятса да, торса да, өзелеп сагынган Фатихын ничек каршы алуы, нинди сый-хөрмәт күрсәтүе, нинди назлар белән куштанланып сөюе турында уйлаудан тыела алмый иде.

Мәрьям абыстай исә, бичара, Гомәрнең һәр сүзен, һәр карашын, һәр хәрәкәтен күз алдыннан һич югалтмаска тырыша, улының җанлы кыяфәте тирәсендә әйләнеп йөргән шикелле, һаман аны тулырак беләсе, ачыграк итеп күрәсе килә. Шуңа күрә дә вакыт-вакыт Мәрьям абыстайга улы турында нәрсәнедер белми калгандай, нindидер сүзен хәтерләп бетермәгәндәй тоела. Ул Галимҗан абзыйдан сорашырга бераз шүрли, ләкин килене Камиләне бер дә тынычлыкта калдырмый. Һич көтмәгәндә ул:

— Килен балам, Гомәрем ничә чынаяк чәй эчте әле? —дип сорап куя.

Яки бераздан борчылып:

— Килен, Гомәрем катыкны яратып ашадымы икән? — ди.

Яки уйланып йөри-йөри дә:

— Килен, Гомәр нәрсә диде әле? — дип, Камилә һич хәтерләмәгән нәрсәне белергә тырышып азаплана.

Шулай да вакыты белән аның әрнеп эче поша башлый. Гүя Гомәр кайтмаган да һәм ул аны күрмәгән дә шикелле булып тоела. Мондый минутларда Мәрьям абыстай сүзсез уйчанлыкка төшә, хәлсез бушлык аны янә акрын гына йота башлаган кебек була. Шундый минутларның берсендә ул картыннан кыюсыз гына:

— Син, кичә Гомәрнең кайтуы төш идеме, әллә өн идеме? — дип сорый.

Галимҗан абзый карчыгына кызганып карый, ләкин йомшак кына елмая һәм дәртләндерергә теләгәндәй:

— Өн иде, карчык, өн иде! — дип кычкырып куя.

Мәрьям абыстай, юату ишеткән бала кебек, тынычлана. Ул, өй түре тәрәзәсенә барып, тимер юл буена карый. Менә аның каршында карт юкәләр ышыгына яшеренгән кызыл түбәле станция, сарыга буяган җыйнак каралтылар һәм станциядән ике якка сырт буйлап еракка, бик еракка сузылып киткән тимер юл... Станция буш... Көмеш дилбегә шикелле ялтырап яткан тимер юл тыныч... Авылның кырыеннан ук киң иген кыры башлана. Яшь, сылу арышларның салмак кына баш чайкавы, кара күләгәләрнең бер-берсен куып йөгерешүе шикелле, тимер юл аша үтеп, якты офыкка китеп югала. Күк аяз. Ерак кырлар түрендә күгелҗем сыек томан. Бу томан эчендә исәпсез күп энҗе тузаны йөзгән шикелле, җем-җем килеп, күзләрне кытыклап тибрәнә... Һәм күңел әнә шул нурлы томан артына китеп югалган яшел кырлар түреннән ерактагы поездның дәртле кычкыртып килеп чыгуын тоеп тора.

Мәрьям абыстайның иреннәре акрын гына кыймылдыйлар:

— Кайтыр күз нурым, кайтыр!

1944

## Ялгыз каз

Немецлардан азат ителгән бер авылда бер каз күрдек. Гаҗәпләнмәгез, тере каз иде. Башы соры, муены белән түше ак, канатлары янә соры — безнеңчә ала каз була. Җитмәсә үзе ана каз икән...

Әгәр безнең солдатлар Калинин урманнарында тәвә кошын очратсалар, бу кадәр гаҗәпләнмәсләр иде: меңләгән авылларны фашистлар коллыгыннан азат итеп, безнең беренче тере каз күрүебез иде. Шулай булды шул, Рәсәй казы немец илбасарларының ач аппетитларын котырткан майлы калҗа булды. Әйтерсең казлар өстенә үләт явы килде — аларны йөзләп-меңләп кырдылар, күп районнарда аларның нәселе дә калмады.

Шуңа күрә ниндидер могҗиза белән бу авылда сакланып калган бердәнбер ала каз безнең солдатларда зур кызыксыну тудырды. Барысы да аны бик тиз күреп алдылар. Һәркем, аз гына булса да тукталып, аңа сокланып карый торган иде. Олырак яшьтәге солдатлар исә, аның тирәсенә җыелып, тыныч тормыш турындагы истәлекләрен бер-берсенә сөйләргә яраталар иде.

Ала каз үзе дә акрынлап безнең солдатларга ияләште, тора-бара беркемнән курыкмас, качмас булды, ә кайберәүләр белән хәтта дуслашып та өлгерде... Соңра ул кинәт кенә безне ташлады, безне онытты, китте бездән...

Ничек булды соң бу?

Ала казның хуҗасы ялгыз торучы Маша исемле бер хатын иде. Машаның ире фронтта, ә җитеп килгән бердәнбер кызы шәһәрдә эштә иде. Машаның әнә шул ялгыз казыннан башка янә ике бәрәнле ак кәҗәсе һәм янып торган кып-кызыл мәһабәт әтәч җитәкчелегендә биш тавыгы да бар. Болар барысы да ялгыз Маша өчен йорт байлыгы гына булмыйча, аның күңелен юаткан гаилә дә иде. Алар арасында татулык зур, ә Машаның яратуы һәм кайгыртуы барысына да тигез төшә. Ләкин җәй көннәрендә бу гаиләгә гел генә бергә булырга, чүкердәшеп бергә вакыт үткәрергә туры килми. Һәр көн ак кәҗә ике бәрәнен ияртеп иртән иртүк көтүгә китә, аның артыннан Маша үзе, күршеләренә казы белән тавыкларын карый торырга кушып, кыр эшенә юнәлә. Биләмдә йөреп өйрәнгән кызыл әтәч тә тавыкларын ияртеп күбрәк урамда яки кеше абзарлары артында йөрергә ярата... Йортта бары ала каз гына кала. Ул көн буена ялгыз, һәм кичкә кадәр аның тавышы чыкмый. Йә ул ишек төбендә башын сыртына салып йоклап ята, йә йорт алдында бәбкә үләнен ялкау гына йолкып әрле-бирле йөренә, тагаракка салып калдырган суны килеп борыны белән шапырдатып ала, яисә кая барырга белмәгәндәй, бәрәңге бакчасына кереп китә дә, түтәлләр арасыннан муенын сузып, башын әле бер якка, әле икенче якка кырын салып, нәрсәдер көткәндәй, озак кына каранып тора.

Бу җәйге озын көндә берүзе калып вакытын үткәргән ялгыз каз нәрсәләр турында уйлый, күңелендә аның нинди моңсу, нинди сагыш ята? Кем әйтә алсын, аның кайгысын кемнең тыңлаганы бар? Әмма бичара казның ялгызлыктан эче бик поша булса кирәк, һәм бу бер дә гаҗәп түгел.

Менә яз килде. Дәртле кояш кытыклап уяткандай, табигать тирләп, көлеп күзен ачты. Бөтен җан ияләрендә эшлекле хәрәкәт, куанычлы ыгы-зыгы башланды. Җир өсте көннән-көн үсә, куера барган яшь үлән белән түшәлде һәм кояшка карап йөзләрен ачкан хуш исле нәфис чәчәкләр белән бизәлде. Ул чәчәкләргә, билен буган, аякларына сары итекләр кигән яшь кияүләр төсле, уңган чая бал кортлары килеп кундылар... Ак, сары, кызыл-чуар купшы күбәләкләр, туй вакытында яшь килен тирәсендә куштанланып йөргән кызлар шикелле, бал корты белән кавышкан чәчәк әйләнәсендә уйнаклап-талпынып очалар. Сылу сыерчыклар, назлы сандугачлар, иркә кәккүкләр, туйга чакырылган җырчылар кебек, су буендагы куе тирәкләрдә туктаусыз сайрап торалар. Җитез сабан тургайлары, такмаклап биюче егетләр сыман, нурлы һавадан төшмичә, сайрый-сайрый, сызгыра-сызгыра җилпенәләр.

Бу туйда берәү дә ялгыз түгел, һәр җан иясенең ише бар. Һәр җан иясе ана була, бала үстерә. Әнә кайбер кошлар инде симез кортларны сыртларыннан тешләп ояларында чыр-чу килгән зур авызлы, ялангач башлы чебиләренә ташыйлар. Менә Машаның ак кәҗәсе берьюлы ике бәрән китерде. Бәрәннәр, аяклары җиргә тияргә өлгермәс борын, ишегалдын бер итеп сикереп, чабып йөри башладылар. Карт кәҗә, «тапкач, баланың шундыен табарга кирәк!» дигәндәй, горурлы мактану белән дөньяга карый, тик масаеп сакалын гына сыйпап куймый. Әнә тавыкларның җыйнавына берәү булса да, үз-үзенә исе китеп йөргән тәкәббер әтәчләре бар. Ә ала каз ялгыз, аның үз ише юк. Ул күкәй дә сала, бала да чыгара алмый. Башкаларның бәхетле яшәүләрен, үзенең шундый аяныч хәлен сизгән казның эче пошмыймы соң? Һичшиксез, эче поша, йөрәге яна торгандыр.

Маша эштән кайткач, кичен, ишек төбенә утырып, кәҗәсен, тавыкларын янына җыеп ашата. Ала каз да шунда була. Тик ул сөйләнүдән бушамый. Әрсез тавыклар аның тирәсендә бәргәләнеп йөреп, бер-берсенең авызыннан өзеп орлык чүплиләр, ә ул һаман сөйләнә. Дәртсез тавыш белән, муенын җыерып, мескен булып сөйләнә, үзе әледән-әле килеп Машаның аякларына ышкына. Гүя ул озын көн буена ялгыз булуыннан, беркемнең дә аңа сүз катмавыннан, башкалар үз ишләре, балалары белән гамьсез чүкердәшеп вакыт үткәргәндә ул күңелсез авыр уйларга чумып, эч пошудан үзен кая куярга белмичә аптырап йөрүеннән, кыскасы, үзенең бәхетсезлегеннән зарлана.

Маша аңа кызганып карый, сөеп, юатып дәшә:

— Җитәр инде, юләр, җитәр! Ач каласың ич! — ди. Соңра итәгенә алып башыннан сыйпап сөя һәм кулыннан ашата башлый.

Әнә шулай ялгыз казның көннәре бертөсле генә үткән чакта, бу авылга безнең часть — фашистларны куып алып киткән фронт артыннан ияреп баручы аерым тәэминат ротасы кереп урнашты. Асылда сугыш үзе бу авылны читләтеп узган иде һәм немецлар киткәннән соң шактый вакыт узгач кына аның урамнары, халык тарафыннан зарыгып көтеп алынган безнең гаскәрләр белән тулып, җанланып китте.

Авылның кинәт болай бертөсле кешеләр белән тулып китүе — немецлар вакытында «идән асты» хәлендә яшәгән ала казда борчылулы кызыксыну тудырды. Ул, хәтәр бер эш көткәндәй башын кырын салып, җитди чырай белән үткән-сүткәннәргә карап тора башлады. Ләкин никадәр сак һәм җитди каранмасын, бу солдатлар кырык беренче елның җәендә авылга кинәт «хальд, валд, һау, һау» дип ямьсез, ят тавышлар белән кычкырып шаулап килеп кергән, муеннарына элгән кара саплы автоматларыннан тиктомалга уңга-сулга пуля сиптергән, кызарып бүртенгән чырайлы, акайган күзле солдатларга һич тә охшамыйлар иде. Бигрәк тә авыл кешеләре һәм хатын-кызлары теге вакытта ул солдатлардан котлары алынып качкан булсалар, хәзер бу солдатлар тирәсенә үзләре төркем-төркем булып җыелалар, сөйләшәләр, көлешәләр иде. Каз үзе дә, кайчандыр бик куркытылган булуына карамастан, ничектер йөрәге төбендә тынычлык тоя, гүя ул да кемнең кем булуын сизенә иде.

Машаның да өенә өч солдат урнашты. Аларның берсе итекче, икенчесе тегүче, өченчесе Иван-повар иде.

Ала каз ишек төбеннән китмичә бу өч солдатны җентекләп күзәтә башлады. Чамасыз озын, очлары орчык очыдай тырпаеп торган кара мыеклы итекче кечкенә өстәле, күн төпле урындыгы, калыплары һәм бер бәйләм иске ботинкалары белән чоланга урнашты. Урнашу белән ул үзенең эшенә кереште. Авызын тутырып вак кадаклар каба да, чүкеч белән шуларны берәмләп ботинка төбенә кага башлый. Какканда авызын әле бер якка, әле икенче якка кыйшайта һәм кара мыегының очлары әле бер колагына, әле икенче колагына тия язып кала... Ул бер дә күтәрелеп карамый һәм бер-ике тапкыр тартып беткән тәмәке төпчеген сүндермичә казның аркасына да ташлады. Тик бер генә кат башын күтәреп:

— Что, гусак?! — дип куйды.

Итекче казга ошамады.

Тегүче дә әллә нинди сәер кеше иде. Ул күзлеген киеп ала да, бөкрәя төшеп, аягы белән бер машинаны әйләндерә башлый. Әйләндерә-әйләндерә, ә машина һич урыныннан кузгалып китә алмый. Аның да бу «мәгънәсез» тырышуын карап тору каз өчен кызык түгел иде.

Иван-повар исә бөтенләй башка тәэсир калдырды. Менә ул — киң, таза гәүдәле, янып торган шома битле —ак калпак, ак алъяпкычтан җитез атлап ишектән килеп чыкты. Чыгу белән казны күреп алды һәм туктала биреп:

— Эхи, каз! — диде, соңра бөтен бите белән җәелеп елмаеп: — Исәнмесез, иркәм! — дип дәште.

Ала каз да, җавап биргәндәй, кыска гына:

—Ког! — дип куйды.

Алар бер-берсенә беренче караштан ук ошадылар. Повар казга сокланып, каз исә поварга ышанып карый. Менә повар казны муеныннан йомшак кына тотып күтәрә һәм:

— Җиңелсең, иркәм, җиңелсең, яхшылап ашатасы бар үзеңне,— ди.

Каз, поварны аңлагандай, җанланып сөйләнә башлый.

— Кый, кый, ког, ког! — ди һәм Машага назланып өйрәнгән гадәте буенча поварның аяклары арасыннан бер-ике тапкыр ышкылып үтә.

Шулай итеп, алар дуслашып та китәләр.

Безнең часть бу авылда озак торасы булганга күрә, Машаның бәрәңге бакчасы артына, ачык җиргә тактадан җәйге кухня ясадылар.

Иван-повар көн дә иртә белән кухняга киткәндә, ала каз да аның артыннан ияреп бара. Үз тиңе белән бергә баргандай, ава-түнә атлап, туктаусыз сөйләнеп бара. Хис белән сөйли кебек, акрын сөйләгәндә муенын җыера, тавышын күтәргәндә муенын да бөтен озынлыгына сузып җибәрә. Иван, дустына игътибарсыз булып күренмәс өчен:

— Ә, шулаймыни? Кара син аны! Дөрес лыгырдыйсың, дөрес! — дигән була.

Кухняга килгәч, ул аңа калган ботканы такта өстенә салып бирә, каяндыр табылган немец каскасына су да салып куя. Каз ботканы ашый, суны эчә, ә аннан тамагы туеп хушлангач, яшел чирәм уртасына чүгәләп, борынын канаты астына тыгып, озак кына йоклап та ала. Торгач, поварның барлыгын белергә теләгәндәй, кухня ишеге төбенә килеп карый. Шуннан соң кухняның хуҗасы сыман муенын сузып, кырын-кырын каранып әрле-бирле йөренә башлый. Аның файдасы да тими түгел — бер генә этне дә ул кухняга якын җибәрми.

Аш өләшкән вакытларда исә ул котелок күтәреп килүче солдатларны башын текә тотып, дәртләнеп кычкырып каршы ала.

— Кыйгак, кыйгак! — ди. Үзенчә «рәхим итегез!» диме инде,— белмим!..

Солдатлар да җавапсыз калмыйлар, еракган ук көлешеп дәшәләр:

— Ә, повариха иптәш, аш өлгердеме?

— Йә, бүген нәрсә белән безне сыйлыйсыз?

— Менә син булыша башлаганнан бирле аш бик тәмле булып китте бит әле!

Ә кайбер шаяннары:

— Иван, син моның башына ак калпак кидерер идең! — диләр.

Кайчак исә каз тирәсенә солдатлар җыелалар. Иван-повар да кухня эссесеннән тирләп-пешеп, аз гына һава алырга дип чыккан була. Ул түгәрәк уртасына басып, казга карап үзенең поварлык осталыгы турында кәефләнеп сөйли башлый:

— Мин,— ди,— элек ресторанда эшләгәндә кош итләреннән иң нәфис, иң затлы ашлар әзерли идем. Әйтик, кыздырылган күркә яки җимеш белән тутырган тавык бик шәп булып чыга иде. Ә менә бу сары аякның ите инде, үзегез беләсез, иң мактаулы симез итләрдән санала. Әйтик, мичтә пешерелгән әче кәбестә белән, никадәр симез булса да, җиңел ашала. Янә, мае агып торган койрык төбе изгән бәрәңге боламыгы белән, керәнләп бик шәп төшә... Нәрсә, дөрес түгелме әллә, чекерәеп карап торасың?!

Чыннан да каз, башын кырын сала биреп, Иван-поварга һәм аның кулындагы зур, үткен кухня пычагына бик дикъкать белән карап тора. Гүя ул поварның нәрсә турында сөйләвен төшенә кебек, ләкин аңарда повар кулындагы зур пычактан һәм аның менә хәзер керәнләп ашардай булып сөйләнүеннән курку

сизелми. Каз үзенең дөньяга нәрсә өчен яратылуын белә төсле һәм шул ук вакытта хәзер үк йолкынып мичкә кермәсенә дә нык ышана. Ул поварның мактавын раслагандай:

— Ког! — дип куя.

Повар:

— Ә шулаймы, дөрес әйтәмме? — ди һәм казның борыныннан тотып ала. Каз артка тартылып ычкына, аннан муенын сузып, батыраеп, кыйкылдап поварга һөҗүм итә. Повар кулларын бутап казның муеныннан эләктерергә тырыша, ләкин аның муены елан җитезлеге белән боргалана, бер озыная, бер кыскара, поварның әле бер ботыннан, әле икенче ботыннан эләктереп, борып ала. Ахырда повар каршы тора алмыйча кача башлый, каз исә аның артыннан кухняга кадәр куып китә... Солдатлар рәхәтләнеп, шаулап көлешеп калалар.

Соңра алар кич белән бергәләп өйгә кайталар. Көн буе бергә эшләп арыган ике дус шикелле, повар кулларын артка куеп, каз салмак кына ава-түнә атлап сүзсез генә кайталар.

Шулай итеп, безнең солдатлар аларны һәрвакыт икесен бергә күрергә өйрәнделәр.

Озын фронт юлында кайчан шулай берәр хайван (күбесенчә этләр, яки хуҗасыз калган кәҗә, тай кебек йорт хайваны да) хәрби частька ияләшеп, ияреп китүчән була. Чөнки солдат җан иясен фронтта башка һичбер җирдә яратмаган шикелле ярата, һәм хайван үзе дә моны сизә булса кирәк; шуның өстенә ул солдатлар тирәсендә һәрвакыт тук булып йөри. Табигый инде, ялгыз каз да, һәрбер солдаттан иркәләп карау, яратып дәшү сизеп торганга күрә, шулай безгә бик нык ияләште. Ала каз чыннан да бик үзгәрде, элекке кебек буш калган өй тирәсендә көн буена ялгыз моңаеп, бер җанлы тавыш ишетергә һәм сүз кайтарырга мохтаҗ булып йөрми инде. Аңа дәрт керде, ул көрәеп, матурланып китте.

Ләкин көннәрдән беркөнне ала каз поварга иярмәде, кухняга бармыйча өйдә калды. Бу хәл поварны шактый гаҗәпләндерде. Иртәнге ашны өләшкәннән соң, ул кызыксынып, өйгә кайтып килде. Ала каз исән-сау һәм элеккечә өй ишеге төбендә ялгызы басып тора иде. Повар аны чакырып карады, бераз үпкәләп, шелтәләп тә алды, ләкин каз аның сүзләренә һич колак салмады; ул ни өчендер тын һәм уйчан иде.

Ул көнне кухняга килгән солдатлар да казның юклыгыннан аптырап калдылар, һәркайсы повардан:

— Иван, озын муенлы ярдәмчең кайда? — дип сорый торган булдылар.

Иван-повар ала казның кинәт болай үзгәреп китүен берничек тә төшендерә алмады. Ә казның болай үзгәрүенә бик җитди бер сәбәп бар иде ул да булса, мич артыннан вакыт-вакыт ишетелеп куйган нечкә бер таныш тавыш иде. Бу шундый җанга якын тансык тавыш казның йөрәгенә төште, ул берьюлы бу тавыш белән сихерләнде һәм дөньясын онытып, ишек төбеннән беркая китмичә, бары шул нечкә тавышның ишетелүен генә көтеп тора торган булды.

Маша төшке ашка кайткач, мич артына кереп, нәрсәдер актарына башлады. Мич артыннан чыр-чу иткән нечкә тавышлар һәм бу тавышларны басып берәүнең «кор-кор» диюе ишетелде.

Каз бичара «инде ни күрәм!» дип тын алырга да куркып тора иде.

Менә берзаман мич артыннан озак вакыт ояда утырып чырае агарган кара тавык яман кабарынып, Машаның аяк тирәсендә әйләнә-әйләнә, «кор, кор» дия-дия килеп чыкты. Машаның алъяпкычында тавыкның чебиләре иде. Ул аларны йорт алдына чыгарып, яшел чирәмгә җибәрде.

Ләкин каз ни күзе белән күрсен, яшел чирәмдә тавык чебиләре түгел, ә каз бәбкәләре иде. Менә алар биш бәбкә нечкә тәпиләренә чак басып, әле алга, әле артка таба чайкалып торалар. Алар шундый кечкенәләр, борыннары үтә күренерлек шундый юка һәм якты сарылар, түп-түгәрәк башларының ике ягында, тамызып куйган ике сумала тамчысыдай, кара күзләре елтырыйлар, ә канатлары шундый кечкенәләр, әйтерсең юри генә ябыштырып куйганнар. Алар барысы да йомшак сары мамыктан гына әвәләп ясалган кебекләр һәм аз гына җил исте исә хәзер очып китәрләр төсле... Алар көн яктысына карый алмыйча башларын боргалаган булалар, нечкә генә тавыш белән:

— Ти, ти, ти, пип, пип! — диешәләр.

Бу күренештән ала каз тәмам таңга калды. Ул бәбкәләргә карап бөтен барлыгы белән йотылган, һич айный алмаслык булып сихерләнгән иде. Бичараның йөрәгендә бу могҗизалы күренештән нинди хисләр уянды икән? Ничек итеп, нинди хәрәкәт, нинди тавыш белән ул аны белгертә алсын! Әгәр каз кеше кебек булса иде, һичшиксез, бу минутта аның ике күзеннән сөенеч яшьләре мөлдерәп агып киткән булыр иде.

Каз түгел, без дә бу эшкә гаҗәпләндек. Дөрес, тавык астында каз бәбкәсе чыгарып булуын без белә идек, ләкин менә каз йомыркаларын Маша кайдан алган — монысы безнең өчен табышмак иде. Бөтен районга берүзе торып калган ала казның чебиләнерлек йомырка салып бирүе мөмкин түгел, чыннан да каян табылган ул йомыркалар? Иван-повар — ярый әле ул каз турындагы бөтен хәбәрне белеп тора — аш өләшкәндә безгә бу хәлнең серен сөйләп бирде. Шулай, яз башында немецлардан азат ителгән авылларына кире кайтып баручы бер эшелон колхозчылар якындагы станция аша үткәннәр. Йорт-җирләреннән аерылып торуга карамастан, аларның үзләре белән бергә саклап алып кайтып килгән мал-туарлары да, кош-кортлары да булган икән. Уңган Маша менә шулардан каз йомыркаларын алып та калган инде. Машаның бәхетеннән, йомыркалар барысы да яраклы булып, әнә кара тавык утыра торгач, һәркайсыннан берәр бәбкә дә дөньяга борынлап чыкты.

Инде ала каз шул бәбкәләрне күргән көннән алып Иван-поварны да, кухняны да, безнең барыбызны да ташлады, ничектер безне күрмәс һәм сизмәс булды.

Ул көннәр буена бәбкәле кара тавык тирәсендә әйләнеп йөри башлады. Тавык бәбкәләрне уяу саклый, казны түгел, тавыклардан берсен-бер якын җибәрми. Һаман кабарынып, туктаусыз коркылдап, тирә-ягына ялт-йолт каранып кына тора. Шуңа күрә каз читләтеп кенә карап йөрергә мәҗбүр, әмма үзе тавыкның бәбкәләргә чын ана булмавын сизенә булса кирәк... Чыннан да, тавык бәбкәләрне су буена илтми, рәхәтләнеп йөздерми, чумып уйнарга, башлары белән суга кадалып, койрыкларын текә күтәреп торырга өйрәтми, ә үлән йолкып ашарга өйрәтәсе урында җир тибеп, җыен юк-бар нәрсә чүпләргә кыстап маташа. Юкка гына бәбкәләр зәгыйфь, аңгыра булып үсмиләр. Казның моңа бик эче поша, ахрысы — кайчак ул үлән йолыккалап, бәбкәләрне үз янына чакырып карый. Ләкин бәбкәләр ишеткәнче, кара тавык зәһәрләнеп килеп җитә. Бәлкем каз юньсез тавыкка кирәген биргән дә булыр иде, тик бәбкәләр хакына ул чигенә.

Вакыт үтә. Ничек кенә булмасын, бәбкәләр үсәләр. Менә аларның сары мамыклары агара башлады, койрыклары очына нечкә генә каурыйлар чыкты, муеннары да шактый озыная төште. Алар инде тавыкның канаты астына сыймыйлар, таралышып яталар, йөргәндә дә һаман тавыктан читтә, үз башларына йөриләр. Тавык үзе дә элеккечә бәбкәләр тирәсендә яныл-көйгән ана булган булып йөрми инде. Ул хәзер артык кабарынып та, туктаусыз коркылдап та маташмый. Тик шунда үзалдына тибенеп, бәбкәләр кая китсәләр, шулар артыннан ияреп йөргән була.

Ә беркөнне исә барыбыз да менә мондый гаҗәп бер вакыйга ишеттек: Маша иртә белән торып тышка чыкса, ала каз да, бәбкәләр дә юк ди... Кара тавык үзе гомердә бәбкәләре булмагандай кызыл әтәч янында куштанланып йөри, имеш. Маша, билгеле, курка кала. «Ах, урлаганнар икән, казларымнан яздым!» дип уйлый, ләкин шулай да ашыгып эзләргә тотына.

Менә бервакытны елга буена эзләп барса, ни күзе белән күрсен, ала каз биш бәбкәне ияртеп, су уртасында акрын гына әрле-бирле йөзеп йөри, имеш. Башын текә күтәргән ди, әйләнә-тирәсенә гаҗәп җитди чырай белән масаеп карана ди, әйтерсең дөньяның шаһы булган, шундый горурлык ди үзендә... Машаның чакыруын колагына да элми икән, бары тик су эченнән сап-сары булып күренгән сыңар тәпиен генә селтәп куя ди.

Ничек бу хәл булган — тавык үзе бәбкәләрне ташлап киткәнме, яки туктаусыз күзәтеп йөргән каз ахырда чыдый алмыйча аларны булдыксыз ана кулыннан тартып алганмы — әйтүе читен. Һәрхәлдә, үсеп килгән ап-ак кына каз бәбкәләренең кара тавык белән һаман ишегалдында, һаман тирес өемнәре тирәсендә пычранып йөрүләрен күрү кызыксыз иде; инде алар ала казга ияреп су буена төшеп киткәч, табигатьнең кечкенә бер хатасы төзәлгән кебек булды.

Төш вакытында ала каз беренче тапкыр су күргән юеш бәбкәләрен ияртеп йортка кайтты. Аны күрергә дип барыбыз да җыелыштык... Ябыштырып куйган шикелле урыннарыннан купмый торган күзлекле тегүче белән кара мыеклы итекче дә чыкканнар иде. Хәтта, кухняда кызу эш вакыты булуга карамастан, аш чүмечен күтәреп Иван-повар да чабып килеп җитте.

Чыннан да, ала каз танымаслык булып үзгәреп өлгергән иде. Кая ул элекке шикелле һәркем белән үз булып, яхшатланып маташу! Муенын җирдән күтәрми, әле берәүгә, әле икенчегә сузылып:

— Ыссс, ыссс! — дип кенә тора.

Тик Маша белән Иван-поварны гына бәбкәләренә якын җибәрде... Иван-повар куанычыннан чыдый алмыйча:

— Әй, җан дускаем, семьялы булдыңмыни?! — дип кычкырып, җитез генә казны ике кулы белән күтәреп алды да баш түбәсеннән үбеп куйды. Каз да җиргә төшкәнче поварның борын очына төртеп алырга өлгерде. Бу тамашадан бәбкәләр дә бик яман шаулашып алдылар: янәсе, ала каз алар өчен хәзер чит түгел һәм аның белән болай шаяруны яратмыйлар.

Озак карап торганнан соң итекче дә, ниһаять, мыегын уңга-сулга сыпырып, бер бик мәгънәле сүз әйтеп ташлады:

— Мин,— ди,— моны ата каз дип торам, ул, хәерсез, ана каз икән ләбаса!..

. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .

Шулай итеп, немецлар явыннан япа-ялгыз торып калган ала каз, Иван-повар әйтмешли, семьялы булып алды. Әгәр ала казның гомере булса, киләсе язга инде үзе йомырка салыр, үзе утырып бала чыгарыр. Машага байлык, ә аңа бер көтү бәбкәле, тигез бәхетле тормыш килер.

Хәзер исә без торган урамга яңа ямь керде. Айлы тын төндә урам чирәмендә бәбкәләрен тирәсенә җыеп ала каз утыра. Берәр кешенең якынлашкан аяк тавышын ишетүгә ул башын күтәреп тавыш бирә башлый. Йоклап яткан бәбкәләр дә борыннарын җылы канат асларыннан чыгармыйча гына «пипелдәшеп» куялар... Аяк тавышлары тына, урам янә көмеш нурлы тынлыкка чума һәм каз тавышлары үтеп китүчене азат ителгән авылда яңадан туып килгән тормышның җанлы сулышы, куанычлы авазы кебек озатып кала.

1944

## Мәк чәчәге

*(Нәсер)*

Киң авызлы тирән бомба чокырының төбендә үсеп утырган ялгыз мәк чәчәге, чокыр кырыена килеп туктаган узгынчы бер солдатка карап, шулай сүз башлады:

— Кеше, сәлам сезгә! Ерактан киләсез шикелле, арыганга охшыйсыз, аякларыгызда тузан, битегез тирләгән, утырып ял итегез, булмаса... Менә шулай! Сез минем әрсезлегемне кичерегез! Бик күптән инде кеше заты күргәнем юк, һаман ялгызым, һаман ялгызым! Ичмасам, янымда берәр үләнчек булса иде!.. Сез күрәсез: мин бер чокыр төбендә утырам, әйләнәмдә, биек тау булып, коры ком өелеп ята. Чокырдан югары анда, тирә-юньдә нәрсә бар, нинди чәчәкләр үсә, нинди кошлар оча, нинди кортлар үрмәләп йөри, юллардан кемнәр үтеп китә — мин берсен дә күрмим. Тик кайвакыт минем янга берәр коңгыз гына тәгәрәп төшә. Ялангач җансыз чокырдан ул бөтенләй куркып кала, күрәсең; бичара, озак тырыша торгач, үрмәләп чыгып китә. Кайчак исә берәр бака, комны ишә-ишә, яныма төшеп азаплана. Ләкин кызу, коры чокыр төбендә дым юклыгын сизгәч, тизрәк кире борылып, чыгып китү ягын карый... Мин аларның да әллә нидә бер күренеп калуларына шатмын. Торган җирем никадәр буш, җансыз булса да, ерак түгел тере сулышлы тормыш барын сизеп торам. Рәхмәт күбәләкләргә!.. Ара-тирә аларның берәрсе яныма төшеп, әйләнәмдә бизәкле канатлары белән җилпенеп очына, йомшак гәүдәсе белән сакланып кына өстемә куна, хуш исле мыеклары белән йөземне кытыклап, назлап китә... Ләкин мондый кадерле кунаклар яныма килгән, яки сөекле дусларым белән кавышкан көннәрем минем бик сирәк була. Гадәттә исә менә шулай беркемсез... Әйе, мин ялгыз! Минем баш өстемдә еракта, бик еракта нурлы күк... Көннәр буена мин шул чиксез, тын күккә карап торам. Һәр таң белән мин кояшның чыкканын көтеп алам, бары аңарга гына карап, аның артыннан гына ияреп мин көннәремне үткәрәм. Ул да миңа гына карый, минем өчен генә балкый кебек... Инде баер алдыннан әнә шул ком өеме артына яшеренгәч, аның соңгы нурлары минем куе кызыл йөземдә тын гына уйнап, акрын гына сүнәләр. Гүя төнгә каршы аерылышу алдыннан мине юатып китәләр. Ләкин мондый җылы рәхәтлек, тыныч куаныч белән тулы көннәр минем өчен гел генә булып тормый... Вакыт-вакыт нурлы күк йөзен ишелеп аккан болытлар каплап ала, авыр, салмак гөрелдәп күкләр күкри, кара-зәңгәр болытларны телгәләп үткән яшен туктаусыз яшьнәп тора һәм, иртә-кичләрен туктамастан, өзлексез яңгыр ява... Мин ышык урынымда башымны иеп кенә утырам. Дөнья буш кебек... Тик кайдандыр, якыннан гына очып үткән юеш карганың авыр гына селеккән канат тавышы ишетелеп кала. Менә шулай үтә минем көннәрем. Сез тагын бу юләр тормышыннан зарлана дип уйлый күрмәгез! Һич юк! Мин бит тере! Ничек мин тере булуымнан зарланыйм ди! Бәлки, сезне минем үсеп утырган урыным гаҗәпләндерә торгандыр?

— Кем бу мәкне чокыр төбенә төшереп утырткан? —дип уйлыйсыздыр.

Ләкин яхшылап тирә-ягыгызга карагыз! Нәрсә күрәсез? Коточкыч хәрабәләр! Бөтен әйләнә-тирәдә котырып үскән алабута, кычыткан, әрекмән, шайтан таяклары... Шулар арасында ватык кирпеч өемнәре, кара кисәүләр, ялгыз моңаеп утырган морҗалар, савыт-саба ватыклары, кием сәләмәләре, китап битләре, тагын әллә ниләр, әллә ниләр... Әгәр чынлап эзләсәгез, сез бу урында балалар имезлеге дә табар идегез... Менә болар барысы да бу җир өстеннән үткән шомлы дәһшәтнең эзләре!.. Сез беләсез инде: бу шомлы дәһшәт, бу рәхимсез явызлык безнең җир өстенә көнбатыштан килде.

Әйе, бу җирдә кечкенә генә, җыйнак кына бер дача-авыл иде. Без — мәк чәчәкләре, гөлчәчәкләр, исле сиреньнәр, шомыртлар, алмагачлар, кура җиләкләре, чияләр,— аның ямьле бизәкләре, аның тәмле җимешләре идек. Менә бу чокыр урынында исә без, мәк чәчәкләре, кайчандыр зур түгәрәк бер түтәл булып үсеп утыра идек... Безнең нәкъ уртабызга ул,— көнбатыштан килгән ерткыч вәхши,— авыр бомба ташлады. Без янартау авызыннан атылган утлы туфрак һәм көл булып һавага ыргытылдык. Бу күз ачып йомганчы булды... Соңра төтен һәм тузан таралды. Тетрәп киткәндәй күренгән кояш та яңадан, бернәрсә дә булмагандай, балкый иде. Мин инде аны яңа урынымнан күрдем, башка бернәрсә дә күрмәдем һәм күрергә мөмкин дә түгел иде... Бомбаның ватыклары, бәлкем, җиргә коелып бетәргә өлгермәгәндер, мин —бердәнбер мәк орлыгы — кире үз урыныма, менә шушы чокыр төбенә очып төшкәнмен. Мин тере, мин яңадан җир куенында, үземнең туып-үскән урынымда!.. Ком бөртекләре каты дип тормадым мин, суларга дымы юк дип зарланмадым мин — бүрттем, шыттым, тамыр җибәрдем. Ә хәзер күрәсез: сылу бер чәчәк булып үсеп утырам! Безнең иркә зәгыйфь мәкләрнең дә нәселен корыта алмадылар алар...

Кызганыч хәшәрәтләр!

Кеше, нигә сез шулкадәр миңа сокланып карыйсыз? Мине оялтасыз... Яшерә алмыйм, сезнең карашыгыз шулкадәр тансык миңа... Сезнең әнә шунда, югарыда басып торуыгызга да әйтеп бетергесез шат идем. Ә сез, иренмичә, минем яныма төштегез. Менә өстемә иелдегез, менә калтыранган олы кулларыгыз белән сакланып кына мине тотып карыйсыз! А, Кеше, рәхмәт сезгә, рәхмәт!.. Ком өстендә калган эзләрегез минем өчен миһербанлы үтүченең җылы тыны белән йөземә сулаганын һәрвакыт исемә төшереп торган иң кадерле эзләрдән булыр. Моннан соң мин бер кояшка, бер сезнең эзләрегезгә карармын. Чәчәгемнең һәр яфракчыгы белән сезгә исәнлек, сезнең туган илегезгә, гөлбакчаларга кайтуыгызны иртә-кичләрен тели торырмын. Сез белсәгез иде: без, чәчәкләр, кешеләрне ничек сөя, ничек алар янында булырга ярата идек! Кайчандыр, ак пәрдәләр җилфердәшкән тәрәзәләр эченнән яңгыраган дәртле тавышларын, шат көлүләрен, моңлы җырларын сөенә-сөенә тыңлый идек. Сылу кызларның ак куллары белән безне өзеп алып, дәртләнеп тибрәнгән күкрәкләренә кадаганда без ничек бәхетле була

идек! Шат балаларның бәйрәмнәрдә, мәк сипкән ак булкалар күтәреп, бакча сукмакларында чабышып йөрүләренә сокланып караудан туймый идек... Әйе, әйе, мин ышанам, мин тормышның мәңге бетмәве, чәчәкләрнең кешеләрдән бервакытта да аерылмавы белән бәхетлемен, мин ялгызлыгымнан һич тә зарланмыйм!

— Кеше, сез китәргә җыенасыз! Сездән аерылып калу авыр миңа... Сез кичерегез мине... Бу тик вакытлы гына... Әйе, сез барыгыз! Хәерле юл сезгә! Ерак юлларыгызны җиңел үтегез!.. Сез көнбатышка таба барасыз! Сезне анда канлы сугышлар көтә булыр, һәр адымыгызны, бәлки, үлек гәүдәләр, кара кисәүләр аша атлап үтәргә туры килер. Ләкин мин — дөньяның матурлыгыннан туймаган, һаман да аны матур итәргә теләгән ялгыз мәк — сезнең һәр үткән адымыгыз артыннан чәчәкләр үсеп калуын телəр идем... Көл һәм каннан яралган чәчәкләрнең рәхмәте сезне мәңгелек дан һәм бәхеткә илтсен! Хуш, Кеше, хуш! Ак юл сезгә!

1944

# Кунакчыл дошман

...Тын, буш юл. Әмма күпме вакытка ул буш, күпме вакытка ул тын? Ике көн буена бу юл һәм моның кебек бик күп юллар өстендә, мәхшәр купкандай, ут, төтен, тузан уйнап торды. Коточкыч дәһшәт урынына әверелде, җан өзгеч фаҗигаләр мәйданы булып китте бу якты офыкларга сузылган җәйге ямьле юллар!

Ләкин никадәр генә куркыныч, хәтәр булмасын, алар ахырда шушы олы юлга чыгарга тәвәккәлләделәр. Чыкмыйча мөмкин түгел иде, болай да өч көн буена кырлар уртасыннан юлсыз-нисез, сай үзәнлекләр буйлап кача-поса килделәр. Инде җитәр, артык түзәр хәлләре калмады, бу билгесезлекнең бер чиге булырга тиештер, ниһаять!

Тузанлы таш юл өстенә килеп чыккач, алар, туктап, сүзсез генә юлның көнбатыш очына бераз карап тордылар. Аннан берсе пилоткасының эче белән тирләгән битен сөртте, икенчесе, җиргә тезләнеп, ботинка бавын рәтләде, өченчесе кесәсеннән тәмәке янчыгын чыгарган иде, ләкин чишә башлаган җиреннән туктап, уйланып торды да ни өчендер янчыкны кесәсенә кире салды. Шуннан соң алар юл кырыендагы җәяүлеләр сукмагы белән көнчыгышка таба карап киттеләр.

Көн буе, ут шарыдай, баш түбәсендә әйләнгән кояш аларның тәмам теңкәләренә тиеп беткән иде; гимнастеркалары манма су булган, иңбашларына тир тозы бәреп чыккан, ә яңаклары, колак артлары буйлап юл-юл кара тир агып төшкән. Тәнгә азрак җил үтсен дип, ахрысы, каешларын билләреннән салып, иңбашлары аша кигәннәр, котелок һәм кружкаларын шул каешларының очына такканнар. Өчесенең дә кулларында каяндыр сындырып алган карама таяклар...

Кемнәр соң бу сәер солдатлар? Аларның берсе Горький шәһәреннән грузчик Василий, икенчесе Норлат егете Хәким, өченчесе Чистай мишәре Талип иде. Нидән соң алар мондый сукбайлар кыяфәтенә кергәннәр?

...Өченче көн сугыш башланды. Гитлер армиясе, совет халкын йомшак урыны өстендә буарга теләгәндәй, безнең илгә таң алдыннан, дөнья иң татлы йокыда чакта бәреп керде. Ә бу өч солдат хезмәт иткән батальон, шушы кабахәт хаинлек эшләнгән көннән бер атна чамасы элек кенә дәүләт чигенә килеп, оборона ныгытмалары төзергә керешкән иде. Аны әле чын мәгънәсендә сугышчан часть дип тә булмый, чөнки солдатлары аның балта, пычкы, көрәк кебек атмый торган кораллар белән генә коралланганнар иде. Хода белсен, корткычлык булганмыдыр инде ул, ләкин чик буенда яткан батальонга коралның чынын, ата торганын төзү эшләре беткәч кенә бирергә вәгъдә итәләр.

Билгеле инде, фашист армиясе үзенең бөтен ут һәм тимер көче белән искәртмәстән бәреп кергәч, батальонның коралсыз солдатлары ихтыярсыз, сарык көтүедәй, тирә-якка сибелеп бетәләр.

Менә шул мәхшәрдән качып котылган чакта бу өч солдат ничектер бергә туры килеп шушы газаплы һәм фаҗигале юлларын башладылар. Сугышның беренче сәгатьләреннән үк аларга дошманның никадәр көчле, хәтәр булуын гына түгел, явыз, ерткыч икәнен дә күрергә туры килде. Батальон торган җирдән сигез-ун километрлар чамасы читтә алма бакчаларына күмелеп утырган бер кечкенә шәһәрчек бар иде. Немец авиациясе очып кергәч тә, менә шул бернинди хәрби часть-мазар тормаган, гомумән, бернинди хәтәр сизмичә һәм беркемнән явызлык көтмичә тыныч кына яшәгән шәһәрне ярты сәгать эчендә җир белән тигезләде дә куйды. Кичтән капка төпләрендә оек бәйләп утырган әбиләр, бакча сукмакларында йөгерешеп йөргән нәни балалар, йокыларыннан уяныргa да өлгермичә, хәрабәләр астында күмелеп калдылар.

Егетләр кара сөремгә чорналган шәһәрчекне читләтеп уздылар. Шул чакта бер нәрсә аларны бик гаҗәпләндерде: шәһәрдән чыккан юл буенда ара-тирә аунап яткан кеше мәетләре очрый башлады. Кай җирдә бер генә мәет, ә кай җирдә исә берьюлы берничә мәет — хатыны-кызы, бала-чагасы аунап ята иде. Күбесе йөзтүбән капланып төшкән... Нидән бу? Кайбер мәетләрне игътибар беләнрәк карагач, егетләр эшнең серен аңлап алдылар: немец самолетлары шәһәрдән качып котылырга тырышкан бу бичараларны пулеметтан кырып йөргән икән... Шундый мәгънәсез явызлык иде бу, егетләр ни уйлап ни әйтергә белмәделәр.

Хәер, немец авиациясенең никадәр нахал булуын, никадәр мәгънәсез, ахмак эш итүен алар үзләре дә бик тиз җилкәләрендә татыдылар. Шулай, икенче көнне арыш басуы эченнән тар гына юл белән китеп барганда, безнең яктан кайтып килүче ике немец самолетының берсе болар өстенә борылды. Ярый әле Хәким шунда ук моңа игътибар итеп өлгерде. Туктала биреп, ул:

— Егетләр, карагыз әле, бу очлы борын безнең өскә килә түгелме соң? — диде.

Василий күтәрелеп караганда самолет инде түбәнәя дә башлаган иде.

— Ятыгыз! — дип бер кычкырды да ул арыш эченә чумды.

Егетләрнең җиргә сеңүләре булды, арыш өстен шаулатып көчле җил исеп китте һәм яман үкереп зур кара күләгә шуып узды. Йомшак камыл төпләренә пулеметтан өзеп-өзеп кенә «тыр-р», «тыр-р-р» иттереп эре пуля тезеп китте. Ләкин тагын әйләнде, тагын арыш өстен өермәләндереп, улап, җирне гаять зур тегү машинасында теккәндәй, тырылдап узды. Үкерә-үкерә ераклашты, югары күтәрелде һәм үз юлы белән китеп тә барды. Иң элек Хәким, тезләнеп, арыш арасыннан тизрәк башын сузды һәм бик хирысланып самолетны озатып калды. Василий торып утырды да, ничек тынычланырга белмәгәндәй, тезләрен кочаклады.

— Вот сволочь, вот подлец! — диде ул, башын чайкап-чайкап.— Нишли, ә? Нишли бит, ә! Их-х, нигә болай булды соң әле бу?! — Һәм ярсудан йодрыгы белән җирне төяргә тотынды.

Болар китәргә дип аякларына да бастылар, ә Талип беләкләре белән башын каплаган килеш һаман ята иде әле. Хәким иелеп аның итәгеннән тартты:

— Талип, ни булды сиңа? Тор әйдә!

Талип иң элек акрын гына чалкан әйләнде, аннан терсәгенә таянып кына башын калкыта башлады. Чырай калмаган иде аңарда. Василий гаҗәпләнеп башын селекте:

— Ай-һай, авиацияне бер дә яратмыйсың икән син, зрә!

Талип нидер әйтмәкче булган иде дә, тик калтырануын тыя алмады.

...Әнә шулай котырынды немец авиациясе. Кайсы якка гына колак салма, гөрс тә гөрс җир селкетеп химаясез шәһәрләрне җимерде, тын авылларны яндырды, тузанлы юллар буйлап төркем-төркем качып баручы хатын-кыз, бала-чагаларны кырып йөрде, хәтта ялгыз кешеләрне куып йөрүдән дә тартынмады. Дошманның шушы оятсызлыгы һәм ерткычлыгы безнең егетләрне иң караңгы, иң газаплы уйларга төшерде. Нигә бу болай? Ничек кенә килеп чыкты соң әле бу? Дошман иркенләп котырынсын, ә син качып-посып, кырлар уртасында адашып йөр, имеш! Йә моңардан да аяныч хәл булырга мөмкинме? Һичшиксез, бу хәлдән чыгарга кирәк иде. Ничек кенә булса да, үзебезнең берәр частьны очратып, шуңа кушылырга кирәк иде. Шунсыз эш харап. Шунсыз алар бетәчәкләр!

Дошман кулына эләгү ихтималы алар өчен хәзер иң зур куркыныч иде. Бу куркыныч аларга гадәттән тыш сак булырга куша. Шунлыктан алар, армый-талмый һаман көнчыгышка таба барсалар да, олы юлга чыгарга җөрьәт итмәделәр. Ара-тирә якын килсәләр дә, анда һаман дошманның үтеп-сүтеп торуын сизеп, читкә тайпылырга мәҗбүр булдылар. Тик менә сугышның өченче көнендә дөнья бераз тынган кебек күренгәч һәм менә болай, өермә күтәреп алып киткән чүп шикелле, кая барганнарын, нишләгәннәрен белмичә йөрүдән тәмам җаннары бизгәч, алар, ниһаять, олы юлга аяк бастылар.

Горький русы Василий ничектер үзеннән-үзе башрак булып танылып өлгергән иде инде, шуңа күрә ул гел алдан бара, ә Хәким белән Талип, тезгенсез җибәргән атлар шикелле, аңардан калыбрак атлыйлар. Алар өчесе дә бик арыганнар, яңаклары суырылган, иреннәре кибеп яргаланган, аякләренә каты төк бәреп чыккан... Эсселектән, туктаусыз килүдән хәлсезләнү өстенә аларны тагын ачлык чынлап борчый башлады. Моңарчы Талипның саклап йөрткән биш-алты шакмак шикәрен суырып, кузгалак чәйнәп, ара-тирә җиләк чүпләп килделәр. Бүген дүртенче тәүлек инде бер локма икмәк капканнары юк, тиздән эчләре арка сөякләренә ябышыр кебек... Тәмәкеләре дә бетеп килә, хәер, ач корсакка тартып та булмый, хәзер үк укшыта башлый.

Алар баралар... Алларында туп-туры сузылып киткән тигез юл. Аның тараеп югалган түренә чаклы күз туктарлык бер генә карачкы да күренми. Бөтен тирә-якта сәер, ят бушлык һәм җансыз тынлык хөкем сөрә. Сугыш әллә бик артта калган, әллә бик алга киткән — белер хәл дә юк. Әйтерсең бу бер үлек ара, ник бер җан әсәре сизелсен, хәтта әйләнәдәге табигать тә, коты алынгандай, тып-тын тора. Солдатларның инде үзара сөйләшүләре дә килми башлады — бик күңелсез уйларга йотылганнар иде алар.

...Күпмедер барганнан соң, менә бервакытны алар үз артларында тоташ, каты бер гөрелдәү ишеттеләр. Өчесе дә туктадылар һәм артларына борылып, тыңлап тора башладылар. Тигез юлның очында ургылып-ургылып соры тузан күтәрелә иде. Ни галәмәт бу? Тузан таралмыйча юл өстендә асылынып тора, шунлыктан нәрсә килгәнен абайлап та булмый. Ләкин бик яман нәрсә килә, ахрысы, каты гөрелдәү бөтен тирә-юньне тутырып һаман көчәя бара.

Ниһаять, Василий шәйләп алды булса кирәк, шомлы тавыш белән:

— Немец танклары! — диде.

Шунда ук өчесе дә бер-берсенә карадылар: «Нәрсә эшләргә?» Аптырау һәм курку шул секундта ук аларның агарган йөзләренә бәреп тә чыкты. Шулай да югалып калмадылар. Хәким кулы белән сул якка изәп күрсәтте:

— Әйдәгез, йөгерик шунда!

Юлдан дүрт йөз метр чамасы гына читтә, тигез кыр уртасында, кечкенә ап-ак каенлык күренә иде. Шунда йөгермичә бүтән чара юк. Василий, ашыгып:

— Әйдәгез! — диде дә юл буендагы канауга сикереп төште. Төшү белән уң ягында сай чокыр аша калын шпаллардан салынган кечкенә күперне күреп алды. Күпер егерме-утыз метр гына арырак иде. Урманга дип омтылган җиреннән Василий, кисәк кенә уңга борылып, иелә-иелә шул күпергә таба йөгерде. Хәким белән Талип та, артларыннан җитеп сукканны көткәндәй, җилкәләрен җыерып, аның артыннан йөгерделәр.

Күпернең эче бик тәбәнәк, кысан булса да, егетләр ничек тә сыйдылар. Сулышын көчкә алган Хәким:

— Ни... нигә монда кердең? — диде.

Василий иң элек бик яман итеп бер төчкерде, шуннан соң гына ачулы тавыш белән:

— Вот голова, тигез кырдан йөгереп кара,— диде.—Пулеметтан бер генә сиптергән булырлар иде.

Талип бизгәк тоткандай дер-дер калтырый иде. Аның калтырануы Хәкимгә бик ямьсез тәэсир итә иде: ахырда түзмичә ул терсәге белән Талипның кабыргасына төртеп алды:

— Булмале шулхәтле... ир башың белән...

— Нишлим соң, мин гаеплемени? — диде Талип, елардай булып, һәм аның тешләре бер-берсенә шык-шык бәрелеп куйды.

...Җир тетрәтеп килгән гөрелдәү шундый коточыргыч дәһшәт белән якынлаша ки, тиздән менә аларны бөтенләй йотар, юк итәр кебек иде... Ул да булмый, таш юл сыгылып тора башлады, күпернең калын шпаллары сикерешергә тотындылар, солдатлар өстенә ишелеп тузан-туфрак коелды, һәм мотор үкерүе, тимер чыңы, ташлар шыкырдавы дөньяны тәмам күмеп китте.

...Танклар үтәләр.

Бер-ике минут кына булса да шушы галәмәткә чыдап утыр әле! Өстәвенә егетләрнең буш эчләре җир белән бергә туктаусыз селкенә, һәм бу нәрсә аларны аеруча газаплый иде. Шыкырдатып тешләрен кыскан Василий эченнән генә танкларны санап утырды. Соңгысы үткәч, тирән сулап:

— Унике... Да... бәдбәхетләр! — диде.

— Дөрес, унике,— диде Хәким дә.

Талипча да шулай булып чыкты. Өчесе дә санап утырганнар һәм өчесендә дә хәзер бер үк авыр, күңелсез уйлар иде: танклар безнең якка таба китте, димәк, алар һаман да немецлар артыннан сөйрәлеп баралар икән әле...

Василий кат-кат башын чайкап куйды:

— Юк, юк. Үзебезнекеләргә җитәбез, җитәргә кирәк. Колбасниклар кулына гына эләкмик!

Танклар шактый кызу ераклаштылар, яман тавыш тирә-якны һаман яңгыратса да, бик тиз тоныклана барды. Шулай да безнең егетләр күпер астыннан чыгарга ашыкмадылар. Исләрен җыеп, үзалларына уйланып, сүзсез генә утыра бирделәр. Ахырда, тавыш тәмам тынгач, Василий урыныннан кузгалды. Бил тиңентен чыгып, сак кына башын күтәрә башлады. Иң элек уңга —кыр ягына карады, аннан акрын гына сулга — юл өстенә борылды. Һәм... менә сиңа кирәк булса: юл өстендә туп-туры аңа карап өч немец басып тора иде. Василий һич сискәнмәде, курыкмады, бер хәрәкәт ясамады, ә немецларга карап катты да калды. Күпме дәвам иткәндер бу хәл, тик бераздан гына ул үзенә төбәлгән бер пистолет, ике автомат көпшәсен күреп алды. Аз гына саксыз хәрәкәт — көпшәләр шул секундта ук аңа ут төкерергә тиешләр. Ләкин немецлар үзләре дә аңа бик хәйран булып карап торалар иде. Курку һәм саклык хисеннән бигрәк, онытылып кызыксыну аларны гүя биләп алган иде. Һәрхәлдә, Василий шуны ничектер сизде булса кирәк, күз ачып йомганчы торып аягына да басты. Автоматлар атмый калдылар, чөнки Василий коралсыз иде.

Берни сизмәгән Хәким белән Талип таякларын сөйрәп күпер астыннан чыктылар да, күтәрелеп тә карамыйча кагына башладылар. Шушы берни абайламау аларны коткарды — немецлар тагын атмый калдылар. Василийның башында бер исәп тә туып өлгерде: менә шулай өркетмичә генә немецларга якынлашып, кинәт кенә автоматларын тартып алып булмасмы? Тик иптәшләр каушап калмасыннар иде, ничек итеп аларга моны сиздерергә?

Ләкин шул минутта ук Василий үзенең артында ниндидер кеше тавышлары ишетте. Борылып караса, әлеге теге кечкенә каенлыктан боларга таба кулларын болгап, кычкыра-кычкыра тагын дүрт немец килә иде. Бары хәзер генә ул эшләрнең никадәр җитди, хәтәр булуын белеп алды һәм чынлап торып шүрләде. Хәким белән Талип та немецларны күреп берьюлы агарынып киттеләр ихтыярсыз Василийга сыена төштеләр. Шулай да Хәким иптәшенең колагына тиз генә пышылдады:

— Әйдә, чабыйк!

Василий башын бормыйча гына:

— Юл буена кара,— диде.

Хәкимгә борылып карауның кирәге дә булмады, артында дошман басып торганлыгын ул ничектер аркасы белән сизеп алды.

Йөгерешеп килгән немецлар юлга чыкмыйча канаудан шактый читтә тукталдылар. Аларның берсе юлда торган өч немецка нидер кычкырып әйтте. Шуннан соң өч немецның әлеге пистолет тотканы үзенчә

бик әтәчләнеп безнекеләргә нидер кычкырды. Бу бер офицер кисәге булса кирәк, киеме һәм билгеләре бүтәнчәрәк, үзе яшь, йөзе алсу, күзләре зәңгәр... Бөтен торышыннан һәм калкына биреп кычкыруыннан аның сугышны күңелле бер эш итеп санавы, ә үзенә гел җиңеп йөргән бәхетле егет итеп каравы сизелеп тора иде.

Ул тагын кулын алга сузып, гайрәтләнеп нидер кычкырды. Ә безнекеләр, сүзен аңламагач, аңа тыныч кына тик карап тордылар. Гаҗәеп хәл! Әллә күзләре матур булгангамы, әллә офицердан бигрәк артистка охшагангамы, ул безнекеләргә бер дә куркыныч булып күренмәде.

Ниһаять, офицер, канау аша йөгереп чыгып, пистолеты белән алга таба селтәп-селтәп күрсәтергә тотынды. Бу —шул якка атлагыз дип боеру иде. Безнекеләр аңлап алдылар һәм, канаудан чыгып, күрсәткән якка таба ашыкмыйча гына атлап киттеләр. Офицер алдан төште, ә калганнары, ата казлардай каңгылдашып, арттан иярделәр. Аларның бу яман шаулап сөйләшүләре, һичшиксез, безнекеләр турында иде. Ни сөйләшәләр — әйтүе читен. Ихтимал, рус солдатының кулында таяк кына, үзе ялангач, үзе аңгыра, йә, шулар белән сугышып йөр инде, дип көлүләре булгандыр.

Безнекеләр чынлап торып дошман кулына эләгүләрен аңлыйлар иде. Өчесе дә тыштан болай тыныч кебекләр, ләкин бу минутта һәркайсының да күңелен игәүләгән үз уе бар иде. Василий, мәсәлән, бертуктаусыз немецлар кулыннан ычкыну турында уйлана. Дошман белән беренче тапкыр күзгә-күз очрашудан ук бер нәрсәне бик яхшы сизеп калды: каушамаска кирәк икән. Шуңа күрә ычкына алуларына ул бик өметле карый. Аннан бу кол-басниклар артык уяу халык түгел шикелле, шаять, алдап булыр үзләрен, тик җай гына чыксын!

Хәким дә немецларны бик җентекләп күзәтеп бара, ләкин Василий шикелле үк алай ашыгып нәтиҗә ясаудан ерак иде. Киресенчә, пленга эләгү шушыдыр инде, кая илтерләр дә нишләтерләр икән, дип уйлана иде. Та-липның исә бар курыкканы үлем булганга, эченнән дога урынына бары бер нәрсәне генә кабатлый: атмасалар гына ярар иде!

Каенлыкка җитәрәк, Василий иптәшләренә пышылдап кына:

— Каушамагыз! — диде.— Бөтен сорауларга җавапны үзем бирәм, ә сез мин әйткәнне кабатлап кына торырсыз!

Егетләр дәшмәделәр.

Каенлык авызында аларны кулларын артка куеп, аякларын аера төшеп басып торган озын, чандыр немец офицеры каршы алды. Бу кечкенә җанвардан булмаска тиеш иде. Башында аның алгы чите иләмсез текә күтәрелеп торган фуражка; шунда тигез канатларын туп-туры җәйгән ак бөркет эмблемасы беркетелгән... Өстендә тар погонлы, яшькелт-соры френч, аякларында краги белән кара ботинкалар, билендә портупеялы каеш, шуның сул ягында зур пистолет кобурасы...

...Безнең өч солдат менә шул, кадап куйган казыктай, тик кенә торган немец алдына килеп бастылар. Алып килүче купшы офицер күкрәген киереп, кулларын бот буена сузып, кызу-кызу гына нидер әйтте, ә тегесе чак сизелерлек итеп кенә башын селкеп куйды. Шуннан соң ул үлекнекедәй яртылаш йомык, хәрәкәтсез күзләре белән безнекеләргә төбәлде. Өч солдатның эченә берьюлы салкын йөгерде: юк, бу ата фашисттан рәхим көтеп булмый иде. Озак карап торды немец өч солдатка, бигрәк тә Василий чыраена «мәхәббәте» төште булса кирәк, энәле күзләрен озаклап аңа текәде. Ә Василийның калын иренле, зур авызлы, җәенке борынлы, чырае чыннан да гаҗәеп серле иде: ул чырайда искиткеч бер ваемсызлык җәелеп ята, шуннан башка берни юк. Кем алдында басып торганын беләме ул, борчыламы, куркамы — һич сизеп булырлык түгел, шайтан алгыры!

Шулай аптырабрак калган немец, ниһаять, ташка баскандай ачык, тимердәй салкын тавыш белән саф русча:

— Сез бөек Германия армиясенең кулына төшкән әсирләр, шуны беләсезме? — дип сорады.

Немецның болай саф русча дәшүе егетләрне бик гаҗәпләндереп җибәрде. Ләкин Василий бер кереп алган кабыгыннан ничек тә чыкмаска тырышты: сыңар иңбашын җыерып, исе китмичә, ялкау гына:

— Күрәбез,— диде.

Әйе, менә шулай һичнигә исе китмичә ваемсыз булып күренү аркасында гына ул үзен дошман капризыннан бәйсез тота алачак. Бу хәзер аңа бик ачык иде.

— Коралларыгыз кайда? — дип сорады немец.

Василий кулындагы кәкре таякка карап, көрсенеп куйды.

— Менә шушы инде...

Немец авызының бер кырые белән генә елмайгандай итте.

— Совет армиясен без шәбрәк коралланган булырга тиеш дип уйлаган идек.

— Шәбрәген алырга өлгермичә калдык шул, парень! —диде Василий, үз ишенә әйткәндәй, гаҗәеп бер текәллефсезлек белән.

— Ә нинди частьтан сез?

— Әллә тагын... Белә алмый калдык.

— Ничек белә алмыйча калдыгыз?

— Шулай... Кич белән генә килеп төшкән идек, иртән чигенә башладык.

Немец тагы да кысыла төшкән күзләре белән Василийга бөтенләй кадалды: «бу мужик» дөресен әйтәме, ялганлыймы? Ә Василий, рәхим ит, кара, дигән төсле, сыңар төген дә кыймылдатмыйча, тыныч кына басып тора. Җитмәсә, теш арасыннан «чырт» иттереп төкереп тә куйды. Немецның нечкә иреннәре кысылып, яңак сөякләре уйнаклап алды. Әгәр ул Василий чыраенда санга санамау шикелле берәр нәрсәнең чаткысын гына сизеп калса да, перчаткасын салып тормастан, «мужикның» аяк астына берне кундырыр иде. Ләкин ник бер андый нәрсә сизелсен. Хәтта пошыну әсәре дә юк. Менә тип!

Шуннан соң ул кечкенә тынгысыз күзләрен Хәким белән Талипка күчерде, Хәким офицерның барлыгын да онытып, каядыр читкә карап тора иде. Ул үзенә төбәлгән авыр карашны тойды, ләкин башын бормады — гүя нидер күреп исе киткән... Ә Талип, намазга оеган мөселман шикелле, кулларын кендеге өстенә куеп, җирән керфекләрен җиргә терәп, тик кенә тора. Әллә уяу, әллә йокыга талган — белмәссең дә.

— Кая барасыз? — диде офицер, аңа төбәлеп.— Мин сездән сорыйм!

Талип сискәнеп башын күтәрде, күзләрен йомгалап алды:

— Ә?..

— Идиот,— диде офицер, йөзен чытып.

Василийга эшне җайларга кирәк иде, немецны һич ярсытырга ярамый. Башта җилкәсен кашыган булды, аннан кыенсыныбрак:

— Кая булсын инде,— диде,— үзебезнең якка таба бара идек.

— Ни өчен үзегезнең якка?

— Хатын, семья, өй шунда бит,— диде Василий, авыр сулап.

Офицер кинәт елмаюга охшатып тешләрен ыржайтты:

— Әһә, хатынны сагындыгызмыни, сугышасыгыз килмимени?

Василий бик аз гына көттереп торды һәм йөзен офицерга күрсәтмәс өчен башын түбән иеп әйтте:

— Бездә берәү дә сугышырга теләмәгән иде...

— А-а-а! — дип сузды немец, аннан «так... так...» дип торды һәм шул минутта аның башында гаҗәеп оригиналь бер исәп туды. Еракка төбәлгән бик мәкерле исәп иде бу. Барыбер аның бу «хайваннарны» куяр урыны да юк, тылга-мазарга озатырга артык кешесе дә, вакыты да юк. Ә Совет Армиясен җимерер өчен ни эшләсәң дә ярый — фюрерның әйткәне шулай! Ләкин... башта сынарга кирәк үзләрен, күнәрлек булмасалар, «расходка җибәрү» беркайчан да соң түгел.

Немецның ничектер берьюлы карашы да, тавышы да «йомшарган» кебек булды.

— Ашыйсыгыз киләме? — дип сорады ул кинәт.

Егетләрнең колаклары торды: бусы ни тагын? Мыскыл итүеме? Ләкин Василий шул минутта ук балаларча беркатлылык белән:

— А как же... килә! — диде.

Ул хәтта чынлап авызына килгән төкереген дә йотып куйды.

— Ну, утырыгыз! Без хәзер сезне сыйлыйбыз.

Һич икеләнү күрсәтмичә, иң элек Василий, аның артыннан Хәким белән Талип яшел чирәмгә утырдылар, таякларын яннарына сузып салдылар...

...Алар ач иделәр, ашау сүзен ишетүгә аларның башлары әйләнеп китте, авызларына өзлексез төкерекләре килә торды... Ләкин алар офицерга ышанмыйлар иде, икмәк урынына берәр әшәке мыскыл белән сыйлар дип шомланалар иде. Хәкимнең Василийга бераз ачуы да килде: «Нигә әйтте, нигә баш тартмады»,— дип ачынып уйланды ул. Василий үзе дә офицердан бернинди дә изгелек көтми иде, әмма ул бөтен эшен бер теләк — дошманны алдап булмасмы дигән теләк белән эшли иде. Шуның өчен дә ул үзенең каушау белмәс беркатлы ваемсызлыгын ничек тә сакларга тырыша иде. Дөресен генә әйткәндә, аның үзен-үзе болай тотуы бик табигый рәвештә иптәшләренә дә йогып өлгерде.

Немец Хәкимнәрне алып килгән әлеге яшь, чибәр офицерга нидер кушты. Анысы, тиз генә борылып, агачлар арасына кереп китте. Һәм озак та тормый аннан пергаментка төргән өч кисәк нәрсә китереп безнекеләрнең алдына салды.

— Ашагыз! — диде немец.

Безнекеләр дүрткырлы каты әйбернең пергаментын ерттылар: алар кулында чыннан да икмәк иде. Немецларның сугыш өчен махсус алдан әзерләп куйган поход икмәге. Шуңа күрә таш кебек каты да икән ул. Безнекеләр, көч белән сындырып, тәмләп ашарга тотындылар.

Бу вакытта аларны зур гына төркем немец солдатлары уратып алганнар иде. Шаккатып безнекеләргә карап торалар. Безнекеләр дә утырган җирләреннән, икмәкләрен чәйни-чәйни, немецларга бик игътибар белән карыйлар. Шушы икән инде ул бәйдән ычкындырып җибәрелгән өер! Ватып-җимереп, яндырып-көйдереп, кырып-бетереп килүче «батырлар»! Әйтәсе дә юк, карап торырга бик шәпләр. Барысы да сугым малыдай көрләр, баштанаяк өр-яңадан киенгәннәр, коралның да яңасын асканнар, шуның өстенә кәефләре дә шул булса кирәк: авызлары колакларына кадәр ерылган...

Тик аларның бу елмаюларында ниндидер аптырау чагыла: җирдә ашап утырган өч коралсыз солдатның бу кадәр пошымсыз булуларын, бу кадәр тыныч карауларын ничек аңларга? Тар-мар ителгән

армиянең пленга төшкән солдатлары шулай булырга тиешме? Әллә алар үзләрен җиңелгәнгә, беткәнгә санамыйлармы? Гаҗәп, бик гаҗәп!

Егетләрнең авызыннан күзен алмыйча карап торган немец:

— Аракы эчәсезме? — диде һәм, аларны шикләндермәс өченме, әйтеп куйды: — Руслар бит аракы эчәргә яраталар.

Василий, аңа җавап бирмичә, Хәкимгә борылды:

— Аким, эчәбезме?

Бик четерекле сорау иде бу Хәким өчен... Алар хәлендә ач корсакка аракы эчү — бик хәтәр бит ул. Ләкин немецның икмәген ашап та аракысыннан баш тарту килешерме, дошманны шикләндермәсме?.. Василий нинди җавап көтә икән соң?

Хәким икмәген чәйнәп йоткан арада шуларны уйлап алды да тәвәккәлләп:

— Печтек кенә эчсәк тә ярый,— диде.

Василий немецка башы белән ымлады:

— Сал, булмаса!

Немец биленнән чехоллы флягасын алып, шуның сырлы капкачына аракы салып, Василийга сузды. Василий сүзсез генә капкачны алды, кул сырты белән авызын сөртеп куйды. Аннан аскы иренен чыгара төшеп, аракыны ипле генә салып та җибәрде. Шунда ук аның эчәгеләре буйлап ут йөгерде, ләкин ул чыраен да сытмады, капкачны немецка кире сузып, ашыкмыйча гына икмәген испәргә тотынды. Офицер Хәкимгә салып бирде. Хәким дә сырлы капкачны кулына алу белән, башын чөеп, эчеп җибәрде, «эһ» тә димәде, тик төкереп кенә куйды. Аннан Талип үз өлешен алды. Аның куллары калтырый иде, шуңа карамастан егет, иске гадәт буенча, капкачны оста гына авызына каплады. Егетләрнең аракыны эчә белүләре немецка ошады булса кирәк, кечкенә күзләре, караңгыда утырган мәченекедәй, елтырап китте.

— Браво, браво! — диде ул, юка иреннәрен ерыр-ермас.

Аның әйләнәсендәге солдатлар да үзара шаулап, көлешеп алдылар. Немец әлеге икмәк китергән чибәр офицерга тагын нидер кушты. Чибәр офицер тиз генә агачлар арасына кереп китте дә бераздан колбаса, сыр, бизәкле кәгазьгә төргән тагын нәрсәләрдер күтәреп чыкты. Немец ымлавы буенча ул шуларның барысын да егетләр алдына китереп салды.

— Ашагыз туйганчы,— диде немец.

Безнекеләр, рәхмәт әйтеп тормыйча, алларына төшкәнне бик эшлекле кыяфәт белән ипләп кенә сыпыра бирделәр. Ләкин, карчыга кебек, күзен алмыйча карап торган немецка һәм шаккаткан солдатларга һич игътибар итмичә ашап утырулары алар өчен җиңел эштән түгел иде. Чөнки немецка энә очы кадәр дә ышанмыйлар, чөнки бу өрәкнең, кирәксә шушы минутта ук, аларның эчләренә икмәк биргән кулы белән бер уч пуля да җибәрә алачагын белеп торалар. Гомумән, немецның мәкерле ният белән сыйлавы алар өчен көн кебек ачык иде. Моны хәтта немец солдатларының чырайлары ук әйтеп тора: янәсе, офицерлары бу өч «русиш» өстеннән бик оста «шуклык» эшли, ә алар шуның нинди эффект белән бетәсен алдан ук сизеп, тәгәрәгәнче шаркылдарга әзерләнеп торалар. Кыскасы, тычканга үлем, мәчегә көлке!

Менә офицер әлеге сырлы капкачка тагын аракы салып, бер сүз әйтмичә, Василийга сузды. Василий сүзсез генә алды, эчте, кире бирде. Аннан бер сөйләшү булсын дип, офицердан сораган булды:

— Сезнеңчә «аракы» ничек?

— Безнеңчәме?.. Шнапс.

— Шнапс?.. Аким, онытма, немецлар аракыны шнапс дип атыйлар икән.

Хәким җитди генә:

— Ярар, онытмам,— диде.

Василий елмаймас өчен тамак кырып куйды.

Ашап беткәч, егетләр кайсы учы, кайсы җиңе белән, әйбәтләп авызларын сөрттеләр; Талип итәгенә төшкән валчыкларны да чүпләп капты. Офицер галифе кесәсеннән көн тышлы портсигар чыгарып алга таба сузды да япып торган яшькелт төймәсенә басты: портсигар капкачы Василийның борын төбендә үк ачылып китте.

— Уйлыйм ки, моңардан да баш тартмассыз?

— Папирос?

— Сигарета!

Василий берсен алып, ашыкмыйча гына ике бармагы белән угалап, авызына капты. Кесәсендә шырпысы булса да ул, аны чыгармыйча, офицерның яндырып тәкъдим итүен көтә башлады. Офицер, Хәким белән Талипка да сигарета биреп, тизрәк икенче кесәсенә тыгылды. Аннан ялтырап торган кечкенә бер әйбер чыгарып кабыргасына баскан иде, капкачы ачылып, гөлт итеп ут кабынды.

— Рәхим итегез!

Василий курыккан булып башын артка каерды һәм гаҗәпләнеп сораган булды:

— Нәрсә бу?

— Курыкмагыз, автомат зажигалка.

— Ә-ә-ә... зажигалка!.. Шәп нәрсә икән.

— Да... Безнең һәрбер солдатта бар ул.

— Кара син аны!

Василийның офицерны бераз шаяртасы килә иде, ничек кенә булмасын, ач корсакка эчкән аракы кәефен күтәреп җибәрде. Ләкин бу иблиснең күзләре шундый очлы, шаяртып маташуыңны хәзер үк сизеп алуы бар. Аннан — бетте баш, пешермичә тереләй ашар! Юк, саксыз кыланырга ярамый, ярамый... Һәм Василий яңадан үзенең кабыгына керде, гаҗәеп бер мәнсезлек белән авызын зур-зур ачып иснәргә тотынды. Иптәшләре дә аның үз ише — Хәким терсәгенә таянып, кырын яткан килеш, тәмләп кенә Истамбул сигаретасын тарта, ә Талип үлән сабагы чәйнәп утыра иде.

Офицерның безнекеләргә вакыты-вакыты белән җен ачулары кузгалып китә иде, ахрысы; тик торганнан яңак сөякләрен кыймылдата башлый ул... Чыннан да, мондый сансызлыкка түзәргә кирәк бит. Ләкин немецның бик шәп планы бар, шуның хакына «русиш»ны аракы, сигарета белән сыйлап, тәмәкесенә ут та тәкъдим итәргә туры килде инде авыз тутырып иснәвенә генә түзәрсең.

Ниһаять, ул, ашау-эчүне йомгакларга теләп, егетләрдән сорады:

— Йә, канәгатьме сез?

— Ничего, әйбәт булып калды,— диде Василий, сигаретасының көлен бармагы белән кагып. Офицер аның йөзенә текәлде.

— Инде нишләргә уйлыйсыз?

«Башлана!» — дип уйлады Василий эченнән, ләкин сорауны аңламаган булып, үз нәүбәтендә офицерга туп-туры карады.

— Мин сездән, бездә каласызмы яки кире үзегезнекеләргә китәсезме, дип сорыйм,— диде офицер.

Сорау гаҗәп аңлаешлы иде.

Безнекеләр уенның инде беткәнен, шушы сораугa ничек дип җавап бирүдән язмышлары хәл ителәчәген яхшы сизеп алдылар. Ләкин алар тыныч гамьсезлекләрен бер генә секундка да җуймадылар һәм утырганы — утырган, ятканы яткан килеш кала бирделәр. Тик Василий гына алдын тәмәке төтене белән тутырды. Офицерның тел төбе кая барганын белергә теләп, ул вакытсыз сүзгә керешүдән ничек тә тыелырга тырыша иде. Һәм офицер, егетләрдән җавап көтеп ала алмагач, тагын үзе сүз башларга мәҗбүр булды. Ул, бу мәхлуклар куркалар, ахрысы, дип уйлап, үзенчә мөмкин кадәр йомшаграк булырга тырышты.

— Без көчләмибез, без сезнең ихтыярыгызга куябыз,—диде ул, перчаткалы кулын суза биреп,— әгәр каласыз икән, пожалысты, рәхим итәсез... Безнең солдатларның азыкларын күрдегез. Алар бездә шоколад ашап, сигарета гына тартып йөриләр. Каласыз икән, сезгә дә шулай булыр. Колбаса, сыр, май гына ашап торырсыз. Аракы — теләгән кадәр, эчә генә күрегез... Ну... әгәр китәбез, үзебезнекеләргә кайтабыз дисез икән, пожалысты, тоткарлык юк, китәсез. Аңлыйсызмы, без көчләп тотмыйбыз.

— Аңлыйбыз,— диде Василий һәм сигаретасының очына төкереп, шактый ераккa ыргытты.

Әйе, офицер бик аңлаешлы итеп сөйләп бирде. Немец солдатлары арасында русча аңлаучылар булды, күрәсең; алар кызу-кызу гына иптәшләренә нидер әйттеләр, аннан барысы берьюлы шаулашып алдылар. Тынгач, безнекеләрнең «кызыклы» җавабын ишетер өчен, бөтен чырайлары белән түземсезлек күрсәтеп көтеп тора башладылар.

...Егетләр өчен хәлиткеч минут килеп җитте. Хәзер инде җавапны бирергә һәм бирә белеп бирергә кирәк иде. Офицер, бу җавапны бары Василийдан көткән шикелле, мәкерле сынау карашын аңа төбәде. Кинәт Василийның йөрәгендә рәхимсез ярсу кузгалып куйды, немецның озын, үлек битенә: «Без колбасага сатылучылар түгел!» — дип яман кычкырасы килде, ләкин... башын салмак кына Хәкимгә борды һәм гади генә итеп:

— Йә, Аким, нишлибез? — диде.— Господин офицер әнә калсагыз да ярый, китсәгез дә була, ди.

Кырын яткан Хәким дошман офицерын бар дип тә белмәгән гаҗәеп бер мәнсезлек белән шунда ук әйтеп тә салды:

— Бәй, нишлик монда, конешно китәбез!

Василий эченнән дустына «молодец!» диде дә Талипка борылды:

— Ну, Талип, китәбезме, калабызмы?

Талип Хәким кебек артист түгел, ләкин, гел иптәшләренә сыенып яшәргә өйрәнгәнгә күрә, үзеннән-үзе килеп чыккан табигыйлек белән:

— Мин сездән калмыйм,— диде.

Василий акрын гына урыныннан кузгала башлады.

— Киттек алайса, дуслар!.. Торыгыз! Шулай, господин офицер, без китәргә булдык.

Офицер мәгънәле генә итеп немецча:

— Зер гут! — дип куйды.

Немец солдатлары хәрәкәтсез, тып-тын торалар. Бу шомлы бер минут иде, гүя, менә хәзер нидер булырга тиеш. Безнекеләр шул хәтәрне ничектер тиреләре белән тоеп, ләкин һич каушау әсәре күрсәтмичә, җирдән таякларын алдылар.

Иреннәрен кысып, озак дәшмичә торган офицер, ниһаять, телгә килде:

— Яхшы, мин сезне җибәрәм, ләкин бер шартым бар,— диде, һәм башы белән ымлап үзе артыннан иярергә кушты. Безнекеләр иярделәр.

Солдатлар төркеменнән читкәрәк китеп туктагач, офицер егетләрнең әле берсенә, әле икенчесенә карап, һәр сүзенә басым ясап, акрын гына сөйләргә тотынды:

— Күрәсез, мин сезне тотмыйм... Хәзер китәрсез, ләкин шартым шул: анда, үзегезнекеләр янына кайткач, монда күргәннәрегезне солдатларыгызга әйбәтләп сөйлисез. Безнең, ягъни бөек немец армиясенең, сезне ничек яхшы каршы алуыбызны, ничек ашатып-эчертеп җибәрүебезне сөйләп бирәсез. Нәрсә ашап-эчүегезне яшермичә сөйләгез: колбаса, сыр, булки, главное — аракы! Исегездә тотыгыз: большевиклар белән еврейләрне яклаудан баш тартып безнең якка чыккан һәрбер рус солдатын без шулай каршы алачакбыз. Менә шуны яхшылап үзегезнекеләргә төшендерегез. Әйтегез, сугыш тиздән бетә, немецлар Мәскәүгә барып җиткәннәр, диегез. Безнең солдатларны күрдегез ич! Кораллары бик күп, бик шәп киенгәннәр, бик таза ашыйлар, барыбер безне җиңәчәкләр, диегез... Аңладыгызмы?.. Ләкин бездә булуыгызны командир һәм комиссарларыгызга белдерә күрмәгез. Аларга ләм-мим, югыйсә харап булырсыз. Бары солдатларга гына сөйләгез. Аңладыгызмы?

Офицер сөйләп беткәнче Василий башын иеп торды. Ул белә: әгәр күтәрелеп караса, дошман тырнагыннан ычкыну булмаячак. Бу минутта тынычлыкны саклау аның өчен тау күтәреп торудан да авыррак иде. Шулай да ул шик тудырмаслык нык тавыш белән:

— Аңладык! — диде.

Офицер Талип белән Хәкимгә карап, кабатлап сорады:

— Аңладыгызмы?

Талип аңлаганын белдереп, тиз генә башын селекте, Хәким исә бер сүз дәшмичә калды.

Әллә офицерның күңелендә берәр шик кузгалды, ул тагын егетләргә авыр сынау карашы белән текәлде:

— Мин әйткәннәрне сөйләрсезме?

— Түкми-чәчми барысын да җиткерербез, господин офицер, тыныч булыгыз! — диде Василий, чегән өлгерлеге белән.

— Яхшы, барыгыз алайса! — Һәм офицер салмак кына кулын селкеп куйды.

Безнекеләр борылып киттеләр, ә хәйран булып урыннарында каткан немец солдатлары, бер тавыш чыгармыйча, алар артыннан карап калдылар.

Аз гына киткәч тә Василий иптәшләренә пышылдап әйтте:

— Артыгызга борылып карыйсы булмагыз!

Талип бер дә борчылуын баса алмый иде:

— Арттан атмаслар микән?

Хәким аңа ачу белән карап, кискен генә:

— Курыкма, ахмак! — диде.

Бераз китә төшкәч, Василий авыз эченнән нидер мыгырдана башлады. Аның йөзе кызарып бүртенгән, муен тамырлары калкып чыккан иде. Ул каты итеп кулын йомарлый һәм туктаусыз төкеренә, әйтерсең «кунакта» ашаган сыйлардан күңеле болгана... Менә Талип алгарак чыгып, кызурак атлый башлагач, ул кычкырудан чак тыелып:

— Кая чабасың, анаңның...— диде һәм рессорлы тарантаста баргандай тибрәтеп-тибрәтеп, биш-алты катлы итеп сүгенеп җибәрде.

Шуннан соң Талип алга чыкмас булды. Василий исә юл буена ачынып сүгенүдән туктамады:

— Ах, бәдбәхетләр, ах, сволочьлар!.. Нинди арзан сатып алдылар, ә?

Хәким аңа борчылып карап алды:

— Нигә бу хәтле тузасың, Василий!.. Ашадык та качтык, кемнең аларга сатылганы бар?

Василий авызының бер як чите белән генә зәһәр елмайды:

— Шул гына калган иде. Их, Аким, Аким, мәнсез кеше син...— Аннан, гердәй йодрыгын яртылаш күтәреп, салмак кына селкеп барды.— Ну, ничево... фашист актыгының «сыен» онытмабыз без... Кулга корал гына алыйк, унлата кайтарырбыз!

Бу вакыйганы миңа 1945 елның язында госпитальдә ишетергә туры килде. Сөйләүче — палатадагы күршем, сугыш дәвамында алтынчы мәртәбә яраланып госпитальгә кергән әлеге шул Норлат егете Хәким булды. Ул көннәрдә кызыклы да, гыйбрәтле дә булып тоелды бу вакыйга, чөнки безнең армия фашистларга каршы Берлинның үзендә соңгы, каты сугыш алып бара иде инде.

1945

## Икенче көнне

Икенче көн инде менә мин туган шәһәремнең урамнары буйлап йөрим. Дүрт ел буена бу шәһәр минем хыялым күгендә, тимер казык йолдызы шикелле, һичбер күз алдымнан китмичә, һаман бер үк яктылык

белән балкып торган иде. Бу шәһәргә исән-сау кайта алу — минем өчен теләргә мөмкин булган теләкләрнең иң ихласы, иң татлысы иде, ә кайтып күрү бәхетенә ирешә алу — язмышым тарафыннан миңа бирелгән иң югары, иң кадерле бүләк булырга тиеш иде. Һичшиксез, ул шулай иде... ләкин, гаҗәп хәл, мин бүген үземне артык тыныч тоям. Гүя мин үтеп барышлый тукталган бер сәяхәтчемен —сабыр гына бу таш йортларга, бу очраган кешеләргә күзәтү, сынау күзе белән карап, акрын гына йөрим. Хәтеремдә, фронтта хыялланган вакытларымда, исән-сау кайтсам, бу урамнардан ал канатлар өстендә очармын, бөтен кеше мине таныр, мин үзем дә очраган бер кешенең, күңелемнән генә булса да, кулын кысып үтәрмен дип уйлый идем... Хәер, очраклы бер шәһәрдә булмыйча, үз шәһәремдә йөрүемне һәрбер йортның миңа бик яхшы таныш булуыннан күреп торам. Хәтта бу йортлар үзләре дә мине таныйлар шикелле... Ә шулай да үтеп киткән авыр сугыш еллары җанлы кешеләргә генә түгел, менә шушы таш йортларга да тирән эз салып калдырган: фасадларының төсләре уңган, штукатурлары кубып-кубып төшкән; кайбер тәрәзәләр фанерлар белән ямалган: менә үзәк урамдагы, заманында иң шәп саналган гостиницаның тәрәзәләреннән тимер мич морҗалары урамга чыгып торалар. Мин бу хәлгә һич гаҗәпләнмим, киресенчә, тузган, таушалган шәһәремә, үз җилкәсендә күп авырлыкларны күтәреп чыкканы өчен, кулымны күкрәгемә куеп, ихтирам белән баш иеп үтәсем килә.

Безнең хәтер кешеләрне аерылышу вакытында ничек күргән булса, шул хәлендә саклый, елларның аларны күпмегә үзгәртүен без яңадан кайтып күргәч кенә беләбез. Дүрт елдан соң кайтып, шушы бер көн эчендә күреп өлгергән таныш-белешләремнең күбесе минем хәтеремдә сакланган элекке сурәтләренә шактый төзәтмәләр кертте. Аларның чырайлары да, үз-үзләрен тотулары да, хәтта өс-башлары да мин уйлаганнан башкачарак булып чыкты; битләрендә җыерчыклар тирәнәйгән, чәчләре көмешләнгән, күзләре эчкәрәк бата төшеп, күп нәрсәләрнең серен белгәндәй, җитди, сабыр карыйлар. Сөйләшкәндә күзгә туры карарга гадәтләнгәннәр һәм үзләре сөйләүдән бигрәк сорашырга, тыңларга ярата төшәләр. Ничектер алар тыштан картаю гына түгел, эчтән олыгайган, рухи чыныккан кебекләр.

Мин, фронттан кайткан кеше булсам да, биредә яшәгән танышларымның шулай үзгәрүләрен күргәч, үз-үземә, тыйнаграк булырга кирәк, дидем. Ихтимал, менә хәзер шәһәрне һәм аның кешеләрен сәяхәтче сыман салкын кан белән күзәтеп йөрүемнең сәбәбе дә шуңардандыр... Ихтимал, бүгенге һаваның да тәэсире юк түгелдер... Ничә әйтсәң дә көз. Ара-тирә кискен генә чиркандыргыч җил исеп куя. Кайсы яктан искәнен дә белеп булмый бу җилнең... тик урам уртасыннан кинәт бөтерелеп тузан күтәрелә, җирдәге вак-төяк чүпләрне әйләндереп, кыштырдатып, кызу гына өереп алып китә, һәм тиз арада бу өермә, каядыр кереп качкан яки бәрелеп таралган шикелле, юкка да чыга. Урам янә тынып кала... Янә берәр чаттан кисәк кенә килеп чыккан очраклы җил биткә килеп бәрелә, итәк чабуларын ачып ташлый.

Күктә, шактый биектә, кара-соры болытлар бер-берсен куа-куа ашыгып агалар. Кайчан алар бер-берсен куып җитәләр дә, аралашып, буталып, күк йөзен тоташ каплап алалар. Кояш күздән югала, шәһәр өсте караңгыланып, һава салкынаеп китә. Кайчак исә ул болытлар бер-берсеннән аерыла башлый. Күктә ачылган зәңгәрлектән янә кояш карый һәм шәһәр өсте кара, якты шәүләләр белән чуарлана.

Мин шәһәрнең иң җанлы, иң төзек урамы буйлап бер очыннан икенче очына кадәр ашыкмыйча гына үттем. Кире борылып килешли миндә бер якын дустымны барып күрү теләге туды. Фронттан кайткан кеше күрешергә үзе башлап барса да, гаептән саналмас, дидем дә, трамвайлар туктый торган урынга таба киттем.

Килеп туктадым, җыелган халыкны караштырам... Хәтеремдә, еллар буенча бер үк маршрутта йөрүче пассажирлар була торган иде. Шуның кебекләр белән көн саен диярлек трамвайда очрашып, танышмасаң да бер-береңә күнегеп бетә торган идең. Ул пассажирлардан кемнәр бар, кемнәр юк икән хәзер?

Шулай уйланып торган чакта каршымда миңа аркасы белән басып торган кечкенәрәк буйлы, җыйнак кына гәүдәле бер ханымга күзем төште. Өстендә аның куе-зәңгәр костюм, башында кар шикелле ак берет, аякларында кара ефәк оеклар өстеннән кигән шундый ук төстәге биек үкчәле модный туфлиләр иде. Бер якка таба аз гына сыгыла биреп басып торган бу җыйнак ханым миндә кинәт зур кызыксыну тудырды. Алдына чыгып, аның йөзенә карыйсым килде. Акрын гына янында үтеп киттем һәм, туктап бераз торгач, борылып аңа карадым. Ничектер, мин карауга ул да миңа карады, тик шул секундта ук карашын читкә борды. Әйе, бу миңа таныш ханым иде. Мин яңадан миңа карамас микән дип бераз көтеп тордым. Ләкин ул, ни өчендер, туп-туры, бары тик трамвай юлы буена карый иде; гүя минем карап торуымны сизсә дә, үзе караудан юри тыела иде.

Шулай да мин аның янына бардым һәм:

— Исәнмесез! — дип баш идем.

Ул җиңелчә гаҗәпсенү белән миңа караган булды. Ләкин аның шулай гаҗәпләнгән булуы мине күреп таныганлыгын, килүемне көтеп торганлыгын күрсәтә иде... Тик сер сынатмас өчен булса кирәк, ул бик аз гына вакыт җавап бирми торды, соңра: «хәзер... хәзер мин сезне таныйм» дияргә теләгәндәй елмайды, сузып кына:

— Исәнмесез! — диде һәм ахырда кызу гына: — Ах, бу сезмени?! — дип, минем исемемне атап, замша перчаткалы кечкенә кулын сузды.

Без сөйләшә башладык. Өстемдә әле погоннары да салынмаган, таушалган шинель булганга күрә, ул миннән кайчан кайтуымны, кайсы фронттан кайтуымны, сугышта күпме йөрүемне һәм тазалыгымны сорашты. Мин очраган һәрбер танышка бирә торган әзер җавапларымны әйтеп чыктым. Ахырда ул сорашуын тәмамлап:

— Сез бик үзгәргәнсез! — диде.

Мин:

— Минем генә үзгәрми калырга хакым юк,— дидем. Ул бу җавапның кинаясен аңлады шикелле, бер сүз дәшмичә тынып калды.

Әйе, мин бу ханымны унбиш-уналты елдан бирле беләм. Беренче мәртәбә күргән вакытымда ул яңа өлгереп җиткән яшь кенә кыз иде. Әле дә хәтеремдә, аның дулкынланып артка яткан аксыл чәчләре, ике якка туры гына сызылып киткән чәченнән тоныграк нечкә кашлары, матур башын ия төшеп, озын керфекләрен югары таба күтәреп, каш астыннан кешегә текәлеп карый торган соры күзләре, киңрәк борынлы түгәрәк бите һәм чак сизелерлек елмаю уйнаган алсу иреннәре... янә шуларның барысын иңбашында назлы гына тотып йөрткән кечерәк буйлы җыйнак гәүдәсе... Һичшиксез, мин беренче очрашкан вакытта ук бу кызга тирән соклану белән караган булырга тиешмен... Хәер, мактанып әйтү булмасын, ул вакытларда мин үзем дә кызларның еш кына серле итеп үземә карап торуларын тотып ала торган бер сылу егет идем. Бу кызның да минем белән никадәр кызыксынуын соры күзләре төбеннән күреп өлгергән идем.

Безгә танышырга кирәк иде һәм без таныштык. Ничек, нинди шартларда булды бу — хәтергә төшереп торуның хәзер кызыгы юк. Һәрхәлдә, танышу ике якның да теләп йөрүе белән булды, ләкин хәзер дә төшенә алмыйм, ни өчендер бу танышлык тирәнәеп, көчәеп, дуслыкка әйләнеп китә алмады. Дөрес, башта, танышуның беренче вакытларында, без еш-еш кына клуб, театр кебек урыннарда очраша идек. Ике арадагы сүзләр дә кайчан йөрәкләрне дулкынлатып алырлык серле, мәгънәле була иде, бер-беребезнең асыл уйларын, чын хисләрен белергә теләп, күзләребезгә дә озак-озак кына карашып торгалый идек. Ихтимал, шул чакларда без бер-беребезгә җан теләгән кешеләр булып күренгәнбездер, йөрәкләребез төбендә мәхәббәт дигән сихри ут менә-менә кабынырга торгандыр, һичшиксез, ул шулай булгандыр — без яшь, без мәхәббәтне теләп, эзләп йөрүчеләр идек. Ләкин —бәхеткә яки бәхетсезлеккә каршымы, хәзер әйтә алмыйм — бездә ул сихри ут кабына алмады һәм безнең арада мәхәббәт тумады... Без бер-беребездән ераклаштык, сукмакларыбыз аерылышкандай, ул каядыр икенче якка, башка кешеләр арасына кереп китте, минем язмышым да икенче берәүләр белән бәйләнде һәм мәхәббәтнең «әчесен-төчесен» башкалар белән татырга туры килде. Тора-бара без бер-беребезне сирәк, елга берничә тапкыр гына күрә башладык, ахырда, баш иеп исәнләшеп үтүчеләр генә булып калдык. Тик ара-тирә менә шулай, трамвай көтү урыннарында очрашканда, электән килгән танышлыкка ихтирам йөзеннән дустанә елмаеп, сөйләшеп тора торган булдык.

Кызык хәл!.. Бу ханымны соңгы мәртәбә кырык беренче елның июлендә фронтка китәсе көнемдә очраткан идем һәм менә фронттан кайтуымның икенче көнендә очраттым. Теге чакта вакыт бик тыгыз иде, очрашу бик ашыгып каядыр барган арада гына булды һәм без бер-ике минуттан артык сөйләшеп тормаганбыздыр. Хәер, нәрсә турында сөйләшәсең? Кырык беренче елның июле иде бит ул, һәркемнең йөзенә чыккан шомлы борчылу хәлләрнең ничек булуын ачык күрсәтә иде... Әйе, әле дә көн кебек хәтеремдә: мин, аның кулын гадәттәгедән катырак итеп кыстым да үз юлым белән китеп бардым... Һәм ни өчендер, бераз киткәч тә, артыма әйләнеп карадым. Шул чакта аның да борылып миңа каравын күрдем. Бу минем өчен һич көтелмәгән нәрсә булды, башта мин уңайсызланып киттем, соңра борчылып уйлана башладым. Чыннан да, аның борылып каравы йөрәгемнең әллә кай җиренә генә барып кагылды... Ни өчен борылып карады ул? — дидем мин, һәм миңа кинәт күңелсез дә, моңсу да булып китте. Гүя ул яңадан бервакытта да мине күрмәячәген сизенеп, шулай борылып карагандыр төсле тоелды миңа... Әйе, мин сугышка китүче, кем белә, бәлкем, мин чыннан да бу урамнан таныш-белешләрем белән соңгы мәртәбә очрашып үтә торганмындыр. Әгәр анда, сугышта, минем белән берәр хәл була калса, соңгы минутларымда күптәнге танышымның бу карашын хәтеремә төшерермен, дип уйладым.

Моннан дүрт ел элек әнә шундый күңелсез уйларга төшереп озаткан иде мине бу җыйнак һәм сөйкемле ханым... Менә хәзер исә бик күп якын танышларым белән күрешергә өлгермәс борын ул очрады, һәм теге вакытта, аның борылып каравын, мин юләргә, яңадан исән-сау күрешү өчен дип юрыйсы калган икән!..

Ни өчендер, мин менә хәзер аңа өр-яңадан танырга теләгәндәй карыйм. Хәер, сугыштан кайткан һәркемнең дөньяга, тормышка, кешеләргә ниндидер яңа сыйфатлар эзләп каравы бик табигый булырга тиеш. Ләкин бу ханымның миңа көтмәгәндә һәм хәтергә сеңеп калыр вакытларда очравы миндә хәзер аеруча бер кызыксыну тудырды. Чыннан да, бу ханым озак еллар буенча минем күз алдымнан югалмады һәм һәрвакыт каршымда да тормады, хәтеремдә дә тота алмадым мин аны, оныта да алмадым. Озын гомер юлында очраган кемнәр генә тора-бара онытылмыйлар! Бигрәк тә, кайчандыр мавыгып йөрүең нәтиҗә бирмәгән, дуслаша алмаган хатын-кыз белән танышлык кыска гомерле булырга тиеш иде, чөнки андый

танышлыкның эзсез генә юкка чыгуын кеше гадәттә үзе тели... Ни өчен соң бу ханым һәм мин, акрынлап булса да, бер-беребезне белмәмешкә салынмадык?

Ниһаять, яшерәсем килми, иртә яшьлегемдә чын күңелдән теләп танышулар, «мин сөям!» дип, үз-үземне ышандырып йөрүләр аз булмады. Ләкин аларның барысы да яшьлеккә хас мавыгу булып кына калдылар, вакыт үтү белән берәм-берәм әкренләп онытылдылар... Күңел хәзер тын күл кебек, һәм мин, үтеп баручы булып, аның ярына килеп бассам, бу күлнең кайчан, нинди җилләрдән дулкынлануын инде хәтерли алмыйм... Ни өчен соң бу ханым да кайчандыр күл өстен җиңелчә генә чуарлап үткән нәфис җилләрнең берсе булып, гомерем сахрасының түренә китеп югалмады? Нигә ул һәр очрашудан соң, хыялым күгендә яңадан табылган ерактагы ялгыз йолдыз шикелле, күңелем күзләрен үзенә тартып торучан булды, соңра янә югалды? Ни сәбәптән мин аерылышып киткән саен аның турында озак кына уйланып һәм аның да минем турыда уйлавын сизеп бара торган булдым; соңра янә оныттым?

Бу хәлләрнең серенә минем ничек төшенәсем килмәсен ди?! Ихтыярсыз мин аңа текәлеп карыйм, гүя хәзерге уйларымның җавабын аның йөзеннән, күзләреннән эзлим, шул ук вакытта, читтән кайтып беренче тапкыр очрашкан кеше булуым сәбәпле, гади генә нәрсәләр турында сорашам:

— Үзегезнең хәлләрегез ничек?

— Рәхмәт, бер килеш кенә торабыз.

— Балаларыгыз үскәннәрдер инде?

Ул минем соравыма гаҗәпсенгәндәй:

— Балам берәү генә ич! — ди.

— Шулаймыни? Ир бала шикелле?

— Әйе.

— Ничә яшьтә?

— Унөч тулды инде, үзем кадәр булды,— ди ул һәм, ни өчендер, бөтен йөзенә җиңел кызыллык йөгерә. Мин аның кечкенә җыйнак гәүдәсенә карыйм да ни өчен кызарганын аңлаган кебек булам һәм шул ук секундта «кечкенә буйлы аналар улларын аеруча ярата торганнардыр» дип уйлап куям. Кинәт минем абыйсы шикелле якын, үз кеше булып аның эчке тормышы хакында сорашасым килә. Ләкин мин җөрьәт итә алмыйм, мин билгеле бер әдәп сакларга кирәклекне хәтеремнән чыгармыйм, ниһаять, аның эчке тормышы миңа шундый билгесез ки, мин күңелемә килгән беренче сорауны ничек итеп бирергә белмичә уңайсызланып калам. Шулай да җәрәхәтле урынына сугылмагаем иде дип, сакланып кына сорыйм:

— Гафу итегез, ирегез мондамы?

— Әйе, монда, бер заводта эшли.

— Фронтта булдымы, юкмы?

— Юк, булмады.

Үзем дә сизмәстән:

— Сез бәхетле икәнсез! — дим.

Ул, «ни өчен» дияргә теләгәндәй, чак сизелерлек итеп, сыңар иңбашын күтәреп куя һәм бу сүзләремнең бернинди арткы уйсыз әйтелүенә ышанмагандай:

— Ул үзе китәргә теләгән иде дә, җибәрмәделәр,— ди.

Чыннан да, бу ханым, бәлкем, минем кебек фронттан кайтучылар фронтка бармый калучыларга көнләшеп, яратмыйча карыйлардыр дип уйлый торгандыр. Мин, аның башына шундый уй килә күрмәсен дип, сүзләремнең саф күңелдән әйтелгән булуын тизрәк белдерергә ашыгам:

— Җибәрмичә яхшы иткәннәр, чын-чын! Бөтен кешегә дә фронтка китәргә димәгән бит... Үзегез беләсез, ул мөмкин дә түгел... Сез бәхетле икәнсез, дидем, чөнки сезнең авыр борчуларга төшмичә калуыгызга куандым. Кем белә, бәлкем, сез олы хәсрәттән котылып калгансыздыр.

Ул дәшмәде. Ул уйчан күзләре белән тутырып миңа бер карап кына алды. Бу минутта аның күңелендә нинди уйлар икән? Мин аның тыныч, тик чак сизелерлек моңсу җәелгән йөзенә никадәр текәлеп карасам да, бер, нәрсә дә күрә, сизә алмыйм. Уема төрле шикләр килә. Ирләрен сугыш куркынычы эченә җибәрмәгән, алар өчен борчылып, кайгырып тормаган, аларның исән-сау кайтуын сагынып көтмәгән хатыннар, бәлкем, мондый чын күңелдән әйтелгән сүзләрне йөрәкләренә якын ала да белмиләрдер? Ә бәлкем, минем сүзләремә һаман шаярып кына әйтелгән сүзләр дип карый торгандыр? Аның дәшми торуыннан шактый уңайсыз хәлдә калам, бераз тик торганнан соң, янә акрын гына дәшәм:

— Гафу итегез, ихтимал, мин урынсыз сүз әйткәнмендер, ләкин ышаныгыз, чын күңелемнән әйткән идем.

Ул, нindидер борчылулы уйдан арынган шикелле, ашыгып:

— А, рәхмәт сезгә! — ди һәм эчке бер нурдан яктыргандай ачылып китә, һич тарсынусыз юмарт итеп елмая, хәтта бит урталары нәкъ кыз вакытындагы шикелле чокыраеп куя. Белсәң иде, нинди уйларның күләгәсе һәм яктысы аның йөзеннән шулай шуып үтте икән!.. Ләкин, әйтәсе дә юк, аның бу нурланып елмаюы мине чын-чыннан сөендерде, ә шикләрем исә җиңел төтен шикелле берьюлы каядыр таралып киттеләр. Аның бик бәхетле булуына ышанасым килде, башка сораулар бирәсем килмичә, бары тик аның турында матур итеп уйлыйсым гына килде... Инде ул утыз яшьтән узган хатын — мин аның маңгаендагы,

күз төпләрендәге вак кына җыерчыкларын күреп торам. Хәтта күңелемә «кешенең иреннәре дә картая ахрысы» дигән уй килә, чөнки кайчандыр, яңа ачылган чәчәк төсле булып хәтеремә сеңеп калган алсу иреннәре өстенә нечкә генә сызыклар төшкәннәр... Ләкин мин аның йөрәге төбендә бервакытта да сүнми торган мәхәббәт уты яшәвен тоям шикелле... Ул һәрвакыт сулмас гүзәл, тигез җылы итеп сөя белә һәм ләззәтле эреп сөелә белә торгандыр кебек... Үзе дә, ире дә бик бәхетлеләрдер дип ышанасы килә... Белмәгән көе болай уйлау гаҗәп тә тоелыр, ләкин була бит дөньяда шундый кешеләр, карау белән аларның бәхетле булуларына ничектер ышанасың да куясың!

Ул минем нинди уйлар белән үзенә сокланып карап торуымны сизенде булса кирәк — йөзенә янә кызыллык чыкты, башын читкә борды, кулындагы ридикюлен ачып, кечкенә ак кульяулыгын чыгарды һәм мин нечкә бер хуш иснең йөземә бөркелүен тойдым. Соңра, минем һаман сүзсез булуымны килештермәде, ахрысы, үзе башлап сүз кушты:

— Фронттан кайткан танышларымны очратсам, миңа әллә ничек уңайсыз булып китә.

— Ни өчен?

— Сез шулкадәр авырлыклар, газаплар күргәнсез...

— Ә сез биредә ансат һәм рәхәт тордыгызмыни?

— Юк, әлбәттә.

— Шулай булгач?

— Ләкин сез күргәннәрне без күргәннәр белән чагыштырып буламыни?! — диде ул һәм күкрәге өстенә салынган кара ефәк кашнесының бер очын, ачылып торган муенын уратып, артка ташлады. Бары хәзер генә мин костюмының сул ягына кадаган ике тар гына медаль билгесен күреп алдым һәм аның минем белән никадәр тыйнак, кечелекле булып сөйләшүенә чын-чынлап гаҗәпләнә калдым... Ничектер үзем дә сизмәстән:

— Нур өстенә нур,— дип әйтеп ташладым һәм бармагым белән күрсәтеп: — Менә бу кадерле билгеләрне сезгә бушка гына бирмәгәннәрдер, һәм тегеннән кайтып сезнең белән очрашкан танышларыгыз, менә безнең җиңеп кайтуның сәбәпчеләреннән берсе шушы ханым икән, дип эчләреннән әйтә торганнардыр,— дидем.

Ул сөенеп минем күзләремә туры карады һәм ашыгып:

— Әгәр минем турыда шулай уйлаучылар булса, чын күңелемнән рәхмәт аларга! — диде.

Шул арада чаттан трамвай да килеп чыкты. Вакытсызрак килде ул килүен, ләкин чара юк, китәргә кирәк иде.

— Сез кайсы якка? — дидем мин.

— Мин каршы якка...— диде ул һәм бик кыска гына паузадан соң: — Ирем янына клиникага барам,— дип өстәп куйды.

Минем бик үк аңлап бетмичә каравымны күргәч, ул янә тавышын акрынайта төшеп:

— Икенче ай авырый инде,— диде.

— Шулаймыни?.. Нәрсә булды соң?

Ул аз гына көттереп җавап бирде:

— Ашказанына операция булган иде...

— Кызганыч! Хәле ничек соң?

— Рәхмәт! Яхшыра инде.

Хәзер генә мин бая аның йөзенә нинди хисләрнең яктысы һәм күләгәсе калкып чыгуын аңладым. Әйе, тормышта һәркем өчен шатлык та, хәсрәт тә була торган нәрсәләр.

Ул, ике арада туа башлаган уңайсыз тынып калуны булдырмаска теләгәндәй, көлемсерәп:

— Аның янына баргач сөйләргә яңа хәбәрем булды,—диде.

— Гафу итегез, нинди яңа хәбәр ул?

— Фронттан кайткан янә бер танышымны очраттым диярмен.

— Андый игътибарга лаек булуым өчен шатмын. Таныш булмасак та, миннән үзенә сәлам әйтегез.

— Рәхмәт, әйтермен, әлбәттә.

Килеп туктаган трамвайга кешеләр ашыгып керәләр иде. Миңа да кузгалырга вакыт җитте.

— Яхшы, хәзергә хушыгыз!

— Хушыгыз!

Ул перчаткасын салып миңа кулын бирде.

Мин трамвайга утырдым. Эчкә үтмичә, площадкада, тыгызланып тулган халык арасында тукталдым һәм артыма борылып карадым. Кузгалып киткән трамвайдан аның әле елмаюы китеп бетмәгән йөзен һәм минем тарафка карап торуын күрдем.

Табигый инде, трамвайга утырып китсәм дә, мин уйларым белән аңардан аерыла алмадым. Яшерәсе юк: бу очрашу мине бик тирәнтен дулкынлатып өлгерде һәм минем үз-үземне сәяхәтче сыман тоеп маташуларымны берьюлы юкка чыгарды. Юк, мин торган шәһәремә генә түгел, бирелә үткәргән гомеремә кайтканмын икән. Менә ул үткән гомернең бер онытыла язган сәхифәсе ачылды, һәм вакыт үтү белән

саргая башлаган бу сәхифәнең юллары арасыннан моңарчы миңа билгеле булмаган яңа мәгънә табылган кебек булды.

Күкрәгемә тулган хисләр яктысында мин бу яңа мәгънәне аңларга тырышам. Нәрсә соң ул?

Менә моннан берничә минут кына элек каршымда басып торган ул ханымның җанлы кыяфәтеннән күңел күзләремне аерып ала алмыйча эчемнән аңа дәшәм: «Сөекле ханым, кем сез миңа? Ни өчен сезнең тыйнак сүзләрегез, күптән онытылып, яңадан хәтергә төшкән тансык көй шикелле, колагым төбендә яңгырадылар? Ни өчен сезнең дустанә карашыгыз яшьлегемдә беренче тапкыр очраткан сөю карашы төсле булып йөрәгемә иңде?.. Нинди кодрәт белән әле сез минем тыныч яткан күңелем күлен якты дулкыннар белән бизәп өлгердегез?» Һәм мин сакланып кына, гүя акылымның ачуы килеп, күкрәгемдә яңа гына бөреләнгән хисләрне качырмасын өчен, курка-курка гына «мәхәббәт!» дим. Әйе, мәхәббәт! Бик күптән әйтелмәгән бу сихри сүзнең чын булуына ышанасым килепме яки аның бөтен хыялый ләззәтен татырга теләпме, мин янә тәкрарлыйм: «Мәхәббәт!»

Ләкин ни өчен, ни сәбәптән мин аны, ул мәхәббәтне, менә хәзер тойдым, таптым?.. Бәлкем, ул ханым хәзер миңа бөтенләй башка, әүвәлгегә һич охшамаган сурәттә күренгәндер?.. Юк, бу бик үк дөрес түгел. Кеше күпме генә үзгәрмәсен — әүвәлге сыйфатларын бервакытта да җуеп бетерми. Шик юк, ул хәзер картая төшкән, ләкин мин аның йөзендә беренче мәртәбә очраткан кызымның чыраен күрмиммени?! Хәзер ул шактый сабырлана, тыйнаклана төшкән, ләкин мин аның нәфис кыз чагындагы рухи нечкәлеген, күңеле пакьлеген сизмиммени?! Ә шулай да «мәхәббәт» дию\ем ни өчендер теге вакытта түгел, ә менә хәзер телемә килде. Күрәсең, озак еллар буена йөрәктә сизелмичә сакланып яткан мәхәббәт тойгысын һич уйламаганда тоеп, табып алу өчен ниндидер яңа шартлар кирәк булган. Әйе, бу шулай!

Чыннан да мин бүген кем, кайда мин? Минем өстемдә ерак илләрнең тузаннарын иялтеп кайткан соры шинель, хыялымда әле күптән түгел генә миннән торып калган ят шәһәрләрнең, ят авылларның, ят кырлар һәм юлларның матур да, ямьсез дә, төзек тә, җимерек тә, куанычлы да, шомлы да булган күренешләре... Һәм менә мин, кичә генә кайтып төшкән солдат, дүрт елдан соң бүген беренче мәртәбә аны — җыйнак гәүдәле, сөйкемле чырайлы, уйчан карашлы кечкенә ханымны очраттым. «Ах, менә ничек! — дим мин, кинәт бөтенесен бик ачык аңлап.—Дүрт ел буена фронтта йөреп кайтуым кирәк булган икән. Сугыштан кайтуым, сугышны бетереп, тере булып кайтуым кирәк булган икән!.. Әйе, әйе, әгәр мин траншея пычракларында аунамаган булсам, бозлы суларны кичеп чыкмаган булсам, үлемнең сөяк кулларын бугазымнан каерып ташламаган булсам, менә хәзер мәхәббәт дигән ул олы тойгының мөкатдәс орлыгын бәгыремнең җанлы төере шикелле итеп тоя алган булыр идеммени?!»

Сүз юк, хәзерге минутта кичергән бу тойгыларым миндә сер булып калыр. Ул ханымның үзенә түгел, дус-ишләремнән кемгә дә булса мин аны бервакытта да, әлбәттә, ачмаячакмын. Әйдә, хәзер тапканым үзем өчен генә эчке юанычым, сөенечем булып калсын! Әгәр ул ханым белән яңадан очрашырга туры килсә, мин аның якты йөзе, әдәпле кыланышы, ирен, баласын сөйгән саф, сизгер йөрәге, ил күрке була алырлык намуслы эшчәнлеге алдында тирән ихтирам белән башымны гына иярмен.

Әмма ул ханымга бу минутта мин кат-кат рәхмәт әйтүдән тыела алмыйм. Гүя ул мине кулларымнан җитәкләп, яшьлегем бакчасына алып керде. Мин чәчәкләрнең исен беренче тапкыр нечкәреп сөенер өчен иснәгән вакытларымны, кошлар сайравыннан беренче тапкыр рухланып канатланган чакларымны, һәр туган язның алсу иртәсе гомерем иртәсе булып күренгән яшьлек елларымны хәтеремә төшердем. Алар исә — ул вакытлар, ул тойгылар — барысы да менә шушы шәһәрдә, шушы шәһәрне чорнаган һавада, шушы шәһәрнең җире, суы, урманнарында, ниһаять, шушы шәһәрнең, сөекле ханым, сезнең шикелле яшьләре арасында туган иде. Йә, сугыш михнәтләрен күптән түгел генә артта калдырып, кичәгенәк кенә әле шәһәремә аяк баскан мин ничек итеп:

— Илем минем — гомерем минем! Үткәнем генә түгел, киләчәк тормышым, бәхетем, мәхәббәтем дә бары синең изге туфрагыңда! — дип, яңадан бер тапкыр иманымны беркетеп куймыйм ди?!

1946

# Тауларга карап

## I

Сугыш беткән елның коры, аяз көзе иде. Соңлап кына фронттан кайткан бер егет, кечкенә төенчек күтәреп, Локман картларга күрешә килде. Менә ул артка таба ава биреп торган капкадан иркен генә ишегалдына керде.

Әйе, монда барысы да аңа бик таныш, әмма... барысы да шулхәтле үзгәрер икән!.. Ишегалдын тоташ чүп үләне басып киткән, әле күптәнме җыйнак-таза гына өй искергән, тузган, ничектер мескенәеп, кечерәеп калган; абзар-куралар ташландык хәлендә... Бөтен ихатага ниндидер бер ятимлек, сүлпәнлек, боеклык яткан кебек... Егет бер мәлгә туктала, сәерсенеп тирә-ягына карана, колак салып тора. Тынлык, шылт иткән тавыш юк, тик кипкән үлән арасында ялгыз чикерткә ялкау гына чырылдый... Егет кузгалып

китә, чалышайган ишектән иелеп караңгы өйалдына керә, капшанып ишекне таба һәм аз гына ача төшеп, каты гына тамак кыра:

— Эһем, эһем... ярыймы?

Җавап бирүче булмый, ул өйгә керә, идән уртасына уза. Шунда гына мич алдыннан егет каршысына Шәмсинур әби ак чәчләрен яулыгы астына сыпырып кертә-кертә килеп чыга.

— Исәнме, Шәмсинур әби, исән-сау гынамы сез?!

Шәмсинур әби танымыйча карый:

— Кем соң син, улым?

— Бу мин, Шәмсинур әби, Әхмәтвәли булам.

— Кем?

— Әхмәтвәли, дим.

— Әхмәтвәли?! Гайниҗамалның Әхмәтвәлиеме?

— Әйе, нәкъ үзе, Шәмсинур әби.

— Ай Аллам! — ди карчык, җанланып китеп.— Карасана, танымый да торам ласа, Әхмәтвәли бәбкәм, син икәнсең... Исән-сау гына кайттыңмы соң?

— Шөкер әле, Шәмсинур әби, сезнең хәер-фатихада менә йөреп кайттык.

— Ярый, ярый, бирсен Алла, Гайниҗамал бичара бик тә куангандыр инде. Менә бит ул исән кеше башлары —бер кайтмаса, бер кайта.

Карчык мич каршындагы сәке түрендә башыннан ук сары тун каплап йоклап яткан картына үреләә:

— Син, сиңа әйтәм, тор әле, Әхмәтвәли кайткан бит. Сары тун селкенми, карчык сәкегә тезләнеп этәрә башлый:

— Карале, сиңа әйтәм, Әхмәтвәли кайткан, әнә безгә килде. Тор әле, бу нинди йоклавың инде... Көпә-көндез... Картайды шул, бик картайды...

Ахырда сары тунның чабуы ачыла, һәм Локман карт терсәгенә таянып башын күтәрә. Ул каршында басып торган хәрби киемле ят кешене күргәч, куркып киткәндәй, күзләрен зур ачып, сүзсез карап тора.

— Исәнме, Локман бабай! — ди егет, аңа юмарт елмаеп.

— Кем бу? — ди карт, һаман күзләрен түгәрәкләндереп.

— Әхмәтвәли бит инде, танымыйсыңмыни, үзебезнең Әхмәтвәли, Гайниҗамал киленнең Әхмәтвәлие.

Карт авызын ача:

— Ә-ә-ә... Әхмәтвәли, мәрхүм Әхмәтгәрәйнең Әхмәтвәлиемени бу? Алай-й.

Ул ике кулына таянып, озын аякларын тезләреннән бөгеп, шуып кына сәке кырыена килә. Әхмәтвәли төенчеген өстәлгә куеп, ике куллап үзләре белән күрешә. Карт белән карчык битләрен сыйпап алалар. Аннан Шәмсинур әби калтыранган тавышы белән сөйләнә башлый:

— Әй Әхмәтвәли улым, үз балабыз кебек якын бит син безгә, Батырҗаныбызның якын иптәше идең бит син... Бергә үстегез, бергә киттегез. Менә гомерең булгач син кайттың, ә ул...

Карчык сүзен әйтеп бетерә алмый, ике күзеннән мөлдерәп агып киткән яшьләрен туктатыр өчен йөзен яулыгы белән каплый һәм кыска гына итеп сулап куя:

— Уф Аллам!

Ә карт зур, хәлсез кулларын өстәлгә сузып салган да, шул кулларына карап, тик кенә утыра. Йокысыннан һаман әле айнып җитмәгәнме ул, кем килгәнен, ни өчен килгәнен аңлап җиткермәгәнме,— ләкин аның бу кадәр ваемсыз тынып утыруын аңлавы читен иде. Әхмәтвәли, картка карап, аның күпме картайган, өшәнгән булуына гына түгел, бигрәк тә менә шулай, яшен суккан агачтай, сүнеп калуына гаҗәпләнә иде. «Әйе,— диде ул эченнән,—хәсрәт кешене нишләтә!» ...Батырҗанның үлеп калганын, кайтмаячагын ул фронтта чакта ук кыр госпиталендә эшләүче Сания исемле бер кыздан килгән хат аша ишетеп белгән иде. «Үз кулларымда җан бирде шул, бәгырькәем!» — дип өзгәләнеп язган иде ул кыз аңа, һәм бу сүзләр егет белән кыз арасында ниндидер бер тирән якынлык булганлыгын сиздергән иде. Ләкин Әхмәтвәли ул чагында монысына артык әһәмият биреп тормады, чөнки кече яшьтән үк бергә үскән якын дустын югалтудан ул бер хәсрәтләнсә, менә бу картларны уйлап өчләтә хәсрәтләнгән иде.

Шуңа күрә Батырҗан турында менә хәзер сүз алып баруы да аның өчен бик авыр иде: ничек итеп бу ике ятимнең ачык ярасына кагыласың? Ул хәтта юатыр өчен әйтергә уйлап килгән сүзләрен дә онытып җибәрде һәм аптырауга төшеп өй эченнән бер күз йөртеп чыкты. Бик таныш иде бу өй эче, әнә теге почмактагы кечкенә өстәл янында ул Батырҗан белән күпме сөйләшеп утырмады, әнә Батырҗанның үз кулы белән җыйнак кына итеп эшләп куйган ике катлы киштәдәге китапларын алар күпме тапкырлар актарып, укып карамадылар, әнә теге өстәл өстендә торган кызыл тышлы патефонны ничаклы гына уйнатмадылар! Бар нәрсә искечә, бөтен әйбер үз урынында, ләкин алар барысы да авыр сагыш сөреме белән өртелгәннәр, гүя алар да гомерлек ятимлеккә дучар ителгәннәр иде.

«Әйе, зур югалту хәсрәте карт белән карчыкка гына түгел, өй эчендә дә сарышып өлгергән икән»,— дип уйлап алды Әхмәтвәли, һәм аңа бу салынкы, тын хәсрәт сөреме бик, бик авыр булып тоелды. Ихтимал, картлар үзләре моңа ияләшеп тә өлгергәннәрдер, әмма фронттан кайткан солдат җаны моның белән һич килешә алачак түгел иде.

«Юк! Бу сөремне ничек тә куарга, таратырга, бетерергә кирәк»,— диде ахырда Әхмәтвәли башын чайкап һәм солдат гадәтенчә бик нечкәләп тормыйча, аз гына кабалана төшеп, күңеленә килгән сүзләрне сөйләп китте:

— Сезгә бик авыр инде, әйтәсе дә түгел, мин аңлыйм моны... Батырҗан урынына үзем ятып калган булыр идем дә бит, тик безнең теләктән генә тормый шул. Әйе, күпләргә, бик күпләргә ачы хәсрәт килде. Ләкин ни булса ул, менә сугыш бетте әле, дошманның муенын астына китердек, шуңа куанырга кирәк... Дошман бик явыз, бик әшәке булып чыкты. Ай-һай аның кылган явызлыклары — сөйләп кенә бетерәсе түгел. Баланы бала, картны карт дип тормадылар бит ул ерткычлар. Менә шундый бәдбәхет дошманнан илне коткарып калдык. Бу — әйтергә генә ансат. Әйе, әле карыйм-торам, сез сау-сәламәт икәнсез, бер көе тыныч кына торасыз икән, колхоз үзегезне карый булса кирәк... Әгәр шуннан сугыш без дигәнчә бетмәсә, бик яман булыр иде бит, ә? Локман бабай, дөрес түгелме?

Локман карт башын аз гына күтәреп, боз салкынлыгы бәреп торган тонык күзләре белән Әхмәтвәлигә текәлеп карады, салынкы иреннәрен акрын гына кыймылдатып куйды, тик бер сүз дә әйтә алмады... Әйтә алмады, чөнки картның йөрәгендә «дошман» дигән сүз кузгаткан усал тойгы тел белән генә әйтеп бирерлек түгел иде. Һәм Әхмәтвәли әнә шул боз салкынлыгы бөркеп, үзенә төбәлгән күзләрдән, картның эчендә бөтен нәрсә көеп бетсә дә, әмма Батырҗанын тартып алган дошманга карата мәрхәмәтсез ачу, тирән нәфрәтнең беркайчан да бетмәячәген, тере булып ятачагын бик ачык аңлап алды.

— Менә шул шул! — диде Әхмәтвәли, картның әйтә алмаган сүзен раслап.— Әле без бәхетле кешеләр булып чыктык. Башка төшкән хәсрәтләр ничаклы зур булса да, шатланырга, шөкер итәргә урыныбыз бар... Шулай түгелме, Шәмсинур əби?

Карчык ике куллап яулыгын рәтли дә җиңел генә бер көрсенеп куя:

— Әй, Әхмәтвәли генәм, ничек шөкраналар кылмыйсың ди. Тома ятим калдык, үлем түшәгенә ятар вакытларыбыз җиткән. Йә, шуннан колхоз карамаса, авыл кайгыртмаса нишләр идек без, кая барыр идек, кемгә сыеныр идек. Юк, юк, ул җәһәттән, Әхмәтвәли балам, зарыбыз юк, бик ризабыз... Әмма — карчык азга гына туктала, гүя бугазына килгән яшьне йотарга тырыша.— Әмма авыр шул, бик тә авыр... Күңелебез китек, башыбыз вәйран, тиле кәккүк булып беттек инде... Бер дә онargt алмыйбыз үзен, бер дә оныта алмыйбыз шул, Әхмәтвәли генәм... Бердәнбер ул үстердек, ул китте — югалды. Менә аңардан калган баланы, Батырҗаныбызны, күз алмасыдай карап үстердек, инде ул да...

Карчык сүзен әйтеп бетерә алмый — янә бөгелеп төшә, мул булып коелган яшьләрен тыя алмыйча һәм тыярга да теләмичә тавыш-тынсыз гына елый.

Әхмәтвәли иреннәрен кыса, башын иеп маңгаен ышкый.

Шул чакта Локман карт, үзалдына әйткәндәй, сүнгән тавыш белән акрын гына:

— Кайтмады шул, нишләтәсең аны!..— дип куйды.

Әхмәтвәли картның сүзләреннән әллә ничек өшеп, калтыранып китте. Тирән бер гаҗизлек белән әйтелгән бу сүзләрдә кайтмый калган кешегә балаларча үпкәләү ишетелгән кебек булды аңа...

Тагын шактый утырып, булдыра алган кадәр үзләрен юатып, алып килгән чәй, шикәрен Шәмсинур әбинең кулына биреп чыгып киткәч тә Әхмәтвәли Локман картның әнә шул йөрәкне өшетерлек сүзләреннән арына алмады.

Дүрт ел буена сугыш эчендә кайнап, күпме авырлыклар күреп, ниһаять, җиңү шатлыгы белән очынып, дөньяда иң бәхетле кеше булып кайтса да, ул сугышның әле күпме кешеләр йөрәгендә тиз генә төзәлмәс авыр яра калдыруын аеруча бер тирәнлек белән тойды... Аның бу ятим карт белән карчыкка бик, бик изгелек күрсәтәсе килде. «Ах, Батырҗанны алыштырып булса иде!» — диде ул, чын-чыннан көрсенеп, әмма бу ихлас теләкнең бары коры теләк кенә булуын яхшы белгәнгә күрә шунда ук: «Батырҗанның үзе була алмасам да, аларның хәлләрен ничек тә җиңеләйтергә, бу салкын, караңгы бушлыктан үзләрен чыгарырга, җан өрергә, яңадан терелтергә кирәк»,— дип уйлады.

## II

Әмма Локман карт тәнгә күпме генә какшаган, рухы нихәтле генә бушап калган кеше булмасын, тирә-юньдәге тере тормышны тоюдан, кешеләр белән кызыксынудан бөтенләй үк әле мәхрүм түгел иде. Сугыштан соң килгән бу беренче көздә авыл шактый җанланып, көязләнеп, хәтта яктырып китте. Исән-сау калган кешеләрнең күбесе фронттан кайтканга күрә, урамнарда ир-ат күбәйде, кызу кулдан туй уйнатып алучылар да булгалады. Бигрәк тә колхозда быел көзге эшләр зур рух күтәренкелеге белән бик дәррәү бара иде. Кайткан ирләр борынгыча төп эшләрдә дилбегәне үз кулларына алдылар. Ындырларда молотилка артына алар баскач, көлтәләрне алар ташып, эскертләрне алар өя башлагач, ашлык сугу бөтенесе өчен — аеруча хатын-кызлар өчен — иртәдән кичкә кадәр уен-көлке белән уза торган бәйрәмгә охшап китте. Көзге чәчүгә дә ирләр чыктылар, дәүләткә ашлык тапшырырга да шинель өстеннән плащ кигән егетләр ат башында бара башладылар.

Локман карт боларның барысын да күрмичә һәм, күреп, зәгыйфь йөрәге белән җилкенмичә кала алмады, билгеле. Шуның өстенә Әхмәтвәли дә аларны «тынычлыкта» калдырмады, һаман килә, килгән саен нинди дә булса эш таба, юньләп утырып та тормый һәм өй эчен тутырып бер шаулый-шаулый да

кыргамы, ындыргамы чыгып чаба иде... Кыска арада абзар түбәсе дә ябылып өлгерде, чалкан аварга маташкан капка да яңадан аягына басты. Әхмәтвәли кушуы буенча өйнең нигезенә туфрак та салып киттеләр, утын да китереп аудардылар.

Ихтыярсыз Локман картка торырга, чыгарга, анда-монда баргаларга, кешеләр белән аралашырга туры килде. Ул үзе үк чыгып, «тагын берәр юнәйтәсе урын калмады микән?» дигән төсле, өй тирәсен әйләнгәләп, анысын-монысын тотып, капшап йөри башлады. Аннары, бер чыккач, якынрак ындырга да, фермага да, тимерчелеккә дә япа-ялгыз гына, таягы артыннан акрын гына ияреп, барып кайткалый торган булды.

Юк, дөньяның «ашын ашаган, яшен яшәгән» ялгыз кунагы булып кына яшәргә иртәрәк икән әле, хәрәкәт кирәк икән аңа, кешеләр белән бергә булу кирәк икән. Һәм, бик табигый буларак, аның гомере буе тик тормаган куллары тагын эш сорап кычыта башлады...

Ләкин кешеләр, ни өчендер, олы хәсрәт кичергән картка карата чын кайгыртучанлык күрсәтү — ул да булса аны һәртөрле эш-мәшәкатьтән азат итү дип уйлыйлар иде. Хәлбуки аларның бу ихлас яхшылыклары сынык күңелле картның ятимлеген генә көчәйтә иде.

Менә бүген дә ул ялгыз — бөтен авыл халкы ындырларга, кырларга китеп беттеләр, ә ул бер читтә торып калды. Иртә таң белән колхоз ихатасына барып, бригадирлар тирәсендә әйләнеп-тулганып йөрде дә кире өенә кайтырга мәҗбүр булды. Бригадирларның кайсы шаяртып, кайсы җитди итеп аңа:

— Локман бабакай, синең түрдә генә утыра торган чагың, эш дип борчылып йөрмә!

— Эшне әле монда сусап кайткан егетләргә дә җиткерер хәл юк.

— Эш бездән, киңәш синнән, бабакай!

— Ял ит әле, карт, ял ит, эшләгәнеңнең игелеген күр!..

— Ярамый, Локман бабай, ярамый, сине дә эшкә җиксәк, оятыбызга көч килер, Батырҗан мәрхүмнән яхшы түгел...— диләр.

Моңа каршы карт ни дисен, олылап хөрмәтләүләре өчен рәхмәттән башка нәрсә әйтә алсын? Батырҗаннан, аның газизе Батырҗаннан яхшысынмыйлар бит, рәхмәт төшкерләре!

Ләкин шулай да аңа авыр, ах, белмиләр генә, үз башына, бары үзенең уйлары белән генә ялгыз торып калу ничек авыр аңа...

Авыр сагыш баса аны, күңелендә аның көзен бушап калган кырлар өстендә була торган моңсу тынлык урнаша, ялкау гына уйлана ул, уйлана... Һәм, ихтыярсыздан, татлы-газаплы истәлекләр иркенә бирелә...

Аеруча мондый хәл аңарда көн менә бүгенгедәй матур, авыл урамы буш, берәү дә килмәгән, күренмәгән чакта була.

Мондый көнне Локман карт сары тунын киеп, капка төбенә чыгып, шомарып беткән зур ак таш өстенә иплән кенә утыра. Ул шулай кулларын җиңнәре эченә тыгып, аркасын кояшка куеп, җылынып утырырга ярата. Көзнең үзенә генә хас шундый кабатланмас җылы, тымызык көннәре була. Кояшның дәртләнеп балкуы, күкнең биек, сыек-зәңгәр булуы белән ул үтеп киткән җәйге көннәрне дә хәтерләтә. Әмма әйләнә-юньдәге хәрәкәтсез тынлык, шул тынлыкта табигатьнең күзен йомган, иңбашларын салындырган шикелле оеп утыруы, офыкларның күк белән тоташмыйча каядыр шунда үзеннән-үзе эреп югалуы бу көннең кичегеп килгән соңгы, кабатланмас бер көн булуын әйтеп тора. Һәм Локман карт та мондый көнне җәйгечә кыздырып җибәргән кояштан эреп, рәхәтләнеп тик кенә утыра. Аның тирәсендә каяндыр терелеп чыккан ялгыз чуар күбәләк талпынып очына. Шул күбәләктәй аның уйлары да терелеп, акрын гына талпына башлый...

Әнә каршыдагы таулар артыннан ак читле күксел болытлар бер-бер артлы ашыкмыйча гына йөзеп чыгалар һәм аларның күләгәләре йомры түбәләр өстеннән тын гына шуып үтәләр. Әйе, күләгәләр шуып үтә, гомерләр шулай акрын гына сизелмичә үтеп китә... Аркасын кояшка куеп, ак таш өстенә утырган картның тын, буш күңеле түрендә ниләр генә уянмый. Еракта, бик еракта торып калган хатирәләр әнә шул таулар артыннан чыккан ак болытлар кәрванысыдай аның хыялы күгеннән йөзеп үтәләр. Бер мәлгә нәкъ бүгенгедәй аның яшьлеге күз алдына килә...

Нәкъ бүгенгедәй, әйтик, моннан илле-алтмыш ел элек тә, тезелешеп киткән таулар итәге буйлап кечкенә елгачык агып килә иде. Елгачык чуерташлар өстеннән сырлана-сырлана йөгерә, тик яр култыгына кергән урыннарда гына ул тирәнәеп китә, караңгылана төшкән чырай белән ашыкмыйча, уймакланып ага.

Бер яктырып-сырланып, бер караңгыланып-уймакланып алга чапкан елгачык тауларга якын ук килә, һәм тау аның өстендә, пәһлеван шикелле, текә-горур басып тора; йә ул таулардан читкә кача һәм тау чәчәкле итәген аның чылтыр-чылтыр көлгән йөзе алдына җәеп сала.

Әнә шулай бик ерактан дәртле уйнаклап, боргаланып кызу гына килгән елгачык, авыл турына җиткәч, акрынлап киңәя, тирәнәя, салмак-сабыр гына ага торган бер елга булып китә. Анда — буа. Буаның уң ягында текә кызыл яр, сул ягында, карт имән ышыгында, салам түбәле, бер якка кыйшая төшкән карсак кына тегермән тора.

Менә шул тегермәндә Локман карт үзенең бала чагын, егет елларын, бөтен аңлы гомерен уздырды. Дөрес, атасыннан мирас булып калган бу кечкенә, бер ташлы тегермән колхоз көннәренә килеп җиткәнчегә кадәр атсыз агайлар, тол карчыклар тегермәне булудан уза алмады. Шуңа күрә карт, «кирәк

оны» гына җитмәгәч, язын-җәен нәрәтә белән балык аулап, кышын җәнлеккә капкын куеп авылның исемле сунарчысы да булып яшәде. Әмма ерак бабалары беренче килеп аяк баскан бу җирләргә, алар башлап буган бу елгачыкка ул барлык җаны-тәне белән бәйләнгән иде һәм буаның өзлексез шаулавы буыннан-буынга күчеп килгән көйле әкият булып аның күңеленә сеңгән иде. Менә шушы ак таш яткан җирдән буага атасы йөреп салган сукмакны ул сиксән ел буена таптады, һәм, аның исәбенчә, бу сукмакны беркайчан да үлән басып китмәскә тиеш иде.

**III**

Локман карт утызлардан узгач кына Шәмсинур карчыгын үзенең ялгыз өенә француз бөркәнчек ябынган яшь килен итеп төшерде. Мәхәббәт дигән нәрсә никахтан соң гына килсә дә, алар бик тату, дус яшәделәр. Шәмсинур Локманга бер-бер артлы дүрт кыз бала табып бирде. Ләкин ел саен авылга килгән кара үләт — чәчәк авыруы сабыйларны бик иртә кабергә дә алып китә торды. (Карт хәтерендә ул сабыйларның бары тик исемнәре генә саклана...) Ниһаять, Шәмсинур бала сагышына дучар булган таза, тынгысыз иренә бер ир бала да бүләк итте. Бу бала һичбер нинди авыруга бирешмичә үсәргә тиеш иде; һәм аңа Тимерҗан исеме куштылар.

Ир бала! Менә бу елганың башы ул, җирдән бәреп чыккан саф, көмеш чишмә ул. Бу елганың буалар аша сикереп һаман алга чапкан дәвамы ул. Әйе, әти кеше ир баланың үзе өчен кем булуын яхшы белә һәм бөтен киләчәк өметләрен Тимерҗанына баглый. Әмма менә хәзер ул Тимерҗанын бик тонык кына күз алдына китерә ала. Бик ерактан, гомере түреннән сөлектәй сылу егет, бүреген кырынрак салып, аңа карап тора кебек... Төсен, чыраен, күз карашларын ул ачык кына итеп күрә дә алмый инде, ә аның балачаклары бөтенләй томан эчендә торып калган шикелле... Тик аерым күренешләр генә шул томан эченнән чыгып, аның күз алдында җанлана. Ул хәтерли: Тимерҗанны бик яшьли үзеннән калдырмыйча тегермәнгә алып йөри башлаган иде. Янәсе, ир бала — ата дусты ул, аягына бастымы — әнисеннән китәргә, әтисе белән бергә булырга тиеш. Аннан ир бала әнисенең җылы канаты астында гына үссә, нечкә көпшә кебек, зәгыйфь, йомшак, кыюсыз була; баланы таза, нык, күндәм итәр өчен аны җилгә, яңгырга, эссегә, суыкка алып чыгарга кирәк, имеш. Шулай уйлаган иде шикелле ул — хәзер исендә юк инде, әмма Шәмсинурның башта атлаган саен елга буена йөгереп төшүен ачык хәтерли.

Тынычлыгын җуйган мескен ана, килеп җитүенә кабаланып:

— Кая үзе, нишли? — дип сорый торган иде.

Ә Локман карт хатынын куркытыр өчен гамьсез генә:

— Белмим тагын, яңарак кына шунда иде,— дигән була.

Шәмсинур бәргәләнеп тегермән тирәсендә әйләнә башлый.

— Ничек белмисең, ни дигән сүз ул, кая үзе, батуы-нитүе бар. Тагын алып төшәм димәссеңме икән, бирмим, бирмим, Алла кушса, бирмим.

Шуннан соң гына Локман карт хатынын тынычландыра.

— Йә, йә, котың алынмасын, юри генә әйттем, бернәрсә дә булганы юк. Әнә Тимерҗаның, таудан таш тәгәрәтә.

Тегермән каршындагы текә тау түбәсеннән кызыл ыштанлы, ак күлмәкле яланбаш малай, шаян кәҗә бәтие сыман, авыл өстенә карап тора.

Шәмсинур аны күреп:

— Ай Аллам! — ди.— Үзе тәгәрәп төшәр бит!

— Төшсә ни, тагын менәр. Әйдә тәгәрәп, аунап үссен! —ди, улының кыю-җитезлегенә кәефе килгән Локман карт.

Тимерҗан чыннан да шулай тәгәрәп, аунап үсте шикелле. Ничектер Локман карт аны үз тирәсендә аз күрә иде; тынгысыз, тере малай көн буе диярлек елга буенда, тау араларында югалып йөри иде. Атасына охшап ул бик яшьли балык тотарга, җәнлек эзәрлекләргә һәвәсләнеп киткән иде бугай... Шуңа күрә Локман карт аны кул-аягы тырналып, өс-башы җебенеп кайтса да орышмый, тик аның каты чәчле кара башыннан кулы белән угалап: «Һай, син, бәләкәй шүрәле!» — дип шаярта иде, һәм хәтере ялгышмаса: «Бу килеш анаңа күренмә!» — дип әйтә торган иде.

Гаҗәп, Тимерҗанның балачагы озак еллар дәвамында түгел, бер мизгел эчендә генә үтеп киткән төсле булып тоела аңа... Кай арада аның яшүсмер егет булып өлгерүен дә хәзер ачык кына хәтерли алмый инде ул. Кинәт булды шикелле, һәрхәлдә, Тимерҗанның зурлар эшенә ярарлык булып үсеп җиткәнен ул кинәт сизгән иде.

...Кыш иде шикелле, әйе, кыш иде. «Февраль ахырлары булса кирәк. Тау-маңгайлары челтәрләнеп, җем-җем итеп уйный башлаган иде. Һаман киңәя, ачыклана барган ак кырлар түрендә зәңгәр шәүләләр йөри башлаган иде. Морҗа төтеннәре арасыннан җил уйнаклап үткәндә акрын гына якынлашып килгән язның җылы, дымлы сулышы биткә тиеп, йөрәккә кагылып китә торган чак иде.

Алар икәүләп әнә шул таулар артындагы куе урманга зур чана тартып бардылар. Карт үз гомерендә Тимерҗан белән дә, Тимерҗаннан башка да урманга күп йөрде, әмма улы белән икәүләп беренче тапкыр барган көн беркайчан да аның күңеленнән чыкмады. Тик еллар үтә барган саен ул көн ничектер чынлыкта

булып үткән төсле түгел, ә бәлки төштә генә күргән кебек тоела башлады. Төшнең дә әле әкият кебеге... Һәм хәзер дә карт ышанып бетми — әллә булган ул көн, әллә булмаган...

Гаҗәеп иде урман... Тын, шундый тын, ник бер җан әсәре сизелсен, ник бер шылт иткән тавыш ишетелсен! Әгәр юри генә кычкырсаң, тавыш калтырана-калтырана яңгырап әллә кайларга китә, китә дә югала, шунда ук куе тынлык, таш чумган су өсте шикелле, кире урнаша, тирә-юньдә бер генә нәрсә дә уянмый, селкенми, ичмасам, берәр озын койрыклы саескан да сискәнеп, агачлар арасыннан кыеклап очып китми — юк, кычкыру түгел, шартласаң да урман, гүя, сине ишетергә дә, белергә дә теләми... Ә яктылык! Әйтерсең урман өстенә бриллиант тузаны яуган, бөтен җир —агач ботаклары, ачык урыннар — бар да утта яна; мамыктай күперенеп, тәңкәләнеп каткан кар өстеннән кояш нурлары кире чәчриләр — һич туры карап булырлык түгел. Шундый өлкән тынлык һәм шундый мул яктылык! — әллә нәрсә бу, сихер кебек серле, аңлавы читен...

Бу серле тамашадан тәмам хәйранга калган Тимерҗан ахырда, урман белән көч сынашырга теләгәндәй, кыю гына:

— Әти, үзем кисәм! — ди һәм җитез генә бишмәт чабуларын билбавына кыстырып, бот төбеннән карга керә. Менә ул кулларына төкереп, кыска саплы үткен балтасы белән йоклап утырган зифа каенга китереп чаба. Урманның, әйтерсең тартылып торган калын кылы кинәт өзелә — шундый бер ачык тавыш тирән тынлыкның иң ерак түренә кадәр яңгырап китә — бөтен урман калтыранып куя, якын-тирә агачлардан исәпсез күп кар чаткылары сибелеп төшәләр. Аннан «тук-тук» чапкан балта тавышы дулкын-дулкын булып урман түренә йөгерә-йөгерә дә кинәт тына — каен ыңгырашып ава.

Локман карт улы артыннан ияреп йөри, ул кисеп аударган агачларны ботакларыннан әрчи. Алар үзара сөйләшмиләр дә, ничектер бу саңгырау урманда кеше сүзе кирәкмидер, урынсыздыр кебек тоела, һәм алар «тизрәк моннан китү яхшы» дигән төсле ашыгып эшләүләрен генә беләләр.

Аннан алар кискән агачларын чаналарына ташып төйиләр дә өс-башларын каккалап, ат йөгедәй зур йөкне икәүләп тартып, урманнан чыгып китәләр. Чыккач туктап, тын, буш, серле урманга бераз карап торалар. Локман карт бүреген күтәрә төшә һәм аның чал йөгергән чәчләреннән пар калка. Ә Тимерҗан бияләйләрен билбавына кыстырып, уттай янган кулларын кар белән уа. Әйе, менә шулай янәшә басып, янәшә сулап — йа Хода, болар барысы да чынлыкта булды микән, әллә төш идеме, берәр төш кенә, уйланып йөри торгач, шулай чын булып күренә микән? Юк, булгандыр, Тимерҗан бар иде бит, Тимерҗан үсеп егет булган иде бит!

Аннан беренче Герман сугышы башланды. Карт моны бик яхшы белә, әйе, онытасы юк, сугышның аның бәгыренә салып калдырган тирән ярасы хәзер дә әле кул белән капшап карарлык җөй булып саклана.

Сугыш башланганда Тимерҗанның солдатка каралыр вакыты җитмәгән иде әле. Ләкин Локман картның күңеленә «Алырлар, барыбер алырлар...» дигән уй сөлек булып оялады, бары Тимерҗанны алганчы сугыш бетеп куймасмы дигән өмет кенә аны бераз тынычландырып тора иде. Айлар, еллар үтте, илдә юньле ир-ат калмады, ат тун тузып бетте, яланнарны ягы-ягы белән сарут басты, хәтта авылда күгәрченнәр кимеп, каргалар ишәеп киттеләр, әмма сугышның очы-кырые күренми иде. Ниһаять, Локман карт, кечкенә өметенең дә һаман сүнә баруын тоепмы, киләчәктә зур бер бәхетсезлек булуын сизенепме, әллә Тимерҗан китә калса, карчыгы белән икәүдән икәү генә ятим торып калмаска теләпме, катгый карарга килде: ул, Тимерҗанны өйләндерергә кирәк, диде.

Ата ихтыярына каршы килүче булмады һәм Тимерҗанны җәйнең умарталарда беренче бал төшкән, яшь тәкәләр өлгергән иң матур чагында, заманына күрә күңелле генә туй ясап, Зәйтүнә исемле кызга өйләндерделәр. Һай, гомерләр! Үтсә дә үтә икән ул. Менә каршыда шул ук таулар, шул ук буа шаулавы... Әмма утыз ел вакыт эчендә кеше башларыннан ниләр генә кичмәде, кемнәр генә бу фани дөньяга килеп китмәде. Уйласаң — исең-акылың китәр. Йә, ул туйдан кемнәр генә торып калды? Үзе дә карчыгы гына шикелле, тагын менә йорт тора, капка төбендә ул утырган ак таш ята. Әйе, башка берни дә калмады. Ә бит Локман карт, ул чакларда үзе дә капка баганасыдай таза, аттай көчле кеше, шушы өенә туй белән кайтып төшкәч, тарантаска аягүрә басып, ачык җиләненең бер як чабуын артка ташлап, уң кулы белән бөеренә таянып, тауларга карап күпме кунаклар алдында көр тавыш белән сузып җырлаган иде. Сокланып тыңлаган халык аны төрлесе төрле яктан:

— Ә-й-й-й, әфарин, кода!

— Мең яшә, Локман кордаш!

— Һай, асыл карт, әйтеп бирде бит! — дип шаулашып котлаганнар иде.

Ни диеп, нинди җыр җырлаган иде соң ул?

> Агыла болыт, ай, агыла.
> Таулардин да тауга кагыла,—

диепме? Әллә булмаса:

> Егет чакта бер җилеп кал,
> Аркалардан үткән боландай,—

диепме?

Юк, хәзер хәтерли алмый инде ул, җыр онытылган, әмма гомерендә бары бер мәртәбә татыган бәхет — Тимерҗанны өйләндереп килен төшерү бәхете — бик ерактагы ялгыз йолдыздай аның күңеле түрендә тын гына нур сирпеп һаман да балкый әле. Онытылачак түгел ул. Бүгенгедәй күз алдында: өстенә утыртма якалы озын кара кәзәки, башына кырын салып кырпу бүрек кигән, сызылып кына чыккан кара мыеклы Тимерҗан шушы ишегалдында үзенең Зәйтүнәсен сул кулыннан тотып тарантастан ак киез өстенә төшергән иде, һәм Зәйтүнә йомшак ак киез өстеннән атлап, менә шушы өйгә аларның килене булып кергән иде.

Һай, Зәйтүнә, Зәйтүнә! Оялчан, сөйкемле кыз бала, сабыр, итагатьле яшь килен. Күпме йомшак җылылык, тын яктылык алып килгән иде ул үзе белән аларның кечкенә өйләренә! Бичараның кабер эче нурлы булсын! —Карт исенә төшергән саен күңеле нечкәреп, иң ихлас догаларын аның рухына багышламыйча калмый. Үзе димләгән иде шул аны Тимерҗанына... Озак күзәтеп йөргәнгә, ахры, менә хәзер дә ул Зәйтүнәнең кыз чагын шактый ачык итеп күз алдына китерә ала. Ул чакларда төркем-төркем кызлар, эре чәчәкле чиләкләрен буяулы көянтәләренә элеп, буа ярындагы салкын чишмәгә төшә торганнар иде. Чишмәгә төшү үзенә күрә бер күңел ачу һәм кешеләр күзенә чыгып күренү булганлыктан, кызлар мөмкин кадәр ыспай киенеп, бизәнеп-ясанып, тәңкә-чулпыларын күңелле чылтыратып киләләр иде. Егет үстергән Локман карт, тегермәненнән чыгып, бу яшь боланнардай сизгер, сылу кызлар төркеменә сынап карап торудан тыела алмый иде. Алар арасыннан аның күзенә гел генә бер ыспай сынлы, вак адымлы чибәр кыз чагылмыйча калмый иде. Бу кызның бөтен зифа торышыннан, кабаланмыйча, ләкин җитез генә ясаган нәфис хәрәкәтләреннән оялчан тыйнаклык, сөйкемле садәлек сизелеп тора иде. Ара-тирә каршы очраган чакларда да бу кыз бала шәльяулыгының бер кырые белән битен каплап, матур башын аз гына читкә борып, озын керфекләрен түбән төшереп, еш-еш кына атлап уза торган иде.

Әйе, җыр онытылды, бу өйгә җитәкләшеп кергән Тимерҗан да, Зәйтүнә дә күптән дөньяда юклар инде, тик Зәйтүнә үстереп калдырган тамчылы гөл генә, Шәмсинур әбинең тәрбияләп тотуы аркасында, өзелеп төшәргә торган күз яше төсле кызыл чәчәкләрен түбән салындырып, урам як тәрәзә төбендә һаман да утыра әле.

Яшьләрнең бәхетле көннәре бик санаулы булды, давыл аларны читләтеп узарга теләмәде, һәркайсы эчтән тынып көтеп, һәркайсының йөрәген өшетеп торган рәхимсез сугыш кара канатын, ниһаять, алар өстенә дә җәйде. Беренче көлтәләр ындырларга кереп, ындыр табакларында чабагачлар дөпелди башлаган чакта, Тимерҗанны солдатка алып, ерак сәфәргә, фронтка озаттылар.

Менә шулай. Ул чакларны искә төшерүнең хәзер нигә кирәге бар? Үткән-киткән инде ул... Кояш аркадан йомшак кына җылыта. Берни уйламый, күзләрне йомып тик кенә утыру яхшырак ич! Әмма картның йомык күзләре алдыннан Тимерҗанны озату минутлары һич китә алмый... Юка болыт белән өртелгән җәйге талгын иртә иде. Тимерҗан туйга тектергән яңа кәзәкиен киеп, билен кызыл билбау белән буып, гадәтенчә бүреген кырын салып, юл капчыгын сул иңбашына элеп, авылдан җәяү чыгып китте. Басу капкасына кадәр аны карт, карчык һәм Зәйтүнә озата бардылар. Буш кыр уртасында дүртәү туктадылар. Тимерҗан калтыранган иреннәрен кысып, бер сүз әйтмичә, әүвәл әнисе белән, аннан әтисе белән саубуллашты. Аннан Зәйтүнәсен ике куллап күкрәгенә кысып торды, берни әйтә алмады һәм зәүҗәсен әнисенә бирде дә борылып китте. Ул китте, алар торып калдылар. Һәм моңарчы, таш йоткандай, сүзсез калып торган Локман карт та телгә килде. Йолкып ташлаган гөл шикелле ничектер берьюлы шиңеп, сулып калган Зәйтүнәгә ул карлыккан тавыш белән:

— Сабыр, кызым, сабыр,— диде.— Тимерҗан шушы юл белән кире кайтыр, насыйп булса... Без өчәүләп аны каршы алырга чыгарбыз. Шул көнне көтик.

Алар озак көттеләр. Үргә таба буш юл буйлап авылдан ераклашып барган Тимерҗанның кызыл билбау буган сылу гәүдәсе озак вакытлар аларның күз алларында сакланды. Ә карт, учына төшкән утлы күмерне тота да, ташлый да алмаган шикелле: «Кемгә кирәк бу сугыш, кемгә генә кирәк бу кан коеш?» — дигән сораудан котыла алмыйча йөрде.

Ул арада 16 нчы елның көзе үтте, кыш керде. Кыш үтеп язгы җилләр исә башлау белән илдә-көндә дә, картның өендә дә бик куанычлы хәлләр булып алды. Февраль ахырлары иде шикелле, юк, март башлары булса кирәк, баскыч төпләренә кар сулары җыела башлаган чакта Зәйтүнәнең беренче баласы дөньяга килде. Балага Батырҗан исеме куштылар. Аны бары әтисенә охшаган итеп күрергә теләделәр, менә әтисе кайтып улын күргәч, ничек шатланыр, дип, бигрәк тә Тимерҗан өчен сөенделәр. Җитмәсә, өй куанычына ил куанычы да өстәлде — авылга патша төшерелү хәбәре килде.

Локман карт бу вакыйгалардан соң никадәр рухланып, канатланып йөргәнен хәзер дә онытмый әле... Онытырлыкмы соң ул көннәр! Хәтерли, хәтерли, иртә-кич өзелмичә шау-гөр килгән авыл җыенынннан дулкынланып кайткач, Батырҗан бишегенә иелеп сөйләнә торган иде:

— Йә, нихәл син, батыр егет, ни карап ятасың, очлы күз! Әтиеңне көтәсеңме, ә? Кайта, кайта хәзер, Алла боерган булса, кайта... Бетте, бар да бетте, сугышы да, патшасы да, әтиеңне бездән аерып торучы берәү дә калмады. Менә шулай, Батырҗан улым, бик хикмәтле заманга туры килдең әле син, сөйләп кенә бетерәсе түгел, әйдә, тизрәк үс, бөркетем!..

Ләкин карт, шулай бишек өстенә иелеп, Батырҗанга никадәр зур вәгъдәләр бирмәсен, әмма сабыйга атасын күрү насыйп булмады. Тимерҗан 17нче елның җәендә, каядыр Польша җирендәге юеш окопта немец снарядыннан һәлак булды. Көзен авылга кайткан ике карт солдат бу хәбәрне китерделәр һәм Тимерҗанны үз куллары белән бер урман авызында җеназалап күмеп калдыруларын сөйләделәр.

Бу хәбәрне ишеткәч, карт үзенең нинди хәлгә төшүен хәзер дә юньләп аңлаганы юк. Кайгырудан битәр, аптырауга төшкән иде шикелле ул, әйтерсең артыннан сиздермичә акрын гына килеп, башына тәртә белән суктылар... Бик озак исәнгерәп йөрде ул. Аны гаҗиз иткән нәрсә — Тимерҗанның сугыш инде бетә дип торганда гына үтерелүе булды: югыйсә ул сугышның корбансыз булмавын белә, Тимерҗан белән дә берәр бәхетсезлек булу ихтималын, кешегә әйтү түгел, үз-үзенә әйтүдән дә куркып, эченнән уйлап куйгалый иде. Инде шул хәтәр үтте дигәч кенә... эх, ничек булып чыкты соң бу, ничек булып чыкты?

Ләкин картның эчендә ниләр генә кайнамасын, ул моны тыштан күрсәтмәскә тырыша иде. Әле аңа янындагы ике кадерле кешесенең хәлләренә дә ир кеше, гаилә башы буларак керә белергә кирәк иде. Менә карчыгы Шәмсинур авыр хәсрәттән урынга ятты. Ә Зәйтүнә, бичара, Тимерҗанның үлү хәбәрен ишеткәч, башта атып төшерелгән кыр казыдай шундый бер өзгәләнү белән үзен кая куярга белмичә бәргәләнде ки, карт аңа карап, эчке тетрәнү белән, кеше хәсрәтенең никадәр тирән, хәтәр булуын бер мизгелдә сизеп алды һәм ничек тә аны юатырга, тынычландырырга ашыкты.

— Сабыр бул, килен балам, сабыр бул! Нишләмәк кирәк, бер безгә генә килгән хәсрәт түгел,— диде ул, чын аталарча кайгырту белән.

Һәм Зәйтүнә күз яшьләрен йота алды, башын миңгерәүлеккә салып, кул-аягын салындырып йөрүдән котыла алды. Тик ул бик ябыкты, йөзенә сары йөгерде һәм еш кына үзалдына көрсенеп, авыр сулап куя торган булып калды.

Карт кинәт сүзсез тынып калган карчыгы өчен дә бик борчыла иде. Ул еш кына аның янына килеп, авыр кулының учын карчыгының маңгаена йомшак кына куя:

— Йә, анасы, хәлең ничек? — ди.— Карлыган кагы белән чәй эчсәң, торып китмәссеңме икән?

Нихәтле авыр булуга карамастан, айнык акылын җуймаган ана да, бу кайгыртуның шифалы тәэсиреннән бигрәк, олы хәсрәтне күтәрә белгән картыннан яхшысынмыйча, урыннан торды. Һәм алар, көчле давыл бөгеп киткәннән соң турайган агачлар шикелле, акрынлап хәл алдылар, аякларына бастылар.

Әйе, болар бар да бик сирәк искә төшә торган хатирәләр, ерак хатирәләр. Моңарчыга кадәр карт үзенең ерак үткәнен мондый эзлекле рәвештә күз алдыннан кичергәне юк иде, дөресрәге, ул үткәнгә кайтудан юри тыела торган иде, чөнки гомер ничек кенә үтмәсен, кеше һаман киләчәкне уйлап яшәргә гадәтләнгән инде ул. Бу шулай, бу — тормышның үзенә күрә бер кануны булса кирәк, әмма бүген Локман карт әче хатирәләр касәсен актыгына кадәр эчеп бетерергә тиеш иде.

Инде тормыш эзгә төште, Тимерҗанны югалту хәсрәтеннән инде терелдек дигәндә генә, Зәйтүнә тиф белән авырып урынга ятты... 19 нчы елның кышы, авыр вакытлар, авылдан беркая чыгып булмый, больницасы ерак, докторы юк... Дәһшәтле авыру алдында тәмам гаҗиз, көчсез булып калган карт белән карчык Зәйтүнәнең түшәге яныннан көне-төне китмичә өзгәләнсәләр дә, бер генә хәлләр дә итә алмадылар шул. Һай, яшь җан, һай, газиз җан!.. Локман карт «эһ» тә димичә рәхәтләнеп үз җанын бирергә әзер иде, тик ул гына, Зәйтүнә генә, әле егермедән дә узмаган яшь ана — бичара гына китмәсен иде!.. Иренеп кенә аткан кышкы таңның зәңгәр шәүләсе туңган тәрәзәләргә төшкән чакта, Зәйтүнә мәңгелек йокыга талган иде. Бөтен газаплардан котылып, көлемсерәп...

**IV**

Әнә буа күпере аша бер төркем чуар киемле хатын-кызлар чыктылар. Аръяктагы ындырдан төшке ашка кайталар, күрәсең. Озакламый Әхмәтвәли дә, бәлкем, килеп җитәр. Ул бит көн дә аларга сугылмыйча калмый. Карт борын очында эленеп торган эре яшь бөртеген сул кулы белән селтәп ташлый... Күпме еллардан соң менә бер яшь бөртеге. Юк, картның күңеле эри ала икән әле.

...Тормыш, тормыш! Таш кыяга үскән нарат шикелле усал җилләрдән күпме сыгылса да, сынмады ул. Ник анда сугыш дигәнең күпме генә үлем чәчеп котырынмасын, барыбер бетте, барыбер тормыш тарафыннан җиңелде.

Батырҗан!

Менә кем торып калды Тимерҗан белән Зәйтүнәдән! Картларның кулында шундый газиз җан, шундый бәхет, өмет, юаныч бар әле, моның өчен, бу газиз җан өчен тагын яшәгән кадәр яшәргә, бу бәхет белән үткәннең бөтен хәсрәт-газапларыннан терелергә мөмкин иде әле. Нәсел гомере өзелми ул, юк, өзелми, берәр буыны төшеп калса да, барыбер ялганып китә, барыбер дәвам итә, юк аны өзәрдәй көч, булачак та түгел — менә Локман картның яңарган иманы шул иде. Һәм Локман карт тегермән ышыгына чыгып, Батырҗанын ике тез арасына алып, зур кулларын аның кечкенә җылы корсагы өстенә куеп утырганда еш кына шул турыда хыялланырга ярата иде. Аның каршында шул ук таулар... тауларны узарга теләп шул ук елгачык чаба... Бер карасаң, таулар олы мал көтүенә, ә елгачык арттан килүче көтүченең алга селтәгән озын чыбыркысына охшый. Икенче карасаң, таулар бик ерак илләрдән килгән баһадирларга охшыйлар;

гүя алар чәчәкле тугай уртасыннан җитез уйнаклап, чылтыр-чылтыр, көлә-көлә аккан шундый сөйкемле, гамьсез, шаян елгачыкны күреп туктаганнар да, атлап чыгарга кыймыйча, сокланып карап торалар төсле... Картның да бит нәсел очы гүя шушы баһадир таудан һәм назлы елгачыктан башланып киткән, ул үзе дә шушы җирләрнең туфрагында аунап үскән, Тимерҗаны да шушы таулар куенында бөркет баласыдай үсте. Инде менә аның тезләре арасында аңа сыенып кына торган Батырҗан да үсмәсмени? Һи, сау-сәламәт булып торганда тагын унбиш-егерме ел вакыт нәрсә ул, күз ачып-йомганчы үтәр дә китәр, Батырҗанның, менә күр дә тор, егет солтаны булып үсеп тә җитәр!

Батырҗан төсе-башы, бигрәк тә холкы-табигате белән мәрхүмә әнисе Зәйтүнәгә охшаган булып чыкты. Әнисенекедәй коңгырт йомшак чәчле, сызылып киткән нечкә кашлы һәм чәче белән кашларына караганда да коңгыртрак озын керфекләре арасыннан нәкъ әнисенеке төсле зур соры уйчан күзләре карыйлар иде. Борын белән иреннәре генә этисенеке иде: борыны туры, иреннәре шактый калын булып, бик матур сызылып киткәннәр, ә матур иягенең уртасында сөйкемле генә чокырчыгы да бар иде... Холкына килгәндә исә, ул нәкъ әнисе кебек нечкә күңелле, аз сүзле, оялчан бала иде. Артык дуамал, шаян булмады, күбрәк әбисе белән бабасы янында чуалып үсте. Ул зиһенле, акыллы бала иде, бик иртә үзлегеннән язу танырга өйрәнде һәм китап укырга яратучан булып китте.

Инде мәктәпкә йөри башлагач, ул бөтен рәхәтне, кызыкны, ямьне шуннан таба торган булды. Карт белән карчык аның өчен сөенеп бетә алмыйлар иде. Шәмсинур әби еш кына аңа, зур тәнәфес вакытын туры китереп, алъяпкычы белән генә каплап агач тәлинкәдә бәрәңге пәрәмәчләре илтә, ә Локман карт кай көннәрне дәрестән соң да мәктәптән кайтмыйча калган улын үзе барып алгалый иде.

...Шулай үсте бала. Кышларын бер көн калдырмыйча мәктәп юлын таптады, җәйләрен үз ишләре белән колхоз эшенә йөрде, кичләрен су буена уеннарга чыкты, егетләр арасына керә башлады, оялып кына кызлар күзли башлады, уеннан таралучы егетләргә ияреп урам әйләнде, кыскасы, буй алган яшь чаган кебек күзгә күренеп үсә бирде. Аннары, урта мәктәпне бетергәч, Алабугадагы укытучылар институтына китте. Яратканы уку иде, хыялланганы укытучы булу иде, әмма дөньяда аның өчен бөтенесеннән дә кадерлерәк нәрсә — әбисе белән бабасы иде. Шуңа күрә ул институтны бетергәч тә алар янына ашыгып кайтты. Инде көздән кайчандыр үзе тәмамлаган мәктәптә укыта да башларга тиеш иде... Әйе, тиеш иде...

Сугыш, сугыш!

Карт, туңып киткәндәй, тун чабуларын тезләре арасына кыстыра төшә, авызын акрын гына кыймылдата. Ләкин сугыш турында йөрәгендә ятканны әйтер өчен гади кеше сүзләре генә җитми аңа, бик көчсез алар, чөнки бу һичкем теләмәгән сугышның башлануы аның өчен, җир түгел, кояш тетрәвеннән яманрак булган иде.

Ә Батырҗан сугышның беренче көненнән үк фронтка китеп тә барды. Тагын шул ук көнбатышка таба, тагын шул ук бәдбәхет дошманга каршы! Бу юлы картлар гаҗәеп зур түземлелек күрсәттеләр, әмма аларның җанын Батырҗан язмышы өчен нинди авыр шик, нинди тирән борчылу биләп алганын әйтеп торасы да юк. Гомер үткән инде, Тимерҗаннан Батырҗан калса да, Батырҗаннан берәү дә калмады, әгәр шуннан... юк, бер генә секундка бу турыда уйлау да әйтеп бетергесез куркыныч иде. Һәм карт бөтен сугыш буена диярлек андый шомлы уйларга баш калкытырга да ирек бирмичә, аларны зур ихтыяр көче белән басып килде... Эшләде ул, көчен аямады, картлыктан йончып тегермәндә оста була алмагач, аның каравылчысы булды, аяз төннәрдә җемелдәгән ерак йолдызларга карап, Батырҗанның кай якларда йөрүен үзенчә чамалаган булды, һәр иртә белән берәр куанычлы хәбәр килмәдеме икән дип, ашыга-ашыга өенә кайтты.

Дүрт елга якын карт белән карчык Батырҗанның исән-сау булуын белеп яшәделәр. Әбисе белән бабасын җаныннан артык күреп яраткан һәм аларның ни хәлдә яшәүләрен бик яхшы аңлаган Батырҗан аларга, тере тавышын ишеттергәндәй, үзе турында еш кына хәбәр итеп торды. Ниләр кичермәгәндер ул сугышта, ихтимал, үлә язып калган чаклары да булгандыр, ләкин җибәргән хатларында ул картларны куркуга салырлык хәтәр хәлләр турында язмаска тырышты.

Картларның өметләре үсте, ныгыды... Инде сугышлар дошман җирендә бара иде. Халык, сугыш бетә, сугыш бетә дип, шул бетәсе көнне көтеп алалмыйча сабырсызланып тора иде... Март аеның иренеп кенә җепшек кар яуган җылымса тын бер көнендә авыл почтальоны Локман карт кулына сары конверт тоттырып китте. Карт конверт эченнән чыккан печатьле кәгазьнең кемнән, нәрсә турында икәнен белмичә, аны колхоз идарәсенә күтәреп барды. Анда кәгазьне укыдылар һәм телсез калдылар. Беренче теләк карттан ничек тә яшерергә тырышу булды, эчләреннән генә ачыгавыз сельсовет секретарен да сүгеп ташладылар: ничек ул шушындый кәгазьне абайламыйча туп-туры үзләренә җибәргән?.. Ләкин идарә уртасында таягын идәнгә нык терәп, ике учлап тотып торган Локман картның аяусыз сораулы, хәрәкәтсез күзләреннән берninди ялган-хәйлә белән котылырга мөмкин түгел иде. Председатель Суфиян кечкенә сары кәгазьне күзлеге тирәсендә әйләндергәләп, тагын бер кат укыган булып:

— Бу, Локман бабай, Батырҗан турында икән,— диде.

— Хуш! — диде карт, күзләрен председательнең йөзеннән алмыйча.

— Менә шул, Локман бабай, бик үк күңелле нәрсә язмаганнар монда... Батырҗан ранин булып госпитальгә кергән икән... Кызганыч, әйе...

— Әйтеп бетер, энем!

Председатель кәгазь кисәген өстәлгә куйды һәм күзлеген ике куллап акрын гына салды:

— Тагын нәрсә әйтим сиңа, бабакай, хәзергә әйтердәе шул гына... Була бит инде ул, үзең дә беләсең: сугыш...

Картның сул як бите дерт-дерт селкенә башлады, ул аз гына тын алмыйча авызын ачып торды да сорады:

— Батырҗан... үлгәнме?..

Председатель, ниһаять, башын иде, картның мәрхәмәтсез сорау белән төбәлгән усал карашы аның чын уен, гүя кадак суырган шикелле, аяусыз тарта иде, һәм ул яшерергә көче җитмәсен сизде. Кинәт аның йөзенә куе кызыллык йөгерде, муенындагы кан тамырлары бүртеп чыкты, уң кулын чытырдатып йомарлап маңгаена күтәрде.

— У-у-у... бәдбәхет сволочьлар, нинди асыл егетебезнең тагын башын ашадылар...

Хатын-кызлардан кемдер кычкырып үксеп җибәрмәс өчен идарәдән уктай атылып чыгып китте.

Локман карт акрын гына чигенеп артындагы эскәмиягә утырды һәм шунда ук җәһәт кенә кире торды.

— Юк, булмас, ялган бу! — диде ул һәм хәлсез кулы белән таягын шак иттереп идәнгә сугып куйган булды. Бер мизгелдә ул Батырҗанның үлгәнен һичшиксез белде һәм шул ук мизгелдә үлү хәбәренә кырт кисеп ышанмады, юри үч итеп ышанмады.

Хәбәр бик тиз авылга таралды. Батырҗанны кызганып, Батырҗаннан да битәр карт белән карчыкны кызганып, чын-чыннан кайгыртучылар күп булды, көн саен хәлләрен белергә, җылы сүз әйтеп юатырга килүчеләр бусагаларыннан өзелмәде. Шәмсинур әби телдән калып урынга ятты, әмма карт һаман башын чайкап, кешеләргә генә түгел, үзалдына да «юк, ялган бу!» дип йөри бирде. Мондый катгый рәвештә чынны инкарь итү олы хәсрәткә каршы торырлык аның бердәнбер йөрәк көче иде. «Әйе» дип килеште исә, ул үзе дә юкка чыгарга, бетәргә тиеш кебек иде.

Ләкин Локман карт күпме генә тискәреләнеп маташмасын, чынлык аның аңында атналар, айлар үтү белән акрынлап ныгый барды һәм сугыш беткәннең икенче көнендә әлеге ышанмау кинәт юкка чыкты. Батырҗан үлгән, кайтмый, юк ул — менә мәрхәмәтсез хакыйкать шул, һәм бу хакыйкать белән карт ахырда чарасыз килеште. Килешүе дә булды — ул үзен фани дөнья белән дә һәртөрле алыш-биреше беткәндәй итеп тойды.

Менә шул. Өйгә керергә вакыт. Кояш та төшлектән авышты булса кирәк, өйнең күләгәсе карт өстенә борылды. Әхмәтвәли дә бүген килмәде, ахры, югыйсә бу вакытка кадәр килеп китә торган иде. Колхозда эшләрнең бик тыгыз чагы шул. Бигрәк тә мондый аяз көнне халык, әйтерсең авылны ташлап чыга, бар да йә кырда, йә ындырда, йә юлда булалар. Әнә киң урам нинди тын, нинди буш. Тик авылдан түбән, елганың кояш чыгышына таба борылган киңлегендә, сөзәк калкулык артыннан һавага тузан өермәсе күтәрелеп, бөтерелеп уйнап тора. Ара-тирә тузан арасыннан бик биеккә очып киткән сары саламнар күренеп кала. Анда колхозның иң зур ындыр табагы, көчле молотилка бер атна буена инде көне-төне ашлык суга. Колак салып торсаң, тонык буа шаулавы аша вакыт-вакыт ерактагы молотилканың «у-у-у... у-у-у» дип үкереп куйганы ишетелеп кала.

Әйе, Локман карт бик хәтәр хәл башыннан кичерде. Шундый искиткеч авыр югалтудан соң ул бер генә тапкыр да елый алмады, зарланмады, сыкранмады, тик яшен суккандай бернәрсә уйлый алмас, тоя алмас булып калды. Бик куркыныч иде бу, аягүрә тере мәет булып йөрү белән бер иде... Дөрес, аның эчендә бөтен нәрсә кинәт корып бетсә дә, дошманга карата гади кеше теле белән генә әйтеп бирергә мөмкин булмаган ачу-нәфрәт тәненнән чыкмаган җаны булып яши иде. Әгәр бу нәфрәтнең бер генә тамчысын менә хәзер яңа сугыш чыгарырга теләп йөргән берәр мистерның өстенә тамызсаң, ул мистердан тәңкә кадәр кара көек кенә торып калыр иде.

Ихтимал, бик ихтимал, Локман картның яңадан терелә башлавына, акрынлап тормышка кайтуына әнә шул бердәнбер үлми калган нәфрәт тойгысы төп сәбәпче булгандыр да... Ләкин моның өчен вакыт кирәк иде.

## V

Әйе, вакыт — иң сыналган, иң яхшы дәвалаучы ул. Айлар үтте һәм менә һәрнәрсә үзенең асыл хәленә кайтты.

Башта, авыр хәсрәттән башларын җуйган чакта, аларны бөтенләй егылып китүдән күрше-күләннәре саклап калды. Аннан кемнәрнеңдер куллары аларның аркаларыннан йомшак кына этәреп, үзләрен акрын гына атлатып җибәрде. Шул ук куллар хәзергә кадәр аларны чайкалып, авып китүдән саклап килделәр. Инде Әхмәтвәли кайтып, үз балалары шикелле кайгыртып йөри башлагач, аларга көч-хәл кергән кебек булды, баш өсләреннән кайгы сөреме күтәрелде, күзләре көн яктысын күрә башлады.

...Шуның өстенә тик ятудан эче пошып, эшкә кулы кычытып йөргән Локман карт яңадан бәрәкәтле һәм шифалы хезмәткә кайтты. Яхшы күңелле кешеләр картның хәлен җиңеләйтә торган бердәнбер дәва хезмәт

икәнен, ниһаять, аңлап, үзенә бер эш тә табып бирделәр. Дөрес, хезмәте аның зурдан түгел, ул бары өендә шорник булып эшли: Әхмәтвәли китереп биргән машина каешларын ялгый, чи каештан камыт баулары кисә, сүтелгән бөятләрне тегеп утыра.

Шулай әкрен-сүлпән генә, моңсу-тыныч кына үтә картларның санаулы көннәре. Хәзер инде алар өчен телисе нәрсә дә, көтәсе нәрсә дә калмаган иде... Әмма тормышның могҗизаларына исең-акылың китәр! Юкка гына борынгылар тереклекне әбелхәят чишмәсенә охшатмаганнар икән.

Озакка сузылган быелгы коры көзнең соңгы көннәре иде. Агачлар тәмам шәрәләнеп калды, елгалар-күлләр юка гына боз белән капланды, ялан-кырларга ак кырау ятты. Җир инде сабыр гына кар төшкәнен көтә иде.

Менә шундый көннәрнең берсендә, өстенә офицер шинеленнән бозып тегелгән путалы пальто киеп, башына ак шәл ябынган яшь кенә бер хатын җыйнак кына биләү күтәреп, Локман карт ихатасына килеп керде. Аз гына тукталып тирә-ягына каранды, аннары ишеккә таба атлады.

Өйгә кергәч ул, биләвен ике куллап кочаклаган килеш, ишек төбендә тукталып калды. Карт белән карчык көтмәгәндә килеп кергән бу ят хатынга аптырап, ни әйтергә белмичә карап тора башладылар. Ниһаять, хатын, телгә килеп, акрын гына:

— Мин ялгышмадым шикелле,— диде.— Тегермәнче Локман бабай өе шушыдыр бит инде?

— Әйе, шушы инде, шушы,— диде карчык, урыныннан кузгалып.— Соң син үзең кем буласың, кызым?

Яшь хатын сөенеп елмайды, күзләре ничектер дымланыбрак киткәндәй булды һәм тирән генә бер сулап әйтеп куйды:

— Алайса инде, әби җаным, мин сезнең киленегез булам.

Шәмсинур әби дерт итеп сискәнеп китте һәм ни дә булса аңлаудан гаҗиз, кызганыч бер кыяфәт белән катып калды. Шул арада, ишекне киң ачып, кызу гына Әхмәтвәли килеп керде. Ул бу хатынның картларга кереп китүен шәйләп калган булса кирәк, ишектән керү белән аңа текәлде.

— Әхмәтвәли, карале, бу кызым әллә нәрсә ди бит әле, Ходаем! — диде Шәмсинур әби, еларга җитешеп.

Егет исемен ишетүгә, яшь хатын, ачылып китеп, аңа карады:

— Сез Әхмәтвәли абый буласызмы?

— Әйе, шул үзе.

— Алайса мине хәтерлисездер. Мин Сания булам. Фронттан сезгә Батырҗан турында язган идем.

— Әйе, әйе, хәтерлим,— диде Әхмәтвәли, артык гаҗәпләнүдән акрын гына башын кагып.

— Менә бик әйбәт булды бит әле,— диде хатын.— Сез аңлатыгыз инде үзләренә, мин менә Батырҗанның кушуы буенча аларны эзләп килдем...

Хатынның иреннәре калтыранып куйды, күзләре яшьләнеп китте, башын тизрәк читкә борды. Әхмәтвәли гадәттән тыш бер хәл барлыгын сизенеп, хатынга тиз генә урындык алып бирде, утырырга кушты. Хатын башта биләвен сак кына сәкегә сузып яткырды, аннары урындыкны тартып утырды да, кулъяулыгын чыгарып, күзләрен сөртте. Бераз тынычлангач ул, хәйран калып, сүзсез көтеп торучыларга үзенең кем булуын, ни өчен килүен кыскача гына аңлатып бирде.

Әхмәтвәли янып киткән күзләре белән алмашлап әле бер Шәмсинур әбигә, әле бер Локман картка кат-кат карап алды. Локман карт баядан бирле ике кулы белән сәке йөзлегенә таянып, авызын ача төшеп, йокыдан айный алмаган төсле иләс-миләс бер кыяфәттә утыра иде. Ул ни дә булса аңлаудан ерак иде шикелле.

— Ишеттегезме? — диде Әхмәтвәли, артык дулкынланудан яман кычкырып.— Ишеттегезме, Шәмсинур әби, Локман бабай, сезгә кем килгәнен? Киленегез бит бу, киленегез!

— Килен? — дип куйды Локман карт, әллә ничек балаларча гына итеп.

— Әйе, килен!.. Менә бу сеңелкәш, Сания, Батырҗанның фронтта кушылган хәләл җефете була. Аңладыгызмы? Батырҗан кушуы буенча килгән ул сезгә, үзе генә түгел, баласы белән, аңладыгызмы, баласы белән!

— Баласы! — дип куйды Локман карт, тагын шулай әллә ничек сискәндерерлек итеп.

— Әйе, баласы, Батырҗан дускайның баласы! Ух, анасының кара бәрхет бишмәте! Яле, килен, күрсәт әле үзен әбисе белән бабасына!

Сания, Әхмәтвәлинең бу хәтле шашынып китүеннән ихтыярсыз елмаеп, биләүнең ак җәймәсен ачып җибәрде. Биләү эчендә, имезлеген кабып, йокыга киткән өч-дүрт айлык бала ята иде. Карчык белән карт аның өстенә иелделәр. Шәмсинур әби авыз эченнән генә кызу-кызу нидер укырга тотынды. Локман карт та нидер әйтмәкче булып, иреннәрен кыймылдатты, каты, кәкре бармаклары белән баланың битенә сак кына орынмакчы булды, ләкин кинәт хәлсезләнеп, сыгылып төште дә аюдай гәүдәсе белән калтырана-калтырана елап та җибәрде. Барысы да бер мәлгә тынып калдылар... Менә кайчан килеп елый алу бәхетенә, ниһаять, ирешә карт!

Әхмәтвәли ишек төбенә китте, тагын әйләнеп килде, бик каты маңгаен ышкып торды, аннары Саниядән акрын гына сорап куйды:

— Кызмы, малаймы?
— Малай.

Һәм кинәт Әхмәтвәлинең да елыйсы килеп китте, ләкин карт шикелле сыгылып төшеп түгел, ә өйгә сыя алмыйча ишекле-түрле йөреп, таштай йодрыгын кемнәргәдер селкә-селкә елыйсы килеп китте.

Яшеннәрдән, давыллардан сынмаган Локман карт һаман да әле аяк өстендә. Кайчагында ул Батырҗанның өч яшьлек улы Газизҗанны җитәкләп буа ярына төшә. Көн кояшлы була, күк ерак, сыек зәңгәр, көньяктан йомшак кына җылы җил исә. Буа шаулый. Локман карт яр буендагы берәр ташка утырып, баланы тезләре арасына ала да, зур кулларын аның җылы корсагына куеп каршыдагы текә тауга, моннан бик күп еллар элек үзенең Тимерҗаны таш тәгәрәтеп уйнаган тауга озак кына карап тора. Ерактан, бик ерактан ак читле күгелҗем болытлар акрын гына йөзеп киләләр һәм аларның күләгәләре йомры тау түбәләре өстеннән тын гына шуып үтәләр... Әйе, күләгәләр шуып үтә, тормыш бетми һаман, һаман дәвам итә.

1948

# Бөке

Һәр җәй саен диярлек мин бер район үзәгенә балык тотарга кайта идем. Һәм кайткан саен диярлек мин анда өзелеп балык сөюче бер иптәшне очрата торган идем.

...Беренче очрашуыбыз моннан дүрт ел элек булды. Җәй уртасының матур бер көнендә мин, нәкъ балыкчыларча, зур кирза итекләрдән, иске плащтан һәм иске эшләпәдән, иңбашка зур бәйләм кармаклар күтәреп, аркага дыңгычлап тутырган рюкзак асып, йөк машинасында, район үзәгенең базар мәйданына килеп төштем. Төшү белән иң элек азык-төлек кибетенә кердем. Елмаерга ашыкмагыз, сез уйлаган нәрсә рюкзакта бар ул, онытылмаган, ә... менә тоз онытылган, хәерсез, тоз алырга кирәк иде. Менә шул тоз алып торган чакта, бер кеше миңа дәште:

— Иптәш, балыккамы?

Мин борылып карадым: аз гына читтәрәк, башына ак фуражка, өстенә кара пиджак, аякларына хром итекләр кигән түгәрәк битле, таза гына бер кеше басып тора иде.

— Әйе, балыкка,— дидем мин.

— Ерактанмы?

— Казаннан.

— Ярый, ярый... Безнең елга балыклы, чабакларны шәп каптырырга була.

Минем авыз, тотылачак чабакларның үзләрен күргәндәй, җәелеп үк китте.

— Шулаймыни? Күңелле хәбәр. Үз тәҗрибәгездән чыгып әйтәсездер инде?

— Юк,— диде бу иптәш, саран гына елмаеп.— Кармак салып утырырга туры килгәне юк. Берәмләп тоту гына мине кызыксындырмый.

«Эредән яра абзый кеше»,— дип уйлап алдым мин һәм аның махсус кораллар белән генә эш итүче балыкчы булуына шунда ук ышандым.

— Димәк, подпуск саласыз?

— Берни дә салмыйм мин, агай-эне! — диде ул һәм, минем шактый гаҗәпләнеп калуымны күреп булса кирәк, сорап куйды: — Нигә ул хәтле исегез китте?

— Сез, берәмләп тоту мине кызыксындырмый, дидегез. Шулай булгач...

— Дөрес, миңа балык килолап түгел, центнерлап, тонналап кирәк.

— Тонналап! Гафу итегез, кем буласыз соң сез?

— Райпищекомбинат директоры. Аңлыйсыздыр инде, балыкны берәмләп тоту минем планга керми. Елганың буеннан-буена зур ау белән иңләп сөзү — менә минем план.

Без кибеттән чыктык. Аерылышыр алдыннан директор иптәш әллә мактанырга, әллә мине үртәргә теләп:

— Икенче килүегездә елга буена барып торырга да кирәк булмас,— диде.— Чуртан кирәкме, корбанмы —бездән генә алып китәрсез.

— Балыкчы бервакытта да балыкны сатып алмый,—дигән булдым мин, ә ул «беләбез!» дигән төсле миңа хәйләкәр генә күз кысып куйды.

Без аерылыштык, ул үз юлына, мин үз юлыма киттем. Район үзәгеннән зур шоссе юлы белән киң тугайга чыгып, елгага таба атладым. Бер өч километр чамасы киткәч, елга күперенә дә килеп җиттем. Мин үзем балык тотар өчен урынны, гадәттә, күпер тирәсеннән эзлим. Күпер тирәсендә, мәсәлән, яту урыннар очрый, андый җирдә су тирән була, акрын ага. Менә хәзер дә, күпердән йөз метр чамасы түбәнрәк, шундый бер киң генә яту җирне табып алдым. Кармак салыр өчен бик уңай ачык урыны да бар икән: текә яр астында такыр комлык, су читтән үк тирәнәеп китә, төбендә балык урынына эләгеп, өстерәлеп чыгардай ләм, тамыр кебек нәрсәләр дә күренми, ә ике яклап чуртан абзаң посып ята торган куе камышлык сузылып китә. Бәхетле урын булсын!

Мин аркамдагы рюкзакны салып, бер гөлҗимеш куагы төбенә куйдым да, сакланып кына яр астына төштем һәм, судагы балыклардан кем булуымны, нинди максат белән килүемне яшерергә теләгәндәй, шыпырт кына кармакларны сүтә башладым.

Шулай да минем бу беренче килүем шактый уңышлы чыкты: ике көн яр буенда ятып, иртә-кич күбенгәнче уха ашап, үзем белән өйгә дә бер өч кило балык алып кайттым.

## I

Икенче җәйне дә мин шул район үзәгенә, шул ук җиргә балыкка барырга булдым. Юлга әзерләнгәч кенә әлеге район кибетендә очраган «Райпищекомбинат» директоры кылт итеп исемә төште. Елгадагы балыкны сөзеп бетермәдеме икән? — дип шикләнеп куйдым мин... Ләкин бер әзерләнгәч, балыкның безгә дигәне дә калгандыр әле дип, юлга чыктым.

Укучыларга мәгълүм булсын ки, чын балыкчы гел бер ияләшкән урынга йөри ул. Һәм без дә былтыргы урыныбызга, әлеге күпер төбенә җитеп, әйбәт кенә урнаштык.

...Көн гаҗәп иде. Таллыклар очына тынлык кунган, су өсте шар тәгәрәтерлек тип-тигез, ник бер шылт иткән тавыш, ник бер хәрәкәт булсын! Тик ара-тирә кармак очына дүрт канатлы энә карагы килеп куна, яки су уртасында берәр балык сыртын елтыратып чумып куя.

Менә шул җылы, рәхәт чынлыкта инде без, балыкчы, «шалт!» җилкәгә, «шалт!» чикәгә, «шалт!» култык астына сугып, сихерләнгән кешедәй, калкавычлардан күзне алмыйча утырабыз. Гаҗәеп хозур! Йөзләп озынборынның җанын җәһәннәмгә җибәргән арада берәр чабак та эләгеп куя. Ялтыратып ярга чөям үзен. Аннан тагын «шалт!» җилкәгә, «шалт!» чикәгә...

Шул көнне кичкә таба райүзәк ягыннан килүче брезент түбәле, киң көпчәкле батыр «ГАЗ-7» машинасы күпергә җиткәндә генә шып туктады. Машинадан таза гына бер кеше төшеп миңа таба килә башлады. Килеп җитәр-җитмәс, бу миңа елмаеп дәште:

— Нихәл, балыкчы! Каптырабызмы?

Кем дип торам, бу әлеге «Райпищекомбинат» директоры икән ләбаса!

— Ә-ә, иптәш директор! Саумысыз!

Ул минем белән кул биреп күреште дә кара чиләк янына чүгәләде.

— Әллә-лә-лә! Чабакларны шактый тарттыргансың икән. Кызыл канат та, алабуга да бар, имеш. Ә чуртан юкмы, чуртан?

— Чуртан суда әле.

— Нишләп тизрәк капмый инде, юньсез! Нәрсә көтә?

— Чуртан хәзер сездән артмый торгандыр.

Директор, кинаяне төшенмичә, миңа карады. Мин былтыргы сөйләшүне аның исенә төшерергә ашыктым:

— Сез зур ау белән елганың бөтен балыгын сөзәргә җыенып йөри идегез бит.

— Ә-ә! — диде бу, сузып.— Аны әйтәсез! Булмады шул, җыенып йөрүдән эш узмады. Сезнең бәхет.

— Нишләп алай?

— Минем план иде ул, ә үзем киткәч, план да һавада эленеп калды.

— Сез хәзер «Райпищекомбинат» директоры түгелмени?

— Юк, мин хәзер «Заготживсырье» башында! — диде ул, юри эреләнгән булып.— Көтмәгәндә генә күчерделәр дә куйдылар, давай, заготовка эшен юлга сал, диделәр. Элекке управляющий, аты корсын, «кабарга» бик ярата иде, аны ашханә мөдире иттеләр.

— Кыскасы, район халкын балык белән сыйларга туры килмәгән икән!

— Килмәде шул, парин!

— Алайса үзегез өчен генә берәмләп тотарга туры килер инде?

Бу юлы директор кинаяне аңлады.

— Һай, бик күңелле эш ул берәмләп тоту! — диде ул, тәмам очынып.— Бераз баш-күз генә алыйм, әбәзәтелне йөри башлыйм. Үзең тоткан балыкның тәме дә бөтенләй башка була бит аның, дөресме?

— Бик дөрес!

— Ихлас, яратам мин балыкка йөрергә, бик яратам! Тик монда безнең ишеләргә буш вакытны бер дә арттырмыйлар, аннан серьезный абзыйлар аны, балыкка йөрүне әйтәм, несерьезный эш дип карыйлар, конешно. Карасалар карарлар! Яренгә исән булсак, бу яр буйларында бергәләп утырырбыз!

Ул шулай үзенең балык каптыруга булган мәхәббәтен ихлас күңелдән әйтеп бирде дә, «машина көтә» дип, ашыга-ашыга китеп тә барды. Китәр алдыннан гына мин аның фамилиясен дә белеп алдым: Сабирҗанов икән.

Иптәш Сабирҗанов әйбәт, шат күңелле кешегә охшый, тик чын балыкчы булмаска тиеш — күп сөйләргә ярата.

Бу килүемдә уханы азрак ашадым. Аның каравы өйгә алты кило балык алып кайттым.

## II

...Тагын ямьле җәйләр әйләнеп килде.

Тагын тугай сукмакларында йөрисе килеп китте. Җитмәсә, төшкә дә, су читенә килеп, кармак салганны көтеп, авызларын ачып торучы җәеннәр керә башлады. Түзмәдем, ялымны алдым да тизрәк шул җәеннәр янына ашыктым.

...Ияләшкән урын. Менә яшел чирәмдә былтырдан калган түп-түгәрәк учак урыны, менә кара янган таш, әнә куак төбендә консервы калае аунап ята. Әйе, бер ел гомер күз ачып йомганчы үтеп тә киткән.

Бу юлы елга тирәсендә нindидер үзгәреш тә бар кебек сизелде. Күпердән таш, кирпеч төягән машиналар бертуктаусыз узып торалар. Елга үреннән тонык кына гүләгән тавыш та ишетелә. Машинасына су «эчерергә» туктаган бер шофердан мин бу җанлануның серен белдем: биш километр гына үрдә районара гидростанция салырга хәзерлек бара икән. Машиналар таш, кирпечләрне шунда ташыйлар, ә теге гүләгән тавыш — җиңел кулдан корып җибәргән такта яргыч тавышы икән.

Икенче көнне бик иртә, балык котырып уйнаган һәм, мин кайсы кармак артыннан күзәтергә белмичә, бик бирелеп каптырган чакта, кара айгыр җиккән тарантас күпердән кызу гына дөбердәп чыкты. Чыгу белән юлдан читкәрәк борылып, яр башында туктады. Тарантастан брезент плащ кигән кеше төшеп миңа таба килә башлады. Ерактан ук кулын болгап кычкырды:

— Булмый болай, аренда бәясе түләтергә туры киләчәк сездән, ияләшеп алдыгыз, ахры, ә?

Бу — «Заготживсырье» директоры Сабирҗанов иде.

— Саумы, дус кеше!

— Исәнмесез, иптәш Сабирҗанов! Ул минем белән күптән таныш үз кеше итеп, кул биреп күреште.

— Ошады, мин әйтәм, сезгә безнең Мишә чабаклары, ел саен киләсез!

— Килмәсәң, чабакларның хәтере калуы бар бит.

— Шулаймы, ярый, ярый! Кая, мактан әле булмаса! Мин бүген иртән генә эләккән, таза җепкә тагып су читенә җибәргән кило ярымлык корбанны алып күрсәттем.

— Әтә-тә-тә! Менә бу ичмаса корбан! Моның янына бер яртыны кыстырып килергә ярый икән... Үлеп яратам, кырын ятып, уха ашарга.

— Рәхим итегез! Уханың мировоен пешерәбез аны.

Сабирҗанов чүгәләгән җиреннән торып, башын чайкап куйды.

— Эх, вакыт, вакыт! Акчага да сатылмый бит!

— Эш бик күпмени шулай?

— Муеннан, брат! Ну ничего. Озакламый балык үзебездә булачак. Уха ашарга безгә килерсез.

— Кая сезгә?

— Безнең колхозга, «Дуслык» колхозына, моннан унике километр гына...

Минем чырай искәрмәстән яр башына килеп төшкән балык чырае сыманрак булып китте, ахрысы.

— Нигә ул хәтле хәйран калдыгыз? — дип сорады иптәш Сабирҗанов та.

— Туктагыз әле, былтыр гына бит сез «Заготживсырье» башында идегез?

— Былтыр бит ул! Ә менә быел, колхозларны эреләндергәч, мине зур бер колхозга председатель итеп җибәрделәр. Давай, Сабирҗанов, барып колхозны ныгыт, диделәр.

— Кы-зы-ык!

— Нәрсәсе кызык? Безнең шикелле житәкче работник өчен берни түгел ул. Чакырып алалар да кушалар, вәссәлам! Әйе, менә шул, безнең колхозның зур гына буасы бар, быел яз меңгә якын зеркальный карп дигән балык җибәрдек. Көзгә сөзеп, куыра башлыйбыз, рәхим итегез! Букчаңа да берничә кило салып җибәрербез.

— Рәхмәт! Кем белә, бәлки, барып та чыгарбыз.

— Пажалысты. Ярый, хәзергә хуш! Айгырны әнә кигәвен сырып алды.

Шулай диде дә иптәш Сабирҗанов, нәкъ уңган председательләрчә плащ итәкләрен җилфердәтеп, китеп тә барды.

## III

Беләсезме, иптәш Сабирҗанов белән тагын бер тапкыр очрашырга туры килде бит. Шул ук күпер төбендә. Былтыр булды бу, соңгы очрашуыбыз булды.

Чәй кайнатып эчим дип, яр башында коры-сары җыеп йөри идем. Карыйм, күпердән әрҗәләр, бау белән ураган төеннәр, чиләк, таз, ялгаш кебек нәрсәләр төягән һәм артына кызыл сыер таккан бер йөк арбасы шыгыр-шыгыр чыгып килә. Арба кырыннан дилбегә тотып, бер агай бара, ә шактый арттан, башын түбән иеп, кулларын артка куеп иптәш Сабирҗанов үзе атлый. Мин аны шунда ук танып алдым һәм кычкырып дәштем. Ул күтәрелеп карады да, ат тоткан агайга нидер әйтеп, миңа таба килә башлады.

Арба күпердән уза төшеп туктады.

Без кул бирешеп күрештек тә яшел чирәмгә утырдык. Сабирҗанов, фуражкасын салып, тирләгән маңгаен сөртте, аннан кесәсеннән папиросын чыгарды. Әйе, бу юлы иптәш Сабирҗановның кәефе башкачарак кебек, шат күңелләнеп, теленә ни килсә шуны сөйләргә ашкынып тору сизелми үзендә. Шулай да мин юри шаяртып сораган булдым:

— Әллә базарга сыер сатарга алып барасыз?

— Күченәм, брат, кире райүзәккә...— диде Сабирҗанов, соңгы сүзенә басым ясап.

— Ә колхоз?

— Колхоз нәрсә? Бер ел ныгыттың, җитәр, хәзер монда кирәксең, диләр. Авыз да ачтырмыйлар. Шулай, агай-эне, иген иктерә башларга өлгермәдем, инде менә кирпеч суктыра башларга туры килә.

Бик сәер булып тоелды бу эш миңа, хәтта иптәш Сабирҗановны бер мәлгә кызганып та куйдым.

— Кем соң сез, профессиягез буенча кем? — дидем, үзем дә сизмәстән кыза төшеп.

— Бөке! — диде Сабирҗанов, кырт кисеп.

— Ничек ул алай... бөке?

— Шулай инде, кайда тишек, шунда бөке без, каян ага башласа, шунда тизрәк илтеп тыгалар безне... Менә кирпеч заводына директор кирәк булып киткән. Давай, Сабирҗанов, кайт, заводны принимать итеп ал!

— Гаҗәп, гаҗәп...

— Гаҗәптер шул...— диде Сабирҗанов, ничектер авызының бер кырые белән генә елмаеп, һәм папиросын итек табанына басып сүндерде дә урыныннан торды.

— Ярый, сүз бозау имезер, ди, кузгалырга кирәк. —Кул биреп саубуллашканда, ул тагын ачылып китте: — Ә шулай да без сезнең белән балыкны бергәләп тотачакбыз әле!

— Ай-һай, туры килерме икән, сез бит әнә бер дә күченүдән бушамыйсыз?

— Юк инде! — диде Сабирҗанов, кинәт батыраеп.—Менә кайтып бер урынга ныклап утырам да, шуннан лом белән каерсалар да, кузгалмыйм, баста! Җитәр! Хушыгыз!

— Хушыгыз, иптәш Сабирҗанов!

Арба ялкау гына шыгырдап кузгалып киткәч, мин кармакларым янына төштем. Бүген чиртүнең дә әллә ни рәте-юне юк. Иң зур кармакка яңа җим куеп, төкергәләп, кыл җепне болгап, елга уртасына ыргыттым. Кургашын батыргыч, шоп итеп, суга барып төште, кызыл калкавыч башта кызу гына йөзеп китте, аннан, сикереп, аягүрә басты. Ичмасам, берәр адашып йөргән ташбаш килеп капмасмы, тамагына... бөке утыргыры!

1953

## Кем җырлады?

Ватан сугышының дәһшәтле көннәреннән берсе иде.

Көзге караңгы төндә кечкенә генә җимерек станциядә ике эшелон очрашып, янәшә туктадылар. Боларның берсе тылдан фронтка яңа хәрби часть алып баручы эшелон, икенчесе фронттан тылга яралылар төяп кайтучы санитар поезды иде. Эшелоннар икесе дә, бик озын булып, гел кызыл вагоннардан торалар. Тик санитар поездының гына паровозга якын очында бер-ике классный вагоны бар, ә калганнары исә кечкенә чуен мичләр куеп җылытылган теплушкалар иде.

Станция дигән нәрсәнең үзе дә, бер генә бер каралтысы да юк — бар да җимерелеп беткән. Тик юллар буенда берничә кат юан бүрәнәләр түшәп һәм балчык өеп эшләнгән зур гына землянка ялгызы калкып тора... Бөтен станциясендә ник бер генә тычкан уты җемелдәсен —әйләнә-юнь морҗа эчедәй кап-кара. Ләкин еракка күз ташласаң, сугыш барган якта, кайдадыр офык артында ук, күк чите буйлап сузылган кандай кызыл шәүлә тибрәнә. Янамы анда берәр зур авыл, туплар атышы шулай чагыламы — моннан карап белеп булырлык түгел.

Бөтен әйләнәдә фронтка якын җирләрдә генә була торган үле тынлык хөкем сөрә. Хәтта эшелоннар башындагы ике кап-кара паровоз да тып-тын тора, әйтерсең казаннарын сүндереп, аларны ташлап киткәннәр... Эшелоннарны томалап куйганнар диярсең, берсеннән-бер көлгән, сөйләшкән тавыш та ишетелми, төшеп-менеп йөрүче дә күренми. Тик араларыннан узганда, туктала биреп колак салсаң, бер яктагы кызыл вагоннардан ара-тирә каты хырылдау, икенче яктагы теплушкалардан авыр ыңгырашу ишетелеп кала. Берәүләр соңгы тапкыр йокы туйдыралар, икенчеләр бер күз йомарга гаҗиз булып яталар, күрәсең.

...Теплушкаларның берсендә түбәнге сәкедә каты яралы яшь лейтенант — татар егете ята. Егетнең хәле авыр, уң аягы аның тездән югары киселгән, ә санитар поезды юлга чыккач, аңарда гангрена башланды. Менә бер тәүлек инде ул, ни йоклый, ни уяна алмыйча, ярым һушын югалткан хәлдә ята. Вакыт-вакыт ул аңына килә, шул чакта авыр газаптан талган күзләрен ача, янында басып торган ак халатлы шәфкать туташын күрә, аның салкын кулын маңгаенда тоя. Бер мәлгә егет үзен җиңеләеп киткәндәй хис итә, хәтта уң аягы бар, ул кычыта кебек тоела аңа... Ләкин бу хәл озакка бармый, тагын бөтен тәне буйлап ут тарала,

күзләрендә бизгәк чаткысы кабына. Бераздан егет күз кабакларын акрын гына йома һәм, һушын югалтып, яңадан эссе томан эчендә йөзә башлый. Яткан урынын да, туташның кагылуын да, хәтта шприцның очлы энәсен дә ул инде тоймый...

Шулай үлем тырнагыннан ычкына алмыйча газапланып ята егет. Врачларның өметләре аз, гангренаның никадәр хәтәр нәрсә икәнен алар яхшы беләләр. Бигрәк тә юл шартларында авыруның хәлен җиңеләйтү бик читен эш иде.

Бу кечкенә станциягә килеп туктагач, күпмедер вакыттан соң, егет тагын бер мәлгә һушына килде. Талган, инде бу дөньядан китә башлаган күзләрен ачты, вагон эченә сибелгән зәгыйфь сары яктылыкны, шул тонык яктылыкта басып торган ак халатлы шәфкать туташын күрде. Тышта вагон стенасына ышкылып кына яуган көзге вак яңгырның әкрен генә кыштырдавын ишетеп алды. Кара янып кипкән иреннәрен хәлсез ялап куйды —эчәсе, бик эчәсе килә иде аның...

Шәфкать туташы моны аңлады, алюмин кружкадан аңа бер йотым су эчерде. Егетнең рәхмәт әйтерлек хәле юк иде, ул бары аз гына җылына төшкән күзләрен туташка күтәреп, кара керфеген генә сирпеп куйды.

...Әллә шул чакта, әллә чак кына соңрак, егетнең колагына каяндыр җыр ишетелде. Татарча җыр!.. Егет, өне катып, тынып калды. Нәрсә ишетә ул, кемне ишетә? Йа Хода, аның Таһирәсе җырлый түгелме соң? Шул ич, шул, Таһирә тавышы! Кайда ул?.. Егет, үзен белештермичә, яткан җиреннән кинәт бер омтылып куйды. Шунда ук аның күз аллары караңгыланып китте, башы хәлсезләнеп, мендәр читенә авып төште. Шәфкать туташы, куркынып, тизрәк аның кулын алды, пульсын капшады. Әмма егет һушыннан язмады, дөресрәге, һичнәрсәне, һичкемне сизмәс булса да, җырны ишетүдән туктамады. Яңадан бөтен дөньясы эссе томанга йотылса да, җыр... җыр калды.

Ә бу җыр чынлыкта бар иде, ул янәшәдәге эшелонның бер вагоныннан килә иде. Әгәр теплушка белән кызыл вагонның ишекләре бер-берсенә капма-каршы туры килгән булсалар, ишек яңагына сөялеп, кулларын шинель җиңнәренә тыгып җырлап торучы кыз, ихтимал, үзе дә күренгән булыр иде. Ләкин теплушканың аз гына ачык ишегеннән ут яктысы кыздан читкәрәк, кызыл стенага тар гына сары юл булып төшкән иде.

Күзгә күренмичә, берничә адымда гына җырлап торган кыз ялгызы гына булса кирәк, чөнки бүтән беркемнең дә тавышы-мазар ишетелми иде. Ихтимал, ул төнге дежурда торадыр, шунлыктан, ахрысы, иптәшләренең татлы йокысын бозарга теләмәгәндәй, ничектер тыелып, әкренрәк җырларга тырыша кебек... Әмма аның иркен, матур, аз гына калынрак күкрәк тавышы төнге тирән тынлыкта бик ачык булып ишетелә иде.

Кыз, үзенең ниндидер яраткан көен эзлиме, бер җырны башлый да, бетермичә икенчесенә күчә, бераз җырлагач, туктап тынып тора, аннан тагын акрын гына башлап китә. Үзенә күбрәк ошаган кайбер көйләрне озаграк та җырлап куя, әмма ул кем дә булса мине ишетәдер дигән уйны күңеленә дә китерми иде, әлбәттә.

Искиткеч таныш, якын тавышны ишетеп, беренче тирән тетрәнүдән соң егетнең рухи хәлендә гаҗәеп бер үзгәреш туды: ул җырлаучының кем булуы белән кызыксынмас булды. Күрәсең, аның сүнеп бетмәгән аңы могҗиза булуына — Таһирәнең кул сузымы гына җирдә җырлап торуына ышана алмады. Хәер, кем җырласа да барыбер түгелмени, тик җыр булсын, җыр туктамасын. Татар җыры, Таһирә җыры, туган ил җыры... Аһ, моңнардан да кадерлерәк һәм ләззәтлерәк нәрсә булырга мөмкинме соң?!

...Һәм вагон стенасына ышкылып кына яуган вак яңгыр аша әкрен-ачык ишетелгән җыр, күктән иңгән ак канатлы фәрештәдәй, егетне ут эчендә яткан җиреннән сак кына күтәреп, каядыр еракка, татлы хыял дөньясына алып менеп китте. Аның хәтта тәне, һавада йөзгәндәй, җиңеләеп калды, акылы ничектер бердән яктырып китте, сизгерлеге искиткеч үткенләште. Җырны инде ул хәзер моң итеп кенә ишетмичә, гаҗәеп ачык сурәтләр тезмәсе итеп тә күрә иде.

...Менә кыз әкрен генә башлап, аннан тавышын күтәрә төшеп, сузып кына җырлый:

Сарман буйлары, ай, киң ялан,
Печәннәре җитәр бер заман шул,
Печәннәре җитәр бер заман...

Һәм егетнең күз алдына үтә ачык булып, әллә кайларга кадәр җәелеп яткан чуп-чуар чәчәкле болын килә. Үлән башларын, чәчәкләрне селкетеп, йомшак кына җил исә, имеш. Каяндыр, тургай сайрауларына кушылып, чалгы янаган тавышлар ишетелә кебек, йомшак җил кибеп яткан покосларның хуш исен китерә кебек, тик егет печән чабучылар ягына нигәдер борылып карый алмый, имеш. Ул да булмый, аның күз алдына бормаланып киткән тар гына болын юлы килә. Хәтта бер мәлгә егет үзе дә ике рәт үлән арасындагы тәгәрмәч эзеннән, җылы туфракка яланаяк баса-баса, китеп бара кебек, ә каршысына киез эшләпә кигән, таяк таянган ак сакаллы бер бабай килә кебек.

Күпмедер вакыт узгач, кызның тагын моңлы җыры ишетелә:

Кояш бата, айлар калка,
Бик ямансу шул чакта...

Һәм егетнең күз алдына үзләренең шәһәрдәге кечкенә өйләре килеп баса. Эңгер-меңгер вакыты, имеш. Өйдә әнисе ялгызы гына икән. Менә ул, ак яулык бәйләгән кечкенә карчык, ут кабызып, бисмилласын әйтә-әйтә, тәрәзә пәрдәләрен төшереп йөри, тәрәзә төбендәге гөлләрнең кипкән яфракларын чүпләп-чүпләп ала, имеш. Өстәлдә яңа гына кайнап чыккан самавыр тора икән. Әнисе аның институттан кайтканын шулай чәй әзерләп көтә, имеш.

— Әнием, әнием! — ди егет, эченнән үксеп, һәм аның йомык күзләреннән сыгылып терекөмештәй кайнар яшь бөртекләре кипкән иреннәренә акрын гына тәгәрәп төшәләр. Шәфкать туташы кулын аның маңгаена куеп, иелеп, нидер сорый шикелле, ләкин егеткә гүя Таһирәсе дәшкән кебек тоела.

Шул чакта кыз, тирән бер сагыш белән:

Инде кемнәргә карармын
Өзелеп сагынганда...—

ди.

Һәм егет ике куллап Таһирәсенең башын күкрәгенә кыса, имеш, йөзен аның күперенке чәчләренә куя, имеш, иреннәрен аның җылы, йомшак муенына тидерә, имеш:

«Бәгырем, бәгырем, күз нурым! Нигә алай дисең, нигә елыйсың? Без мәңге, мәңге бергә ич!»

Һәм кыз, башын аның күкрәгеннән алмыйча, назланып, зарын әйтә кебек:

Сагынам үзем, юлда күзем,
Саргайды нурлы йөзем...
. . . . . . . . . . . . . . . . . .

Юк, юк, бүтән аерылу юк. Инде без бергә, дустым, мәңге бергә!.. Менә алар җитәкләшеп, ашыга-ашыга, Идел тавына менәләр, имеш. Тау бик биек икән, туктап-туктап тын алалар, кулларын җибәрмичә, сүзсез генә бер-берсенең күзләренә карап, бәхетле елмаялар, тагын кузгалып китәләр... Ниһаять, менеп җитәләр, йа Хода, нинди киңлек, нинди киңлек, нинди чиксез нур һәм ямь дөньясы бу туган җир! Шундый җиңел, шундый рәхәт аларга! Менә алар, тотынышкан хәлдә кулларын киң җәеп, таудан күтәреләләр һәм пар аккоштай елгалар, кырлар, урманнар өстеннән шул чиксез нур дөньясына очалар, очалар...

. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .

Кыз җырлавыннан кайчан туктады, каршыдагы эшелон кайчан тавыш-тынсыз гына кузгалып китте — егет моны сизмәде. Ул инде яңадан аңына килә алмады. Ә икенче көнне санитар поезды тагын бер җимерек разъездга җитеп туктады. Кызыл теплушкадан егетнең үле гәүдәсен носилкага салып чыгардылар да юлдан ерак түгел бер калкулык өстендәге ялгыз нарат төбенә илтеп күмделәр. Күмеп беткәч, туфрак өеменең башына кечкенә фанер кадакланган казык утыртып куйдылар. Фанерга кара буяу белән егетнең исеме, фамилиясе, туган һәм үлгән еллары язылган иде. Күмүчеләр, башларыннан салып, кабер әйләнәсендә бераз тынып тордылар да аннан барысы берьюлы вагоннарына таралдылар.

Поезд китте, ялгыз кабер торып калды.

Кинәт җил исте, биек нарат, эре яңгыр тамчыларын җиргә коеп, салмак кына башын чайкады. Күктәге салынкы соры болытлар, кемгәдер юл ачкандай, икегә аерылдылар. Шунда ук зәңгәр ачыклыктан, бәхилләшергә соңга калгандай, ашыгып кояш карады. Нарат төбендәге кабер өсте, әйтерсең егетнең җирдә калган, үлмәгән һәм мәңге үлмәячәк якты хыяллары белән кинәт нурланып балкыды.

Караңгы төндә каршы очраган эшелонның вагон ишегенә сөялеп, ялгызы гына моңаеп җырлаган кыз исә чыннан да бу егетнең сөйгәне Таһирә иде.

1956

## Ялгызлык

...Шушы елның февраль аенда мин Казаннан ерак түгел Бөреле совхозына барып чыккан идем. Бу зур һәм бай бер хуҗалык, биредә нәселле кроликлар һәм кара төлке, кеш, чәшке кебек кыйммәтле җәнлекләр үрчетәләр. Совхозга минем беренче генә килүем түгел, моннан биш-алты ел элек килеп, мин биредә берникадәр вакыт торып киткән идем инде. Шуңа күрә совхоз үзе дә, аның кешеләре дә миңа бераз таныш иде.

Директорның иркен бүлмәсендә совхоз хәлләре турында сөйләшеп утырган чакта, мин шул танышлардан берсен искә төшереп сорадым:

— Әйтегез әле, Николай Михайлович, сезнең хатын-кызлардан бер белгечегез бар иде, исеме, ялгышмасам, Тамара... Тамара... Ничек кенә үзе?

— Тамара Сергеевнамы?

— Әйе, Тамара Сергеевна. Бармы ул ханым, эшлиме хәзер дә?

— Ә сез аны беләсезмени? — диде директор, минем соравыма каршы.

— Элек килүемдә ул миңа үзенең төлкеләрен күрсәтеп йөргән иде. Сезнең кара төлкеләр фермасында баш зоотехник иде шикелле ул... Дөресме?

— Дөрес, шулай... Ләкин хәзер юк ул бездә, китте бездән, күптән китте инде.

Николай Михайлович моны ничектер эчке бер кызгану белән әйткән кебек булды, һәм мин моңа, билгеле, игътибар итмичә калмадым, шунлыктан тагы да кызыксына төшеп сорадым:

— Ни өчен китте? Нинди сәбәп аркасында? Әгәр сер булмаса, бәлкем...

— Юк, сер түгел,— диде Николай Михайлович, минем сүземне бүлеп.— Ләкин аның китүенең сәбәбен бер сүз белән генә әйтеп бирү дә читен. Үзенә күрә бер вакыйга булды ул.

— Шулаймыни? Алайса сөйләгез әле! Гафу итегез, болай үтенеп, мин сезнең вакытыгызны алмыймдыр ич?

— Зарар юк, конторада эш сәгате бетте, иркенләп сөйләшеп утырырга була хәзер,— диде ул, көлемсерәп.

Чынлап та, кышкы көн сүнеп бара иде инде. Бүлмә эченә сыек караңгылык акыртын гына иңә башлады, шулай да ут кабызырга иртәрәк иде әле. Николай Михайлович, үзе әйткәнчә озаклап сөйләшергә җыенгандай, иркен креслосының артына ята төште, өстәлдә яткан «Казбек» тартмасыннан үрелеп ашыкмыйча гына папиросын алды. Бу кырыкларга җитеп килгән таза, мәһабәт кеше моннан ике-өч ел элек кенә шушындагы белгечләрдән күтәрелгән директор иде. Аның белән беренче тапкыр гына очрашып сөйләшүем булса да, ул миңа ошап өлгерде. Фасон тотып маташмый, ягъни директор икәнлеген белдереп тору кайгысыннан азат, һәрвакыт үзенең табигый хәлендә, ләкин табигый хәленә аның бәйсезлек һәм үз-үзенә ышану хас булса кирәк, һәркем белән бертөсле, алдына килүченең йөзенә күтәрелеп карарга һәм сүзенә җавап бирергә иренми, кыскасы, чын кеше һәм әйбәт директор булырга тиеш.

...Менә ул миңа ике сәгать чамасы вакыт диярлек кеше язмышы турында сөйләде. Белмим, бик мавыктыргыч итеп сөйләдеме, әллә вакыйгасы бик гыйбрәтле идеме, ләкин мин хикәянең башыннан ахырына кадәр бер тапкыр да аның сүзен бүлмичә тыңлап утырдым.

— Сез беләсезме икән,— дип сүзен башлады Николай Михайлович,— Тамара Сергеевна безгә кырык беренче елның көзендә Ленинград тирәсендәге бер совхоздан үзенең җәнлекләре белән күчеп килгән иде. Бик йончып, бетеренеп килеп җиткән иде ул... Сугыш аларны тиз килеп баса, хәтта совхозның күп җәнлекләрен ирекkә чыгарып җибәрәләр... Тамара Сергеевна соңыннан шул җәнлекләренең таралмыйча совхоз ихатасына кире борылып-борылып кайтуларын сөйләгән иде... Бары җәнлекләрнең иң тазаларын гына берничә вагонга төяп, хатын-кыз, бала-чагаларны утыртып, Тамара Сергеевнаны шуларга баш итеп тизрәк ашыктырып озаталар. Тамара Сергеевнаның ире Ленинградта бүленеп кала, китәр алдыннан алар хәтта күрешә дә алмыйлар, кыскасы, мәхшәрдән качу була бу... Өч тәүлек юлны, тупиктан тупикка күчә-күчә, өч атна киләләр, җәнлекләренең яртысы ачтан кырыла, үзләре дә ачыгып, керләнеп, бетләп бетәләр. Тамара Сергеевна өчен аеруча зур бәхетсезлек тагын шул була — юлда бердәнбер кызы чирләп үлә. Өч яшьлек баланың кечкенә мәетен каядыр юл буенда күмеп калдыралар.

...Әнә шулай килеп җитәләр алар безгә... Ләкин сугыш, үзегез беләсез, кешене ташка әверелдерде. Кешенең, бәлкем, атна эчендә чәче агаргандыр, әмма бәгыре аның, тирән сызланудан соң, эретеп койган чуен шикелле катып калды. Шуңа күрә үз башыңа төшкән хәсрәт турында сөйләү юк, елау юк, барысы да бик тирән яшерелгән, тик нидер өзелеп теләү, нәрсәгәдер теш кысып омтылу бар... Ленинградтан килүчеләргә карап, моның шулай икәнлегенә ышанмыйча мөмкин түгел иде.

Тамара Сергеевна бездә дә кара төлкеләр фермасында баш зоотехник булып эшли башлады. Аның авторитеты үзе белән бергә үк ияреп килде: югары белемле, зур хуҗалыкта эшләп тәҗрибә алган яшь белгеч иде ул... Шуның өстенә ул чын-чыннан Ленинград кешесе иде. Ленинградта туып үскән, шунда укыган, шунда тормыш башлаган... Өс-башы да аның бүтәнчәрәк, йөреш-торышы да бүтәнчәрәк, сөйләшүе, хәтта көлүе дә бүтәнчәрәк, кыскасы, зур культура мәркәзеннән килгән кеше, әйтик, безнең ише район халкыннан үзенә генә хас ниндидер бер нәфислек, пөхтәлек һәм әдәплелек белән аерылса, бу яшь ханым да күпләрдән шулай аерылып тора иде. Ул чын, яхшы мәгънәдә, ягъни тышкы калыбы белән генә түгел, эчке җаны белән дә интеллигент кеше иде. Мин хәтта әйтер идем, бу «интеллигентлык» аңардан ничектер менә нәфис бер ис шикелле аңкып тора кебек иде. Дөрес, безнең шартларда хуш ис акрынлап бетте, һәрхәлдә, безнең борыннар сизми башлады, әмма асылда ул барыбер шундый ук культуралы, әдәпле, нечкә җанлы хатын булып калды.

Без аның Бөреле совхозында утырып калуына һич ышанмый идек. Хәер, ул үзе дә моны яшерми иде. «Сугыш кына бетсен!» — ди торган иде ул, вакыт-вакыт тирән көрсенеп, һәм артыгын әйтеп торуны кирәк тә санамый иде. Гомумән, ул баштa бик аз сөйләшә иде, гүя бөтен уе аның магнитка тартылган компас теле кебек шул туган шәһәренә, анда калган якын кешеләренә төбәлгән иде. Сүзсез йөрәгендә күпме сагыш, күпме борчылу таш булып ятканлыгын аның җитди-моңсу кара күзләре үк әйтеп тора иде. Бигрәк тә блокадада калган Ленинградтан бер хәбәр дә килмәү, иренең язмышы билгесез булу аны бик изә иде шикелле. Тик күп айлар үткәч кенә һәм эш дигән шифалы дәрьяга башаягы белән чумгач кына, ул, үзенең хәле белән килешкәндәй, бераз тынычланган кебек булды. Анда да, сүз чыккан саен, Ленинградын сагынды, кире шунда кайтып, яңадан искечә яшәү турында хыялланды. Өмет, өмет! Менә нәрсә кешене яшәтә бит!

Ниһаять, көтә торгач, Ленинград блокададан азат ителде, ахырда сугыш та бетте, һәм Тамара Сергеевнаның тормышына тулы ачыклык та керде. Иренең фронтта, әти-әнисенең блокада вакытында

һәлак булулары беленде. Бүтән туганнары да кайсы кая таралып беткәннәр икән. Шулай итеп, сугыш Тамара Сергеевнага иң авыр бәхетсезлек — ялгызлык бәхетсезлеген китерде. Иске өметләр сүнде, инде яңасын кем кабызыр?

Шулай да без аны үзенең Ленинградына кайтып китәр дип уйладык, ләкин ул ни өчендер китәргә ашыкмады. Туздырылган оясын кайтып күрәсе килмәдеме, яки кинәт туган бушлык аркасында дөньясына кул селтәдеме, белмим, нәрсәдер, әмма яшь ханым күләгә төсле безнең арада һаман йөри бирде. Сүзе юк, өне юк, кечкенә бүлмәсен белә дә фермасын белә, калганы гүя аның эше түгел!

Биредә шуны әйтергә кирәк: әле сугыш бетмәс борын ук безнең җәнлек тиреләрен Америка сатып ала башлаган иде. Сугыштан соң затлы мехларга сорау тагы да артты. Ләкин Американың бик еш мода алыштырырга яраткан хатын-кызларына мехның йә ачыграк төслесе, йә тоныграк төслесе кирәк була иде. Без, билгеле, бу таләпкә яраклашырга тиеш идек. Ләкин ничек итеп? Җәнлек бит кулдан эшләнми, үзе кебек җәнлектән туа. Аның төсен бик аз гына үзгәртү дә гаять катлаулы, нечкә эш. Менә шул эшкә Тамара Сергеевна кереште. Бик әһәмиятле нәрсә иде бу безнең өчен... Әйтергә кирәк, бер-ике елдан соң Тамара Сергеевна өметле генә нәтиҗәләргә дә ирешә, ягъни аның ихтыяры белән безнең төлкеләр йә ачыграк, йә тоныграк төсле булып үсә башладылар...

Мин биредә бу эшнең махсус якларына керешеп тормыйм, әгәр кирәксә, анысын соңыннан сөйләрмен, ә хәзер тизрәк төп вакыйгага барып җитәсем килә. Билгеле инде, бу зур уңыштан соң Тамара Сергеевнаның дәрәҗәсе тагы да үсте, кадере тагы да артты. Бу аның үзенә дә, һичшиксез, зур юаныч, зур канәгатьләнү китергәндер. Ләкин ул безнең арада, оясыз күккүк шикелле, һаман ялгыз иде.

Кырык сигезенче елның җәендә ул, ял алып, ниһаять, Ленинградка кайтып китте.

Озатканда барыбыз да, моның бөтенләй китүедер, кире безгә кайтмас инде дип, аңа һәртөрле уңышлар, бәхетләр теләп калдык. Ул үзе дә, ачыктан-ачык әйтмәсә дә, шундыйрак ният белән кайтып китте шикелле. Озаткан чакта ул, дымланган күзләре белән кызганыч елмаеп, безгә: «Хушыгыз, дуслар, әгәр күрешмәсәк, яманат белән искә алмагыз!» — дип китте. Моны инде чынлап та бөтенләйгә саубуллашу дип аңларга кирәк иде.

Ләкин... ялы тулуга, Тамарабыз кире кайтып төшмәсенме! Сез, бәлкем, ялдан кайтмыйча калырга ярамый бит диярсез. Дөрес, әмма эвакуацияләнгән кешеләргә үзләренең торган җирләренә бер тоткарсыз кайтып китү хокукы бирелгән иде, шуңа күрә Тамара Сергеевна Ленинградтан кечкенә бер гариза кисәге җибәрсә, шуның белән эше дә бетә иде. Ләкин ул кайтты, Ленинградтан Бөрелегә кайтты. Ни өчен, ни сәбәп? Үзе ул безгә бары:

— Сездә аяз көннәр күбрәк, шуның өчен кайттым,—дигән булды.

Асыл сәбәбен төпченеп сорашу, әлбәттә, читен иде, берәү дә моңа җөрьәт итмәде.

...Кайтты һәм яңадан үзенең фермасында, үзенең кыргый сылу төлкеләре арасында эшләп йөри башлады.

...Айлар үтә, еллар үтә, рәхимсез вакыт кешегә бирелгән гомер йомгагын акрын гына сүтә бара. Тамара Сергеевна безгә килгәндә егерме алты-егерме җиде яшьлек нәфис хатын иде, инде менә утыз бишкә дә җитеп килә. Кара чәчләрендә сирәк кенә ак җепләр дә күренгәли башлады, күз төпләрендә вак кына челтәр дә пәйда булды, яңак сөяге астына беренче сызык та ятты. Ләкин шулай да ул яшьлек гүзәллекләрен җуеп бетермәгән иде әле. Гәүдәсе һаман шулай җыйнак-сылу, хәрәкәт-йөреше җиңел, бите чиста, кара күзләре якты, иреннәре тулы, саф... Ләкин барыбер инде ул — көзге чәчәк, тагын берничә ел — һәм ул сабагында шиңәчәк.

...Бу әле кешенең, ничек дип әйтим, тышкы ягы, тышкы яктан булган үзгәреше генә. Ә аның эчендә нindirәк процесс бара? Бу кадәресе тагы да катлаулырак һәм газаплырак түгелме?

Менә хәзер мин сезгә аның бездән китүенә сәбәп булган вакыйганы сөйлим. Чыннан да, уйлап карагыз: гаепле идеме ул, әгәр гаепле булса — нидән гыйбарәт аның гаебе?

...Илле икенче елның җәй башында Тамара Сергеевна тота да Петр Котов дигән бер егет белән тора башлый. Кешеләр арасында еш кына була торган бу хәл шулай да күпләрне бик гаҗәпләндерде. Иң элек бу «кушылуның» алдан бернинди билгесе булмады, кинәт көтмәгәндә килеп чыкты ул... Совхоз поселогы кечкенә җир, биредә кешенең һәр адымы күз алдында, ялгыз кешеләрнең бер очрашып сөйләшүләре дә хәзер үк халык теленә кереп китә... Ә Тамара Сергеевна эшен шундый шома йөрткән булса кирәк, бары җәйге иртәләрнең берендә ул, Петр Котов белән үз квартирасыннан чыгып, поселок урамыннан икәү янәшә атлап киткәч кенә кешеләр ни булганын белделәр. Белделәр... һәм хәйран калдылар. Ләкин көтелмәгән яңалык булганы өчен генә түгел... Мәсьәлә җитдирәк иде.

Кем соң ул Петр Котов? Нәрсәсе белән, нинди кешелек сыйфатлары белән ул Тамара Сергеевнага яраган, аңа тиң була алган?

Иң элек шуны әйтергә кирәк, егет Тамара Сергеевнадан нәкъ сигез яшькә кече иде. Хәер, тол хатыннарның үзләреннән шактый яшьрәк ирләргә тормышка чыгулары очрый торган хәл, моның ахыры ни белән бетә торгандыр, ләкин, һәрхәлдә, гаептән саналмый. Бу очракта да, чырай сытыбрак булса да, килешергә туры килә... Инде егетнең бүтән якларын алып карыйк: ул безнең ремонт мастерскоенда слесарь булып эшли иде. Урта кул слесарь, күбрәк фермаларга барып, водопровод трубалары төзәтеп

йөри. Белеме шул биш-алты класс тирәсендә булгандыр. Хәер, яхшы кеше һәм итагатьле ир булыр өчен профессиянең әллә ни зур әһәмияте юк. Безнең район җирендә, әйтик, врач кыз белән шофер егетнең өйләнешеп, матур гына торуларын кайчагында күрергә була. Ләкин һәр очракта да бу шулай дип әйтүе читен, әлбәттә. Биредә, газетчалап әйткәндә, уңышны тәэмин иткән нәрсә — кушылучыларның аң һәм культура дәрәҗәләре бертигезрәк булуыдыр, ахрысы... Хуш, бу җәһәттән безнең Петя Котов ничегрәк иде соң? Мисал өчен, Тамара Сергеевна белән янәшә куеп карасак, без аны ниндирәк кыяфәттә һәм сыйфатта күрер идек?

Күз алдыгызга китерегез: кичкырын клуб алдында егерме биш-егерме алты яшьлек чибәр егет басып тора. Өстендә аның кызыл майка өстеннән генә кигән кара пиджак, тез башлары чыгыбрак торган кара чалбар, аякларында көрән брезент ботинкалар. Ашыкмыйча гына папиросыннан «алкалар» җибәрә һәм, чабак сагалаган чуртан шикелле, кызлар күзәтә. Теләсә кемгә ташланырга тормый ул, сайлап кына дәшә, простой ферма кызлары белән эре сөйләшә, аларга ни әйтсә дә ярыйга саный, ә культурныйрак туташлар белән сүз башлый калса, аларга инде «сез үзегез», «без үзебез» дип сайрарга тотына, бөгелгәләп тә ала, кулларны да матур гына уйнаткалап куя. Мондый «нечкә» кыланышларны ул каяндыр отып алырга өлгергән иде инде, күрәсең, безгә килгәнче урыннан урынга еш кына күчеп йөрүләр аның өчен бушка китмәгән. Күпме-азмы шомарган егет! Шулай да кызлар аның тирәсендә үзләрен, утка пешүдән курыккандай, сак тоталар иде.

...Иптәшләре арасында Петя бозык яки начар холыклы егетләрдән саналмый иде. Әтәчләнеп, кешеләргә бәйләнеп йөрми, юктан да тавыш куптарырга тормый, йодрыгы белән масаймый, теле белән мактанмый, кыскасы, тупаслыкны егетлеккә санап, скандаллар герое булып йөрүчеләрдән түгел иде. Ул хәтта аз сүгенә дә иде (ә бу әшәкелек бер категория яшьләр арасында шактый таралган чир бит), бик ачуы килгән чакта гына, дүрт юллык шигырь әйткәндәй, рифмалап сүгенеп җибәрә торган иде. Эчү белән дә артык мавыга иде дип әйтеп булмый аны, тик получка вакытларында гына салгалый иде. Бусы инде традициягә хөрмәт. Слесарь булсын да, получкада эчмәсен, имеш!

Егетнең максаты нәрсә, нинди интереслар белән яши ул,— әйтүе читен. Нәрсәгә булса да омтылышын ул бервакытта да сиздермәде. Гомумән аз сүзле егет иде ул, акылын эшләтергә яратмый иде шикелле, карасу шома йөзендә берни юк дияр идем, тик кеше әйткән пустяк сүзгә дә көлеп җибәрергә әзер тору гына бар. Сез тагын аны томана, мокыт нәрсә икән дип уйлый күрмәгез, һич алай түгел. Киресенчә, егеттә мин-минлек тә Аллага шөкер, кирәк урында үзен тәкәббер тота да белә, кыюлык та җитәрлек (бигрәк тә хатын-кыз тирәсендә), ә инде берәрсе аңа кагыла калса, егет сүзен дә таба, йодрыгын да иснәтә белә. Так что, бу юаш икән дип, бармагыңны авызына тыга күрмә!.. Ләкин характеры белән ваемсыз, пошыну белмәс, нибарына канәгать булып яшәүче бер кеше иде ул. Андый кешенең тормыштагы кагыйдәсе: «Әйдә, ярар!»

Әмма ул төскә-башка бик чибәр егет иде. Урта буйлы, бик төз, җыйнак тыгыз гәүдәле, көч үзендә яман булырга тиеш, беләкләрендәге таштай мускуллары буын-буын калкып тора. Кашлары куе кара, керфекләре озын, борыны туры, ияк очы чокырлы, ә тешләре — үлчәп эшләнгәндәй тип-тигез дә ап-ак... Ялкау гына атлап йөри ул, гүя көче-куәте тамырларына кургашын булып таралган.

Менә шундый егет иде безнең Петя Котов. Һәм шушы егет белән хөрмәтле Тамара Сергеевнабыз ачыктан-ачык тора башлады. Чыннан да, хәйран калдырырлык һәм уйландырырлык хәл бит бу!

Сезне, бәлкем, ничек итеп алар табышканнар да кушылып киткәннәр дигән сорау борчый торгандыр. Бу кадәрәсе безнең шартларда читен эш түгел. Мондагы халык барысы да бер җиргә тупланган, барысы да бер хуҗалыкта эшлиләр, хәтта таптап йөргән сукмаклары да бер үк... Шулай булгач, Тамара Сергеевна белән Петяның күптән бер-берсен күреп йөрүләре бик табигый. Аннан Петя еш кына аның фермасына тегене-моны төзәтергә барып йөри иде, ихтимал, шул чакларда карап торырга болай зарарсыз, тыйнак кына күренгән аз сүзле чибәр егет яшь ханымның күңелен җилсетеп куйгандыр. Шуның өстенә мастерскойда эшләүче егетләрнең тулай йорты Тамара Сергеевна торган өйнең күршесендә генә иде. Бу да әледән-әле бер-берсенең күзенә чагылырга бер сәбәп. Аннары, ничектер юллары туры килеп, берничә тапкыр төнлә клубтан да бергә кайталар, һәм, ниһаять, егет, үз инициативасы беләнме, әллә чакыру буенчамы, Тамара Сергеевнаның өенә дә керә. Бер керә, ике керә һәм озак та үтми шунда торып та кала. Күп кирәкмени, итәгеңә утлы күмер төшсә, кабынып китәргә... Сез аңлагыз, күпме еллар ир назы күрмичә яшәгән хатынның хәлен! Йә, аның, дым эчкән туфрак шикелле, сагыш белән тулы йөрәгенә нинди генә орлык төшсә дә, ул тиз генә тамырланып китмәс идемени?

...Билгеле, күпләр, аеруча хатын-кызлар, Тамара Сергеевнаның бу эшенә бары бер яктан гына карадылар: янәсе, аңа яшь, таза ир кирәк булган, һәм китте шушы хакта селәгәй агызып гайбәт чәйнәү... Белмим, хатыннар, бәлкем, мәсьәләнең бу ягын нечкәрәк аңлый торганнардыр, ләкин минем өчен, хәер, бер минем өчен генә түгел, ә Тамара Сергеевнаны якыннан белгән күпләр өчен мәсьәлә тирәнрәк һәм катлаулырак иде. Хәзер дә исемә төшсә ачуым килә: ир кирәк булган, имеш! Әйтегезче, зинһар, ә кемгә ир кирәкми? Кемгә хатын кирәкми? Кешеләр балигъ булгач та шул турыда уйлый, кайгырта башламыйлармы соң? Тамара Сергеевна гарип хатын түгел бит. Ни өчен һәркемгә яраган нәрсә аңа ярамый? Ни өчен табигать тарафыннан һәр җан иясенә бирелгән теләктән ул гына мәхрүм булырга тиеш? Ханжалар карашы

бу... Киресенчә, гомеренең иң матур чакларын тол үткәрергә мәҗбүр булган сау-сәламәт хатынның үзенә иш табып ир белән тора башлавына сөенергә генә кирәк иде.

Ләкин, кабатлап әйтәм, мәсьәлә тирәнрәк һәм катлаулырак... Ялгызлык, әйе, ялгызлык! — менә нәрсә, минемчә, аңлатса кирәк Тамара Сергеевна кичергән тирән йөрәк фаҗигасен... Юк, аңа ир генә түгел, кеше кирәк булган, дус кирәк булган. Кемнеңдер гел янында булуын теләгән ул, кемнеңдер аның тормышына кереп урын алуын теләгән ул. Шуның белән кешеләр арасына чыгасы, үзенең бүтәннәр кебек үк ишле-парлы булуын күрсәтәсе килгән аның... Ә бу нәрсә хатыннарга бик хас теләк, алар кушылган кешеләрен яшереп тотарга яратмыйлар... Һичшиксез, Тамара Сергеевна семья җылысын сагынган, шул турыда күп хыялланган булырга тиеш. Беләсезме, хатын-кыз йөрәге һәрвакыт кем турында булса да кайгыртып торуны ярата бит ул. Ир дигән кешенең күлмәгенә төймә генә тагып бирсә дә, юаныч таба ул. Ниһаять, аның яңадан ана буласы килгәндер, бала өмет иткәндер, һәм, һич шик юк ки, ул, Тамара Сергеевна, мәхәббәткә сусаган йөрәгенең бөтен кайнар дәрте белән егетне яратып киткән булырга тиеш.

...Бик табигый хисләр, бик аңлаешлы теләкләр ич болар. Ничек шуларны күрмәскә мөмкин ди? Безнең секретарь әйтмешли, просто кабахәтство бу!..

Соң, белә идеме Тамара Сергеевна үзе хакында йөргән шул алама гайбәтне? Әлбәттә, белгәндер, хәле шундый аның, белмичә калуы мөмкин түгел... Ләкин ул аңа һичбер нинди борчылу, уңайсызлану яки кәефсезләнү кебек нәрсә күрсәтмәде. Гүя берни юк, бар да нормаль, бар да тәртиптә. Петя Котов белән кешеләр арасына чыгып йөрүдән һич тартынмый иде, аның белән култыклашып киносына да бара, бакчасына да чыгып утыра. Кайчак бергәләп шәһәргә дә барып кайталар. Әлбәттә, яңа гына кияүгә чыгып, бәхетен тапкан яшь кыз шикелле үзеннән-үзе сөенеп, очынып тору юк аңарда. Ул тыныч, ул басынкы, ул үзен күптәнге ир хатыны кебек тота. Һәм аның Петяга булган мөнәсәбәтендә егетне үзенә чын ир, якын кеше итеп күрсәтергә тырышуы сизелә иде... Ул бераз ябыга, суырыла төште, күз төпләре уелып, моңсу-тыныч карый торган күзләре зурайган кебек булды, ә акыллы йөзендә аның нидер көтүне чагылдырган бер дә югалмас җитдилек күренә иде.

Ләкин ничек кенә булмасын, әмма аларга караган саен ихтыярсыздан күңелне бер сорау борчый иде: ничек итеп Тамара Сергеевна бу Петяны үзенә тиң итә алды икән, нәрсә уйлап ул аның белән тормыш итә башлады икән? Үзе белән егет арасында никадәр тирән чокыр ятканлыгын, егетнең бер ягы белән дә үзенә лаек булмаганлыгын ничек күрмәде икән?

...Юк, күргән булырга тиеш, һичшиксез күргән булырга тиеш. Тамара Сергеевна кебек акыллы, сизгер хатынның кеше танымавына ышанып буламы соң! Алайса эшнең сере нидә?

Петя Котов кебек егетләрнең гадәттә кешене, бигрәк тә хатын-кызны, алдата торган бер сыйфатлары була. Алар, ягъни Петя кебекләр, үзләренең әнә шул ваемсызлыклары, беркатлы простойлыклары белән ничектер кулга ияләшердәй җәнлек кебек күренәләр. Әгәр аларны кулга алып, үзеңә буйсындырсаң, алардан менә дигән кеше ясап булачак. Бозылмаган яшь күңел — язылмаган чиста кәгазь, диләрме әле? Янәсе, бозылмаган яшь күңелгә бары изгелек белән яхшылыкны гына язып барырга була... Бичара хатын үзенең шушы яшерен хыялларына ирешер өчен, яраткан Петясын кеше итәр өчен шактый тырышып карады. Хәтта кайбер нәтиҗәләргә дә ирешкән кебек булды. Моңарчы общежитиедә керле урын өстендә аунаган Петябызга мамык куна башлады. Иң элек, Тамара Сергеевнаның якын кешесе булып киткәч, аның беркадәр дәрәҗәсе күтәрелде, өлкәнрәк абзыйлар, совхоз җитәкчеләре аңа, Петр Васильевич, дип дәшә торган булдылар... Егет үзе дә эреләнеп, олы сымаграк булып китте, йөзенә аның төче елмаю астына яшеренеп кенә «шаярмагыз минем белән» дигән масаю чыкты. Дөрес, өлкәнрәк кешеләргә ул моны күрсәтмәскә тырыша, ләкин ничек кенә тырышмасын, бик әйбәт тәрбиягә эләккән песи шикелле үз-үзеннән тук канәгатьләнүне беркая да куя алмый — кыяфәт үзе үк кычкырып тора... Егетнең өс-башына да бераз культура йокты: майка өстеннән күлмәк киеп йөри башлады, пиджак-чалбары үтүкләнгән, чистартылган булды, моңарчы тузгытып йөрткән чәчләрен дә матур гына итеп тарап куярга өйрәнде... Ашау-эчү ягы да үзгәрмичә калмады. Хәзер инде егетебез төшке ял вакытында мастерской күләгәсендә коры икмәк күшәп утырмый, ә көн дә Тамара Сергеевна биреп җибәргән завтрак — май яккан күмәч, пешкән йомырка, кайнаган сөт белән сыйлана... Болары әле кеше күзенә чагылган кадәресе генә, ә яраткан хатын янында ул нинди тәрбия, нинди ихлас кайгырту күрмәгәндер?

Шулай, дус кеше! Ләкин, кызганычка каршы, бу үзгәрешләр бары тышкы яктан гына иде шул. Ходай егеткә көтмәгән бәхетне җирдән табып бирде. Инде аңа шул бәхетенә ике куллап ябышырга, Ходаем, кире ала күрмә, дип ялварып кына торырга кирәк иде; Тамара Сергеевна кебек кешене бит ул көндез чыра яндырып эзләсә дә яңадан табачак түгел! Ләкин Петя, дурак, өстенә ауган бу бәхетнең әһәмиятен дә аңламый, кадерен дә белми иде булса кирәк. Чөнки ул үзенең характеры белән дә, гадәтләре белән дә һич үзгәрмәде диярлек. Элеккечә ваемсыз, мәнсез ул; аның өчен үгез үлсә — ит, арба ватылса — утын, һаман шул «әйдә, ярар!» дигән принцип белән селкенеп йөрүче кеше булып кала бирде. Тамара Сергеевна белән кушылуына ул чираттагы «җиңү» һәм вакытлы бер эш итеп карады. Гәрчә шундый дәрәҗәле, матур, интеллигент хатынның аны тиң итүенә борынын күтәрсә дә, бу бары: «Күрдегезме, мин кемне эләктердем»,— дип мактанудан гына гыйбарәт иде. Шуңа күрә бичара хатынга тиешле хөрмәт тә юк, аның кем икәнен аңлау да юк, аның яхшы исемен, абруен сакларга тырышу да юк. Ул гынамы әле!

...Менә Петя иртәнчәк мастерскойга килә. Сүлпән генә эшкә тотына, йокысы калгандай киерелә-сузыла, әледән-әле яңак сөякләре шытырдаганчы исни... Беләсез инде, мондый чакта яшьләрдән кайберәүләр (Петяның үз ишләре) шаяртырга яраталар, бер дә тарсынмыйча, «ничегрәк соң?», «алайракмы, болайракмы?» дигән төсле, күңелдән уйларга да оят сораулар бирәләр. Ә Петя нишли шул чакта? Берәү булса, кызыксынучыларның авызларын мәңге ачылмаслык итеп томалар иде, ә ул, ишәк, тегеләрнең әйткәннәрен раслагандай, мәгънәле төче итеп елмая, бик туры китереп әйткәнне ишетсә, «черти-и!» дигән булып башын гына чайкап куя... Бөтен бәла шунда, минемчә, Петя Котов гомумән интим мөнәсәбәтнең никадәр изге-яшерен булырга тиешлеген, якын кешеңнең намусын, чисталыгын саклау белән бәйләнгән булуын аңлаудан ерак тора иде. Һәм аның әнә шулай үз ишләренең пычрак шаяртуларына кинәнүен күргәннән соң, Тамара Сергеевна очрый калса, аңа каравы әллә ничек авыр да, уңайсыз да булып китә иде. Бичара хатын өчен чеметтереп күңел әрни, шул ук вакытта аңа ачу да килә иде. Ихтыярсыздан, әлеге гайбәтчеләр сүзе күңелгә килмичә калмый иде.

Ә Тамара Сергеевна — горур хатын, һаман элеккечә башын текә тотып, иренен кысып йөри бирә. Гүя беркемдә, бернәрсәдә эше юк, бары фермасын да өен, кара төлкеләрен дә Петясын гына белә. Хәтта, мин әйтер идем, аның горурлыгы соңгы вакытларда көчәя төште, әйтерсең горурлык аның өчен һәртөрле начар сүз, яман карашлардан саклый торган бердәнбер калкан иде... Әмма шулай да бу акыллы хатынның җаны тыныч булмаска тиеш иде. Ул әллә егетнең ни уйлап масаюын, аңа, үзеннән сигез яшькә олы хатынга, ничегрәк каравын, ниһаять, аның иң кадерле, иң яшерен хисләрен ятларга фаш итүен сизмәгәндер дисезме? Юк, сизгәндер, Петя аның өчен табышмак түгел ич! Һәм горур ханымга вакыт-вакыт бик хурланырга да, әрнеп сыкранырга да туры килгәндер, әлбәттә. Ләкин ниләр генә кичермәсен, бөтенесен дә ул, бердән, үзенең әнә шул горурлыгы, икенчедән, яшерен өмете белән җиңәргә тырышты булса кирәк... Әйе, бик гаҗәп иде болар барысы да безнең өчен, әмма вакыйга үзе ахырда бу сәер төенне чишеп бирде безгә!

...Сүз бит Тамара Сергеевнаның ни өчен бездән китүе турында башланган иде. Тыңлагыз, бу аяныч вакыйганың соңы бик гыйбрәтле.

Шул елның көзендә (ә алар — Тамара белән Петя —җәй башында кушылганнар иде) бер механикны Ленинградка алты айлык курсларга җибәрергә кушып, безгә главкадан язу килгән иде. Менә шул хәбәрне ишеткәч тә, Тамара Сергеевна тиз үк директорга килеп җитте. Ул бик үтенеп директордан курска Петр Котовны җибәрүен сорый башлады. Директор коры гына «карарбыз» дию белән чикләнгәч, ул парткомга да кереп сөйләште. Аңардан «Ни өчен ул хәтле Петяны җибәрәсегез килә?» дип сорагач, Тамара Сергеевна, мескен, хәтта уңайсызланып та калды. Асыл теләген әйтергә кыймыйча, шунлыктан дулкынланып, ул Петяның яхшы слесарь, әйбәт кеше булуын, тик аңа уку җитмәвен исбат итәргә кереште. Хәер, ни өчен дип сорау урынсыз да иде, болай да хатынның теләген аңларга мөмкин иде. Әгәр курс бүтән бер шәһәрдә булса, ул, бәлкем, бу кадәр ялварып сорамаган да булыр иде. Ләкин Ленинград бит, аның туып үскән шәһәре! Йә, ничек ул үзенең Петясын шунда җибәреп, укытып-йөртеп кайтарырга теләмәсен ди?

Әлбәттә, совхоз җитәкчеләре каршында Петя Котов курска җибәрер өчен бик үк лаеклы кандидатлардан түгел иде. Аңардан куда шәбрәк егетләр бар иде. Ләкин Тамара Сергеевнага хөрмәт йөзеннән, аның телдән әйтә алмаган изге теләген аңлап дигәндәй, Котовны курска җибәрергә булдылар.

...Китәр көннәр якынлашкач, Петя мастерскойдагы иптәшләре алдында болай дип мактана икән: «Беләсезме, егетләр, минем Тамара миңа целый список төзеп бирде: менә, имеш, син, дустым, шуларның барысын да күреп кайтырга тиешсең. Эрмитаж, Смольный, Петергоф, Зимний, тагын әллә нинди дворецлар, әллә нинди музейлар —барысын да тезгән. Ә театрларны әйткән дә юк... В общем, агартырга уйлый мине Тамарочка...» Бу юлы егетләр сүзне уенга бормыйлар, киресенчә, вәт шундый хатының булса иде дип сокланалар, син, тиле, Тамара Сергеевнаның кадерен бел, диләр, тик арадан берсе генә шаяртып: «Ә ресторганнарны күрсәткәнме?» — дип сорап куя. Петя, гәрчә чәйханә буфетыннан юньлерәк җирне күрмәгән булса да, эре генә җавап бирә: «Аларын мин үзем дә табам...»

Ниһаять, безнең асыл егетебез, яңа пальто, фетр эшләпә киеп, Ленинградка китеп бара... Хәерле юл!

...Көннәр, атналар узалар, совхозда җәнлекләр үрчиләр, Петя берәүнең дә төшенә кереп борчымый. Бердәнбер борчылып торучы һәм сагынып көтүче — мескен Тамара Сергеевна. Башта егеттән кешегә күрсәтмәслек кыска-кыска гына кайнар «мәхәббәт» хатлары килә, аннан сирәгәя бара, ахырга таба онытылганда бер генә килә башлый. Хатларында «мәхәббәт» акрынлап сүрелә, аның каравы акча теләнү көчәя. Тамара Сергеевна, билгеле инде, акчасын да җибәреп тора, соңгы көнгәчә озын-озын хатларын да язып тора.

Ләкин ул, Петя киткәннән бирле, ни өчендер гел боек йөрде, әлеге нидер буласын көткән киеренке җитдилек аның йөзеннән бер дә китмәде. Гомумән, мин аның, Петя белән бәйләнгәч, җәелеп бер, хәсрәтсез дигәндәй, елмайган чагын күрмәдем.

Менә бер заман Петя Котовның кайтыр көннәре дә килеп җитте, һәм шул чакта бөтен совхоз халкын таңга калдырган гадәттән тыш вакыйга булды: язгы төннәрнең берендә Тамара Сергеевна совхоздан югала. Бу ни хәл бу? Икенче көнне Тамара Сергеевнаның күршесендә торучы хатын совхоз директорына

бер конверт китереп тапшыра. Конверттан записка һәм бер кечкенә хат чыга. Записка Тамара Сергеевнадан булып, анда түбәндәге сүзләр язылган:

*«Хөрмәтле Иван Петрович!*

*Мин совхозны ташлап китәргә мәҗбүрмен. Сәбәбен шушы записка белән бергә салган хаттан аңларсыз. Әлбәттә, минем болай «качып» китүем ярый торган эш түгел, мин моны беләм, ләкин аңлагыз, бүтән чарам юк минем... Әгәр бер генә көнгә калсам да, сез барыгыз да мине юатып, үгетләп, кыстап биредә калырга, шулай итеп хурлыгым белән килешергә мәҗбүр итәр идегез. Мин моны булдыра алмыйм... Берничә көннән ул кайтырга тиеш... Шуңа күрә артык бер көн дә тормыйча китәргә булдым. Аңлагыз мине, кичерегез...*

*Мине эзләмәгез, яңа җиргә урнашкач, үзем хәбәр итәрмен.*

*Хушыгыз!*

*Тирән хөрмәт белән Т.В.»*

Ә кечкенә хат Петя Котовтан. Ул менә нәрсә яза:

*«Исәнме, Тамара!*

*Син мине бик көтәсеңдер инде, сагынгансыңдыр инде бик. Конечно, аңлыйм мин моны... Үземнең дә теге, ни, понимаешь, бик күрәсем килә. Ну вот нәрсә, Тамара, син ачуланма миңа... Мин ялгыз кайтмыйм бит, то есть, өйләнеп кайтам... Яраттым бит бер җирән шайтанны!.. Конечно, моны белү сиңа авыр булыр, ну ничево, дөньяда ир бетмәс. Без бит синең белән болай, шаярып кына дигәндәй тордык, ә миңа чынлап өйләнергә вакыт. Так что, син ачуланма и безнең араны өзелгәнгә сана.*

*Конечно, мин сине онытмам, ну мин хәзер бүтәнне яратам. Кем икәнен әйтмим, кайткач, үзең күрерсең. Менә шул. Барысы өчен дә рәхмәт. Минем сиңа шактый бурычым бар шикелле, но анысын акрынлап түләрмен.*

*Да, тагын сиңа шуны әйтеп куям: без кайткач, кара аны, миңа бәйләнеп, бузить итеп йөрмә, яме!*

*Ну, пока, исән бул! Сиңа бәхет телим.*

*Сәлам белән Петр К.»*

«Бузить итмә» дигән сүзнең астына Тамара Сергеевна үз кулы белән өч тапкыр сызып куйган.

Йә, ничек, абзыкаем? Лач итеп төкердеме хам күпме яхшылык күрсәткән хатынның нәкъ бәгыренә? Качу түгел, беренче очраган ботакка асылынырсың!

Шул кичне без, совхозның җитәкчерәк кешеләре, директор бүлмәсенә җыелдык. Барыбыз да бик борчылышкан идек, ачулы идек. Ләкин, мәет чыккан өйдәге шикелле, сүз таба алмыйча утырдык. Ни әйтәсең? Әлбәттә, эш ташлап качу һич тә ярамый, закон белән дә тыела ул, әмма бу очракта беребез дә Тамара Сергеевнаны гаепләргә җөрьәт итә алмадык. Хәтта директор да, шактый коры һәм кырыс кеше, нинди дә булса чара күрү турында авызын ачмады; тик ул әледән-әле: «Ах, бу хатыннар, хатыннар»,— дип үрсәләнде, бер-ике тапкыр авыз эченнән генә сүгенеп тә куйды, аннан, ант иткәндәй йодрыгын төйнәп, Петя Котовны кайту белән, бер көн тотмыйча, совхоздан куарга сүз бирде.

...Менә шулай китте бездән Тамара Сергеевна. Әйтерсең төште дә югалды... Шунсы гыйбрәтле тагын, бу вакыйгадан соң кешеләр ничектер бер уңайсызлану хис иткән кебек булдылар, әйтерсең ялгыз хатынның язгы төндә каядыр китеп югалуы аларның «каты йоклаулары» аркасында гына килеп чыкты... Аннан... акрынлап барысы да онытылды, тик менә сезнең кебек кызыксынып сорашучы очраган чакта гына искә төшереп сөйли торган бер вакыйга булып калды.

Николай Михайлович сүзеннән туктады, һәм без караңгы иңгән бүлмәдә озак кына тын калып утырдык. Була шундый вакыйгалар, алар күңелдә күп кенә уйлар тудырсалар да, ни өчендер төпченеп сорашасы килү теләген кузгатмыйлар. Вакыйга бик ачык булганга күрә генә түгел, ә акылга зур йөк булып төшкәнгә күрә шулайдыр инде ул... Ләкин бер сорау күңелне һаман тырнап тора: Тамара Сергеевна табылдымы, кайда ул?

— Әйе, табылды,— диде Николай Михайлович, кулына яңа папирос алып.— Без башта аны туган-үскән якларына китеп бармадымы икән дип уйлаган идек. Ләкин хәбәр ерак Себердән килде. Ул Иркутск өлкәсендәге зур бер җәнлекләр совхозына барып урнаша һәм яңадан зоотехник булып эшли башлый. Яхшы специалист бит ул... Былтыр Ленинградтагы халыкара аукционда аның үстергән төлкеләре югары бәя алдылар.

Мин тагын нидер сорамакчы булган идем дә, дәшмәдем. Әйткәнемчә, кеше язмышы турында кайчак эчтән генә уйлану яхшы.

1957

# Майбәдәр карчыкның туган көне

Соңгы вакытларда туган көнне бәйрәм итү бик ешаеп китте әле. Зәйни иптәшнең чынлап торып шуңа эче поша башлады. Йә берәр начальник: «Мин тудым!» — дип, йә берәр дус: «Хатыным туды!» — дип, кәефең-хәлең белән хисаплашмыйча, тоталар да өстеңә авыр бер мәҗбүрият йөклиләр. Бик әйбәт, тугансыз икән, яши бирегез! Дөнья киң, эш җитәрлек! Әмма ни өчен ул һәркемнең тууына гадәттән тыш бер вакыйга итеп карарга, шуңа шаккатарга, җитмәсә, «ярый тугансың әле, син тумасаң — без нишләр

идек» дип кесәсеннән акча чыгарырга тиеш? Аннары шул бәйрәмнән соң ике-өч көн шешенеп, маемлап, сода эчеп, эч уып йөрергә туры килә. Яшь чагы түгел бит инде аның. Юк, тәмам туйды Зәйни иптәш бу майлы каз мәҗлесләреннән... Җитәр! Берәү дә аңардан сорап дөньяга килмәгән, җәзасын ул күтәрергә тиеш түгел, бигайбә!

Ләкин, гөнаһ шомлыгына каршы, тагын бер «туган көн» аяк астыннан килеп чыкты. Ниндие диген! Һичбер котылып булмый торганы! Һарун Хәйрулловичның анасы Майбәдәр карчыкка җитмеш яшь тула икән. Ә Һарун Хәйруллович ул Гайнүш ханымның начальнигы. Ә Гайнүш ханым Зәйни иптәшнең гаять тә уңган, гаять тә булган хатыны. Менә бит ул ничек бер-берсенә ялганып китә!

Дөрес, Зәйни иптәш җилкәсен кашыбрак: «Гайнүш, кадерлем, әллә бу юлы... теге ни... казага калдырабызмы? Карчык яшен яшәгән инде...» — дия башлаган иде дә, Гайнүш ханым, күзләрен түгәрәкләндереп, аның сүзен бүлде:

— Ни сөйлисең син? Майбәдәр абыстай Һарун Хәйрулловичның анасы ич, анасы! Неужели шуны да аңламыйсың?

— Аны гына аңлыйм инде мин,— диде Зәйни иптәш, чыраен сытып.— Тик шулай да бик күпкә китте бит. Әллә карчыкка тагын бер җитмеш ел гомер теләп, телеграм гына бирәбезме?

— Илаһи, бу чаклы да туң күчән булырсың икән! Берәү шундый зур башы белән сине кеше рәтеннән чакыра, ә син, мокыт, җилкәңне җыерып, кашынып торасың! Менә нинди бүләк алабыз, шул турыда уйлаш син миңа, башың бераз эшләсә! Һарун Хәйрулловичның анасына ич!

Зәйни иптәш:

— Ишеттек, белдек! — диде дә кулын гына селтәде. Йә тагын әллә ниләр ишетерсең. Әйдә инде, беткән баш беткән!

Ә Гайнүш, Зәйнүшенең авызын шулай ансат кына томалап, гаять зур дәрт белән Майбәдәр карчыкның туган көненә әзерләнә башлады. Бу әзерлекнең үзәгендә иң элек бүләк табу мәсьәләсе тора иде, әлбәттә. Бик нечкә эш ул — бүләк табу! Озак баш ватты Гайнүш бу хакта. Иске сандык актаргандай, бик күп нәрсәләрне хәтереннән кичерде. Кечкенә йөгерек күзләре Зәйнинең бөрешкән кыяфәтенә очрап туктаган чагында, һаман аңардан сорый торды:

— Йә, ни уйлыйсың?

— Нәрсә хакында?

— Бүләккә ни илтәбез, дим, миңгерәү! Зәйни, башына сугуны көткәндәй, тагы да бөрешә төшеп, мыгырданып кына бер үк җавапны бирде:

— Белмим шул...

Аның бу бүләк мәсьәләсенә һич тә тыгыласы килми иде, ахырдан каһәре буласын бик яхшы белеп тора. Дөрес, «белмим шул» өчен дә аңа характеристиканың һәртөрлесен ишетергә туры килде, ләкин, аның каравы, мәҗлес үткәч җаны тыныч булачак. Ә тыгылса, Гайнүше: «Кешеләр әнә ни китергәннәр, ә син, саран тәре, нәрсә алдырдың!» — дип, икенче берәүнең туган көненә чаклы, һичшиксез, колак итен чәйнәячәк.

Ниһаять, барасы көнне Гайнүш аңа катгый рәвештә белдерде:

— Самавыр илтәбез!

Зәйни, никадәр битараф калырга тырышмасын, шулай да әйтмичә булдыра алмады:

— Ни өчен самавыр? Майбәдәр карчык кияү куенына кереп, яңа тормыш башларга җыенмыйдыр ич!

Ах, ник әйтте ул моны! Ахмак шул, ахмак! Олаеп чәчләре коелгач та ишетәселәре бар икән әле!

— Оятсыз,— диде Гайнүш яшь көнчелек зәһәрлеге белән.— Намазлык өстендә утырган карчык турында шулай әйтергә ничек телең әйләнә? Күңелеңдә гел бозыклык! Бар белгәнең...

— Туктале, Гайнүш! — диде Зәйни, ялварып.— Әллә кая чулулап алып китмә әле син! Самавыр кебек нәрсәне кияүгә чыгучы кызга гына илтәләр түгелме соң?

— Кызга гына димәгән, карчыкка да бик әйбәт сыя ул. Чәй эчкән саен, догасын укып, безне искә алыр. Аннары шуны белеп тор син, сантый: карчыкның туган көнен бүләк җыяр өчен үткәрәләр ич!

Зәйни, ертык гармун шикелле, озын гына бер уфлап куйды, әмма кайтарып сүз әйтмәде.

Шулай «җылы гына» сөйләшеп алганнан соң, Гайнүш, гадәтенчә, ялгызы гына магазиннарга чыгып китте... шактый озак йөреп, бу, ниһаять, бик әйбәтләп төреп бәйләгән бүрәнә башы сыман нәрсә күтәреп кайтып керде. Ә кичен, таксига утырып, болар «туган көн» мәҗлесенә киттеләр.

Кунаклар күп иде, ашау-эчү гаять мул иде. «Юбилярны» түр почмакка кертеп утыртканнар. Алдына чәй ясап куйганнар, өлеш тәлинкәсе белән чәкчәген, бәлешен, балын куйганнар. Ак батист яулыгын ияк астыннан китереп бәйләгән бәләкәй генә йөзле карчык, «әйдә, кыланыгыз инде» дигән битараф бер чырай белән, ашыкмыйча гына чәен эчә, алдына коелган валчыкларны чүпләп-чүпләп каба. Ә мәҗлес хуҗасы, ягъни карчыкның улы, закуска әзерләгән чакта ук капкалый торгач, чөгендердәй кызарып өлгергән Һарун Хәйруллович өстәлнең түр башында чын юбиляр сыман киерелә биреп утыра. Рюмкаларны да күбрәк аның хөрмәтенә күтәрәләр; янәсе, нинди шәп кеше ул, Һарун Хәйруллович, хатыны белән үзенекен генә түгел, менә әнисенең дә туган көнен бәйрәм итә. Хәтта бер «нечкәреп» өлгергән кунак, аягүрә басып, өстәл аша карчыктан кычкырып сорады:

— Майбәдәр абыстай, җаным, ни-чек таптыгыз, ә?

— Как тоес... ничек таптыгыз? — диде кунакларның икенчесе, бик гаҗәпләнеп.

— Һарун абый кебек кешене, дим.

— Таптык инде,— диде карчык, үзалдына көрсенеп кенә.— Һарун ишеләрне тугызны таптык, тик гомерләре генә булмады.

— Ай-һай-һай! Ишеттегезме, хатыннар? Вәт кемнән үрнәк алырга кирәк.

Моңа каршы бер ханым кырын торыбрак эре генә:

— Ул заманда хатыннарның бүтән эше булганмыни! —дип куйды.

— Ул заманда да эшсез тормадык,— диде карчык, тыныч кына.— Бәбидән котылгач та, торып, йә басуына, йә ындырына китә идек... Назланып ятулар безгә насыйп булмады инде ул!

Ирләр берьюлы шаулашып алдылар:

— Вәт нинди чаклар булган! Ә хәзер сезгә дүрт ай ял бирәләр.

— Шуңа күрә бердән артыкны тапмыйлар да.

— Совет кына аздырып бетерде үзләрен,— диде Зәйни, үзалдына акрын гына; бу шау-шуда берәү дә ишетмәс дип ышанган иде ул, әмма, каһәр генә суксын, Гайнүше ишетеп калды лабаса! Шундый итеп карады Гайнүш бу бичарага, Зәйнинең хәтта бавырына энә барып утыргандай булды. Ну, эләгәчәк инде аңа! Ярамаган сүз, теркәп куярлык сүз әйттең дип, очып куначак инде! Тирән хәсрәткә төшеп: «Ахрысы, нык кына салырга кирәк булыр, аннары өстемә менеп биесә дә сизмәм әле»,— дип уйлап куйды ул эченнән генә.

Шул арада кунаклар, «юбиляр»ны мактый торгач, кызып китеп, алып килгән бүләкләрен дә карчык алдына чыгарып сала башладылар.

Гайнүш башта кемнәрнең нәрсә китергәнен күзәтеп кенә торды. «Алай әллә ни юк икән, гел чүпрәк тә чапрак»,— дип, эченнән кинәнде ул һәм иң ахырдан гына бөтенесен үзенең бүләге белән шаккатырмакчы булды, һәм, дөресен әйтергә кирәк, шаккатырды да!..

Менә барысы да бүләкләрен биреп бетергәч, ул алгы яктан түбәсенә пыжик бүрек кидергән ак самавырны җиңел генә күтәреп керде дә, бик тантаналы итеп:

— Майбәдәр абыстай, улыгызга, киленегезгә, шулай ук сезнең үзегезгә дә озын гомер теләп, шушы бүләкне тапшырырга рөхсәт итегез! — диде һәм шап иттереп карчыкның алдына куйды.

Кунакларның күзләре тоз булды. Аларның берсе дә ике бүләк алып килүне уйлый белмәгән иде. Хәтта Зәйни иптәш өчен дә бу начальник башына чамалап алынган бүрек һич көтелмәгән «сюрприз» булып чыкты. Хәйран калу һәм көнчелек — икесе берьюлы кунакларның телләреннән ычкынды:

— Ну, бу Гайнүш ханым!

— Оригинально!

— Гаҗәп инде!

Тик урыныннан кузгалмыйча ялгызы утырып калган Зәйни генә теш арасыннан: «Зобани!» — дип, бер төкереп куйды.

...Тагын рюмкалар, стопкалар күтәрелде. Кемдер «Зөһрә матур, Таһир батыр»ны җырлап җибәрде. Шул шау-шу эчендә Һарун Хәйруллович Гайнүшкә, артыннан якынаеп, колагына пышылдап кына: «Май кап! Премия булыр!» — диде. Әллә хуҗаның кайнар сулышы колагын кытыкландырды, әллә сүзләре чыннан да күңеленә май булып ятты,— Гайнүш, башын чөеп, яман шаркылдап көләргә тотынды.

...Әмма шәп узды да соң Майбәдәр карчыкның «туган көне»! Тик «юбиляр» үзе генә озак утыра алмады, бер җай табып, мыштым гына өстәл артыннан чыкты да каядыр үз оясына кереп сеңде. Берәү дә аның «югалуын» сизмәде.

1958

# Туган туфрак

## I

Кларaның бабасы, мәрхүм, аңа еш кына: «Клара бәбкәм, безнең Каракошны бер кайтып күрер идең, ата-бабаңның туган туфрагы бит ул!» — дип әйтә торган иде. Бабасының бу сүзләренә каршы Клара, ни әйтергә белмичә, уңайсызланып кала торган иде. Әллә кайдагы ул «туган туфрак» дигән нәрсә аңа билгесез, ят иде, шуңа күрә бабасының сүзләре аңарда бернинди теләк тә, кызыксыну да уятмый иде. Гомумән, Клара, чын шәһәр кызы булганлыктан, авыл җирен өнәп бетерми иде. Нәрсә ул авыл? Азрак күрергә туры килде аңа мактаулы авыл җирен. Салкын, пычрак көзләрдә барып, бәрәңге казып йөрде. Чыланды, күшекте, тыгыз өйләрдә тараканнардан җирәнә-җирәнә кунып ятты, өс-башы тузып, үзе керләнеп бетте һәм бөтен кайгысы — тизрәк шул «бәрәңге базыннан» котылу турында гына булды. Бернинди кызык та, матурлык та тапмады ул анда.

Ничек кенә булмасын, бабасының «туган туфрак» дигәнен Клара ихтыярсыздан элек үзе барып йөргән әнә шул Питрәчнең көл балчыклы бәрәңге җирләре белән бертөслерәк итеп күрә иде. Шунлыктан ул авыру картның: «Кызым, кайтып бер күрер идең»,— дигән сүзләрен һаман колагы төбеннән үткәрә килде.

Ә бабасы үзенең Каракошын, шунда үткәргән гомерен еш кына сагынып исенә төшерә торган иде. Бала чагын, егет вакытларын, каз өмәләрен, туйларын, җыеннарын, ярминкәләрен — барысын да кызык итеп, тәмле итеп, көрсенеп һәм юксынып сөйләп утырырга ярата торган иде. Клара, карт кешенең хәтере өчен генә аны тыңлаштырса да, барыбер үзенчә уйлый иде. «Боже мой,— ди иде ул эченнән генә,— хәзерге авылның коты юк, ә иске авыл нинди булгандыр инде ул?..» Аның укып белүе буенча, иске авылның бер яме дә, бер кызыгы да булмаган. Иске авылда бары хәерчелек, караңгылык, наданлык, вәхшилек кенә булган. Байлар ярлыларны изгәннәр, крестьяннар гел ач утырганнар. Йә, моның нәрсәсен сагынасың? Дөрес, аның бабасы, сөйләвенә караганда, таза гына тормышлы булган (Клара исәбенчә, середняк булырга тиеш), аты булган, сыеры булган, иген иккән. Әмма шулай да хәзерге вакытта иске авылны сагынып утыру һич килешә торган эш түгел инде. Политик артталык, наданлык бу... Кайчакта Клара, артык түзә алмыйча, бабасының сүзен дә бүлә иде: «Куй инде, бабакай, мактама инде син иске авылны. Йә, сезнең шул Каракошыгызда элек мәктәп булганмы, клуб, радио, электр булганмы?»

Юк, аларның берсе дә булмаган. Хәер, мәчет катында кечкенә мәдрәсә булган, әмма ләкин электр да, клуб та булмаган. Хәтта бабасы малай чагында керосин лампасы да булмаган. Чыра яндырганнар. Бабасы әйтә, кышкы кичләрдә, бөтен өй эче кул эше белән утырганда, миңа шәмдәлгә кыстырган чыраларның күмерен сулы ләгәнгә өзеп төшерергә кушалар иде, ди. Махсус кыскычы була торган иде, шуның белән бик тырышып чыра башын өзеп утыра идем, ди... Менә сиңа иске авыл!

Әмма шуңа да карамастан бабасы үзенең Каракошын һаман сагына иде. Әледән-әле Кларага әйтә торган иде: «Кайтып күр, кызым, гомер иткән нигезебез шунда, ерак бабаларыбыңның каберләре шунда, сиңа якын түгелмени алар?» — ди иде. Аннары Каракошның яланнары, таулары матур, имеш, халкы бик әйбәт, кунакчыл, имеш, гомумән, ягы белән үк бөтенләй башка: хозур, ямьле, җанга ягымлы, имеш.

Ә менә Кларааның әтисе, шул авылда туып үскән булса да, Каракошны сагынып бер дә телгә алмый иде. Бәлкем, эченнән генә сагынгандыр, ләкин тыштан бервакытта да күрсәтми иде. Әтисе аның алдынгы кеше шул, капитализм чорындагы авылны сагынып, мактап сөйләүнең килешмәгәнлеген бик яхшы белә ул.

Инде менә үткән көз Кларааның бабасы каты авырудан соң үлеп тә китте. Сиксән елдан артык дәвам иткән гомер өзелде. Барысын да — сагыну-юксынуларын да, җыр-әкиятләрен дә бабай үзе белән бергә кабергә алып китте.

Хәзер инде гаиләдә Каракошны телгә алучы да юк, «туган туфрак» дигән сүз үзе үк бөтенләй онытылырга тиеш иде. Ләкин, ни гаҗәптер, Клара, бабасы үлгәннән соң, аның әйткән сүзләрен исенә төшергәли башлады. Каракош та әледән-әле күңеленә килгәли торды. «Бабакаемның гомер иткән җире, безнең «туган туфрагыбыз», миңа ул кайтып күрергә кушып калдырды бит»,— дип уйлана торган булды.

Ахырда, эчке бер тынычсызлану белән уйланып йөри торгач, Кларада бабасының туган авылын кайтып күрү теләге туды. Ничектер менә, бабасы алдында бурычлы кебек ул, әгәр аның васыятен үтәмәсә, җаны бервакытта да тынычланмас шикелле... Мөмкинчелеге бар, әтисенең хәле иркен, аның теләгенә каршы төшмиләр — шулай булгач, эш нидә? Бер елдан ул институтны бетерергә тиеш, аннары инде үзең теләгән җиргә барып йөрүләр авыр булачак.

Клара әнә шулай уйлады һәм, җәйге каникул вакытында тиз генә җыенып, ерак Каракошка китеп тә барды.

## II

Клара туры Каракошның үзенә түгел, ә Каракоштан күчеп утырган Зиреклебаш авылына кайтырга тиеш иде. Чөнки аларның кайтып төшәрлек бердәнбер якын кардәшләре Зиреклебашта тора иде. Дөрес, Каракошның үзендә дә кардәш-ыру күп булырга тиеш, ләкин бабасы үлеп киткәч, алар ничектер билгесез булдылар да калдылар.

Инде Клара хәтерендә онытылмыйча сакланганнардан иң якыны — бу Хәмдия җиңгәчәсе, ягъни бабасы белән бертуган Мөхәммәтша дәдәсенең карчыгы була. Дәдәсе күптән вафат, Хәмдия җиңгәчәсе Зиреклебашта Рәхмәй атлы уртанчы улы белән тора. Рәхмәй инде Кларага тудык абый була. Аның күз төбәп кайткан якыннары әнә шулар иде.

Клара кояш баер алдыннан гына кечкенә бер станциягә килеп төште. Поезд ике генә минут торды да китеп тә барды. Аз-маз гына төшкән халык таралып бетте, һәм Клара, ак чехол кидергән чемоданын күтәреп, ялгыз калды. «Неужели телеграмманы алмадылар икән?» — дип борчыла башлады ул. Ләкин шул арада, әллә кайдан гына калкып, аның каршысына соры плащ, кара кепка кигән, чыбыркы тоткан, кечерәк буйлы чандыр гына бер егет килеп басты.

— Клара?! Синме, Клара? — диде ул, гаҗәпләнү катыш сөенеч белән кызга текәлеп.

— Әйе, мин,— диде Клара, егетнең кыяфәтенә тиз генә күз салып: Рәхмәй абыйсы дияр иде, егет ничектер яшь, малай сыман күренә; ул түгелдер дияр иде, эндәшүе бик үз, якын булып ишетелде. Шулай да бу ак чырайлы, соры күзле егетнең авыз читендә тирән сызыклар күреп һәм шуңардан аның бик үк яшь кеше булмавын чамалап, Клара кыюсыз гына сорады:

— Сез... Рәхмәй абый буласызмы?

— Нәкъ үзе, нәкъ үзе! — диде Рәхмәй абыйсы һәм, чыбыркысын култык астына кыстырып, ике кулын күрешергә сузды.

— Исәнме-саумы? Әйдүк, хуш киләсең!

Ул Кларaның кулын тотар-тотмас күреште дә тиз үк чемоданга үрелде. Ат янына киттеләр. Биле сыгылыбрак торган тарантаска яңа чапкан печән тутырып, өстенә чуар палас бөкләп салганнар. Рәхмәй абыйсы ике куллап паласны суккалап алды.

— Әйдә утыр, сеңелем! Менә аласыңмы? Ул гүя күтәреп утыртмакчы да иде, ләкин Клара үзе җиңел генә менеп утырды. Печәнне бераз кайтаргалап, чемоданны Клара янына кырын утырткач, Рәхмәй абыйсы кучерга сикереп менде дә дилбегәне тартты.

— Кузгалдык, бахбай!

Йомры гына туры ат кырын-кырын борылды да, юлга төшеп, вак адымнар белән юыртып китте. Кларaның гомерендә беренче мәртәбә диярлек ямь-яшел сусыл печән салган тарантаска утырып, атта баруы иде. Бик рәхәт булып тоелды аңа бу нәрсә. Җир якын, үләннәр якын, аттан тир һәм каеш исе килә, юк, бу әтисен йөрткән «Волга»дан поэтичныйрак иде. Әллә каян гына килеп бабасының: «Бар иде лә бәнем атларым, җигеп кенә чыга идем чаптарын»,— дип җырлавы исенә төшеп куйды. Әйе, бабасы мәрхүм дә кайчандыр бу юллардан менә шулай чапкан печән өстенә утырып, авыз эченнән генә җырлый-җырлый юырттырып узгандыр... Әлбәттә, узгандыр...

Рәхмәй абыйсы, артына борылып аңа, бөтен бите-күзе белән дигәндәй, елмаеп карады.

— Һәй, Клара, Клара! Син икәнсең инде ул Клара, ә?

— Әйе, Рәхмәй абый. Клара дигән кызый мин булам инде,— диде Клара, ничектер сагышлы һәм рәхәтле көрсенеп.

— Бик якын туганнар бит без, уйласаң, Клара аккошым! Беләсеңме шуны?

— Беләм. Бабакайның братының улы буласыз бит сез! Шулай бит?

— Син миңа пләмәш буласың, канатым! Ник дисәң, синең атаң белән мин ике бертуган малайлары булабыз. Безнеңчә әйтсәк, тудыклар... Ә күрешкәнебез юк, вәт тамаша? Бик ерак киттегез шул, ерак киттегез!.. Их-ма!.. Яле, бәләкәчем, кызурак атлале!

Туры ат, сүзне аңлап, башын кага-кага, тырышыбрак юыртырга тотынды. Клара ихтыярсыздан пошынып уйлады: менә беренче күрешүдән үк аңа туганлык хисен ничек сөенеп һәм юмартланып күрсәтәләр. Ә ул хәзергәчә мондый хисне үзендә сизмичә килде. Ниндидер Рәхмәй атлы «тудык абый» аның өчен әллә бар, әллә юк иде.

Җиде чакрымдагы Зиреклебашка караңгы төшеп, тәмам күз бәйләнгәч кайтып җиттеләр. Бер йортның җил капкасыннан кереп туктагач, тарантасны кемнәрдер сырып алдылар, кемнәрдер Кларaны култыклап төшерделәр, нәфис кулын тотып-сыйпап күрештеләр. Аннары өйгә алып керделәр.

Кечкенә өй эче бер мәлгә бала-чага һәм хатын-кызлар белән тулып китте. Күрше-тирәдән керүчеләр дә бар иде, ахрысы, һәрхәлдә, шактый югалып калган Клара бу ыгы-зыгы эчендә кемнең кем булуын тиз генә аера да алмады. Тик ул үзе тирәсендә бертуктаусыз бөтерелеп, шатлык-иркәләү сүзләре чәчкән какча гәүдәле хатынның кем икәнен бусагадан атлау белән үк танып алды: бу —Хәмдия җиңгәчәсе иде. Гаҗәп җиңел сөякле, куштан һәм татлы телле булып күренде ул Кларага.

Шулай да бу беренче кич Клара өчен томанлырак булып калды. Кемнәрнең нәрсә әйткәнен дә, үзенеңниләр кичергәнен дә соңыннан ачык кына хәтерли алмады. Дөрес, аны чын ихластан куанып, зурлап каршы алдылар, юынганда кулына комганнан җылы су салып тордылар, астына йомшак көрпә салып, түргә утырттылар, бик тәмле токмач белән сыйладылар — әмма болар барысы да аңа сәер, кызыклы төш шикелле генә булып тоелды.

...Күпмедер утыргач, аны өйалдындагы махсус юып җыештырылган ак чоланга кертеп, озынча түшәк җәйгән агач караваткa яткырдылар. Мамык түшәккә менеп баткач та, аның юлдан талчыккан тәне май кебек эреде дә китте һәм, уйланып ятуына карамастан, ничектер һични сизмичә үзеннән-үзе сеңде дә куйды. Болай эреп, томанга әйләнеп дигәндәй, йокыга китүне аның әле беркайчан да татыганы юк иде.

Ә иртәгесен аны күз кабакларын кытыклаган ниндидер җылы яктылык, борынына кергән ниндидер тәмле хуш ис йокысыннан уятты. Күзләрен ачкач, ул шактый биектә салам кыекны күрде: чоланның такта түшәме юк, имеш, ә кояш нурлары аның күзенә ике кыек арасындагы такта ярыкларыннан төшә икән. Югарыдагы аркылы киртәгә икешәр-икешәр бәйләп быелгы каен себеркеләрен элгәннәр, ә бүрәнә стенага мәтрүшкә бәйләмнәре асып куйганнар. Борынны кытыклаган бу гаҗәеп хуш ис шулардан тарала икән.

Клара, күзен ачкач, тагын «ак» чоланның шүрлегендә һәм чөйләрендә аңа исемнәре дә билгеле булмаган әйберләрне — йон кабасын, тәрәш таракны, каен тузыннан теккән кечкенә тубалны, кипкән шомырт белән тулы агач шаваны күрде. Бу әкәмәт нәрсәләр аны бик борынгы бер заманга кайтаргандай итте. «Странно, но мило!» — дип уйлап куйды ул эченнән генә һәм шуларның барысына да сокланып, йомшак урыныннан кузгалырга иренеп, озак кына карап ятты.

...Өйалды тып-тын, һичкемнең кергәне-чыкканы ишетелми иде. Клара ихтыярсыздан: «Әллә тормаганнар инде»,— дип уйлап алды, хәлбуки хуҗалар кадерле кунакның йокысын кызганып, өй

тирәсендә чуалмыйлар иде. Югыйсә алар әллә кайчан торганнар, күптән үк иртәнге чәйләрен эчкәннәр, эшләренә таралганнар, хәтта балалар да күптән инде урамга чыгып киткәннәр иде.

Клара, ниһаять, торып, киң билбаулы ефәк халатын гына киеп һәм яланаякларына ак танкеткаларын элеп, чоланнан чыкты. Ишегалдына чыгар өчен чалышаебрак торган тышкы ишеккә баруга, чыбык-чабык күтәреп килгән җиңгәчәсе очрады.

— Ә, Иркә туташ, тордыңмы, якты күзем? — диде ул, җыр әйткәндәй көйләбрәк.— Хәзер, хәзер сөлге белән комган чыгарам, чирәмдә генә юынырсың!

Клара аптырый калды: «Нигә Иркә туташ? Әллә аның чын исемен яратмаганнармы? Әллә озак йоклаган өчен көлеп әйтәләрме?» Ләкин соңыннан төшенеп алды: юк, көлеп түгел икән, ә чын ихластан аны кадерләп, сөеп дәшү икән бу... Иркә туташ! Нинди матур, нинди ягымлы! Карагызчы, авыл кешесе дә шулай әйтә белер икән?!

Ишегалдына чыккач, Клара хәйран булып тукталып калды: йортның киртәсеннән кул сузымы җирдә генә иген кыры башланып китә. Очы-кырые күренмәгән бу күкрәп үскән иген шулкадәр якын, хәтта башакларның бер-берсенә ышкылып кыштырдаулары ишетелә.

Клара киртә буена килде дә, уңга-сулга салмак кына чайкалып, акрын гына шаулап утырган бодайлар галәменә карап тора башлады. Ул да булмый, аның колагына якында гына нәрсәнеңдер пошкырып куюы ишетелде. Караса, ни күрсен: киртә буенда гына казыкка бәйләгән бер яшь сарык кетер-кетер чәчәкле үлән кимереп йөри... «Ах, душечка, ах, җаным! — диде Клара, тәмам нечкәреп.— Килче, килче миңа, матурым!..» Сарык, башын текә генә күтәреп, авызындагы үләнен чәйнәүдән туктап, аптырау-курку тулы күзләрен Кларага төбәде. Юк, бу төпсез, хәйләсез, бары җан калтыравын гына чагылдыра алган якты күзләргә озак карап торуы мөмкин түгел иде.

Шул арада җиңгәчәсе сөлге, сабын һәм комган күтәреп чыкты.

— Иркә туташ, кил әле мондарак! — диде ул, ишек төбеннән читтәрәк яткан зур ак таш янына чакырып.—Үзем салып торырмын.

Клара, җиңгәсенең комган тотып көтеп торуын күргәч, уңайсызланып, кызарып китте.

— Юк, юк, мәшәкатьләнмәгез! Мин үзем, мин үзем...

— Һәй, аппагым, аякларыңа чәчрәтерсең бит.

— Юк, юк! Мин юына беләм бу нидән... савыттан.

Җиңгәчәсе ирексездән көлемсерәп куйды.

— Ярый инде алайса,— диде ул, комганны таш өстенә куеп.— Иплән кенә юын, мин тизрәк чәемне хәстәрлим, булмаса.

Һәм ул ашыгып өйгә кереп китте.

Клара юынган арада ашыга-ашыга Рәхмәй абыйсының хатыны кайтып керде. Бу яшь җиңгәчәй — Мөнирә җиңгәчәй була инде. Таза гына, сылу гына гәүдәле, үзеннән-үзе елмаерга торган сөйкемле чырайлы, матур кара кашлы, кара күзле яшь хатын иде ул... Фермада сыер сава икән, әле шуннан ашыгып кайтуы.

Ул туп-туры Клара янына килде дә, күптәнге ахирәтенә дәшкәндәй, бик гади, үз итеп:

— Йә, Клара, әйбәт кенә йоклап тордыңмы? — дип, кулын аның аркасына салды.

— Рәхмәт, Мөнирә җиңгәчәй, бик әйбәт, бик тыныч йокладым.

— Ярый инде алайса. Безнең ни... синең кебек тансык кунакка чоланнан башка урыныбыз да юк.

— Әйтмәгез. Чоланыгыз йоклар өчен прекрасный урын икән, гел чәчәкләр исе аңкып тора!

— Син бигрәк! — диде Мөнирә, көлеп.— Ал, дидем энкәйгә шул кипкән үләннәреңне, кунакның күзенә чүп коелыр, дидем. Алмады бит... Йә, әйдә керик, иркәм!

Шул арада болар янына урамнан ике яшь кенә бала тупылдашып йөгереп килде. Зуррагы — биш-алты яшьләрендәгесе — малай, ә кечкенәсе өч-дүрт яшьлек кызчык иде. Аларны бүген, кунак апалары килү уңае белән, пөхтә итеп киендергәннәр. Малайның өстендә ике сәдәпле ак күлмәк, бау белән иңбашына аскан кыска балаклы кара чалбар. Ә кызчыкны нәкъ курчак төсле итеп киендергәннәр: чәчен, ике кечкенә толым итеп, кызыл тасма белән үргәннәр, ике кулына да вак кына кызыл мәрҗәннән беләзек кидергәннәр. Аңа карагач, сөенеп елмаймыйча мөмкин түгел иде.

Кларaны тагын шул гаҗәпләндерде: алар шактый әрсез-чая булып чыктылар. Авыл балалары да димәссең. Шунда ук, апаларына сарылып, такылдый да башладылар.

— Апам, бу минем алма апам!

— Юк, синеке түгел, минем апам!

— Тимә, тимә, минеке!

Клара, чүгәләп, икесен ике кулы белән кочаклап алды.

— Менә сез нинди икәнсез! Матур икәнсез, акыллы икәнсез! Йә, синең исемең ничек?

— Алмас! — диде малай, авыз тутырып, батыр гына.

— Ә синеке, күбәләгем?

Кызчык башын кырын салды һәм акрын гына:

— Алсу! — диде.

Клара аларны, сөеп, күкрәгенә кысты. Балалар тагы да иркәләнебрәк аңа сыендылар.

— Йә, йә, килешми болай, апагызның өстен буярсыз,— диде әниләре һәм башларыннан этәреп кенә читкә тибәрде.

...Барысы да җыйнаулашып өйгә керделәр. Карт җиңгәчәсе Кларань өтәләнеп каршылады.

— Әйдә, Иркә туташ, әйдә, күз нурым! Карының да бик ачыккандыр инде синең, уятырга җәлләдек, юлдан соң туйганчы бер йокласын, дидек... Әйдә, уз әле, уз, кереп утыр әле әнә шунда!..

— Хәзер, Хәмдия җиңгәчәй, чәчемне генә тарап алыйм.

— Ә ярый, ярый, тара! — диде җиңгәчәсе, тагын үзе шунда ук килешеп.

Клара, түбән каратыбрак стенага элгән, башына кәгазь чәчәк кыстырган, чебеннәр шактый «бизәп» өлгергән көзгегә каршына басып, кыска коңгырт чәчләрен, бер кулы белән тузгыткалап, тарарга кереште. Бу минутта нигәдер барысы да, эшләреннән калып, Кларага карап тордылар. Клара аларның үзенә, үзенең нечкә, зифа буена, затлы матур киемнәренә, гомумән, шәһәр зәвыгын, шәһәр нәфислеген аңкытып торган чибәр туташ булуына сокланып карауларын сизде. Бу аңарда горурлык һәм өстенлек тойгысы уятты. Әмма шул ук вакытта үзе белән алар арасында никадәр тирән аерма барлыгын, үзе яшәгән җиңел, гамьсез тормышның аларда юклыгын, хезмәтнең әле нәрсә икәнен белмәстән, үзенең алар күрмәгән ганимәтләр белән файдалануын, ләкин аларның, шушы аерманы сизгән хәлдә дә, аны әнә ничек якын туган итүләрен ул эчке бер уңайсызлану белән хис итмичә кала алмады.

...Ул чәчен тарап бетерүгә, барысы да тагын хәрәкәткә килделәр. Тагын түргә узып утырырга кыстый башладылар. Ләкин Клара, кереп утырганчы, иң элек стена буенда торган чемоданын алып урындыкка куйды да, ачып, бүләкләрен чыгара башлады. Карт җиңгәчәсенә ул яшел сатин күлмәклек белән ак батист яулык бирде, яшь җиңгәчәсенә бик матур ефәк күлмәклек бирде (аларның моңарчы каладан яшь киленгә бүләк җибәргәннәре юк иде әле), Рәхмәй абыйсына дип китергән ике якалы күлмәкне дә галстугы белән бергә чыгарып сузды, балаларның берсенә — малайга — чиккән үзбәк түбәтәе кидерде, ә кызчыкка бик матур кызыл туфлиләр тоттырды. Аннары ул күчтәнәчләрен — шоколад-конфетларын, тартмалы печеньеләрен, чәйләрен, шикәрләрен чыгарып өстәлгә салды. Барысы да искиткеч куандылар. Карт җиңгәчәсе, кәнәфигә утырып, озын итеп дога кылды. Яшь килен дә, әнкәсенә ияреп, тиз генә битен сыпырып алды, әмма үзе, бик уңайсызланган хәлдә, ни әйтергә белмичә, рәхмәт тулы күзләре белән Кларага карап тик торды. Балалар исә бүләкләрен әниләренә сузып: «Әни, кара, әни, кара!» — дип сикергәләргә тотындылар.

— Бик тә зурладың, бик тә сөендердең безне, Иркә туташ! — диде карт җиңгәчәсе.— Рабби Ходам, әти-әниеңә озын гомерләр бирсен, сезгә бакый рәхәт бәхетләр насыйп итсен! Амин!

Клара күңеле тулудан бер сүз дә әйтмәде, яшьләремне тыя алмам дип курыкты ул...

...Ахырда, түргә кереп утыргач, аның алдына таба өеп майлаган әче коймак китереп куйдылар. Шуның өстенә тагын самавырдан алып дүрт күкәй, агач тустаган белән пешкән каймак куйдылар. Болар бар да аның өчен генә...

— Иркә туташ, рәхим ит әле, рәхим ит! Коймактан җитеш, кайнар чакта,— диде җиңгәчәсе һәм коймакның майлыракларын астан өскә әйләндереп салды да бармакларын ялап куйды. Ул кыстаудан һич туктамый иде, Клара алдына әле эремчекле маен, әле кәрәзле балын этәрә генә тора. Яшь җиңгәчәсе ал чәчәкле, калай борынлы чәйнектән кечкенә чынаякларга чәйне куе итеп ясый да зур кашык белән сөт өсте салып бирә иде... Шушы чәй Кларага аеруча ошап китте...

...Клара өчен биредә һәрнәрсә яңа, сәер, кызыклы иде. Менә өй эче. Ап-ак зур мич, кечкенә тәрәзәләр. Тәрәзә төпләрендә эреле-ваклы савытларда чыра кадап сабакларын бәйләгән гөлләр... Тәрәзә яңакларында — кызыл башлы озын сөлгеләр, кашагаларда — ак челтәр... Түр почмакта пыяла капкачлы карсак кына кара шкаф; шүрлекләрендә төрле төстәге, төрле иштәге савыт-сабалар; түбәсендә нindидер катыргы кенәгәләр һәм тузган китаплар... Мич катыннан өйне икегә бүлеп сузылган бүлмә тактасы буенда күпертеп, пөхтәләп җыештырылган иске генә тимер карават. Аннары менә кулдан гына эшләнгән, текә артлы агач кәнәфи, шомарып-саргаеп беткән, калын аяклы таза урындыклар, киҗеле ашъяулык япкан шундый ук гади өстәл, өстәлдә патша башлары белән бизәлгән җиз самавыр... Тагын нәрсә? Менә яңа «ходиклар», калаена Кремль манарасы төшерелгән... Менә календарь...

Баймы-ярлымы бу — Клара ул кадәресен белми иде, ләкин өй эче аңа тулаем бик борыннан үзгәрмичә сакланып килгән шикелле күренә иде. Кем белә, менә бу әкәмәт самавырдан бабасы гына түгел, бәлкем, бабасының әти-әниләре дә чәй эчкәннәрдер әле. Һәрхәлдә, монда искесе, яңасы бергә иде.

Чәйдән соң Клара, чоланга кереп, өстен алыштырып чыкты. Җиңсез ак кофточка һәм киң итәкле чуар юбкадан ул нечкә билле чегән кызына охшап киткән иде.

...Инде авылны күрергә кирәк. Яшь җиңгәчәсе ашыгып фермасына китте, карт җиңгәчәсе өй эшләренә тотынды, Кларага иптәшкә Алмас белән Алсу калды. Көзге алдында тагын бер әйләнгәч, ул балаларны ияртеп урамга чыкты.

Аларның өе иң кырыйда иде. Капка төбеннән кечкенә авыл буеннан-буена ап-ачык күренеп тора. Урам киң, тип-тигез, куе бәбкә үләне белән түшәлгән, нәкъ уртадан, кара еландай, юл сузылып киткән.

Авылның утырган җире гаҗәп матур иде, монда кечкенә авыллар тирәсендә генә очрый торган ниндидер үзенә бер ямьлелек бар иде. Каршыдагы өйләр артыннан ук яшь урман башлана. Урамның түбән очы яшел чирәмлеккә барып чыга һәм шуннан ерак та түгел, ялгызы гына утырган мәһабәт биек тау күренеп тора. Ә бирге очта, менә киртәләр янынннан ук, иген кыры башланып китә. Ничектер барысы да — урманы да, тавы да, кыры да — кул сузымы гына җирдә, һәм атлап чыгу белән үзеңне табигать кочагында күрәсең! Клараны аеруча менә шушы якынлык сокландырды да. Ялан күрер өчен машинага утырып әллә кая чабасы юк икән монда...

Иң элек аның әнә шул каршыда гына торган урманга барасы килде.

— Алмас акыллым,— диде ул биш яшьлек «егеткә»,—урманга илт әле мине. Алып бара беләсеңме?

Һи, Алмас алып бармыймы соң! Ике дә уйламыйча: «Әйдә, апам!» — диде дә тыпыр-тыпыр алдан йөгереп тә китте. Клара, кечкенә Алсуны җитәкләп, аның артыннан иярде. Каршыдагы йортның киртәсе буеннан үтеп, бер йөз-йөз илле адым китүгә, алар урманга барып та җиттеләр.

Нәкъ урман авызында аларга юкә бәйләме күтәреп чыгып килүче бер бабай очрады. Бабай базык кына гәүдәле, түгәрәк йөзле, мыексыз, ап-ак сакаллы иде. Ул, тукталып, Кларага дәште:

— Исәнме, кызым?

— Исәнмесез, бабай!

— Безнең мондагы кызларга бер дә охшамагансың, кайдан син үзең?

— Мин шәһәрдән, бабай!

— Шәһәрдән? Өфедән алайса?

— Юк, Казаннан...

Бабай бәйләмен җиргә куйды.

— Казанна-ан?.. Бик ерактан килгән кунак икәнсең, алай! — Ул бераз башын селкеп торды.— Кемгә кайттың соң син, рәхмәт төшкере?

— Менә Рәхмәй абыйларга,— диде Клара.

— Ә, Рәхмәйләргә... Ябалак Хамматшаның Рәхмәенә була инде алайса!

Клара дәдәсенең ябалак булуын белми иде, әлбәттә, бу яңалыктан бераз аптырый калды. Бабай тагы да төпченебрәк сораша башлады:

— Соң син үзең, канатым, кем кызы буласың?

— Мин... мин, бабай, ни, Кәбир кызы булам.

— Кәбир? Кайсы Кәбир?.. Кем Кәбире?.. Нигә мин белмим икән аны?

— Бабай, сез аны белмәссез. Әтием минем авылдан бик күптән киткән. Бәлкем, әтиемнең әтисен, минем бабамны беләсездер?

— Кем ул бабаң?

— Мөхәммәтҗан. Каракошта торган ул.

— Мөхәммәтҗан! Тукта, тукта, Хамматшаның бертуган агасы Хамматҗанмы?

— Әйе, Мөхәммәтша дәдәмнең агасы.

— Ә-ә, әнә ничек икән! Һе, чулай Хамматҗанны белмәскә соң, безнең кодабыз бит ул, чулай Хамматҗан! Минем анайның бертуган энесенең, Әптел дәдәйнең уртанчы кызын синең әбиең Гайшә тутай белән тудык бәлеш Усман малаена биргәннәр иде. Пыкрауда туйлары булды. Бабаң белән әбиең дә кодалар булып килгәннәр иде. Әмма егет тә кеше иде яшь чагында бабаң! Бөеренә таянып, бер җырлап җибәрсә, кунакларның һушын ала иде. Исән-сау гынамы соң әле Хамматҗан кода, рәхмәт төшкере!

— Юк, бабай, үлде инде ул! Былтыр көз...

— Үлде? Иһи-һи...

Бабай, чүгәләп, җитди-моңсу кыяфәт белән дога укырга кереште. Шул чагында Клара, бу изге күңелле картка садака бирергәме, юкмы дип, кат-кат уйлады, бер-ике тапкыр беләгенә элгән кечкенә сумкасын да ачмакчы булды, ләкин комсомолкага андый эшнең ярамаганлыгын уйлап, ахырда садака бирү ниятеннән кайтты.

Бабай авыз эченнән генә: «Урыны җәннәтнең түрендә булсын, амин!» — дип, битен ашыкмыйча гына сыйпады да кире торды.

— Һай гомерләр, гомерләр! — диде ул, үзалдына башын селкеп.— Берәү килә, берәү китә, шулай ул бу дөнья!.. Инде менә сезгә калды тормышлар... Сылу кыз булып үскәнсең, бәбкәм, Алла тәүфыйк бирсен үзеңә!

— Рәхмәт! — диде Клара, нигәдер калтырый башлаган иреннәрен көчкә тыеп.

Бабай бәйләмен алырга дип иелде һәм шул чакта Кларага сыенып торган Алсуны күреп, аның башыннан сыйпады.

— Һи, минем кошчыгым! Исемең ничек әле синең?

— Алсу! — диде бала, акрын гына.

— Әй-һәй-һәй, нинди матур икән! Үзең Алсу, әнкәң чәчәктер инде синең, әткәң кем икән соң? — дигән булды бабай, кызчыкны тагын бер кат сөеп, аннары бәйләмен җирдән күтәрде: — Юлыгызны бүлдем, барыгыз инде, үскәннәрем.

Бу очрашу бик дулкынландырды Кларaны. Аерылып киткәч тә һаман: «Нинди ягымлы кешеләр, нинди яхшы күңелле кешеләр!» — дип уйланды ул. Моңарчы бер җирдә дә әле аның мондагы кебек йомшак мөгамәлә, якты чырай күргәне, мондагы кебек шигъри тәмле итеп сөйләүне ишеткәне юк иде. Гаҗәп иде бу! Әллә аңа карата гына шулай микән? Үзара, бәлкем, алай ук түгелләрдер. Тормышны бик мәкерле нәрсә дип әйтәләр бит! Бер төчесен, бер әчесен каптыра, кешеләрне әледән-әле маңгайлары белән чәкәштергәли генә тора, диләр. Әмма шулай да кешеләргә изгелек хас булырга тиеш. Бик борыннан аларның йөрәкләренә салынган орлык булырга тиеш бу... Инде тормышлар яхшыра һәм бәхетләр тигезләнә барган саен, ул орлыклар тулысынча шытып, барлык кешеләрнең дә үзара мөнәсәбәтләре менә шулай якты, җылы булып китмәсмени?

Кларaның дулкынланган күңеленнән ихтыярсыз әнә шундый уйлар кичеп үтте. Аңа рәхәт иде, гүя бабай аны «туган туфракның» саф суына манып алды, ул рухи баеп, пакьләнеп киткәндәй булды.

Урманга керделәр. Монда торганы яфраклы агач иде: каен, юкә, усак, чаган, карама, элмә — танып та бетермәссең, ләкин бер генә дә ылыслы агач юк. Шуңамыдыр, урман эче ничектер нурлы иде, әледән-әле хисапсыз чәчәкләр белән чуарланган кечкенә аланчыклар ачыла гына тора иде. Бу күренештән Кларaның башы әйләнеп, кайсы аланчыкта тукталырга, кайсы чәчәккә үрелергә белмичә, ул әле уңга, әле сулга кереп китә, аннары тагын иске урынына килеп чыга иде... Ул тик балаларны югалтудан курыкты. Алсуны бер дә кулыннан ычкындырмады, ләкин Алмас тәмам аның теңкәсен кортып бетерде. Малай, урман җәнлеге шикелле, каядыр китә дә югала иде. Клара кычкыра, эзли, кечкенә Алсу елый башлый, ә җен малай, берни булмагандай, әллә кайдан гына килеп чыга да: «Әйдә, апам!» — дип, йә җиләк тулы берәр уйдыклыкка, йә оясы белән утырган бөрлегәнлеккә ияртеп алып китә иде. Менә бит ул нинди! Ә җиләк-бөрлегәннәрне ашап кына бетерерлек түгел. Сумка элеп чыкканчы, чиләк күтәреп килгән булсачы?.. Ахырда, урманны шактый айкап йөргәннән соң, бер дә күрмәгәндәй зур кочак чәчәк җыеп, кайтырга чыктылар.

Кайтсалар, Клара ни күрсен: «Рәхмәй абыйсы лапас астында баштүбән салындырып аскан сарыкны тунап ята. Җирдә табак, комган, Мөнирә ире янында басып тора. Балалар туры шунда йөгерделәр, Клара, карамаска тырышып, тизрәк өйгә узды. Казан тирәсендә булашкан җиңгәчәсеннән ул куркынган бала сыман:

— Җиңгәчи, Рәхмәй абый сарыкны нигә суйды? —дип сорады.

Җиңгәчәсе, көлемсерәп:

— Әй, Иркә туташ, гомердә бер кайткан кадерле кунак бит син безгә,— диде.— Синең өчен тәкә дә суймагач, ярыймы соң!

Клара, ни әйтергә белмичә, бераз сүзсез торды, аннары рәхмәт әйтәсе урында, ихтыярсыздан:

— Ничек инде кызганмыйча? — дип куйды.

Җиңгәчәсе аны бөтенләй башкача аңлады.

— Әйтә күрмә, аккошым! — диде ул, кулын селтәп.—Кызганып торырга тагын... Аллага шөкер, актыгы түгел әле, быел сигез бәрәнебез булды. Игелеккә язсын!

Шулай да Клара күңелсезләнеп калды. Аның өчен дип кенә берни сизмичә кетер-кетер үлән кимереп йөргән яшь тәкәне тотсыннар да суйсыннар, имеш! Бу авыл кешесе җан иясен нигә бер дә кызгана белми икән? Үзләре шундый яхшы күңелле кешеләр, ә хайван суярга куллары бара. Менә аша инде хәзер шул... мескен тәкәне! Үз күзе белән күрмәгән булса, тагын бер хәер иде.

Шул арада Мөнирә җиңгәчәсе зур табак белән тәкәнең итен, үпкә-бавырын кертеп чыкты, ә Клара, бер эш булсын дип, чәчәкләр көлтәсен кәнәфигә таратып салды да яңадан тигезләп, матурлап җыйды. Аннары карт җиңгәчәсеннән бер тар муенлы чүлмәк сорап алды да, шуңа су салып, чәчәкләрен тутырып, зур букетны нәкъ өстәл уртасына бастырып куйды. Җиңгәчәсе дәшмәде инде, аш өлгергәнче торып торсын, диде, ахрысы. Шәһәр кызының юанычы чәчәк икән, әйдә бер кинәнсен!

Аш сосар алдыннан гына аларга кара күн фуражка кигән таза, чибәр генә бер яшь кеше килеп керде. Аны: «Әйдүк, Хәсән, мактап йөрисең!» — дип, якты йөз белән каршы алдылар. Ләкин ул ашка калып тормады, бер чүмеч тутырып салкын су эчте дә китәргә ашыкты. Эшкә әйтер өчен генә керүе икән. Берсекөнгә авылның бөтен картын-яшен печәнгә чыгарабыз, ди, ике-өч көндә кибәнгә куеп бетерергә кирәк, йә һавалар бозылып китәр, ди. Аннары игеннәр дә тәмам өлгереп килә икән, алдагы атнада, насыйп булса, ура башларбыз, ди.

Җиңгәчәсе егетнең бөтен әйткәннәрен хуплап торды, тик ахырдан гына:

— Һәй, Хәсәнкәем, әйткәнеңне дә көтмәс идем,—диде,— кунагым бар бит!

Егет елтыр кара күзләре белән Кларага туры гына карап алды да көлемсерәп:

— Кунак кызга да тырманың җиңелен әзерләп куярбыз,— диде.

Клара егетнең сүзеннән бигрәк, туры карашыннан уңайсызланып кызарды һәм башын горур гына читкә борды. Ә җиңгәчәсе шунда ук егеткә ташланды:

— Һи, мут күз! Иркә туташымны колхоз эшенә чыгарып имгәтер идеңме әллә? Булыр синнән, денсездән...

— Курыкма, тәтәй, имгәнмәс, утырып, ныгып кына китәр,— диде егет һәм тамак кырып куйды.

«Вот какой нахал!» — диде Клара эченнән, гадәтенчә бик ачуы килгәндәй итеп, ләкин нигәдер чынлап ачулана алмыйча.

Шуннан соң ул егетнең тыныч кына болай дип әйтүен ишетте:

— Хәмдияттәй, мин сине артык кыстамыйм, кунакны ялгыз калдырып булмый, канешно, аны гына беләбез... Үз җаеңа карарсың тагы, эш синнән качмас... Ярый, мин киттем. Хушыгыз, туташ!

Клара, борылып, аңа чак кына башын иде, ә җиңгәчәсе кинәт урыныннан кубып:

— Тукта, тукта, Хәсәнкәем, кая ашыгасың? — диде.—Тәкә суйган йортка кереп, ит капмыйча китсәң, языгы кемгә булыр?

Һәм табактан бер тәлинкәгә зур гына ит кисәге, берничә бәрәңге салып, өстәлгә китереп куйды. Бригадир, нишлисең инде дигәндәй, иңбашын җыерды да, утырып, итне мул гына тозлап, турамыйча-нитмичә, тотып ашый да башлады.

— Ай-һай, Хәмдияттәй, тәмле пешкән дә соң бу яшь тәкә! — диде ул, умырып капкан саен башын чайкап... Ахырдан гына бер бәрәңге кабып җибәрде, аннары майланган бармакларын итегенең кунычына ышкыды да, торып, өйгә бәрәкәт теләп, рәхмәт әйтеп чыгып та китте.

Ниһаять, бар да ашка җыелдылар. Балаларны казан ягына сәкегә урнаштырдылар — кунак барында аларның урыны шунда икән.

Җиңгәчәсе зур агач табак белән аш сосып китерде. Өреле шулпага катык тугылап ашадылар — Кларага бик ошады авылча «симез» токмач белән шулпа... Шулпадан соң җиңгәчәсе һәммәсенең тәлинкәсенә тутырма дигән нәрсә салып чыкты. Бусы — тәкәнең үпкә-бавырыннан, дөге белән бергә эчәккә тутырып, шулпада пешерелгән казылык иде. Клара, аны капкач, телен йотардай булды — гаҗәп тә тәмле иде ул! Шунда ук кечкенә блокнотына, бу тутырма дигән хикмәтнең ничек эшләнүен сорашып, язып та алды. Янәсе, Казанга кайткач, үзе пешереп, өйдәгеләрне бер сыйлаячак.

Аннары коштабак белән калҗалап тураган ит килде. Җиңгәчәсе аның өстенә суганлы, борычлы кайнар өре салып җибәрде — һәм өйгә әчкелтем хуш ис таралып китте.

Шуны әйтергә кирәк, баягынак Кларaның кәефен боза язган тәкәне кызгану хисе хәзер каядыр югалган иде инде... Ашаганда тере тәкә аның күз алдына килеп җанын борчымады. Хәер, табын яны гел сүз белән узды, һәм Кларaның уе бөтенләй башка нәрсәләргә китте. Менә хәзер генә ул туганнары белән якыннан танышты. Рәхмәй абыйсы гади колхозчы икән, бригадир кая җибәрсә, шунда эшләп йөри икән, ләкин болай селкенеп йөрүдән туйдым, ди, колхозыбызның хәзер үз машиналары булачак, берәр комбайнга басарга исәпләп торам, ди. Председательләре аңа вәгъдә биргән икән инде.

Мөнирә җиңгәчәсе, әйткәнебезчә, фермада сыер сава. Клара ни өчендер аны тирә-якка даны таралган алдынгы сыер савучыдыр дип уйлаган иде. Ләкин алай ук түгел икән, газетада рәсеме чыкмаган икән әле... Җиңгәчәсе, акланырга теләгәндәй, сыерларыбыз вак, ди, югыйсә тырышабыз инде, ди. Шулай да ферма тактасына гел язылып бара икән.

Клара аларның көнкүреш хәлләре белән дә, читләтеп кенә булса да, кызыксынып карады. Карт җиңгәчәсе ике сүзнең берендә «Аллага шөкер» дип тора. Ипи кайгысы китте, ди, түбәбездән су үтми, ди, мал-туарыбыз бар, ди, аяк-кулыбыз сау, ди. Аннары аның читтәге ике улы белән бер кызы да онытып бетермиләр икән, чәй-шикәрлек карчыкка килгәләп тора икән.

Гомумән, ул бик азга да шөкер итәргә өйрәнгән, ахрысы. Чөнки сугыш башланган елны иреннән калып, берсеннән-берсе яшьрәк алты баласын бик зур авырлык белән үстергән. Ә нужа азның да кадерен белергә өйрәтә икән ул...

Әле дә менә, сүз чыккач, гади генә бернәрсә итеп сөйләп алды:

— Шулай, сугыш вакытында, яшь ярымлык Һәдиямне күтәреп, стансага икмәк эзләп бардым,— дип башлап китте ул, тирләгән битен тастымал очы белән сөртә-сөртә.— Икмәкне таптым, кайтырга чыктым, бер beләгемдә бала, икенчесендә — ашъяулыкка төреп элгән ике зур каравай... Кайта-кайта кулларымның чистый хәле бетте бит, өзелеп төшәләр дип торам... Нишләргә инде?.. Күп тә калмады югыйсә, ә баралмыйм гына бит, хет ташла да кит... Шуннан, Һәдиямне юл кырыена утыртып калдырдым да төенемне бер җир буе алга илтеп куйдым. Аннан баламны килеп алдым. Тагын төенемне алга илтеп куйдым, тагын баламны кире кайтып алдым... Шулай итеп, әле ипекәемне, әле балакаемны күчерә-күчерә, көч-хәлгә кайтып егылдым!

Клара шактый сүзсез калып утырды, әллә нишләтте аны бу кечкенә хикәя, әйтерсең бәгырен туңдырып җибәрде. Ләкин моның сәбәбе җиңгәчәсен яки юл буенда утырып калган баланы кызганудан гына түгел иде (кызгану бу очракта бик зәгыйфь хис ул), ә дөреслекнең кайвакытта никадәр рәхимсез булуын аңлаудан, кешеләрнең шуңа тыныч карый алуларына хәйран калудан иде. Гаҗәеп бит! Җиңгәчәсенең сүзендә ник бер сыкрану ишетелсен! Булган да узган — бары шул гына! Җитмәсә, әле Кларaны юатып маташа: «Синең, Иркә туташ, исең китмәсен,— ди.— Һи, аның ише генә хәлләр кем белән булмады,— ди.— Адәм баласы әрсез бит ул, көлдә аунар —көнен күрер,— ди.— Һәдиям дә менә, шөкер, фызу бетерде, калада шкатурчы булып эшли, үзебез дә, колхозыбыз тернәкләнгәч, күкәй эчендәге сары кебек тора башладык»,— ди.

Әлбәттә, Клараның үзеннән дә күп нәрсәләр турында сораштылар. Ләкин Клара өчен үз хәлләрен ачык кына сөйләп бирү шактый читен мәсьәлә иде. Аерма бик зур, тормышлар бөтенләй икенче төрле, теләкләр дә, юанычлар да башкача иде. Сөйләсә, ихтыярсыздан шул аерма ачылачак, ничектер мактану булып чыгачак. Ә аның бу кешеләр алдында мактанасы, шәп, рәхәт торулары белән ялтырап күренәсе килми иде. Шуңа күрә ул күбрәк бабасы турында, бабасының Каракошны ничек сагынуын, ничек аңа туган якларны бер кайтып күрергә әйтә килүен сөйләп утырды.

Сүз ахырында, иртәгә Каракошка барып кайтырга булдылар. Җае да чыгып тора икән — Рәхмәй абыйсы, бригадир кушуы буенча, шунда барырга тиеш.

## III

Икенче көнне, иртәнге чәйдән соң, Рәхмәй абыйсы әлеге биле сыгылыбрак торган тарантаска Алмас белән Алсуны утыртып, шул ук бәләкәй атта кызу гына ишегалдына юырттырып килеп керде. Балаларны төшереп, печән өстенә чуар палас чыгарып җәйделәр, ике мендәр салдылар.

Иң элек Хәмдия җиңгәчәсе — кызыл эчле тирән галошлардан һәм эре чәчәкле шәльяулыктан, туйга баручы кодача төсле, бисмилласын әйтеп, иплән кенә тарантаска менеп утырды. Аның янына чажлап торган ефәк плащтан, каурый кадаган бик килешле күк эшләпәдән Клара менеп урнашты.

Кузгалып киттеләр. Балалар әниләре янында елашып калдылар. Шулар гына Клараның йөрәген бераз сыкратып алды...

...Авыл урамының түбән очыннан барып чыккач, сулга борылып, тау итәгеннән киттеләр. Ялгыз утырган тау шактый биек һәм мәһабәт иде. Таулар Кларада һәрвакыт ихтыярсыз соклану уяталар. Гүя алар, дөньядан югары күтәрелеп, түбәндәге тормышка бәйсез бер горурлык белән, тын гына карап торалар. Алар бик күп хәлләрне күреп беләләр һәм эчләренә җыеп баралар төсле... Нинди генә тауны күрмәсен, Клараның шуңа менәсе, шуның түбәсеннән дөнья өстенә карап торасы килә иде.

— Җиңгәчәй, бу нинди тау? — дип сорады ул, калкына биреп.

— Бу безнең Чабылтавыбыз,— диде җиңгәчәсе.

Моны ишетүгә, Клараның исенә бабасы кылт итеп төште. Мәрхүм бабасы еш кына: «Чабылтау, Чабылтау»,— дип сөйләнә иде. Шушы икән инде ул Чабылтау! Бабасы малай чагыннан ук бу тау тирәсендә күп йөргән булырга тиеш. Шунда аларның җирләре, шунда печәнлекләре булган шикелле... Клара бу хакта сорагач, җиңгәчәсе:

— Әйе, аккошым, каенатамнарның Корысазлык дигән печәнлекләре шушында иде шул,— диде.

Кучерда ат тотып барган Рәхмәй абыйсы борыла төшеп:

— Корысазлык бездән сулда кала, күрсәтермен әле,—диде.

Һәм бераз киткәч тә, ул сирәк-мирәк кенә нечкә каеннар үскән, ә урта бер җирен яшел таллык каплаган зур гына уйсулыкка чыбыркысы белән төртеп күрсәтте.

— Әнә шунда инде Корысазлык. Борын аның уртасында түмгәкле күл булган, диләр. Хәзер ул күл юк инде, кибеп бетте...— Һәм Рәхмәй абыйсы боларга кырын утырып, Клара өчен кызык бернәрсә итеп, сөйләп китте: —Элек заманда бу сазлыкка торналар күп килә торган булганнар... Торна ул оясын түмгәк өстенә ясый икән. Бала чыгарганда, шул түмгәккә атланып утыра икән, аягы бөкләнми, имеш, аның... Бервакытны Хәнәфи дигән карт, сазлык яныннан үтеп барганда, түмгәк өстендә утырган торнаны шәйләп алган, ләкин торна икәнен танымаган... «Кемнең чикмәне анда ята?» — дип уйлаган карт. Шуннан тиз генә ыштанын салган да, бер чыбык сөйрәп, суга кереп киткән бу... Түмгәккә якынлашкач, «чикмәнне» эләктереп алыйм дип, чыбыгын торнага төртүе булган, торна, сискәнеп: «Тар-тар!» — дип кычкырып җибәргән... Моны ишеткәч, карт, тураеп, күкрәгенә сугып: «Шаярма, тар-тар түгел, Хәнәфи абзаң булыр бу!» — дип әйткән, ди...

Көлештеләр, ә җиңгәчәсе: «Һи, заманнар, картлары да балалар төсле булган»,— дип, бер көрсенеп куйды.

Юл, Чабылтауны әйләнеп, көньякка табан борылгач, Клара алдында гаҗәеп күренешләр ачылды. Бу ялгыз тау үзе дә гаять зур биеклек өстендә утыра икән. Шушы биеклек өстеннән кайсы якка гына карасаң да, җәелеп яткан аксыл иген кырлары, яшел үзәннәр, күгелҗем урманнар, бөдрә куаклыклар белән капланган озын чокырлар, якында һәм еракта утырган тагы да ниндидер мәһабәт таулар күренә иде. Рәхмәй абыйсы юл буенча диярлек шуларның әле берсен, әле икенчесен күрсәтеп барды: «Ә-әнә теге Өзектау инде! Шуннан уңга таба китсәң, безнең Зирекле буена барып чыгасың. Әнә нәкъ каршыбызда Әркәсле яланы... Сулга карасаң, әнә анда Имәнлек башланып китә... Бабакаеңнан ишеткәнең дә бардыр әле».

Әйе, дөрес, Клара боларның барысын да бабасыннан ишеткәне бар иде. Шуңа күрәдер инде хәзер аңа бу кырлар, бу таулар, бу урманнар электән үк таныш төсле булып тоела иде. Хәтта берара аның күңеленнән: «Тукта, мин үз күзләрем белән дә боларны кайчандыр бер күрдем түгелме соң?» — дигән гаҗәеп сәер, шул ук вакытта ничектер бик якты, ләззәтле сизенү кичеп үтте. Бик ышанасы килде шуның

чын булуына! Ләкин... юк, күргәне юк, әлбәттә. Әмма шушы ачык сизенү тәэсиреннән ул ихтыярсыз авыз эченнән генә берничә мәртәбә: «Туган туфрак, туган туфрак!» — дип кабатлап куйды.

Гел юырттырып бара торгач, алар ахырда ак маңгайлы тәбәнәк таулар өстенә килеп чыктылар. Түбәндә кечкенә елгачык, шул елгачык буйлап сузылып киткән Каракош авылы җәелеп ята.

Ике тау арасындагы текә юлдан атны тыя-тыя гына түбән төштеләр һәм чуерташлар өстеннән сырланып аккан инешне кичеп, бер тыкрыктан авылның зур урамына барып керделәр... Менә сиңа Каракош!

Тәҗрибәле күз бу авылның кайчандыр бик зур булуын һәм бик тыгыз утырганлыгын чамалар иде. Төп урамның бер очыннан икенче очын күреп булырлык түгел... Тагын янәшә сузылган һәм аркылы кисеп узган урамнар да бар. Кыскасы, искечә әйткәндә, элек бу өч-дүрт мәхәлләле бер авыл булган булырга тиеш. Хәзер исә, өстеннән давыл узгандай, ул бик сирәкләнеп, тузгып калган иде. Заманында Каракоштан өч-дүрт кечерәк авыл бүленеп чыккан. Аннары елдан-ел акрынлап, йорт-җирләрен бетереп, читкә китүчеләр дә күп булган... Колхозлашу елларында мондый зур авылдан читкә сөрелүчеләр дә аз булмагандыр, һәрхәлдә, Каракош башыннан күп хәлләр кичкән булырга тиеш.

Ләкин Клара боларның барысыннан да хәбәрсез иде, билгеле. Авыл аңа шактый табигый һәм тыныч-имин булып күренде. Хәер, асылда Каракош хәзер шундый иде дә.

Авыл уртасына җитәрәк алар урамга буй салынган, такта белән япкан таза гына йортның капкасына килеп туктадылар. Бу — Кларага әллә кайсы яктан, әллә ничек кенә кардәш тиешле Сәйфетдин абзыйның йорты иде. Капканы өстенә ак күлмәк, башына кара кәләпүш кигән кәкрерәк аяклы хуҗа үзе ачты.

— Һай, бәрәкалла! Әйдәгез, хуш килдегез! — дип каршы алды ул кунакларны.

Ат ишегалдына узып, кунаклар тарантастан төшәргә өлгермәделәр, өйдән шәһәрчә диярлек киенгән, кечкенә буйлы, йөзгә бик сөйкемле яшь хатын һәм буйга-сынга таза гына егет ашыгып чыктылар. Болар Сәйфетдин абзыйның улы белән килене иде...

Хәмдия җиңгәчәсе Кларaны терсәгеннән этәребрәк:

— Менә Иркә туташны сезгә күрсәтергә алып килдем,— диде.— Хамматҗан дәдәбезнең внукасы була инде. Каладан кайтты.

— Һи-и-и, шулаймыни? — диде Сәйфетдин абзый, тәмам шаккатып.— Хамматҗан абзыйның шундый внукасы бармыни? Машалла! Күз генә тия күрмәсен, алтын алма булып җиткән икән! Әйдүк, әйдүк, ике күзем, түребездә бул!

Барысы да аның белән бик куанышып күрештеләр. Аеруча Кларaны күрүенә яшь килен бик шат иде шикелле — ничектер беренче караштан ук ул аңа, үз тиңен очраткандай, бик җылы, бик якын итеп карады. Аннары кунакларны өйнең түр ягына алып керделәр. Өй эче тәмам шәһәрчә дип әйтерлек иде. Биредә никель караватта, шифоньер да, китаплар тулы этажерка да, хәтта зур радиоалгыч та бар иде. Чебеннең әсәре дә юк, үзе чиста, үзе рәхәт, салкынча... Күренеп тора, шәһәр тәртибен алып килгән кешенең кулы хуҗа монда...

Яшь килен, биленә кечкенә алъяпкыч буып, аш-чәй хәстәренә кереште. Ире дә аңа, кушмастан, булыша башлады... Хикмәт шул яшь килендә түгелме икән?.. Картлар үзара хәл-әхвәл сораша башладылар, Сәйфетдин абзыйның карчыгын сагынып исләренә төшерделәр, ул күптән вафат икән инде.

Хуҗа бер чыккан арада, Клара җиңгәчәсеннән акрын гына: «Бабакайлар йорты еракмы, кайчан барабыз?» —дип сорап куйды. «Ерак түгел»,— диде җиңгәчәсе; шуннан, Клара бик үтенгәч, алар чәйгә хәтле барып килергә булдылар.

Урамга чыккач, җиңгәчәсе Кларaны югары очка таба алып китте һәм, бераз баргач та, ике йорт арасындагы иркен генә бер буш урын каршында тукталды.

— Менә шушы була инде бабаңнарның утырган җирләре, Иркә туташ! — диде ул, кабер өстенә килгәндәй, тавышын акрынайтып.

Клара берни аңламыйча әүвәл алга, аннан тирә-ягына каранды. Нәрсә соң бу?.. Урамнан алып инешкә төшеп җиткәнче алабута, кычыткан, әрекмән басып бетергән буш җир җәелеп ята. Ник бер агач, ник бер таш, ник бер каккан казык күренсен! Бу урында кайчан да булса кемнәрнеңдер йорт-җир белән дөнья көтеп яшәүләрен күз алдына китерүе дә бик читен иде. Клара, тәмам аптыраган хәлдә, ни әйтергә белмичә, шактый сүзсез тынып торды. Җиңгәчәсе, аның хәлен аңлап булса кирәк, җиңелчә көрсенеп әйтеп куйды:

— Бетте шул инде, нигез дип әйтерлеге калмады...

— Ә кая булды соң мондагы йорт, бабакайдан калган йорт? — диде Клара, нигәдер бераз сабырсызланып.

— Соң белмисеңмени, бабаң бит, сезнең янга киткәндә, йортын сакау Хисамига сатып китте!

— Беләм. Ишеткәнем бар... Ну, ә ул Хисами кайда соң монда?

— Хисамимы? Хисами сугыш беткәч тә сафхузга күчеп китте... Йортын да шунда күчерде... Бик әйбәт тора, диләр... Күркәсенә чаклы асрый икән... Ишетмәдегезмени?

Клара башын гына чайкады... Һәм алабута, кычыткан баскан буш җиргә карап тора башлады. Шушы икән инде... «нигез»!.. Бернинди кызгану-фәлән кебек нәрсә хис итмәде Клара үзендә, тик алдануы өчен кәефе генә азрак кырылды... Бер генә дә күрер нәрсә калмаган ич! Хыялы белән дә ул биредә нәрсәләр

булганын күз алдына китерә алмый иде... Юк, билгесез, ят бер урын икән бу аның өчен... Ләкин шулай да ул уйламыйча булдыра алмады: әгәр бабасы үзе бу ташландык урынны кайтып күрсә, нишләр иде икән? Түзмәс иде, елар иде, һичшиксез елар иде... Туган җирем, гомер иткән җирем, дип, шәһәрнең дүрт стенасы эчендә гел сагынды да утырды бит!

Инде китәргә дә ярыйдыр. Шулай да Клара, нидер исенә төшереп, җиңгәчәсеннән сорады:

— Бабакай: «Бакчабыз бар, бакчабызда зур каен үсеп утыра»,— дип сөйли торган иде. Кайда ул?

— Каенмы?.. Ә әйе, бар иде шул, бар иде... Кистеләр. Каенын да, барысын да кистеләр. Хуҗасыз калгач ни...—Җиңгәчәсе башындагы яулыгын алгарак тартып куйды.—Бабаң картайды,— диде ул, сузып кына...— Малайлары таралышып беттеләр. Карчыгы үлде. Ялгыз нишләсен ул монда?.. Барысын сатты да китте...

— Җиңгәчәй, син бу йортны яхшы беләсеңдер инде?

— Һи, белмичә соң! Мин бит шушы йортка килен булып төштем. Минем Хамматшам бабаңнан аерылып чыкмаган иде әле... Туебыз бик тә күңелле, бик тә шәп узды... Вәлиулла абзый, мәрхүм, туй капкадан килеп керүгә, мылтыктан атып җибәрде. Ул халык, мин сиңа әйтим, ул бала-чага!.. Мине җитәкләп ак киез өстеннән генә өйгә алып керделәр... Һи, сөйләсәң, Иркә туташ, исең-акылың китәр. Үтте инде... үтте. Аллага шөкер, менә хәзер үзем дә киленле булдым. Тик Хамматшам гына күрмәде.

Шулай элекке нигездән бер таш кисәге дә калмаган буш җир өстендә анысын-монысын искә төшереп бераз сөйләшеп торганнан соң, алар акрын гына кузгалып, Сәйфетдин абзыйларга кайтып киттеләр.

Яшь киленнең тәртипле, матур, мул табыны әзер иде. Биредә инде күп сыйлар өстенә тагын быелгы җир җиләгеннән кайнаткан варенье да һәм баллап катырган чәкчәк тә бар иде.

Чәйне озаклап, тәмләп эчтеләр. Сәйфетдин абзасы белән җиңгәчәсе сөйләшеп рәхәтләнделәр генә. Әллә кайчангы хәлләрне искә төшереп, әллә кемнәрне телгә алып беттеләр. Кем белән ни булган, кем кая киткән, ул анда ничек тора, кемнең баласы кайсы шәһәрдә кем булып эшли, кемнең улыннан яки кызыннан күпме акча килгән, ә кем бер тиен дә җибәрми — барысын да санап чыктылар. Клара бернәрсәгә гаҗәпләнде: Каракоштан дөньяга сибелгән кешеләр гаять күп икән... Ерак Көнчыгыш, Себер, Урта Азия, Урал, Мәскәү, Ленинград, Киев, Баку —кая гына барып чыкмаганнар алар! Тагын шунысы кызык — кайда гына булмасыннар, ниндидер нечкә җепләр аларны Каракош белән һаман бәйли икән әле.

Чәйдән соң яшьләр авыл буйлап бер йөреп кайтырга дип чыгып киттеләр. Хәмдия җиңгәчәсе үзе кушты: «Сания килен, барыгыз, Иркә туташка авылны күрсәтегез, казаныңны үзем карармын»,— диде ул яшь киленгә.

Сания үзе дә, аның ире Зиннур да Клара өчен бик кулай кешеләр булып чыктылар. Алар икесе дә Каракош мәктәбендә укыталар икән. Сания үзе шәһәр кызы икән, педагогия институтын бетергәч, аны шушы авылга җибәргәннәр... Клара башта ук аның авыл кызы булмавын сизенгән иде. Инде белгәч, ул аңа үзе ишедәй бик якын булып күренде.

Зиннур инде төп Каракош егете иде. Ул эше белән дә, укуы белән дә Саниядән түбәнрәк тора шикелле — Клара шулайрак сизде... Аннары егет үзенең кечкенә хатынын бик ярата иде булса кирәк. Ничектер менә хуҗасына бик ияләшкән юаш ат шикелле тота иде ул үзен Саниясе янында.

Алар Кларaны урам уртасыннан түбән очка таба алып киттеләр. Авылның хәл-әхвәлен аз-маз сөйләп бардылар. Әлбәттә, киләчәген күбрәк сөйләделәр, чөнки алар яшьләр, чөнки Каракошның киләчәге, үткәненә караганда, һичшиксез, матуррак булырга тиеш. Бу ышаныч, бу теләк бигрәк тә шәһәрне ташлап килгән Саниядә нык сизелә иде. Гүя аңа шунсыз монда яшәү мөмкин дә түгел!

Дөрес, Каракошның хәзергә әле ерактан килгән кунакка мактап күрсәтерлек әллә нәрсәсе юк. Күп нәрсәләр яңа башланган яки планда гына икән әле... Хәер, бу гаҗәп тә түгел, чөнки ярты халкы таралып беткән Каракош, озак еллар бер урында таптанып торганнан соң, яңарак кузгалып, югары үрмәли башлаган иде.

Кларага колхозның былтыр гына салынып беткән яңа идарәсе белән гаражын күрсәттеләр. Рәшәткәләп алган иркен ихата эчендә зур, матур йорт. Алты тәрәзәсе урамга карап тора. Бер башында китапханә икән... Клара: «Ә клубыгыз бармы?» — дип сорагач, Сания аңа бер генә сүз белән җавап бирде: «Булачак!»

Идарә артындагы яшел чирәмгә салынган ике ишекле кызыл кирпеч гараж да болай зур гына, чибәр генә кебек иде. Зиннур әйтә, монысы, ди, идарә машиналары өчен генә, ди, ә колхозның барлык машиналары өчен авыл читендә зур сарай салынып ята, ди.

Бер уңайдан Кларага идарә каршында торган мәчетне дә күрсәттеләр. Клара гаҗәпләнә калды: мәчетнең тәбәнәк кенә манарасы белән кәкрәйгән ае да бар, имеш! Ничек сакланган ул! Ләкин бик тә искергән, тузган инде. Түбә такталарына яшел мүк чыккан, бүрәнәләре тәмам караеп беткән. Тәрәзәләре яшькелт зәңгәргә әйләнеп, карасу төшкән күзләрдәй, дөньяга күрмичә карыйлар төсле... Мәчет Кларада ятсыну һәм шомлануга охшаган ниндидер бер авыр хис уятты. Ә бабасы аның мәчет катындагы мәдрәсәдә укып йөрүен сөйли торган иде. Анысы хәзер юк, күрәсең. Әйе, бабай заманындагы нәрсәләр акрынлап менә шулай тузып, череп, юкка чыгып беткәннәр яки бетеп баралар икән инде... Алар урынына әнә бабай күрмәгән, бабай белмәгән яңалары туа...

Мактаулы Каракош! Клара үзенчә бик кызыксынып, сынап карый аңа. Монда беренче күзгә ташланган нәрсә —авылга каршы яклап тезелеп киткән таулар иде. Бабасы: «Каракошкайның таулары киртләч-киртләч, киртләчләре бетә кар киткәч»,— дип җырлый торган иде. Чынлап та, бу ак маңгайлы текә тауларны вак ерганаклар агып һәм кәҗәләр таптап, аркылыга-буйга сырлап бетергәннәр икән. Таулар Кларага ни өчендер тәбәнәк һәм боек күренделәр.

Авыл үзе бик чуар. Өйләрнең искергән-тузганнары да күп, ишелергә торганнары да бар; нигезен яки түбәсен яңартып җибәргәннәре дә шактый гына, өр-яңадан салынганнары да очрый... Әгәр Клара урынында берәр дөнья күргән олы кеше булса, ул, бу өйләргә карап, авылның үткән тарихын да, бүгенге хәлен дә китаптан укыган шикелле укыр иде.

Авылда яшеллек тә аз икән. Агач бакчалары юк диярлек, тик кайбер йортларның гына тәрәзә алларында сирень куагы, киртә буйларында ялгыз каен яки шомырт, яки миләш агачы үсеп утыра. Әмма һәрбер йортның койрыгында сузылып киткән бәрәңге җире бар. Клара өчен кызыклы түгел ул бәрәңге җире. Хәер, аны шагыйрьләрнең дә мактап җырлаганнары юк әле. Авыл кешесенең үзе өчен генә кадерле ул... бәрәңге!

Шулай карап уздылар Каракошның зур урамын. Очраган бер бала, алар белән исәнләшеп, авызын ачып калды. Ишегалдында йөргән агай яки җиңги дә тукталып, каз шикелле башын кырын салыбрак карап калды. Чөнки безнең Кларабыз бик сылу кыз иде, бик чибәр киенгән иде. Шуңа күрә инде һәркемнең күңеленә: «Кемнеке булыр бу, кайдан кайткан, ниләр алып кайткан?» — дигән уйның килмичә калуы һич мөмкин түгел иде.

Авылдан тип-тигез тугайлыкка барып чыктылар. Алда — буа, буада — иске тегермән, ә тегермәннән ары ферма каралтылары күренә. Ямь-яшел тугайда көтү-көтү ап-ак казлар утыралар.

Яшьләр фермага барып тормадылар, чөнки анда буш абзарлардан башка берни дә юк, маллар — көтүдә... Авыл артына, чирәмлеккә күтәрелеп, шуннан ашыкмыйча гына кайтырга булдылар.

Монда җире дә, һавасы да бөтәнчәрәк икән — ничектер дала исе аңкый. Бөрчекләнеп торган кара туфрак, эсседән кипкән сирәк үлән һәм ефәк чуклы кылганнар... Кылганнар... Гел бер якка таба селкенеп торалар икән бу... кылганнар. Казан тирәсендә юк бит алар.

Сания, иелеп, җиргә учлам-учлам ябышып үскән вак кына зәңгәр чәчәкле бер үләнне йолкып алды да Кларага:

— Мәгез әле, иснәп карагыз! — дип сузды.

Клара үләнне алып борынына китерде һәм хәйран калды: үлән искиткеч хуш исле иде.

— Нәрсә бу?

— Ислекәй... Ислемай үләне,— диде Сания.

Ислемай үләне! Клара аны тирән итеп, кат-кат иснәде һәм бер мәлгә исереп киткәндәй булды. Чиксез дала аның күз алдына килде. Бабасының яшь малай чагын, шушы ислемай үләннәрен җыя-җыя йөгереп йөргән чакларын ап-ачык күргәндәй булды... Кинәт шулкадәр ерак үткәнгә кайта алу әллә ничек шомлы да, әйтеп бетергесез татлы да булып тоелды аңа... Айнырга теләп, ул башын кат-кат чайкап куйды.

Сания тагын ак әремне дә уып иснәтте. Монысыннан да дала эссесе, дала исе аңкып тора иде. Клара ихтыярсыздан: «Әтием бу исләрне ничек оныта алды икән?» —дип уйлап куйды. Ә менә бабасы онытмаган иде, сагына иде. Әгәр ул исән булса, Клара бу үләннәрне алып кайтып, аңа иснәткән булыр иде.

Көн бик эсселәнеп китте, шуңа күрә яшьләр артык юанмыйча өйгә кайтырга ашыктылар. Хәтта авылдан читтәрәк тигез чирәмлектә утырган зур таш мәктәпкә дә кереп тормадылар, тик Сания генә бу мәктәпнең районда иң зур, иң бай мәктәп булуын сөйләп алды. Алар шунда укыталар икән инде...

Кайткач, тагын чәй эчтеләр. Аннары каклаган ит, яңа бәрәңге турап һәм күкәй калҗасы салып пешергән бик тәмле аш ашадылар. Ниһаять, көн сүрелгәч, Сания белән Зиннурны берсекөнгә Зиреклебашка кунакка чакырып, юлга чыктылар.

Авылны чыкмас борын Рәхмәй абыйсы атын беразга гына кибет алдында туктатты. Җиңгәчәсе кибеттән, зур бер яулыкка барысын бергә салдырып, чикләвек, йөзем, кипкән өрек кебек нәрсәләр алды. Күлмәгенең тирән кесәсеннән кулъяулыкка төргән акчасын чыгарганчы, Клара барысы өчен түләп тә өлгерде. Аннары ул тагын бишбылтырдан бирле сатылмыйча яткан краб консервысын да, тозы өстенә чыккан селедканы да алмакчы булган иде дә, җиңгәчәсе моңа бик каршы төште. «Акчаңны әрәм итә күрмә, бездә андый нәрсәләрне ашаучы юк»,—дип, тәки алдырмады. Шуннан соң Клара Рәхмәй абзасына, көчләп дигәндәй, илле сумлык акча бирде. Рәхмәй үзеннән дә өстәп ике шешә акны, бер шешә кызылны алды. Шуларны кучер астындагы печәнгә әйбәтләп яшергәч, утырышып, авылдан чыгып киттеләр.

Кояш баер алдыннан гына Чабылтау итәгенә килеп җиттеләр. Кайтышлый сүз аз булды. Җиңгәчәсе, тирбәлеп килә торгач, оеп китте. Рәхмәй абыйсы башта колхоз эшләре турында аны-моны сөйләнеп килде-килде дә аннары ул да тынды. Кларанны бу сүзсезлек, бу юл талгынлыгы бер дә ялыктырмады, киресенчә, ул аңа риза иде, чөнки ул да, үз эченә йотылып, үз уйларын уйлап кайта иде.

Тау итәгенә җиткәч, барысы да җанландылар. Җиңгәчәсе калкынып:

— Мәшалла, кайтып җитәбез түгелме соң? — диде.—Һи, көтү дә кайтып бара икән ләбаса!

Чынлап та, алда, Корысазлык ягыннан юлга таба көтү чыгып килә иде. Рәхмәй абыйсы атын кызулата төште, һәм алар тузан, йон, сөт исе аңкыган көтүнең нәкъ алдыннан уздылар. Шул чакта Клара бик сәер бернәрсә күрде: җирдән, кәҗә-сарыклар арасында, әллә нихәтле сыерчыклар кайтып килә. Нәкъ менә көтүгә чыккан йорт кошлары шикелле очмыйча, җәяүләп, йөгерә-йөгерә кайтып киләләр. Бу гаҗәп сәер, кызыклы күренештән кәефе бик килгән Клара кычкырып ук җибәрде.

— Җиңгәчәй, карале, көтүдә сыерчыклар!

— Ә, ие шул! Бала очыргач, көтүдән калмыйлар инде алар.

— Нигә, ни өчен?

— Нигә дип, мал тирәсендә аларга азык табыла. Мал белән бит чебен дә корт та ияреп йөри... Шуларны чүплиләр инде бу Алла кошлары!

«Удивительно!» дип уйлап куйды Клара эченнән. Аңа ничектер берьюлы күңелле, рәхәт булып китте.

Рәхмәй абыйсы, артына каерылып, кояш баешына карап алды.

— Иртәгә дә аяз булмакчы икән,— диде ул, башын кагып.— Бик әйбәт. Печәнчеләргә мач килә.

Клара, кинәт җанланып:

— Җиңгәчәй, минем дә печәнгә барасым килә,—диде.— Миңа барырга ярыймы?

— Ник ярамасын! Ярый, бик ярый, аккошым! Үзем алып барырмын,— диде җиңгәчәсе, ничектер Кларaның бу теләген шунда ук куәтләп.

— Көлмәсләрме?

— Юк, нишләп көлсеннәр, Аллам сакласын! Менә кызларыбыз белән танышырсың... Кызларыбыз бик куштаннар, кунак итеп, үзеңне урталарына гына алып йөртерләр.

Рәхмәй абыйсы кисәк кенә көлеп куйды:

— Хәсән, бригадир, нибуч кунак дип тормас!

— Ә мин кунак булып түгел, эшләргә барам! — диде Клара, эре генә башын чөеп.

— Әйе, әйе, эшләргә инде, печән җыярга,— диде җиңгәчәсе, бала көйләгәндәй итеп.— Бергә барырбыз. Мин үзем дә бик яратам печән эшен, Иркә туташ!

— Барабыз, җиңгәчәй, барабыз! — диде Клара, чын-чыннан рухланып, һәм аны кинәт ниндидер бер канатлану, җилкенү биләп алды. Һич уйламаганда, аның менә хәзер үк әнә шул Чабылтауга менәсе, шуннан дөнья өстенә бер карыйсы килде. Ул атны туктатырга кушты: «Мин тауга менәм!» — диде. Җиңгәчәсенең аптырап: «Һай, Иркә туташ, каян уйладың әле, кояш та баеп бара, ялгыз куркырсың ич!» — диюенә карамастан, ул тарантастан төште дә ашыга-ашыга тауга таба китте.

Тауны менү читтән караганда гына ансат булып күренә икән ул. Иң элек тау, менә башлагач, шактый биек булып чыкты, аннары югарырак күтәрелгән саен ул текәрәккә әйләнә барды. Кларaның әледән-әле аягы тая башлады, хәтта ара-тирә артка таба шуып та киткәләде. Ләкин һичнигә карамыйча, үлән төпләренә аягын ныграк терәп, тазарак үскән сабакларга тотынып, иелә-бөгелә һаман күтәрелде. Ахырда, азаплана торгач, Чабыл башына менеп җитте... Туктады, тирән сулап, бермәл тын алып торды.

Тау түбәсе — ап-ак ташлык, үлән бик сирәк, урта бер җире чокыраеп тора. Монда сәер бер тынлык хөкем сөрә. Әллә нинди генә шунда, түбәндәге тормыштан аерылу хисен уяткан, бушлык халәтенә якын бер тынлык иде бу... Бу тынлыкта бары җилнең акрын гына исүе ишетелеп тора кебек...

Клара түбә уртасынарак атлады. Кояш баеп өлгергән иде инде... Ләкин бөтен әтраф бик якты иде әле, шунлыктан иң ерак офыклар да ачык күренә иде. Клара тантаналы бер киеренкелек кичергән хәлдә тирә-як дөньяны карарга кереште. Никадәр ерак җирләр ачылган иде аның күз алдында! Бик-бик еракта күгелҗем томанга өртелгән ялгыз таулар күренә, чиксез киңлекләргә сибелгән, әле тегендә, әле монда җиргә ябышып яткан авыллар күренә, җептәй сузылган юлларны да бик ачык аерып була. Хәтта юлларның теге яки бу төшендә, бөтерелеп сузылган тузанга карап, машиналар чабуын да шәйләп була иде. Һәм әнә шул таулар, кырлар, авыллар аша, ниндидер бер пәһлеванның зур адымнары шикелле, тимер челтәр баганалар әллә кайлардан килеп, әллә кайларга узып китәләр...

Клара озак кына Каракошны эзләде. Кайда ул, нигә күренми? Ниһаять, түбәндәге ике тау арасыннан ниндидер бер авылның читен күреп алды. Ул ерак та түгел иде. Клара чамалап карады: хәзер генә алар кайткан юл нәкъ менә шул ике тау арасыннан килеп чыга икән. Димәк, Каракош шунда. Тик ул тоташы белән күренми, әлеге ак маңгайлы тәбәнәк таулар аны каплап торалар. Әмма Каракошның бер генә читен күрү дә Клара өчен күңелле булып китте, ничектер менә авылдан аңа җанлы бер җеп сузылган кебек булды. Каракош аңа да якын икән ләбаса!

Аннары тирә-якка күз йөртеп, акрын гына артына борылды. Кинәт аның күзенә нидер көзгедәй уйнаклап-чагылып китте. Шуны эзләп түбәнгә карагач, ул тау итәгеннән авылга таба кешеләр төялгән өч атның китеп баруын күреп алды. Менә шул алдагы атта баручы кешеләрнең баш өсләрендә нидер җылык-җылык уйнаклап куйгалый... Нәрсә бу?.. Ах, чалгылар түгелме соң? Әйе, әйе, чалгылар шул! Арбага ике яклап тезелешеп утырган егетләрнең бастырып тоткан чалгылары ара-тирә әнә шулай чагылып-чагылып киткәли икән!.. Печән чабучылар кайтып баралар. Арттагы атларга, тырмаларын югары күтәреп, хатын-кызлар төялгән... Бу күренеш Кларaны аеруча сөендереп җибәрде. Иртәгә бит ул үзе дә печәнгә чыгачак. Менә шулай, үзе кебек кызлар белән бергә, аякларын салындырып, арбага утырган килеш, тырмасын

күтәреп болынга барыр, болыннан кайтыр!.. Теге кем, Хәсән дигәннәре: «Кунак кызга тырманың җиңелен әзерләп куярбыз!» — диде бит... Мут күз! Шәһәр кызының кулларын үзенчә кызгана торгандыр инде. Тукта, күрсәтер әле ул аңа үзенең кулларын!

...Менә Зиреклебаш. Карасана, яп-якында гына икән ул. Бөтен өйләре, каралтылары, ишегаллары, көтүдән таралган маллары, кечке эшләрен бетереп йөрүче кешеләре белән, уч төбендәге шикелле, ап-ачык күренеп тора. Ә-нә иң кырыйда Рәхмәй абыйларының өе. Ә-нә капка төбендә моннан бармактай гына күренгән Алмас белән Алсу тауга карап торалар бугай. Исләре китеп, Клара апаларын күзәтә торганнардыр инде алар. Уңган җиңгәчәсе кай арада кайтып, учагын ягып та өлгергән — морҗаларыннан аксыл төтен акрын гына һавага күтәрелә... Кунакчыл өйнең сый-хөрмәт төтене бу... Юк, алай гына түгел, туган туфрак төтене бу... Бар икән ул туган туфрак дигән кадерле җир! Һәм Клара үз гомерендә беренче тапкыр моның буш сүз генә булмавын аңлап, шуңа искиткеч сөенде. Беренче тапкыр, бик табигый рәвештә, туган җиренә, туган халкына, телдән генә сөйләнә торган түгел, ә кан тамырында йөри торган чын якынлык-мәхәббәт хис итте ул... Һәм бөтен хисләрдән дә изгерәк, көчлерәк бу хис аның яшь йөрәген әйтеп бетергесез куанычлы бәхет белән тутырды.

Ул, башыннан эшләпәсен алып, йөзен кичке тау җиленә куеп, күзләрен дым каплаганчы чиксез киңлекләргә карап торды. Аерыласы килми иде аның бу тын биеклектән, бу яңа, тансык хисләр дулкыныннан...

*1959*

# Шаяру

## I

Кечкенә генә Идел пароходы, өч тапкыр өзеп-өзеп кычкырткannan соң, акрын гына дебаркадердан аерылды. Халык җыелган якка шактый кырынаеп, үзенчә гайрәтләнгән булып, зур калаклы тәгәрмәчләрен шапылдата-шапылдата, ул елга уртасына таба борылды. Кайчандыр тар суларда, аккош төсле горур йөзеп, гомерен уздырган бу пароход, хәзер инде ашын ашаган, яшен яшәгән бабайга охшап, киң Идел уртасыннан ашыкмыйча гына түбән төшеп китте. Аның юлы Уфага чаклы, шушы юлда йөреп картайды ул. Бәлкем, Агыйделгә барып кергәч, һәм аның үрелеп сыйпарлык чәчәкле тугаен күргәч, пароходыбыз борынгыча яшәреп, дәртләнеп тә китәр, әмма хәзер исә, ярларыннан чыккан дәрья уртасында, ул ничектер көчсез дә, мескен дә булып күренә иде. Әйе, үтә икән шул, үзгәрә икән шул барысы да!

...Палубада каюта ачкычын кулында уйнаткалап басып торган ялгыз ханым, пароход пристаньнан бераз ераклашкач та, урыныннан кузгалып китте. Ярдан кульяулык болгый-болгый озатып калучылар арасында аның күздән югалганчы карап барырлык беркеме дә юк иде. Ирен ул пароходка утыргач та кайтарып җибәрде, чөнки ире аның бик эшле кеше, һәр минуты исәптә... Хәер, тор дисә, ул торыр да иде, кешеләр арасыннан такыр башын елтыратып, бу күздән югалганчы, эшләпәсен селкеп тә калган булыр иде, ләкин ханым аны тотмады инде. Ире үзеннән яшькә күп олы булганга күрәме, ханым аның белән кешеләр күзенә артык чалынырга, ирле-хатынлы икәнлекләрен ачык сиздерергә бик үк яратып бетерми иде. Ире үзе дә моны сизенә иде шикелле. Ләкин алар арасында бу нәрсә бервакытта да, ялгыш кына да телдән әйтелгәне юк, киресенчә, яшь аермасын әнә шулай эчләреннән генә уйлаган хәлдә, алар бик тату яшиләр иде... Моңа артык гаҗәпләнергә дә туры килми, чөнки ире аны уч төбендә генә кадерләп тота иде.

Ханым палубаны бер әйләнде, ике әйләнде, ахырда, йөрүдән кызык тапмагач, стена буендагы үргән креслоларның берсенә килеп утырды һәм уйсыз-нисез генә ерак ярларга карап бара башлады. Бу әле утызга да җитмәгән, төскә шактый чибәр генә бер ханым иде. Өстендә аның инде тулылана башлаган гәүдәсенә ыспай ятып торган тар итәкле ачык изүле әфлисун төсендәге йон күлмәк, аягында кара «лодочка» туфлиләр, ялангач беләгендә кечкенә алтын сәгать. Куллары аның бик ак, бик нәфис, тырнакларына тип-тигез алсу кына салган, бер бармагында кечкенә бриллиант каш яна. Чем-кара шома чәченең озын толымнарын бик пөхтәләп артка өеп куйган, һәм ап-ак муенында сөйкемле генә кара миңе дә бар. Кашлары да бик нечкә итеп сызылган, сөрмәле күзләренең кара керфекләре дә берәмләп диярлек югарыга һәм түбәнгә матурлап бөгелгән, кыскасы, әнә шулай шартына бик җиткереп көязләнгән, үзе чибәр, үзе яшь, үзе нигәдер боек бу ханымга игътибар итмичә узарлык түгел иде.

...Күпмедер утыргач, ханымның тагын эче поша башлады. Бөтен әйләнәдә күңелсез бертөрлелек: су да су, ярлар ерак, җәйге матур яшеллекне якыннан күреп тә булмый. Аннары бит ул биредә ялгызы... Барысы да бар кебек — байлык та, яшьлек тә, хөрлек тә — ләкин берүзе генә ул алар белән нишләсен? Менә ул өендә дә һаман бертөрлелектән туеп, тик ятудан йөдәп беткәч, тотты да «әниемне күреп кайтыйм» дип, шушы юлга чыкты. Күңеле талпынып, бик теләп чыкты ул бу юлга. Идел өсте, ак пароход, аулак каюта, гүзәл салон — болар барысы да аның хыялын котыртып, ниндидер кызык, ниндидер онытылмас күңелле хатирә вәгъдә итәләр иде кебек.

Ләкин пароход ялгыз йөрүчеләр өчен кызыклы урын түгел ул. Менә кузгалып китүенә озак та үтмәде, безнең ханым инде үзен үги кешедәй хис итә дә башлады. Дөрес, уфтанырга бик иртә әле, алда ике тәүлеккә якын юл бар. Бу аз вакыт түгел, ике тәүлектә ни булмас!

Ханым палубада йөрүчеләрне дикъкать белән күздән кичерде. Ул, әлбәттә, танышыр өчен кеше эзләми, күңеле аның андый нәрсәдән ерак иде, хәтта берәрсе танышырга чамаласа да, ул әле уйлап карар иде. Һәрхәлдә, абруен төшермәячәк ул... Ләкин кешеләр белән кызыксынмаска мөмкинме соң? Һәркемгә дә хас бер гадәт ич бу. Шуңа күрә ханым бер ирләрне генә түгел, гомумән, һәркемне күздән кичермичә калмый иде.

Ләкин күпме генә күзәтеп утырса да, ул кызыксыну уятырлык кеше очратмады. Яшьләр юк диярлек, күбрәк парлы халык, ә сирәк-мирәк очраган ялгыз кешеләр әллә нинди шунда күңелсез, таушалган бәндәләргә охшыйлар.

Ханым утырган җиреннән торып китте, тагын палубаны бер әйләнде, икенче әйләнүендә, пароходның арткы очына җиткәч, палуба рәшәткәсенә таянып, койрыкта баручыларны күзәтергә кереште. Анда кызыграк та, күңеллерәк тә кебек иде. Кешеләре дә бүтән — авылларына кайтып баручы агайлар, җиңгиләр, студентлар. Кайберсе тимер идәнгә аягын сузып утырган да капчыгын чишеп янына гына куйган, ак булка һәм уалган хәлвәне капчык авызыннан гына алгалап, зур калай кружкадан, өрә-өрә, чәй эчеп бара. Кайберсе, аулаграк урынны сайлап, төенчеген баш астына салып, шунда йокларга җайлашкан. Әнә ике кыз койрыкның иң очына кочаклашып утырганнар да пароход артыннан ургылып калган суга карап баралар. Алар үз алларына акрын гына җырлыйлар шикелле, тик пароход шаулавыннан ишетелми генә... Ә болары кемнәр? Ишектән читтәрәк өч егет һәм бер кыз нидер сөйләшеп торалар. Уртагарак баскан, иптәшләреннән калкурак буйлы, гәүдәгә какча булса да, шактый киң җилкәле таза егетнең кулында ефәк баш яулыгы. Сүз шул яулык турында бара, ахрысы, чөнки әле берсе, әле икенчесе яулыкны тотып-тотып карый да башын селкеп куя. Ара-тирә аларның:

— Кайдан алдың моны, малай?

— Ну тапкансың бит үзең дә! — дигән кебек сүзләре дә ишетелеп калгалый.

Ә егетнең кулындагы яулык искиткеч матур иде. Нинди генә бизәк, нинди генә төс юк аңарда, нәкъ менә ачылып киткән тавис койрыгы диярсең! Егет башта, бәлкем, үзе дә бу кадәр гүзәл нәрсә алуын аңлап җиткермәгәндер, ә хәзер исә, иптәшләре исләре китеп мактагач, аның куе кара кашлы ак чыраена гаҗәпсенү катыш балаларча сөенү җәелгән иде. Сүзен дә әйтә алмый ул, бичара. Яулыгын ике кулына тоткан килеш, иптәшләренең мактавына бары баш кагып кына тора.

Егет үзе дә, аның кулындагы нәфис яулык та безнең ханымда гаять зур кызыксыну уятты. Кем ул, нинди яулык аның кулында, каян алган, кем өчен алган ул аны? Кинәт ханымның түбәндә, шул яшьләр арасында буласы килде, яулыкны тотып карыйсы, битенә куеп карыйсы килде. Нигәдер, ни сәбәптәндер аның хәтта яшь буласы, ваемсыз-шат буласы, әле берни дә үтмәгән, барысы да — мәхәббәте дә, бәхете дә — алда булачак дип ышанасы һәм әнә шул яшьләр шикелле, юк кына нәрсәдән дә куаныч табып, хыялланып, өметләнеп яшисе килеп китте. Шунда ук яннарына йөгереп төшәрдәй булды, ләкин... бу мөмкин түгел иде. Ара ерак. Ул югарыда, алар түбәндә. Әгәр шуннан юләрләнеп төшсә дә... көлкегә генә калыр иде.

Ханым тирән итеп бер сулады һәм, каядыр алып киткән хыялларыннан айнырга теләгәндәй, башын чайкап куйды. Үзе һаман, түбәндә баручы яшьләрдән күзен ала алмыйча, онытылып карап торды. Менә егет яулыкны, ак кәгазьгә иплә͏п кенә төреп, эчке кесәсенә салды, шуннан, янә бераз сөйләшеп торгач, алар барысы да эчкәре кереп киттеләр. Ханым да кузгалды... «Студентлар, ахрысы?» — дип уйлады ул эченнән. Аннары: «Нишләргә соң?» — дип тә уйлады. Каютасына ни өчендер керәсе килми иде, ялгыз палуба таптау да килешми. Таушалган пижамаларын киеп, китап тотып чыккан эчпошыргыч «командировочныйлар» ул үтеп киткән саен китаптан башларын күтәреп, аның артыннан карап калалар. Ни уйлап карыйлар өнсез, йөрәксез балыклар? Үзләре әле шулай да, зәһәр йоткан хатыннарын исләренә төшереп, эчләреннән калтыранып та куя торганнардыр. Хатыннарыннан курыккан ирләрне ул, үзе әйтмешли, терпеть не могла!

Ханым, палубаны ташлап, беренче классның салонына килеп керде. Төшке аш вакыты күптән узганга, ә кичке ашка әле бик иртә булганга күрә, салонда беркем дә юк иде. Ханым тирән эчле йомшак креслоларның берсенә утырды. Салон эче тын, бары бөтен җирендә вак кына калтырау сизелә, официантканың бер өстәлгә җыеп куйган бокал-стаканнары акрын гына зыңлыйлар, ә көн яктысыдай тоташ калын тәрәзәдән ничектер ачыкланып, якынайгандай булып күренгән яшел урманлы тау битләре акрын гына артка таба йөзәләр. «Нишләргә соң?» дип, тагын пошынып уйланды ханым. Ашыйсы-эчәсе дә килми, чөнки ире белән соңгы тапкыр кара-каршы утырып, өеннән бик әйбәт сыйланып чыккан иде. Шулай да официантка кыз салонга килеп кергәч, ул аңа бер стакан чәй белән пирожный китерергә кушты.

Менә шул бер стакан чәй белән юанып, ул зур тәрәзәдән әлеге артка таба йөзгән тау битләренә, арыш кырларына озак кына карап барды. Ләкин бу күренешләр, җансыз көзгедә чагылган шикелле, аның күңелендә берни уятмыйча, хәрәкәтсез төбәлгән күзләреннән генә кичәләр дә кичәләр. Барыбер нидер юк, нидер җитми, ә калын пыяла аша күренгән табигать үзе генә аның күңел бушлыгын тутыра алмый иде.

Нәрсә теләгәнен ул үзе дә белми, бөтен нәрсәсе бар да кебек, ә шулай да җаны тыныч түгел, җаны һаман нидер тели, нидер көтә.

Акрынлап кына кояш та җир читенә якынлашып бара, Идел өстендә алсу шәүләләр уйнаклый башлады. Биек ярларның суга яткан күләгәләре торган саен киңәя һәм караңгылана, ә кояшка каршы яктагы чиксез Идел түре, аннан да ары сөзәк кенә күтәрелгән күгелҗем кырлар өсте аеруча яктырып балкый иде. Ханым, палубаны тагын бер әйләнергә булып, салоннан чыкты.

Пароходның койрыгына җиткәч, ул нигәдер түбән карады һәм ихтыярсыздан тукталды. Түбәндә баягы таза чандыр егет ялгызы гына әрҗәләр өеменә йөзе белән борылып, әлеге тавис койрыгыдай яулыгына карап тора иде. «Бу ни хәл,— дип уйлады ханым,— әллә тилергәнме ул, шулкадәр исе киткән!» Ә егет, чынлап та, бераз гына шөребе какшый башлаган кешедәй, аны-моны сизмичә яулыгын бер җәеп карый, бер йомарлый, битенә дә куеп ала, иснәгән кебек тә итә, гүя сихерләп маташа. Аннары бик сак кына ак кәгазьгә төреп, эчке кесәсенә салып куя.

Бу күренеш ханымда шундый бер сабырсыз кызыксыну уятты ки, аның ничек кенә булса да егет белән танышасы һәм яулыкның серен беләсе килде. Ә кичкырын түбәндә баручы кыз, егетләрнең берсен ияртеп, палубага менде. Алар сагаеп кына бер әйләнделәр дә, пароходның алгы очына туктап, Идел өстенә карап бара башладылар. Ханым алар яныннан бер-ике тапкыр сүзләренә колак салып үтеп китте. «Әйе, болар студентлар булырга тиеш». Кечерәк кенә буйлы җыйнак кыз беренче кышын гына шәһәрдә үткәргән, ахрысы, район кыяфәте үзеннән китеп тә бетмәгән әле; көл төслерәк чәчләрен уртадан ачып, калын толымнар итеп үреп салган, өстенә кызыл бөрчекле ак ситсы күлмәк киеп, билен тар гына каеш белән буган, ә аягында арзанлы оек белән үкчәсез кара туфли... Егет исә шәһәрчәрәк: өстендә аның эре шакмаклы «молния» каптырмалы күлмәк, балаклары бөрмәле күк шаровар, аягында «тапочка» дип йөртелгән резин чүәк — базык, тыгыз гәүдәсенә караганда, ул берәр институтның спортчысы булса кирәк.

Ханым алардан аз гына читкәрәк килеп туктады да, кирәк кадәр тынып торгач, гади-мөлаем булырга тырышып, яшьләргә дәште:

— Иркәләрем, кая кайтып барасыз?

Яшьләр җәһәт кенә аңа борылып карадылар; кызның, борыны кечкенә булганга күрәме, соры күзләре бу минутта аеруча зур да, якты-матур да иде. Шәп киенгән чибәр, көяз ханымны күргәч, ул бераз гаҗәпсенебрәк, теләр-теләмәс кенә.

— Төрлебез төрле җиргә,— диде.

Аның болай кырын торып, салкын гына җавап кайтаруына ханымның артык исе китмәде: хатын-кыз башта бер-берсенә шулайрак була инде, нишлисең! Мөлаем ягымлылыгын саклап, ханым сораша бирде:

— Шулаймыни? Бик әйбәт. Сез студентларсыздыр инде?

— Әйе, студентлар.

— Шулайдыр дип уйлаган идем. Танып була бит. Кайчан гына әле мин үзем дә студентка идем.

Яшьләр һич тартынусыз ханымга тагын бер сынаулы караш ташладылар. Ханымның үзен менә шулай гади-якын итеп тота белүеме, әллә соңгы сүзен әйткәндә ничектер сагышлы күренеп куюымы — нидер яшьләрнең салкын торып маташуларын бик тиз эретә башлады. Озак та үтмәде, телләре дә чишелде һәм сөйләшеп тә киттеләр.

Башлап үзләре үк ханымның исемен дә сорап белделәр. Ханым аз гына көттереп, гүя чын исемен әйтергә икеләнгәндәй җавап бирде:

— Мин... Диләрә.

Аннары ул үзе сораша башлады. Яшьләр, билгеле, икеләнеп тә, яшереп тә тормадылар — аларныкы уч төбендә!

Тиз арада ханым һәркайсының исемен белде, кайда укуларын, кая кайтуларын белде, тик бер генә төер аның күңелен һаман борчып торды. Ул теге яулык хуҗасы чандыр егет тә менмәсме икән дип көтте, әмма егет менмәде. Бер-ике тапкыр ханым җай чыгарып аның хакында сорашырга да теләп карады, әмма булдыра алмады. Бары аерылышканда яшьләргә:

— Сезнең белән танышу бик әйбәт булды әле. Иртәгә дә менегез, бергә-бергә кайту күңелле ич! — дип калды.

Яшьләр:

— Рәхмәт, апа, килербез,— дип, түбән төшеп киттеләр. Ханым, ялгыз калгач та, каютасына керергә ашыкмады. Палуба баганасына сөялеп, битен кичке саф җилгә куеп барды. Төн, тынлык, елга өсте кап-кара, аз гына чи балык исен аңкытып, түбәннән дым килә. Ярлар күренми, каршы очраган пароход та, вак утларын ерактан гына җемелдәтеп, тавыш-тынсыз уза...

...Менә түбәндә ничәдер тапкыр җиз кыңгырауга суктылар — һәр сугудан, гүя ике кат тавыш чыгарып, сәер генә яңгырады ул... Диләрә ханым иренеп кенә урыныннан кузгалып китте, каютасына керде, ашыкмыйча гына урынын рәтләп, чишенә башлады. Аяк йөзеннән үк яткан төнге ефәк күлмәген киеп, көзге каршына баскач, ничектер уйга китеп, тулы-тыгыз күкрәкләрен акрын гына сыйпап торды. Әйе, ул яшь, ул таза, ул чибәр әле! Ләкин... нигә соң болай йөрәген савып, эче поша икән аның? Ни җитми, ни кирәк? Тагын әлеге ак чырайлы чандыр егет аның исенә төште. Кем ул, ни өчен ул да, кешедән яшерен

сере бар шикелле, иптәшләреннән үзен читтәрәк тота, йөрми, күренми? Тагын эчке кесәсендә генә саклап йөрткән яулыгы... нигә ул аңа бик кадерле?

...Кинәт ханымда шул яулыкны егет кулыннан ничек тә тартып аласы килү теләге туды. Яулыгын алырга, яулыгы белән бергә серен алырга!

Һа, ул моны булдыра алмасмыни? Нинди егетнең әле яшь чибәр хатын сихереннән котыла алганы бар? Теләү генә кирәк, теләү генә — иблисең дә тез чүгәр!

## II

Иртәнчәк Диләрә ханым палубада кемнәрнеңдер кычкырып сөйләшкән-көлешкән тавышларыннан уянып китте. Тәрәзәгә тарткан кыек рәшәткәнең ярыкларыннан кергән яктылыкка караганда, вакыт шактый булырга тиеш иде инде. Ханым, урын өстендә бераз киерелеп-сузылып ятканнан соң, кинәт нидер исенә төшкәндәй, ашыгып урыныннан торды. Тиз генә чуар халатын киеп, тәрәзәнең рәшәткәсен шылдырып җибәрде. Илаһи, көне дә көне! Үзе тын, үзе нурлы, үзе җылы, әйтерсең балачакта күргән бәйрәм иртәсе! Су өсте тип-тигез, яланаяк йөгер дә кит! Пароход та аның өстеннән гүя шуып кына бара. Кояш та әле яңа күтәрелеп килә икән — җылына башлаган елга урыны-урыны белән сөттәй ак пар көйрәтеп ята. Ярлар да биредә якын икән — әнә көтүләре белән кузгалган карлыгачлар канат какмыйча гына, кыеклап-кыеклап, бер югары менеп китәләр, бер түбән атылып төшәләр. Юк, мондый иртәне, мондый нурлы иртәне, йоклап, күрмичә калырга ярыймы соң!

Диләрә ханым тиз генә юынды да, яңадан рәшәткәне тартып, киенә башлады. Бүгенге иртәнең үзенә охшарга теләп, иң матур, иң килешле алсу күлмәген киде, энҗе муенсасын такты, күзләренә оста гына итеп сөрмә тартты, шуңардан, ахры, керфекләре дә аска һәм югарыга таба матур гына бөгелгән кебек булдылар. Бизәнеп беткәч, чәченә, түшенә «Ак сирень» хушбуен бөркеде, шуннан соң, рәхәт бер җиңеллек хис итеп, палубага чыкты.

Палубада куанычлы бер җанлылык иде. Бар да торып чыкканнар, бар да иртәнге елга өстен һәрьяклап күрергә теләгәндәй, төркем-төркем кучеп йөриләр, кулларын сузып, бер-берсенә нидер төртеп күрсәтәләр, һич юктан да шатланып көлешәләр. Диләрә ханым да чыгу белән сөттәй ак пар шуышып йөргән елга өстенә, нурлы пәрдәгә төренгән тау битләренә бермәл сихерләнгәндәй карап торды. Бу кадәр дә матур, сөйкемле булыр икән! Әйтерсең менә бөтен дөньясы назланып, елмаеп алдында ята синең! Әгәр Диләрә ханымның канатлары булса, шуларны җәеп, пароходтан төшәр иде дә, аякларын суга тидерер-тидермәс кенә атлап, тын, якты тауларга таба китәр иде. Күргәннәр: «Бу нинди фәрештә, кайдан гына иңде әле ул!» — дип, тик хәйран булып калсыннар иде.

Шулай сихерләнеп, хыялга бирелеп, күпмедер торганнан соң, ул акрын гына кузгалып китте. Пароходның арткы очына җиткәч, тукталып, ихтыярсыздан түбәнгә караса, әлеге таныш яшьләрнең койрыкта, тимер идәнгә газеталардан табын җәеп, күңелле генә ашап-эчеп утыруларын күрде. Аның йөрәге кинәт урыныннан купкандай булды, җанын әллә нинди бер түземсез талпыну биләп алды. Бик якын идеме алар аңа, әллә мондый иртәдә үзенең ялгызлыгы белән һич килешә алмаганга күрәме, әмма ничек кенә булмасын, аның чын ихластан тизрәк шулар янында буласы килде, һәм, бер дә уйланып-икеләнеп тормыйча, ул ашыгып түбәнгә төшеп китте.

Яшьләр аны якты каршы алдылар. Дөрес, ханымның бик шәп киенгән булуы, бигрәк тә «югарыдан» төшүе аларны беркадәр ятсынырга мәҗбүр итә иде. Ханым үзе дә моны сизмичә калмады, ләкин игътибар итмәскә тырышты.

Яшьләр бераз каушабрак аңа табын янына утырырга тәкъдим иттеләр. Ханым, чүгәләп, күлмәк итәген кайтара төште дә, чистарак урынны чамалап, җылы тимер идәнгә утырды. «Табын»да газетка турап салган ак икмәк, арзанлы колбаса, йомырка, яшел суган, шырпы тартмасында тоз — нәкъ менә безнең кадерле кунак өчен генә әзерләнгән сый!.. «Табын»ның хуҗасы — әлеге чәчләрен уртадан ачып тараган бала чырайлы кыз икән. Ханымны да башлап ул кыстарга кереште:

— Апа, рәхим итегез! Безнең табын студентларча, такы-токы гына инде, гаеп итмәссез!

Ханым ничек тә гади, үз булырга тырышып:

— Сөйләмә, иркәм! — диде.— Бик әйбәт, тагын ни кирәк?

Һәм бер йомырканы алып, идәнгә бәреп ватты да әрчергә тотынды.

Егетләрнең берсе аның алдына колбаса телемнәрен этәрә төште:

— Менә моны да алып карагыз, әгәр яратсагыз... «Халыклар дуслыгы» дибез без аны, ите — атныкы, мае —дуңгызныкы...

Яшьләр көлештеләр, ә ханым комачтай кызарды, шулай да сынатырга теләмәде.

— Беләм, беләм! — дигән булды.— Ашаганым бар, әйбәт була ул ат казылыгы...

Һәм бер-ике түгәрәкне батыр гына ашап та җибәрде. Алай авызга алмаслык нәрсә түгел икән. Тик кызыл ит арасында сирәк-мирәк очраган бармак башыдай дуңгыз мае гына чәйнәр өчен авыр икән. Ярый инде! Менә артыннан яшел суган капкач, берни булмас, үтәр әле.

Ә шулай да бик күңелле! Пароход, тип-тигез су өстен ертып, тонык кына шаулап бара, йомры-якты дулкыннар ике якка салмак кына куышып китәләр. Җылы, рәхәт. Егетләр, әвен сугучылар шикелле, бик тәмләп, авыз тутырып ашыйлар. (Диләрә ханым исәбенчә, боларның ашказаннары ташыңны да сеңдерер!) Тик яулык иясе егет кенә ашауга артык исе китмәгәндәй күренә. Ул аякларын идәнгә сузып, табынга кырын утырган, ашыкмыйча гына чәйни һәм күбрәк читкә, су өстенә карап бара. Ханымга ара-тирә генә күз ташлап куйгаласа да, артык кызыксыну да, ятсыну да күрсәтмичә, ничектер битараф кала бирде. Шулай да бер мәртәбә, ханым нидер әйткәч, ул зур кара күзләрен тутырып, үтә сынау белән аңа карап алды. Әллә нишләтеп җибәрде бу караш Диләрә ханымны, әмма ул аны батыр күтәрде, хәтта горур гына башын да чөеп куйды. Тынычлыгын саклап, ул берни булмагандай сөйләнә бирде:

— Урыныгыз да ямьле, ашыгыз да тәмле, ярый төштем әле яныгызга.

— Ә югарыда... нигә, начармыни? — диде кичә танышкан шакмак күлмәкле егет...

— Югарыда... сезнең кебек күңелле компания юк.

— Нишләп булмасын! Әнә анда нинди шәп абзыйлар баралар.

— Абзыйлар шул. Ә миңа үз тиңнәрем кирәк.

— Ә-ә, алай икән!

Егетләргә күңелле булып китте, ахрысы, дәртләнеп, баш кагып елмаештылар. Юк, бу ханым, нинди генә асыл кош булмасын, «түбәндәгеләр» компаниясенә алырлык икән. Үзен әнә ничек иркен, кыю, гади тота ул!

Ләкин табынчы кыз, сокланырга ашыкмыйча, күбрәк белергә теләп, җитди генә сорап куйды:

— Кем буласыз соң сез, апа?

Диләрә ханым кинәт сагаеп калды.

— Ничек инде ул... кем буласыз?

— Кайда, нинди эштә эшлисез дип соравым,— диде кыз, бераз уңайсызланып.— Сез тагын ачулана күрмәгез, апа!

— Юк, нишләп ачуланыйм,— диде ханым, елмаерга тырышып, әмма кыз аның иң авырткан җиренә кагылды. Мондый сораудан ул һәрвакыт курка торган иде. Ни дип кенә җавап бирергә соң? «Институтны бетерер-бетермәс зур кешегә иргә чыктым да шуннан өйдә утырып калдым»,— дип әйтә алмый бит инде ул. Ләкин берни сиздермәгән кыяфәт белән тизрәк җавап бирергә ашыкты:

— Мин финансово-экономическийны бетергән идем. Мин — финансист! Менә шулай!

— Һо, финансист! — диде егетләрнең берсе, күзләрен зурайтып.— Алайса сез бик байсыздыр?

Ханым кызарды, шулай да югалып калмыйча, шаяруга каршы шаяртып әйтте:

— Гаҗәп инде, нәкъ менә Драйзерның финансисты кебек...

Кырын утырган егет тагын бер карап куйды, бу юлы шактый кызыксынгандай итеп, һәм ханым үзе өчен өметле булган бу карашны бик тиз тотып алды. Ул шунда ук сүзне яшьләрнең үзләренә күчерде:

— Ә шулай да студент вакытка ни җитә. Бөтенесе алда: матур хыяллар, зур планнар... Әгәр мөмкин булса, яңадан сезнең хәлгә кайтыр идем. Нинди рәхәт ич! Бергә уку, бергә кайту, бергә ял итү.

— Ә безнең тизрәк бетерәсебез килә,— диде шакмак күлмәкле егет.— Укуы бер дә рәхәт түгел, бигрәк тә финанс ягы такыр булган чакта... Аннары, сез әйткәнчә, бергәләп ял итүләр дә бик тәтеми хәзер. Менә бер айга гына җибәрделәр, кайтып, әни карчыкларга утын, печән әзерлибез дә, аннан, давай, кире шәһәргә!

— Ни өчен шәһәргә?

— Целинага китәр өчен... Беләсезме, нәрсә ул целина? Һо, целина, апа җаным, бик интересный җир ул! Менә кайда кәҗә майларың чыга.

— Быел Фәнияне дә үзебез белән алып барабыз,— диде егетләрнең икенчесе, табынчы кызга җылы көлемсерәп.—Курыкмыйсыңмы, Фәния?

— Исем китә! — диде Фәния, эре генә.— Куркып торырга, сездән кай җирем ким минем?

Ул табында калган азыкларны әйбәтләп төреп җыештырырга керешә, егетләр «Прибой»ны кабызып җибәрделәр. Диләрә ханым кемнәрнеңдер югары палубадан аңа сәерсенеп карап баруларын күптән шәйләп алган иде. Шулардан уңайсызланып булса кирәк, үзенчә сылтау табып, җәһәт кенә урыныннан торды.

— Карагызчы, бу акчарлакларны әйтәм, бер дә пароходтан калмыйлар бит! Нигә икән?

Егетләр дә урыннарыннан тордылар. Кыз газеттагы сынык-санықларны илтеп, су өстенә селекте:

— Менә шулар өчен иярәләр инде алар! Әнә, әнә күрдегезме, икмәк кисәкләрен ничек кенә эләктереп алдылар! Ә шакмак күлмәкле егет, папиросын тирән суырып:

— Их, акчарлак шикелле менә шулай җелт иттереп кенә берәр җәенне сыртыннан эләктереп алсаң иде! —диде.— Ярап куяр иде ул безгә обедка!

Икенчесе яулык иясе егетнең аркасына сугып алды:

— Эләктерсә, Харис эләктерә инде аны, безнең иң шәп йөзүчебез!

Харис моңа каршы бер сүз дә әйтмәде, тик аның уйчан ак чыраенда ниндидер сызлану аша боек көлемсерәү чагылып киткәндәй булды. Ә кыз шунда ук егетләргә, дәү апаларыдай, җитди генә әйтеп куйды:

— Тимәгез сез аңа! Белмисезмени, җәен кайгысы түгел, җан кайгысы ич аңарда.

— Җанаш кайгысы диген, дөресрәк булыр.

— Җанаш кайгысы — җан кайгысы инде ул! — диде шакмак күлмәклесе, авыр көрсенгән булып.

Барысы да, иптәшләренең хәтерен калдырмаска тырышкандай, аңа карап, тыелып кына көлешеп алдылар. Харис һаман шулай уйчан, тыныч калды, ә Диләрә ханым исә, күзләрен елтыратып, егеткә тәмам йотылып карап торды. Шаярып кына әйтелгән бу сүзләр, егетнең килешкәндәй дәшмичә калуы аңа бик хикмәтле булып тоелды.

Бераздан ул, яшьләрне югарыга чакырып, палубага менеп китте... Харис, Харис! Бу исем һаман аның телендә әйләнде, «җанаш кайгысы» дигән сүзләр һич күңеленнән чыкмады. Шунда ул егет куенындагы әлеге матур яулыкны да исенә төшерде. Яңа гына ишеткән сүзләр белән бу яулык арасында тәгаен бер бәйләнеш барлыгын да ул сизмичә калмады. Көнчелеккә охшаш бер хис кузгалып куйды аның йөрәгендә, һәм егетнең үзен дә, аның серен дә тизрәк беләсе килү аны чын-чынлап котырта башлады.

Хәзер инде ул хөрмәтле Харис иптәшне тынычлыкта калдырмаячак! Үпкәләштән булмасын, үзе гаепле. Аңа, роза чәчәгедәй ханымга, ниндидер студент кисәге шулкадәр кырын, салкын торсын, имеш! Гаҗәп бит! Кайчан әле мондый хәлнең булганы бар? Бүтәннәр аның кулын бер үбәр өчен генә дә түшләре белән җирдән шуарлар иде. Ә ул?.. Ниндидер яшерен сергә төренеп, үзен чуен статуя шикелле тотып маташа. Мәхәббәт трагедиясе кичерә, янәсе! Туктале, менә без, җан кисәгем, синең өчен дә яраклы ачкычны таба белербез!

Ул яшьләрнең югарыга менүләрен көтеп йөри башлады. Алар, әлбәттә, менәчәкләр, тик менә Харис менәрме? Бу шик аңа бер дә тынгылык бирми иде. Әгәр барысы да менсәләр, ул аларны үзенең каютасына кунакка чакырырга булды. Аның әле башланмаган тавыгы бар, вак бәлешләре, паштеты, печеньесы, кыйммәтле конфетлары бар — сые җитәрлек. Шулар янына берәр шешә яхшы вино алганда ничек булыр икән — менә шул хакта гына ул бераз уйланды. Ахырда, теге целинага барудан да курыкмый торган, егетләргә карата үзен хуҗа сыман тоткан ябык кыздан ничектер яхшысынмыйча, вино алу ниятеннән кайтты. Шул кыз булмаса, ике дә уйлап тормас иде ул, әлбәттә.

Күпмедер вакыт узганнан соң, яшьләр палубага менделәр. Харис та алар белән бергә иде... Диләрә ханым палубага чыга торган ишектән уң якта, беркадәр читтәрәк утырып тора иде. Яшьләр ишектән сулга таба борылып киттеләр. Бу хәл ханымга бик начар тәэсир итте, хурланудан ачуы килеп, торырга омтылган җиреннән кузгалмыйча, утырып калды. «Үзләренә күрә түгел, йолкышлар!» — диде ул, эченнән усалланып. Ләкин бераздан яшьләр палубаның икенче очыннан килеп чыгып, аңа якынлашкач, ханым каршыларына торып басты. Үзен көчләп булса да, елмаерга мәҗбүр итеп:

— Менә тагын очраштык! — диде.

— Бик әйбәт, бик әйбәт! — диештеләр егетләр.

Әлбәттә, бу яшьләрдә Диләрә ханымны ачыктан-ачык ят күрү яки өнәмәү дигән нәрсә һич юк иде. Бигрәк тә бер табынга утырып ашап-эчкәннән соң, алар аңа инде ияләшеп тә өлгергәннәр иде. Тик әле шомарып җитмәгәннәр, ханымнарга, аеруча Диләрә кебек ханымнарга, бик игътибарлы булырга кирәклеген белеп бетермиләр — һаман шул «культура» җитмәү бәласе инде.

...Сөйләшә-көлешә палуба буйлап киттеләр, ләкин алар тар юлга барысы да сыя алмыйлар иде. Кыз белән Харис арттарак калдылар. Палубаның арткы очына җиткәч, Диләрә ханым тукталды һәм, нечкә тимер терәүгә тотынып, күкрәген киереп бераз тынып торды.

— Яратам менә шулай пароходтан ярылып калган эзгә карап барырга! — диде ул, очарга торган кош сыман күзләрен алга текәп.

— Ә сикерәсегез килмиме шунда, бөтерелеп аккан суның нәкъ уртасына? — диде егетләрнең берсе.

— Килә! — диде ханым, башын кисәк кенә артка чөеп.— Кайдан сизеп әйттегез әле моны?

Харис та, килеп, бер читкәрәк туктаган иде. Аның һаман да сүзгә катнашмыйча салкын-җитди генә басып торуы безнең ханымны ничектер тагы да кыюландыра төште. Ул торган саен җанланыбрак сөйләде, гадәттәгедән кычкырыбрак көлде һәм һәр әйткән сүзеннән соң егеткә туп-туры карап куя торган булды.

Аннары тагын палуба буйлап киттеләр. Харис белән кыз тагын арттарак калдылар. Бер әйләнгәч тә, Диләрә ханым, эчкәре уза торган ишек каршында туктап, кинәт кенә:

— Әйдәгез, минем каютага кереп утырабыз! — диде.

Кыз аптырап калды:

— Нигә, апа?

— Ә минем сезне кунак итәсем килә,— диде ханым, бик гади генә итеп.

Яшьләр, сәерсенеп, бер-берсенә карашып алдылар, әллә ничек кенә булып тоелды бу чакыру аларга.

— Мин сезнең яныгызга төшеп сыйландым бит,— диде ханым.— Инде минем чират, мин сыйлыйм. Әллә кермәс идегезме?

Һәм яшьләр риза булдылар. Дөресен әйткәндә, студент халкы сыйлаганны ярата ул, тик сыйлаучы гына булсын.

Харис та аерылып калмады, һәм ханымның рухы бердән күтәрелеп китте.

Бер генә кешелек каюта тыгыз иде, шулай да сыйдылар. Ханым кунакларын койкага тезеп утыртты. Рәшәткәне шылдырып куйдылар. Яктырып киткән каюта эчен егетләр бик сокланып карадылар; аларның кайберләре мондый рәхәт, чибәр урынны беренче тапкыр күрәләр иде әле.

Ханым үзе, урындыкка утырып, зур гына сумкасын алдына алып, шуннан бөтен сыен өстәлгә чыгарып салды. Тавыкны да оста гына ботарлап куйды, аннары егетләрне чын ихластан кыстарга тотынды.

— Ягез әле, иркәләрем, җитешегез! Менә тавыктан, менә бәлешләрдән... Ягез, йә!

Хәер, егетләр кат-кат әйттереп тормадылар, бер дә тартынмыйча гына ханымның сыйларын «ура» башладылар. Тик Харис кына баштарак тыелып утырды, чөнки ханым аңардан бер дә күзләрен алмый иде. Аннан инде ул да: «Син мине ашасаң, мин бәлешеңне ашыйм әле»,—дигәндәй, иптәшләреннән калышмыйча, ләкин алар шикелле бик кызуламыйча капкаларга тотынды. Иптәшләре, бу сыйлау өчен мактау кирәктер инде дигән төсле, капкан саен берәр сүз әйтмичә калмадылар:

— Ну бәлешләрегез, апа! Үзегез пешердегезме?

Диләрә ханым исә, бик хуш булып, раслап кына утыра:

— Үзем, әлбәттә!

— Тавыкны да үзегез куыргансыздыр инде?

— Үзем булмыйча!

— Ә менә бу нәмәстәкәйне? — диде егетләрнең берсе, зур гына паштет кисәген урталай тешләп.

— Анысын да үзем пешердем.

— Их, минем дә булачак хатыным шушындый ашлар пешерә белсә иде!

— Пешерә белгәнгә өйләнерсез.

— Алмас борын белеп буламыни аны!

— Ә син, алырдан элек, өенә йөреп бәлешләрен ашап кара! — диде егетләрнең икенчесе.— Мин үзем шулай итәчәкмен.

Көлештеләр. Ләкин авызлары тик тормады, сумса, бәлешләрдән валчыклар гына торып калды, тавыкны да ялт иттерделәр. Ханымга аларның берсе дә кызганыч түгел, тик күңелендә яткан теләге генә булмыйча калмасын иде. Ә теләге аның шул һич сүзгә катнашмыйча утырган, бары ялкау гына елмаеп куйгалаган Хариста... Шул ак чырайлы, куе кара кашлы Харисның телен чишәсе килә, шул горур-салкын егетне ничектер менә котыртасы, үзенә каратасы, һич булмаса, үзе белән хисаплашырга мәҗбүр итәсе килә. Һәм менә, һәрбер оригиналь уй кинәт туган шикелле, аның башында әллә каян гына килеп гаҗәеп бер мәкерле хәйлә туды. Үзе кимереп куйган ядәч сөяген алып, ул егетләргә шаян гына:

— Әйдәгез, кем белән ядәч аерышабыз? — диде.

Шакмак күлмәкле егет шунда ук кулын сузды:

— Минем белән.

Ләкин ханымның күзе Хариста иде. Ул кулын сузучыга карамыйча, назлы гына итеп:

— Ә минем менә... Харис иптәш белән аерышасым килә,— диде.

Харис аз гына кызарынып елмайды, нидер әйтмәкче булды, ләкин иңбашын гына җыерып куйды. Иптәшләре аны кыстарга тотындылар:

— Йә, Харис, бәхетеңне сына. Курыкма, курыкма! Оттырсаң, үзебез түләшербез.

Ханым инде ядәчен аңа сузып ук тора иде. Харис шикләнебрәк ханымга карады.

— Ягез,— диде ханым, кыю гына.

— Нәрсәдән соң? — диде Харис, ашыкмыйча гына кулын сузып; аның тавышы да күр, матур иде.

— Нәрсәдәнме?..— Ханым аз гына уйланып торган булды.— Юк, баштан билгеләмибез. Американча булсын!

— Анысы тагын ничек була?

— Ә менә ничек: сез отсагыз — миннән теләгән нәрсәгезне сорыйсыз, мин отсам — үзем теләгән әйберне сорыйм.

Егет кулын кире алды.

— Юк, булмый!

Ханым, күзләрен кыса төшеп, егеткә төбәлде:

— Куркасызмыни?

— Юк, курыкмыйм... Ләкин ни өчен американча?

— Ягез, йә,— диде ханым, елмаеп.— Мин бит студент кешенең хәлен беләм, әллә ни сорамам.

— Әйдә, рискуй,— диделәр иптәшләре дә.— Синең ни... кашың да күзең... нәрсәңне алсын ул?

Һәм алар ядәчне аердылар — егет кулында зуррак чаты, ханым кулында кечкенә чаты калды. Ни өчендер егетләр ханым отарга тырышмас, киресенчә, үзе юри оттырыр дип уйладылар. Әйе, ханым отарга ашыкмады, ләкин егет берәр әйбер сузган саен, ул, сөйкемле елмаеп кына: «Исемдә!» — дип әйтергә дә онытмады. Аннары Харис та ханымга еш дәшүдән тыела башлады, чөнки сөйкемле елмайган ханым, әледән-әле тынгысыз күзләрен кечерәйтеп, ничектер аның эченә үтеп керергә теләгәндәй карый, һәм бу хәл егетне ихтыярсыздан шомланып куярга мәҗбүр итә иде.

Алар бөтен төркемнәре белән тагын палубага йөрергә чыктылар. Бүтәннәр барысы да алдан китте, Харис гадәтенчә арткарак калды, ә ханым иң арттан иярде. Пароход борынына җиткәч, ул җилдән тузгый башлаган чәчен рәтләргә теләп, кырын баскан килеш, кулындагы ридикюлен егеткә сузды.

— Тотып кына торыгыз әле! — диде ул, чәче белән мавыгып.

Егетнең һични уйламыйча алуы булды, ханым кинәт кычкырып та җибәрде:

— Ядәч!

Барысы да аларга борылып карадылар. Харис тәмам аптырап калган бер кыяфәттә кечкенә ридикюль тотып тора, а ханым бөгелә-сыгыла рәхәтләнеп көлә иде.

— Их син... дус кеше! Тәки оттырдың, ә? — диде егетләрнең берсе, ачынып.

— Үзебез гаепле,— диде икенчесе,— саклый белмәдек. Уйлары аның ядәчтәмени!

— Ярар, телегезгә күп салынмагыз! — диде Харис, кырыс кына, һәм ханымга ридикюлен кире бирде: — Йә, ни сорыйсыз?

— Тукта, ул хәтле ашыкмагыз! — диде ханым, ничектер берьюлы тынычланып.— Иң элек менә шушында утырыйк.

Башлап ул үзе ак эскәмиягә утырды, аннары Харисны да кыстап үз янына утыртты. Шуннан соң гына ул, ни таләп итсә дә хакы бар кешедәй, ашыкмыйча иплəп кенә егеткә әйтте:

— Кичә сезнең кулыгызда бер яулык күрдем. Менә шуны сорыйм мин!

Егет кашларын җыерды.

— Юк, мин аны сезгә бирмим.

— Ә миңа бары шул кирәк.

— Булмый. Бирә алмыйм. Бүтән нәрсә сорагыз.

Ханым, тынып, җитди сынау белән егеткә беравык карап торды.

— Хәтерләгез әле, без ничек килештек? Әгәр сез отсагыз, мин сездән бернәрсәмне дә кызганмаган булыр идем...— Ул сүзен әйтеп бетермәде.

Харисның ак чыраена кызыл таплар бәреп чыкты; дәшмәде ул, тик иреннәрен нык кысудан яңак сөякләрен уйнаткалап куйды. Шул чакта Фәния ашыгып һәм борчылып әйтте:

— Апа, сез аңардан ул яулыкны сорамагыз инде.

Диләрә ханым, аңа күтәрелеп тә карамыйча, үтергеч бер салкын «әдәплелек» белән:

— Иркәм, сезнең өчен алынган яулык түгелдер ич ул, нигә тыгыласыз? — диде.

Кыз кайтарып җавап бирә алмады. Ул әле болай, гүя үтеп барышлый гына, кешенең бәгыренә кадап китүне күргәне юк иде. Ханым исә, берни булмагандай, шунда ук егетләргә сүз катты:

— Әйтегез инде менә сез, аның дуслары, егет кеше сүзендә торырга тиешме, түгелме?

Егетләр, җилкәләрен җыерып, икеләнеп кенә:

— Конечно, шулай инде ул,— диештеләр.— Сүздә тору кирәктер инде... Ну бит...

Ләкин ханым, артыгын тыңламыйча, тизрәк Хариска борылды:

— Ишеттегезме, Харис иптәш, дусларыгыз ни диләр? Чыгарыгыз яулыкны!

— Мин сезгә яулык вәгъдә итмәдем,— диде Харис, тәмам караңгыланып.

— Сез мин сораган әйберне бирергә булдыгыз!

— Сорагыз бүтән нәрсә.

Ханымның күзләре кысылды, усал карашы энәләр шикелле егеткә кадалды.

— Их сез! — диде ул, акрын гына.— Мин сезне чын егет дип торам, ә сез...— Ул, сүзен әйтеп бетермичә, җирәнгәндәй борынын җыерып, кулын гына селтәде.

Бу мәсхәрәләп кул селтәү иң авыр сүздән дә әшәкерәк тәэсир итте егеткә. Ул ихтыярсыздан артка тайпылып куйды, кинәт үтә бер гарьләнү белән: «Ни өчен әле мин үземне шушы курчактан бу кадәр хурлатып торам?» —дип уйлап алды һәм шул секундта ук эчке кесәсеннән ак кәгазьгә төргән яулыкны чыгарды да ханымның алдына ташлады:

— Мәгез!

Ханым егетнең бу бер генә сүзгә никадәр ачу-нәфрәт салып әйткәнлеген ачык сизде, әлбәттә, ләкин юри, гүя ныграк үртәргә теләгәндәй, балаларча кычкырып куйды:

— Менә молодец!

Һәм яулыкны, кәгазеннән алып, сүтеп тә җибәрде. Яулык, нәкъ тавис койрыгыдай әллә ничә төрле төсләр уйнатып, аның кулында җилферди иде.

— Нинди матур! Нинди матур, Ходаем! — дия иде ханым, гадәттән тыш сокланып.— Килешәме миңа?

Ул яулыкны башына каплады, һәм чибәр яулык чынлап та аны бердән нурландырып җибәргәндәй итте. Барысы да бу минутта ханымның чәчләре өстендә йомшак кына яткан яулыкка аптырау-кызгану катыш чын соклану белән карап торалар иде. Харис, кире тартып алудан тыелып калуына ышанмыйча, ахрысы, кисәк кенә торды да кызу-кызу атлап китеп тә барды.

— Нигә качасыз? — дип кычкырды ханым аның артыннан һәм тилерергә җитешеп көләргә тотынды.

Әллә ни булды аңа. Яулыкны әле башына каплады, әле муенына чолгады, әле иңенә салды. Кулында болгап йөртте. Үзе көлде, очынды, тилерде... Ә бераздан япа-ялгыз калуын күрде: Харисның иптәшләре дә, үзлекләреннән юкка чыккандай, каядыр китеп беткәннәр иде.

Ханым кинәт аңлады: ул яшьләрне үзеннән качырган икән ләбаса! Тынып, аптырап калды ул, ничектер берьюлы шиңде дә төште. Бераз каранып торганнан соң, яулыкны бер почмагыннан тотып, әле генә бергә уйнаган тиңдәшләрен югалткан баладай, нәүмизләнеп, елыйсы килеп, палубаны акрын гына әйләнеп чыкты. Аннары, каютасына кереп, хәлсезләнеп, урынына утырды. Уйга калды... Менә ничек икән ул! Ят кеше икән ул аларга! Тиң күрмиләр икән алар аны! Ташладылар да киттеләр... Ни өчен? Шушы яулыкны ирексезләп алган өченме? Шаярды гына бит ул, шаярды гына! Кайтарып бирәчәк бит ул аны!

Диләрә ханым, кинәт урын өстенә капланып, тавышсыз гына калтыранып еларга тотынды... Аңа шаярырга да ярамый икән хәзер. Ул яшьлеген, ваемсыз, хөр яшьлеген югалткан икән инде!.. Нишләргә тиеш соң ул? Үзеннән егерме дүрт яшькә олы кешенең хатыны булгач, абыстай шикелле бөтенесеннән качарга, берәү белән дә уйнамаска-көлмәскә тиешмени инде ул? Нигә мондый вафасызлык? Нигә бу яшьләр шулкадәр каты йөрәкле, бер дә кешенең хәленә керә белмиләр?

...Көнчелектән бу, көнчелектән! Алар аны үзләреннән рәхәтрәк яшәгән өчен яратмыйлар. Әйе, чибәр, таза булуы өчен, яхшы, матур киенүе өчен, ялгызы аерым каютада иркенләп баруы өчен ят күрәләр. Ә күңелендә аның нинди бушлык, ни җитми аңа — бу хакта белергә дә теләмиләр.

Шулай рәнҗеп, елап ята торгач, ул, ниһаять, изрәп йокыга талгандай булды.

Күпмедер вакыттан соң, берәү сак кына аның ишеген какты. Ханым сискәнеп башын күтәрде, өстәлдәге көзгесенә карап, тиз генә күзләрен сөртте, чәчен рәтләде. «Улмы икән әллә?» дигән уй яшендәй күңеленнән узды һәм ниндидер бер өмет чаткысы йөрәгендә яңадан кабынгандай булды. Ашыгып, шактый дулкынланып ул:

— Керегез! — диде.

Ишек ачылды һәм Харисның иптәшләреннән әлеге шакмаклы күлмәк кигән егет килеп керде.

— Апа, борчыган өчен ачуланмагыз, мин бер йомыш белән генә,— диде ул, ишек төбендә тукталып.

— Узыгыз! — диде ханым, өмете сүнсә дә, ачык чырай күрсәтергә тырышып.

Егет эчкәрәк узып урындыкка утырды һәм, сүзен нидән башларга белмәгәндәй, бераз тезләрен угалап торды. Ханым үзе башлап сорады:

— Йә, ни йомыш соң?

— Әлеге шул яулык турында инде,— диде егет, сер әйткәндәй тавышын акрынайтып.— Сез аны шулай да кире бирсәгез иде.

— Иптәшегез сезне үзе җибәрдеме?

— Юк, ул җибәрмәде. Без, үзара гына сөйләшеп, сездән сорарга булдык. Беләсезме, Харис бит ул яулыкны берәүгә бүләк итеп алып кайта иде. Сездән яшереп тору кирәкмәс: берәү дигәнебез аның яратып йөргән кызы була инде. Ә ул кыз яңарак кына каты авырудан терелгән икән. Менә ничек бит ул!.. Харис аның янына бер дә буш кул белән кайтырга теләмәгән иде, ә студент кешенең хәлен беләсез инде, кат-кат бүләк ала алмый ич ул... Аннары бу яулыкны табуына бик куанган да иде. Инде менә, уеннан уймак дигәндәй, ычкындырды да куйды! Ә сезгә ул яулыкның әллә ни кирәге юктыр, шәт? Ахыр чиктә без бергәләп сезгә берәр нәрсә...

Ханым егеткә сүзен әйтеп бетерергә бирмәде.

— Кемгә саныйсыз сез мине? — диде ул, ашыгып һәм гасабиланып.— Неужели сез менә мине берәүнең кадерле нәрсәсен тартып алыр дип уйлыйсыз? Шаяру гына ич бу, шаяру гына, аңлыйсызмы шуны? Миңа бернәрсәгез дә кирәкми, бирәм, бирәм, яулыгыгызны да бирәм! Тик... ни өчен соң иптәшегез... Харис... үзе минем белән ачык кына сөйләшергә теләми? Ояламы, хурланамы, горурлыгына көч килер дип куркамы? Бер дә юкка лабаса! Менә сез әйтегез үзенә, килсен, мин үз кулым белән аңа бирермен.

Егет маңгаен ышкып алды.

— Менмәс ул!

— Ни өчен?

— Ялына торган егет түгел ул!

— Ходаем, ни өчен ялынырга? Миңа аның ялынуы кирәкми. Минем просто яулыкны үз кулым белән аңа бирәсем килә. Аннары... минем аның белән сөйләшәсем килә. Аңлыйсызмы? Безнең арада бернинди дә үпкә, ачу калмасын иде. Сез шулай дип әйтегез дә: апаның, диегез, сиңа әйтәсе сүзе бар икән, диегез. Ярыймы?

— Ай-һай! — диде егет, башын чайкап.— Шикләнәм, килмәс. Яман хәтерен калдырдыгыз сез аның!

— Ни белән? — диде ханым, өзгәләнеп.

— Бик кадерле нәрсәсе белән уйнадыгыз ич!

— Юк, юк, дөрес түгел! Мин аңлатырмын, кирәксә гафу үтенермен, тик килсен генә!

— Ярый, әйтеп карармын! — диде егет, сүлпән генә, һәм теләр-теләмәс кенә каютадан чыгып китте.

...Әмма Харис менмәде. Ханым, яулыкны әйбәт кенә төреп, күкрәгенә кыскан килеш, каютасыннан бер чыкты, бер керде, палубаны әллә ничә тапкыр әйләнде, ләкин һич юкка! Егетнең хәтта иптәшләреннән берәү дә яңадан менмәде. Димәк, Харис үзе килмәү генә түгел, аларны да сорап йөрүдән катгый рәвештә тыйган булырга тиеш —шулай аңлады Диләрә ханым. Бу нәрсә аны гаять авыр хәлгә куйды, чөнки хәзер ул үзе дә алар янына төшә алмый иде инде. Төште исә, шул тәкәббер «малайлар» алдында үзен тулысынча гаепле дип санау булачак. Әмма гаеплемени соң ул?

Шулай ук бу яулыкны үзендә калдырырга да ярамый иде. Йә, нишләтергә тиеш ул аны? Иделгә ташларгамы?

...Җәйге озын көн акрынлап кына сүнде; ниһаять, төн булды, пароход халкы да тынды. Салонда, палубада утларны сүндерделәр. Тик борындагы мачта башында гына нурсыз ут караңгы бушлыкта ялгызы гына йөзеп баргандай күренә иде.

Диләрә ханым, әйләнеп-тулганып йөри-йөри тәмам арыгач һәм бөтен палубасында берьялгызы торып калуын күргәч, ахырда каютасына керде... Керү белән, чишенмичә-нитмичә, койкасына утырган килеш кенә башын мендәргә куйды һәм шунда ук оеп та китте; күрәсең, аруы, йончуы бик җиткән иде... Бу — хәлсезләнеп, миңгерәүләнеп, әмма җан сызлавын оныта алмыйча йоклау күпме дәвам иткәндер, менә берзаман ул пароходның селкенеп шыгырдавыннан һәм каяндыр түбәннән ишетелгән кешеләр тавышыннан уянып китте. Күзен ачты, башын калкытты, түбәндә ни барын аңларга тырышып, аз гына тыңлап торды, аннары кинәт нидер сизенеп, урыныннан сикереп торды да каютасыннан атылып чыкты. Яулыкны ул йоклаганда да кулыннан ычкындырмаган иде. Һәм, шуны күкрәгенә кыскан килеш, ашыгып, пароходның дүртенче классына төште, ары-бире сугылып, теге яшьләрне эзләргә кереште. Ахырда, таба алмагач, түбәнге сәндерәләрнең берсендә йоклап яткан баланың аяк очында йокымсырап утырган бер олы яшьтәге апайдан сорады:

— Апа, монда студентлар баралар иде. Өч егет, бер кыз... Шулар кайда?

— Сту... студиннар! — диде апа, тыела алмыйча исни башлап, һәм авызын учы белән каплады.— Кайсылар икән ул?

— Менә инде ни... берсе озын гына буйлы кара егет... берсенең өстендә шакмаклы күлмәк...

— Ә-ә!.. Аларны әйтәсез икән... Төштеләр шул алар, чибәрем.

— Төштеләр? — диде ханым, кисәк кенә апага омтылып.— Кайчан, кайда?

— Менә хәзер генә төшеп калдылар. Күрмәдегезмени? Әле яңа гына кузгалдык ич.

Диләрә ханым, шунда ук борылып, пароход ишегенә йөгерде. Ләкин киң ишектән ул караңгы судан башка берни дә күрмәде. Шуннан йөгереп югары менеп китте, чабып пароходның койрыгына барды... Менә, менә күп булса, йөз илле-ике йөз адымда гына сирәк утлары белән җемелдәп кечкенә пристань күренә. Әле ярга чыккан кешеләрне дә шәйләп булырлык... Диләрә ханым, нишләгәнен белештермичә, кулын күтәреп, ачынып бер кычкырды:

— Ха-а-рис!

Ләкин артык ашкынудан көчсез яңгыраган тавышы аның төнге бушлыкта бик тиз сүнде — йотылды, хәтта үзенә дә юньләп ишетелмәде. Бер мизгел ул, күзләрен йомып, баганадай катып торды, аннары кинәт кенә кулындагы яулыкны сүтте дә һавага, Идел өстенә, очырып җибәрде. Ефәк яулык, аның кулыннан ычкынуга, югары күтәрелде, бер талпынды, бер тибрәнде дә, караңгылык эчендә үзлегеннән эрегәндәй, юкка да чыкты...

Пристань инде еракта калды. Төн, берни юк, берни күренми. Тик ярдагы утлар гына, гүя Диләрә ханым йөрәгендә көйрәгән күмерләр төсле, аны үртәп, аны газаплап яналар иде...

1959

# Яшьлек хатасы

Бүген халык судында әллә ни кызыклы эшләр булмады. Башта «вак караклык» дип йөртелгән бер эшне карадык, аннары бер квартира җәнҗалын тикшердек. Соңгысы шактый озакка сузылды. Бер кухняга сыеша алмаган ике гаиләнең кайсысы хаклы, кайсысы гаепле — иблис үзе дә аерып бетә алмас. Кыскасы, кухня тарлыктан түгел, күңел тарлыктан килеп чыккан вак, мәгънәсез, эчпошыргыч бер эш иде бу... Инде менә соңгысы... аерылышу турында.

...Квартира җәнҗалы буенча суд карарын игълан иткәч, без кечкенә тәнәфес ясап алдык. Яңадан суд залына чыкканда, халыкның күпчелеге таралган, анда биш-алты кеше генә калган иде. Шулар безне аягүрә басып каршы алдылар. Без тәбәнәк сәке өстендәге кызыл япкан өстәл артына кереп утырыштык... Тынлык. Декабрь аеның кыска көне инде сүнеп бара, тәрәзәләрдә кичке эңгер акрын гына куерып килә, һәм зур урамның шау-шуы, залдагы тынлыкны бозмыйча, тонык кына ишетелеп тора иде.

Судья да шушы сүлпән тынлыкка иплəшкəндəй басынкы тавыш белән генә суд утырышының дәвам иттерелүен белдерде. Аннары «Эш» дигән юка папканы ачып, шуннан герблы марка ябыштырылган бер кәгазь чыгарды. Бу аеруны сорап язган гариза булырга тиеш. Кәгазьгә күз төшереп алгач, судья залга карап дәште:

— Гражданин Зәбиров!

Икенче рәттән өстенә каракүл якалы әйбәт пальто кигән, кулына пыжик бүреген тоткан берәү күтәрелде.

— Мин.

Судья аңа сөзеп кенә бер карап алды да тагын дәште:

— Гражданка Зәбирова!

Шул ук икенче рәттән, ләкин ир кешедән читтәрәк утырган, башындагы мамык шәле, өстендәге кара бостон пальтосы белән татар абыстаена охшаганрак бер арык кына ханым күтәрелде.

— Мин,— диде ул, чак ишетелерлек итеп.

— Алгарак узыгыз! — диде судья аларга.

Ир белән хатын алга чыгып бастылар. Иң элек күзгә ташланган нәрсә шул — болар инде яшь кешеләр түгел иде. Иренә кимендә бер илле яшь булыр, хатыны да кырыктан узган булырга тиеш. Бу нәрсә берьюлы безнең кызыксынуны уятты, һәм шунда ук күңелгә мондый очракларда килмичә калмый торган уй да килде: нинди сәбәпләр боларны монда китерде икән?

Кайчакта моны, кешеләренә карап, шактый дөрес чамалап та була. Аеруча яшьләрнең «серен» тиз сизәргә мөмкин. Әмма боларныкын алай тиз генә чамалау бик читен иде: икесе дә абруйларын саклап, бик тыныч басып торалар, борчылу, уңайсызлану кебек нәрсәнең әсәрен дә күрсәтмиләр. Тик буйга таза ирнең куе кашлары бер-берсенә тартылган, иреннәре кысылган, шуңадыр, ахры, йөзе артык җитди, хәтта караңгы чырайлы булып күренә. Ә хатынның йөзендә, киресенчә, андый киеренкелек тә, пошыну да, кайгы да — гомумән, берни дә юк, әйтерсең җансыз битлек белән капланган ул. Һәм бу йөзгә каравы авыр иде, гүя берни сиздермәгән хәлдә ул бик тирән фаҗига турында сөйли иде. Шул ук вакытта алар үзләрен бер-берсеннән бөтенләй бәйсез тоталар — беренче карауда ир белән хатын дип тә белмәссең. Нәкъ менә чит кешеләр төсле ерак, ят иде алар. Бусы да безнең өчен гаҗәп-сәер иде, чөнки аерылышырга килгән кешеләр арасында, гадәттә, яшерен бер дошманлык сизелә торган иде, ә биредә анысы да юк. Әйе, боларның «эше» шактый гыйбрәтле булырга тиеш.

Шул арада судья утырышны дәвам иттереп:

— Суд гражданин Зәбировның аерылышу турында сорап биргән гаризасын карарга керешә,— диде һәм икесен дә суд составы белән таныштырып, ризалыкларын сорады. Ир өзеп кенә «риза» диде, хатын исә башын гына кагып куйды. Судья аларга утырырга кушты. Шуннан соң ул Зәбировның гаризасын укып чыкты. Кыска гына язылган бу гаризада аерылышуны нигезләп бер генә сәбәп тә китерелмәгән иде. Анда бары тик, без аерылышырга телибез, икебез дә моңа риза, шуңа күрә судтан безне аеруын сорыйбыз, дип кенә әйтелгән иде...

Гаризаны укыгач, судья Зәбировка дәште:

— Зәбиров!

Зәбиров яңадан торды.

— ...Исем, фамилиягезне тулысынча әйтегез!

— Зәбиров Ильяс Кәримович.

— Ничә яшьтә?

— Кырык тугызда.

— Кайда, кем булып эшлисез?

— Мин... доцент. Институтта укытам.

Гадәттә башлап танышу өчен бирелгән бу сораулардан соң судья, кресло аркасына сөялеп һәм Зәбировка җитди-сынаулы карашын төбәп, яңадан сүз башлады:

— Йә, гаризагызга өстәп сез нәрсә әйтергә телисез? Зәбиров, уйланып, бераз дәшми торды да шактый катгый рәвештә әйтеп куйды:

— Юк, өстәп әйтер сүзем юк!

— Шулай да? Мәсәлән, гаризагызда сез аерылышуның сәбәбен күрсәтмәгәнсез. Бәлки, шул хакта әйтерсез?

— Аны ничек итеп әйтәсең? — диде Зәбиров, иңбашын җыергандай итеп.— Аннары кирәкме соң ул? Без бит икебез дә аерылышырга риза.

— Ләкин аерылышуны сез таләп итәсез... Ни өчен? Суд моны белергә тиеш.

Зәбиров иреннәрен кысты, башын иеп, беравык алдына гына карап торды. Күренә, кешенең «сәбәп» дигән серне бер дә ачасы килми, хәтта судны канәгатьләндерер өчен бу зарури булган хәлдә дә нигәдер сөйлисе килми. Чынлап та ни өчен? Бик авыр булганга күрәме яки үзен гаепле тоеп, шуны белгертәсе килмәгәнлектәнме, яки коры бер тискәрелектәнме?.. Суд сабырлык белән аның җавабын көтә.

Ниһаять, ул, шактый көттереп, тагын үзенекен кабатлады:

— Гафу итегез, шулай да мин бездән аерылышуның сәбәпләрен әйттереп тору кирәк түгелдер дип беләм. Без икебез дә риза, безнең арада бу хакта тартыш-бәхәс юк, тагын ни кирәк? Мондый очракта суд өчен шуны белү бик җиткән, минемчә...

— Без әле хатыныгызның теләген белмибез.

— Ә сез аңардан сорагыз!

— Вакыты җиткәч, әлбәттә, сораячакбыз. Ә хәзер әле без сездән сорыйбыз: ни өчен?.. Әйе, ни өчен суд сезне аерырга тиеш? Ә бәлки, семьяны саклау өчен, сезнең үтенечне кире кагарга кирәктер? Без бит белер-белмәс, сукыр килеш мәсьәләне дөрес хәл итә алмаячакбыз. Кыскасы, суд алдына килгәнсез икән инде, рәхим итеп, үзегезнең үтенечегезне нигезләгез!

— Нигез шул,— диде Зәбиров ризасыз-караңгы чырай белән,— без артык бергә торырга теләмибез.

— Ни өчен теләмисез?

Зәбиров җавап бирмәде һәм бирергә уйламый да иде шикелле.

Шактый көткәннән соң судья, ниһаять:

— Әйтегез әле,— диде,— ничә ел сез бергә торасыз?

— Егерме өч ел,— диде Зәбиров, акрын гына.

— Егерме өч ел! Димәк, тиздән көмеш туегыз булырга тиеш. Ә сез аерылышуны таләп итәсез! Ничек соң ул алай, егерме өч ел бергә гомер иткәннән соң, сез кинәт семьягызны ташларга уйлыйсыз? Моның бит гаять җитди сәбәбе булырга тиештер инде?

— Әлбәттә, шулай,— диде Зәбиров һәм башын күтәреп, судьяга бик туры карады.— Сәбәбе бар аның, ләкин яңа гына килеп чыккан сәбәп түгел ул... Бик күптәннән килә ул...

Судья да Зәбировка бик төбәлеп карап тора иде. Мин хатынга күз төшердем: ул ике арада барган сүзгә бер дә катнашы юк кеше шикелле, үз урынында башын түбән иеп, тик кенә утыра иде. Залда һаман шул ук сүлпән тынлык. Ләкин бу тынлык ниндидер бер авыр киеренкелек белән тулы иде.

Алар шулай карашып торганнан соң, судья сакланып кына, гүя Зәбировның әйтеп бетермәгән сүзен алырга теләп, сорау бирә башлады:

— ...Һәм ул сәбәп бер сүз белән генә әйткәндә... нидән?

— Без ялгыш кушылганбыз! — диде Зәбиров, дорфа гына кырт кисеп.

— Моны ничек аңларга?

— Теләсәгез ничек аңлагыз! Мин сезгә бер генә сүз белән әйтеп бирдем.

Судьяның да ачуы килеп китте, ахрысы, рәсми-коры гына әйтеп куйды:

— Сез, гражданин, судны хөрмәт итмисез!

— Юк, мин судны хөрмәт итәм,— диде Зәбиров, тыенкы бер тискәрелек белән.— Ләкин ни өчен мин безнең арада булган бөтен... ямьсезлекне, бәхетсезлекне фаш итеп торырга тиешмен? Нигә кирәк ул? Аңардан бит сез барыбер безне килештерә дә һәм семьяны коткарып кала да алмыйсыз.

Судья, моңа каршы ни әйтергә белмәгәндәй, бер мәлгә тынып калды, үзалдына гына «да-а!» дип сузды, аннары тагын телгә килде:

— Яхшы. Алайса әйтегезче, зинһар, ни өчен сез менә хәзер генә аерылышырга кирәк таптыгыз, ни өчен бу хакта элегрәк уйламадыгыз?

Зәбиров, сиздерер-сиздермәс кенә, тирән сулап куйды:

— Уйлау... уйланулар күп булды... Дөресен генә әйткәндә, суд алдына безнең беренче тапкыр килүебез түгел. Без бер булган идек инде.

— Кайчан ул? Күптәнме?

— Моннан унсигез ел элек.

Әйе, бу төскә-биткә, буйга-сынга чибәр-таза гына, ләкин караңгы чырайлы кешенең һәр сүзе безне гаҗәпкә калдыра иде. Һәр сүзе табышмак шикелле, һәм аңлавы читен иде аны... Менә ул тыштан тынычлык сакларга тырышып, ләкин эчке киеренкелектән таштай каткан йөз белән безнең алда басып тора. Яшерен, йомык, һәр сорауга, тешен суырткандай, көчәнеп, газап белән генә җавап бирә. Күрәсең, бик авыр аңа... Чынлап та зур бәхетсезлек кичергән булса кирәк ул — моны хәзер сизмичә мөмкин түгел иде.

— Ни өчен соң ул вакытта сезне аермадылар? — диде судья, сак кына.

Зәбиров, бераз иреннәрен кысып торганнан соң, алдына карап кына әйтте:

— Ул чагында безнең яшь балабыз бар иде. Судта безгә, дөресрәге миңа, балагызны сез ничек ятим итеп калдыра аласыз, диделәр. Әйе. Бала хакына торырга кирәк, диделәр. Бу дөрес иде. Мин китмәскә булдым.

— Ә хәзер?

— Ә хәзер улыбыз үсеп җитте, быел университет бетерде. Үзенә хуҗа кеше ул хәзер...

— Димәк, шулай булгач, хәзер инде семьядан китәргә дә ярый, сезнеңчә?

Зәбиров, тагын да караңгылана төшеп, кашларын җыерды.

— Сез дөрес аңлагыз,— диде ул, авыр-басынкы тавыш белән,— мин күптән китәргә тиеш идем. Бу минем әллә кайчангы ныклы карарым. Тик мин китүне унсигез елга кичектереп тордым. Бары шул гына...

Бары шул гына, имеш, шайтан алгыры! Моны ишеткәч, әллә ничек аркалар чымырдап киткәндәй булды. Әллә нәрсә бу, ничек дип атарга да белмәссең! Хәтта судья да гаҗәпләнүдән башын гына чайкап торды, ләкин артык бер сорау да бирмәде.

Хәзер инде безнең чират җитте. Башта судья миңа дәште:

— Сезнең соравыгыз бармы?

Мин икеләнебрәк, ләкин ихтыярсыздан «юк» дидем, чөнки, дөресен әйткәндә, унсигез ел буена хатыныннан китү теләге белән яшәгән, әмма чын сәбәбен һич әйтергә теләмәгән бу кешенең йөрәген аңларга ярдәм итәрлек җитди берәр сорау миндә туып та, оешып та өлгермәгән иде әле. Аннары күптән инде мине әнә ялгызы бер урындыкта бөрешеп кенә утырган хатын үзе бик кызыксындыра иде. Әле аның торып җавап бирәсе бар. Ул ни әйтер, бу гаҗәп сәер, буталчык хәлгә нинди ачыклык кертер —шуны ишетәсе килә иде.

Судья икенче ягында утырган киңәшчегә борылды:

— Сезнең соравыгыз бармы?

— Бар, бар,— диде, ашыгып, безнең киңәшчебез. Тегү фабрикасыннан сайланып килгән бу өлкән яшьтәге Хатирә исемле апа аерылышу эшләрен караганда һәрвакыт бик активлык күрсәтә, ирләргә бик бәйләнә, гомумән, аерылышуны, нинди генә сәбәптән булмасын, ул һич якламый һәм гел аңа каршы төшә торган иде. Бу юлы да күптән сабырсызланып утырган апа Зәбировка бик капыл ябышты!

— Ничек инде сез,— диде ул, чын-чыннан ачынып,—сез, аңлы, укыган кеше, олыгайган көнегездә гомер иткән хатыныгызны ташларга батырчылык итәсез? Акылга сыймый бит бу!..

— Гомер итү төрлечә була,— диде Зәбиров, тыныч кына.

— Торгансыз бит моңарчы, торгансыз! Нигә, моннан соң да тора алмас идегезмени?

Зәбиров сул иңбашын сикертеп куйды.

— Гаҗәп!.. Тора алсам, суд алдына килеп тә йөрмәс идем,— диде ул, мыгырданып кына, һәм, зинһар, җанымны кыйнамагыз дигән төсле, урам як тәрәзәгә таба борылып, туйган-алҗыган бер кыяфәт белән карап тора башлады. Ләкин Хатирә апа аның бу кыяфәт кыланышына игътибар итеп тормады, сорыйсын сорый бирде:

— Алайса гаеп кайсыгызда соң?

— Аңламыйм.

— Ничек аңламыйсыз? Аерылышырга мәҗбүр иткән гаеп кайсыгызда дип сорыйм.

Зәбиров, тәрәзәдән акрын гына борылып, авыр, салкын карашын Хатирә апага төбәде:

— Гафу итегез, мин әйтергә мөмкин булган кадәресен әйттем, һәрхәлдә, монда хатын гаепләп, аның өстенә сүз сөйләп торырга теләмим. Кыстамагыз. Бик кирәксә, бөтен гаепне үз өстемә алырга әзермен, тик безне аерыгыз гына. Бүтәнчә мөмкин түгел, аңлагыз шуны!

— Ни өчен мөмкин түгел? Бу ни дигән сүз! — диде Хатирә апа, кинәт кабынып.— Кара аны, әйтми-сөйләмичә генә, гомер иткән, бала үстергән хатынын ташламакчы була. Оят кайда, намус кайда? Бәлки, сез читтә берәр теге... нигә... ияләшкәнсездер дә хәзер шуның янына качарга чамалыйсыздыр? Ә без монда шуңа ризалык биреп торыйк, имеш! Ученый баш!

Шул арада судья, тиз генә иелеп, Хатирә апаның колагына нидер пышылдады. Хатирә апа: «Соң... ни... әйтмичә тагы»,— дип торды да, ниһаять, тынды. Судья Зәбировка утырырга кушты, ләкин ул утырырга ашыкмады. Аның йөзе кара көйгән, яңак сөяге дерт-дерт селкенә иде.

— Мин... бу хәкарәтне катгый рәвештә кире кагарга тиешмен,— диде ул, тыныч булырга тырышып, әмма карлыккан тавыш белән:— Минем берәүгә дә ияләшкәнем юк. Безнең арада гомер буе кабер салкынлыгы яшәп килсә дә, мин...

Судья аның сүзен бүлде:

— Аңлашылды, гражданин Зәбиров. Шик рәвешендә генә әйтелгән сүз ул... бары үзегез ачык, туры җавап бирмәгәнгә күрә генә... Ә хәзергә утырып торыгыз!

Зәбиров ашыкмыйча гына утырды, кесәсеннән кулъяулык чыгарып, маңгаен сөртергә кереште, ә судья аның хатынына мөрәҗәгать итеп дәште:

— Гражданка Зәбирова, якынрак килегез!

Хатын урыныннан торды да бер генә адым атлап тукталды. Кайчандыр ул чибәр генә булганга охшый, күзләре зур гына, кашлары нечкә, борыны туры, авыз-ияк тә килешле генә. Тик күз төпләрен вак кына җыерчыклар каплап бетергән. Игътибар беләнрәк караганда бу җыерчык челтәрен ирене өстендә һәм иягендә дә күреп була. Бу аны бик йончыган һәм вакытыннан иртә картайган итеп күрсәтә иде. Ләкин болардан да бигрәк күзгә ташланган нәрсә — аңардагы гаҗәеп бер җансызлык, мескенлек иде. Әйтерсең аягүрә сүнгән ул. Кайгыра да, борчыла да, шатлана да, елмая да белмидер кебек иде.

— Йә, гражданка Зәбирова, сез ни әйтәсез? — диде судья.

Хатын үзлегеннән яшьләнебрәк торган зур күзләрен иренеп кенә судьяга күтәрде. Аннары көттереп кенә әйтеп куйды:

— Ни әйтим? Белмим мин...— һәм, бүтән сүз таба алмагандай, тукталып калды.

Судья, авыру кеше белән сөйләшкәндәй, йомшак кына итеп, бер-бер артлы сорауларын бирә башлады:

— Менә гражданин Зәбиров сезнең белән аерылышуны сорап судка мөрәҗәгать итә. Сез моны алдан ук белгәнсездер дип уйлыйм, шуңа ничек карыйсыз?

— Әйе, белдем... Мин риза.

— Риза?.. Ләкин, гафу итегез, безгә бу аерылышуның сәбәбе ачык түгел. Бәлки, сез аңлатырсыз, ни өчен аерылышырга булдыгыз?

— Булдык инде... Вакыты җитте.
— Ни өчен соң?
Хатын озак кына башын иеп торды. Судья, аның җавабын көтеп алалмагач, тагын сорады:
— Берәр сәбәбе булырга тиештер бит... Әллә бик начар тордыгызмы?
— Тордык инде,— диде хатын ни үкенү, ни көенү сиздермәгән бер җансызлык белән.
— Ничек тордыгыз?
Хатын дәшмәде.
— Төрлечә тору бар бит. Тату тору бар. Киресенчә, талашып, ызгышып тору бар...
— Бездә алай булмады.
— Ә ничек булды?
Хатынның ияге тетрәнеп куйды, күзләре бер мәлгә яшь белән тулды, ләкин елап җибәрүдән тыела алды һәм чак ишетелерлек итеп кенә әйтте:
— Ул... минем белән... торырга теләмәде.
— Ни өчен?
— Белмим, үзеннән сорагыз.
Судья, аңа тынычланырга вакыт бирер өчен булса кирәк, бераз дәшми утырды. Ләкин шул арада Хатирә апа үз алдына сукранып әйтеп куйды:
— Гомер иткән иреңнең кем икәнен, ни теләгәнен белмә, имеш. Нинди хатын сез?
— Каян белим мин? — диде хатын, ничектер балаларча бер гаҗизлек белән.
— Ничек инде, бергә тор да...
— Без бергә тормыйбыз... Без бер квартирада гына торабыз.
Хатын үзе өчен гаять авыр, гарьлекле булырга тиешле бу хакыйкатьне һичбер уңайсызлану, хурлану сиздермичә бик гади генә итеп әйтте дә бирде. Күрәсең, ул үзенең фаҗигале хәленә күптән ияләшеп беткән иде. Һәм аның бу әйткәннәре суд кешеләрен тагын бер мәлгә сүзсез калдырды. Судья, аптырагач, башын кашып алды.
— Әй-е! — дип сузды ул, ни диярге белмичә, аннары ризасызлыгын яшермичә әйтеп ташлады.— Алай булгач, ирегезгә күптән развод бирү кирәк иде. Ул бит кайчандыр сездән шуны таләп иткән?
— Әйе, судка биргән иде. Тик ул чакта бала хакына аермадылар, мин дә риза булмадым.
— Ә хәзер ризасыз инде?
— Риза. Нигә кешене азаплап тотарга? Китсен!
Мәсьәлә ачык иде. Судья бүтән сорау биреп тормады. Мин дә бу хокуктан баш тарттым: нигә кешенең җанын суырырга? Ләкин Хатирә апа, мондый эшне йөрәгенә бик якын алганга күрә, сорау бирү хокукыннан файдаланып, хатынга үгет-шелтәсен ачынып әйтергә тотынды:
— Син дә, җаным, боламык икәнсең. Семья таркатырга юл куеп торасың. Бу яшькә җиткәч, нинди аерылышу ди ул! Кеше көлдереп... Яшь чакларыгыз, яхшымы-яманмы, үткән дә киткән инде, хәзер картлык турында уйларга вакыт. Килеп җитәчәк бит ул. Шуны сизмисеңмени? Ярый, ул — ир кеше, вакыты үтмәгән әле, тагын үзенә табар. Ә син... син нишләрсең? Кемгә сыенырсың?
Ләкин хатынга бу сүзләр һич тәэсир итмәде, ахрысы, ул сүнгән бер кыяфәт белән ничек басып торса, шул хәрәкәтсез, җансыз хәлендә кала бирде. Мин иренә күз салдым. Ул да башын түбән салындырып, терсәкләрен тезләренә куеп, дөньясыннан ваз кичкәндәй, тик кенә утыра иде.
Судья аягүрә басты.
— Суд киңәшкә чыга,— диде ул, папкасын ябып, һәм без урыныбыздан кузгалдык.
Озынча тар бүлмәгә кергәч тә, судья иң элек үрелеп тәрәзә форточкасын ачты, аннары икебез дә бер үк вакытта кесәләрдән папирос чыгардык. Тәмам сусаганбыз икән, утырышып, сүзсез генә тартырга керештек.
Без, билгеле, киңәш корып, карар чыгарырга җыенмый идек. Халык судының мондый эш буенча карар чыгарырга хакы юк. Ул ир белән хатынны килештерергә тырыша, килештерә алмаса, эшне югары судка җибәрә. Бәс, шулай булгач, Зәбировлар да югары суд алдына барып, бүгенге күренешне тагын бер мәртәбә шунда кабатларга тиешләр.
Әгәр дә инде карар чыгару безнең ихтыярда булса, ышанам ки, без аларны аерыр идек. Бер-берсеннән туеп-бизеп беткән кешеләрне, юк, сез торыгыз әле дип, нигә көчләп маташырга? Беткән, сүнгән ич барысы да!.. Хәтта, минемчә, Хатирә апа да бу очракта карышып тормас иде. Аның өчен дә сакларлык яки якларлык берни дә калмаган монда.
Хәзерге минутта безне бары бер генә нәрсә кызыксындыра, бер генә сорау күңелне гел борчып тора: ничек итеп алар бер-берсеннән шулкадәр бизделәр, читләштеләр икән? Моның төп сәбәбе нәрсәдә соң? Үзләреннән бу хакта ачык кына ишетеп булмады. Судья әйтә, олы яшьтәге кешеләр аерылышырга килсәләр, һәрвакыт шулай бик яшерен булалар, серләрен ахыргача әйтеп бетермиләр, яшьләр генә ул капчыкны төбеннән тотып селкәләр, ди. Чынлап та, бу дөрес булырга тиеш. Менә хәзер яңадан ир белән хатынның теләр-теләмәс, кыстатып кына әйткән сүзләрен искә төшергәч, мине кинәт бернәрсә гаҗәпләндерде: ни өчендер аларның берсе дә, ялгыш кына да, ярату-мәхәббәт сүзен теленнән

ычкындырмады бит!.. Очраклы хәлме бу? Дөрес, кеше, олыгайгач, мәхәббәт турында җәелеп сөйләргә яратмый яратуын. Ләкин хикмәт бары шунда гына микән? Ихтимал, алар арасында гомумән беркайчан да чын, ныклы мәхәббәт булмагандыр. Әлеге иң төп сәбәпне менә шуннан эзләргә кирәк түгелме? Мин бу шигемне судьяга әйттем. Судья, алдан ук моның шулай икәнен белгән шикелле, бик тиз минем белән килеште:

— Бик дөрес. Асылда бу кешеләр — яшьлек хатасының корбаннары... Өйләнешкән чакта ук алар бер-берсен чынлап яратмаганнар да, белмәгәннәр дә, аңламаганнар да. Ә калганы инде бары шуның нәтиҗәсе генә.

Ләкин Хатирә апа судьяның бу сүзләре белән килешергә теләмәде:

— Сөйләмәгез! — диде ул, кулын селтәп.— Мәхәббәт, имеш! Мәхәббәт ул туйда гына кирәк. Ә соңыннан кешеләрне уртак тормыш, бергәләп көн итү, балалар үстерү бер берсенә бәйли. Шулар гына семьяны да саклый.

— Ә менә саклый алмаган бит! — дидем мин.

— Хатын — җебегән, ирен кулында тота белмәгән...

— Ә көчләп тотып буламыни? Һәм нигә кирәк ул? Хатирә апа миңа усал гына бер карап алды.

— Нәрсә сез, ирләрне бөтенләй йөгәннән ычкындыру ягындамыни? Алайса ни өчен без монда утырабыз?

Хатирә апаны мин хөрмәт итә идем. Суд өстәле артында менә шулай бергә утыргалагач, мин аның холкын, табигатен дә үземчә беркадәр белеп өлгергән идем инде. Асылда, тормышның әчесен, төчесен күп татыган олы яшьтәге бу хатын кешеләргә игътибарлы һәм миһербанлы иде, аларның хәлләренә керергә ярата иде. Мәсәлән, төрле җинаять эшләрен караганда ул, кеше нахакка әрәм була күрмәсен дип, бик борчыла торган иде, әгәр инде җинаятьче яшүсмер булса, ул аңа ничек тә җиңелрәк хөкем чыгартырга тырыша иде. Әмма инде ир-хатын мөнәсәбәтенә һәм аерылышу мәсьәләсенә килгәндә, Хатирә апабыз, әйткәнемчә, кинәт рәхимсез казыйга әверелә дә куя. Бернинди җан кичерешен, шуның белән бәйләнгән кешенең эчке фаҗигасен белми дә, белергә дә теләми ул... Ник анда семья тормышы кеше өчен җәһәннәмгә әйләнми, аның таләбе бер генә: тор, чыда, китмә, китәсе булма!..

Әйе, урта гасыр крепосте кебек искереп бетсә дә, гаять нык, таза һәм шомлы-хәтәр иде аның бу мәсьәләдәге карашы.

Шулай да мин аның соңгы сүзләренә каршы әйтмичә кала алмадым.

— Иң элек, хөрмәтле Хатирә апа,— дидем мин, ничек тә әдәп саклап,— кеше хайван түгел, аңа гомумән йөгән кирәкми. Кешеләр бер-берсенә йөрәкләре белән бәйләнгән булырга тиешләр... Икенчедән, без монда аерылышырга килгән ир белән хатынны килештереп булмасмы дип утырабыз. Булмый икән, йөгән түгел, тимер аркан да ярдәм итмәячәк.

— Һе, кара сез нинди... адвокат икәнсез,— диде Хатирә апа, зәһәр генә елмаеп.— Карга карганың күзен чукымый дигәндәй, сез ни, ирләр, бер-берегезне якларга гына торасыз.

— Юк, Хатирә апа, ялгышасыз! Мин ирне яклап түгел, менә хәзер генә каршыбызда басып торган хатынны кызганып сөйлим. Күрдегезме, ул нинди хәлгә төшкән? Ә бит ул бала хакына, семья хакына, ихтимал, кешеләр гайбәтеннән куркып, ирен үзеннән җибәрмәскә, сез әйткәнчә, аны кулында тотарга күпме еллар тырышып карагандыр. Һичшиксез, ул ирен яраткан да булырга тиеш, ләкин әнә хәзер «китсен!» дип тора. Ни өчен?.. Чөнки яратмаган ирне көчләп, ирексезләп тотуның үзенә дә, семьяга да газаптан башка берни дә китермәгәнлеген ул, ниһаять, аңлаган. Ләкин бик соңга калып, гомерен заяга уздырып, рухи тәмам сүнеп беткәч кенә — йә, бу искиткеч зур фаҗига түгелмени?! Һәм үзе өчен генә түгел, ире өчен дә, чөнки ире аның яратмыйча, теләмичә, тешен кысып, көчләнеп торырга мәҗбүр булган... Юк, Хатирә апа, теләсәгез ни әйтегез, шулай да мин ир-хатын тормышының бердәнбер таза нигезе — мәхәббәт дип саныйм.

— Мәхәббәт... мәхәббәт... тапкансыз бер сүз! — диде Хатирә апа, отыры тискәреләнеп.— Тормышны белмисез сез, вәт нәрсә! Итәгең тулы бала булса, яткан саен, иртәгә үзләренә ни ашатырмын, ни эчертермен дип хәсрәт чиксәң, мәхәббәтне аны онытып та торасың... Үзең өчен генә дөньяда яшәп булмый шул, иптәшкәй! Ә болар нәрсә, нужа күрмәгән интеллигент, бар кайгылары —мәхәббәт!

Мин, ни диим, бары башымны гына чайкадым. Күрәсез, мәхәббәтне яклавы бик авыр. Гәрчә ул, мәхәббәт, яшәү һәм бәхет чыганагы булса да, ни сәбәптер кешеләр аны тора-бара әнә шулай йә михнәт аркасында, йә томаналык (ә күбесенчә ханжалык) аркасында кирәксез, әһәмиятсез, хәтта зарарлы бернәрсәгә әйләндереп калдыралар.

Судья, безне килештерергә теләп булса кирәк, ахырдан гына мондый мисал китерде.

— Кайчагында судка тәмам бозылышып беткән ир белән хатын аерылышуны таләп итеп киләләр. Алар бер-берсе өстенә шундый гаепләр өяләр ки, тыңлап утырганда колаклар яна башлый. Килешү өчен бөтен юллар өзелгән диярсең! Ләкин төпченебрәк сорашкач, сизеп аласың: болар бер-берсен рататалар бит, шайтан алгыры!.. Тукта, дисең, боларның пыр тузулары очраклы гына булырга тиеш, эш үтмәгән, килештерергә мөмкиндер әле, дисең... Һәм чынлап та әлеге шул мәхәббәт дигәнебез аларның йөрәгендә сүнеп бетмәгән булса, килештереп була бит үзләрен!.. Соңыннан әле килеп рәхмәт тә әйтеп китәләр... Әйе,

мәхәббәт шундый нәрсә икән ул, кайчагында ирнең хатынга яки хатынның иргә ялгышып кылган хыянәтен дә кичерергә кодрәтеннән килә. Ә боларга килгәндә исә эш өметсез! Боларда мәхәббәтнең чаткысы да юк, һәм булмаган да ул. Югыйсә унсигез ел буена кеше аерылышу уе белән яшәмәс иде!

Шуның белән сүз киселде. Залда күтеп утыручыларны озак зарыктырырга ярамый иде, без папиросларыбызны тартып бетергәч тә кузгалдык.

Чыксак, караңгы иңгән залда берәү дә калмаган, Зәбировлар гына икесе ике җирдә тын гына утыралар иде. Иренеп кенә урыннарыннан тордылар. Судья аларга ике арада килешү мөмкин булмаганлыктан, аерылышу мәсьәләсен хәл итү өчен югары судка мөрәҗәгать итәргә кирәклеген иплән кенә төшендереп бирде. Алар моңа каршы бер сүз дә әйтмәделәр. Башта ир, бүреген киеп, ишеккә юнәлде, аның артыннан хатын чыгып китте.

Зал бушап калды. Суд шуның белән тәмам булды.

1961

## Сыбызгы

«Кызыл йомычка» артеленең председателе Франц Фәррәхович үзенең бер генә тәрәзәле фанер кабинетына тирләп-пешеп кайтып керде. Шунда ук ул күрше фанер бүлмәләрдән артельнең баш кешеләрен янына чакыртып алды.

...Һәм менә тәэминат-тарату бүлегенең башлыгы Ислам Сәләхович, бухгалтер Роман Илларионович һәм бердәнбер цех начальнигы Василий Иванович тар кабинетка кереп тулдылар.

Франц Фәррәхович аларны гадәттән тыш мөһим сүз буласын аңлатып торган үтә җитди кыяфәт белән аягүрә каршы алды. Тегеләр утырышып бетүгә, ул, йодрыклары белән өстәлгә таянып, сүзен болай башлады:

— Мин яңа гына Борис Абдуловичның үзендә булдым. Ә Борис Абдулович кичәгенәк Макар Захаровичта булган. Ә Макар Захаровичның баҗасы иптәш Галәветдинов,— сез иптәш Галәветдиновны беләсез инде,— так вот, иптәш Галәветдинов...— ул, хәзер әйтәсе сүзенең нинди зур әһәмияткә ия булуын сиздерер өчен, аз гына тукталып торды,— ...вызов буенча олы йортта, хуҗаның үзендә булып чыккан.

«Олы йорт»ның нәрсә икәнен һәм «хуҗа»ның кем икәнен тыңлап утыручылар беләләр иде. Моны ишетүгә, Ислам Сәләхович, чынлап та берәр хикмәтле хәл барлыгын сизенеп, тиз үк сорау бирде:

— Так, так... Нәрсә ишетеп чыккан соң иптәш Галәветдинов аннан?

— Ә менә нәрсә,— диде Франц Фәррәхович, читәнгә кунган көзге этәчтәй, күкрәген киерә биреп,— милиция бетә!

Койрыклы йолдыз атылып уздымыни — шулай таңга калдырды барысын да бу хәбәр. Кинәт ничектер бик кызык та, күңелле дә һәм аз гына шомлырак та булып китте аларга. Ислам Сәләхович, артка каерылып, кулларын җәеп җибәрде.

— Сөбеханалла! — дип ычкындырды ул ихтыярсыздан. Гүя гомере буе шуны ишетәсе килеп кенә йөргән.

Бухгалтер Роман Илларионович, ничаклы гына һичнәрсәгә исе китми торган философ табигатьле кеше булмасын, шулай да сүзсез кала алмады:

— Да-а, кызык бу! Әгәр чын булса...

Хәтта иске күн диванга чумып утыру белән йокымсырый башлаган цех начальнигы да кинәт сискәнеп, күзләрен йомгалый-йомгалый кабатлап сорады:

— Милиция дидегезме? Нишли дидегез, бетә дидегезме?

— Әйе, бетә! — диде Франц Фәррәхович, тантаналы пафос белән.— Коммунизмга килеп җитәбез, иптәшләр!

Бухгалтер тамак кыргалап куйды:

— Ыһым, ыһым! Әмма ләкин, Франц Фәррәхович, милиция мешәйт итми бит моңа...

— Ә кем сезгә мешәйт итә дип әйтә? Нечево мөгез чыгарырга! Сүз, теге ни, югары баскычка күтәрелү турында бара. Яңа процесс бу, беләсегез килсә, иптәш главбух!

— Шәп процесс! — диде тәэминат-тарату бүлегенең башлыгы һәм, гаҗәп бер иркенлек хис иткәндәй, кыска аякларын сузып җибәрде.— Бәлкем, әле суд белән прокуратура да бетеп китәр?

— Ашыкма! — диде Франц Фәррәхович, аңа усал гына карап, һәм, тагын да нидер чәнчебрәк әйтергә теләгәндәй, иреннәрен кыймылдатып торды. Ләкин ышанычлы кешесен аяды булса кирәк, кинәт сүзен бүтәнгә борды: —Без бу положениедән үзебезнең производство өчен ашыгыч нәтиҗә ясарга тиешбез.

Ислам Сәләхович начальнигын хупларга ашыкты.

— Бик дөрес. Нәтиҗәне ясамыйча ярамый.

— Нәтиҗә шул,— диде Франц Фәррәхович, ялагайлыкка күнегеп беткән бер игътибарсызлык белән аны ишетмичә,— без бүгеннән яңа продукция эшләп чыгаруны үзләштерергә тиешбез. Ишеттегезме, Василий Иванович?

Цех начальнигы тагын калкынып, күзләрен йомгалап алды:
— Продукция? Нинди продукция?
Франц Фәррәхович һәр сүзенә басым ясап, йодрыгы белән өстәлгә төртә-төртә әйтеп бирде:
— Безгә хәзер сыбызгы эшләп чыгара башларга кирәк. Аңладыгызмы?
Василий Иванович хәтта урыныннан күтәрелә башлады:
— Сыбызгы? Нинди сыбызгы?
— Кара сыбызгы. Милиционер сыбызгысы.
Василий Иванович кире урынына ауды.
— Суйсагыз да аңлый алмыйм.
Әйе, биргәли инде мондый табышмакларны Франц Фәррәхович үзенең кешеләренә. Моны кайчандыр аның бер клубта уен-мәзәк оештыручы булып эшләгән заманыннан калган гадәте дип тә әйтә торганнар иде.
— Йә! — диде ул акылдан мәхрүм тәкәләр шикелле үзенә сүзсез төбәлеп утыручыларга.
Ниһаять, Ислам Сәләхович учы белән шап иттереп маңгаена сукты.
— Бастым мәченең койрыгына! Хәзер милиция сыбызгысын балаларга уенчык итеп сатарга ярый, менә ни өчен без аны эшләп чыгарырга тиешбез. Шулаймы?
Франц Фәррәхович, чыраен сытып, башын селекте.
— Шулай да наданнар сез! Милиция бетсә дә, төрле жуликлар, хулиганнар, дебошерлар кала бит әле. Алар белән көрәшергә кирәкме? Кирәк. Менә бу эшне хәзер халык өстенә йөклиләр. Бөтен җирдә дружиналар төзеләчәк. Бер милиционер урынына ун, егерме, утыз дружина булачак.
— Ах, шулаймыни? — диде тәэминат башлыгы, кинәт сүнеп.
— Шулай шул менә! Так што итәгеңне җыебрак йөр!
Ислам Сәләхович ахырда бөтенләйгә тынды, ә Франц Фәррәхович, отыры җибәрелеп, үзенекен сөйли бирде:
— Сизәсезме, сыбызгыга хәзер спрос күпме артачак! Без бу конъюнктурадан файдаланып калырга тиешбез. Менә, Ислам Сәләхович әйтмешли, мәченең койрыгына басарга, причем чабып барган вакытында басарга кирәк.
Тыңлап утыручылар тагын ни әйтергә дә белмәделәр. Мәсьәлә алар өчен әллә ничек шунда бик сәер дә һәм бик буталчык та иде. Ышаныр идең, ничектер болар берсе дә акылга сыймый; ышанмас идең, кеше «югарыдан» ишетеп кайтканын сөйләп утыра.
Шулай да Роман Илларионович күңелендәге шиген әйтми булдыра алмады:
— Франц Фәррәхович, ничек соң, бу эш безнең промсоветта согласовать ителгәнме? Алай-болай галошка утырып куймабызмы икән?
Бу сүзләр председательне кыздырып кына җибәрделәр.
— Бухгалтер башыгыз белән коммерциянең серләрен белмисез,— диде ул, үзенчә мәсхәрәле-әче итеп.— Согласовать, имеш! Баштан ук шаулап йөри башлагач, бүтәннәр сизеп ала бит аны, голова! Юк, сыбызгыны иң элек ясыйк әле, аннары инде хуҗаларның өстәлләренә илтеп салырбыз. Во, карагыз! Без моның белән берьюлы ике куян атып алачакбыз: бердән, политик ситуацияне дөрес аңлавыбызны күрсәтәчәкбез, икенчедән, инициативаны үз кулыбызга эләктерәчәкбез! Беләсезме, «Кызыл йомычка»ның даны кая китәчәк?
Тыңлап утыручылар бер-берсенә караштылар, җилкәләрен җыердылар, әмма начальникларына каршы сүз әйтә алмадылар. Аларны «политик ситуация» дигән хәтәр сүз аптырауга төшерде. Ничегрәк аңларга соң моны? Ә бу исә, Франц Фәррәхович исәбенчә, моннан соң безнең җәмгыять тәртип бозучылардан һәм шуларга каршы көрәшүчеләрдән генә торачак дигән сүз иде. Һәм менә шушы зур көрәшкә, югарыдан команда биргәнне көтмичә үк, җиң сызганып кереп китү Франц Фәррәховичның никадәр сизгер һәм өлгер җитәкче булуын күрсәтергә тиеш иде.
Ниһаять, ул, бәхәсне беткәнгә санап, үзенең артеле алдына сугышчан бурыч куйды: ел ахырына чаклы йөз мең данә кара сыбызгы эшләп чыгарырга!
Әйе, бер кабынса, дөрләп яна торган кеше иде Франц Фәррәхович!
Цех начальнигы Василий Ивановичның йокысы тәмам качты. Ул бу эшнең, комнан аркан ишү шикелле, мәгънәсез бернәрсә булуын сизенеп, күпме генә аяк терәп маташмасын, председатель аның да җан жиреннән тотып ала белде. Ул аны политик сукырлыкта, партия чарасын өзәргә тырышуда гаепләде. Шуннан соң Василий Иванович кул селтәде: мәсьәлә болай куелгач, ул агач калдык-постыкларыннан сыбызгы түгел, газ трубалары ясарга да риза иде.
...Ә берничә көн узгач, Франц Фәррәховичка «Кызыл йомычка» артеленең яңа продукциясен күрсәтергә китерделәр. Председатель, ачык тәрәзә каршына басып, күкрәген киерә биреп, кара сыбызгыны кычкыртып җибәрде. Ай-һай яман да икән тавышы, каһәрнең! Әйтерсең Василий Иванович үзенең бөтен үт әчесен салып ясаган аны: чы-р-р... ыр-р-р! Шунда ук урамда халык җыелып өлгерде һәм чаттан ашыгып килгән милиционер күренде. Тизрәк тәрәзәне яптылар, аннары Франц Фәррәхович, яңа производство җиңүе белән котлап, бүлмәдәгеләрнең кулларын кысып чыкты.

Без Франц Фәррәховичны, бер кабынса, дөрләп яна торган кеше дигән идек. Әмма бу юлы аның януы шундый көчле булды ки, күп тә үтмичә ул, ут шарына әйләнеп, «Кызыл йомычка» артеленең морҗасыннан билгесез тарафка бөтенләйгә очып китте. Аның каравы артель цехында ящик-ящик сыбызгылар өелеп калды. Кирәк булып чыкмады алар дружиннарга. Сыбызгы кычкыртып чабарлык эш юк, ә ара-тирә очраган хулиганнарны бер дә чыр-чу куптармыйча гына авызлыклый беләбез, дип әйтәләр икән.

Хәзер вакытлыча артель председателе булып Ислам Сәләхович калган, имеш. Бу инде, үзегез беләсез, сыбызгыны бер дә яратмый торган кеше. Әле менә Франц Фәррәховичның «мирасын» ничек тә кулдан озатыр өчен, ул сыбызгыга тишекле көпшә куеп, борчагын алып, курай ясатмакчы була икән. Тәэминатчы шул, спросның хәзер нәрсәгә күбрәк буласын сизә, хәйләкәр төлке.

1961

## Гадәт колы

Бүрек урынына эшләпә кигәннән баш үзгәрәме? Юк, үзгәрми. Барыбер шул ук үткен күз-колаклары белән йомры баш булып кала ул. Баш югары, кул-аяк түбән; баш ни кушса, алар шуны эшләячәкләр.

«Терәк» колхозының күптәнге председателе Шәймәрдән агай, район органнары бетеп, алар урынына колхоз-совхоз идарәләре төзелүгә әнә шулайрак карады. Райүзәктәге ике катлы таш йортның ишек башына нинди генә исем язып куймасыннар, аның эчендә һаман «башлар» утырачак, ә ул, колхоз председателе, шул башларның боерыгы белән элеккечә тирләп-пешеп чабачак. Ул шуңа күнегеп беткән инде.

Тик бер генә нәрсә аның күңелен бераз борчып тора: яңа идарәгә яңа кешеләр килделәр,— менә шуларны белеп бетергәне юк әле. Кемнәр алар, нindirәк кешеләр? Характерлары, тотышлары дигәндәй, ничегрәк икән аларның?

Ә Шәймәрдән агай өчен алар турында алданрак хәбәрдар булып тору бик әһәмиятле, чөнки шуннан чыгып ул киләчәктә алар җаена ничектер көйләнә белергә тиеш. Кемнең чанасына утырсаң, шуның җырын җырлыйсың!

Кыш уртасында яңа җитәкчеләр зонадагы колхоз председательләрен, совхоз директорларын, партоешма секретарьларын, танышып сөйләшер өчен, райүзәкнең клубына җыйдылар. Бу беренче очрашуда Шәймәрдән агай җитәкчеләрнең күзенә бик кермәскә, аларны читтән генә күзәтергә булды. Шуңа күрә ул президиум өстәле тирәсендә чуалмады, залның да арттагырак рәтенә кереп утырды, тәнәфес вакытында да, кулларын артка куеп, кешеләрнең ни сөйләнүләренә колак салып кына йөрде.

Шулай да аңа җитәкчеләр күзеннән бөтенләй үк котылып калырга туры килмәде. Бер тәнәфес вакытында идарә начальнигы үзе аны сәхнә янына чакыртып алды.

— Шәймәрдән абзый,— диде яңа начальник, колхоз председателен култыклап һәм халыктан читкәрәк алып китеп,— без бүген барыгызны да тыңлап өлгермәбез инде. Бер ике-өч көннән мин үзем сезгә барып чыгармын... Йә, хәл-әхвәлләр ничегрәк соң?

— Ярый әле, ярый,— диде Шәймәрдән агай, сакалсыз ияген сыйпап.

— Исәпләр-уйлар, киләчәккә планнар дигәндәй?..

— Отчетларны биреп бетердек. Язга әкренләп әзерләнәбез... Тагын менә сез ни кушарсыз.

Начальник аңа сынап кына бер карап алды.

— М-да!.. Кушмыйча гына булмыймыни, Шәймәрдән абзый?

— Булмас шул, иптәш Батыршин! Үзегез беләсез, арбаның алгы тәгәрмәче кайдан тәгәрәсә, арттагылары да шуннан тәгәри бит аның! — диде Шәймәрдән агай, көлгән булып.— Так што...

Ләкин шул арада звонок яңгырады, тәнәфес бетте, аларның сүзләре бүленде, Шәймәрдән агай үз урынына барып утырды... Кыска гына бу сөйләшү аңа әйбәт кенә тәэсир иткән кебек булды. Абзаңны култыгыннан да алды, тазалыгын да сорарга онытмады, тик менә «Сез ни кушарсыз» дигән сүзгә генә ни өчендер гаҗәпләнгәндәй булды. Хәер, Шәймәрдән агай үзе дә аптырап калмады, шәп җавап тапты: «Так што, эш бездән түгел, күбрәк сездән тора, иптәш Батыршин!»

Ә яңа начальник вәгъдәле кеше икән, бер-ике көннән соң ул «Терәк» колхозына килеп тә чыкты. Шәймәрдән агайны ияртеп, аның барлык хуҗалыгын карап йөрде, бик күп сорашты, төпченде, әмма, гаҗәп хәл, ник тегене эшләмисең дә, ник моны эшләмисең дип җанына тимәде. Алай гына да түгел, китәр алдыннан ул, председательне каршысына бастырып, боерыклар бирәсе урында, «үзегез уйлап карагыз, үзегез хәл итәргә тырышыгыз» дигән шикелле, бернигә дә мәҗбүр итми торган киңәшләр бирү белән генә чикләнде.

Чынлап та әллә нәрсә бу! Үзенчә Шәймәрдән агайны сынап каравымыдыр инде! Янәсе, председатель үз белдеге белән берәр нәрсә эшләп ташламасмы? Аннары чакырып алып, суганлап-борычлап, кара тиргә батырганчы өшкерер иде бугай... Беләбез без аларны! Шәймәрдән абзыйның үз белдеге белән эшләгән

өчен авызы пешкән чаклары, Аллага шөкер, аз булмады. Бер елны шулай таптау җиргә кукуруз чәчмичә тары чәчкән өчен аңа «строгачны» чак кына чәпәмичә калдылар. Җитеп торыр, бигайбә, язганнан узмаска өйрәндек инде без, энем!

Шулай дисә дә, Шәймәрдән агай тынычлана алмады. Мөнәсәбәтләр ачык түгел. Ә ачыкларга кирәк, һәрхәлдә, яңа начальник аның өчен көн кебек ачык булырга тиеш. Ләкин моның өчен нишләргә?

Ахырда җае табылды шикелле. Март башларында «Терәк» колхозының клубында кустовой киңәшмә үткәрергә булдылар. Бу киңәшмәдә язгы чәчүгә хәзерлек эшләре каралырга тиеш иде.

Шәймәрдән агай төп хуҗа сыйфатында идарә начальнигын һәм тагын үзенә якын берничә кешене киңәшмәдән соң өенә, ашка алып кайтырга булды.

Тик менә начальникны партком секретареннан ничек тә аерырга кирәк. Теге, кем, керәшен карты әйтмешли, берьюлы ике почмакка чукынып булмас. Аны инде икенче бер вакытта коймаклы чәйгә алып керергә туры килер. Әйе, шулай, җитәкчеләрне аерым-аерым сыйлау яхшырак. Шуңа күрә Шәймәрдән агай колхозның партоешма секретарена: «Безгә кунакларны бүлешмичә булмас, миңа гына сыеп бетмәбез, адашыңны үзеңә алып кайтырсың»,— диде. Тегесе моңа берсүзсез риза булды.

Киңәшмә бетәр-бетмәс, Шәймәрдән агай чакырасы кунакларының колагына әйтеп, үзе тизрәк өенә ашыкты.

Өй эче майдай җылы, тәмле аш исе чыккан, түрдә матур итеп өстәл әзерләнгән иде. «Смирно» баскандай, шешәләр дә зәһәр генә тезелешеп торалар. Шәймәрдән агай хәтта кулларын угалап куйды. Әйбәт кенә салып, каздан капкалый башлагач, монда начальник түгел, министрның да эреп китәр!

Шулай кәефләнеп, ул ян тәрәзәдән урамга карагач, авызын ачып, аптырап та калды. Урам уртасыннан ашыкмыйча гына килүче кунаклар арасында озын буйлы, күзлекле партком секретаре да бар иде. Бу ни хикмәт? Җитмәсә, колхоз секретаре үзе дә ияргән.

— Эх, нәләт орган нәрсә! — диде Шәймәрдән агай, ботын чабып.— Изде бит эшне... Вәт син, ә!..

Инде нишләргә?.. Иң элек ул өстәлдән шешәләрне эләктереп, тиз генә мич артына кертеп куйды. Секретарь исен дә сизәргә тиеш түгел. Югыйсә шунда ук әллә ни уйлап чыгарыр чалмасыз «хәзрәт»!.. Ә начальникка гына салып бирер өчен инде ничек тә башка хәйләсен табарга кирәк, менә бәла.

Ул арада кунаклар өйгә шаулашып килеп керделәр һәм чишенеп түргә уздылар. Шәймәрдән агай кунакларга ияреп кайткан малаен ишек төбендә туктатып, аның колагына нидер пышылдап кына әйтте. Малае башта кече якка кереп чыкты, аннары, чүмеч белән су күтәреп, чаршау корылган мич артына кереп китте. Үзара шаулап сөйләшкән кунаклар аның нишләп йөрүенә игътибар да итеп тормадылар. Ә бераздан Шәймәрдән агай кунакларын кул юарга чакырды. Иң элек ул, билгеле, начальникка дәште:

— Иптәш Батыршин, рәхим итеп, менә монда узыгыз!

Начальник мич артына узгач, Шәймәрдән агай чаршаудан башын тыгып кына:

— Әнә сабын, менә сөлге,— диде, һәм кул югыч өстендәге кечкенә шүрлектә торган кырлы стаканга ияге белән генә ымлап өстәде: — Тегесе җылы су, авыз чайкарга, рәхим итегез!

Начальник башта сабынлап кулын юды, аннары шүрлектәге кырлы стаканны алып, авызына китерде, шуннан соң елмаеп башын чайкады да, күтәреп... эчеп тә җибәрде.

— Булды бу! — диде Шәймәрдән агай, эченнән генә бик кәефләнеп һәм, начальник, тамагын кыра-кыра, мич артыннан чыккач та, малаена кычкырды:

— Сәет, су өстә!

Башка кунакларны да ул үзе «кул юарга» чакырып, үзе мич артына кертә торды. Тик бер партком секретаре гына утырып калды. Ул әдәп саклап һәм нидер сизенеп, дәшкәнне көтә иде шикелле, ләкин Шәймәрдән агай көлгән булып, ниһаять, аңа әйтеп куйды:

— Сезне борчымыйбыз инде, секретарьларның куллары гадәттә чиста була, рәхим итеп, әнә түрдән узыгыз!

Шул чакта моңарчы елмаеп утырган начальник үзенең көр тавышы белән салмак кына әйтеп салмасынмы:

— Син, Шәймәрдән абзый, безнең секретарьны нигә аерып калдырасың әле? Без бит анда кул гына юмадык, ә кырлы стаканнан авызны да «чайкадык»... Ярамый болай!

Шәймәрдән агай башта аңламаган булып торды, аннары бурлаттай кызарды, ә кунаклар шаркылдап көлешә башлагач, ничектер берьюлы шиңеп төште.

— Анысы аның, теге ни, болай гына,— дип мыгырданды ул, сүз таба алмыйча,— әлеге шул кабул итмәс дигәннән генә, әгәр ярый икән, пажалысты, жәл түгел.

— Ник ярамасын, ул да кеше ич! — диде начальник.

Шәймәрдән агай секретарьга кыюсыз гына күтәрелеп карады.

— Алайса әйдәгез мич артына!

Секретарь кычкырып көлеп җибәрде:

— Ни өчен мич артына? Сезнең бүтән куркыр кешегез калмады бит инде.

— Соң, өстәлгә генә китериммени? — диде Шәймәрдән агай, баскан урынында таптанып.

— Үзең кара инде, син бит хуҗа кеше!

Шәймәрдән агай оятыннан нишләргә белмичә бераз җилкәсен кашып торды, аннары кинәт кенә: «Хатын, давай, казыңны чыгар!» — дип кычкырды да, барып, мич артыннан шешәләрен өстәлгә китереп куйды... Суйды бу начальник, кычкыртып суйды! Гомерендә әле аның мондый хурлыкка төшкәне юк иде.

Кунаклар, берни булмагандай, кәефләнеп ашадылар-эчтеләр, үзара күңелле генә сөйләшеп, көлешеп утырдылар. Бигрәк тә начальникның теле ачылды. Ул «Терәк» колхозын бераз мактады да, бераз гына яманлады да, ә Шәймәрдән агайга төбәп: «Көтәбез әле без аңардан, көтәбез. Теләсә, хикмәтләр уйлап чыгара белә икән ул!» —дип төрттереп тә куйгалады.

Шәймәрдән агай боларны әллә ишетте, әллә юк, тик шунда эченнән генә: «Сакаллы дурак, сакаллы дурак, сиңа шул кирәк!» — дип, үзен сүгеп утыра бирде.

1963

# Әзер хикәя

Бервакытны мин «Чулпан» колхозы председателе Сәхәби иптәштән сорадым:

— Әйтегез әле, колхозны аяктан егар өчен председатель нишләргә тиеш?

— Күп йокларга,— диде Сәхәби иптәш, ике генә сүз белән.

Шуннан соң мин сорауны киресенчә китереп куйдым:

— Ә аякка бастырыр өчен?

Әлбәттә, ул «аз йокларга» дип әйтмәде, озак кына дәшми торды, борын очын кашып алды, аннары яшерен-авыр гына сулап куйды да болай диде:

— Монысы инде, туган, бер председательдән генә тормый. Монда эт эткә, эт койрыкка бәйләнеп беткән. Кемдер синең койрыгыңнан тота, син кемнеңдер койрыгыннан тотасың — шулай тотышып бер түгәрәк тирәсендә әйләнәсең дә әйләнәсең... Ә шулай да председатель — «төп фигура». Әгәр фигураның башы үгезнекедәй нык, үзе хәйләкәр, чегәндәй тынгысыз булса, ул күп нәрсә эшли ала. Мактанудан түгел, ә мисал итеп кенә мин сезгә бер кызыклы вакыйга сөйлим әле... Түлке, зинһар, блокнотыгызны чыгармагыз, бу ике арада гына калырга тиеш.

Сәхәби иптәш, гадәтенчә, күзләрен хәйләкәр генә кыса төшеп, «килештекме» дигәндәй, миңа беравык карап торды. Мин, билгеле инде, аны тынычландырырга ашыктым. Шуннан соң ул сөйләп китте.

— Моннан берничә ел элек, иске акча заманында булды бу эш. Минем дә каладан яңа килеп, колхозның чиләнеп беткән төеннәрен тырнак белән генә түгел, теш белән дә чишә алмыйча азапланып йөргән чагым... Яз керде, малларга курмы юк, сатып алырга акча да юк, суярга яки сатарга бернинди права да юк. Әмма үтерергә ярый, моңа права бар, тик актларың гына форма буенча төзелгән булсын. Ләкин күрәләтә торып җан иясен ачтан үтертәсе килми бит, парин! Нишләргә?.. Уйлыйм, барган җирдән урам уртасында туктап та уйлыйм, ашарга кайткач, кашыкны авызга китереп җиткерә алмыйча да уйланып калам. Баш кына чыдасын!

Шуннан, көннәрдән бер көнне «газик»ка утырдым да Өчиледәге Заготскотка киттем. Директоры, Шәмсетдинов, таныш кеше. Аның дуңгызлар фермасы бар. Туктале, мин әйтәм, барып карыйм әле, кәпәчләренә нәрсә ашаталар, нәрсә эчертәләр икән, дим. Болай ни дә булса өмет итеп баруым түгел инде, тәк, аптыраган үрдәк хәленә төшкәнгә күрә генә,— ул заманда бит минем ише каңгырап йөрүче председательләр күп иде.

...Машина белән туп-туры фермасына барып туктадым, киң ишектән абзарына атлап кердем. Араннарда дуңгызлар, алларында ялгашлар, нидер кетер-кетер ашыйлар бу ак керфекле чибәрләр. Иелебрәк карасам — карабодай!.. Тәк, тәк! Ләкин ни өчен карабодай?.. Байлыктанмы бу, хәерчелектәнме?.. Хикмәт шунда: яз көне дуңгызларга карабодайның үзен түгел, саламын да ашатырга ярамый — ак тиреләре кояштан пешә башлый. Шундый авыру бар... Туктале, мин әйтәм, бу рационның серен белим әле. Киттем Шәмсетдиновның үзенә. Кердем, күрештем.

— Ни хәлләр? — мин әйтәм.

— Ничава,— ди бу, ләкин чырае караңгы малайның.

— Барамы?

— Бара,— дигән була.

— Әле,— мин әйтәм,— дуңгызларыгызны карап чыктым. Карабодайда гына тотасыз икән үзләрен.

— Нишлисең,— ди Шәмсетдинов, җилкәсен җыерып,— бүтән азык булмагач.

«Әһә,— дим эчемнән генә,— бу бичараның да көймәсе комга терәлгән икән!» Шунда ук башыма бик шәп бер уй килде.

— Карале, Шәмсетдинов,— мин әйтәм,— карабодай ашатып дуңгызларыңны син авыруга саттырасың бит, беләсеңме шуны?

— Беләм,— ди бу, теш арасыннан гына.

Үзенә бераз карап тордым да, дусларча хәленә кергән булып, әйттем моңа:

— Вәт нәрсә, агай-эне, миннән бер яхшылык булсын, дуңгызларыңа мин бик әйбәт азык табып бирәм.

— Нәрсә ул?

— Борчак. Ярылган, эше беткән борчак... Кәпәчләр аның өчен үләләр дә китәләр.
— Китче,— ди Шәмсетдинов, берьюлы яктырып.—Кайдан табып бирәсең?
— Үземдә бар.
— Шулаймыни?.. Күпмедән?
— Юк, мин сатып бирмим. Карабодаеңа алышабыз.
«Алышабыз» дигәч, киреләнә башламасын дип куркыбрак торган идем дә, юк, киреләнмәде тагын, ничектер ансат кына риза булды бу...
— Түлке,— мин әйтәм, тагы да батыраебрак,— синең карабодаеңны суыртасы бар, шуңа күрә ун процент өстәп бирәсең.
— Йә, йә, син бөгештермә инде, агайне! — ди Шәмсетдинов.— Нинди процент ул тагын, башма-баш!
— Юк, булмый,— мин әйтәм,— миңа кибәге кирәкми, кибәге өчен өстисең...
Ахрысы, карабодайдан бик туйган бу, бераз кашынса да озак тартышып тормады. Шулай итеп, килештек моның белән: минем биш тонна борчакка биш ярым тонна карабодай бирергә булды. Тик миннән эшне тизрәк әйләндерүемне сорап калды.
Шәмсетдиновтан чыккач та, мин шофер Галәвигә туп-туры шәһәргә, мельтрестка чаптырырга куштым. Юлда барышлый минем башта бик шәп коммерческий план туып өлгергән иде инде.
Кырык минуттан без тегермән капкасы төбенә килеп тә туктадык. Моның да директоры, Иван Савелич Салганик, күз күргән кеше.
Кабинетына барып кердем. Дусларча ике кулын сузып, «Наше — вам!» дигән булып күрештем үзе белән, аннары, эшемнең бик тыгыз булуын юри сиздерергә теләп, туп-туры әйттем үзенә:
— Иван Савелич, друг, бер изгелек эшләле минем колхозга... Алты тонна карабодаем бар, шуны, пожалысты, тиз генә суыртып бир әле.
— Нәрсә, ут каптымы әллә? — ди бу, сабыр гына.
— Капты, яна, бөтен нәрсә эри-ага, юллар да өзелергә тора... Син, Савелич, положениегә кер инде.
Ашыкмый, каһәр! Ныграк ян әле дигәндәй, мыекларын сыпыргалап тик утыра. Күземне алмыйча көтәм... Ахырда бу мөгрәнеп кенә әйтеп куя:
— Ярый, китерерсең булмаса.
Иван Савелич каршында артык биеп тормадым инде, тизрәк машинага йөгердем.
— Хәзер, Галәви, җанкисәгем, коопторгка элдертик! Коопторг директоры Әхмәдиев исә үзебезнең күптәнге малай. Минем белән бер вакытта колхозга китәргә тиеш иде, ләкин этләшә торгач, ничектер шушы коопторгында утырып калды. Очрашкан чакларда бу миңа, колониягә эләккән кешегә карагандай, бераз кызганып та, куркып та карый торган иде. Тик бер дә урынында тотып булмый үзен. Әмма изге юлга чыкканмын икән, парин! Аны да кабинетында туры китердем. Эре генә барып кердем, күрештем, киерелә биреп каршысына утырдым. Ашыкмыйча гына анысын-монысын сорашам,— күпме утырсам да бу чыдаячак... Инде кузгалам дигәндә, гүя болай гына әйтеп куйдым:
— Да, онытa язганмын, сиңа, дус кеше, карабодай кирәкмиме?
— Карабодай?
— Әйе, карабодай. Үзебездән бераз артып калганы бар иде, килешсәк, могу сатарга.
Әхмәдиевнең күзләре, караңгыда утырган мәченеке төсле, шунда ук яшькелтләнеп кабынып китте.
— Күпме соң ул синдә?
— Бер биш тонна чыгарырмын... Суыртылган, эше беткән, энҗе бөртегедәй менә. Жәл дә инде, ну...
— Ә күпмедән бирмәкче буласың?
— Килосы җиде сумнан.
— Ай-һай, чамасыз каерасың,— ди бу, көлгән булып.
— Бер дә чамасыз түгел. Базарга чыгарсам, мин аны, беләсеңме, күпмедән сатам?
— Базар! Базар белән куркытма әле син!
— Куркытмыйм, ләкин минем өчен кем алса да барыбер. Тик әле үз кеше, әйдә, миннән бер файда күрсен дип, иң элек сиңа әйтергә булдым. Җаеңа карыйсың. Хуш!
— Тукта, тукта,— ди Әхмәдиев, минем җилкәмнән басып.— Ашыкма!.. Йә, алты сумнан килештекме?
— Булмый.
— Ә ничек була соң?
— Мин әйткәнчә — җиде сумнан. Әхмәдиев миңа озак кына карап торды да кулын селтәде.
— Эт каешы икәнсең, ярар, син дигәнчә булсын! Кайчан китерәсең?
— Берсекөнгә хәбәр итәрмен... Түлке синнән шул: карабодайны китерү белән, акчасын минем счетка күчерәсең. Вәгъдәме?
— Булды — вәгъдә!
Шулай итеп, Әхмәдиев белән дә кулны кулга сугып, эшне өзеп, килешеп чыктым. Күрәсез, бөтенесе дә майлагандай шоп-шома барды. Инде хәзер эш пүчтәктә генә калды: борчак табарга кирәк... Хуш!.. Нигә көләсез? Юк, сез көләргә ашыкмагыз әле, тыңлап бетерегез... Дөресен генә әйткәндә, мин ул борчакны бер элеватордан тапкан идем инде, тоннасы алтмыш сумнан гына, ләкин минем түләп алырга сукыр бер тиен

дә акчам юк иде. Ә хәзер акча булачак. Моның өчен нишләргә кирәк иде?.. Әхмәдиевтән чыккач та мин шул элеваторга чаптым. Барып, сразы ун тоннага счет яздырып алдым, акчасы берсекөннән калмас, керер, дидем, ләкин борчакны иртәгәдән үк җибәрә башлагыз, юл өзелергә тора, положение критически, дидем. Күнделәр, яртысын бирә торырга булдылар. Ә миңа шул гына кирәк тә иде... Озын сүзнең кыскасы, дускай, минем бу планым борып җибәргән кебек эшли дә башлады. Икенче көнне иртән иртүк борчак элеватордан Заготскотка китте, Заготскотның карабодае тегермәнгә китеп барды, аннан чыгып коопторгка барып керде. Ә бер атнадан колхоз счетында утыз биш мең сум акча ята иде инде. Берьюлы иркен сулыш алдык. Акча булгач, азрак печәнен дә таптык, концентратын да, борчаклы да булдык. Малларның күзләре ачыла төште, дуңгызлар да чабудан тешләп тартмый башладылар.

Сәхәби иптәш сөйләвеннән туктады да миңа туры гына карап: «Менә шулай ул!» — дип әйтергә теләгәндәй, башын кагып куйды. Мин исә эчемнән генә: «Шайтан алгыры, әзер хикәя бит бу»,— дип уйлап утыра идем. Ул, шуны сизгәндәй, тагын ашыгып:

— Сез, зинһар, бу турыда яза күрмәгез,— диде.— Йә мактана дип әйтерләр... Соравыгызга мисал итеп кенә сөйләдем мин моны... Авыр хәлдән чыгар өчен колхоз председателе, бичара, кайчак ниләр генә эшләп ташламый, аларны яза китсәң, һи-и! — Сәхәби иптәш сулагай кулын гына селтәде.

Ә минем күңелемдә һаман бер генә кайгы: юк, түзеп булмас моны язмыйча. Күрәсез, түзмәдем. Сәхәби иптәш гафу итсен, үзе гаепле. Язучыга ышанырга ярыймы соң! Ул да бит, җае чыкса, эләктереп алырга гына тора.

1964

# Әҗәл дигәнең

Әйе, каян килә бу әҗәл дигәнең? Кеше аны үзе чакырып китерәме, әллә чакырмасаң да килеп җитәме ул? Котылып булмый аңардан, әллә бер эләктереп алса, ычкынып булмыймы? Юк, чынлап та нәрсә ул серле-хәтәр сүз — әҗәл дигәнең?

Пләтән башындагы «Вторсырье» алачыгы янына күрше-тирәдән чыгып утырган берише агай-эне арасында бүген сүз нәкъ шул турыда бара. Сүзне кем нәрсәдән башлап җибәргәндер — анысы намәгълүм, ә хәзер исә алачык күләгәсенә чүгәләшкән агайларга «Вторсырье» приемщигы Коддус әҗәл мәсьәләсендә бик гыйбрәтле бер кыйсса сөйләп утыра:

— Сез, агай-эне, теге Фәхри картны беләсездер инде... Кайсы Фәхри, имеш, тагын... Әлеге миңа утил җыеп китерүче озын, шадра картны әйтәм ләса. Соң!.. Акком астында, Чүкет Ибрайлар белән бер ишегалдында тора. Малае да бар, Сәхәп, шофер. Соң!..

— Ә, әйе, белдек, хуш, сөйлә! — диештеләр агайлар. Бусагада утырган Коддус башта ике аягы арасына төкереп, папиросын сүндерде, җилле генә чиртеп җибәрде, шуннан соң ашыкмыйча, тәмләп кенә, төп вакыйганың үзен сөйләргә керешә:

— Былтыр булды бу хәл... Шулай, көннәрдән бер көнне минем янга Фәхри карт килеп чыкты. Мин тышта ларек тирәсен себереп йөри идем... Килде бу, сәлам-фәлән юк, таягын җиргә терәп, миңа тик карап тора бу. Нихәл, Фәхри абзый, мин әйтәм, бу арада күренмисең, «товар» да китергәнең юк, нишләп кенә йөрисең, мин әйтәм. Дәшми карт, сөзәргә җыенган үгез төсле башын иебрәк басып тора да тора... Карыйм мин моңа, әллә ничек кенә шунда, йөзе дә агарынган, күзләре дә акайган, мыегы да сәлперәеп төшкән моның... «Ни булды, Фәхри абзый, әллә авырыйсыңмы?» — мин әйтәм. Шуннан бу тирә-ягына каранып алды да әкрен генә әйтеп куйды: «Әйдә, эчкә керик әле, шунда мин сиңа әйтермен ни булганын!..» Кердек. Чүпрәкләр тутырып куйган бер капчык өстенә утырды бу, миңа да якынрак утырырга кушты. Шуннан соң таягын бераз ышкып торды да кинәт кенә миңа таба иелде бу: «Иң әүвәлтен, Коддус энем, ант ит!» — ди. Мин аптырап киттем: «Нинди ант ул, нәрсә өчен?» — мин әйтәм... «Хәзер мин сөйләгәннәрне берәүгә дә әйтмәм дип ант ит! Йә, йә, Алла исеме белән ант ит! Мин сиңа бик зур серемне ачам хәзер»,—ди. «Куй әле, Фәхри абзый, мин ант итә белмим, сөйләсәң — болай гына сөйлә, сөйләмәсәң как хош!» —мин әйтәм. «Юк, сөйлим,— ди,— сөйләмичә кала алмыйм,— ди,— тик син хайван булма, кеше бул,— ди,—давай ант ит!» Менәтерә генәсе, өзми дә куймый бит бу үзенең антын. Чүт талашып китмәдек. Ахырда, әйдә, картның күңеле булсын дип, мин: «Валлаһи-билләһи, торган урынымда яшен суксын, җир йотсын...» — дип тезеп киткән булдым.

Шуннан соң бу миңа, тагы да иелә төшеп, пышылдап кына әйтте: «Мин хәзинә таптым!» — «Хәзинә?» — «Әйе, хәзинә!» — «Нинди хәзинә?» — «Нинди хәзинә икәнен хәзер белерсең»,— ди бу, ә үзе агарынган күзләре белән, ашарга җыенгандай, миңа тик карап тора. Түзмәдем, сөйләсәң тизрәк сөйлә, мин әйтәм, ничу, мин әйтәм, монда кешенең нервысы белән уйнарга!.. Шуннан Фәхри абзый торып, ишектән башын тыгып, урамга бер карап алды да, яңадан кап өстенә утырып, пышылдап кына сөйли башлады. Сөйләгәндә үзе һаман минем якамнан борып тота, прәме менә буа язды...

«Тыңла син, әйбәтләп ике колагың белән дә тыңла! Яме!.. Шулай атна кич иртәнге чәйдән соң капчыгымны култык астына кыстырдым да Бакалтай ягына чыгып киттем. Ул тирәләрдә ниләр бар икән дип, бер йөреп кайтасым килде. Үзең беләсең, Коддус, шәһәр эчендә хәзер чүпрәк тә, сөяк та алай бик аунап ятмый — малай-салай җыеп бетерә. Әмма ләкин шәһәр чүбен Бакалтайга да күптән чыгармыйлар икән,— бардым, йөрдем, берни тапмыйча кире борылдым... Бер сай чокыр буйлап кайтып килә́м. Эссе, бөркү, тузан... Ни тарган сиңа, карт дүрәккә, мондый көнне эт шикелле телеңне сәлендереп йөрергә дип, үземне эчемнән бертуктамый сүгәм. Менә бит ул адәм баласының сукырлыгы! Ходай Тәгалә үзе мине Бакалтай тарафларына юнәлдергән, ә мин... Туктале, Коддус, авызыңны ермале син!.. Әүвәле тыңла син, тыңла, Алланың дәргаһыннан сөрелгән бәндә!.. Зиһенемне чуалтасың... Ни әйтмәкче идем әле?.. Әйе, менә шул, бара торгач, карт кешене беләсең, кысталдым да чокырга төштем. Җиңелгә генә... Инде шуннан, аяклардагы тузан үләндә бераз ышкылсын әле дип, чокыр төбеннән киттем... Егерме-утыз адым да китмәгәнмендер, хикмәте Хода, таягым бер каты әйбергә төртелде. Туктап, юри генә шакып караган булдым,— таш түгел, тимер бу... Шуннан, нәрсә икән соң бу дип, таягым белән читләрен тырнаштыра башладым. Ул да булмады, бер тимер тартмамы, сандыкмы кебек нәстәнең почмагы күренде. Тукта, мин әйтәм, хикмәтле әйбергә охшый бит бу, әйбәтләбрәк карыйм әле, мин әйтәм. Бисмилла әйтеп тезләндем дә таягымның очы белән моны, як-ягыннан әйләндереп, казырга тотындым. Зур нәрсә түгел икән, азрак казыгач та тоткалы бер башы килеп тә чыкты... Моны күргәч, йөрәгем дөп-дөп тибә, кулым калтырый башлады. Йа Алла, йа мәүлә, мин әйтәм, ярдәмеңнән ташлама, куәт кенә бирә күр!.. Тыңлыйсыңмы син, Коддус? Тыңла, туган, тыңла!.. Казый торгач, моның астына да җиттем, икенче башын да туфрактан арчыдым... Киерелеп бер тын алдым... Шуннан соң әгузе-бисмилла әйтеп, тоткасыннан тартып чыгардым мин моны... Әһә, үләт кыргыры нәрсә! Күптән ятасың ахры, бөтенләй тутыгып беткәнсең икән!.. Нәрсә, дисеңме? Бәй, әйтмәдеммени әле? Тимер сандык инде, җаным-бәгърем, тимер сандык!.. Күтәреп карыйм, шактый авыр үзе, Ходай орган нәрсә! Бикле, алай-болай гына ачарлык түгел. Чокыр төбендә әллә нишләтеп булмый, тиз генә капчыкны сүттем дә салдым мин моны капчык эченә... Инде кая илтергә? Уйланып тордым да өйгә алып кайтырга булдым... Аулак урамнардан мыштым гына тирләп-пешеп кайтып җиттем. Ярый әле малай белән килен эштәләр, өйдә берәү дә юк, Алланың рәхмәте белән, барсы да җай килеп кенә тора. Утынлыктан балта алып кердем дә, эчтән бикләнеп, идәнгә тезләнеп, сандыкны ачарга булдым. Башта иске ачкычлар белән мәтәштереп карадым,—булмый, биге тутыгып беткән... Аннары балтага тотындым... Коддус, тыңла син, атаңа нәләт!.. Сандыкны әйләндергән-тулгандырган саен эчендә нәрсәдер шалтыр да шолтыр йөри. Бар, мин әйтәм, монда хикмәтләр, бар! Азапланып, кара тиргә батып, эт булып беттем. Ахырда, каергалый-суккалый торгач, ачылып китте бу иблис тартмасы!.. Йа Алла, йа мәүлә, йа кадир!.. Күреп, шаклар гына каттым да калдым: сандык эче тулы алтын тәңкә!.. Син беләсеңме, Коддус, алтынның нәрсә икәнен? Төшеңә кергәне бармы? Син — йолкыш, үтил чүбе, хәерче тәресе!.. Тәүбә, тәүбә!.. Ачуланма, туган, иблис телемне бутый!.. Менә шул: туп-тулы алтын тәңкә! Уч төбе хәтлеләре дә бар, бармак битедәй кечкенәләре дә бар... Төрлесеннән... Кайсында әби патша сурәте, кайсында Питр сурәте. Әләксәндернеке дә, үзебезнең дурак Николайныкы да, әлхасыйль, бөтен патша җәнапләренең сурәтләре бар... Тәңкәләрне бер уч тутырып алдым да, түзмәдем, җылап та, көлеп тә җибәрдем. Утильщик Фәхри кулында хәзинә! Хәзинәкәй! Хәзинәбану, сылуым иркәм! Хи-хи-хи! Тукта, нәрсә син миңа күзләреңне акайттың?.. Матри!.. Ату мин...

Уф-ф, кайда, синең башлап куйганың була торган иде, сырлы стаканыңны тутырып бир әле, киптем!»

...Карт белеп сорый, минем шкафтан бер дә өзелми ул, тиз генә салып бирдем моңа. Залпым эчте бу, ә мин аңа елышып, иплэп кенә сорыйм: «Фәхри абзый, әйтче, бәгърем, нишләттең син аны, кая куйдың?» — «Ә-ә, беләсең киләмени, мөртәт? — ди карт, бармак янап.— Юк инде, белми генә тор әле, яме! Эрәгә нәфесеңне сузма! Бик ерак җыйдым мин аны, ай-һай ерак, иблис үзе дә таба алмас!.. Иллә-мәгәр шулай да мин менә сиңа килдем әле. Син кирәксең миңа... Сандык турында берәү дә белми, хәтта малай белән киленгә дә әйтмәдем. Белмәссең бу заман яшьләрен, тотарлар да җәвит итәрләр... Менә беренче башлап әйтүем сиңа гына, аңлыйсыңмы шуны, сиңа гына! Дөньяда бүтән берәү дә белергә тиеш түгел, ишетсен колагың! Ләхет бул, ярыймы? Ә сиңа әйтүем менә ни өчен: тәңкәләрне акрынлап тәгәрәтергә кирәк. Аңлыйсыңмы?.. Вәт, син миңа шул эштә булыш. Мин сине буш итмәм, өлеш чыгарырмын... Күпме, имеш? Мондый эштә күпме дип сорап тормыйлар, дүрәк! Баш өсте, Фәхретдин абзыкаем, дип урталай бөгеләләр. Аңладыңмы?» — «Аңладым, Фәхри абзыкаем!» — «Аңласаң, менә шул! Давай, Аллага тапшырып, кыймылдый башла. Синең монда, чүп-чар оясында, нишләп ятканыңны күрүче булмас, шәт! Әмма шулай да сак бул! Белер-белмәс кешегә ычкындырсаң, бугазыңнан алырмын... Йә, ярар. Мин киттем. Безнең монда сөйләшкәнне ай күрде, кояш алды, яме!.. Аллага тапшырдык! Бер дүрт-биш көннән тагын әйләнермен...» Шулай диде дә Фәхри абзыкаем, танавын-битен пинҗәк чабуы белән сөрткәләп, ава-түнә ларектан чыгып та китте. Ә мин... мин, ни, баскан җиремдә авызымны ачып, багана шикелле каттым да калдым.

— Хуш-ш! — дип сузды тыңлап утыручыларның берсе.— Ә әҗәл кайда, әҗәл юк бит әле монда...

— Тукта, сабыр ит, Сөнгать абый, хәзер әҗәле дә булыр,— диде Коддус, сәер генә аркасын уйнаткалап.—Иң элек шуны әйтим әле, карт чыгып киткәч тә мин, ни сәбәптәндер, кашына башладым.

Бөтен җирем кычытып кына кычыта бит, түзәрлек кенә дә түгел, ике кулым, алмаш-тилмәш, йөреп кенә тора. Ә үзем һаман уйланам: нәрсә сөйләп китте соң әле бу карт, сандык, диде, алтын, диде, саташып кына йөрмиме икән, хыялга сабышып? Әгәр дә мәгәр чын була калса, нишләтергә соң аның ул сандыгын, барып җәвит итәргәме әллә үзен?.. Ике көн баш ваттым, ике көн корчаңгы тайдай кашындым... Ә өченче көннең иртәсендә картның малае Сәхәп, шофер, минем алачыкка йөгереп килде. Төсе-бите качкан малайның... «Коддус абый,— диде бу,—эти үлеп китте бит әле, нишлибез?..» Мин, балык шикелле, авызымны ачтым да калдым. Телем аңкавыма ябышты... «Ничек ул алай»,— дип кенә пышылдый алдым. «Шулай инде,— ди Сәхәп, җилкәсен җыерып,—кичтән күкрәген уып, ыңгырашып ятты-ятты да таң алдыннан аяк тә какты,— ди,— врач та чакыртырга өлгермәдек»,— ди... Шуннан кинәт кычкырып җибәрүемне үзем дә сизми калдым: «Ә сандык,— мин әйтәм,— ә хәзинә?!»

Сәхәп, күзләрен чикләвектәй түгәрәкләндереп, миңа карап тора: «Нинди сандык, нинди хәзинә ул, без бернәрсә дә белмибез»,— ди. «Соң,— мин әйтәм,— этиең карт үләр алдыннан, саташып кына булса да, әйтеп ташламадымыни?..» — «Юк, юк, әйтмәде,— ди Сәхәп, башын селкеп,— тик үләр алдыннан эти ни өчендер сезне генә телгә алды»,— ди.— «Йә, йә, нәрсә дип?» —«Нәрсә дипме?.. Шулай төнлә белән бу, мәрхүм, бер-ике тапкыр кинәт урыныннан йолкынып: «Коддус, матри! Коддус, атаңа нәләт, авызыңнан ычкындырасы булма!» — дип кычкырды да, хәлсезләнеп, кире түшәгенә ауды. Без, ни, берни дә аңламадык, саташа бу, дип кенә уйладык. Шуннан соң инде озак та тормады...» Мин, тез буыннарым йомшарып, бусагага утырдым. «И-их, Фәхри абзыкаем, Фәхри абзыкаем,—дим, күкрәгемне тырнап,— хәзинә түгел, үз башыңа әҗәл генә тапкансың икән син, әҗәл генә!.. Тик менә кайда гына яшереп калдырдың икән син ул тимер сандыкны, чукынган карт?»

Коддус кисәк кенә сөйләвеннән туктады да ашыгып ике ботын ышкырга тотынды. Кемдер шунда аңардан сорап куйды:

— Ә кашыну бетмәдемени әле?

Коддус сораучыга җәһәт кенә ачулы бер караш ташлады:

— Бетте, ник бетмәсен, шунда ук бетте. Карт та юк, хәзинә дә юк, ни пычагыма кашынырга?

Агайлар башларын каккалап, авызларын кыймылдаткалап сүз әйтергә ашыкмыйча бераз фикер җыеп утырдылар. Аннары берсе, җиңел генә сулап, әйтеп куйды:

— Алай-й, бичара картның әҗәле хәзинәдән булган икән, хәзинә табарга ярамый икән бу заманда!

Икенчесе шунда ук аңа каршы төште:

— Ник ярамасын, хәзинәне аны табарга яр-рый, тик тапканыңны кешегә генә әйтергә ярамый. Вәт әҗәлнең сәбәбе нәрсәдә!

Бүтәннәр үз сүзләрен әйтергә ашыкмадылар: бу ике фикернең кайсына кушылырга — шул хакта уйлыйлар иде әле алар.

1964

# Матурлык

*(Бер карт әдип авызыннан)*

Күптән, бик күптән булган вакыйга, әмма бүгенгедәй күз алдымда: без, өч шәкерт, бер атка утырып, өяз мәдрәсәсеннән авылыбызга кайтырга чыктык. Дөресрәге, Гыйлемдар белән без икәү бер авылга — Чуаркүлгә кайтабыз, ә Бәдретдинне юл өстендәге Ишле авылында калдырып китәргә тиешбез. Тагын шуны да әйтим, безне ялкау гына юыртып алып кайткан күк алаша Гыйлемдарларныкы иде. Без авылда алар белән күрше генә торабыз. Шул сәбәпле Гыйлемдар белән мине алырга бер язын безнең ат килсә, икенче язда алар аты килә торган иде.

Ә Бәдретдин безнең очраклы юлдашыбыз. Дөрес, без мәдрәсәгә бер вакытта җыелабыз, бер вакытта таралабыз, ләкин моңарчы аның белән бергә кайтырга туры килгәне юк иде әле. Бәдретдин кешегә бер дә йөк булырга яратмый иде. Укулар беткәч тә ул базарга килгән авылдашларының берсенә ияреп китә дә бара, яки ялгыз үзе генә утыз чакрымдагы авылына җәяүләп сыптыра торган иде. Бу юлы инде без аны, үзебез сорап дигәндәй, бергәләп кайтырга күндердек.

Бәдретдин безнең мәдрәсәдә иң ярлы шәкерт иде. Аңа авылыннан бернинди дә ярдәм килми иде. Тик Ишледән базарга килүче берәрсе бик сирәк кенә аңа әнисенең киндер чүпрәккә төреп җибәргән тары ипиен яки берәр йомарлам маен кертеп чыга торган иде. Бәдретдин шуны да бик кыенсынып: «Нигә инде бу? Әнкәйгә әйтегез, мин ач түгел, үзеннән өзеп җибәрмәсен!» — дип алып кала иде. Һәм шул майны ул ни өчендер без белән чәнчеп ашый иде. Шәкертләр аңардан: «Нигә алай итәсең?» — дип сорасалар, Бәдретдин көлгән булып кына: «Без белән ашагач, озакка җитә ул!» — дип җавап бирә торган иде.

Илдә чыпчык үлми дигәндәй, безнең Бәдретдин дә, бик интегеп, ачка киселеп булса да, укуын әнә шулай алып бара иде. Һәм бик яхшы укый иде ул. Хәер, бу күп сыналган нәрсә: рәхимсез нужада торып укыган ярлы шәкерт гадәттә бик сәләтле булып чыга. Башкача аңа мөмкин дә түгел. Бай шәкерт, әйтик, туң күчән булса да, мәдрәсәдә теләсә күпме ята ала, ә ярлы шәкерт, начар укыдымы, беренче кыштан ук

мәдрәсәдән очарга мәҗбүр була... Аннары, ярлы шәкерт бик яхшы укыса гына үзенең матди хәлен дә беркадәр җиңеләйтә ала.

Менә безнең Бәдретдингә дә, ул замандагы тел белән әйтсәк, истикамәтле вә иҗтиһатлы шәкерт булганга күрә, байлар иганәсеннән ара-тирә ярдәм тия иде; начар укучыларның дәресләрен хәзерләшкән өчен дә аңа аз-маз тама иде, хәлфәләргә дә ул булышкалый иде, аннары авыру-сырхауларга догалыклар, Аятел Көрсиләр күчереп тә азрак бакырлар төшергәли иде. Кыскасы, эшсез тормый иде шәкерт. Ләкин эшне дә, ярдәмне дә ул үзе бервакытта да сорап алмый иде. «Мин бит ярлы, миңа ярдәм итү сезнең вазифагыз» дигән әрсез мескенлекне без аның йөзендә беркайчан да күрмәдек.

Табигате белән үк ул, ничек дим, шундый тигез, сабыр холыклы бер егет иде. Ялагайлана да белмәс, масая да белмәс, яхшы белән яхшы, ә яман белән алыш-биреше юк — андыйлардан үзен ничектер бөтенләй читтә тота белә иде. Тагын шунысы кызык, никадәр генә ярлы булмасын, ул берәүдән дә бернәрсә дә сорарга яратмый иде. Гадәттә, шәкертләр аңардан гел анысын-монысын сорап торалар, чөнки аның үз кулы белән ясаган каеш тупсалы, әрҗә сыман сандыгында мәдрәсә тормышы өчен кирәк бөтен нәрсәсе — энәсе дә, җебе дә, уймагы да, безе дә, пәкесе дә, эскәге дә, көзгесе дә, төрле каләмнәре дә, кәгазь-дәфтәрләре дә, хәтта җилем белән балавызы да саклана торган иде. Ничек җыйгандыр ул аларны, ләкин һаман шул ярлылыгым кешегә йөк булмасын дип, тамагыннан өзеп булса да, тырышкан, күрәсең инде. Дөрес, ул калын-калын дәрес китапларына бик мохтаҗ иде. Ләкин булган кадәресен бик пөхтә тышлап, битләре керләнмәсен өчен көмеш кәгазьдән тоткыч ясап, кадерләп кенә саклый иде.

Ул заманда, ягъни революция алды елларында, шәкертләрнең яңа әдәбият белән мавыгуы искиткеч көчәйгән иде. Икмәк шикелле үк зарури бернәрсәгә әйләнеп киткән иде безнең өчен әдәбият!.. Һәрбер шәкерт төпләп алган калын дәфтәренә җыр күчерә, шигырь күчерә, хәтта романнардан өзекләр дә күчерә. Ике шәкертнең берсе шигырь яза. Бик күпләр Сәгыйть Рәми белән тилерә. Аңа ияреләр, аңа охшарга тырышалар, аны яттан сөйләп йөриләр... Дөрес, безнең барыбыз өчен дә бөтенесеннән өстен, бөтенесеннән якын — Тукай иде, иң күп күчерелгән, иң сөеп укылган да Тукай иде.

Шигырь чире безнең Бәдретдингә дә йоккан иде, ул да яза иде, ләкин язганын бервакытта да күтәреп, очраган берәүгә укып йөрми иде. Аны сорап та укырга күндерүе читен иде. Инде укый калса, аның әйберсе башкаларныкы төсле зар еламыйча гына язылган, күбрәк табигать күренешен гади генә сурәтләгән яки үзенчә берәр тормыш фәлсәфәсе әйтергә тырышкан кыска гына шигъри парча булып чыга торган иде.

Әнә шундый сәер генә, серле генә һәм сөйкемле генә бер егет иде безнең Бәдретдин шәриктәшебез!

Ярый, сүз озынга китте, без бит әле өчәүләшеп читән тарантаста хозур гына авылыбызга кайтып барабыз. Юл такыр, тузан юк, күк алаша, эченә кату төшүдән «горт-горт» иткән тавыш чыгарып, үз көенә салмак кына юырта... Күптән түгел, май урталарында, беренче җылы яңгырлар явып узган иде. Хәзер бөтен нәрсә дәррәү кузгалып, күтәрелеп, үсеп бара: арышлар сабакка сузыла башлаган, бодайлар куе булып, кучкыл-яшел булып, егетләр мыегыдай, сызылып кына чыгып килә; сөрелмәгән чирәмнәрдә яшь үлән былтыргы корыган үләнне басып, каплап та киткән, кайберләре инде чәчәкләрен дә ачарга өлгергән... Юл буенда әнә эт эчәгесенең беренче ал «кыңгыраулары»... Әйтәсе дә юк, табигатьнең иң саф, иң садә, иң ямьле чагы!..

Безгә, кыш буе мәдрәсәдә кибеп яткан шәкертләргә, бу чиксез иркен, якты, җылыкай дөнья искиткеч тансык иде, шифалы-рәхәт иде, без аны иснәп тә, сулап та, күзләребез белән күреп тә туя алмый идек. Баштарак без әледән-әле тарантастан төшеп, аякларыбыз җирнең җылысын бер рәхәтләнеп татысын дигәндәй, чирәмгә кереп киттек, йөгереште-куыштык, иелеп чәчәкләр өздек. Бәдретдин тау юасы тапты, аны өзеп чәйнәдек. Мин безнең авылда «тәмлекәй» дип йөртелә торган, сабагы дүрт кырлы, озын гына бер үсемлекне җыеп алдым. Аны да, тиресен суеп, ашап карадык. Бәдретдин әйтә, моны башкортларда «кияү камчысы» дип йөртәләр, ди, чөнки очындагы менә шушы бөреләре зәңгәр чәчәк булып ачылгач, ул чынлап та чуклы камчыга охшап китә, ди.

Ә безнең Гыйлемдар, озын сыйрак, гел йомран эзләп чапты, туктап, ике учын кушлап сызгырып та карады, ләкин хәйләкәр җәнлек шәкерт сызгырганын сизә иде ахрысы, оясыннан чыгып, колакларын торгызып, арт тәпиләренә утырмады.

...Юл буе безне тургайлар сайравы озатып барды. Гүя менә төпсез нурлы аяз күктән өстебезгә сихри бер моң тибрәнеп-чыңлап, өзлексез явып торды. Ә беләсезме, тургай сайравының сихере нәрсәдә?.. Иң элек, сынаганыгыз бардыр, тургай сайраганда җир өстенә җиңелчә генә уйчан-моңсу бер тынлык җәелә. Әйтерсең барлык табигать, барлык җан иясе, әдипләр әйткәнчә, сөкүт калып, тәмам мөкиббән китеп, бары аны гына тыңлый, аны тыңлап сөенечле, сагышлы, ләззәтле бер рәхәткә чума... Икенче сихере шунда ки, тургай сайраганда дөнья ничектер искиткеч җәелеп, киңәеп, яктырып киткәндәй була. Әнә шул югарыда кечкенә кошчык талпынган күкнең үзе шикелле үк, җир йөзе дә иксез-чиксез булып, гаҗәеп тын, нурлы булып тоела башлый...

Белмим, бу вакытта бүтән кошлар сайрый торгандырмы — игътибар иткәнем юк, әмма бер кошның тавышы, бөтен җир өсте тургайлар сайравыннан өзлексез чыңлап торса да, безне сискәндереп, колагыбызга килеп керә. Бу — кәккүк! Кешеләрнең исләренә нииндидер бик мөһим нәрсәне төшерер өчен

табигать тарафыннан яратылган күзгә күренмәс сәер кош!.. Юлдан шактый читтә торган күксел урман янында узганда, без аның да тынып калырга мәҗбүр иткән кисәтүле тавышын ишеттек.

Шулай кәефләнеп, күңелле генә кайта торгач, без, ниһаять, кызыл ярлы тауларга каршы тигез үзәнлектә сузылып утырган Ишле авылына да якынлаштык. Юлга чыккач та Бәдретдин безне, Ишледә туктап, чәй эчеп чыгарга чакырган иде. Без, билгеле, кыстатып тормадык, шәриктәшеңә кереп, чәй эчеп, күңел ачып чыгу шәкертләр өчен табигый бер низам инде ул.

Авылга җиткәндә генә Бәдретдин, дилбегәне үзенә алып, атны олы юлдан уңга каерды да бәбкә үләне түшәлгән җир өстеннән генә иң арткы урамга таба алып китте. Һәм озак та үтми, шул урамның иң читендәге, бүтән йортлардан аерылыбрак, ялгызы гына торган бер өйнең каршысына безне китереп тә туктатты.

Без фәкыйрь кешеләргә керәсебезне белеп килә идек, әмма бу кадәр ярлы хуҗалыкны күрербез дип һич тә көтмәгән идек. Хәер, моның хуҗалык дип атар җире дә юк иде. Шыр кырда утырган бәләкәй генә ялгыз өй үзе искереп-тузып, яртылаш җиргә кереп беткән. Салам түбәсе череп, каралып, тирескә әйләнә башлаган. Әйтерсең шуның авырлыгыннан өйнең кайбер бүрәнәләре бүселеп чыккан, ишек-тәрәзәләре кыйшайган, ә тәрәзә пыялалары тора-тора инде яшькелт-зәңгәр төскә кергән... Капка юк, койма юк, тик урам яклап та кыр яклап кына ике рәт киртә сузылган... Ишегалдын кыр үләне басып киткән. Анда чикерткәләр тыз-быз сикерешәләр. Димәк, бернинди аяклы мал да юк.

Без инде хәйран булып, гаҗәпләнеп калуыбызны Бәдретдиннең үзенә ничек тә сиздермәскә тырыштык. Арба эзе төшмәгән ачык ишегалдына узып, түбәсе чыбык-чабыклар белән ябылган иске генә бер читән абзар алдында атыбызны туктаттык. Өйдән кечерәк буйлы, ак чырайлы, җирән сакаллы, арык-өшән генә бер абзый чыкты. Аның өстендә киндер күлмәк, тез башларына зур ямаулар салынган киҗеле ыштан, башында мескен бүрек, аякларында тула оек белән тузган чабаталар иде. Ул, тарантас янына килеп, бары: «Улым!» — дип кенә Бәдретдин белән күреште, аннары безгә дә шулай сүзсез генә ике кулын сузды һәм шунда ук ат башына барып, аны тугара да башлады...

Бәдретдин сандыгын күтәреп өйгә ашыкты. Өй ишегендә бер хатын күренде, ләкин ул ни өчендер тиз генә кире борылды. Бу — Бәдретдиннең әнисе булгандыр инде, тик менә аның ишектән чыгар-чыкмас кире чигенүе безне бераз гаҗәпләндерде.

Атны тугарып бетүгә, Бәдретдин өйдән чиләк белән су, чүмеч һәм тастымал күтәреп чыкты. Чирәм өстендә генә чиләктән бер беребезгә су коеп юынып алдык. Күңелгә: «Комганнары да юк, күрәсең»,— дигән уй килде. Һәм без бернәрсә күрмәгән, белмәгән булып кыланырга яки ваемсыз гына сөйләнергә ничектер сүз дә, сәләт тә таба алмый идек. Ләкин Бәдретдин үзе тыныч иде, һәрхәлдә, оялу-уңайсызлану кебек бернәрсә дә сиздерми иде.

Юынып беткәч, сәлам биреп, өйгә кердек. Бәдретдиннең әтисе бер читтәрәк торган килеш безне бик гади генә: «Әйдәгез, шәкертләр!» — дип каршы алды.

Караңгырак кына өй эче дә тышкы ягы кебек үк искереп, тузып беткән икән инде. Ләкин күпме генә искереп-тузып бетмәсен, аның бүрәнәләре тома балавыздай сары-көрән иде әле, тапталып, кырылып ашалган идәне дә чип-чиста иде... Өйнең бөтен түрен иңләп, өстенә киез җәелгән зур сәке тора, ике урындык, бер эскәмия, мич буенда тагын бер бүкән тора — менә җиһаз дигәне бары шул гына. Мич алды иске генә чүпрәк чаршау белән бүленгән, анда кемнеңдер озын гына итеп чыра телүе ишетелә.

Өйгә кергәч тә безнең иң элек күргән кешебез сәке түрендә, стенага терәлеп, текә генә утырган бер бабай булды. Бабай Хозыр Ильяс төсле ап-ак сакаллы, ап-ак күлмәк-ыштаннан иде. Бары тик башындагы беленгә әйләнгән түбәтәе генә аның күксел-кара иде.

Без бабайга күрешер өчен кулларыбызны суздык. Бабай селкенмәде. Бәдретдин ашыгып әйтеп куйды:

— Бабакай, шәкертләр синең белән күрешергә телиләр.

— Ә, шулаймыни, бәрәкалла! — диде бабай, аз гына җанланып, һәм безгә кипкән, зур каты кулларын сузды. Күзләре ачык булса да, ул дөм сукыр иде.

Без утырышып дога кылдык һәм, шәкертләрчә кулларыбызны тез өстенә куеп, бер мәлгә тынып калдык. Безнең үзебезгә сүз башлавы, билгеле, кыенрак иде, аннары нидер менә телебезне һаман бәйләп тора иде. Ләкин, гаҗәп хәл, хуҗалар үзләре дә сүзсезләр иде. Гомумән, бу өйдә сүз бик аз сөйләнә булса кирәк —ничектер бик тиз без шуны сизгәндәй булдык. Бабай, үзенең эчке дөньясына киткәндәй, текә каткан килеш тып-тын утыра. Бәдретдин әрле-бирле йөренә, нидер әйтмәкче дә шикелле, ләкин сүз таба алмый кебек... Әтисе башта мич буендагы бүкәндә безгә бераз шаккатып утырды да, аннары, торып, сәке кырыена чәй урыны әзерли башлады. Иске генә киҗеле ашъяулык китереп җәйде, мич кашагасыннан кайсы замазка белән ябыштырылган, кайсының сабы кителеп төшкән өч кенә чынаяк алып куйды, кыска гына чалгы пычагы, чүпрәккә төргән ярты ипи, тустаган белән сөт китереп куйды. Шуннан соң тагын бүкәненә барып утырды. Бәдретдин үзенең сандыгыннан бер-ике уч шикәр алып, шуны ашъяулык уртасына салды.

Бераздан чаршау эченнән әкрен генә: «Булды, улым!» — дигән сүз ишетелде. Бәдретдин, кереп, самоварны алып чыкты. Бу самоварның да борын һәм колак төпләре кургашын белән ямалып беткән иде.

Бәдретдин безгә сәкегә менеп утырырга кушты. Без, менеп, аякларны бөкләп утырдык. Шуннан соң алдыбызга өчаяк белән йомырка тәбәсе килде. Без әле ашка сузылмыйча хуҗаларның утырганын көтә идек. Ләкин бабай да урыныннан кузгалмады, абзый кеше дә бүкәненнән тормады. Шул чагында Бәдретдин, йомшак кына, чаршау эченә дәште:

— Әнкәй, чәй ясарга үзең чык инде.

— Әткәң соң? — диде чаршау эченнән әнисе, акрын гына.

— Әткәйме?.. Юк, син үзең яса инде безгә,— диде Бәдретдин, ничектер бик ихластан үтенгәндәй итеп.

Чаршау эче бераз тынып торды, аннары киндер күлмәк өстеннән шундый ук киндер алъяпкыч буган, оек-чабаталы хатын ситсы яулыгының читләрен битенә тартып һәм башын иеп кенә чыкты да самовар артынарак килеп утырды.

Аңа күтәрелеп карагач та минем йөрәк әллә нишләп китте. Дөресрәге, яшермичә әйтим, бер чиркану тойгысы йөрәкне өшетеп җибәргәндәй булды: бичара хатынның бөтен битен-күзен кайчандыр кичергән рәхимсез чәчәк зәхмәте тәмам бозып бетергән иде. Өстенә карап, моны сурәтләп торуы авыр, ничектер тел бармый, ләкин шулай да сул күзенең бөтенләй кысылып, ә уң күзенең иләмсез зураеп калуын әйтмичә булдыра алмыйм, чөнки шушы яшь пәрдәсе аша караган кашсыз-керфексез күзендә бичараның бөтен эчке җаны чагылырга гына тора кебек иде. Әйтерсең бу һич йомылмас яшьле-моңсу күз аның шәрәләнеп калган бердәнбер күңел көзгесе!

Аны күреп беренче чиркану һәм кызгану тойгысын кичергәч тә күңелгә иң башлап шундый уй килде: ничек итеп Бәдретдин бу бәхетсез әнисен чакырып алырга һәм безгә күрсәтергә җөрьәт итте икән?.. Без бит гадәттә кешене куркытырлык ямьсез яки гарип туганнарыбызны ятлар күзенә күрсәтмәскә тырышабыз. Хәтта әниебезне дә, әгәр ул менә шушындый булса, үзебез чакырып алып күрсәтергә кыймас идек, уңайсызланыр идек, оялыр идек. Бәдретдин бу кыен хәлне бөтенләй күрми, аңламый микәнни? Әллә күрсә, аңласа да бик тирән яшерә беләме?

Ә җиңги шул арада чынаякларга чәй ясап, йөзен самовар артына яшерә төшеп, безгә сузды. Без башларны күтәрмичә генә, сүзсез генә чәебезне эчәргә тотындык. Бәдретдин безне кыстап:

— Йәгез әле, шәрикләр, ни бары белән ашап кына эчегез, ашап кына! — диде, һәм аның тавышында мин көткән уңайсызлану яки оялу ник кенә бер ишетелсә иде!

Йомырка тәбәсен капкалап, икешәр чынаяк чәй эчкәч, без чәшкеләребезне каплыдык. Бәдретдин, сыеның ярлылыгыннан булса кирәк, үзалдына, сиздермәскә тырышып кына, бер сулап куйды. Аннары кисәк кенә аягүрә басты да:

— Булмаса, мин сезгә үземнең китапларымны күрсәтим әле,— диде һәм тәрәзә башына ясаган кечкенә шүрлектән бер өем китапларын алып безгә бирде. Без бер эш чыкканга куанып, шуларны карый башладык. Монда яңа әдәбияттан ике-өч роман, дүрт-биш шигырьләр мәҗмугасы, иске әдәбияттан шактый тузган «Бүз егет», «Тутыйнамә», «Ләйлә вә Мәҗнүн», «Каһарман катыйль» кебек китаплар һәм гарәп, фарсы телендә берничә дәреслек бар иде. Без күбрәк вакыт үтсен өченгә бу китапларның кайсы укылган, кайсысы укылмаган, кызыкмы-түгелме — шул турыда сөйләшкәләп, карап чыктык.

— Минем бит әле сезгә, шәрикләр, тагын бер күрсәтәсе нәрсәм бар,— диде Бәдретдин һәм, яңадан торып, шүрлектән кечкенә генә скрипкә алды. Бу кулдан гына ясалган, буялмаган, хәрти генә бер скрипкә иде.

Без гаҗәпләнеп сорадык:

— Кайдан бу синдә?

— Үзем мәтәштергән булдым инде,— диде Бәдретдин һәм скрипкәнең тонык кына тавыш чыгарган кылларын көйләргә тотынды. Аның кубыз уйнавын, мандолина чирткәләвен без белә идек. Әмма скрипкә!..

— Әй, Бәдри, нигә моңарчы яшердең? — дидек без.—Мәдрәсәдә Сәгыйть скрипкәсен алып, үзеңнән уйнаткан булыр идек бит!

— Оста барда кулың тый! — диде Бәдретдин, тыйнак кына елмаеп.

Ул айлар буе кул тимичә яткан скрипкәсен шактый озак азапланып көйләде. Шул чакта мин аның әнисенә күтәрелеп карадым: ана үзенең шәкерт улына шундый бер бәгырьгә төшәрлек тирән мәхәббәт белән, бәхет-сөенеч белән сихерләнеп, ереп, мөкиббән китеп карап утыра иде ки, мин хәтта йөрәгем-тәнем белән әллә ничек тетрәнеп куйгандай булдым. Аңлыйсызмы, күз алдыгызга китерә аласызмы — гүя бу зураеп ачылган сыңар күздәге өнсез караште, бер адәм затына гына түгел, бөтен җан иясенә хас нииндидер менә үзе эшләгән могҗизага таң калу һәм шуңа чиксез куану, шуның белән әйтеп бетергесез горурлану ап-ачык чагылып тора иде: ул тапкан бит бу баланы! Ул имезгән бит аңа күкрәк сөтен! Ул шушы сөлек кебек егетнең әнисе бит! Шәкерт әнисе, гыйлем иясе булачак кешенең әнисе... Ихтыярсыздан йөрәгем үкси башлап, мин тизрәк башымны түбән идем.

Бәдретдин, маташа торгач, ахырда скрипкәсен көйләде, иңбашына терәде, җәя сыман смычогы белән сызгаларга тотынды. Скрипкәнең тавышы бик зәгыйфь иде, чеби тавышыдай көчсез-нечкә иде, ләкин бу минутта безнең күңелләргә ул да бик ягымлы, бик тансык иде. Бәдретдиннең уйнавын барыбыз да шылт та итмичә, тып-тын калып тыңлап утырдык. Бу ярлы өйнең һавасында ук нииндидер бер авыр сагышлы

моң —мәңгелек моң йөзә кебек иде. Текә генә катып утырган ап-ак бабай ни уйлый, бөкәне өстеннән бер генә дә кузгалмаган абзый кеше ни кичерә — моны белүе һич мөмкин түгел иде. Тик шушы моң эчендә, томан аша караган тулы ай төсле, Бәдретдиннең әнисе үзенең сүзсез шатлыгы белән яктырып утыра. Нинди язмышлар бәйләгән бу кешеләрне, нинди серләр саклана алар арасында?

Бер-ике көй уйнагач, Бәдретдин, ниһаять, әнисенә дәште:

— Әнкәй, сиңа нәрсә уйныйм?

Әнисе бер мәлгә балаларча кызарып, шул ук вакытта куанычыннан тагы да балкыбрак китте, ләкин кайтарып сүз әйтә алмады.

— Әнкәй, син шушы көйне ярата идең бит! — диде Бәдретдин һәм «Салкын чишмә»не уйный башлады. Аның сүзләре, сүзләреннән дә бигрәк, шулкадәр гади, табигый, җылы-якын итеп дәшүе минем соңгы шикләремне дә чәлпәрәмә китерде. Әнисе өчен уңайсызлану дигән нәрсәнең әсәре дә юк икән Бәдретдиндә!.. Кайда ул уңайсызлану! Берәүне дә күрмичә, бары әнисенә, әнисенең әнә шул башта безне чирканырга мәҗбүр иткән шадра, чалыш, акайган күзле йөзенә генә карап, ул скрипкәсен уйнады. Аның бу аз гына моңсу уйчанлык, яшерен генә кызгану белән өртелгән җитди-җылы карашында, әнисен өзелеп ярату гына түгел, аны беткәнче аңлау, кадерләү, юату сизелеп тора кебек иде. Белмим, болай карый алыр өчен күңелләрдә нинди генә тирән мәхәббәт дәрьясы ятарга тиештер инде?! Әллә бу шулай бик ямьсез ана белән бик матур бала яки, киресенчә, бик матур ана белән бик ямьсез бала арасында гына буламы икән? Соңгысы, ихтимал, еш очрый торгандыр, әмма беренчесен ишеткән дә, күргән дә юк иде.

Шулай да безгә кузгалырга вакыт иде инде. Бәдретдин уйнап туктагач, без хуҗалардан дога кылырга рөхсәт сорадык. Абзый кеше ямаулы тез башларын ышкып куйды, ә Бәдретдин, бабасына үрелеп:

— Бабакай, шәкертләр бездән фатиха бирүебезне сорыйлар,— диде.

Бабай башын какты, һәм без кулларны күтәрдек.

...Күк алашаны җигеп, капкасыз-коймасыз, кыр үләне басып киткән «ишегалдыннан» урам уртасындагы тигез юлга чыктык. Бәдретдин һәм әтисе безне озатып, киртә буенда янәшә басып калдылар. Юк, алай гына түгел, алар белән бергә безнең артта авыл читендәге иң фәкыйрь йорт, бу йортның безгә билгесез нindидер тирән сере —бәхетсезлегеме, фаҗигасеме, әллә без аңлаудан гаҗиз бөек бер өмете-бәхетеме — торып калды.

Кояш баюга таба борылган иде инде. Ә шулай да тургайлар, көн яктысыннан туя белмәгәндәй, тагын да биеккәрәк менеп, тагын да сузыбрак, ярсыбрак берөзлексез сайрыйлар да сайрыйлар. Дөнья киң, киң, киң, әләләләләүү! Җире-күге тын, буш, моңсу... бик моңсу миңа!.. Берни эшли алмыйм үзем белән: самовар артыннан гына улына карап утырган ана күз алдыма килә дә эчемнән тагын үкси башлыйм... Кемгәдер йодрык селкеп, кычкырасым килә: ямьсез түгел бит ул, матур бит ул, матур, матур Бәдретдиннең әнисе!

1964

# Төнге тамчылар

## I

Апрель киче. Юеш, җылы, томанлы. Караңгы, тын урамнарда тып-тып тамчылар тама. Күңелгә нидер әйтмәкче, нәрсәнедер искә төшермәкче була бу тамчылар... Тып-тып... Нәрсәне икән соң, нәрсәне генә оныттың икән лә син, кеше?

Нәкъ шундый караңгы, җылы кичләрнең берсендә Хәлил Ишмаев Ләйлә ханымның Ленинградтан кайту хәбәрен ишетте. Кайда, кем алдында диген!.. Эштән кайтып керсә, боларда Зәйнәп исемле хатын Мәрвәр ханым белән кухняда сөйләшеп утыра. Менә шул хатын, аны күргәч исенә төшердеме, әллә кызыклы хәбәрне юри аның алдында әйтер өчен көтеп утырганмы, ләкин ничек кенә булмасын, Хәлил кереп өстен салырга да өлгермәде, бу кычкыра биреп әйтеп тә куйды:

— Әй-й, Мәрвәр җаным, оныта да язганмын лабаса, миңрәү түгел диген инде син мине!.. Теге ни... Ләйлә Ленинградтан кайткан бит!

— Кайсы Ләйлә? — диде Мәрвәр ханым, гадәтенчә исе китмичә генә, ә Хәлил пальтосын элеп маташкан җирендә бер мәлгә тынып калды.

— Соң теге, әлеге Гайшә апаның сеңлесе, доктор Үзбәковның балдызы була инде... Беләсең инде син аны, бик яхшы беләсең... Ләйлә туташны!

— Ә-ә! — дип сузды Мәрвәр ханым һәм ни өчендер башын каккандай итте.— Кайчан кайткан?

— Әле күптән түгел булса кирәк, үзем дә кичә генә ишеттем... Ул бит, җаным, Ләйләне әйтәм, анда бик зур кешедә кияүдә ич. Әллә латыш, әллә яһүд шунда. Гел заграницага йөреп тора икән. Ә Ләйлә үзе бер дә үзгәрмәгән, ди, һаман шулай карлыгач кебек сылу да, чибәр дә, ди... Ә өстен күрсәң, баштанаяк заграничный, ди, җаным! Соң шулай булмыйни, ире ни бит, әллә яһүд, әллә латыш...

Мәрвәр ханым аның сүзен бүлде:

— Ә озакка микән?

— Белмим, җаным, белмим. Торыр әле, торыр, беренче кайтуы бит. Йөрер әле Казан хатыннарын шаккаттырып, шуның өчен генә кайткандыр да әле, җаным!

Мәрвәр ханым авыз эченнән генә нидер мыгырданып куйды да шунда ук алгы якка ваемсыз гына кычкырып әйткән булды:

— Хәлил, ишеттеңме, Ләйлә кайткан ди әнә...

Хәлил тиз генә җавап кайтара алмады. Бу гади-ваемсыз сорау юри аны сынар өчен бирелгән мәкерле сорау иде. Үзенең шушы секундта ни кичерүен ул сүзе белән генә түгел, тавышы белән дә сиздермәскә тиеш иде. Ләкин... ләкин кеше күпме генә качарга, яшеренергә, ялганларга өйрәнмәсен, әмма тормышның кайбер минутларында аптырап, югалып кала икән ул. Нәкъ шундый хәтәр бер минут кичерде Хәлил дә... Ләкин дәшми тору озакка китсә, тагын да хәтәррәк буласын сизеп, ул исе китмәгәндәй:

— Шулаймыни? — дип кенә куйды да, вакыты юк кешедәй ашыгып, ясалма эшлекле-салкын кыяфәтен сакларга тырышып, тизрәк үзенең кабинетына узды.

...Калын портфелен урындыкка ташлады, ишекле-түрле бер-ике тапкыр йөреп алды, аннары язу өстәле янына утырып, башын йодрыклары белән учлады... Ләйлә кайткан... Ләйлә кайткан... Ләйлә, Ләйлә! Йа Хода, нигә бу көтелмәгән хәбәр, бу кечкенә факт, чоңгылга төшкән таш кебек, кинәт аның бөтен җанын шулхәтле сискәндереп җибәрде соң әле?.. Күптән киселгән сынык бит инде ул, күптән онытылган иде бит инде! Аңардан башка да узды бит гомер, уза иде бит әле, чәнчелгере!.. Ә ул кайткан... Нигә, ни өчен? Әлбәттә, аның өчен, Хәлил Ишмаев өчен түгел инде. Ләйлә өчен Хәлил юк ул, юк, күптән төтенгә әйләнеп таралган, беткән, юкка чыккан кеше... Кайткан икән, шәһәр таптап йөрер дә кире китәр. Сорашып та тормас... Сукмаклары да аларның очрашмас, юк, очрашырга тиеш түгел! Бәс, шулай булгач, яшел эшләпәңне батырыбрак ки дә, алдыңа карап кына, үз юлың белән йөри бир!

Яшендәй китереп суккан бу хәбәрдән соң бер көн узды, ике көн узды, өч көн дә узды шикелле... Кафедра мөдире профессор Хәлил Ишмаев институтка барды, институттан кайтты, тып-тын аудиториядә башларын салындырып, йокы белән көрәшеп утырган студентларга мең дә беренче кат лекциясен сөйләде, тагын каядыр керде, нидер эшләде, аннары, арып, авыр портфелен сөйрәп кайтырга чыкты. Кайткач, Мәрвәр ханымның ашын ашады, чәен эчте, нәрсәдәндер зарлануын тыңлаган булып утырды. Соңыннан иренеп кенә газеталар караштыргалады... Бөтенесе дә гадәт буенча гына, акылдан тыш, теләктән тыш эшләнә иде. Әмма ни генә эшләмәсен, әлеге хәбәр, тып-тып тамган тамчыдай, аның миенә өзлексез бернәрсәне тукып торды: «Ләйлә кайткан!» «Ләйлә кайткан!» «Кайткан... кайткан!..» Юк, моны... моны аңлый белергә кирәк, дуслар! Әгәр кешенең, очрашу-күрү түгел, исенә төшерүдән дә катгый рәвештә тыелган беренче иң газиз, иң саф мәхәббәте менә шулай, күктән иңгәндәй, кинәт әйләнеп кайтса, әйтегезче зинһар, ул кеше нишләргә тиеш? Аңлагыз, сүз сөяп куйган бүрәнә турында түгел, ә тере кеше турында бара. Сүз, ниһаять, исемле, дәрәҗәле, олы яшьтәге кеше турында бара... Чынлап та, менә ул үзенең еллар буенча тырыша-тырыша тапкан бик кадерле тынычлыгын бозмас өчен, көчләнеп-азапланып булса да, хатын итеп яшәгән Мәрвәренең каһәренә юлыкмас өчен ни эшләргә, нинди калыпка керергә, нинди сабырлык һәм чыдамлык күрсәтергә тиеш?

Моннан егерме җиде ел элек Хәлил Ишмаев педагогия институтын бетереп килгән чагында доктор Максут Үзбәковның энесе мәрхүм Мисбах белән танышып, бик дуслашып киткән иде. Алар Чехов урамында торалар иде. Менә шул Мисбах янына барып йөргәндә, Хәлил доктор Үзбәковның уналты-унҗиде яшьлек балдызын күрде. Бер күрде, ике күрде, аннары ничектер бик табигый рәвештә танышып та киттеләр, сөйләшә, көлешә, уйный-шаяра да башладылар. Кызның исеме Ләйлә иде. Гаҗәп, кайчагында кешенең исеме үзенә ничектер бик туры килеп, бик килешеп тора. Гүя менә бу кыз да ак күбәләк кебек нәфис, җиңел, нечкә җанлы булганга күрә Ләйлә исемле иде. Ләйләдән башка бүтән бер исем дә аңа һич туры килмәс кебек иде. Һәм, әйтерсең ак күбәләккә охшаганга күрә дә аңардан чәчәкләр дөньясына хас табигый садәлек, назлы-нәфис сөйкемлелек аңкып тора иде. Хәлил аңа җитеп килгән, инде гашыйк булырга ярый торган кыз итеп карарга да курка иде. Ә ул кыз тотты да үзеннән ун-унике яшькә олы, карап торырга әллә ни матурлыгы да, маһирлыгы да булмаган, киресенчә, Тәкәнеш якларыннан ияртеп килгән, пединститут та кырып-юып бетерә алмаган «гыйбадлыгы» күзгә бәрелеп торган Хәлилгә чәчәк йөрәген ачты да куйды. Хат аша искиткеч бер самимилек һәм батырлык белән үзе ачты ул... Мондый кыюлыкны, мондый тирән ышануны, мондый һичбер исәп-хисап белән бәйләнмәгән керсез, хыялый мәхәббәтне бары унҗиде яшьлек кыздан гына көтәргә мөмкин иде. Һәм Хәлил өчен бу мәхәббәт диңгез төбеннән табылган саф энҗе бөртеге кебек гаҗәеп бер байлык иде, ак итә, пакь итә, яктылыкка илтә торган гомерлек бәхет иде. Хәлил моны бөтен йөрәге белән сизде, аңлады һәм үзе дә сөенеп, дәртләнеп, рухланып Ләйлә туташны чын-чынлап яратып китте. Соңыннан бу хәлне сизгән-белгән кешеләр дә моңа бер дә гаҗәпләнмәделәр, киресенчә, алар балалыктан яңа чыгып килгән яшь-яшь кызның акылга утырган, сабыр-басынкы егеткә мәхәббәт тотуын, шуның канаты астына керергә теләвен хуплап каршы алдылар... Хәзер инде Хәлил шул ак күбәләкнең нечкә мәхәббәтен куркытмыйча сак кына ике учына алырга тиеш иде.

Ләкин аның куллары, әллә бәхетенә, әллә бәхетсезлегенә каршы, богауланып өлгергән иде инде. Хикмәт шунда Ләйлә туташны күргәнчегә кадәр үк ул шушы Мәрвәре белән шактый якынаеп йөри

башлаган иде. Тынгы белмәс активист, сизгер-уяу, сүзгә оста, өркетергә ярата, кыскасы, яшьләр арасында бик ялтырап йөрүче кызларның берсе иде ул... Аның шактый югары урыннарда утырган ишле туганнары да шул заманның (ягъни теге заманның) бик гайрәтле кешеләре иде. Аларга курку катыш хөрмәт белән карамыйча мөмкин түгел иде. Менә Хәлилне дә, ни сәбәптәндер, кызның шул туганнары да бик кызыксындырды. Дөрес, бу кызыксынуда ачык билгеләнгән ниндидер яшерен исәпләр юк та кебек иде, әмма шулай да андый шәп кешеләрнең сеңелләре белән яратышып йөрү, ә киләчәктә, бәлки, туганлашып та китү ихтималы аны ихтыярсыздан мавыктыра иде. Ничектер менә шул кешеләр арасына керсә, аның алдында киң мәйданнар ачылып китәр кебек иде. Шуңа күрә дә ул Мәрвәр тирәсендә яратучы булып, ягъни яратам дип үзен ышандырырга тырышып, башта бик егетләнеп, бөтерелеп йөрде. Әмма Ләйләне күргәч, бу тырыша-тырыша үзен котыртып йөрүләр кинәт җимерелде дә куйды. Баксаң, чын мәхәббәт тә, чын якынлык та юк икән, бары коры мавыгу да үз-үзеңне алдап маташу гына булган икән.

Әйе, эш узмаган иде әле. Чая кызга кагылмаган-тимәгән, хәтта өйләнешик дигән сүзне дә ычкындырмаган иде әле ул. Чигенергә мөмкин иде, бик мөмкин иде. Ләкин кем җәтмәсенә эләгүен егет, бичара, бер дә аңламаган икән шул. Кыз моның чигенергә чамалавын сизеп алгач та, һич ялварып яки тарткалашып тормыйча, егеткә бары шуны гына әйтте: «Бел, мин синең чын йөзеңне фаш итәчәкмен!» — диде. Фаш ителү! О, бу, иң гөнаһсыз кешенең дә котын ала торган, гаять куркыныч сүз иде. Ә бит бергә яратышып йөргәч, егетнең кызга төрле уйларын яки шикләрен әйткән чаклары да булгандыр. Хәер, әллә ни хәтәр сүз әйтмәсә дә, төймәдән дөя ясап булмыймыни?! Моның мисаллары күз алдында бит. Юк, институтны тәмамлап, аспирантурада калырга өметләнеп йөргән чакта гына «фаш ителеп» куйсаң, беттең дигән сүз! Алла сакласын!..

Кыскасы, Мәрвәр әнә шул бер янавы белән Хәлилне бөкте дә салды. Кая ул чигенү! Песи булды егетең, бөтенесеннән ваз кичеп, тизрәк Мәрвәр итәгенә капланды. Әйе, ул заманда, теләсәң, «мәхәббәтне» дә кешедән буып алырга була иде.

Ә Ләйлә берәүгә бер сүз әйтмичә кинәт кенә Ленинградка китте дә барды. Аның ниләр кичереп, нинди хәлдә китүен Хәлил күз алдына китерергә дә курка иде. Ак күбәләк, әйтерсең кара мунча тирәсеннән иркен кырга очты... Көн яктысында эреп югалды... Тик күпмедер вакыт узгач кына аның Герцен институтында укуы ишетелде, аннары инде, фин сугышы алдыннан булса кирәк, Зәйнәп ханым әйткәнчә, бер яһүдкәме әллә латышкамы, һәрхәлдә, зур дәрәҗәле инженер кешегә иргә чыгуын сөйләделәр. Ул кеше, имеш, безнең чит илләр белән сәүдә алып бара торган оешмаларда эшли. Сугыш вакытында Ләйлә үзе дә ире белән кайсыдыр илдә торган, шунда совет хезмәткәрләренең балаларын укыткан, имеш. Булыр, төшеп, югалып калыр өчен яратылмаган иде ул. Бәхетен, һичшиксез, табарга тиеш иде.

...Күп еллар узды, күп җилләр исте, күп сулар акты... Күпме кешеләр тормыш юлында очрап, тиеп-кагылып үттеләр, онытылдылар, эзсез югалдылар. Әмма ләкин Ләйләне Хәлил бервакытта да онытып бетерә алмады. Гел генә күз алдында тормаса да, күңеленең әллә кайсы гына почмагында яшеренеп кенә ул яши бирде. Тик Хәлил үткәннәрне бик сирәк кенә исенә төшергән минутларда ак күбәләк шул яшеренгән урыныннан гүя терелеп чыга иде дә, кунарга чәчәк эзләгәндәй, аның хыял күгендә тын гына талпына башлый иде. Йа Хода! Ниндидер әйтеп биргесез үкенечле һәм татлы сагыну Хәлил йөрәген әрнетеп, телгәләп җибәрә иде. Югалган бәхет, онытылмаган мәхәббәт, соңга калган үкенү, зарыгып сагыну — менә шул газаплары белән ләззәтле иде бу минутлар! Әйе, бары тик минутлар!

Ә Мәрвәр белән бергә аның егерме биш ел гомере узып та китте. Гаҗәпләнерлек берни дә юк — тордылар, хәтта әйбәт тордылар. Мәрвәре күптән инде бик тырыш, бик уңган хозяйкага әверелде, кызыл кисеп, активист булып йөрүләре әллә кайчан бетте, ләкин сизгер уяулыгы нәкъ элеккечә калды, һәм шушы көнгә кадәр ул Хәлилне һәртөрле ялгыш адымнардан, ата күркә шикелле саклап килде. Тормышлары да үзләре теләгән эздән тәгәрәде. Институтны бетергәч, Хәлил татар теле кафедрасында аспирант булып калды... Гәрчә ул татар телен яратып бетермәсә дә һәм аның киләчәгенә зур өмет багламаса да, гыйльми дәрәҗәгә ирешер өчен, бернигә карамыйча гомерен шуңа багышлады. Акрынлап аспирантураны да бетерде, кандидатлык диссертациясен дә яклады, ахыр килеп, бик тырыша торгач, татар теленең зур, сары портфельле профессоры да булып куйды... Кеше үзенең түшәменә җитте бугай. Ул канәгать, язмышыннан да, тормышыннан да канәгать. Аңардан: «Вөҗданың сафмы, намусыңа каршы берәр нәрсә эшләмәдеңме, үкенмисеңме, газапланмыйсыңмы?» — дип сораучы юк. Хәер, кем сорасын? Ят кеше түгел, ул үзе дә үткәненә борылып карарга, күңелендә казынырга яратмый иде.

Ләкин ни өчен соң егерме биш ел буена күренмәгән бер хатынның бары шушы шәһәргә кайтып килүе аны кинәт сискәндереп җибәрде? Нигә әле ул аның күптән мәрткә киткән күңелен төртеп уятты, күптән сүнгән хисләрен, онытылган уйларын яңадан кабындырып, дөрләтеп җибәрде? Күрәсең, хикмәт монда бер Ләйлә ханымда гына түгел. Күрәсең, кайчандыр яшь кенә кызыйга булган мәхәббәттән тыш, аның эчендә озак еллар буенча ниндидер бүтән кичерешләр дә акрынлап җыела килгән. Ленинградтан кайткан ханым исә, кинәт искән язгы җилдәй, әнә шул эчендә боз катлавы сыман туңып яткан кичерешләрен эретеп, кузгатып җибәрүче генә булды, ахрысы... Нинди вакытта диген! Тып-тып язгы тамчылар тамган апрель кичләрендә бит, җитмәсә!.. Ах, Ләйлә, Ләйлә!

Шулай да беренче өермә бөтерелеп, йөгереп узды шикелле. Бераздан Хәлил дә исен-акылын җыеп өлгерде. Аның эчендә ниләр купканын берәү дә, хәтта соңгы көннәрдә аеруча уяу йөргән Мәрвәре дә сизмәде. Чын хисләрен гомере буена яшереп тотарга өйрәнгән гадәте Хәлилгә бу юлы да бик нык ярдәм итте — ул һаман җитди-йомык кыяфәтен бик оста саклаучы, олы, таза гәүдәсен текә тотып, ашыкмыйча гына йөрүче шул ук профессор Ишмаев булып кала бирде. Инде акылын җыеп, бераз тынычлангач, бу көтелмәгән исәрләнүен үзе үк хөкем итәргә тырышып карады: «Йә, нәрсә булды соң әле, нигә бу кадәр мин зиһенемне җуйдым, диванага әйләнә яздым, тиле шәкерт!» — диде ул, үз-үзен шелтәләп... Ләйлә ханым кайткан, имеш! Кайтса соң? Күптән, һай, күптән югалган Ләйлә бит ул аның өчен! Кайтса да, китсә дә аңа хәзер барыбер түгелмени?.. Юк, болай ярамый, килешми, оят!.. Онытырга кирәк бу кысыр хәсрәтне, күңелдән йолкып атарга кирәк бу мәгънәсез яну-көюләрне... Үткәнгә кайту юк ул, юк!

Шулай диде аңа айнык акылы. Шулай качарга теләде ул һәртөрле вәсвәсәдән... Бөтенесен — җилкенү-талпынуларын, газаплы уйларын салкын акылы белән әнә шулай буарга тырышты. Әмма ләкин бер генә теләген ул һичничек тә җиңә алмады. Бу аның Ләйләне күз кырые белән генә булса да бер күреп каласы килү теләге иде. Әйе, бернинди максатсыз, бары тик коры кызыксынудан гына, үзенә насыйп булмаган Ләйләсен бик тә күрәсе килә иде. Нindirәк икән ул? Кайчандыр күбәләктәй җиңел-сылу кыз хәзер кырыктан узган хатын булгач нинди кыяфәткә керде икән? Бер күрүдә таный алыр идеме икән ул аны? Бик нәфис, бик чибәр иде бит ул, шайтан алгыры! Керфекләре кара, ә күзләре якты-соры иде, шунлыктан кара каймалы булып күренәләр иде ул күзләр. Озаграк карап торсаң, шул күзләрнең төбендә акрын гына эреп югалган шикелле тоя идең үзеңне... Хәзер ничек икән? Саклandымы икән аның кара каймалы якты күзләре, нурда югандай бик чиста көрәнсу йөзе, җиргә тияр-тимәс кенә йөргән камыштай нечкә, зифа гәүдәсе?.. Хәер, әнә күргән хатыннар аны бик сакланган, хәзер дә шундый ук сылу-чибәр дип әйтәләр. Гаҗәп түгел. Ул бит явызлыгыннан чыбыктай кибә яки ваемсызлыгыннан камырдай күперә торган хатын булмаска тиеш иде. Нәфислекне бик нечкә тоя торган гаҗәп сизгер җан бар иде аңарда... Юк, күрәсе иде үзен, ничек тә күрәсе иде. Шушында, шушы шәһәрдә генә йөри ич ул, кайтып төшкән җире дә моннан ерак түгел — Чехов урамында гына югыйсә!

Ләкин махсус барып күрү турында сүз дә булырга мөмкин түгел. Мәрвәр ханым сизә калса, утыз сигезле башмаклары белән бөтен саф хисләреңне таптап изәр. Яшьлекнең гөнаһсыз бер хатирәсе бу, кеше күңеленең нечкәреп бер сөенүе, үткәннәре турында сагышлы бер уйлануы дип тормас. Карт алаша, күрсәтермен мин сиңа Ләйләне, закон минем якта дип кенә җибәрер.

Димәк, очраклы туры китереп кенә очрашу турында хыялланырга мөмкин. Ләкин вакытлы гына кайткан кешене алай очрату, ай-һай, бик шикле шул! Кайда йөри, нинди урамнардан йөри ул, кайларда була, кемнәргә керә? Берәр күзәтүче ялларгамы, яки үзеңә якынрак чат башында сагалап торыргамы?.. Һе, кызык булыр иде бу: яшел эшләпәсен өч яктан яньчеп кигән, култык астына зур портфелен кыстырган мәһабәт профессор чат башында басып тора. Ә үткән-сүткәннәр аның ни өчен басып торганын гүя белеп, мыек асларыннан гына көлеп узалар. Көт, профессор, көт, бәхетеңнән каршыңа... Мәрвәрең килеп чыкмасмы?

Шулай да Хәлил эшкә барганда да, кайтканда да һәрбер ят хатынга игътибар беләнрәк карап уза башлады. Бәлки, шуларның берәрсе «ул» булып чыгар. Өмет, өмет! Бер генә чаткысы да кайчан кешене тилегә сабыштыра: тукта, әнә «ул» килә түгелме соң? Әнә тагын «ул»! Бер-бер артлы әллә ничәү!.. Хәлил хәсрәтле итеп әче елмая: егерме биш ел буена аның Ләйләгә охшаганрак бер генә хатынны да күргәне булмады.

Ә өмет дигәнең аны һаман каядыр дәшә, каядыр өстери иде. Кай кичләрен ул, эштән кайтышлый, сагаеп кына Үзбәковлар торган урамга да барып чыккалады. Монда «аның» очравы бик мөмкин бит!

...Чехов урамы. Апрель киче. Тып-тып түнгә тамчылар тама... Тәрәзәләрдә ут, пәрдәләр төшерелгән... Әнә каршы якта ике катлы агач йорт, шуның югары катында Үзбәковлар тора. Ике якка ачылмалы парадный ишек, сары баскыч югарыга алып менә. Моннан егерме биш ел элек шул баскычтан аңа каршы Ләйлә йөгереп төшә иде... Күпме хатирәләр! Китап битләре арасында кипкән чәчәктәй сакланган хатирәләр!

...Ике тапкыр ул каршы яктан гына доктор квартирына карап узды. Тәрәзәләре якты, челтәр пәрдәләр корылган, түшәмнән асылынган өч чатлы люстра да күренә... Докторның бөтен семьясы өйдә булса кирәк. Ләйлә дә шулар арасындадыр инде. Йөри микән, утырып тора микән, әллә берәр яры чыгып китәргә җыена микән?.. Бу нәрсә аңа бик ихтимал төсле булып тоелды. Театрга яки киноga дип чыгуы мөмкин ләбаса. Нинди шәп форсат булыр иде бу. Һәм, Хәлил кичегүдән курыккандай, ашыгып урам аша чыкты да, гәүдәсен туры гына тотып, салмак кына атлап, докторларның парадный ишеге яныннан узып китте. Бераз барып, кире борылды, тагын парадный ишеккә кырын гына карап узды. Ләкин ишекнең ачылырга исәбе юк иде. Ун тапкыр, егерме тапкыр узсаң да ачылмас, ахрысы бу, таза ишек... Өйнең якты тәрәзәләре югарыдан урамга һавалы, ваемсыз карыйлар, гүя түбәндә юеш тротуар таптап йөрүчене күрмиләр дә, белмиләр дә алар... «Бу нинди балалык!» — диде Хәлил, үз-үзенә ачуы килеп. Олы башы белән түбәнсенеп йөрүенә кинәт хурланып куйды. Болай урам таптаганчы, туп-туры гына керергә иде дә: «Ләйлә ханым, мин сезне күрергә килдем»,— дип әйтергә иде. Кем гаеп итәр иде? Бер дә гөнаһсыз, бик табигый

теләк ич бу! Ләкин юк, мөмкин түгел, җан-теләкләргә кемдер салган богау бар... Һәм шул богауның авырлыгын соңгы көннәрдә аеруча нык сизгән Хәлил, Үзбәковлар өе яныннан берничә тапкыр узгач, башын түбән иеп кенә үз квартирына таба атлады. Кирәкмәс, булмас, йөрүдән мәгънә юк, диде ул киткән саен, ләкин барыбер Чехов урамына кичләрен барып чыкмыйча түзә алмады. Тагын батыраеп килгән булды, челтәр пәрдәле тәрәзәләргә карап узды, туктап төнге тамчылар тавышына колак салып торды, аннары үз-үзеннән оялып, юашланып, башын түбән иеп кире кайтып китте.

Бер кайтуында күңеленә әллә ничек кенә Дәрдмәнд сүзләре дә килде:

Агарды чәч,
Куарды баш,
Сары юллар сызылды,
Өмидләр, кем...
Өмидләр, кем...
Дәригъ, бер-бер өзелде!

Әмма язмыш рәхимле икән. Кичләрнең берсендә аңа, ниһаять, Ләйлә ханым белән очрашырга туры килде.

## II

Ул көнне университетның гыйльми советында чит шәһәрдән килгән бер егет кандидатлык диссертациясен яклады. Профессор Хәлил Ишмаев оппонентларның берсе иде. Диссертацияне яклау күптән килгән тәртип һәм кагыйдә буенча үтте. Булачак яшь галим кирәк дәрәҗәдә әдәп һәм тыйнаклык саклап, кирәк дәрәҗәдә генә бәйсез һәм кыю булырга тырышып, бераз гына дулкынланып һәм бераз гына масаеп, диссертациянең кыскача эчтәлеген сөйләп чыкты. Оппонентлар да коры рәсмилеккә беркадәр җылы хәер хаһлык кушып, күбрәк мактап, азрак тәнкыйтьләп, кыскасы, бөтен шартын китереп, диссертация турында үз фикерләрен әйттеләр. Ахырдан булачак галим өлкән галимнәргә түбәнчелек белән үзенең рәхмәтен белдерде, тиешле вәгъдәләрен бирде, аннары гыйльми совет членнары шар салып, егетебезне бик хаклы рәвештә кандидат ясап куйдылар.

Шуннан соң инде максатына ирешкән бәхетле егет, күптән килгән йола буенча, үзенең оппонентларын һәм утырышта булган кайбер якын кешеләрен «Казан» ресторанының аулак бер бүлмәсенә кичке ашка алып китте. Әзер табынга унбишләп кеше утырды, тамада итеп мондый мәҗлесләрнең берсеннән дә калмый торган бик борынгы кандидат Кәли иптәшне сайладылар. Кәли иптәш аягүрә басты, тамагын кырды, көлдерергә теләп нидер әйтте, көлүче булмагач, пычак сырты белән шешә муенына сукты һәм коньякларны, столичныйларны рюмкаларга салырга кушты... Монда инде яңа кандидат, яшь килендәй, баштан ук алдына карап, тыйнак кына утырырга тиеш иде, чөнки хәзер аның исеменә мактау сүзләре китәчәк. Һәм чынлап та рюмкалар күтәрелгән саен, мактау сүзләре егетнең бик дөрес уйлый белә торган өметле башына ява гына торды.

Мондый мәҗлесләр Хәлилгә бик таныш иде. Ул моның шикелле «юу» мәҗлесләрен котылгысыз бернәрсә итеп санарга һәм анда артык сөенмичә-көенмичә генә чыдап утырырга күнеккән иде инде. Чамалап кына эчү, чамалап кына ашау, чамалап кына сүз кыстыру һәм ахырдан шулар бәрабәренә, килеп, мәҗлесне бизәп утыруы өчен рәхмәт ишетеп китү — менә аның күнеккән гадәте шул иде.

Ләкин бүгенге мәҗлескә ул башта ук күңеле тартмыйча килде. Кәефе начар, җаны тыныч түгел, йөрәгендә нindидер бер суырылмас сызлавык утыра кебек... Ни калган миңа монда дип, эче пошып, хәтта үкенеп тә куйды. Шулай да хуҗа егет бик зурлап каршы алгач, өстәлнең түренә үк узып, алдына карап, сүзсез генә утыра бирде. Мәҗлес башланды, яшь кандидат хөрмәтенә тостлар күтәрелде. Һәм, гаҗәп хәл, моңарчы бик сакланып кына эчә торган Хәлил бу юлы, кеше рәтеннән, салган бер рюмкасын эчеп бетерә барды. Шулай эчеп, бераз җиңеллек табарга уйлады, ахрысы... Ләкин исерү алып килгән бу җиңеллек гадәттәге ваемсыз, кәефле җиңеллек түгел иде. Ничектер болытлардан ачыла башлаган күктә тулы ай күренгәндәй, аның да бераз яктыра төшкән хыял күгендә... Ләйләсе акрын гына калкып чыкты. Һәм аңа шул җитте, шул минуттан ул барысын да онытып, үз эченә йомылып, бары Ләйлә турында гына уйланып утырды. Бу кызыксыз, шау-шулы мәҗлестә, ялгызлыкка бирелеп, Ләйләне генә уйлап, Ләйләне генә сагынып утыру аңа гүя нindидер моңсу, хәсрәтле бер рәхәтлек китерде.

...Ул тагын һәм тагын эчте, исерә башлавын бик ачык сизсә дә, юри тыелырга теләмәде. Чөнки эчкән саен акылын-җанын буып торган тышаулардан үзен бушана барган шикелле тойды. Уйлары гаять ачыкланып, тирәнәеп, үткенләнеп киткәндәй булды. Мәхәббәт турында, язмышлар турында, заман һәм кешеләр турында тирән фикерләр, әче хакыйкатьләр күңеленә килде. Ләкин монда аларны әйтерлек сылтавы да, кешесе дә юк иде, алар барысы да хәзергә, эсседә кузгалган умарта күчедәй, аның эчендә генә кайный иде.

Ахырда ул үзенең шактый нык исерүен аңлады. Мәҗлес әле кызып кына барса да, кузгалырга вакыт җиткәнлеген чамалады. Ә бераздан ул үзен ничек тә айнык тотарга тырышып урыныннан торды һәм тотлыга биреп, кайтырга рөхсәт итүләрен сорады... Мәҗлестә утыручылар аңа бик сәерсенеп карадылар,

шунда гына аның исереп киткәнлеген сизеп алдылар, ләкин шулай да гаҗәпләнгән булып: «Профессор, бу ни эш бу?.. Сөйләмәгез әле, Хәлил Кәримович, утырыгыз әле, утырыгыз, сездән башка мәҗлеснең яме китә бит!» — дип кыстарга, юмаларга тотындылар. Профессор, артык сүз ычкындырмас өчен, бары кулын күкрәгенә куеп, башын гына чайкады, мәҗлес хуҗасының кулын кысып, аркасыннан какты һәм, гәүдәсен аеруча текә тотып, ишеккә юнәлде. Аны кемнәрдер түбәнгә кадәр озата төштеләр, пальтосын, эшләпәсен кидерделәр, портфелен кулына бирделәр. Кемдер аңа: «Хәлил Кәримович, озатып куйыйм сезне булмаса!» — дип тә карады, ләкин ул елмаеп кына башын селекте дә үз аягы белән ашыкмыйча гына чыгып китте.

Чыккач та ул аулак урамга борылды. Мондый кыяфәттә үзәк урамнан кайтуның хәтәр булуын яхшы белә иде, әлбәттә. Булган икән шул, шактый күп булган икән, хәерсез! Күпме генә туры барырга тырышмасын, аяклары әледән-әле чалыш-чолыш атлап киткәлиләр иде.

Әмма аның акылы гаҗәп ачык, үткен иде, бик кыю, бик кызу эшли иде. Моңарчы эчендә генә кайнаган уйлары хәзер, ялгыз калгач, атылып чыгарга гүя юл эзлиләр иде. Һәм менә ул, нindидер бер ярсулы рәхимсезлек белән, үзенең үткән тормышын, эшен, гамәлен тәнкыйтьләргә тотынды; искиткеч батыраеп, үз-үзенә ачы хакыйкатьләрне ярып әйтә башлады.

Йә, ничек яшәдең син моңарчы, профессор Хәлил Кәримович Ишмаев? Профессор! Син, егерменче елларның ахырында Бөгешле авылыннан җәяүләп чыгып киткән чабаталы йолкыш малай, менә кем булдың бит! Молодец! Дан сиңа, дан! Ләкин әйт, ничек ирештең син моңа? Акылың, талантың бик зур булып, башка галимнәр белән гадел рәвештә ярышып, фән дөньясына үз буразнаңны ерып килеп кердеңме? Шундый чын галим булып күтәрелдеңме син? Йә, әйт, курыкма!

Әйе, хакыйкатьне әйтмичә булмый... Син, иптәшкәем, болганчык авыр бер заманда, күп кенә укымышлы ирләр нахакка сөрелгәннән соң, бушап калган урынга килеп утырдың. Сиңа беркем белән бәхәсләшергә дә, нидер исбат итәргә дә, үзеңнең нindидер принципларыңны, карашларыңны яклап маташырга да туры килмәде. Хәер, дөресен генә әйткәндә, алар синдә беркайчан да булмады да. Син баштан ук үзеңнән өстеннәргә буйсынып, алар авызына карап, алар әйткәнне генә кабатлап килдең. Конъюнктурага яраклашып нәрсәнедер мактадың, нәрсәнедер яманладың, каһәргә юлыккан кешеләрне тизрәк гаепләргә ашыктың, хаклыгына үзең дә ышанмаган теорияләрне яклап мәкаләләр язган булдың... Ә асылда, бу минеке дип, горурланып, кулыңа тотарлык бер җитди, төпле хезмәтең дә юк синең!

Ни өчен болай булды соң бу? Ни өчен ул, ташу өстендәге йомычка шикелле, җиңел генә чайкалып акты да акты? Үзе генә гаеплеме ул моңа? Әйе, аның яшисе, эшлисе, үсәсе-күтәреләсе килә иде. Иленә һәм халкына ихлас күңелдән хезмәт итәсе килә иде. Әмма ләкин ул елларның кырыс шартлары аны, аны гына түгел, бик күпләрне әнә шулай иректе кол итте; мөстәкыйль фикерләүне, шәхси намусны үз кулың белән буарга мәҗбүр итте. Бер ише кешеләр, җан саклауны, хәвеф-хәтәрсез яшәүне бөек идеаллар хакына дигән сылтау белән аклап, ихтыярсыз курчакка, обывательгә әверелде. Менә фаҗиганең тамыры кайда!.. Замана үзгәрде, кеше язмышы белән уйнау бетерелде, кешегә намусы кушканча яшәргә, иҗат итәргә мөмкинлекләр туды, ә шулай да теге еллардан канга сеңеп калган коллык зәхмәте һаман чыгып беткәне дә юк. Кем әйтмешли, эчкә кереп оялаган куян һаман калтыранып утыра әле. Шуны озын колагыннан сөйрәп чыгарырга көчең җитми, батырлыгың җитми синең... Кызганыч бәндә син! Кукыраеп йөрүче буш куык син!

...Хәлил нindидер бер урам чатында тукталды. Кулын тирләгән маңгаена куйды, күзләрен йомды һәм бераз вакыт тик кенә тынып торды. Якында гына нәрсәдер тып-тып тама. Хәлил газап тулы күзләрен ачты. Йа Хода, яз ич бу, яз! Ләйлә ич бу, Ләйлә! Тамчылар шуны тукыйлар бит аңа: ак күбәләгең яз булып, яшәрү булып, яңару булып кайтты, диләр!..

Хәлил тирән итеп бер сулады, кулы белән йөзен иягенә чаклы сыпырды, аннары кисәк кенә кузгалып, чалыш-чолыш атлый-атлый китеп барды. Ул болай ашыгып кая баруын, нишләргә теләвен ачык кына белми иде, ләкин бара торгач, аяклары үзләре аны бер киң урам чатына китереп чыгардылар. Бу — Чехов урамы иде. Каршы чатта биек цемент баганада бик якты булып электр яна. Аңардан өч-дүрт метрда гына газета-журнал киоскысы тора, Хәлил, бу таныш чатны күргәч, тукталып калды һәм, үзенең ни хәлдә булуын исенә төшереп, бераз куркып-борчылып та куйды. Ләкин киң урам буш иде, тын иде. «Йә, менә килдең,— диде Хәлил, башын салындырып.— Йә, ни күрдең, ни таптың? Кем көтә сине монда, исерек җүләр!» — Һәм оятыннан, хурлануыннан кая таба барырга белмәгәндәй, каршы чатка таба атлады. Барып җитәрәк кенә, тротуар буенда торган киоскының икенче ягыннан бер ханым килеп чыкты да Хәлил янынннан кызу-кызу гына үтеп китә башлады. Хәлил аны күз кырые белән генә күреп өлгерде. Әмма үзенә һич исәп бирмәстән, бөтенләй танымыйча-нитмичә, гүя актыккы өметен сынар өчен генә ул ят хатынга дәште:

— Ләйлә... Ләйлә ханым!..

Ханым ишетте. Ишетү генә түгел, артына борылып карады һәм кинәт тукталып та калды. Башта, куркуыннан булса кирәк, аз гына артка чигенгәндәй итте, аннары күпмедер вакыт өнсез калып, Хәлилдән күзләрен алалмыйча карап торды. Тик шуннан соң гына ул, артык гаҗәпләнүдән пышылдап:

— Хәлил абый!.. Хәлил абый, сезме бу? — диде, ниһаять.

Хәлил дә үз күзләренә үзе ышанмыйча өнсез катып калган иде. Берьюлы айнып киткәндәй булды ул, ләкин шул ук вакытта бөтен зиһене чуалып, бөтен реаль чынлыкны югалтып, ниндидер галәм бушлыгына чумгандай хис итә иде үзен. Тик иреннәре генә: «Ләйләмени бу, Ләйлә шушымыни, төш кенә түгелме, йа Рабби! — дип әйтергә тырышкандай, кыймылдыйлар иде. Шуңадыр инде Ләйләнең сүзләре дә аңа каяндыр бик ерактан килеп ишетелгән шикелле булды. Күпмедер секунд үткәч кенә ул, телгә килеп:

— Әйе, бу мин, мин, Ләйлә! — диде, бер үк вакытта көләргә дә, елап җибәрергә дә әзер торган чырай белән.

Тагын алар, бер-берсенә карашып, бер мизгел тынып калдылар. Шул чагында Хәлил, үзенең чын хәленә кайтып, исерек булуын исенә төшерде, һәм шуны сиздерүдән гаять куркып, арты белән киоскыга таба аз гына чигенә төште. Ләкин аны-моны сизеп өлгермәгән Ләйлә ханым, чын шатланудан яктырып:

— Менә нинди көтелмәгән очрашу! Просто гаҗәп! —диде һәм Хәлилгә кулын сузды.

Хәлил, түбәнчелек белән башын иеп, аның кулын кысты.

— Нинди җилләр ташлады сезне бу якларга?.. Шулай соң гына...— диде ханым, инде тынычлана төшеп.

— Болай... кичке прогулкага чыккан идем,— диде Хәлил, тотлыгыбрак, һәм, шулай дигәч кенә, кулында портфеле барын исенә төшерде. Ләкин ханым моңа игътибар итмәде булса кирәк.

— Килмисез дә, күренмисез дә,— дип сөйләнеп китте ул.— Ничек диләр әле, алты яшәр кайтса, алтмыш яшәр күрешә килер диләрме?.. Ә сез үзгәргәнсез, Хәлил абый, бик нык үзгәргәнсез... Сәламәтлегегез ничек соң? Ничек кенә торасыз?..

— Рәхмәт, зарарсыз,— дип кенә куйды Хәлил.

Ләйлә ханымның үзен бу кадәр тиз кулга алуы һәм шулкадәр гади, табигый сөйләшүе аны тәмам хәйранга калдырды. Әйтерсең бу ханым аңа беркайчан да мәхәббәт хаты да язмаган, әйтерсең аулак урамнарда, башын аның күкрәгенә салып, матур хыялларын сөйләп тә утырмаган, курка-калтырана чәчәк иреннәреннән дә үптермәгән, кыскасы, алар арасында берни дә — өзелеп яратышу да, әрнеп аерылышу да булмаган. Әйе, гаҗәп бу, бик гаҗәп!

— Мәрвәр ханым ничек соң, исән-саумы? — диде Ләйлә ханым, шундый ук эчкерсез табигыйлек белән.

«Бусы бигрәк тә инде», дип уйлады Хәлил, ачынып, һәм теләр-теләмәс кенә җавап бирде:

— Рәхмәт, тап-таза!

Ул үзе, исерек булуын сиздерүдән һаман әле куркып, сорашырга яки ни дә булса әйтергә кыймыйча азаплана иде. Бары томанланган күзләрен Ләйлә ханымнан аера алмыйча, гүя белергә, танырга, танып күңеленә сеңдереп калырга теләгәндәй, аңа тик йотылып карап тора иде. Әйе, бу ят хатын, бөтен килеш-килбәте, хәтта өс-башы белән дә ят хатын... Бөтенесе бик модный, бик затлы, бик бай... Әйе, мондый байлыкка һәм, ихтимал, югары бәхеткә ирешкән хатын үткәннәрне оныта, онытмаса, аларга салкын, битараф карый аладыр шул!..

Ләкин шул ук вакытта бу — Ләйлә. Дөрес, шактый нык үзгәргән, әмма матур булып үзгәргән Ләйлә бу... Ничектер буйга үсә төшеп, бераз тулыланып киткән. Кыз чагындагы самими нәфислегенә үзен бик карый белә торган хатыннарга гына хас нәзакәтле гүзәллек өстәлгән... Хәзер аны гамьсез ак күбәләккә түгел, ә горур аккошка охшатырга мөмкин булыр иде... Ә йөзе шул ук тулы иренле, бик чиста йөз, күзләре дә шул ук кара каймалы якты күзләр... Ах, аныкы буласы иде бит, аныкы буласы иде бу зифа сын, бу нәфис йөз, бу якты күзләр!

Ләйлә ханым, Хәлилнең бу кадәр йотылып карап торуыннан борчыла башлап, як-ягына җәһәт кенә каранып алды да ашыгып әйтте:

— Нигә без чат башында басып торабыз әле. Әйдәгез безгә, апалар ятмаганнардыр әле, мине көтәләрдер... вакытыгыз булса, сез дә кереп чыгарсыз.

Хәлил, авыр гына көрсенеп, башын чайкады:

— Юк, Ләйлә, бүген мин сезгә бара алмыйм, мөмкин түгел.

— Алайса мине озатып куегыз.

— Рәхәтләнеп! — диде Хәлил, ничектер ашыгыбрак, һәм үз хәлен онытып җибәрдеме, кинәт кузгалуы булды, Ләйләгә таба чайкалып та китте. Ләйлә ханым читкә тайпылып өлгерде. Соң дәрәҗәдә гаҗәпләнеп, ул Хәлилгә карады.

— Ни булды сезгә, Хәлил абый?

— Зарар юк, ул болай гына,— диде Хәлил, кызганыч елмаеп. Тиз генә тураймакчы булды, ләкин гөнаһ шомлыгына каршы, бер тотрыклылыгын югалткан гәүдәсе тагын чайкалып китте дә, ава язып, аркасы белән киоскыга сөялде. Бары менә хәзер генә Ләйлә ханым, аның агарган йөзенә, азрак кан җәелгән күзләренә һәм өс-башының да бик үк тәртиптә булмавына игътибар итеп, эшнең серен сизеп алды.

— Сез исерек бит, Хәлил абый! — диде ул, коты алынып. Куркынып тирә-ягына каранды, аннары тавышын әкренәйтеп, йомшаграк булырга тырышып әйтте: — Ходаем, сез исереп килгәнсез ич, сезгә кайтырга кирәк, сез кайтыгыз, Хәлил абый...

Әле эшне төзәтергә була иде. Моның өчен аз гына вакыт тынып тик кенә торырга кирәк иде. Шул арада исен җыеп, ныгып өлгергән булыр иде ул. Ләкин җүләрләр белән исерекләр һәрвакыт ашыгалар. Хәлил дә тизрәк акланырга, бөтенесен әйтеп калырга ашыгып, каршысында ташлап китәргә ничектер кыймыйча басып торган Ләйлә ханымга кинәт ике кулын сузды да:

— Ләйлә!.. Ләйлә бәгырем, ...бәгырькәем! — диде, иңрәп-ялварып.— Мин көттем, егерме биш ел буена мин сине көттем... Мин эзләдем, кайтуыңны ишеткәч тә, кичләрен шушы урамга килеп, сине эзләп йөрдем... югалган бәхетемне эзләдем мин... Кичер мине, ташлама мине, Ләйлә!.. Ләйләм!..

— Юк, юк, Хәлил абый! — диде Ләйлә ханым, артка чигенеп һәм агарынып.— Сез ни сөйләгәнегезне белмисез, сез ни хәлдә булуыгызны белмисез!.. Оят ич, килешми ич болай... Гафу итегез!..

Һәм ул кисәк кенә борылды да йөгерә-атлый китеп тә барды. Хәлил күзләрен йомды, сыны каткандай күпмедер вакыт хәрәкәтсез басып торды.

...Тып-тып тамчылар тама. Тып-тып төнге тамчылар тама. Беркемең дә юк, юк синең, беркемең дә юк, юк синең!..

Хәлил бер-ике адым алга атлады, аннары нәкъ каршысында торган салкын цемент баганага маңгае белән сөялде дә, калтыранып, үксеп җибәрде.

Икенче көнне ул айныган иде инде.

Бөтен газапларыннан, куркыныч-хәтәр уйларыннан, сүнми килгән соңгы мәхәббәтеннән, күптән югалган Ләйләне эзләп йөрүеннән — барысыннан да айныган иде. Кинәт купкан өермә тиз генә үтеп тә китте. Хәзер инде бу берәүгә дә эчен ачмый, чын сүзен әйтми торган шул ук салкын, йомык, горур профессор Хәлил Ишмаев иде.

Иртәнчәк ул, Мәрвәр ханым тирги-тирги чистартып биргән пальтосын киеп, зур портфелен кыстырып, кафедрасына китте. Мең дә беренче тапкыр аудиториягә керде, мең дә беренче тапкыр татар теленең морфологиясе турында лекциясен укып чыкты. Кеше үзенең күпме еллар буе таптаган сукмагына яңадан кайтып төште. Аның фикеренчә, бу такыр сукмактан чыгу мөмкин түгел, чыгарга соң иде инде.

1964

## Коръәнхафиз *

Унҗиденче елның көзендә, укулар инде башлангач, безнең мәдрәсәгә яңа хәлфә килде. Гаҗәп кызыклы, шуның белән бергә әллә нинди буталчык бер вакыт иде бу... Узган кыш патша төшерелгәч, шәкертләр хөррият диделәр дә бөтенләй авызлыкларын салдылар. Мәдрәсәдә электән килгән тәртип-низам бозылды, укуларның рәте-чираты китте. Җитмәсә, былтыр гына килеп укыта башлаган арык гәүдәле һәм юаш табигатьле Гариф хәлфә дә бик йомшак кеше булып чыкты. Аны җәдит хәлфә диләр иде, ул шәкертләргә кул күтәреп суга белми иде; хәер, шәкерт кыйнарлык аның көче дә юк иде. Ибтидаи (кече) сыйныфларда ыбыр-чыбыр балаларны ничек җитте алай тыңлата алса да, рөшдиләрдә (өлкән сыйныфларда) ул бөтенләй көчсез-гаҗиз иде; андагы аттай таза шәкертләр бәләкәй, арык хәлфәнең тәмам башы өстеннән йөриләр иде. Акыралар, бакыралар, бер сүзен колакларына элмиләр, үзе күрмәгәндә, артыннан мыскыллап көләләр, кыскасы, мескенкәйгә көн күрсәтмиләр иде. Кайда инде ул монда дәрес! Хәтта бичара хәлфәнең сыйныфта утырып елаган чаклары да булган дип әйтә торганнар иде. Мондый хәлне ничектер аңлавы да читен иде. Гүя моңарчы башлары тукмалудан чыкмаган шәкертләргә кешечә әйтелгән яхшы сүз керми дә, күнекмәгән дә алар аңа, гүя сыртларына аларның һаман йодрык кирәк тә таяк кирәк. Шулай булмаганда, алар өчен хәлфә хәлфә дә түгел, хөрмәткә лаек кеше дә түгел... Юк, түзмәде безнең йомшак күңелле мескен хәлфәбез мондый бәйдән ычкынган кыргыйлыкка, тотты да мәдрәсәбезне, мәдрәсәбезне генә түгел, кариябезне ташлап каядыр китте. Бер генә кыш укып калдык без аңардан.

Инде менә аның урынына яңа хәлфә килде. Билгеле, без аны бик кызыксынып каршы алдык. Бу инде Гариф хәлфә кебек шәкертләр арасында югалып калырлык кечкенә, өтек кеше түгел иде. Озын кара казаки кигән, нечкә билле, киң күкрәкле, уртадан калкурак нык, какча гәүдәле, бәрхеттәй кара сакал әйләндереп алган ап-ак чырайлы, юешләнебрәк торган кызыл иренле, ефәктәй йомшак кара мыеклы һәм аз гына сары йөгергән елтыр кара күзле бик чибәр бер кеше иде ул. Беренче керүендә үк ул безгә, күзләрен кысыбрак, матур иреннәренең чите белән генә елмайгандай итеп, гүя менә аны-моны сизмәгән куяннарга агач ботагыннан койрыгын уйнаткалап карап яткан сүлән шикелле, эченнән генә нидер уйлап, нидер чамалап, яшерен-астыртын гына карап торган иде. Һәм без, аның чын уен, чын теләген белмәсәк тә, бу елмаюлы астыртын карашыннан ихтыярсыз шомланып, эчебездән генә калтыранып та куйган идек. Онытмас борын тагын шуны да әйтим: баштарак, без аның исемен дә ачык кына белә алмыйча тордык. Безгә аны: «Хафиз хәлфә»,— дип таныштырдылар, шул ук вакытта бу кеше — «Коръәнхафиз» дип тә әйттеләр. Тик бераздан гына төшенеп алдык: чын исеме дә Хафиз һәм шуның белән бергә Коръәнхафиз да икән ул. Ләкин тиз арада ул шушы соңгы «коръәнхафиз» дигән ләкабы белән халык теленә кереп китте. Без, шәкертләр, аны «Карый хәлфә» дип йөртә башладык.

Бер уңайдан тагын шуны да әйтеп үтәргә кирәк: безнең мәдрәсәне Искәндәр ахун мәдрәсәсе дип йөртәләр. Таш мәчеткә урам аша, иркен генә ихата эчендә аның ике бинасы бар. Берсен, гади авыл өе сыман, бүрәнәдән салынган кечерәген, яңа мәдрәсә дип, ә икенчесен, такта белән тышланган зуррагын, иске мәдрәсә яки сары мәдрәсә дип атыйлар (сарыга буялган иде ул). Яңа мәдрәсәдә күбрәк Дәүләкән балалары укып йөри. Аларны ибтидаи сыйныфлар дип атыйлар. Хәер, болай сыйныфлар дип зур итеп әйтү дөрес тә булмас, чөнки бер өй эчендә, бер хәлфә алдына утырып, беренче тапкыр әлифба һәм иман шарты күтәреп килгән җиде-сигез яшьлек балалар белән бергә инде ничәдер кыш рәттән Коръән һәм хәдис ятлап йөргән ундүрт-унбиш яшьлек малайлар да укыйлар иде. Беренче, икенче, өченче сыйныфлар дигән сүз юк. Барысы да тик ибтидаи дип кенә йөртелә.

Ә сары мәдрәсәдә рөшди сыйныфлар, ягъни анда төрле авыллардан килгән зур шәкертләр ятып укыйлар. Болар инде типсә тимер өзәрлек таза егетләр. Өсләрендә бәрән эчле билле бишмәт, башларында кама читле бүрек, муеннарында ак шарф, кулларында ак перчатка, ә аякларында читек яки тула оек өстеннән кигән тирән киез каталар. Бик көяз булырга яраталар, эскәк белән кашларын нечкәртәләр, бармакларына берәр кыз исеме язылган кашсыз йөзек кияләр һәм безнең ише вак малайларга «кайнеш» дип кенә дәшәләр иде. Аларның күбесе Дим буендагы башкорт муллаларының һәм байларының мулла-мәзинлеккә укый торган малайлары иде. Аларга йөге белән азык килә, һәм, кыш буе җылкы ите ашап, сары май ашап, бавырсак ашап ятканлыктан, алар бик тазалар һәм бик мутлар иде. Кайберәүләре качып-посып кына яр буендагы Шәйморат бичәсенә бал эчәргә дә йөриләр иде.

Менә безнең яңа хәлфәбез Коръәнхафиз да, сары мәдрәсәнең бер кечкенә бүлмәсенә урнашып, өйләгә чаклы безне, өйләдән соң рөшдиләрне укыта башлады. Рөшдиләргә шулай ук карт хәзрәт Искәндәр ахун үзе дә көн саен диярлек дәрескә керә иде.

Әйе, беренче очрашу бик нык хәтердә калган. Әйткәнемчә, кара казаки кигән, ак чырайлы, кара сакаллы чибәр кеше тузан эчендә шау итеп торган мәдрәсәгә ничектер мыштым гына килеп керде һәм, тукталып, бер сүз әйтмәстән, безнең утырышып беткәнне көтеп торды. Без әле бу елларда да борынгыча, астыбызга киез салып, тәбәнәк өстәлләр артына тезләнеп утыра торган идек. Бик уңайсыз, бик авыр иде болай утыруы, аяклар оеп, катып бетә, аларны кая сузарга, нишләтергә белмичә йөдәп, җәфаланып бетәсең. Әмма бу тәбәнәк өстәлләрдән күрәсе җәфалар алда булган икән әле.

Шулай без утырышып беткәч, Карый хәлфә дә өстәлләр алдында торган артсыз биек урындыкка килеп утырды һәм әлеге шул сүләннеке шикелле елтыр күзләрен кысып, аз гына көлемсерәп, берни сиздермичә безгә карап тора башлады. Без барыбыз да тынып калдык. Шактый дәшми торганнан соң, хәлфә акрын гына сорап куйды:

— Бүген кизү кем?

— Мин,— диде арткы рәттән бер олырак шәкерт.

— Торып җавап бир,— диде хәлфә аңа, тавышын үзгәртмичә генә.

Шәкерт торып басты.

— Мин кизү.

— Исемең ничек?

— Хәкимҗан.

Ямаулы чалбар, җиңнәре беләзегенә дә җитмәгән иске пинжәк кигән озын, чандыр шәкерткә хәлфә, аның ныклыгын, тазалыгын, холкын чамалагандай сынап, күпмедер карап торды. Аннары сорады:

— Бүген сыйныфта ничә шәкерт?

— Егерме биш.

— Килми калганнары бармы?

— Бар. Өчәү.

— Утыр,— диде хәлфә һәм кулындагы катыргы тышлы озын дәфтәрне тезләре өстенә куеп ачты да малайларны исемнәре белән дәшә башлады. Җавап бирүченең һәркайсына каш астыннан сөзеп кенә карап алды, кайберәүләрдән: «Мондагымы, читтәнме?» яки «Атаң кем?» — дип сорап та куйгалады. Бу эшне бетергәч, торып, шыгыр-шыгыр иткән өр-яңа читекләре белән йомшак кына басып, тәбәнәк өстәлләр яныннан китап-дәфтәрләребезне карап узды. Шул чагында бер малайның түбәтәе астыннан чыгып торган җилкә чәчен каты гына тартып куйды. Көлемсерәп: «Поп малаемы әллә син?» — диде. Малай дәшмәде, тик күзенә мөлдерәп яше генә килде. Тагын, күршесенә нидер пышылдаган икенче бәләкәй генә малайның маңгаена, бер сүз әйтмәстән, куш бармаклап чиртеп алды. Җиңел генә чиртте кебек, ә шулай да малайның маңгае кызарып, бүртеп чыкты. Без барыбыз да, ни өчен бу дип, бик аптырап, сагаеп калдык. Малай көлемсерәп басып торган чибәр хәлфәгә сискәнеп һәм сыкранып бер генә карап алды да, маңгаен тотып, тизрәк башын иде. Ләкин тавышын чыгармады. Бу хәлдән безнең эчебезгә, салкын бизгәк шикелле, өшеткеч бер курку йөгерде.

Хәлфә яңадан үзенең биек урындыгына барып утырды. Ак кулы белән кечкенә кара сакалын сыпыргалагандай итеп торды, шуннан соң бер-ике зуррак шәкерттән берничә генә тыныш Коръән укытып карады. Ләкин бер сүз әйтмәде, төзәтү-фәлән дә ясап тормады, аз гына уйланып утыргач, тыныч кына:

— Бүгенгә җитте,— диде,— иртәгә чынлап тотынырбыз, ә хәзер, бар, кайтыгыз!

Гариф хәлфә вакытында без дәрес бетәр-бетмәс ду килеп урыныбыздан куба идек тә, ишек төбенә ташланып, өерелешеп-көрмәкләшеп, букчалар белән сугышып, мәдрәсәне тузанга батыргач кына чыгып китә торган идек. Бу юлы инде без, иске гадәт буенча, алай дәррәү кубып ишеккә ташланмадык, ничектер, ихтыярсыздан тыелып, кабаланмыйча-шауламыйча гына киез итекләребезне, каталарыбызны киеп, бер-бер артлы мыштым гына чыгып киттек. Хәлфә, урыныннан кузгалмыйча, башын ия төшеп, сүзсез генә безгә карап калды.

Һәм менә шушы беренче очрашудан соң атна-ун көн дә үтмәгәндер, мәдрәсәдә, гомумән, һәртөрле шау-шу басылды, тузан да басылды, эчен генә түгел, бөтен ихатасын үле бер тынлык басып алды. Безнең өчен уйнау да бетте, көлү дә бетте, ә шаяруны исә бөтенләй онытгык дияргә ярый.

Икенче көнне үк инде без хәлфә кулында өч талдан үреп ишкән озын чыбык күрдек. Хәер, шәкерт өчен чыбык бик таныш нәрсә ул, әмма чыбыркы сыман итеп үргәнен безнең әле татыганыбыз юк иде. Бик зәһәр нәрсә икән. Ничектер, сиздермичә генә килеп чага торган елан төсле булып күренә башлады ул безгә... Әйтик, сыйныфта шәкертләр, китаплары өстенә иелеп, тонык кына гүләп, һични уйламыйча сабакларын ятлап утыралар. Шул чакта әлеге өчтән ишкән чыбык кинәт, баш очыбыздан выжлап, берәрсенең сыртына барып төшә. Шәкерт, чынлап та елан чаккандай, үз-үзен белештермичә сикереп-чинап җибәрә. Бөтен сыйныф сискәнеп, агарынып китә: ни булды, ни өчен бу? Берәү дә шауламады, тынлыкны бозмады бит югыйсә! Тик соңыннан гына беләбез: бичара малай, күршесенә борылып нидер әйтмәкче булган, имеш, бары шуның өчен генә!

Ләкин бу коточкыч усаллыкның безне тетрәткән, безне таңга калдырган хикмәте, билгеле инде, чыбыкта түгел, ә чыбыкны тоткан хәлфәнең үзендә иде. Беләсезме, ул бит бер сүз әйтмичә, бернинди кисәтү-фәлән ясап тормыйча, җитмәсә әле, майлы елтыр күзләре һәм кызыл иреннәре белән көлемсерәп кенә, сине сыйпап алгандай, китереп суга. Һәм, әйтергә кирәк, бик яман суга. Ә берни көтмәгән малай исә, чыбык әчесеннән өзгәләнеп китсә дә, хәлфәнең әнә шул елмайган чибәр йөзенә күтәрелеп карау белән ничектер ярым үлектәй өнсез катып кала, ачу-нәфрәте дә аның кабынып китми, күзеннән яше дә бәреп чыкмый, бары тик ак кәфендәй йөзенә искиткеч бер аптырау-курку гына җәелә. Кычкырып елый да алмый ул, елап җибәрсә, хәлфә моның өчен ишкән чыбыгын бер-бер артлы тагы да катырак төшереп ала. Башынамы, битенәме, аркасынамы — карап та тормый. Кечерәк шәкертләр моңа түзә алмыйлар иде, күбесенең кайткан чакта балак буйлары юеш була торган иде.

Шулай итеп, башта безне үзенең чибәрлеге һәм көязлеге белән сокландырган Коръәнхафиз бик тиз арада бөтен мәдрәсәнең котын алган ерткыч зобанийга әверелде. Ерткычлыгының һич чамасы юк иде. Өчтән үргән чыбык нәрсә ул! Чыбык кына эләксә, шөкер итә идек әле... Бер кызып китсә, аның елмаюы ыржаюга әйләнеп, күзләрен тәмам кан баса торган иде. Мондый чагында ул шәкертне колагыннан сөйрәп торгыза иде дә, бар көченә кизәнеп, яңагына салып җибәрә иде. Шәкерт егылып китсә, яңадан торгызып, тагын сугып ега иде. Аннары баз ишеген ачтырып, шунда типкәләп төшереп җибәрә иде. Беркөнне ул Миңнәхмәт дигән шәкертне чәйханәдән вакытында чәй китереп җиткермәгән өчен генә шулкадәр рәхимсез кыйнады ки, теге бичара һушыннан язды, авызыннан канлы күбекләр килде. Үлә дип торабыз. Бары йөзенә салкын су сипкәч кенә күзен ачты, анда да бик озак тора алмыйча, идән уртасында бөгәрләнеп ятты. Шуннан соң Миңнәхмәт мәдрәсәгә аяк басмас булды. Моның ише кансыз кыйнаулар еш кына булып тора иде. Мәсәлән, Сафиулла абзый малае Габделбариның да, шундый кыйналудан соң, колагы агып йөри башлады. Ләкин мондый имгәнүләргә Коръәнхафизның һич исе китмәде, аз гына да тыела белмәде, һаман әүвәлгечә елмайгандай ыржаеп, тиргәми-сүкми генә шәкертләрне вата бирде.

Гаҗәп, залим булган җирдә хаин дә табыла икән ул. Безнең залимның да шундый хаине табылды. Бу —җиләк-җимеш подвалы тотучы Гыйбаш сәүдәгәр малае Шәрифҗан бөкре иде. Ул яше белән шактый олы булса да, рөшдигә күчә алмыйча һаман безнең арада, ибтидаи сыйныфта утыра иде. Берәү белән дә аралашмыйча, берәү белән дә дуслашмыйча, һәркемгә шом салып, өнсез-сүзсез генә йөрүче бер карачкы булып күренә иде ул безгә. Аның колаклары иләмсез зур иде, һәм малайлар аңардан: «Бер колагын астына җәеп, икенче колагын өстенә ябынып ята икән»,— дип көлә торганнар иде.

Безнең Дәүләкәндә, «Марҗа базары» дип йөртелгән мәйданда, кино дигән нәрсә бар иде. Ул заманда без аны кино дип түгел, ә «томанный» дип йөртә идек. Билгеле, шәкертләргә томанный карау катгый рәвештә тыелган иде, шунлыктан бу сихри җир безне үзенә гел тартып тора иде. Шунда әләгүнең хәйләсен-җаен без эзләп кенә йөри идек. Һәм кайчагында, бигрәк тә кышкы ярминкә вакытында, без, кырык хәйлә корып, бик нык яшеренеп, томаннийга барып чыккалый идек. Ләкин, гөнаһ шомлыгына каршы, безнең томанный тирәсендә йөрүебез икенче көнне үк хәлфәгә билгеле була торган иде. Моның җәзасын сөйләп торасы да юк, тик бер нәрсәгә без хәйран кала идек: кайдан белгән бу зобаний? Бары берничә тапкыр шушы каһәргә юлыкканнан соң гына төшенеп алдык: Гыйбашлар томанный каршысында гына торалар ич, менә шуның ләгыйнь малае, әлеге бөкре Шәрифҗан, капка төпләреннән томаннийга кемнәр килгәнен күзәтеп тора икән дә икенче көнне хәлфәнең колагына җиткерә икән. Шул хаин аркасында без өчтән үргән чыбыкны күпме ашамадык. Безнең, иң явыз дошманыбыз булып китте ул, тик бөкре булганы өчен генә без аны эт итеп тукмаудан тыелып калдык.

Кыскасы, Карый хәлфәдән күргәннәрне сөйләп бетерәсе дә түгел һәм, дөресен генә әйткәндә, максат та ул түгел. Мәдрәсәдән читкә, зуррак дөньяга чыгыйк әле, кызыгы аның шунда. Әйе, безне утлы табада биеткән шул ерткыч залим, беләсегез килсә, мәдрәсә тышында бөтенләй икенче кеше булып йөри иде. Коръәнхафиз!.. Аның шушы бер исеме үзе генә ни тора! Һәркемнең телендә ул, һәркемнең күзе аңарда. Мәчеткә ул кара казаки өстеннән көмештәй елык-елык уйнаклаган атлас чапан, башына кара чуклы зәңгәр фәскә җыйнак кына итеп чорнаган ак чалма киеп бара. Намаз вакытында гомуми сафка басмыйча, ахун хәзрәттән бер генә адым арттарак ялгыз басып тора. Намаздан соң, хәзрәтнең уң ягына утырып, матур, көчле Мысыр мәкаме белән кычкырып Коръән укый. Аш мәҗлесләреннән дә аны һич калдырмыйлар. Анда да ул Искәндәр ахун белән янәшә утыра һәм хәзрәт рөхсәте белән Коръәнне дә ул укый. «Әгузебилләһи...» дип аз гына сакауландырып, тавышын аз гына калтырата төшеп башлап җибәрүгә, мәҗлес халкы тәмам оеп, мәрткә киткәндәй тынып кала, ә ишек артына җыелган хатын-кызлар, авызларын яулык читләре белән каплап, тәмам эреп, яшьләрен агыза-агыза аны тыңлыйлар.

Ул елны, җитмәсә, ураза да кышкы айга туры килгән иде. Бөтен рамазан буена Коръәнхафиз мәчеттә тәравих вакытында кычкырып Коръән чыкты. Аны тыңлар өчен генә халык ябырылып тәравихка йөрде. Менә шуннан соң инде Коръәнхафизның шөһрәте һәм дәрәҗәсе аеруча үсеп китте. Базарда, кибетләрдә, мәҗлесләрдә агай-эне аның зур гыйлем иясе булуына, зирәклегенә, чибәрлегенә исләре китеп, тел шартлатып сөйли торган булдылар. Хәтта күп кенә сәүдәгәр кызларының да ул, хыялларына кереп, күңелләрен кытыклый һәм төн йокыларын качыра башлаган иде.

Озак та үтми, халык арасында Коръәнхафизны карт хәзрәттән соң мәхәлләгә имам итеп кую турында да сүзләр йөри башлады. Бу инде колакны торгызырлык хәбәр иде. Дөрес, ахун хәзрәтнең фани дөньяда озак тормасын истә тотып, аның урынына имам табу мәсьәләсен мәчет картлары элек тә үзара сөйләштергәлиләр иде. Ләкин бик сак кына, ахунның үзенә ничек тә барып җитмәслек итеп кенә, чөнки бу бик четерекле, бик катлаулы мәсьәлә иде. Ә инде Коръәнхафизны ахун урынына димләүгә килгәндә, бу аеруча зур гәп, зур бәхәс тудырырга тиеш иде. Хикмәт шунда: Искәндәр ахун үзе саф башкорт иде, ә Коръәнхафиз — Ыслак татары. Шуның белән бергә, мәхәллә халкы да ике груһка бүленеп йөри: төп халык — җир-су биләүче башкортлар, ә сәүдәгәрләр, приказчиклар, тегүчеләр, итекчеләр — барысы да читтән килгән татарлар. Болар арасында мәхәлләгә хуҗа булу өчен һәрдаим яшерен көрәш бара. Башкортлар мәхәллә башына «килмешәк татарны» куярга һич теләмиләр, ә татарлар ахун хәзрәттән соң мәхәлләгә имам итеп берәр уңган, өлгер, гыйлеме шәп татар мулласын китерергә ашкынып торалар.

Шуның өстенә әле тагын Искәндәр ахунның Бохарадан укып кайткан Әхмәди атлы үз улы да бар иде. Тик бичара мәхзүм чатан иде, бер аягы белән чокырга төшеп киткәндәй, бик каты аксап йөри иде. Ләкин башкортлар барыбер аны атасы урынына имам итәргә ниятләп торалар: «Сатан булһа ла, үзебездеке булыр»,— диләр иде алар. Ә татарлар исә: «Мәхзүм ул — гарип кеше, гарип кешегә оеп намаз уку дөрес булмаячак»,— дип каршы төшәләр. Билгеле, алар шушы сылтау белән имамлыкны ничек тә башкорт кулыннан алып, татар кулына бирергә тырышалар иде.

Ә Искәндәр ахун үзе соң бу мәсьәләләргә ничек карый, нииндирәк мөнәсәбәттә тора? Моны ачык кына белүче булдымы икән? Иң элек, ахун хәзрәт табигате белән бик аз сүзле, йомык бер кеше иде. Мәҗлесләрдә дә, бүтән муллалар шикелле, үзе башлап акыл сатарга яратмый, бары сорауларга җавап кына биреп утыра, Коръәнне дә күбрәк мәзиннән укыта, хәтта мәчеттә мөнбәргә менгәч, вәгазьне дә бик кыска тота иде. Ихтимал, бу кадәресе аның картлыгы җитүдән дә килгәндер инде. Дөрес, ул бик башкорт җанлы мулла иде, бөтен исәп-гамәлендә иң элек үзенең башкортларына таяна торган иде. Ләкин татарлар белән дә ул бик нык хисаплашырга тиеш иде. Мәсьәлә шунда ки, башкортлар үзләре дин өчен, шәригать өчен алай бик җан атып тормыйлар. Гомумән, дингә җиңел карый торган халык. Күпчелеге мәчеткә бик сирәк йөри, шәригать кушканнарны бик иренеп кенә тота. Сер түгел, мәсәлән, Дим буендагы Көрмәнкәй, Шәрип, Казангол кебек саф башкорт авылларындагы мәчетләрнең сукмагын җәй көне үлән басып бетерә, ә муллалары базардан базарга кумәкләшеп кымыз эчеп, бал эчеп, курай тартып, җырлашып, кәеф-сафа сөреп йөриләр, һәм берәү дә моны гаеп итми, киресенчә, андый мулланы мактап кына сөйлиләр: шәп кеше! Менә шуңа күрә дә башкортка хәзрәт үзенеке булса шул җиткән, калганына аның артык исе китми. Ә татар инде андый түгел. Татар, бигрәк тә аның сәүдәгәрләре — гаҗәп тәкъва халык, дин-ислам өчен җанын да, малын да кызганмый, шәригать кушканны үзе үтәү генә түгел, хәзрәтнең дә бик төгәл үтәп баруын тикшереп торырга ярата. Аннары хәзрәткә тигән күптөрле садака да, мәчет-мәдрәсәне карау өчен бирелгән һәртөрле иганә дә күбрәк алардан керә. Шулай булгач, Искәндәр ахунның үз мәхәлләсендәге татарлар белән хисаплашмыйча һич мәҗәле юк. Аңа ике халыкның да көен көйләргә туры килә. Ихтимал, шуңа күрә ул имамлыкка кемне варис итү мәсьәләсе буенча барган бәхәсләрне ишетмәмешкә салынган булып, тел яшереп торырга мәҗбүрдер дә... Ләкин шулай да Коръәнхафизга аның үз мөнәсәбәте ничек, ни уйлый ул бу кинәт калкып чыккан татар турында җаны кабул итә аламы аны? Мөгаен, юктыр, хәер, ачык кына әйтүе бик читен. Дөрес, ул аңа юл куя, бернинди көнчелек-мазар күрсәтми, әмма шуннан башкасын сизү һич мөмкин түгел. Мәҗлесләрдә ул, ап-ак сирәк сакалын күкрәгенә терәп, күзләрен шешенке кабаклары астына яшереп, тын гына утыра. Сүзе бик сирәк чыга, тик әллә нидә бер генә бик хикмәтле һәм усал итеп берәр кинаяле сүз әйтеп куя, шуңа күрә аңардан бераз куркалар да, шул ук вакытта аны, билгеле,

олылап хөрмәт тә итәләр. Ләкин мәчеттә булсын, мәҗлестә булсын, хәзрәт үзенең янәшәсендәге Коръәнхафизны гүя күрми дә, белми дә. Атналар буена ул аның белән сөйләшмидер кебек.

Аның каравы, Коръәнхафизның ахун хәзрәткә булган мөнәсәбәтен ачык сизәргә мөмкин иде. Иң элек шуны әйтергә кирәк: Дәүләкән кебек зур бер җирнең бай мәхәлләсенә килеп эләккәч һәм татар сәүдәгәрләренең бихуш булып күтәреп алуларын, хәтта имамлыкка юрый башлауларын белеп алгач, бу хәйләкәр-елгыр бәндә мондый форсатка теше-тырнагы белән ябышырга тиеш иде. Ахун хәзрәт урынына имам булып калу — бу инде төшеңә дә кермәслек бер бәхет! Моның өчен иблиснең үзе булырга да, теләсәң нинди җәтмәләр корырга да ярый. Ләкин шуның белән бергә ахун хәзрәтнең башкорт булуы һәм, башлыча, үзенең башкортларына таянуы Коръәнхафизның эшен гаять читенләштерә иде. Хәтта өметсезгә әйләндерә иде. Бу эштә ачыктан-ачык татарлар ягына да басарга ярамый иде, алай иткәндә бөтенесен оттырырга мөмкин иде. Шуңа күрә безнең Коръәнхафиз, башкорт ышанучан, башкорт олылаганны ярата дип булса кирәк, иң элек хәзрәтнең үзенә ничек тә ярарга, ничек тә елышырга тырышты. Ачыктан-ачык ялагайлык күрсәтмәсә дә (чөнки аңа үз дәрәҗәсен дә сакларга кирәк иде), ул, карт хәзрәтне гүя хөрмәт итү, олылау йөзеннән, аның алдында «тәкъсир» дип, «мөбарәк зат» дип, баш иеп кенә торды Һәрвакыт янында булып, аның һәр теләген, һәр боерыгын үтәргә әзер торды. Мәчеттә ул аны култыклап мөнбәргә менгерде. Мәҗлесләрдә ул аңардан узып сүз сөйләмәде, Коръәнне дә бары аның рөхсәте белән генә укыды. Кыскасы, бик итагатьле бер кыяфәт белән, ахун хәзрәткә чынлап та бик якын торган бер кеше сыман, ул бөтен җирдә аның күләгәсе булып йөрде.

Ләкин болар гына карт хәзрәтнең күңелен җәлеп итмәсен, татар файдасына аның фикере үзгәрмәсен Коръәнхафиз сизенә иде булса кирәк. Монда юхаланып маташу юлы белән генә эш чыгарып булмаячак иде, әлбәттә. Карт хәзрәтне тәмам әсир итәрлек ниндидер бүтән бер бик көчле, бик тәвәккәл чара табарга кирәк иде. Ә безнең Ыслак мишәре, явыз, усал булу өстенә, бик чая кеше дә иде. Чынмы-ялганмы, ләкин ялкынсыз төтен булмый диләр, аның әнә шулай имамлыкны өмет итеп йөргән чагында, Дәүләкән шинкарларына барып, марҗалар белән кумешкә эчеп утыруы турында да сүзләр чыккан иде. Тик, хикмәте Хода, моның аңа бер зыяны да булмады. Зур дәрәҗәле чибәр кешенең гамәлен алай бик хөкем итмиләр, күрәсең... Менә шул әрсезлегенә һәм үзенең дәрәҗәсенә таянып, карт хәзрәткә тагы да ныграк якынаю нияте белән, Коръәнхафиз әфәнде гаҗәп бер кыю адым ясый. Ул үзенчә бик дөрес исәп йөртә, ләкин моңардан ни килеп чыкканын алда күрерсез.

Эш болай тора: Искәндәр ахунның чатан мәхзүмнән башка тагын Гайшә исемле җитеп килгән кызы да бар иде. Башкорт кызларының Дим камышыдай бер сылуы иде ул. Озын кара калын толымлы, түгәрәк карасу йөзле, сызылып киткән нечкә кашлы, чиядәй иренле, энҗедәй ап-ак тешле, елмайганда бит урталары чокыраеп китә, үзе карлыгачтай уйнак-сөйкемле иде. Сары мәдрәсәдә ятучы шәкертләр «Гайшәҗан!» дип авалар да китәләр иде. Шул «карлыгасты» бер күрер өчен генә, алар атна саен хәзрәтнең абзарындагы тиресен түгәргә йөриләр иде. Җомгадан соң ун-унбишләп шәкерт, туй мәҗлесенә хәзерләнгәндәй бик көязләнеп, ак шарфларын чорнап, ак перчаткаларын киеп, бүрекләрен кырын салып, шагыр-шогыр хәзрәт ихатасына атлыйлар. Анда аларны хәзрәтнең ялчысы озын Гыймади каршы ала, һәркайсысына йә сәнәк, йә көрәк тоттыра. Шәкертләр, шарфларын, туннарын салып, дәррәү эшкә тотыналар. Зур үрәчәле чанага тиресне төягәч, биш-алты шәкерт аны, һай-һулап сөйрәп, яр астына алып төшеп китәләр. Болай ат җикмичә генә кумәкләшеп тарту кызыграк та, һәм вакыт та озаккарак сузыла. Ләкин тирләп-пешеп эшләгән шәкертләрнең күзләре гел аш өенең ишегендә генә — шуннан Гайшәҗан комган күтәреп килеп чыкмасмы? Тик, гөнаһ шомлыгына каршы, җиз комганны күтәреп, йә чатан мәхзүм, йә карт остабикә, йә Гыймади хатыны килеп чыга, ә Гайшәҗан юк, Гайшәҗан чыкмый да чыкмый, һай, аны күрүләре бик тә читен шул! Бигрәк тә хәзрәт үзе өйдә булса, бу бөтенләй өметсез эш инде. Әмма, өметсез шайтан дигәндәй, кайчагында көтүләре бушка да китми. Гайшәҗанның да бит әле үз җаны бар, ул да бит шәкертләрнең, ишегалдында тирес түккән булып, зарыгып көтүләрен сизеп тора... Һәм менә уйламаган бер чакта гына сылу кыз, тәнкәле юка җиләнен башына бөркәнеп, аш өеннән ялт килеп чыга да башын түбән иеп кенә, кечкенә ак пималары белән вак-вак атлап кына капка төбенә китә. Урамга чыгып, кемнедер көткәндәй, бер уңга, бер сулга борылып, каранып тора... тора да, аннары керфекләрен шулай ук җиргә төшереп кенә, вак-вак атлап кына кире өйгә таба килә һәм ишеккә җиткәндә генә кыр кәҗәседәй кинәт атылып кереп китә. Авызларын ачып каткан шәкертләр шул чакта мәхзүмәнең озын кара толымлы зифа буен да, кыйгач кашлы, бит урталары чокыраеп торган түгәрәк йөзен дә ичмасам бер рәхәтләнеп күреп калалар Һәм аларга шул җитте дә! Шунда ук көрәк-сәнәкләрен ташлап (калганын Гыймади үзе дә көрәп бетерер), туннарын киеп, тизрәк мәдрәсәгә элдерәләр. Кайткач, бөтен кич буена, «ах, Гайшә хурый» да «их, Гайшә җаный!» дип, котырып киткән хыялларыннан тәмам исерешеп, киезләре өстендә аунап яталар. Бигрәк тә пешеп кенә өлгергән кып-кызыл җиләк шул! Кемнең генә авызына өзелеп төшәр икән ул татлы-сусыл җиләк?!

Менә шушы җиләктәй мәхзүмәгә безнең Коръәнхафиз нәфесен суза да инде. Әлбәттә, ул шәкерт түгел, хәзрәткә шактый якын торган, аның өенә кергәләп-чыккалап та йөргән кеше, һәрхәлдә, сылу Гайшәне күргәләгән булырга тиеш. Ничек кенә булмасын, сүлән шикелле астыртын-мыштым гына каранып йөргән Коръәнхафизда унҗиде яшьлек хәзрәт кызына дөрләп ялкынлы дәрт кабына. Ихтимал, моны мәхәббәт дип

тә атарга ярый торгандыр, чөнки мәхәббәт ерткыч җанварларга да хас нәрсә диләр. Кыскасы, ул Гайшәгә өйләнергә тели. Ләкин бу теләкнең нигезендә башлыча бик еракка каратып төбәлгән зур исәп тә ята: әгәр ул берәр могҗиза белән Искәндәр ахунның кияве булып алса, бай мәхәллә һичшиксез аныкы булачак. Башкорт бик туган җанлы, урын һәм дәрәҗәне үз токымына яки үз кардәшенә тапшырырга ярата, шулай булгач, карт хәзрәт тә, гәрчә бердәнбер улын үз урынында күрергә теләсә дә, мәхәллә халкы мәхзүм гарип ул дип каршы торгач, имамлыкны, ахыр чиктә, яраткан кызының киявенә бирер иде. Бирмичә хәле юк, чөнки мәхәлләнең иң көчле өлеше — татарлар —шуны таләп итәчәкләр. Шулай итеп, Коръәнхафиз үзенең яшерен максатларына ирешәчәк... ирешәчәк, әгәр дә Гайшә дигән карлыгачны үткен тырнакларына эләктереп ала алса.

Ул башта Гайшәгә булган өметен сиздерергә ашыкмады, ул иң элек үзен бик мәһабәт тотып, бик көяз йөреп, мәхәллә халкы алдында дәрәҗәсен күтәрергә һәм суфиланып, итагатьлек күрсәтеп хәзрәткә елышырга тырышты. Әмма ләкин коры исәп һәм азгын теләк һәрвакытта берәр очыннан сүтелә башлый. Коръәнхафизның мәдрәсәдәге ерткычлыгы тышка чыкты, халык теленә керде, кайбер ярлы-ябагай балалары укуларын да ташладылар. Хәлфә кыйнаганнан соң колагы ага башлаган әлеге Габделбаянның этисе Сафиулла абзый — әйтергә кирәк, Дәүләкәннең мөхтәрәм сәүдәгәрләреннән берсе — хәлфә өстеннән хәзрәтнең үзенә туп-туры шикаять белдерә. Бу инде хәтәр нәрсә, ышанычлы терәкләрнең берсе какшый башлау дигән сүз. Кем баласы икәнен абайламыйчарак малайның колагына тондырган икән, хәерсез!

Шуның өстенә, бозык хатыннар белән чуалуы турындагы сүзләр дә ешрак кабатлана башлады. Әгәр бу сүзләр ахун хәзрәткә барып җитә калса, Гайшәдән генә түгел, бөтенесеннән колак кагарга мөмкин. Кыскасы, Коръәнхафизга ашыгырга кирәк иде.

Ә тарихи вакыйгалар ул кышны бик куерып китте. Әйткәнемчә, Коръәнхафиз безнең мәдрәсәгә унҗиденче елның көзендә килгән иде. Бөтен Рәсәйне инкыйлаб ташкыны басып киткән бер заман иде бу. Ерак пайтәхеттән көчле инкыйлаб җиле, ниһаять, безнең кечкенә Дәүләкәнгә дә килеп җитте. Бездә дә совет дигән яңа власть урнашты. Дөрес, көндәлек гади тормыш үзенең моңарчы хөкем сөргән тәртип-низамы, дине-шәригате белән искечә һаман бара иде әле. Ләкин шуңа карамастан бу инде яңа чор, яңа заман иде. Тиздән бөтен иске тәртипләр җимерелергә тиеш. Берәүләр моны бик теләп көтә, икенчеләр хафага төшеп куркып тора. Әмма яңаның тууы кискен, каты көрәшсез булмас кебек. Эшләр шуңа таба бара.

Коръәнхафиз менә шушы буталчык, хәвефле вакыттан файдаланып калырга уйлый да. Көннәрдән бер көнне ул карт хәзрәт алдына барып, түбәнчелек белән, ләкин ачыктан-ачык сүзен башлый:

— Тәкъсир, сезгә зур гозерем бар,— ди, чибәр йөзендә әдәп белән әрсезлекне бергә чагылдырып.— Тугры сүзем өчен кәефегез кырыла күрмәсен, бары изге теләктән чыгып әйтәм, Тәңрем моңа шаһит! Үзегез күрәсез, тәкъсир, заманнар бик буталды, иртәгә ни буласын берәү дә белми, зур афәтләр килүе мөмкин... Әйе... Хосусән сезнең кебек тирә-якта дан тоткан ахун хәзрәтнең хәле бик мөшкелләнеп китүе мөмкин, ник дисәгез, әһле ислам арасында да бердәмлек бетте, груһларга бүленеп якалашу китте, хак сүзне җиткерүче дин әһелләренә колак салмый башладылар. Алай гына да түгел, бу дәһри бәлшәвикләр чыгарган влас халыкны ачыктан-ачык дин-шәригатькә каршы котырта, хәзрәт-имамнарны халыкның дошманы итеп күрсәтергә тырыша. Мондый шартларда изге мөнбәрдән әһле голәмәне хак юлга өндәүнең никадәр авыр булуын, шаять, үзегез дә аңлый торгансыздыр... Шуның өстенә, тәкъсир, мәгълүм булганча, без барыбыз да бу фани дөньяда мөсафирлар гынабыз, зинһар, сүземне авырга ала күрмәгез, әмма ни кыйлмак кирәк, картлыгыгыз бик җиткән, Хак Тәгаләнең тәкъдирен белеп булмый, үз янына чакырып алуы да мөмкин... Аз гына сабыр итегез, остазым! Сезгә булган хөрмәтем искиткеч зур, максатым иманым шикелле саф; сез галиҗәнапка бөтен вөҗүдем белән тугрылыклы булып калуда гына... Мөбарәк җилкәгездә күтәреп барган авыр йөкне ышанып миңа тапшыра аласыз. Изге юлда җаным фида — мин сезнең калканыгыз булырга телим. Тик хәер-фатихагыздан ташламагыз, тик кальбем түреннән чыккан соңгы үтенечемне генә кире какмагыз... Пәйгамбәремез алдына килеп тезләнгән сәхабә шикелле, кулларымны гарешкә сузып, йа хәзрәтем, сездән сорарга җөрьәт итәм: кадирмәүләнең ихтыярына буйсынып, кызыгыз Гайшәбикә мәхзүмәне миңа хәләл җефетлеккә бирсәгез иде...

— Җитте, хәлфә, җитте! — ди хәзрәт, кулы белән ишарә ясап һәм көчкә сулышын алып.— Сез кем хозурына килүегезне белеп килдегезме?

— Белеп килдем, тәкъсир, бик яхшы белеп килдем.

— Сез үзегезнең кем идекегезне дә яхшы беләсезме?

— Мин сезнең тугрылыклы хадимегез, тәкъсир! — ди Коръәнхафиз, өр-яңа кәләпүшле башын ия төшеп.

Карт хәзрәт, авыр күз кабакларын яртылаш кына ачып, судай тонык күзләре белән көяз-сылу Коръәнхафизга текәлә.

— Алайса ишек төбенә китеп, минем сүземне тыңлагыз: килмешәк мишәр өчен минем үстергән кызым да, әзерләп куйган мөнбәрем дә юк. Ишеттегезме?.. Барыгыз, моннан соң бусагама аяк басасы булмагыз.

Моны ишетеп, Коръәнхафиз башта агарынып китә, беравык сүз таба алмыйча катып тора, аннары кара янып, буылып әйтә:

— Сез... сез, тәкъсир, бу сүзләрегез өчен бер үкенерсез!.. Мин... мин бу тәхкыйрьне онытачак түгелмен.

Хәзрәт аңа кулын гына селти. Коръәнхафиз, елан шикелле, хәзрәт өстенә ысылдап: «Моннан соң сез миннән рәхим-шәфкать көтмәгез!» — ди дә, бәрелә-сугыла чыгып та китә.

Шулай итеп, моңарчы дәшми-тынмый гына йөргән карт хәзрәт, үз-үзенә бик нык ышанып, масаеп, имамлыкны өмет итеп, хәтта мәхзүмәгә нәфесен сузып йөргән «килмешәк мишәрне» бер селтәнүдә үтерде дә куйды. Билгеле инде, Коръәнхафиз өчен бу — хәзрәт бусагасыннан гына түгел, гомумән, мәхәлләдән куылу дигән сүз иде. Чынлап та, Дәүләкән сәүдәгәрләрендә хәзер Коръәнхафиз кайгысы юк, һәм башкорт мулласы моны бик нык исендә тоткан булса кирәк. Ләкин ул Ыслак мишәренең никадәр усал-явыз булуын гына уйлап җиткермәгән икән...

Ул кышны мәдрәсәдә укулар бик иртә тукталды, читтән килгән олы шәкертләр чана юлы өзелгәнче үк авылларына таралышып беттеләр. Коръәнхафиз да озакламый юкка чыкты. Без дә, ерткыч тилгәннән котылган чебиләр шикелле, бер иркен сулыш алдык.

Әмма шулай да ул мәлгуньнең бөтенләй үк юкка чыгуына күңел нигәдер ышанып бетми иде. Кешесе андый түгел. Кабердән әйләнеп кайта торганы. Чынлап та, Дәүләкәннең таш мәчетле бай мәхәлләсенә шулай ансат кына кул селтәп китәме соң ул! Байларның кыйммәтле келәмнәр белән түшәлгән залларында Мысыр мәкаме белән кычкырып Коръән укуларын, чапан кесәсенә шыгырдап торган кәгазьләрне карамыйча гына салып куюларын тиз генә онытыр дисезме? Юк, әлбәттә. Кеше тиресен алыштырса да, гадәтләнгән кәсебен алай җиңел генә ташламый. Дөрес, соңгы вакытта дөньялар үзгәреп киткәч, бигрәк тә ахун хәзрәт тарафыннан шундый мәсхәрәле рәвештә куылгач, Коръәнхафизның Дәүләкәндәге майлы-ширбәтле тормышы ничектер кинәт өзелгәндәй булды. Имамлыкка омтылу да бер мәлгә әһәмиятен югалтып җибәрде шикелле. Ләкин бу, ихтимал, вакытлы гына бер күренештер. Дин бар, шәригать бар дигәндәй, бәс, шулай булгач, аның мәхәлләсе дә сакланыр, муллasыз да, билгеле, тормаслар. Юк, өметне һич тә өзәргә ярамый... Аннары килеп, Дәүләкән үзе һәм аның мәчете утка янса да, Гайшәбикә мәхзүмә кала бит әле, ул бар бит әле. Искәндәр ахуннан кайтарасы үч бар, үч! Моны инде ул «та кыямәт» онытачак түгел. Җае гына чыксын, Гайшәбикәне тартып алыпмы, бүтәнчәме, әмма ул карт хәзрәтне кәҗә урынына бер үкертәчәк әле! Әйтте диярсез, һәм озакка да сузмаячак ул моны. Белеп тора ул, башкорт җитеп килгән кызын озак асрарга яратмый, бүрек белән бәргәч егылып китмәсә, тизрәк туйлап озату ягын карый. Ахун хәзрәтнең Гайшәсенә, уналты яше тулар-тулмас, тирә-якның исемле муллаларыннан һәм бай башкортларыннан яучылар килә башлаган иде инде, тик хәзрәт ни өчендер үзе генә бирергә ашыкмый иде. Ә хәзер дөньялар болай булып киткәч, сылу кызын исән-имин чагында озатып җибәрүе дә бик мөмкин иде. Шул сәбәпле Коръәнхафиз каядыр китеп югалса да, Дәүләкән тирәсеннән алай бик еракта йөрмәскә тиеш иде.

Озын сүзнең кыскасы, Коръәнхафизның тагын әле бер Дәүләкәндә «пәйда» буласын без ничектер сизенеп, көтеп йөрдек. Тик кайчан, ничек, нинди кыяфәттә пәйда буласын гына алдан юрый белмәдек — хыялыбыз җитмәде. Ә ул, чалмалы иблис, һич уйламаган чакта, һич акыл ирешмәс бер яктан килеп чыкмасынмы! Бу шулкадәр шаккатыргыч әкәмәт бер вакыйга булды ки, Дәүләкән халкы перәме бот чабып «ах» итте. Валлаһи дип әйтәм, әгәр шушы вакыйга булмаса, мин дә күпме гомердән соң ул бәндә турында вакыт әрәм итеп язып та тормас идем. Ярар, барысын да ишеткәнемчә сөйлим әле, ишеткәнемчә дим, чөнки Коръәнхафизның бу килеп китүен бары эш узгач кына белдек.

Мин инде ул кышны илдәге хәлләрнең кискенләшә баруын, мәдрәсәдә укуларның иртә бетүен әйткән идем. Чынлап та, язга чыгу белән, дөньялар тагын буталып китте. Аклар-кызыллар сугышы башланды. Каяндыр нindидер тагын чехлар дигән нәрсә калкып чыкты. Менә шул чехлар җәй башында безнең Дәүләкәнгә дә килеп керделәр. Совет урнаштырып йөрүчеләр каядыр юк булдылар. Өяздә нинди власть, кем кемгә хуҗа — белгән кеше юк. Әллә нинди билгесез, ышанычсыз бер вакыт, һәркем өендә посып ята. Баерак кешеләр хатын, бала-чагаларын читтәрәк торган тынычрак авылларга күчерделәр. Искәндәр ахун да буй җиткән Гайшәсен, солдат күзеннән саклау өчен булса кирәк, үзенең туган авылы Ташлыярга озатты.

Шулай да бу чехлар дигәнең бездә алай озак хөкем сөрмәде. Аларның солдатлары, җирле халык белән артык аралашмыйча, станциядә үзләренең вагоннарында тордылар. Тик бик фырт киенгән офицерлары гына сәүдәгәр өйләрендә граммофон уйнатып, купец кызлары белән парлап биешеп, кәеф-сафа кылып йөрделәр. Ә бер айдан соң Бәләбәй ягыннан килүче кызылларга каршы торырга теләмичә, тиз генә Дәүләкәнне ташлап чыгып та киттеләр.

Дәүләкәнгә беренче тапкыр кызыллар килеп керделәр. Кырыклап олау, ике йөзләп кеше; берәзы ат өстендә, ә күпчелеге — җәяүле гаскәр... Чын армия идеме бу — хәзер инде әйтә алмыйм — ахрысы, Богырыслан, Бәләбәй тирәсеннән җыелып чыккан аерым бер отряд кына булгандыр. Өс-башлары да, кораллары да аларның бик чуар иде; беришеләре окопларда аунаган иске шинельдән, икенчеләре үзләренең чикмәннәреннән; күбесендә штыклы озын мылтык, калганнарында көпшәсе киселгән кыска

мылтык, ә кайберләрендә бернәрсә дә юк. Хәер, араларында чын командирларча аркылы-торкылы каеш киеп, шпорлы итек киеп, ян-ягына кылыч, наган тагып йөрүчеләре дә бар иде. Кыскасы, кем нәрсә тапса, шуны кигән, шуның белән коралланган булса кирәк. Ләкин бөтенесендә уртак бер нәрсә — башларында яки күкрәкләрендә зур кызыл тасма. Шушы тасма булмаса, аларның акмы, кызылмы, яшелме икәнен дә тиз генә аерып булмас иде.

...Инде тыңлагыз. Отряд килеп кергән көннең төнендә үк Искәндәр ахунның капкасын кемдер бик каты дөбердәтергә тотына. Өй эчендәгеләр сискәнеп уяналар, тын да алырга куркып көтеп торалар. Озын Гыймади капкага чыга... һәм менә бер заман туп-туры хәзрәт яткан түр якка берәү атылып килеп керә. Шпорлы итекләрдән, кызыл галифедан, ак папахадан, папаханың бөтен буена кыеклап кызыл тасма тоткан; аркылы-торкылы каеш шлеялар кигән, бер янтыгында — кылыч, икенче янтыгында — наган. Зур кара мыеклары орчыктай ике якка сөзеп тора... Идән уртасына аякларын аерып баса да бу, түшәгендә утырган хәзрәттән кычкырып сорый:

— Йә, тәкъсир, таныйсыңмы?

— Таныйм,— ди хәзрәт, аз гына көттереп.

— Танысаң бик әйбәт, безгә хәзер исәп-хисапны өзәр вакыт җитте.

Йөзе генә түгел, иреннәре кәгазьдәй агарган һәм сакал-мыегы әкрен генә калтыранган хәзрәт, әллә артык дәрәҗәдә хәйран калудан, әллә чиксез ачу-нәфрәттән инде, телдән язып, керфеген дә кага алмыйча, Коръәнхафизга озак кына карап тора. Аннары тәмам аптыраган, исе киткән кешедәй ихтыярсыздан сорап куя:

— Ничек сине җир йотмый, ә? Йа кадир, йа мәүла!.. Күзләрен ялт-йолт йөрткән Коръәнхафиз сабырсызланып аңа кычкыра:

— Хәзрәт, Аллаңа сыеныргa өлгерерсең, минем вакытым юк, сүзне бетерик.

— Сиңа миннән ни кирәк, иблис мәлгунь?

— Гайшәбикә... Кайда Гайшәбикә?

Хәзрәт, балаларча һәртөрле куркуны онытып, кинәт тәштитләп каргарга, тиргәргә тотына:

— Алланың даргаһыннан сөрелгән хаин син, яәҗүз-мәәҗүз булып кубарылган ерткыч вәхши, син, җир күтәрмәс нәҗес, кабих зиначы син... Күкләрнең каһәре яусын башыңа, мөртәт!..— Һәм бәддога кылгандагыча ике кулының сырты белән битен сыпырып куя.

Коръәнхафиз, котырып китеп, наганын тартып чыгара.

— Тукта, хәзрәт! Күрәсеңме менә моны? Авызыңны хәзер кайнар кургашын белән тутырам... Кайда Гайшәбикә?.. Чакыр тизрәк, йә!..

— Гайшәне түгел, көчегемне дә бирмим мин сиңа!..

— Юк, бирерсең!.. Җаныңны алам, тәкъсир, сузма!

— Җанымны да син ала алмыйсың, бәдбәхет! Җаным Алла хозурына китәчәк.

— Атам!

— Ат, йә, ат!.. Ник атмыйсың?

Коръәнхафиз, сыңар күзен кысып, наганын хәзрәтнең нәкъ башына төзи... Ике кулы белән түшәгенә таянып, артка каерыла биреп утырган хәзрәт, ап-ак иреннәрен кыймылдатып, күзен дә йоммыйча наган көпшәсенә карап тора... Коръәнхафиз акрын гына наганын кире төшерә.

— Тәкъсир,— ди ул, ниһаять, карлыккан тавыш белән.— Кирелегеңә барма. Бел, синең кебек ахуннарга көн бетте хәзер... Ә минем аркада әле син котылып калачаксың... Аңлыйсыңмы шуны? Йә, ник дәшмисең?.. Чакыр алайса Гайшәбикәне, үзем сөйләшәм мин аның белән...

— Ул өйдә юк,— ди хәзрәт, тыныч кына.

— Юк? Ни өчен юк, кайда ул?

— Китте...

— Кая китте?

— Авылга.

— Кайсы авылга?

— Анысы сиңа кирәк түгел.

— Хәзрәт, син уйнама минем белән!.. Мин синең җаныңны да җәһәннәмгә җибәрермен, Гайшәбикәне дә җир астыннан эзләп табармын... Яхшы чакта әйт, кайда ул?

— Ул монда юк, вәссәлам!.. Син кабихкә ялганлап тору бик зур түбәнлек булыр иде... Ә кайда икәнен сорама, барыбер әйтмим.

— Әйтмисең?

— Әйтмим.

Коръәнхафиз, кызыл галифе кигән аякларын ике җәпле сәнәктәй аерып, җилкәсен җыерып, хәзрәткә бүредәй карап тора. Әлбәттә, хәзрәт алдашмый, юк, алдашмый, тик нишләтергә үзен? Түшәгендә атып үтерергәме, нишләтергә?

Ә карт ахун, аны үчекләгәндәй, күзенә туп-туры карап әйтә:

— Йә, мәлгунь, атсаң — ат, атмасаң — чыгып олак, җәллад шикелле алдымда басып торма!..

Шуны әйтүе була, Коръәнхафиз чытырдатып наганын кыса да селтәнеп бер... түшәмгә атып та җибәрә. Аннары бик яман сүгенеп, ишеккә бөтен көченә тибеп, атылып чыгып та китә. Һәм таң алды караңгылыгы аны, әйтерсең баш-аягы белән йота.

Шуннан соң ул, чынлап та төн эчендә эреп югалган гыйфриттәй, каядыр юк була. Иң гаҗәбе шунда ки, кызыл галифелы, ак папахалы Коръәнхафизны хәзрәттән башка Дәүләкән кешеләреннән берәү дә күрми. Ә бәлки, күреп тә танымаганнардыр? Һәрхәлдә, кызыллар отряды озак тормыйча Дәүләкәннән чыгып киткәч кенә, карт хәзрәт өендә булган төнге вакыйга халык арасына тарала. Ахрысы, шуңадыр, бу вакыйга кешеләргә нииндидер бер җен әкияте сыман булып тоела, башта аңа ышанырга да, ышанмаска да белмиләр, аннары гадәттәгечә үзләреннән әллә ниләр өстәп бетерәләр. Хәтта Коръәнхафизның яңадан әйләнеп кайтуын көтеп, сагалап йөрүчеләр дә була. Ләкин атналар үтә, айлар үтә, кешеләр бу маҗараны чәйнәүдән, ниһаять, арып туктыйлар, ә Коръәнхафиз шул китүеннән Дәүләкән тирәсендә, нә чалмадан, нә папахадан дигәндәй, бүтән инде күренми.

Отыры көчәя барган канлы һәм шомлы вакыйгалар аны безнең тирәдән шактый еракка өереп алып китте булса кирәк, югыйсә козгын шикелле ул тагын әйләнеп килеп җиткән булыр иде.

Шулай да Коръәнхафиз әфәнде безгә табышмакның бик авырын биреп китте. Кем булып чыкты бу кансыз, икейөзле кеше, кая кадәр барыр ул, язмышын кайларда, ничек итеп очлар икән дип гел баш вата идек. Әгәр кызыллар үзләре аның кем икәнлеген сизеп, башын чапмасалар, ул бит, төрле кыяфәтләргә кереп, әллә нинди явызлыклар эшләп бетерер. Бик хәтәр кеше!

Ләкин күпме генә юрап маташмыйк, ул иртәме-соңмы, барыбер һәлакәткә очрарга тиеш дигән нәтиҗәгә килә идек. Чөнки явыз кешенең башын нәкъ менә үзенең явызлыгы ашый да бит инде. Моның мисалларын без бик күп күрдек. Һәм Коръәнхафиз турында да бүтәнчә юрау мөмкин түгел иде.

1964

# Җиз кыңгырау

*(Хикәя-истәлек)*

Минем китаплар шүрлегендә тавыш-өнсез генә җиз кыңгырау тора. Кайчандыр, моннан бик күп еллар элек, туйга яки кунакка барган чагында ул кара дугага тагылган килеш ат башында йөри иде. Хәзер кара дуга да юк, кара дуга белән җигелгән ат та юк, хәтта дилбегә тотып утырган хуҗа үзе дә юк, ә менә җиз кыңгырау ничектер торып, сакланып калган... Әллә нидә бер мин аны кулыма алып, әкрен генә селкеп карыйм. Җиз кыңгырау шунда ук, телгә килгәндәй, дәртле тавышын чыгара: «Зың-зиң, зың-зиң!..» Нәкъ менә кара дугада чактагы шикелле чыңлап, яңгырап китә. Гаҗәп, вакыт дигәнең дә көчсез икән бу җиз кыңгырау алдында, вакыт аны әз генә дә, ичмасам, үзгәртә алмаган. Ул элеккечә яшь, дәртле, моңлы һәм ниндидер бер могҗиза белән мине күз ачып йомганчы кырык ел артка, яшүсмер чагыма күчерә дә куя.

## I

Әйе, яхшы хәтерлим, егерме дүртенче елның җәе иде бу. Нигъмәтулла абзыйкайларның яшел чирәмле иркен ихатасына килеп керсәм, ишек төбенә тарттырып куйган җигүле ат тора. Озын яллы сары ат җиз кыңгыраулы кара дуга һәм эшлияле камыт белән читән тарантаска җигелгән. Тарантасның артына салындырып чуар палас җәелгән, палас өстенә ике мендәр дә кабартып куелган. Моны күргәч тә мин: «Абзыйкайлар каядыр кунакка барырга җыенганнар икән»,— дип уйладым, һәм аулак өйдә калу мөмкинлеге мине шунда ук куандырып та җибәрде. Аулак өй безнеңише малай-шалайлар өчен үзенә күрә бер хөрлек инде ул... Шулай уйлап, өйгә кердем; керсәм, абзыкай белән җиңгәчәй өсләренә киенгәннәр, чыгып утырырга гына торалар. Җиңгәчәйнең өстендә киң итәкле озын кәшимир зәңгәр күлмәк, яшел камзул, башында көмеш тәңкәле тар гына калфак, калфак өстеннән чәчәкле яулык ябынган, юка шәлен иңенә салган, аягында сары читек белән кара галош. Нигъмәтулла абзыкай кыек якалы сатин күлмәк өстеннән яңа көрән пинжәген кигән, шундый ук көрән чалбардан, балакларын читек өстеннән салындырып төшергән, аягында өр-яңа галошлар. Башында шактый ямьшәйгән күк эшләпә, эшләпәсенең бер кырыеннан кара кәләпүшенең чите күренеп тора.

Мине күргәч, абзыкай гаҗәпләнүеннән кычкырып дәшә куйды:

— Пәрәмәч, син кайдан?

— Дәүләкәннән,— дим мин, авызны ерып.

— Ничек килдең, үзең генәме?

— Үзем генә. Рәхмәтулла абзыйга утырып килдем.

— Шулаймыни? Кара син! Һе, кунакка кайттым диген... Ә без менә Абзанга чыгып китәргә торабыз.

Мин ни әйтергә белмим. Нигъмәтулла абзыкай озак уйлап тора торган кеше түгел иде. Ул шунда ук җиңгәчәйгә карап әйтә куйды:

— Син! Шәкертне үзебездән калдырмыйк.

— Теләсә,— диде җиңгәчәй.

— Безнең белән барасыңмы, бәбкәм?

— Кая соң?..

— Абзанга инде... Туйга барабыз.

— Туйга?! Белмим шул,— дидем мин, шактый икеләнеп.

— Йә, нәстә тагын «белмим». Барабыз, вәссәлам! Туйдан тукмак та калмый.

— Туктале син,— диде җиңгәчәй.— Әхтәмнең өстен карыйк, кала кунагы, йөзенә кызыллык килмәсен.

Җиңгәчәй дөрес әйтә иде. Мин өйдән туйга барасымны белеп чыкмадым. Дөрес, минем өс-башым болай бик хөртидән түгел. Бик яңадан булмаса да пинжәк, чалбар, аякта ботинка, тик арбада кырык чакрым килеп, алар шактый таушалган һәм тузанланган иде... Җиңгәчәй минем өс-башымны күздән бер кичереп чыкты да:

— Алмашка күлмәгең бармы? — дип сорады.

— Бар,— дидем мин, кулымдагы төенчекне селкеп.

— Булды болай булгач,— диде Нигъмәтулла абзыкай, сүзне тизрәк бетерәсе килеп.— Ә Абзанга баргач, син аңа күлмәген каталап бирерсең*.

— Синең гел шул ордым-бәрдем булыр инде,— диде җиңгәчәй, сукраныпбрак, аннары мич кашагасыннан миңа канат алып бирде: — Бар, өстендәге тузаныңны бераз чистарт.

Мин ишегалдына чыгып, башта пинжәгемне салып, аны канат белән чистарттым, аннары чалбарыма тотындым. Үзем чистартам, ә үзем эчемнән генә уйланам: барыргамы-юкмы бу туйга?.. Әлбәттә, туй бик күңелле, бик кызык нәрсә инде ул... Минем башкорт туен да, үзебезнең Каракош туен да күргәнем бар. Хәтта әткәйнең сеңелесе Сәрвәр апаны биргән чакта кайнеш булып, җизнидән пәке дә алганым бар. Үзеңә якын кешенең туе башка инде ул, андый вакытта өстеңә яңа кием дә тектереп кидерәләр, кулыңа әзрәк акча да бирәләр, кыскасы, берничә көн эчендә кинәт үсеп киткәндәй, күрше-тирә малайларының күзләрен яндырып, һаваланып йөри бирәсең. Ә бу туйда мин кем булып йөрермен? Монда, минем белүемчә, җиңгәчәйнең сеңелесен, ягъни Нигъмәтулла абзыкайның балдызын бирәләр. Аларга бит мин кода тиешле кешенең малае гына... Ничек каршы алырлар, ничек карарлар миңа, ят халык арасында арбаның бишенче тәгәрмәчедәй буталып кына йөрергә туры килмәсме?! Аннары аулак өйдә калу да бик кызыктыра бит әле. Бусы да сирәк эләгә торган бер хөрлек... Нишләргә соң?.. Әллә бармыйча калырга микән?..

Ул арада өйдән җиңгәчәй белән Нигъмәтулла абзыкай киҗеле ашъяулыкка төргән ике зур төенчек күтәреп чыктылар. Чыгуга, абзыкай миңа кычкырды:

— Йә, шәкерт, булдыңмы?

Мин, торып калырга бер сылтау тапкандай, ашыгып сорадым:

— Ә Зөләйха кайда соң?

— Зөләйханы апакае Өфегә алып киткән иде шул,—диде абзыкай.

Әйтәм җирле ул күренми. Зөләйха өйдә булса, бәлки, калып та булыр иде. Хәзер нишлисең инде, бармыйм дип кәҗәләнә башласаң, абзыкай йә тузып китәр, аның талканы һәрвакытта коры була.

Төеннәрнең берсен, печәнне кайтарып, кучер астына тыгып куйдылар. Аннары җиңгәчәй палас япкан мендәр өстенә киң итәкләрен җыештырып менеп утырды. Икенче төенчекне ипләп кенә үзенең алдына куйды — изәргә ярамый торган нәрсәдер, ахрысы... Абзыкай кучерга бер иске сырма салды.

— Кил, утыр, синең урының шушында булыр, очып төшмәссеңме? — диде ул миңа.

Мин, алгы тәгәрмәчкә басып, кучерга менеп утырдым. Шуннан соң абзыкай, күн бияләйләрен киеп, каеш дилбегәне кулына алды да, бер аягын читкә салындырып, җиңгәчәй кырына утырды һәм авыз эченнән генә: «Тапшырдык»,— дип, атын капкага таба борды. Җиз кыңгырау күңелле генә чыңлап куйды. Капкадан чыккач, абзыкай эшләпәсен күз өстенә тарта төште, җайлабрак утырырга теләгәндәй, селкенгәләп алды, аннары: «Яле, малкай!» — диде дә дилбегәсен кагып җибәрде. Сары ат кызу гына юыртып китте. Җиз кыңгырау, бердән дәртләнеп, «зың-зиң, диң-диң» килеп, көмеш чыңлавын сибәргә тотынды. Нигъмәтулла абзыкай авыл урамыннан матур һәм кызу юыртып узарга ярата иде. Хәзер дә ул ат чапмасын, ә юырттырып кына барсын өчен дилбегәсен ике куллап нык кына тартып тотты, атка нидер дәшкәндәй итте, һәм сары ат, аның кулын тоеп, озын яллы матур башын аккоштай кырынрак бөгеп, кыска аякларын күз иярмәс тизлек белән юлны типчегәндәй, вак-вак кына алыштырып, йомры янбашын тибрәтә-тибрәтә юргалап кына элдерергә тотынды. Урамдагы малайлар уеннарыннан туктап, ишегалларында йөргән агайлар башларын борып, җиткән кызлар ачык тәрәзәләрдән сузылып безгә карап калдылар. Бер-ике эт тә, каяндыр атылып чыгып, ат аягына ташланганнар иде дә, ләкин тавышларына бик тиз буылып, читкә тайпылып калдылар. Без Каракошның озын урамын әнә шулай кешеләрне сокландырып, этләрнең ачуын китереп, матур һәм шәп кенә узып киттек.

Авылдан кырга чыккач, абзыкай дилбегәне миңа бирде. (Бу аның гадәте, авыллардан узганда гына ул дилбегәне үзе тота.) Ат та шунда ук, дилбегәнең кем кулына күчүен сизеп алды булса кирәк, юргалап баруыннан туктап, гади юыртуга күчте. Мин, тарткалап, суккалап карасам да, аны барыбер тыңлата алмадым. Каяндыр болыты белән вак чебен иярде, һәм сары ат башын селкә-селкә ялкау гына бара

башлады. Нигъмәтулла абзыкай тарантас артына киерелеп ята төште дә, тургайлар сайравына кушылгандай, «ихи-хи-хи!» дип бер сузып куйды.

Без Сынны юлы белән барабыз. Көн бик тын, бик эссе. Ике якта да яшь игеннәр йокымсырап, оеп утыра. Иген арасыннан күзгә күренмәс чикерткәләрнең иренеп кенә чырылдавы ишетелә. Юл буендагы эт эчәгесенең кыңгырау чәчәкләре тирәсендә ак, сары, чуар күбәләкләр талпына. Ара-тирә иген арасыннан берәр кошчык пырылдап күтәрелә яки кәкре томшыклы карчыга тычкан эзләп түбәннән генә, канат какмыйча йөзеп кенә үтеп китә... Үр менәбез... Сары ат йомшак юл тузанына тып-тып басып кына атлый. Абзыкай башта ниндидер бер көйне исенә төшерергә теләгәндәй әкрен генә сызгырырга тотынды. Аннары күзләрен яртылаш йомып, тавышын калтырата төшеп, башта авыз эченнән генә сузып, тик соңгы сүзләрен генә ачык әйтеп җырлый башлады:

И-и-и... яланнары сарылай кәрешкә-ә-ә-ү,
Тырышлыклар кирәк лә һәр эшкә-ә-әү.

Мин ул чагында бик нечкә күңелле идем, бик тиз тәэсирләнә идем, шуңа ачуым да бик килә иде, ләкин нихәл итим? Менә абзыкайның сузып җибәрүе белән үк минем күземә мөлдерәп яшьләрем дә килде. Әллә нинди шунда эчтәге бөтен нәрсәне бик төптән кузгата торган, бер үк вакытта бөтен җан иясен — адәмнәрне, кошларны, чәчәкләрне, бөҗәкләрне әрнеп кызганырга һәм өзелеп сөяргә мәҗбүр итә торган көй иде шул бу дәдәм көе! Һәм ул аны киң сулыш белән гаҗәп иркен, тирән, моңлы итеп җырлый белә иде. Җырлап бетергәч, тургайларны да үзенә кушылырга чакыргандай, тавышын тибрәтә-тибрәтә дәртләнеп бер «үлү... лү... лүү» дип сузып җибәрә иде. Һәм тургайлар, чынлап та аңа кушылгандай, тын, якты кырлар өстендә тагы да талпыныбрак, исеребрәк сайрарга тотыналар иде кебек.

Менә хәзер дә ул җырын әнә шулай әллә кайларгача җәелеп китәрлек итеп сузып бетерде дә, үзе дә шуңардан әсәрләнеп булса кирәк, кәефләнеп бер көлеп куйды. Җиңгәчәйгә таба борыла төшеп, кычкырып дәште:

— Ни әле син, якты көнем, уйга калдың? Әллә минем кияү булып яныңа кергән чакларым исеңә төшеп киттеме?

— Тилермә,— диде җиңгәчәй, сабыр гына елмаеп.

Мин дә, күземнән китеп бетмәгән яшьләрем аша елмаеп, аларга борылып карадым. Абзыкай кәефе килгән чакта җиңгәчәйне гел менә шулай көлеп шаяртырга ярата. Ә җиңгәчәй бер дә үпкәләргә тормый, күп вакытта сөйкемле-уйчан гына елмаеп, ачусыз гына җавап кайтара. Мондый чакларда алар миңа бер-берсен бик аңлыйлар, бик канәгатьләр һәм бәхетлеләр төсле булып күренәләр. Мин шуңа бик сөенәм, үземә дә ничектер җиңел, рәхәт булып китә.

Гомумән, мине, ундүрт яшьлек малайны, ул чакларда бәхет нәрсә ул, ярату нәрсә дигән сораулар бик борчый, бик уйландыра башлаган иде. Кешеләр ашыйлар-эчәләр, яталар-йоклыйлар, көн дә торып нужа куалар, ә бәхетлеме алар, ярату дигән нәрсә бармы алар өчен — моны һич сизеп булмый иде. Бигрәк тә гади авыл кешеләренең бәхет һәм мәхәббәт турында уйларга вакытлары да юк, аларны кирәк диеп тә белмиләр шикелле тоела иде миңа.

Ярый, сүз бик озынга китте, без бит әле Абзанга туйга барабыз. Сынны авылын күптән уздык, инде Ивановка дигән зур рус авылына җитеп киләбез. Ивановканы үткәч, Абзанга да ерак калмый.

Яхшы атта җиңел генә барсак та, шактый җилектерде. Көн эссе, юлда бер дә урман-фәлән юк, гел ачык кырдан барабыз. Сүз бетте, барыбыз да тындык. Абзыкай ат юырткан уңайга талгып, азрак черем дә итеп алды. Мине дә вакыт-вакыт йокы басып киткәләде, ләкин кулда дилбегә булгач, бирешмәдем, кыңгырауның күңелле генә чыңлавын, юл буендагы чикерткәләрнең ялкау гына чырылдавын тыңлап, үз уйларыма йотылып бара бирдем.

Ивановканың ике-өч чакрымга сузылган урамын узганда, Нигъмәтулла абзыкай уянып күзен ачты.

— Бәй, Ивановканы үтәбезмени? — диде ул, гаҗәпләнеп, һәм эшләпәсен күтәрә төшеп, тураебрак утырды.

Капка-койма буендагы таза балтырлы яланаяклы апайлар, ап-ак җитен башлы малайлар, эскәмияләрдә текә генә утырган зур картузлы рус агайлары безне кызыксынып озатып калалар. Монда абзыкайның «знакомнары» да бар икән. Шуларның кайберләре белән ул, баш кагып:

— Ә, Митрофан агай, сәлам!

Яки:

— Ә, Ягур Иваныч, здрастуй! — дип исәнләшеп узды.

Тегеләр иренмичә картузларын күтәреп, башларын кат-кат селкеп калдылар. Арадан берсе тагын:

— Князь кая китеп бара? — дип тә кычкырды.

— Туйга инде, туйга! — диде абзыкай, көлеп.— Свадба гүләем!

— Көлмә шул тикле, тиле кебек! — диде җиңгәчәй, ничектер бераз уңайсызланып.

Ләкин көлмәслек тә түгел икән шул. Нигъмәтулла абзыкай Ивановка урамыннан кыңгыраулы атта узып, менә дүртенчеме-бишенчеме балдызының туена бара, имеш. «Знакомнар» моны белеп бетергәннәр инде.

...Инде Абзанга да җитәбез шикелле... Алдагы сыртны гына менәсе калды. Шуннан Түреш буенда утырган авыл күренергә тиеш.

Бер сай чокырны чыккач, абзыкай миңа, юлдан читкәрәк борып, атны туктатырга кушты. Мин, ахрысы, кисәгрәк бордым, тарантас кинәт чалышаеп китте.

— Һәй, шәкерт,— диде абзыкай, тиз генә сикереп төшеп.— Җиңгәчәңне өстемә аудара яздың бит...

Мин нибары тик кызардым гына... Эчкәрәк узып, чирәмгә төштек. Тураеп, киерелеп, бераз сөякләрне яздык. Тузаннарны кактык, үләннең чистарак җиренә кереп, аякларыбызны ышкыдык.

Абзыкай, авыз эченнән генә сөеп, сары атның ялын тараштыргалады, тирләгән муенын сыпыргалады, тәртәсен селкетеп, аркалыгын тартып карады. Җиңгәчәй тарантастагы мендәрләрне каккалап, күпертебрәк куйды... Шулай бераз селкенгәләп алгач, яңадан утырышып, кузгалып киттек.

Сыртны менүгә, алдыбызда Түреш буе ачылды һәм ерак түгел Абзан да күренде. Нигъмәтулла абзыкай дилбегәне миннән алды, гадәтенчә, эшләпәсен күзенәрәк төшерде һәм: «Әйдәле, канатым!» — дип бер кагып җибәрүе булды — сары ат озын яллы муенын текә генә бөгеп, йонлач бәкәлләрен вак-вак кына алыштырып, томырылып юырта да башлады. Җиз кыңгырау, тәңкәләр сипкәндәй, дәртләнеп еш-еш кына тагын да чыңларга тотынды. Кырлар уянып киткәндәй булды, тургайлар гүя сискәнеп тагы да югарырак күтәрелделәр.

Минем бик кечкенә чагымда Иске Абзанда булганым бар иде. Анысы бик зур авыл булган, диләр. Мин аны белмим, хәтерләмим, тик зур кара тараканнан куркып елавым гына истә калган. Бусы моннан берничә ел элек кенә шул авылдан күчеп утырган Кечкенә Абзан. Барлыгы утызлап кына йорт булыр. Өйләр барысы да яңалар, тазалар һәм бер яклап кына утырганнар. Каршыларында гына буйдан-буйга киртә тоткан иген басуы башланып китә. Каралты-куралары, бәрәңге бакчалары болынга таба караган. Болын тип-тигез, чып-чуар чәчәк кенә, Түреш үзе күренми дә, аның кай тирәдәнрәк акканын бары яшел талларга яки биек, карт тирәкләргә карап кына чамаларга була... Бик күңелле, бик сөйкемле җирдә утыра икән бу Кечкенә Абзан. Мин үзем нигәдер менә шушындый иркен, матур табигатьтә утырган кечкенә, җыйнак авылларны күбрәк яратам.

Без менә шул авылга шәп кенә юырттырып, дәртле кыңгырау тавышы белән сәламләп килеп кердек... Авылның икенче очына җитәрәк, урам башын такта, эчкәре башын салам белән япкан йортның урыс капкасын безгә бер дәү, таза абзый ачып ук тора иде инде. Бу туй буласы йорт — җиңгәчәйнең әтиләре, ягъни кода бабайлар йорты. Капканы ачып торучы — җиңгәчәйнең агасы Хөбәйбулла кода иде.

Ишегалдына килеп керүгә, безнең тарантасны хуҗалар сырып алдылар. Куе чал төшкән түгәрәк кара сакаллы, базык бәдәнле, йомры, сөйкемле генә карт — кода бабай, аның янында ап-ак чырайлы, юка гәүдәле карчык —кодагый әби иде. Тагын бик куанышып безнең тирәдә бөтерелүче ике җиткән кыз — җиңгәчәйнең сеңелләре —миңа кодачалар. Шушы кодачаларның кайсындыр (ихтимал, әнә теге оялыбрак, арттарак торганындыр, мин әле ачык кына белмим) кияүгә бирәләр — менә шуның туе булачак инде.

Нигъмәтулла абзыкай тарантастан егетләрчә тиз генә төшеп, башта ике куллап, иелә биреп, бабасы һәм әбисе белән күреште, аннары көлә-көлә балдызларының аркаларыннан кагып, алар белән күрешә башлады... Җиңгәчәйнең төенчекләрен алдылар, үзенә тарантастан төшәргә булыштылар... Билгеле, шунда ук миңа да игътибар итеп өлгерделәр. Кучердан җиргә төшүемә, кода бабай:

— Кара, бу Әхмәтҗан коданың улы түгелме соң? —диде, куанычлы гаҗәпләнгәндәй.

— Әйе, шул үзе инде, кече кодагыз Әхтәм,— диде җиңгәчәй.

— Бәрәкалла, бик кадерле кунак алып килгәнсез икән, рәхмәт төшсен! Әйдүк, шәкерт, әйдүк! — диде кода бабай, миңа ике кулын сузып.

Бу хәтле зурлап дәшүне ишеткәч, мин шактый каушап калдым, кызарып киттем. Бигрәк тә яшь кодачаларның күзләрен елтыратып миңа кызыксынып карауларын күргәч, бик уңайсызландым, әллә ничек менә үземне котсыз, килбәтсез, ә өс-башымны ярлы, начар итеп тойгандай булдым. Алар миңа «каладан килгән кунак» дип карыйлар инде. Ә минем кай җирем генә каланыкына охшаган соң?! Талчыбыктай нечкә, озын бер малай гына ич мин... Шулай кызарып, уңайсызланып кына мин, кода бабай, кодагый әби, Хөбәйбулла кода белән күрештем, әмма кодачаларга кул сузарга көчем җитмәде.

Ыгы-зыгы килеп, исәнлек-саулык сораша-сораша күрешеп беткәннән соң, безне өйгә чакырдылар. Хөбәйбулла кода атны, йөгәненнән алып, туарыр өчен лапаска таба атлатты. Кодачалар чирәмгә тиз генә таз белән комган чыгардылар, рәшәткә башына озын сөлге элеп куйдылар. Абзыкай дәртле тавыш белән:

— Ягез, балдызлар, кайсыгыз уңганрак, безне юындырыгыз әле,— диде.

Ә мин һаман уйланам: бу ике кодачаның кайсысын бирәләр икән. Шушы түгәрәк йөзле, соры күзле, тулырак гәүдәлесенме, яки әнә теге озын кара толымлы, коңгырт күзле, нечкәрәк буйлысынмы? Тулырак гәүдәлесе яшькә олырак кебек — бәлкем, шунысындыр. Алай дисәм, нечкәрәк буйлысы ничектер уйчанрак кебек, үзен ул эрерәк, җитдирәк тота да төсле... Безгә комганнан суны да түгәрәк йөзлесе салып торды, ә тегесе аз гына юанды да тизрәк кереп китте. Шуннан соң безгә бүтән күренмәде дә һәм юрарга урын да калмады: шул озын толымлы, нечкәрәк буйлы Сәлимә дигәнен кияүгә бирәчәкләр икән инде.

Иртәгә туй киләчәк һәм никах укылачак икән. Бүген исә шуңа соңгы зур әзерлек бара. Әнә аш өенең тәрәзәләре ачык, ишеге ачык, мичен көнәнә икешәр ягудан тәмугка әйләнгән эсседә хатын-кыз кайнаша.

Зур сәке өсте туп-тулы табак-савыт, тәпән-чүлмәкләр, мичкә тыгар өчен әзерләп куйган табалар... Ничәмә төрле туй ашлары пешмидер бүген анда!

Өйнең урам башында да шул ук тамаша: кызлар тәрәзә башларына кашагалар сузалар, тәрәзә араларына чиккән башлы озын сөлгеләр эләләр, өйнең бөтен түр башын алып торган сәкегә киез, паласлар җәяләр. Чирәмгә чыгарып, су бөркеп юдырылган, сөртелгән гөлләрне кире кертеп үз урыннарына куялар. Кыскасы, тавык та чүпләп бетмәс кызу эш бара.

Безгә чәйне дә бакчадагы каен төбенә чыгарып куйган өстәлгә әзерләделәр. Чәй янына кода бабай үзе генә утырды, башкаларның вакыты юк. Кода бабайның өстендә ике генә сәдәпле ап-ак күлмәк, кара камзул, башында яңа кәләпүш. Мин аның шушы бик пакь булып күренгән кыяфәтенә һәм түгәрәкләп кырыккан чал сакаллы алсу, тыныч йөзенә кызыксынып, хәтта сокланып карыйм. Ул миңа бик күпне белгән, бик акыллы, сабыр, кешеләргә мәрхәмәтле бер карт булып күренә. Ничектер менә, ул дөньяда бик гадел торгандыр, бернинди дә начарлык эшләмәгәндер һәм берәүне дә урынлы-урынсыз рәнҗетмәгәндер дип ышанасы килә. Ашыкмыйча гына чәй ясый-ясый, ул миннән әткәй-әнкәй турында сорашты: «Әхмәтҗан кода ничек, тазамы, авырмыймы? Хәкимә кодача сау-сәламәтме? Ярый, ярый, бирсен Алла! Әнкәең —бик әйбәт, бик сабыр акыллы хатын, тик, бичара, бала хәсрәтен күп күрде. Ничәү әле, сигезме-тугызмы баласы үлеп китте бит?.. Туган берсен Ходай ала торсын әле, йә, ана кеше өчен моңардан да авыр хәсрәт бармы соң?! Син инде аның уннан берсе буласың, Хак Тәгалә үзеңә гомер бирсен, әткәң-әнкәңә картайган көннәрендә игелегеңне күрергә насыйп итсен».

Ахырдан минем үземә дә: «Укыйсыңмы? Бик яхшы, уку кирәк, укуда хәзер бар өмет!» — дип әйтеп куйды. Мин моны үземчә дөрес аңладым шикелле: заманасы шундый, укып кына чын кеше булырга мөмкин дип әйтүе иде бу аның... Әйе, минем япь-яшь кенә башымны иң нык уйландырган мәсьәлә дә шул инде, шул!

Чәй янында озак утырмадык — вакыты ул түгел. Иң элек җиңгәчәй торып, чоланда гына өстен алыштырып, аш өенә кереп китте. Бераздан Нигъмәтулла абзыкай белән Хөбәйбулла кода да, кабык арбага ат җигеп, каядыр китеп бардылар. Мин ялгызым бер эшсез калдым. Өй тирәсендә хәзер җыен хатын-кыз гына — миңа нишләргә соң? Кунакка килгән җиреңдә үз ишең булмаса, шактый читен икән ул...

Мин шулай рәшәткә буенда ялгыз басып торган чагымда ике яшьрәк хатын өйдән каршыдагы ак келәткә түшәк-ястык, чыбылдык-чаршаулар ташый башладылар. Ни өчен, кем өчен бу дип уйларга өлгермәдем, келт итеп башыма килде: ак келәткә кыз урыны әзерлиләр. Кияүне кыз янына шунда ябачаклар... Юк, миңа бу тирәдән китәргә кирәк иде. Ераккарак, аулаграк җиргә, һәм мин абзарларга таба уздым да шундагы арт капкадан болынга, Түреш буена чыгып киттем.

Башта, уйланып барудан, ахрысы, ничектер тирә-ягыма күтәрелеп карарга да онытканмын. Күпмедер җир киткәч, үземне бил тиңке куе үлән эчендә күреп, гаҗәпләнгәндәй тукталып калдым. Алдымда шау чәчәктән торган тип-тигез болын җәйрәп ята... Шушымыни инде ул Түреш буе?.. Хәйран калмаслык та түгел икән шул!

Мин үзем дә Дим буенда үскән малай, болыннарны күп таптаганым бар, әмма моның кебек тоташ чып-чуар чәчәкле, ерып йөри алмаслык куе үләнле, тын-якты болынны беренче күрүемдер. Күңелгә кинәт нур тулды, күзгә хәтта сөенеч яшьләре килде, һәм шул чакта табигатьнең кешегә газиз ана кочагыдай никадәр якын-кадерле булуын, кешенең аңа мең төрле җепләр белән бәйләнгән булуын, алай гына да түгел, кешенең бөтен хыялы-өмете, эше-гамәле шушы җылы, якты, тере сулышлы табигатьтән яралган булуын ихтыярсыз аңладым, тойдым, белдем шикелле... Болар берсе дә яңа нәрсә түгел кебек, әмма кеше йөрәгенең табигать белән мондый гомерлек тирән якынлыгын кинәт бик ачык хис итүе дә, минемчә, еш булмый торгандыр.

Үлән каплап киткән иске арба эзенә төшеп, мин юри миңа сузылгандай ышкылып, сыгылып калган ал, кызыл, күк, сары чәчәкләрне учым белән сыпыра-сыпыра, болын түрендә кара-яшелләнеп торган агачлыкларга таба киттем. Барып җиттем. Бер карагай төбендә тукталдым. Менә елгачык үзе дә. Киң түгел икән, ярлары якын, ләкин тирән генә күренә. Суы зөбәрҗәттәй яшькелт, бик чиста; күләгә урыннарда караңгыланып китә, кояшлы җирләрдә җем-җем уйнакларга тотына, ә шулай да, үз дәрәҗәсен белгәндәй, ашыкмыйча уйчан тыныч кына агып ята. Чыккан җире дә, барып койган урыны да ерак түгелдер инде бу тын-сөйкемле елгачыкның, әмма гомере аның хыял җитмәс озын булырга тиеш. Күңелнең нечкәргән чагы иде, карап тордым да шагыйрь сүзләре белән үзенә дәштем:

— Әй, агым су, ни уең, ни хәсрәтең бар синең? Ниләр күрдең, ниләр беләсең син?.. Синең буйларыңда кызлар туалар, кызлар үсәләр, үсеп җиткәч әнә кияүгә чыгып китәләр. Син аларның бит-башларын, ап-ак тәннәрен югансың, зарларын, серләрен ишеткәнсең. Ни юрыйсың син аларга, ни телисең? Тормыш әллә нинди, тормыш бик серле, кызларыңны нәрсә көтә — алар үзләре дә белмиләр... Син аларга бәхет юра, син аларга чын мәхәббәт телә, әй, агым су!

Ә агым су ага, миңа «әйдә» дигән сыман, бөтерелеп-уймакланып ага да ага. Мин ихтыярсыз аңа ияреп киттем. Яр кырындагы тар гына сукмак бормаланып куе таллыклар арасыннан, гөлҗимеш, карлыган, зелпе куаклары яныннан уза, тип-тигез, ачык, якты аланлыкларга килеп чыга... Шулай агым суга ияреп йөреп, шактый вакыт уздырып, ниһаять, авылга таба борылдым.

Җәйге озын көн күптән инде төшлектән авышса да, кояш баерга ерак иде әле. Кайтып керсәм, өйдә хәрәкәт тагы да көчәйгән кебек — көн үтә, ә эшнең очы-кырые күренми, ахрысы. Яшь кызлар, яшь киленнәр тыз-быз йөриләр, өйдән нәрсәдер чыгаралар, нәрсәдер кертәләр, селкәләр, кагалар... Кайсы кое янында нидер чайкап-чайкап юа, кайсы рәшәткә буенда комлап-катыклап самавыр, поднос агарта. Кар базының капкачы бертуктаусыз шап-шоп ачыла да ябыла — аннан өйгә чүлмәк-чүлмәк сөт, май, каймак ташыйлар. Аш өенең ачык тәрәзәсеннән мунча эссесе килеп тора — мичнең ничәнче ягылуыдыр инде, җиңгәйләр урак өстендәге шикелле янып, кызарып беткәннәр.

Лапас астында Хөбәйбулла кода белән Нигъмәтулла абзыкай түбән салындырып аскан бер зур сарыкны тунап яталар. Бая алар ат җигеп көтүгә киткән булганнар икән, менә шуннан бер кысыр сарыкны алып кайтып суйганнар. Мин килгәндә тунап бетереп торалар иде. Кода бабай да килеп карады. Хөбәйбулла кода үткен пычак очы белән сарыкның кабырга арасын берничә җирдән телеп җибәрде — кара ите юк диярлек, торганы май гына.

— Сөбеханалла,— диде кода бабай, башын селкеп.—Җыйган икән майны үзе дә, ризыкка язсын.

— Хәзрәтләрнең эченә тимәсә ярый инде,— диде Нигъмәтулла абзыкай, көлеп.

— Тимәс, ашап өйрәнгән халык. Сигез капканчы, симез кап, дигән борынгылар... Каклаган ит белән җиңел үтәр, иншалла.

Кода бабай киткәч, Нигъмәтулла абзыкай комганнан җылы су белән кулларын юды да, җиргә чүгәләп, учына яшереп кенә тәмәке көйрәтергә тотынды. Хөбәйбулла кода да аның янына чүгәләде.

— Туйны кемнәр күтәрешә? — диде Нигъмәтулла абзыкай.

— Әхмәтсафа абзыйлар, Сабирҗан җизниләр, Галекәйләр... шул үзебезнең якыннар инде.

— Сәләхи абзыйлар?

— Юк, алар катнашмый.

— Пәрәмәч, ник?.. Бик якын туганыгыз лабаса.

Хөбәйбулла кода авыр гына сулап куйды.

— Туган да бит, һәркемнең үз исәбе, кияү... Әтәй дә, мин дә әйтеп карадык югыйсә. Быел елыбыз авыр, туй кебек зур мәшәкатьне күтәрә алмыйбыз, ди... Анысы инде берәүгә дә җиңел түгел дә бит, туганлык хакына күтәрәләр. Ә үзебезне әйтмим дә инде... Туй уткәрүнең нәрсә икәнен беләсең, кияү, әнә өсәкләребездә канат белән сыпырып алырлык та бөртек калмады. Ләкин җәл түгел, бетсен, тик баш кына сау булсын, ие!.. Сәләхи абзый бик карун кеше ул, ипиен дә иләтмичә генә салдыра, ә үзенең ындырында сукмаган эскерте тора... Әмма ләкин хикмәт анда гына түгел, хикмәт бүтәндә. Аларның да бит безнең Сәлимәдән олырак җиткән кызлары бар. Мәфтуха... Менә Сәлимә китә, ә Мәфтуха калып тора әле... Шуны бер дә күтәрә алмыйлар, кияү, көнчелек ашый үзләрен...

— Алай икән,— диде Нигъмәтулла абзыкай, сузып кына.— Хикмәте бар икән шул... Кайнагай, теге ни, Сәлимә балдыз, мин әйтәм, Мәфтуханың юлын кисмәгәндер бит?..

— Алла сакласын! — диде Хөбәйбулла кода, ашыгып.—Андый нәрсә буламы соң?! Язмыш эше, кияү, язмыш эше. Берәүнең дә монда гаебе юк.

— Аптырап кына әйтүем инде, әллә Мәфтуханың да ул егеттә өмете булдымы икән дип кенә...

— Өмет... өмет, ни, һәрбер җиткән кызда була инде ул... Әмма нишләмәк кирәк, язмыш!.. Хәзерге яшьләрне беләсең, үзләре бер-берсен табалар. Мунчаклап китереп булмый.

— Дөрес инде анысы, кайнагай, дөрес... Һай, Мәфтуха!.. Әйтәм җирле, ул сездә күренми.

— Чакырдык, бик чакырдык үзен,— диде Хөбәйбулла кода, ачынып.— Инәкәй үзе барып чакырып карады, юк, килмәде, чәкчәк пешерешергә дә килмәде. Әтәсе, Сәлахи абзый, инәкәйгә әйткән, үзебез туйны күтәрешә алмагач, Мәфтуханы да җибәрә алмыйбыз дигән. Йә, шул да булдымы сүз?! Әлеге дә баягы, көнчелек... көнчелек ашый адәм баласын!

— Хәерле булсын! — диде Нигъмәтулла абзыкай, тәмәкесен җиргә басып.— Кызлы йортка кырык ат бәйләнер дигәннәр. Мәфтуха да утырып калмас әле, насыйбы табылыр.

Алар чүгәләгән җирләреннән тордылар.

— Кызлы йортлар күбрәк, егетле йортлар әзрәк шул хәзер,— диде Хөбәйбулла кода, көрсенеп.— Канатлар чыкты егетләргә, еракларга оча башладылар... Их-ма, дөньясы!

Аларның бу кыска гына сөйләшеп алулары миндә шактый күңелсез уйлар кузгатты. Менә туй, бәйрәм, зур шатлык булырга тора, ә баксаң, аның эчендә дә әнә нинди каршылыклар, ризасызлыклар бар икән... Гаҗәп бу тормыш!

Ниһаять, кич тә булды. Тузан, сөт исе аңкытып көтү кайтты. Сыер, сарыкларны капкадан ук туры абзарга куып кертteләр. Җиңгәчәй белән кече кодача, чиләк күтәреп, шунда ук сыерларны саварга киттеләр. Эш бер дә бетәр кебек түгел иде, ләкин кода бабай, күз бәйләнгәнче халыкны ашатырга кирәк, дип, кичке ашны тизрәк ашыктырырга кушты. Ике җиргә — берсен бакчадагы кечкенә өстәлгә, икенчесен, зур торыпша җәеп, ишегалдының тапталмаган чирәменә табын әзерләделәр. Барлык эшләп йөрүче кызлар, җиңгиләр, апайлар, арган аякларын сузып, чирәмдәге зур табынга урнаштылар. Бакчадагы кечкенә табын кунаклар белән хуҗалар өчен генә — без шунда утырыштык.

Безнең табынга графин белән бал да килде. Бу туйга дип әчеткән бал инде, бүген шуны ничегрәк булган икән дип эчертеп карыйлар. Кода бабай беренче башлап Нигъмәтулла абзыкайга салып бирде. Ул балның остасы —стакан кырыннан әз-әзләп кенә эчеп, авызын чәпелдәтеп торды да:

— Булган бу,— диде.— Әчүе дә җиткән, кыркуы да юк, ширбәт кенә... Әмма үзе, борыч салгандай, авызны яндырып бара. Шәп булган бу, шәп!

— Инәйнең балы беркайчан да начар булмый торган иде,— диде җиңгәчәй дә.

— Һи, минем әби, минем әби бишенче кызын бирә шул, ничек итеп аның балы начар булсын ди. Күз яшьләрен тамыза-тамыза койгандыр әле ул аны.

Кодагый әби көләргә итте, көлә алмады, күзләренә яшьләре килгәндәй булды, ләкин аларны да күрсәтмәде, тик тирләгән битен генә яулык очы белән сөртеп куйды.

Кода бабай балны миңа да салып бирде. Мин, эчимме икән, юкмы икән, эчсәм килешер микән дип, шактый аптырауда калдым. Кода бабай шуны сизгәндәй:

— Йә, йә, шәкерт, аз гына эчкәннән гөнаһ булмас,—диде.

Яртылаш кына эчтем, һәм чынлап та бал гаҗәп тәмле иде. Башта куәтен дә сизмәдем, тик соңыннан гына ул әкренләп бөтен тамырларыма җәелгәндәй булды.

Шуның тәэсиреннәндер инде, мин, өстәл тирәсендә барган сүзләргә колак салмыйча, кинәт Сәлимә кодачаны исемә төшереп, аның язмышы турында уйлана башладым. Минем бит әле аны юньләп күргәнем дә юк. Йөрми, чыкмый, менә безнең табынга да утырмады. Ярәшелгән кызлар бик оялчан булалар дип ишеткәнем бар, сизгер җәнлек шикелле, кеше күзенә күренергә бер дә яратмыйлар, имеш... Әйе, Сәлимә кодачаны да хәзер никахтан ярты гына тәүлек вакыт аерып тора, иртәгә ул кыз чагының соңгы сызыгын үтәчәк, икенче тормышка керәчәк, кеше кешесе булачак. Ни уйлый ул, ниләр кичерә, үзен ничек тотарга мәҗбүр — менә шуны белер өчен генә мин аңа хәзер бер тутырып карар идем. Күңелемнән генә: «Мин сине кызганам, мин сине көнлим, әмма сиңа бик күп, бик күп бәхет телим»,— дип әйтер идем.

## II

...Аш ашап, чәй эчкәннән соң, безгә ятарга куштылар. Мине, кунак дип, түр өйгә яткырмакчы булганнар иде, ләкин мин туй мәҗлесе өчен шулкадәр тырышып юган-җыештырган җиргә кереп ятарга бер дә теләмәдем. Рәхмәт Нигъмәтулла абзыкайга, ул гадәттәге өлгерлеге белән: «Йә, мондый кичтә кем өйдә ятсын, без шәкерт белән печәнлектә йоклыйбыз»,— диде. Кунакларның атлары өчен лапас башына күп итеп печән китереп өйгәннәр икән, без шул әле кибеп тә өлгермәгән хуш исле печәнгә палас җәеп, ике мендәр ташлап менеп яттык. Нигъмәтулла абзыкай башын мендәргә кую белән гырлап йоклап та китте. Мин алай тиз генә йоклап китә алмадым. Ишегалдында һаман кешеләр йөри, көлгән, сөйләшкән тавышлар ишетелә, лапас эчендә арбага бәйләгән безнең сары ат ашыкмый гына үлән кетердәтә, ара-тирә авыр гына сулап та куя, салдырылган авызлыгын әледән-әле чылтыратып ала. Ә аяз күктә миңа туп-туры карап тулган ай тора. Юк, тормый, китеп бара. Юк, китеп бармый, тора. Әллә тора, әллә китеп бара?! Ә тулган айга җитез-тере генә бер йолдыз ияргән... Ул да тибрәнә-тибрәнә... тибрәнә-тибрәнә... Мин йоклап китүемне сизми дә калдым.

Төшемдә кояш чыкканын күрдем. Бер биек кенә калкулык өстеннән ерактагы кара-зәңгәр офыкка карап торам, имеш. Менә бервакытны шул зәңгәр караңгылык әкрен генә сыеклана-сыеклана алсуланып яктырды. Озак та үтми, чыгып килгән кояшның нечкә кавын телемедәй сары кырые күренде. Бераздан ярты калач хәтле булып чыкты бу, аннары, чыга торгач, түп-түгәрәк ут шарына әйләнеп, җирнең читенә үк чыгып утырды. Менә бер заман аның әйләнәсендә әллә никадәр алтын кыршаулар чайкалып уйнакларга тотынды — һич карап та булырлык түгел, һәм шул чакта мин дә күзләремне кытыклаган җылы яктыдан уянып киттем. Баксам, кояш шактый күтәрелгән, кечерәйгән, кызган, һәм мине: «Тор, малай!» дигән төсле, бик әйбәтләп пешерә дә башлаган. Ишегалдында шул ук кешеләр мәш килеп йөриләр — кайчан ятып, кайчан торганнардыр, Ходай белсен!

Лапастан төшүгә, мине коедан су чыгарып торган кече кодача күреп алды. Оялчан гына елмаеп дәште:

— Әхтәм, кил, салкын су белән юын!..

Үзе, рәшәткә буена тиз генә барып, чиләгеннән комганга су салды да мине көтеп тора башлады. Мин килеп комганга үрелгәч, ул ашыгып: «Юк, юк, үзем»,— диде һәм бик теләп миңа су салып торды. Аннары сөлге бирде.

Кече кодача!.. Миннән ничә яшькә олырак икән? Бу инде теге кияүгә китәчәк кодачаның сеңелесе, кода бабайларның төпчек кызлары. Менә апасы китә, ә ул шуны гүя үзенең иң зур шатлыгы итеп, канатланып, бөтерелеп йөри. Аңламыйм мин бу кызларны. Кияүгә чыгу алар өчен дөньяның иң зур бәхете микәнни? Сакланып кына сорыйм:

— Апаңны... кызганмыйсыңмы?

Кече кодача миңа бик гаҗәпләнеп карый:

— Нигә?

— Сезне аералар ич.

— Һии,— дип көлде кодача.— Аерсалар ни, ерак китми әле. Күрешә торырбыз.

«Ә син кайчан кияүгә чыгасың?» — дип сорыйсым килде минем, ләкин тыелып калдым. «Әдәпсез»,— дияр, гәрчә бөтен кайгысы кияүгә чыгу булса да.

Ләкин шулай да минем аңардан егет турында бераз сорашасым килде.

— Кияү кем инде?

— Кем булсын, кеше! — диде кече кодача, мине үчекләгәндәй.

— Алаша түгел икәнен мин дә беләм,— дидем, үз нәүбәтемдә шаярткан булып.— Мин синнән, кайдан, нинди егет ул, дип сорыйм.

— Түбән Абзаннан, Фазылҗан малае Шакирҗан... Йә, белдеңме?

— Чибәр егетме?

— Чибәр, күргәч гайрәтең чигәр,— диде кече кодача, шаркылдап.

Нигәдер аның минем белән гел уйнап кына сөйләшәсе килә.

— Юк, мин чынлап сорыйм,— дидем мин, көлмәскә тырышып.

— Мин дә чынлап әйтәм. Ихлас, чибәр егет, тәтәй өчен бик тә чибәр...

— Йөреп өйләнештеләрме?

— Ничек... йөреп?

Мин азрак уңайсызланып киттем: әллә юри аңламаган була инде, пәри кыз!

— Ни... теге... алдан танышып, яратышып йөрделәрме дим?

— Ә-ә! — диде кече кодача, күзләрен хәйләкәр генә кысып.— Каян белим, аны кешегә сиздермиләр ич.

— Син бит сеңелесе, белгәнсеңдер әле.

— Белсәм ни, тәтәйнең гайбәтен сатарга мин юләр түгел лә.

— Өйләнешкәч, гайбәт булмый инде ул хәзер.

Кече кодача аз гына уйга калды һәм беравык миңа сынагандай карап торды. Аннары кисәк кенә:

— Ә син кешегә әйтмәссеңме? — дип сорады.

— Кемгә әйтим, мин бит монда берәүне дә белмим.

Кече кодача, тирә-ягына ялт-йолт каранып алды да, миңа иелә биреп, шыпырт кына әйтте:

— Мин алар арасында хат йөрттем.

— Шулаймыни? — дидем мин, бик кызыксынып. Аннары аптырабрак сорадым: — Хатны ничек йөрттең соң? Ул бит икенче авылда.

— Булса соң... Түбән Абзан аръякта гына... Болынга кичке уенга без моннан, ә алар теге яктан төшәләр. Менә шул чакта Шакир җизни... әем лә, ул чакта җизни түгел әле... шыпырт кына миңа хат төртә иде. Ә мин тәтәйнекен аңа...

— Алар үзләре бер дә очрашмыйлар идемени?

— Ник очрашмасыннар, очрашалар иде. Ләкин бит гыйшык сүзен телдән әйтеп булмый, хатка гына язып була... Син, шәкерт башың белән, шуны да белмисеңмени? — диде кече кодача, мине тәмам үтерердәй итеп.

Мин комачтай кызарып киттем: юк икән шул әле, гыйшык тотуның серләрен белмим икән әле мин... Ләкин дәрәҗәне саклар өчен, эре генә әйткән булдым:

— Хатны танышыр өчен башта гына язалар, ә танышкач барысын да телдән сөйләшәләр.

Кече кодача, «тиле син» дигәндәй, тагын шаркылдап көлде.

— Әйттең сүз! Аларга нигә танышып торырга, алар болай да бер-берсен би-ик күптән беләләр. Ә менә егет хат язмаса, аның яратуын кайдан беләсең? Вәт әйтеп кара!

Чынлап та шулай, күрәсең... Минем бит үземнең дә бергә укыган Әминә исемле кызга «танышыйк» дип «гыйшык» хаты язып караганым бар, тик ул, юләр, тоткан да хатны әнисенә биргән, ә әнисе минем әнкәйгә әйткән: «Малаең иртәрәк аза башлаган түгелме, Хәкимәттәй?» —дигән. Ай-һай, шул чактагы хәлемне белсәгез иде, оятымнан пәрәме җир тишегенә керердәй булдым... Әмма шулай да яратуыңны аңлатыр өчен барыбер хат язу кирәк икән, акка кара белән язмыйча торып кызларны ышандыруы читен икән. Менә кече кодача миңа нинди сабак биреп куйды бит әле...

...Тагын аңарданниләрдер бик сорашасым килә, ләкин шул арада аш өеннән кемдер аны кычкырып дәште, һәм кече кодача, кәҗә бәтиедәй уйнаклап, йөгерә-йөгерә китеп тә барды.

Җиңгәчәй миңа ак сәдәпле кара сатин күлмәгемне каталап бирде. Мин, лапаска кереп, шул күлмәкне кидем, өстемдәге пинжәк белән чалбарымны сыпыргалап кына чистарткан булдым, аягымдагы ботинкаларны печән белән сөрткәләдем. Менә кала кунагы туйга әзер дә!

Бакчадагы әлеге кечкенә өстәлдә майлы коймак белән ашык-пошык кына чәй эчтек. Берәүнең дә озаклап утырырга вакыты юк, хәтта сөйләшү дә юк, санаулы гына сәгатьләр калды. Җомгадан соң хәзрәтләр килергә, туй килергә тиеш.

Ләкин миңа болай көязләнеп, туй көтеп, эшсез йөрү бик уңайсыз иде. Йомыш-фәлән кушучы да юк һәм, күрәм, минем монда хәзергә кирәгем дә юк. Әйләндем-тулгандым да, эш белән әвәрә килгән хуҗаларның күзләреннән бераз югалып торыйм дип, тагын болынга чыгып китәргә булдым. Китәр чакта

гына түр өйнең ачык тәрәзәсеннән Сәлимә кодачаны күреп алдым. Ул тәрәзә төбенә куйган көзге алдында озын кара чәчләрен тарап утыра иде. Аның тирәсендә җиңгәчәй һәм тагын өч-дүрт кыз чуала. Үзара нидер сөйләшә-сөйләшә кызның әйберләрен — күлмәген, яулыгын, калфагын, тасмаларын, тагын әллә нәрсәләрен карыйлар, барлыйлар, куялар, кыскасы, кәләшне киендерергә әзерләнәләр. Бу кызларны «ястыкчы кызлар» дип йөртәләр икән. Алар, туйга әзерлек башланган көннән алып кызны кияү куенына керткәнчегә кадәр гел кыз янында булып, бөтен эштә аңа ярдәмләшеп, булышып торалар икән. Белеп кушканнар аларга «ястыкчы кызлар» дигән шундый кызыклы исемне!.. Мин кодачаның түбән иелгән йөзенә бераз гына карап тордым. Әйтергә кирәк, бу тип-тигез кояш карасы төшкән бик чиста, чибәр йөздә моңаю, уйлану яки хәсрәтләнү кебек һичнәрсә сизелми иде, бары үз эшенә бирелгән җитдилек һәм беркадәр тынычсызлану, пошыну гына чагыла иде сыман... Менә ул, минем онытылып карап торуымны сизеп алды булса кирәк, кисәк кенә башын күтәрде дә, нечкә кашларын җыерып, бик сәерсенеп, гаҗәпләнеп калды. Мин, тотылган каракта‍й, гаять уңайсызланып, кызарып киттем һәм тиз генә борылып, ак-караны күрмичә, китеп тә бардым. Шуннан соң инде мин аны бөтенләй диярлек күрмәдем дә.

Бүген төнлә болынга бик мул булып чык төшкән икән, әле дә кибеп беткәне юк. Үләннәр юеш, ямь-яшел, чәчәкләрдә энҗе бөртегедәй түгәрәк тамчылар җемелди, Түреш өстендә ефәктәй юка гына ак томан тибрәнә. Көн тымызык, эссе-бөркү. Бөтен әйләнәдә тын гына, әмма өзлексез бер хәрәкәт сизелә. Үлән сабакларында ниндидер бөҗәкләр әрле-бирле ашыгып йөриләр, кайбер чәчәкләргә күбәләкләр ябышып сеңгәннәр дә, аерылырга теләмичә, бары канатларын гына җилпеп куялар, ә кайбер зуррак чәчәкләр эченнән төклетуралар, тузанга баткан йонлач тәпиләрен көчкә сөйрәп, ава-түнә чыгалар. Ләкин шулай да бу тын хәрәкәттә, колак салыбрак тыңласаң, тонык кына гүләү, нечкә генә безелдәү өзлексез ишетелеп тора.

...Барам, туктыйм, колак салып торам. Тагын кузгалып китәм, тагын туктыйм. Үлән арасында мәш килгән хисапсыз кортларга, бөҗәкләргә озак кына карап торам. Аннары күтәрелеп, ерактагы күксел киңлекләргә бер гаҗәпләнеп карыйм, йа дөнья, нинди киң, нинди иркен син! Әмма шушы чиксез, нурлы иркенлектә, шушы иркә, назлы, йомшак табигать кочагында мин үземне нигәдер бик ялгыз тоям. Күңелемне ниндидер сәбәпсез сызлану, моңаю гел биләп тора кебек... Бөтен җанымда әллә нинди бер тирән кичереш бара... Нигә соң ул алай?!

Минем ундүрт яшьлек чагым. Мин күп уйланам, бик аз беләм. Тормыш нәрсә, бәхет нәрсә, мәхәббәт нәрсә ул?! Бигрәк тә мәхәббәт дигән серле ут, оят булса да әйтим, минем йөрәгемә үрмәли башлады. Тиздән шуның кабынып китәсен ничектер йөрәгемнең бөтен тамырлары белән тоеп торам, әмма мин әле аны һич аңлый алмыйм. Чынлап та, нәрсә соң ул рәхимсез һәм котылгысыз мәхәббәт?.. Кызны ярату, кызны теләү генә микәнни ул? Кыз үзе дә шулай егетне яратырга теләп тора микәнни?.. Бары шул гынамы ул мәхәббәт?.. Менә бал корты чәчәккә килеп кунды — чәчәк сыгылып төште. Бәлки, бу да мәхәббәт галәмәтедер. Бәлки, егет белән кыз да бер-берсен яратырга теләгәнгә күрә генә, бал корты белән чәчәк төсле, бергә кушыла торганнардыр. Ләкин мәхәббәтнең башымы бу, әллә ахырымы — һич аңлый алмыйм мин моны... Егет белән кыз үзләре моны аңлыйлар микән? Нинди максат хакына, нинди өмет, нинди хыяллар белән алар кушылалар икән?.. Менә мин дә, вакыты җиткәч, өйләндерегез дип әйтермен, әмма бу мине куркыта. Миңа мәхәббәт кирәк, мәхәббәт телим мин, мәхәббәт бирегез миңа!.. Ә нәрсә ул — мин аны белмим, белмим...

Әйе, бу минем ундүрт яшьлек чагым. Мин гел нидер көтеп яшим. Хыялым бары киләчәктә генә... Киләчәк мине дәшә, чакыра, әллә ниләр вәгъдә итә, ләкин мин беләм, бу әле якты, томанлы рәшә генә, аңа әле барып җитәсе бар... Нәрсә ачылыр ул томан артында — миңа билгесез, мин күрмим әле аны. Менә шушы билгесезлек мине гел борчып, үртәп, җанымны ничектер ләззәтле сыкратып тора да шикелле... Күңелдә әледән-әле өмет белән өметсезлек чиратлашып туа, вакыт-вакыт үземне, кешеләрне, җирдәге бөтен җан иясен өзелеп кызгана башлыйм, берәүгә дә афәт килә күрмәсен иде, берәү дә бу якты дөньядан мәхрүм булмасын иде дип тели-ялвара башлыйм. Ләкин шуның артыннан ук миндә искиткеч бер көч, дәрт, өмет кабына ки, мин бөтен дөньяны ал да гөл итеп, бөтен кешеләрне тигез, шат, бәхетле итеп, үземне исә бәхетнең җиде кат күгендә итеп күрә башлыйм. Өмет, өмет, өмет!.. Мин аңа ышанам, мин аңа табынам, мин аның өчен диңгезләр кичәргә, таулар аша сикерергә әзер торам... Менә нинди тиле, хыялый «бала» чагым бу минем!

Мин кайтканда, бөтен әзерлек эше беткән иде булса кирәк. Иртәнге яктагы шикелле арлы-бирле чабып йөрүләр күренми диярлек. Хәрәкәт басылган, зур бер тантана алдыннан гына була торганча, нәрсәнедер шауламыйча, кабаланмыйча сабыр гына көтү сизелә. Ачык тәрәзәләрендә әкрен генә ак пәрдәләр җилфердәгән өйгә һәм бер чүп әсәре калдырмыйча себерелгән ишегалдына чын бәйрәм төсе кергән. Эшләп йөрүче хатын-кызлар да өсләрен алыштырып, киенеп-ясанып куярга өлгергәннәр. Ишегалдында яңа кешеләр — ир уртасы агайлар һәм көяз егетләр дә күренә: болар туй каршы алырга килгән якын кардәш-ыру булса кирәк.

Ак келәт алдында ястыкчы кызлар кайнаша. Кызны киендереп-бизәндереп ак келәткә күчергәннәр инде. Ә лапас астында иярле ат тора — никах укылгач та кемдер, шул атка атланып, егеткә хәбәр итәргә чабачак.

Егетнең авылы ерак түгел, моннан өч-дүрт чакрымда гына, Түреш аръягында. Туй җомгадан соң килергә тиеш. Мәчет тә шул ук авылда (Кечкенә Абзанның үз мәчете юк). Кода бабай белән Нигъмәтулла абзыкай аның атында җомгага киткәннәр инде. Димәк, күп көтәсе калмаган.

Таза гәүдәсенә озын кара казаки, зур башына бәләкәйрәк кәләпүш кигән Хөбәйбулла кода бер өйгә кереп, бер йортка чыгып, һаман нидер кайгыртып, тынычсызланып йөри.

— Әхтәм кода,— диде ул, миңа бер үткәндә,— син тагын китеп югалма инде. Шушында гына бул!

Әллә ничек кызык та, уңайсызрак та булып китте миңа: «кода» дип бик зурлап дәшә һәм бер үк вакытта балага әйткәндәй югалмаска да куша.

Озак та үтми, кода бабай белән Нигъмәтулла абзыкай сары атта җомгадан кайтып керделәр. Шунда ук өйдә, ишегалдында хәрәкәт көчәеп китте. Ак келәт алдындагы ястыкчы кызлар тыз-быз килә башладылар. Капка төбенә бала-чага җыелды... Ул да булмый, икенче атта чалма-чапан кигән хәзрәтләр дә килеп керделәр. Кучерда утырган кара сакаллы абзый атын өйнең нәкъ баскычы төбенә китереп туктатты. Муллалар тарантастан ашыкмыйча гына төшеп, сәлам бирделәр:

— Әссәламегаләйкем!

Кода бабай, Хөбәйбулла кода, Нигъмәтулла абзыкай өчесе беравыздан бик тайяр рәвештә сәламнәрен алдылар:

— Вәгаләйкүм-әссәлам! Хуш килдегез, хәзрәтләр!

— Туйлар мөбарәк булсын!

— Амин, шулай булсын. Әйдәгез, рәхим итегез! Юл биреп, муллаларны өйгә уздырдылар. Алар кереп утырырга һәм дога кылырга да өлгермәгәннәрдер, каяндыр ерактан, ап-ак арыш кырлары түреннән «зиң-зиң» чыңлаган кыңгырау тавышлары ишетелде. Бу тавыш ерак һәм әкрен булса да, капка төбендә торучы бер егет яман кычкырып җибәрде:

— Туй килә-ә!

Әйе, туй килә, туй! Бар да капкага ташланды. Мин дә урамга йөгереп чыктым. Ләкин атлар күренмиләр иде әле, тик кыңгырау тавышлары гына отыры дәртләнебрәк, ашыгыбрак яңгырый-көчәя бара иде. Бөтен капкалардан йөгерешеп хатын-кызлар, бала-чагалар чыкты. Алар белән бергә, «кайда, кемнәр килә?» дигән төсле, ялт-йолт каранып, койрыкларын үрә бастырып этләр атылып чыктылар. Юл буенда йөргән тавыклар, алдан ук керер тишек эзләгәндәй, муеннарын суза-суза читән буйларына йөгерештеләр...

Ниһаять, авыл очындагы сай чокырдан бер пар ат атылып килеп чыкты, аның артыннан икенче пар ат, аңардан кала ялгыз ат җиккәннәре килеп чыга тордылар. Ничәү үзләре? Бишәү, юк алтау икән... Һай, киләләр, агай, һай, киләләр дә соң! Җирең генә чыдасын!

Капка төбендәге бала-чагалар, чебиләр шикелле, читкә сибелделәр. Ишегалдына беренче пар ат шаулап килеп керде. Кучердагы егет, ишегалдын уратып, атларын баскыч төбенә үк китереп туктатты. Тарантастан, хатыны белән, кара сакаллы, таза гына бер абзый — баш кода төште. Аларны кода бабай һәм башкалар: «Әйдүк, хуш килдегез, рәхим итегез!» — дип, зурлап каршы алдылар. Беренче атлар кузгалгач, икенче пар ат ишек төбенә килеп туктады. Бусыннан егетнең эти-әнисе — түп кода белән кодагый төштеләр. Түп кода — озын, җирән кеше —ир уртасы гына икән әле, күрәсең, беренче малаен гына өйләндерә торгандыр... Аларны аеруча зурлап каршы алдылар. Шулай итеп, атлар ишек төбенә килеп туктый тордылар, китә тордылар, ә төшкән кунакларны каршы алып, ирләрен түр якка, хатыннарын уртадагы салкын якка кертә тордылар.

Кунакларны каршы алып беткәч, хуҗалар да өйгә керделәр. Мине дә, билгеле, онытмыйча кунаклар янына чакырдылар. Без кергәндә зур сәкенең түренә, бөкләп салган юрганнар өстенә хәзрәтләр һәм кодалар менеп утырганнар иде инде. Калган кунаклар да, дәрәҗәләренә карап, хәзрәтнең ике ягына тезелешеп утырдылар. Минем урыным сәке кырыендагы тәрәзә янына туры килде. Кода бабай да, урындык алып, хәзрәтләргә каршы утырды. Урын җитмәгән кайберәүләр (кызның яшьрәк туганнары) ишек төбенә чүгәләделәр.

Түрдә тыныч кына көтеп утырган чалма-чапанлы, ак сакаллы карт хәзрәт зәгыйфь кенә тавыш белән:

— Йә, утырышып беттегезме, җәмәгать? — дип сорады.

Кода бабай түбәнчелек белән генә:

— Ие, хәзрәт, барыбыз да әзер,— диде.

— Алайса башлыйбыз.

— Аллага тапшырдык, хәзрәт! — диде кода бабай.

— Изге сәгатьтә! — дип куйды түп кода.

Өйдә, өйдә генә түгел, тышта, хәтта урамда да тантаналы тирән бер тынлык урнашты. Иң мөһим, иң киеренке вакыт җитте — бөтен кеше җитди уйчан, аз гына моңсу бер кыяфәттә оеп калдылар. Хәзрәтнең никах укуы хатыннар ягына да ишетелсен дип, ак пәрдә корган өй ишеген чак кына ачып куйдылар. Ул якта да шылт иткән тавыш юк иде.

Шуннан соң хәзрәт аз гына тынып торды, бөгелә төште һәм күзләрен йомыбрак, зәгыйфь-моңсурак тавыш белән әгузе-бисмалласын әйтеп, ашыкмыйча гына никах укый башлады. Кешеләр уйлары белән каядыр бик еракка киткәндәй, алларына гына карап, һичбер селкенмичә тыңлап утыралар. Минем нигәдер

кинәт кенә күңелем тулып китте, ирексездән күз төпләрем кымырҗый башлагандай булды... Кемдер бу минутта миңа бик кызганыч булып тоелды, ләкин кем — кызмы, эти-әниләреме —үзем дә белмим. Тәмам аптырадым инде бу калтыравык күңелнең һич юкка да нечкәреп китүенә...

Никах укылып бетте, хәзрәт һәм аның артыннан барлык кунаклар берьюлы кулларын күтәреп, озак кына дога кылдылар. Мин дә, кулларымны кушырып, нидер укырга тырышып карадым, ләкин ни сәбәптәндер бөтен белгән догаларымны онытып җибәргәнмен, бары өзек-өзек сүзләрне генә кабатлап, ахырдан «бәхет телим, бәхет телим» дип битемне сыйпап куйдым.

Дога кылып бетүгә, башта кода бабай торып хәзрәткә, икенче муллага һәм мәзингә кәгазь акчалар сузды. Тагын озын гына итеп дога кылдылар. Аннары Хөбәйбулла кода, аның артыннан Нигъмәтулла абзыкай торып садака бирделәр. Нәкъ шул чакта иярле атка атланган бер егет, тасыр-тасыр чабып, капкадан чыгып китте: кияүгә никах укылуын хәбәр итәргә.

Садака бирү, дога кылулар беткәч, кунаклар алдына ике-өч кулдан тәлинкә-кашыклар тарата башладылар. Кече яктан ике зур миски белән аш керттеләр. Нигъмәтулла абзыкайны оста табынчы дип әйтә торганнар иде. Менә ул, егетләрнеке сыман сылу гәүдәсе белән табын каршына басып, бик әйбәтләп бисмилласын әйтеп, иң элек никах укыган хәзрәттән башлап, бөтен кунакларга да аш салып чыкты.

Аштан соң ике таба бәлеш, бәлештән соң зур табакларда өеп туралган ит чыгардылар. Кунаклар шуларның барысын да сүзсез генә, күңел биреп, бик тырышып һәм яратып ашадылар. Тик һәр аштан соң хәзрәтләр, өлкән кодалар ашны олылап, өйгә бәрәкәт-муллык теләп, мактау сүзләре әйткәләп куйдылар.

Бушаган табакларны кире чыгаргач, агач тустаганнар белән өрек суы бирделәр. Кунаклар салкын ширбәтне шул савытлардан гына кашыклары белән алгалап капкаларга тотындылар.

Менә бер заман урам буйлап бик кызу сиптереп килгән кыңгырау тавышы ишетелде. Кунаклар бу тавышка аз гына колак салгандай булдылар, ләкин беркем бер сүз әйтмәде. Әдәп һәм тынычлык саклап, алларына карап кына ашый-эчә бирделәр. Кем килә, ни өчен килә — гүя аларның моңарда эшләре юк. Ә бит кияү килә, кияү!.. Тик Хөбәйбулла кода гына ашыгып урыныннан торды да, сак кына басып, өйдән чыгып китте.

Ул да булмый, төпкә озын яллы кара ат, мичәүгә тимеркүк җиккән тарантас ишегалдына бик кызу гына килеп тә керде. Мин дә, бөтен әдәп-кагыйдәне онытып, тизрәк тәрәзәгә борылдым. Пар ат ак келәт алдына шып итеп туктады. Атларны бик көязләп җиккәннәр — ялларына ал, кызыл тасмалар үрелгән, калын кара дугада куш кыңгырау, тәңкәле йөгән, тәңкәле эшлия, эшлиянең каеш чуклары ике яктан асылынып тора... Тарантастан дүрт егет төштеләр. Егетләр барысы да карадан киенгәннәр, барысының да башларында кара кәләпүш, аякларында ялт иткән итекләр. Егетләрнең берсе култык астына, сары яулыкка төреп, бәләкәй генә гармун да кыстырган... Ләкин боларның кайсысы соң кияү тиешле? Әһә, әнә берсенең башында сай гына кырпу бүрек икән, кулында кечкенә саквояж... Шулдыр инде кияү дигәне, һичшиксез, шул!.. Калганнары — кияү егетләре.

Аларны келәт ишеге төбендә ястыкчы кызлар сырып алдылар. Аз гына ыгы-зыгы килгәннән соң, егетләр, кулга-кул тотынышып, киек казлардай тезелештеләр. Алдан — баш кияү егете, аңа тотынганы — кияү үзе, калганнары — кияү егетләре. Шулай тезелешкәч, алар келәт ишегенә килделәр. Келәт ишеген тотып торучы бер җитү кызмы яки яшь хатынмы, башын чөебрәк егетләргә нидер әйтте. Баш кияү егете аңа нәрсәдер дип җавап кайтарды. Тагын кара-каршы нидер әйтешеп алдылар. Әйләнәдә тыңлап торучы ястыкчы кызлар дәррәү генә көлештеләр. Шуннан соң теге кызмы яки хатынмы келәт ишеген ачып җибәрде һәм егетләр эчкәре уздылар.

Шушы минуттан минем дә бөтен күңелем-уем келәт эченә күчте. Бу вәкарьле, дәрәҗәле, йомык-салынкы картлар җыелган никах мәҗлесе минем күземә бөтенләй күренмәс булды. Бөтен хикмәт, бөтен кызык хәзер тегендә, ак келәт эчендә. Кияү егетләре, ястыкчы кызлар анда нишлиләр, нәрсә сөйлиләр, кияү үзен ничек тота, кыз ни хәлдә — шуларны минем үлеп күрәсем, ишетәсем килә. Ләкин мин менә шушы табында, шушы хәзрәтләр янында әдәпле, инсафлы, тыйнак бер шәкерт булып утырырга тиешмен. Кагыйдәсе шундый — кузгалырга ярамый... Ә олылар тыныч, олылар, берни булмагандай, гамьсез генә чәйләрен эчәләр, тик ара-тирә язмышлар, тәкъдирләр, гомерләр турында бик мәгънәле сүзләр әйткәләп куялар. Никадәр ерак та соң бу хыялый яшьлек белән акыллы картлык арасы, уйласаң!..

Ниһаять, мәҗлес бетте, хәзрәтләрне озаттылар, карт кодалар, хәл алыр өчен, утырган җирләрендә генә мендәргә таяндылар, ә кайбер яшьрәкләре тәмәке тартырга абзар артындагы бәрәңге бакчасына киттеләр. Мин дә, мәҗлес бетүгә, тизрәк ишегалдына чыктым. Кияүне китергән пар атны лапас астына тарттырып, тезгеннәрен чишеп кенә баганага бәйләп куйганнар. Ак келәтнең ишеге ябык, анда кияү үзенең егетләре белән генә чәй эчеп утыра. Келәт янына беркем бармый, хәтта ул якка карамаска да тырышалар. Бары кияү белән кызны карарга куелган бер елгыр яшь хатын гына озын чәч үргеченә таккан чулпыларын чыңлатып, тыз-быз кергәләп-чыккалап йөри. Минем белүемчә, кыз әле үзе дә бу минутта чыбылдык эчендә генә утырып тора, кияү егетләре ашап-эчеп киткәч кенә ул кияве янына чыгачак.

...Нишлим, кая барыйм икән дип аптырап торган чагымда, мине Нигъмәтулла абзыкай үз янына дәшеп алды. Ул тирләгән, күлмәк якасын чишеп җибәргән, кулындагы зур чиккән яулык белән һаман битен-муенын сөрткәли.

— Син беркая да китеп югалма,— диде ул миңа.—Хәзер кодалар белән кунакка китәбез.

— Нишлим мин анда? — дидем мин, тискәреләнеп.

— Менә тиле. Син дә кунак бит, кодалар белән йөрерсең.

— Кирәкми, йөрисем килми,— дидем мин, отыры үҗәтләнеп.

— Күп сөйләнмә,— диде абзыкай кискен генә.— Монда калып нишлисең?.. Ярамый, килешми...

«...Ярамый, килешми» — бу сүзләр мине ничектер сискәндереп, айнытып җибәргәндәй итте. Ни өчен дип мин, абзыкайдан гына түгел, үз-үземнән сорарга да оялдым, тик бер нәрсәне бик яхшы аңлап алдым: юк, ярамый, ярамый бу тирәдә йөрергә!

Озак та үтми, кунак өйнең ишек төбенә кыңгыраулы атлар килеп туктады һәм кодалар чыгып шуларга утырыша башладылар. Нигъмәтулла абзыкайның да аты җигүле иде, без шуңа өчәүләшеп утырдык... Билгеле булганча, кыз ягының якын туганнары чиратлашып «туйны күтәрешәләр». Никахтан соң менә шул туйны күтәрүчеләргә йөрү башлана. Без хәзер кода бабайның бертуган энесе Әхмәтсафа абзыйларга барабыз икән.

Барасы җир ерак булмаса да, кодаларны атта гына йөртәләр. Пар атлар, алар артыннан ялгыз атлар тезелешеп, артык кызуламыйча, урамны салмак кына бер әйләнеп, хуҗа йортына барып керәләр. Анда кунакларны бик зурлап каршы алгач, ирләрне бер табынга, хатыннарын икенче табынга кертеп утырталар.

Табыннарга аш-су килә, чирекләр белән бал килә, мәҗлес башлана. Бу инде эчке мәҗлесе, күңел ачу мәҗлесе. Монда аракы да була икән, ләкин аны ачыктан-ачык табынга куймыйлар. Яшьрәк кунакларны ымлап кына мич артына чакырып алалар да шунда гына кырлы стаканга салып бирәләр. Буеңа сеңдер, картларга сиздермә!

Мәҗлес башлангач та кияү егетләре үзләренең кара һәм тимеркүк җиккән пар атларында ишегалдына чаптырып килеп керделәр. Аларны да хуҗалар зурлап, шаулап каршы алдылар. Гадәт буенча, алар, кияүне кәләш янында калдырып чыккач, менә шулай кодаларга кушылып, мәҗлестән мәҗлескә йөриләр. Тик һәр көнне иртән иң элек кияү янына кереп, кодачаларның коймагын ашап, чәй эчеп чыгалар.

Кияү егетләре килгәч, мәҗлес бердән җанланып китте. Дәртле, шат күңелле егетләр сәкегә менеп, аяк бөкләп утыруны белмиләр дә. Хуҗаларга каршы торып җырлау, җор-шаян сүзләр әйтү, мәҗлесне көлдерү — менә аларның бөтен эшләре шул. Шуның өчен дә алар кияү егетләре!

Кыз ягының яшьрәк туганнары — Хөбәйбулла кода, Нигъмәтулла абзыкай, тагын бер кара мыегын тәкә мөгезедәй бөтереп куйган чандыр кеше — гел аяк өсте торып, кунакларны сыйлыйлар. Әле берсе, әле икенчесе бал тулы стаканны кодаларның әле берсенә, әле икенчесенә җырлап бирә. Җырны күбрәк Нигъмәтулла абзыкай белән әлеге тәкә мөгезедәй кара мыеклы кеше алмашлап җырлыйлар. Кайчагында исә икәүләп, билләреннән тотынышып һәм көй уңаена чайкала биреп, җырлап җибәрәләр. Кара мыеклының тавышы калынрак, Нигъмәтулла абзыкайныкы нечкәрәк, бергә кушылгач, гаҗәеп матур, ягымлы килеп чыга. Һәр җыр артыннан күңелләрне дәртләндереп җибәрердәй берәр кушымта әйтеп куялар:

> Атлый-йөгерә килә күк юрга,
> Безнең лә дуслык китсен күп елга.

Шулай үткәзеп җырлаганнан соң, кунаклар бер шаулашып алалар:

— Һай, ирләрнең асыллары!

— Рәхмәт, афәрин, мең яшәгез!

Кияү егетләренең берсе кыстырып йөрткән кечкенә гармун да тик тормый. Егет аны бер тезе өстенә генә куеп, җәя бөккәндәй ике якка да тигез генә тартып, уйнап җибәрә. «Баламишкин», «Эрбет», «Сәфәр» кебек кыска көйләрне гаҗәп шәп сиптерә, парин!.. Көй уңаена иңбашларын да дәртле генә сикертеп тора, җитмәсә. Аңа карап, кунакларның да йөзләре, аяк-куллары ничектер үзлегеннән хәрәкәткә килә башлый. Ә бию көен тартып җибәргәч, шунда ук берәр җиңел сөякле абзый бөеренә таянып, башын чөя биреп, уртага чыгып та баса һәм читеге белән идән тактасын «чаш-чош» ышкый-ышкый текә генә йөзеп тә китә. Аннары урта бер җирдә, иңбашларын уйнатып, вак-вак кына тыпырдап тора башлый. Кунакларның моңа бик тә кәефләре килә, барысы да шаулап көләргә, ә кайберләре исә әтәч кагынган шикелле терсәкләрен җилпеп: «Һайт сине, әйт шуны!» дия-дия такмакларга тотыналар.

Әнә шулай, әле озын көйгә сузып, әле гармун тартып, җырлап та биеп дәвам итә бу туй мәҗлесе... Миңа да бик күңелле иде, мин хәтта зурлар рәтенә кереп, үземнең малай гына булуымны да онытып җибәрдем.

Мәҗлес бетеп, кунаклар таралганда таң сызыла башлаган иде инде. Кодаларның күбесен туй күтәрүчеләр, бүлешеп, үзләренә алып киттеләр, ә төп кода белән башкода кыз йортына кайттылар. Анда аларны салкын итләр, әчегән бал белән чәй табыны көтә иде. Мин күргән-кичергәннәрдән бик арыганга күрә, чәйгә кереп тормыйча, мыштым гына лапас башына үрмәләдем. Лапаска үтешли, аш өенең ишеге төбендә басып торган кече кодачаны, тагын берничә кызны күрдем. Алар нәрсәдер көтәләр иде, ахрысы, миңа дәшмәделәр. Мин, нигә болар йокламыйлар икән дип, гаҗәпләнебрәк уздым.

Үткән төннән җыелмыйча калган хуш исле печәндәге урынга менеп ятуым булды — бөтен талчыккан тәнем рәхәткә чумгандай изрәп оеп та китте. Ләкин чү! Бу нинди тавышлар? Башымны кисәк кенә күтәреп, колак салып тора башладым: нечкә кыңгырау тавышына кушылып кызлар көлүе ишетелде, ул да булмый, сыздырып гармун уйнап җибәрде. Әнә нәрсә икән ул. Кияү егетләре, пар атларына ястыкчы кызларны утыртып, урам әйләнәләр... Әнә алар киттеләр, буш, тын авыл өстенә тәңкәләр чәчкәндәй, җыр, моң сибә-сибә киттеләр.

Мин изелгән мендәремә тизрәк капландым — йөрәгемне кинәт нидер бик авырттырып, телеп узды. Нигә мин алар белән бергә түгел, нигә мин алар кебек түгел?! Кызлар, кызлар, ни өчен минем берүземне генә калдырып киттегез? Малай гынамыни әле мин сезнең өчен?..

Сызланып, сискәнеп күпме йоклаганмындыр, белмим, менә бер заман кемнеңдер аягымнан кат-кат тартуын сизеп уяныл киттем. Күземне ачсам, лапаска менә торган баскычта җиңгәчәйнең башы! Бите кып-кызыл, чәче юеш, маңгаенда, борынында сыпырып алырлык тир бөртекләре.

— Әхтәм, бар тизрәк мунча кереп чык, дәдәң киенә калды,— диде ул миңа.

— Әй лә, бармыйм, йоклыйм әле,— дидем мин.

— Юк, бармыйча ярамый,— диде җиңгәчәй,— сансызлык була ул... Туйда озак йоклап ятмыйлар, кайткач йокыңны туйдырырсың.

Берни эшләр хәл юк, тордым да, чалбар белән ботинкаларымны гына киеп, мунчага киттем. Туй уңае беләндер инде, сипләп яңартылган мунча курчак өе кебек иде. Кечкенә тәрәзәсенә ак пәрдә корылган. Чишенә торган мунча алды чип-чиста, агач чөйләргә кызыл башлы сөлгеләр эленгән, киң сәкегә зур ак җәймә ябылган... Шул сәкедә ычкырлы кызыл ыштаннан гына Нигъмәтулла абзыкай, тезләренә таянып, тәмәке тартып утыра. Какча тәне кара янган, беләк һәм күкрәк мускуллары таштай беленеп тора, сукса — җенеңне өзәр!

— Әйдә, шәкерт! — дип каршы алды ул мине.— Кияү мунчасында бер юынып чык.

Кияү мунчасы?! Их, ниләр генә күрсәтми бу туй миңа! Хәер, минем бу хакта ишеткәнем бар иде инде. Иртән иртүк, кеше-кара аякка басканчы, кияү белән кызны мунча кертеп чыгаралар. Гадәттә бу җаваплы эшне берәр уңган-житез, тәҗрибәле хатын башкара. Ул мунчаны өлгертә, мунчаны карый, саклый, ә вакыты җиткәч, келәт ишеген әкрен генә шакып, яшьләрне мунчага дәшә. Моның өчен аңа, билгеле, кияүдән зур гына бүләк тә тия.

Яшьләрне шулай кеше күзеннән яшереп кенә кертеп чыгаргач, мунчаның парын-суын яңартып дигәндәй, башта кодаларны, аннары безнең ише кунакларны кертә башлыйлар. Мунча туйда иң зур сыйлардан санала.

Мин чишенеп эчкәре уздым. Мунча әле май кебек җылы иде, чиста иде, казанында һәм зур агач кисмәктә суы җитәрлек иде, хәтта мич авызында чуен белән селтесе дә тора иде. Идәндә ялт иткән зур таз белән җиз комган, тәрәзә төбендә исле сабын. Ләүкәдә яшь каеннан бәйләгән ике себерке ята, ахрысы, шулардан мунча эченә җиңел генә, тәмле генә бер хуш ис таралган...

Өстемә тагын берәрсе килеп кермәсен дип ашыкканга күрә мин, чабынып-нитеп тормыйча, кечерәк бер табакка кайнар суны таманлап кына салып алдым да, ләүкәгә менеп, каткан чәчемне юарга тотындым.

Мунчадан чыккач та мине ак келәткә, кияү янына чакырдылар. Башта җиңгәчәй килеп әйтте:

— Хәзер бар инде, кияү белән күрешеп чык,— диде.

Мин аптырабрак калдым, ничектер тез буыннарым да хәлсезләнебрәк киткәндәй булды. Кияү янына керү бик зур эш булып тоелды миңа... Шул ук вакытта бу бик кызыктыргыч та иде, моңарчы минем хыялым гел шул кияү белән кыз тирәсендә әйләнде бит. Шулай да җиңгәчәйдән икеләнеп кенә сорадым:

— Ярар микән соң, җиңгәчәй, мин бит әле бик яшь, малай гына.

— Син инде егет исәбендә, үзең кунак кеше,— диде җиңгәчәй.— Керергә кирәк.

— Ә нишләрем соң мин анда?

— Кияү белән күрешерсең, никах белән котларсың... Син бит кала шәкерте.

Ул да булмый, безнең янга кече кодача очып килеп җитте. Мин аңа тагы да бер гаҗәпләнеп карадым: апасының кияүгә чыгуына бу кадәр дә исереп, шатланып йөрер икән сеңел дигәнең!.. Килеп җитүенә, мине тотарга теләгәндәй кулын сузып:

— Әйдәгез инде, әйдәгез җизни янына, сезне көтәләр,—диде ул, кабаланып.

Көтеп үк торалар микәнни дип, борчылып уйладым мин эчемнән генә һәм, каршы әйтер сүз тапмыйча, лапас түбәсеннән пинжәгемне алып, каккалап кидем дә кече кодача артыннан иярдем.

Көн яктысыннан келәт эченә килеп кергәч, башта бернәрсә шәйли алмыйча тордым. Ягымлы хатын-кыз тавышы: «Әйдәгез, рәхим итегез!» — диде һәм: «Менә монда утырыгыз»,— дип, бер буш урындыкны күрсәтте. Мин утырдым. Шуннан соң гына тирә-юнемне ачыграк күрә башладым. Келәт эче иңеннән-иңенә зур, чуар чаршау белән бүленгән булып чыкты, ләкин хәзер аны, көн яктысы төшсен дип, ике якка тартып куйганнар. Сул яклап бүрәнә стена буена эре чәчәкле ситсы чыбылдык корылган. Чыбылдык эчендә караваT... Менә шул чыбылдыклы караваT янына гына кызыл чүпләм эскәтер япкан кечерәк өстәл куелган. Өстәлдә бармак төртер урын юк: тәлинкәләрдә өем-өем төрле камыр ашлары, эреле-ваклы савытларда бал, май, чәкчәк, конфетлар, чирек белән әчеткән бал, нәкъ уртада таба белән коймак... Өстәл

әйләнәсендә дүрт егет утыралар. Ә өстенә күпертмә иңбашлы яшел сатин күлмәк, аягына сары читекләр кигән, күкрәкчәле ак алъяпкыч бәйләгән, ак батист яулыгын колаклары өстеннән генә кыстырып куйган, бер егерме биш-утызлар тирәсендәге чибәр хатын кунакларын аягүрә кыстап-кыстап сыйлый... Кияү белән кыз янына куелган хатын инде бу,— үзе бик алчак, җор булса кирәк, теле-телгә йокмый, гел нидер әйтеп, көлдереп кенә тора.

Минем күзем, билгеле, барысыннан элек чыбылдык авызында гына утырган егеткә төште. Шушы кияү үзе! Нәкъ үз өендә яңа гына урыннан торган хуҗа сыман утыра: кыек якалы сары сатин күлмәгенең изүен чишеп җибәргән, кара кәләпүшен арткарак этәргән, кулындагы кызыл башлы озын сөлге белән тирләгән, кызарган муенын-битен әледән-әле сөрткәләп ала... Мин аңа карадым да каттым, башымда әллә никадәр сораулар туды: кем ул, кемнең баласы, нинди кеше, яхшы егетме, белеме бармы, яратып өйләнгәнме, бәхетлеме?.. Заманның кемне үз, кемне үги итүен бик нык сизә башлаган чагым, шуңа күрә кемнең кем булуы мине үтә кызыксындыра иде. Сүз дә юк, бу кияү — чын авыл егете. Байданмы, ярлыданмы — ул кадәресен ачык белмим, һәрхәлдә, кода бабайларның үзләре кебек таза тормышлы кешенең баласы булырга тиеш дип уйлыйм. Ул инде бик яшьтән түгел, ким дигәндә бер егерме бишләрдә булыр. Кызыл Армиядә хезмәт итеп кайткан дип ишетеп калган идем, димәк, күпме-азмы чарланган егет!

Ул түгәрәк йөзле, киң генә маңгайлы, кысыграк күзле, туры гына борынлы, борын төбендә бер чеметем генә мыегы да бар. Юк, болай сөйкемле генә, Сәлимә кодача яратырлык егет, минемчә... Бәхетлеме ул? Хәер, бу бик балаларча уйлау инде. Бәхетле булмыймы соң! Әнә киң битендә елмаю катып калган, хәтта ашаган чагында да язылмый ул. Кысык күзләре аз гына түгәрәкләнеп, ничектер хәрәкәтсез карыйлар. Ул күзләрдә ниндидер хәйран калу, ис китү, хәтта бераз миңгерәүләнеп калу да сизелә кебек... Өстеңә шундый бәхет аугач ни, миңгерәүләнерсең дә шул!

Мин утыргач, күпмедер ара авыр гына тынлык булып алды. Ахырда кияү телгә килеп, теге хатыннан йомшак кына сорады:

— Бу егетне кем дип беләбез инде?

Хатын, шуны гына көткәндәй, гаҗәп бер өлгерлек белән:

— Бу инде, кияү, Нигъмәтулла баҗаңның агасы Әхмәтҗан коданың улы Әхтәм була,— диде.— Безгә кече кода, кала шәкерте, зур кунак!

— Ә-ә! — дип кенә сузды кияү моңа каршы. Мин уянып киткәндәй булдым. Бурлаттай кызардым. Әлеге шул «кала кунагы», «кала шәкерте» дигән сүзләре белән тәмам җелегемә үттеләр инде. Өфедән түгел мин, Бәләбәйдән дә түгел, ә Дәүләкән дигән зур бер авылдан гына... Дөрес, Дәүләкән ул волость үзәге, аның бик шәп базары була, ярминкәсе була, анда зур-зур таш тегермәннәр бар, станция белән элеватор да бар, ләкин шулай да аның беркайчан да кала булганы юк әле. Мин үзем дә шәкерт түгел, укучы (урта мәктәпнең 7 нче сыйныф укучысы) —«шәкерт» сүзе бездә күптән төшеп калды инде, аны хәзер кода бабай шикелле картлар гына әйтәләр. Ә монда шуны белепме, әллә белмичәме, тоталар да йә «шәкерт», йә «кала кунагы» диләр. Үзләренчә миңа куштанланып, зурлап дәшүләреме соң бу?! Әллә шулай исемләгәч, үзләренә күңелле буламы? — Янәсе безнең туйда, малай гына булса да, кала кунагы да бар бит әле!..

Шул арада уңган хатын мине бик юмартланып кыстарга тотынды:

— Ягез әле, кече кода, балдан, майдан, коймактан рәхим итегез. Ягез, йә, тартынып тормагыз, кияү ашларын авыз итегез!

Шулай диде дә алдыма, стакан тутырып, әче бал да куйды.

Кылт итеп исемә төште: котларга кирәк ләбаса! Моңарчы кияүгә шаккатып утыру аркасында мин аны онытып та җибәргәнмен. Нишләргә хәзер! Әлбәттә, «кала шәкерте» була торып, миңа мокытлык, җебегәнлек күрсәтергә һич ярамый иде. Ахырда, үземне беркадәр кулга алып, бал тулы стаканны күтәрә төшеп:

— Сезне ни... никах белән котлыйм, ие,— дидем мин, тотлыгып кына.

Барысы да шуны көтеп кенә утыргандай беравыздан:

— Ә, рәхмәт, рәхмәт, кода, рәхмәт, шәкерт,— диештеләр. Кияү егетләре, тышаулары бушагандай, шактый җанланып та киттеләр. Алар барысы да тазалар һәм көязләр иде. Кәләш куенында яткан иптәшләренә җылы дуслык, куштанлык күрсәтеп, шул ук вакытта аңа ничектер яшерен бер кызыксыну-көнләшү белән дә карап, ләкин моны берәүгә дә сиздермәскә тырышып, күбрәк табынчы яшь хатынга уен-көлке әйткәләп кенә утыралар.

Хәер, минем уем аларда түгел, башкада иде: ни өчен табында яшь кәләш үзе юк — шуңа бик гаҗәпләнеп утырам. Хикмәт нәрсәдә икән? Әллә аңа, гомумән, кияү егетләре янына чыгып утырырга ярамыймы икән? Алай дисәң, кияү кырында гына эчелеп бетмәгән чынаяк тора, өлеш тәлинкәсендә ашала башлаган сыныклар ята. Болар аныкы булырга тиештер бит, югыйсә кияү белән янәшә кем утырсын?! Димәк, Сәлимә кодача мин керә башлагач кына торып, чыбылдык эченә качкан. Ни өчен бу? Ни өчен ул ундүрт яшьлек малайдан кача. «Кала кунагын» санламыймы, өнәмиме, аңа юри күренәсе килмиме? Юк, мондый хәлнең булуы мөмкин түгел, бу мине соң дәрәҗәдә кимсетү булыр иде. Ышанмыйм, юк, ышана алмыйм. Әмма нәкъ менә шушы минутта мин кинәт бик ачык итеп, эчке бер калтырану белән эшнең серен

аңлап алгандай булдым: Сәлимә кодача миннән ояла! Миннән, ундүрт яшьлек малайдан, оялып кача! Йа Тәңре, ул минем хәлемне аңлаган, ул минем артык сизгер, артык тиз җәрәхәтләнүчән йөрәгемне аяган!..

Әмма соң ул, кодача, минем күз алдымнан качса да, хыялымнан кача аламыни?! Менә ул нәкъ каршымда, чыбылдык эчендә генә утыра. Мин хәтта аның чыбылдыкны аз гына төртеп торган тез башларын да шәйлим шикелле... Тез башларын гына түгел, бөтен кыяфәтен — сөрмәле күзләрен дә, хуш исле чәчләрен дә, уйчанлана төшкән, әмма бәхетле көлемсерәгән йөзен дә, ничектер үсебрәк киткән нечкә-сылу гәүдәсен дә ап-ачык күреп торам кебек... Юк, ул минем хыялымнан барыбер качып котыла алмый, котылу мөмкин түгел!

Ишегалдында кыңгырау тавышлары ишетелде, кодаларны тагын берәрсенә мәҗлескә алып китә торганнардыр. Тышта хәрәкәт көчәйде, кешеләрнең йөргән, сөйләшкән тавышлары ишетелә башлады. Кияү егетләре дә, сыйлаучы хатынга рәхмәтләр әйтеп, кияүгә, дусларча шаярту белән, кәләше янында күңелле вакыт үткәрүен теләп, урыннарыннан кузгалдылар. Алар да хәзер кодалар белән бергә мәҗлескә китәргә тиешләр.

Келәттән чыккач, егетләрнең берсе, үз иткәндәй, минем җилкәмә кулын салып, сорады:

— Йә, Әхтәм, безнең белән йөрисеңме? Бу дуслык ишарәсе миңа бик ошады, ләкин шулай да:

— Белмим шул,— дидем мин, икеләнебрәк.— Алай ярыймы соң?

— Һи, ник ярамасын,— диде егет, бер дә исе китмичә.— Син дә кунак вет, бергә-бергә йөрү күңеллерәк булыр.

Белмим, бәлки, бу кагыйдәгә сыеп та бетмәгәндер (мин бит кыз ягыннан туйга катнашучы), ләкин Нигъмәтулла абзыкай да, җиңгәчәй дә миңа ярамый дип әйтмәделәр. Шулай итеп мин кияү егетләре белән бергә, аларның пар атларына утырып, мәҗлесләргә йөри башладым. Атлар шәп, егетләр шәп, билләреннән алышып, аягүрә генә баралар, юлда берәр җәяүле күренсә, «һайт!» дип бер кычкырып кына салалар. Мине алар, бу шәкерт очып төшә күрмәсен дигәндәй, урталарына алып кына йөртәләр иде.

Мин инде ничә җирдә мәҗлестә булуыбызны сөйләп тормыйм, бик озынга китәчәк. Әмма берсен, гомерлеккә күңелдә уелып калганын тулырак итеп сөйләмичә булдыра алмыйм.

Туйның өченче көнендә иң соңгы мәҗлес тагын кыз өендә булды. Шушы мәҗлес белән кыз ягында туй тәгәлләнә, кодалар да, кияү белән кыз да, кызны озата баручы җиңгәләр дә моннан китәләр, туй кияү ягына күчә... Соңгы озату мәҗлесе булганга күрә, бирегә кызның бөтен агай-энесе һәм тирә-як күршекүлән дә җыелган иде. Өйгә генә сыйдырып бетерерлек булмагач, үз-тирә гадирәк кунаклар өчен бакчага да бер табын әзерләнгән иде.

Өйдәге түр табынга, билгеле, кодаларны, кияү егетләрен, кызның өлкән туганнарын һәм кайбер мөхтәрәм кунакларны утырттылар. Шул «мөхтәрәмнәр» арасына, гөнаһ шомлыгына каршы, мин дә эләктем. Бакчада гына торып калмакчы булган идем дә, Хөбәйбулла кода үзе чыгып мине чакырып кертте, янәсе, минем урыным монда түгел, тегендә... Һай, эләкмәгән генә булсам иде!.. Башта ук бу мәҗлес минем өчен зур газапка әверелде. Бөтенләй хур була, оятка кала яздым. Кыска гына араданиләр уйлап, ниләр кичерергә туры килмәде миңа...

Эш менә нәрсәдән башланды. Табынга кунаклар утырышып беткәч тә, ике кеше зур тәпән белән койган бал күтәреп керттеләр. Тәпәнне сәкедән читкәрәк, бер урындык өстенә куйдылар. Нигъмәтулла абзыкай, һәрвакытта беренче табынчы, кәләпүшен егетләрчә кырын салып тәпән янына басты. Аңа кечерәк өлеш тәлинкәсенә куеп, бер стакан бирделәр. Нигъмәтулла абзыкай тәпәннең өстен ачты, чүмеч белән бер шөбердәтеп коеп карады, аннары кунакларга карап әйтте:

— Хөрмәтле кодалар, туебызның иң зур сые — кыз балы табынга килде. Сезнең рөхсәт белән шуны рәхим итеп башлыйк.

Шулай диде дә балны, чүмеч белән стаканга салып, иң элек кияүнең атасы төп кодага сузды. Төп кода: «Рәхмәт, котлы булсын киленебезнең балы» дип, иплән кенә стаканны алды да бетергәнче эчеп куйды һәм тәлинкәсенә өч сумлык акча салып, стаканны кире кайтарды. Аңардан соң табынчы стаканны тутырып башкодага сузды. Башкода да, рәхмәт әйтеп, балны бетергәнче эчте дә күпмедер акча салып, стаканны тәлинкәсе белән кире бирде. Шуннан соң инде Нигъмәтулла абзыкай стаканны рәттән йөртә башлады. Табынның түр очында утырган беренче кунакка, аннан икенчесенә, өченчесенә — шулай күчә-күчә китте кыз балы. Һәм эчкән бер кунак тәлинкәгә акча салып кире кайтара торды... Менә шушы хәлне күргәч, мин тәмам коелдым да төштем. Стакан миңа да килеп җитәчәк бит, мин дә акча салып кайтарырга тиешмендер инде. Йоласы шулай икән аның, ә йоладан котылу юк. Нишләргә? Минем кесәмдә бер генә тиен дә акчам юк лабаса! (Мин бит туйга эләгәсемне белеп өйдән чыкмадым.) Менә кайда ул хурлык! Әгәр минем кем булуымны, кайдан килүемне белмәсәләр иде —беләләр шул, барысы да бик яхшы беләләр. Белү генә түгел, «кала кунагы» кыз балына күпме төшерер икән дип көтеп утыра торганнардыр әле... Мин хәтта уттай яна башладым. Уйларым, читлеккә эләккән кош кебек, бәргәләнергә тотынды: нишләргә, нишләргә? Әллә мыштым гына чыгып сызаргамы!.. Юк, мөмкин түгел, барысы да күрәчәкләр, беләчәкләр, эчләреннән генә көләчәкләр. Ә стакан якынлаша, отыры якынлаша...

Миңа җитәргә ике-өч кенә кеше калды. Булмый, булмый күрәсең инде бу хурлыктан котылып... Соңгы өмет белән Нигъмәтулла абзыкайга карыйм, аңа ничек тә миңа бирмә дип ымлыйсым килә, ләкин ул

минем якка сыңар күзен дә төшерми, ичмасам! Балны бутап-бутап стаканга сала, мактап-мактап кодаларга суза, әйтерсең изге бер эш башкара. Шулай да ахыр чиктә генә миңа бер күз ташлап алды шикелле, ләкин мин аның карашын тотарга да, аңлашырга да өлгермәдем, билгеле.

Ниһаять, минем чират та килеп җитте. Нигъмәтулла абзыкай, бөтен табын ишетсен дигәндәй, кычкыра биреп, бал тулы стаканны миңа сузды.

— Йә, шәкерт, иплэп кенә тот әле кодача тәтәңнең ширбәтен!

Стаканны ничек кулга алуымны, иреннәремә ничек китерүемне белмим, барысы да йокыдагы кебек эшләнде шикелле, тик бер нәрсәне бөтен тирем белән сизеп торам — кунакларның күзе миндә генә... Маңгаема салкын тир бәреп чыкты, ә үземә бик эссе кебек... Күпмедер эчкәч, берни күрмичә, калтыранган стаканны кире сузуым булды, нәкъ шул мизгелдә Нигъмәтулла абзыкайның бик ачык итеп әйткән сүзләре ишетелде:

— Шәкерт акчасын миңа биреп куйган иде,— диде ул, тыныч кына, һәм түш кесәсеннән бер сумлык кәгазьне чыгарып, кунакларга күрсәтә биреп, тәлинкәгә дә салды.

Бу шулкадәр вакытлы һәм табигый килеп чыкты ки, кодалар төрле яктан:

— Һай, афәрин!

— Муладчина! — дип куйдылар.

Ә миңа... миңа ни, яшем тәгәрәп төшмәсен өчен бары иренемне тешләп, башымны гына түбән иярге калды. Юк, оялудан түгел бу, җиңеләеп китүдән, сөенечтән, рәхмәттән генә... Нигъмәтулла абзыкайга рәхмәттән. Мин дә адәм баласы, сизгерлеккә бик мохтаҗ адәм баласы!

Ә мәҗлес кызганнан-кыза бара. Кыз балын акча салып авыз итү бетте, хәзер инде табында берничә стакан йөри. Нигъмәтулла абзыкай тирләгән-кызарган, чиккән зур яулыгы белән һаман сөртенеп тора, үзе бертуктаусыз сөйләнә, көлә, кайчак нечкә сары мыегының очын хәйләкәр генә бөтереп тә куя. Аңардан җыр көтәләр,—ул моны белә, тик җаен гына көтә... һәм, менә, турая биреп, тамак кыргалап алды да, пинжәк чабуын кайтара төшеп, әз генә калтыравык нечкә тавышы белән сузып җырлап та җибәрде:

Утырдым ла көймәнең, ай, түренә,
Карадым ла суларның төбенә.
Су төпкәйләрендә һич кара юк,
Хак язганны күрми чара юк.

Мәҗлес шундук тынып калды. Җыр һәркемнең йөрәген учлап алды. Кеше, мәрткә киткәндәй, сагышка, хыялга чумды. Кемгәдер яшьлеге кайтты, кемнеңдер заяга узган гомере күз алдыннан кичте, кемнеңдер күптән онытылган ярасы ачылды, әмма барысын да ниндидер бер искиткеч ләззәт-шашыну билэп алды.

Җыр бетүгә табын, аз гына өнсез торганнан соң, дәррәү хәрәкәткә килде. Әллә шатлыктан, әллә исәрләнүдән тыела алмыйча яман шауларга, көләргә тотындылар, кемдер сүз таба алмыйча: «Эх-х, Нигъмәтулла-а!» — дип өзгәләнеп кычкырып куйды... Кемдер шунда ук яңадан җыр башлады — уздырырга теләп, тагы да ныграк исертергә теләп, дәртләнеп, кабынып җырлый башлады. Кайсылары җырга кушылды, кайсылары үз стаканын хөрмәт иткән кунагына сузып: «Кодакаем!», «Абзыкаем!» — дия-дия, аны үтереп кыстарга тотынды. Кемдер миңа да стаканын төртте, атамны мактарга, анамны мактарга тотынды... Балдан, җырдан, шау-шудан минем башым әйләнде, һавага чыгасым килде, һәм, ыгы-зыгыдан файдаланып, урынымнан мыштым гына кузгалдым.

Чыксам, ишегалдында да кунаклар, тыз-быз йөргән хатын-кызлар. Ак келәтнең дә ишеге ачык. Ул тирәдә дә ниндидер хәрәкәт сизелә... Мин тукталып тормыйча абзарларга таба уздым да арт капкадан гына болынга чыгып киттем. Яраттым мин бу Түреш буен. Тынлыгына, иркенлегенә, чәчәкләренә, бөҗәкләренә иялэшеп өлгердем. Монда ялгыз йөрү рәхәт, барысы да — якты-йомшак тынлык та, иркә-оялчан чәчәкләр дә сине әкрен генә, сөеп кенә юата кебек, уйларың-хәсрәтләрең үзлегеннән тына-басыла, ә ялгызлыгың үзе бер рәхәт, тансык юанычка әйләнә... Әйләнә дигәннән, минем башым чынлап та әйләнә шикелле... Әллә башым түгел, күз алдымда дөнья әзрәк әйләнәме?.. Алай дисәң, әнә-ә тегендә, кечкенә елгачык буендагы карт тирәкләр тик кенә, тын гына утыралар төсле. Алардан да ары, тау итәгендә кечкенә авыл да үз урынында бик нык утыра кебек... Ләкин шулай да, күз алдында бернәрсә селкенмәсә дә, бу чиксез дөнья үзенең кырлары-болыннары, таулары-сулары, авыллары-шәһәрләре белән йә уңга, йә сулга әкрен генә чайкаладыр төсле. Тик кенә тору мөмкин түгелдер инде ул. Һәм күңелгә гаҗәеп сәер бер уй килде: әгәр дә мәгәр, мин әйтәм, дөнья болай чак-чак кына түгел, ә кинәт бик нык йә уңга, йә сулга чайкалып китсә, ни булыр иде икән? Җирдәге бөтен нәрсәнең асты өскә килер иде бугай... Алла сакласын! Юк, мин моны теләп, юрап әйтмим, тик уйнап кына, малай башым белән хыялланып кына әйтәм. Ә бәлки нидер сизенептәдер...

Бу туй арасында вакыт дигән нәрсә бөтенләй онытылып, буталып бетте. Бүген нинди көн, кайсы число — һич хәтерли алмыйм. Июль башы — шуны гына беләм. Кояшның зураеп, бик әкрен генә бата торган чагы. Әнә ул җир өстенә сузылып яткандай иренеп кенә сырт читенә төшеп бара...

...Шактый киткәнмен икән, кире борылдым. Ниндидер кызыкны күрми калырмын төсле, ашыгыбрак атларга тотындым. Шул ук арт капкадан гына ишегалдына кайтып кердем. Өй тирәсе гү-ү итеп тора,

ишегалдында да, урамда да җигүле атлар тора, ә ак келәтнең ачык ишегеннән егетләр һәм кызларның җырлаганы ишетелә. Ахрысы нәрсәгәдер әзерләнәләр, нәрсәдер булырга тиеш.

Лапас яныннан узганда, күземә ике кеше чагылды. Бәлки игътибар итмичә узып та киткән булыр идем, ләкин караңгылана төшкән лапас эчендә берәүнең багана төбенә сәер генә чүгәләп утыруы мине туктата калды. Кем ул, нишләп утыра?.. Мышык-мышык борын тарткан тавыш та ишетелеп куя. Әллә елый инде шунда?.. Якынрак атлап, чынлабрак карасам, багана төбенә чүгәләп, башын учлап утырганы Хөбәйбулла кода булып чыкты, ә аның янында тик кенә басып торган кара кәзәкиле, озын кеше кемдер — анысын танымадым. Хөбәйбулла коданың иңбашлары селкенеп-селкенеп куя, мыгыр-мыгыр нидер сөйләнә, үгезнекедәй калын тавышы сынып-сынып китә:

— Ух, Шәмсетдин абзый-й, белмисең, китә, йөрәк парәм китә! Тагын бер күгәрченебезне оч-очырабыз-з... Бишенчесен озатам бит, Шәмсетдин абзый, бишенчесен. Ят кулларга китеп бетәләр шулай, ох-ый!

Дәү, таза кешенең әллә кайдан гына сыгылып чыккан саран күз яшьләре!.. Мин ник күргәнемә үкенгәндәй, йөгерә-атлый китеп бардым. Каршыма җиңгәчәй очрады. Туктатып сорадым:

— Җиңгәчәй, нәрсә бар монда?

— Тиздән туй китә,— диде җиңгәчәй.

— Сез дә китәсезме?

— Без дә җиңгәли озата барабыз... Син инде монда калырсың, акыллым, яме! — дип өстәде җиңгәчәй, йомшак кына.

— Ярый,— дидем мин, тиз генә килешеп. Кияү ягы өчен мин ерак кеше — мин моны аңлый идем. Тик туй киткәннән соң бушап, боегып калган йортта ялгыз каңгырап йөрүнең миңа никадәр авыр буласын гына уйлый белмәгәнмен.

Җиңгәчәй ашыгып келәткә таба китеп барды, ә мин, рәшәткә буенарак узып, тынычрак урыннан ишегалдында барган тамашага карап тора башладым.

Бу вакытта кияү егетләре келәттә җырлый-җырлый чаршау-чыбылдыкны чишәләр, ә озата баручы җиңгәләр кызның урын-җирен җыялар иде. Кияү йортына баргач, шул ук кияү егетләре чаршау-чыбылдыкны яңадан корып, җиңгәләр кыз урынын җәеп куячаклар икән, йоласы шундый, имеш.

Менә келәт ишеге төбенә кабык арба җиккән ат килеп туктады. Шул арбага кыз артыннан барасы әйберләрне чыгарып сала башладылар. Ике егет өр-яңа яшел сандыкны ике башыннан күтәреп чыгардылар. Алар артыннан кызлар зур-зур төеннәрне чыгарып салдылар. Төеннәр өстенә зур гына җиз тазны каплап куйдылар. Җиз комган белән ак самоварны да төеннәр арасына иплэп кенә утырттылар... Барысын да шулай чыгарып, өеп бетергәч, йөкне озын бау белән аркылыга-буйга нygытып бәйләделәр. Шуннан соң бу арбада барасы егет атын бер читкәрәк тарттырып куйды.

Биредә бөтен эштә билгеле бер тәртип булса кирәк. Мин, әйберләр чыгып беткәч, алар артыннан ук кияү белән кыз да чыгар дип көткән идем, ләкин алай булмады. Хәзер өй баскычы төбенә кыңгыраулы пар атларны берәмләп китерә башладылар. Халык та шунда җыелды. Беренче атка шактый мәлҗегән баш коданы ике ягыннан култыклап чыгардылар да, зурлап, юатып, тарантаска иплэп кенә утырттылар. Чирек күтәреп чыккан берәү шунда ук аңа стаканга салып бал сузды... Башкоданың аты кузгалгач та аның урынына икенче пар ат килеп туктады. Монысына төп кода белән кодагый менеп утырдылар. Төп кодага да бал салып бирделәр. Шулай итеп баскыч төбенә атлар бер-бер артлы килә тордылар, калган кодалар да утырышып, ишегалдыннан урамга чыга тордылар. Кодалардан соң кызны җиңгәли озата баручылар атларына утырдылар. Туй килгәндә алты ат булса, хәзер урамда унике җигүле ат тезелешеп торалар иде.

Бары менә шуннан соң гына келәт алдына кияүнең кара һәм тимеркүк җиккән пар атын китерделәр. Шунда ук келәт алдын ястыкчы кызлар һәм егетләр сырып алдылар. Мин дә, күрми калмыйм дип, рәшәткә буенда яткан ташка бастым. Менә берзаман Хөбәйбулла кода сеңелесен (бишенче күгәрченен) таза беләкләрендә келәттән күтәреп чыгарды да тарантаска, күпертеп салган мендәрләр өстенә иплэп кенә утыртты. Кызның өстендә ак чүченчәдән җәйге җилән, башында ак ефәк шәл иде. Шул шәле белән ул, күзләрен генә калдырып, битен каплаган — мин ни теләп тә аның йөзен тагын күрә алмадым... Кыз янына кара җиләннән, кырпу бүректән кияү эре генә менеп утырды. Кияү егетләренең берсе дилбегә тотып, икенчесе, гармунын тезенә куеп, кияү белән кызга каршы кучерга урнашты, ә өченчесе тарантас артына басты. Егет, кулларын сузып, дилбегәсен какты, атлар кузгалдылар, озатучы кызлар, егетләр, бала-чагалар, тарантаска орына-сугыла, шау-гөр килеп, барысы да капкага юнәлделәр. Мин дә, агымга эләккән йомычка шикелле, кысыла-кысыла халыкка ияредем.

Кияү атлары урамга чыккач, туй кузгалды. Иң алдан башкоданың пар аты, аңың артыннан төп коданыкы, аннары кияү атлары, алар артыннан калганнары тезелешеп киттеләр. Иң арттан гына кыз әйберләрен төягән ялгыз ат, төеннәр өстенә каплап салган җиз тазы белән ялтырап, чаба-чаба китеп барды. Дәррәү кузгалып киткән атларның кыңгырау тавышлары кечкенә авылны тәмам күмеп, бөтен Түреш буйларын яңгыратып җибәрде. Әйе, бу искиткеч бер тамаша иде. Капка төбендә өелешеп калган егетләр һәм кызлар ераклаша барган кыңгырау тавышларын сихерләнеп, онытылып, шылт та итмичә тыңлап

тордылар. Туй китте. Туй белән бергә кемнеңдер яшьлеге китте... Тагын кемнәргә насыйп булыр икән бу кыңгырау тавышлары?!

Минем китаплар шүрлегендә тавыш-өнсез генә җиз кыңгырау тора. Ул шул Абзан туена, Нигъмәтулла абзыкайның сары ат башында, кара дугага тагылып барган кыңгырау икән, аны миңа күп еллардан соң Мәдинә җиңгәчәй биргән иде. Ул туйга катнашкан кешеләрнең бик күбесе — кода бабайлар, Хөбәйбулла кода, Нигъмәтулла абзыкай — күптән бу дөньяда юк инде. Җиңгәчәй исән әле, сиксәнгә якынлашып бара, зур калада профессор киявендә тора. Аннары тагын Сәлимә кодача белән аның кияве дә исән-саулар икән — мин моны былтыр гына ишетеп белдем... Еш кына алар турында ничек яшәделәр икән, бәхетле булдылармы икән, дөньяда бармы икән үзләре дип уйлана торган идем. Гаҗәеп бер нәрсә, күпме еллар минем хыялымда алар, нәкъ әнә шул туйда күргәнемчә, яшь чибәр кыз белән яшь таза егет булып сакландылар. Ә бит кырык елдан артык вакыт узып китте — әйтергә генә ансат!.. Баксаң, алар үз авылларында тигез генә гомер итеп, уллар-кызлар үстереп, әби белән бабай да булганнар икән инде... Куандым да мин моңа, әллә нигә моңайдым да... Озын кара толымлы сылу кодача тик хыялда гына торып калды.

Әйе, дөньяда бөтен нәрсә искерә, туза, үзгәрә, тик менә җиз кыңгырау, ни хикмәттер, һич кенә дә бер үзгәрми. Чак кына кагылдың исә, нәкъ теге вакыттагы шикелле, көмештәй саф, нечкә дәртле тавышы белән бүлмәне яңгыратып җибәрә һәм күз ачып йомганчы мине ундүрт яшьлек чагыма — үземә урын таба алмыйча гел борчылып йөргән, нидер сизенеп көткән иртә яшьлегемә кайтара да куя. Барысын-барысын да үтә бер ачыклык белән терелтә ул минем хыялымда... Яңгырап җибәрүенә, Нигъмәтулла абзыкайның җырын ишеткәндәй булам: утырдым ла көймәнең, ай, түренә... Юк, кирәкми, искә төшермик. Иясенә калсын ул...

Хәзер инде бик күп яңа җырлар туды. Яңа гадәтләр, яңа йолалар туды. Туйларга да хәзер кыңгыраулы пар атларда түгел, ә күбрәк «Волга», «Москвич»ларга гына утырып баралар. Егет белән кызны да өч көн буена ак келәттә ябып тотмыйлар, ә туйның түренә мендереп утырталар... Әмма мәңге үзгәрми торган бер нәрсә калды: бу —кешенең яшьлеге, мәхәббәте!.. Һәркемгә килә ул, һәркем кичерә аны... Менә ни өчен җиз кыңгырау бик кадерле миңа — аның дәртле, көмеш тавышында гүя яшьлек һәм мәхәббәт саклана.

1966

## Картлар

Бүген таң алдыннан Рамазан бабайның карчыгы Әсмабикә әби үлгән дип әйттеләр... Авылда үлем-бетем сирәк булганга күрә, бу хәбәр бик тиз таралып өлгерде. Күпләр өчен ул хәтта көтелмәгәнрәк хәбәр дә булды, чөнки әби атна-ун көн генә ятып, ничектер тиз генә үлеп тә киткән. «Һай Алла, кай арада гына булды соң әле бу, күптән түгел генә әбиебез кәҗәсен куып йөри иде бит!» дип гаҗәпләнделәр... Ләкин үлемгә, бигрәк тә карчык кешенең үлеменә, хәзер берәүнең дә артык исе китми. Була торган эш... Аның каравы, исән калучыны күбрәк кызганалар. Менә сиксәннән узган Рамазан картның хәле чынлап та мөшкел инде. Көтмәгәндә генә алтмыш ел гомер иткән карчыгыннан аерылды да куйды. Нишләр ул, бахыркай?.. Кем карар, түшәген кем җыяр, кем җылы сүз дәшәр?.. Көчсез, хәлсез — ятим бала белән бер бит инде ул хәзер!

Ул көнне карт өенә килүчеләр күп булды. Карт-корыны әйткән дә юк, эштәге ирләр дә, авылның икенче очындагы хатыннар да, хәтта яшь-җилкенчәкләр дә килеп, бабайга күренеп кенә булсалар да чыгарга тырыштылар. Авыл советы председателе белән колхоз председателе дә килеп киттеләр. Үлгәнне күмү эшләренә һәрвакытта бик күңел биреп йөрүче идарә члены Әзһәл абзыйга колхоз председателе әйтте: «Белегез, нәрсәләр кирәк? Кәфенлеге булмаса, хәзер сельподан ак материя җибәртермен. Тагын нәрсә?.. Акча?.. Тиздән хисапчы бер утыз сум китереп бирер... Ат җибәртермен, машина кирәксә, машина да җибәртермен... Карт сораганны көтмәгез, үзегез белеп эшләгез!» — диде. Бу бик урынлы боерык иде, чөнки картның үзенең ни дә булса уйларлык, хәрәкәт итәрлек чамасы калмаган. Фани дөнья белән алыш-биреше беткәндәй ул иртә таңнан бирле карчыгының аягы очында бөкрәеп утыра — һичкемне күрми дә, ишетми дә. Мәетне юарга кирәк булгач та аны иплəп-юатып кына урыннан кузгата алдылар. Хәсрәттән генә түгелдер инде бу, күрәсең, картлыгы да бик җиткән бабайның!

Безнең халыкта мәетне озак яткырмыйлар, бигрәк тә җәйнең менә мондый эссе көннәрендә. Әле иртәнге якта ук өч-дүрт кеше, көрәкләрен иңбашларына салып, зиратка кабер казырга киткәннәр иде... Зират авылдан өстәрәк, тигез чирәмлектә. Моннан биш-алты ел элек зиратны әйләндереп киртәләгәч һәм терлек кереп таптамый башлагач, андагы агачлар бик тиз куерып үсеп киттеләр. Хәзер ул кечкенә бер урман булып утыра, җәй башларында аннан өзлексез кошлар сайравы ишетелеп тора...

Төш җиткәндә инде Әсмабикә әбине әзерләп тә өлгерттеләр. Монысы өчен берни дә кирәк булмады — карчыкның күптән әзерләп куйган кәфенлеге дә, кабергә төшерүчеләргә дип саклаган сөлгеләре дә, тагын нәрсә өчендер җыйган тәңкәләре дә бар икән... Колхоздан ике ат килде, озатырга шактый гына халык та

җыелды. Башта бер арбага палас җәйделәр, мендәр куйдылар, аннары әбинең, иске юрганга ураган гәүдәсен өч кеше ипләп кенә күтәреп, чыгарып салдылар. Карчыгы артыннан өстенә озын җилән, башына бүрек кигән Рамазан бабай үзе дә күренде. Ул, бусагадан атлап чыккач та тукталып, зәгыйфь тавышын күтәрә төшеп, көтеп торучыларга эндәште:

— Оланнар, Әсмабикә әбиегез, мәрхүмә, әйбәт кеше иде бит!

— Әйбәт кеше иде, Рамазан бабай, бик әйбәт кеше иде! — диделәр аңа каршы төрле яктан.

Шуннан соң гына Рамазан бабай болдырдан төшеп, ике егет ярдәмендә карчыгының аяк очына менеп утырды. Башка картлар икенче арбага тезелештеләр. Атлар кузгалды. Ирләрнең бер өлеше мәет артыннан иярде, ә күп кенә өлеше атларның бераз ераклашканын көтеп тордылар да үз юллары белән китеп бардылар. Капка төбендә исә хатын-кызлар гына күзләрен сөрткәләп торып калдылар.

Атлар һәм озата баручылар тыкрыктан авыл читенә чыгып, зиратка таба күтәрелделәр. Зират янына җиткәч, туктап, мәетне арбадан, паласының дүрт почмагыннан тотып кына, яшел чирәмгә төшерделәр. Авылда, билгеле, күптән инде мулла юк, ләкин шәригать гамәлләрен аз-маз белүче Яхъя исемле чатан бер карт бар, менә шул бабай үлгән кешенең якыннары сораган чакта, кышын өйдә генә, җәен яшел чирәмдә җеназа да укый иде. Хәзер дә шул ук бабай, үзе кебек берничә карт белән сафка басып, мәет өстендә кычкырып җеназа укыды. Башкалар исә читтән тын гына карап тордылар... Мәет әйләнәсендәге үләндә «ак тәтәйләр» хәйран күп иде (бездә ромашка чәчәген шулай дип атыйлар), ак тәтәйләр өстендә ак күбәләкләр оча, киртә буендагы агачлардан әрсез кошларның чыр-чу килеп тавышлануы ишетелеп тора, ә якында гына чирәмгә чөй кагып, шуңа озын бау белән бәйләп җибәргән бер кызыл бозау: «Кешеләр монда нишлиләр?» дигән шикелле, башын гына борып, җеназа укучыларга карап тора. Һәм шушы тереклек эчендә Әсмабикә әби үзе дә юри генә үлгән булып ята кебек... Бер уйласаң, бик гади нәрсәгә охшый бу үлем дигәнең!..

Кыска гына җеназа укыганнан соң, мәетне кире арбага салмыйча, паласы белән генә күтәреп, зират эченә, кабергә алып киттеләр. Кабер әзер, бер читтә тәмәке тартып утырган кабер казучылар, сукмак буйлап килүчеләрне күргәч, кагынып урыннарыннан тордылар. Монда тагын Яхъя карт җитәкчелек итә башлады. Аның кушуы буенча өч кеше мәетне ләхеткә куяр өчен кабергә сикереп төштеләр. Әсмабикә әбинең ак кәфенгә төргән гәүдәсен юрганнан чыгардылар, астыннан өч тастымал үткәреп, шуларның башларын кабердәге әлеге кешеләргә бирделәр. Алар мәетне ипләп кенә кабергә төшерә башладылар. Шул чакта Рамазан бабай, тураеп, халыкка нидер әйтергә теләде:

— Оланнар, Әсмабикә әбиегез...— Ләкин кинәт тавышы өзелде, бөгелеп төште һәм иңбашлары калтыранып китте. Кабер әйләнәсендәгеләр аның ни әйтергә теләгәнен аңлагандай:

— Әйбәт карчык иде Әсмабикә әбиебез, бик тә әйбәт карчык иде, мәрхүмә! — диештеләр.

Ун-унбиш минут та үтмәгәндер, таза егетләр әбине күмеп тә куйдылар. Башкалар шул чакта иелеп йә көрәк, йә кулы белән генә кабергә туфрак ташладылар. Шуннан соң картлар кабернең ике ягына тезелеп утырдылар. Яхъя карт моңсу гына итеп Коръән укыды (хәер, аның нәрсә укыганын хәзер кем белә инде), аннары Рамазан бабай җилән чабуына баса-баса садака өләшеп маташты. Дога кылдылар, шуның белән эш бетте һәм халык ашыгып тарала да башлады. Рамазан бабайны, атка утыртып, күршеләре алып китте, кабер казучылар, Әзһәл абзыйга ияреп, сельпога таба төшеп киттеләр... Кабер очында, ниндидер бер фәрештәнең Әсмабикә әби белән сөйләшергә килүен ишетер өчен, Яхъя карт ялгыз үзе генә утырып калды.

Гаҗәп, безнең зират буенда «ак тәтәйләр» быел нигә бу хәтле күп икән?

...Рамазан бабай хәзер көн дә иртә-кич зиратка, карчыгы янына барып йөри. Без моны һәр көн диярлек күреп торабыз. Эш шунда: әлеге зиратка илтә торган тыкрык каршында гына, Ясәвиләр коймасы буенда өелеп яткан бүрәнәләр бар — менә без, бу тирәдә торучылар, эштән бушагач, кичләрен шул бүрәнәләр өстендә тәмәке тартып, гәп сугып утыргалыйбыз. Шулай булгач, Рамазан бабай да зираттан кайтышлый гел безнең каршыдан узып китә. Без аны, күреп алсак, сүздән туктап, артыннан гына карап калабыз. Аның зиратка йөрүенә артык исебез дә китми, хәлен аңлыйбыз да кебек, чөнки карчыгы янына бару карт өчен хәзер бердәнбер юаныч булса кирәк... Ләкин шулай да аны күргән саен күңелне ничектер тырнабрак торган шундыйрак уй да туа: картның Ходай бирмеш һәр көнне иртә-кичен зиратка йөрүе бары үзенә юаныч табар өчен генәме, әллә моның бүтән берәр тирәнрәк сәбәбе дә бар микән?

Бер кичне шулай түбән очның Лотфи карт, узып барышлый безнең янда туктап, бераз утырып торды. Шул чакта тыкрыктан Рамазан бабай да килеп чыкты. Ул, гадәтенчә, таягына таянып, бөкрәя төшеп, зираттан кайтып килә иде. Без аның каршы яклап үтеп киткәнен сүзсез генә карап калдык. Бабай ераклаша төшкәч, кемдер җиңел генә сулап:

— Йөри карт, йөри! — дип куйды.

— Юксына инде, мескен, юксына! — диде аңа каршы икенче берәү.

Безнең Лотфи карттан ни дә булса ишетәсебез килә иде. Лотфи карт, Рамазан бабайдан бер ун яшькә кечерәк булса да, аның егет чагын, ир чагын күргән кеше. Аннары үзе дә карт булгач, ялгыз калган бабайның эчке хәлен дә дөресрәк аңлыйдыр инде, билгеле. Ләкин картыбыз таш сын шикелле бер сүз

дәшмичә, хәтта чыраен да үзгәртмичә тик кенә утыра. Шуннан соң безнең күрше Казбек, шәһәрдән кайткан студент, үзе башлап Лотфи карттан сорады:

— Лотфулла бабай, әйтегез әле, Рамазан бабай, имеш, яшь чагында бик таза, бик чибәр егет булган, диләр, дөресме шул?

— Нигә, Рамазан бабаегызның яшь чагында ниндирәк егет булганын хәзер дә чамалап була торгандыр,— диде Лотфи карт, чак кына елмая биреп.

— Чамалап булса да, күз алдына китерүе читен. Сиксәннән узган карт бит... Ә сез аның яшь чагын үзегез күргәнсез. Йә, ничегрәк иде соң?

Лотфи карт, күзләрен кыса төшеп, нидер уйлагандай, бераз дәшми торды. Аннары ашыкмыйча гына әйтте:

— Рамазан карт егет чагында мин малай гына идем әле, шулай да яхшы хәтерлим: өрлектәй төз гәүдәле, таза егет иде ул, төскә дә чибәр иде, борыны пычак сыртыдай туры, күзләре шомырттай кара, ә кашлары карлыгач канатыдай кыйгачланып тора иде... Авылда бер егет иде бабагыз!

— Әнә ничек икән?! — дидек без, гаҗәпләнеп.— Күз алдына китереп кара син аны хәзер!.. Сөйләп бирсәң үзе дә ышанмас!

— Ә менә Әсмабикә әбине ямьсез кыз булган диләр, дөресме шул? — диде Казбек, бер дә тыйнакланып тормыйча.

— Анысы инде сорамасаң да билгеле,— диде кемдер шунда.— Картлык ямьсезлекне яшерә алмый икән... Мәрхүм әбинең авызы зур, борыны ямьшек, шадрасы да бар иде — кая куясың?

— Юк, менә Лотфулла бабай әйтсен әле,— диде Казбек, һаман картны кыстап.

— Ни әйтәсең инде,— диде карт, авыр гына сулап.—Ходай Әсмабикә әбиегездән матурлыкны кызганган шул.

— Алайса шундый чибәр егет ничек итеп шундый ямьсез кызга өйләнде икән, ә?.. Лотфулла бабай, сез беләсездер?..

— Беләм?.. Каян?.. Мин үзем дә ул заманда малай гына идем бит әле...

— Юк, шулай да?.. Ну, ничек булырга мөмкин бу?..

— Дөресе аның шул,— диде Лотфи карт, бераз көттереп.— Рамазан бабагыз Әсмабикәсенә күрми өйләнгән.

— Күрмичә?.. Ничек ул алай? Күрмичә кеше өйләнәмени?

— Сез, оланнар, ул заманны белмисез... Рамазан бабагыз яшь чакта әле күрмичә өйләнү, күрмичә кияүгә чыгу булгалый торган иде. Исегез китмәсен!

— Ну бит, күрмәсә дә ишеткәндер... Бөтенләй белмичә алмагандыр инде.

Лотфи карт башын әзрәк кагып торды да аннары әйтеп куйды:

— Аны алдаганнар.

— Алдаганнар?.. Ничек итеп?.. Кызык бу, кызык! Лотфи карт җавап бирергә ашыкмады, нидер күңелен борчыгандай, ул уйга калыбрак утыра иде. Ләкин аны төрле яктан: «Сөйләгез инде, Лотфулла бабай, сөйләгез»,— дип, бик нык кыстарга тотындылар. Бары шуннан соң гына картыбыз эчке икеләнүен җиңгәндәй бер сулап:

— Ярый алайса,— диде.— Үлгән кешенең йөгенә керү килешми килешүен, күңел дә тартып бетерми, әмма мин сезгә, оланнар, үзем ишеткән кадәресен генә сөйлим. Гайбәт түгел, Ходай кичерсен!.. Иң элек шуны әйтәм: Әсмабикә әбиегез безнең авылдан түгел бит, Такталачыктан, шуннан безгә килен булып төшкән кыз. Такталачык, үзегез беләсез, бездән унсигез чакрымда, кайчандыр зур базарлы, биш мәхәлләле бер авыл иде. Анда байлар да күп булган, хәер, сез аның ул чагын белмисез инде —ә соңыннан бу авыл яртылаш диярлек таралып бетте... Менә шул Такталачыкта Гобәйдулла исемле бер бай була. Ходай аңа кызларны күп биргән икән, бер-бер артлы җитеп килгән дүртме-бишме кызы булган, имеш. Арада иң өлкәне менә шушы Әсмабикә әбиегез булган инде... Ишле кызга кияү табып бетерү ансат эш түгел, хәтта бай кешегә дә... Шуның өстенә, ул чактагы гадәт буенча, башта иң өлкәнен бирергә тырышканнар, өлкәнен бирмичә торып, кечерәкләрен бирә башлауны килештермәгәннәр, теге беренче кызлары утырып калыр дип курыкканнар. Бу урында шуны да әйтергә кирәк: байның кече кызлары барысы да бик чибәр булганнар, имеш, тик Әсмабикә бичара гына матурлыктан мәхрүм булып калган... Шулай да атасы, Гобәйдулла бай, өлкән кызына ничек тә кияү табарга тырышкан. Бай кешенең, мәгълүм инде, тирә-якта таныш-белешләре күп була, безнең авылда да аның кемдер бер якын танышы булган, менә шул кеше Ризван картка, дөресрәге, Ризван картның малаена, байның кызын димләргә тотынган. Шәт, аңлыйсыздыр, Ризван карт ул Рамазан бабагызның атасы — мин дә аны яхшы хәтерлим әле... Юаш кына, адәмчелекле бер кеше иде, мәрхүм!.. Җирдән башын күтәрмәгән гади бер мажик... Бай кеше белән туганлашып китү картның күңеленә, билгеле, хуш килә — соң шулай булмыйча, заманасы шундый бит аның... Тик ышанып кына бетми, булмас, бай кеше кызын безнең ише мужикка бирмәс, ди. Ә димләп йөрүче ышандыра, яучы гына җибәр, Гобәйдулла бай кызын берәүгә бирмәсә дә синең малаеңа бирәчәк, ди, ант итеп ышандыра. Шуннан соң Ризван карт мәсьәләне улына чишә: «Менә, ди, шундый җирдән, шундый кешенең кызын сиңа димлиләр, ни уйлыйсың, соратып карыйбызмы әллә?» — ди. Рамазан бабагыз моңа риза була

(булмыйча, бай кызына кем өйләнмәс!), ләкин бер шартын куя: кызны күрмичә алмыйм, ди... Инде теге димләүче ике арада йөри бит, менә шул — егетнең теләгән байга җиткерә. Бай моңа каршы әйткән, имеш: кызны никахка чаклы егеткә күрсәтергә шәригать кушмый, атасы килсен, атасы күреп китәр дигән, имеш... Шуннан нишләргә кала? Киңәшәләр дә, әлеге димләүче белән Ризван карт, ат җигеп, Такталачыкка китеп тә баралар... Анда баргач, Гобәйдулла байның үзенә төшмиләр, ярамый, бай бернәрсә дә белмәскә тиеш, янәсе... Каршыдарак торган бер йортка керәләр, Ризван картны урам тәрәзәсенә утырталар һәм көтәргә кушалар. Менә берзаман, күпмедер вакыт узгач, бай капкасыннан купшы гына киенгән, көянтә-чиләк аскан бер кыз килеп чыга... Картка әйтәләр: әнә кара инде, синең улыңа буласы кыз шул үзе, диләр... Кыз чынлап та бик сылу, бик чибәр була. Карт аның вак-вак кына атлап чишмәгә киткәнен дә, чишмәдән кайтканын да карап тора... Әлхасыйль, кыздан бик канәгать булып калган Ризван карт... Кайткач улына да кызны бик мактап сөйләгән: «Улым, үз күзем белән күрдем, кызның килмәгән җире юк, алсаң — уңарсың!» — дигән.

Шуннан эш җайлана инде. Тәвәккәлләп яучы җибәрәләр (шул ук димләп йөрүчене), бай кызын бирергә риза була, аннары озакка сузмыйча туен да итәләр. Ике авыл арасы якын җир түгел, моннан Такталачыкка туй барып җиткәнче дә никах укылганчы, күзге көн үтеп тә китә. Рамазан бабагыз инде ак келәткә, кәләш куенына күз бәйләнгәч кенә барып керә... Оланнар, мин сезгә ишеткәнемне генә сөйлим, чын дөресен инде аның Рамазан бабагыз үзе генә белә торгандыр... Кыскасы, зөфаф төне узгач, икенче көнне генә ул янында яткан Әсмабикәсен ачык күргән, диләр. Бик гаҗәпләнгән, имеш, ни уйларга да белмәгән, әмма кызның үзенә берни дә сиздермәгән. Тик җаен туры китереп атасыннан: «Әткәй, киленеңә бер күз сал әле, шунымы син миңа димләдең?» — дип сораган. Ризван карт киленен күргәч бик аптыраган: «Юк,— дигән,— минем моны күргәнем юк, миңа бөтенләй башка кыз күрсәттеләр»,— дигән. (Әлеге чибәр сеңелләреннән берсе булган икән ул.) Моны белгәч, Рамазан бабагыз башта бик яман дуламакчы, туйны ташлап китмәкче булган. Ләкин атасы, әйткәнемчә, сабыр, адәмчелекле кеше, малаен ул эштән тыйган: «Кыз хәзер синең никахлы хатының,— дигән,— эт баласы түгел, эт баласын да ташлап китмиләр, кара аны, җылатасы булма!» — дигән... Дөрес тә инде, никах укылган, бер кич янында кунган, ничек итеп, нинди җан белән кыз баланы ташлап китмәк кирәк?! Ямьсез дигәч тә гарип түгел бит ул, кул-аягы, бөтен җире тап-таза. Озын сүзнең кыскасы, Рамазан бабагыз, өлешемә чыккан көмешем шушы икән дигән дә Әсмабикәсен әйбәтләп туйлап өенә алып кайткан... Менә шул аның тарихы, оланнар!

Лотфи карт сөйләп бетерде дә җиң очы белән нечкә мыекларын сыпырып куйды. Ләкин аның бик гади генә итеп сөйләгән бу сүзләрендә нидер җитми иде әле. Ярый, алдап булса да егетне өйләндергәннәр, ди, әмма өйләнгәч бергә торасы бар бит әле. Соңыннан ничегрәк яшәгәннәр алар?..

— Алтмыш ел гомер иттеләр,— ди Лотфи карт, тыныч кына.

— Ләкин гомер итү төрлечә була бит, Лотфулла бабай!

— Булмыйча... Гомер юлы бик озын, чокырлы да чакырлы, шома гына бармый ул... Шуны да әйтергә кирәк, Рамазан бабагыз яшь чагында шактый кызу канлы кеше иде, юктан да дулап китә торган гадәте бар иде. Әмма ләкин Әсмабикә әбиегезгә Ходай матурлык бирмәсә дә, күркәм холык биргән. Сабыр, чыдам, артыгын әйтмәс, яшен йота белер... Хәзерге кайбер яшь киленнәр төсле тавыш чыккан саен тырт итеп әтиләренә йөгермәгән.

— Анысы инде үзен гаепле дип белгәнгә күрәдер...

— Ә нинди гаебе бар аның?.. Ризван картка сеңелесен күрсәткән чакта аңа әллә әйтеп торганнар дисезме? Юк, булмас, андый нәрсә бик яшерен эшләнә ул, хәтта суга барырга чыккан сеңелесе дә белмичә калгандыр әле.

— Ә ярату? — диде Казбек, егетләнеп.— Ярату булганмы соң алар арасында?

— Сезгә тагын нинди ярату кирәк? — диде Лотфи карт, бик гаҗәпләнеп.— Әнә Рамазан бабагыз карчыгының кабере өстеннән кайтып та керми, ә сез монда ярату дип, оялмыйча, лыгырдап утырасыз!..

Без дәшмәдек, хәтта ничектер уңайсызланып та калдык, гүя без бик гади бер хакыйкатьне аңламый идек. Дөресен генә әйткәндә, картларны тыңлап утыру яхшы, әмма аларны аңлап бетү, бигрәк тә алар белән бәхәскә керү һич тә мөмкин түгел. Әнә «ярату» дигән бер сүздән картыбыз кызды да китте. Ни өчен, бик гаеп сүзмени ул?.. Әллә яратуны картлар бөтенләй башкача аңлыймы?

Ә Рамазан бабай карчыгы янына һаман да йөри дә йөри. Һәр кичне диярлек без аның зираттан кайтканын күрәбез һәм сүзсез генә артыннан карап калабыз. Мескен бабай!.. Хәер, ни өчен мескен, бәлки, бер дә мескен түгелдер? Бәлки, аның гомере буена әкренләп төшенгән һәм үзе генә белгән зур бер хакыйкате бардыр, ихтимал, шуңардан аңа ялгызлыгын җиңеләйткән чын юаныч килә дә торгандыр. Серле-тирән булса кирәк картларның җаны, тик безгә генә ни өчендер караңгы ул!

1970

# Бер сүз

Ул һәрвакытта ресторан залының түр почмагына, тәрәзә янына барып утыра торган иде. Бу аның ияләшкән урыны. Әгәр шул урын буш булмаса, аның әзрәк кенә кәефе дә кырылган шикелле була, күрәсең; башка урыннар аңа ошап бетми иде. Ләкин ул гел генә диярлек халыкның аз чагында (төшке аш белән кичке аш арасында) килә, шунлыктан күп вакытта яраткан урыны да буш була торган иде. Дөресен генә әйткәндә, официантлар да инде аның килү вакытын да, кайсы өстәлгә утыруын да, хәтта нинди ашлар яратуын да белеп өлгергәннәр иде. Тик менә кем ул бу сәер кеше?.. Чын интеллигентларга хас чиста ак йөзенә, яртылаш агарган куе чәчләренә, һәрвакыт диярлек зәвык белән пөхтә итеп киенгән туры, ыспай гәүдәсенә караганда, аның вак-төяк кенә кеше булмавы ачык күренеп тора. Мөгаен ул йә галим, йә язучы, йә артист булырга тиеш. Әмма Казанныкы түгел, чөнки Казанның ресторannарга гел кереп йөри торган күренеклерәк кешеләрен официантлар күптән беләләр. Аннары бу яңа кунак үз-үзен тотышы белән дә тегеләрдән нык кына аерыла: мөгамәләсе һәрвакытта нәзакәтле, ә ашау-эчүгә килгәндә шактый талымлы — моны инде официантлар беренче нәүбәттә сизеп алалар. Шулай да кем соң ул?

Ләкин кагыйдә буларак, ресторанга даими кереп йөргән кеше озак билгесез булып кала алмый, һәм күп тә үтмәгәндер, официантлар бу сәер-мөлаем кешенең дә кем икәнен белеп алдылар. Ихтимал, моңа аның бервакытта да кулыннан төшерми торган искерәк зур портфеле дә һәм килеп утырган саен шул портфеленнән чыгарып караштырырга тотынган калын-калын журналлары да ярдәм иткәндер... Кыскасы, ул фән кешесе, галим, профессор булып чыкты. Ләкин кайсы фән өлкәсеннән — бу кадәресен алар белмәделәр, хәер моны белүнең алар өчен әллә ни кирәге дә юк иде. Аның каравы, икенче бер бик мөһим нәрсәне белделәр: профессор безнең шәһәрдә яңа кеше икән, ялгызы гына тора икән һәм ресторанга ашарга йөрүе дә шуның өчен икән.

Мөхтәрәм профессорны килгән саен Нина исемле бер официантка карый торган иде. Бу, ничегрәк дип әйтергә, арада шактый юаш һәм сөйкемле генә официанткаларның берсе. Фигурасы да аның нәфис-сылу гына, кызларныкы кебек диярлек, әмма нечкә йөзе инде таушалган, күз әйләнәсенә дә, ияк тирәсенә дә вак кына җыерчыклар сызылып өлгергән. Шулай да ул ягымлы, нәрсәсе беләндер ягымлы, аның әнә шул иртә таушалган йөзендә ниндидер яшерен оялчанлык та, нәүмизлек тә бар кебек... Аңа карагач, ихтыярсыздан күңелгә, бу үзенең тупас ире тарафыннан шактый изелгән, җәберләнгән хатын булырга тиеш, дигән уй да килә.

Профессор залга кереп, түрдәге үз урынына барып утыргач та официантлар тизрәк Нинага дәшәләр: «Нина, әнә профессорың килде, бар, йөгер!» — диләр. Алар моны, билгеле, шаярткан булып әйтәләр, ләкин шулай да үзләренчә ниндидер киная дә сиздерәләр иде. Нина аларга ачулана алмый, киресенчә, «профессорың» дигән сүзләрдән аңа ни өчендер әзрәк кенә күңелле дә булып китә иде. Ул шунда ук хөрмәтле кунагы янына барып җитә, мөлаем генә исәнләшә, матур тышлык эченә куйган менюны тәкъдим итә һәм чиста өстәлне тагын бер кат сыпыргалап ала. Профессор ашыкмыйча гына менюны карый, теге юкмы, бу юкмы дип сораштыра, бары шуннан соң гына заказын яздыра башлый. Гадәттә аның заказлары бертөрлерәк була: яшелчәдән салат, май белән сыр, җиңелчә шулпа һәм икенчегә тавык яки бозау ите... Яхшы балык булса, аны калдырмый. Ләкин кыздырган яки тапап куырган итләрне бер дә алмый диярлек, тик теләгән нәрсәсе юк чакта гына алырга мәҗбүр була, анда да каты кыздырмасыннар дип әйтеп куя... Шулай ук аракы, коньяк кебек куәтле эчемлекләрне дә беркайчан да алганы юк, хәер, чит ил коньягын берме-икеме тапкыр алып караган иде дә, ахрысы, яратмагандыр, Нинаның үзенә дә: «Әремнән дә әче, тәмсез, безнекенә җитми»,— диде. Әгәр инде яхшы грузин виносы булса, ул аны берәр фужер гына китертмичә калмый. Һәм иң соңыннан ашыкмыйча гына кофе эчә.

Нина заказны алып киткәч тә ул портфеленнән берәр журнал яки китап чыгарып, аш килгәнче, ә күп вакытта исә ашаган чагында да шуны караштырып утыра. Гәрчә официантлар эчмичә генә ашаган кешеләрне бик үк өнәп бетермәсәләр дә (чөнки андыйлардан файда аз) профессорның «айнык баш» булуын гаеп итмиләр иде. Кешесе бүтән, һәр кич ресторанга эчәр өчен генә тула торган клиентлар җөмләсеннән түгел. Инде Нинага килсәк, ул үзенең профессорын нәкъ менә бик әдәпле һәм бик тәртипле булганы өчен дә чын ихластан хөрмәт итә иде. Ул инде җыен мокытның әзрәк эчеп алгач та официанткаларның кыска итәкле аякларына күзләрен майландырып карап утыруларыннан, шуның өстенә, җитмәсә, әллә нинди ямьсез ишарәле, мәгънәсез комплимент әйтүләреннән бик туйган иде. Ә профессор алдында ул тыныч йөри, үзен саф хатынга һәм кирәкле кешегә санап йөри. Әле бер генә тапкыр да, ялгыш кына да, ул аңардан гарьләндерерлек яки намусына тиярлек бер сүз, бер караш та ишеткәне-күргәне юк. Аннары профессор бик саран да түгел иде, исәпләшкән чакта бер сумнан ким сдачаны алып та тормый иде. Хәер, алса, Нина өчен яхшырак буласы икән, чөнки ул калдырып киткән тиеннәрдән Нина үзен ничектер бераз кимсетелгән шикелле тоя иде.

Хәлбуки профессорның Нинага үз мөнәсәбәте яхшы да, начар да түгел иде. Аның алдында официантка — бары шул гына. Әгәр инде официантка аны якты чырай белән каршы ала икән, бигрәк тә кушканнарны тизрәк китерә икән — бу бик табигый, адәм рәтле ресторанда ул шулай булырга тиеш тә. Моның өчен ул аңа рәхмәтен әйтә, вак-төяк акчасын калдырып китә. Шуңардан тыш официанткага ниндидер аерым игътибар күрсәтүнең һичбер хаҗәте юк. Һәркем үз урынын, үз дәрәҗәсен белергә тиеш, ахыр чиктә!

Ләкин шулай да килгән саен бер үк официантканың хезмәтен күргәнлектән булса кирәк, ул аңа ничектер үзеннән-үзе шактый гына иялəшеп өлгерде. Дәрәҗә аермасын онытыбрак, үз итебрәк карый башлады, исемен дә сорап белде һәм күбрәк «Ниночка!» дип кенә дәшә торган булды. Ә кәефе бер яхшы вакытта ул аңа хәтта үзенең исемен дә әйтте: «Виктор Иванович» икән ул. Ләкин фамилиясен, кем булуын, кайда эшләвен, билгеле, әйтеп тормады. Нина исә бу кадәресенә дә бик шат иде, артыгын көтми иде, чөнки ул күреп тора, аның профессоры бик җитди, аз сүзле кеше... Зур кеше!

Әмма гаҗәеп бер хәл, Нина үзе белән бергә эшләүче официанткалардан ишетеп, профессоры турында тагын шуны да белде: имештер, ул бөтенләй ялгыз кеше икән, имештер, аның яшь, чибәр хатыны булган, ләкин ул хатын ире белән безнең шәһәргә килергә теләмәгән, аңардан аерылып, чын булса, зур урындагы бер хәрби кеше белән торып калган, имеш... Кайдан, кемнән чыккан хәбәр бу?.. Һәрхәлдә, профессорның үз авызыннан чыккан сүз түгел һәм чыгуы мөмкин дә түгел. Ләкин шушы берничек тә расланмаган, дөреслеге бик шикле булган хәбәргә Нина ышана калды. Гүя профессорның әнә шундый ялгыз, бәхетсез кеше булуы аңа кирәгрәк иде, күп кенә хатын-кызлар шикелле үк ул да хатыннары ташлаган ирләрне кызгана иде. Шушы кызгану тойгысына бирелеп, ул күңеленнән профессорын юата, назлый иде... Хәтта, әгәр аның хатыны булсам, мин аны ничек кенә карамас идем, ничек кенә сакламас идем, минем янымда ул, җаным, күкәй эчендәге сары кебек яшәр иде дип хыялланып та китә торган иде.

Хәлбуки Нинаның вакыт-вакыт болай хыяллануы ирсез, ялгыз хатын булудан түгел иде. Юк, аның да ире бар, ул да бүтәннәр рәтеннән ирле хатынга исәпләнеп йөри. Әмма нинди ир соң ул?.. Әйтсәң, кешедән оят, башы эчүдән чыкмаган бозык, әшәке, тупас бер адәм актыгы шунда... Нина ресторанда эшләгәнгә күрә генә ире аны, кайтып урынга яткан саен, син шундый хатын да мондый хатын дип, пычрак сүзләр белән төрлечә мыскыл итә, берөзлексез бәгырен талап кына тора. Шуңардан башка ул исерек иреннән бер җылы сүз, бер йомшак мөгамәлә ишеткәне, күргәне юк. Асылда, аңа бары Нинаның акчасы кирәк, Нинаны елата-елата азаплау кирәк, шуңардан гына тәм таба ул һәм шуңа күрәдер инде, күпме генә җәберләсә-хурласа да, Нинага чат ябышып ята. Инде Нина китәм, тормыйм дия башласа, ул аны имгәтеп ташлау, хәтта үтерү белән дә куркыта. Менә шундый ерткычның тырнагына эләккән хатынга ни эшләргә кала соң?.. Кешеләрдән яшеренеп җыларга, эчтән генә сызарга һәм вакыт-вакыт бүтән кеше, бүтән тормыш турында уйланып ничектер онытылырга, юанырга гына кала. Ирдән уңмаган һәрбер хатынның яшерен сагышыдыр инде бу...

Тик әнә шуңа күрә генә безнең Нинабыз да ресторанда пәйда булган әлеге сөйкемле, әдәпле профессорга бүтәнчәрәк карый башлады. Ничектер әкренләп кенә профессор үзе дә һич сизмәстән, бичара хатынның сүнеп бетмәгән дәртен, бик тирәндә яткан өмет-хыялларын уятты. Әйдә, бу хыял — кысыр хыял булсын, гомердә вөҗүдкә ашмый торган булсын,— ә Нина аның шулай икәнен бик яхшы белә иде,— әмма шул әйбәт кешенең хатыны булсам иде дип эченнән генә уйлап куйгалау да аңа чын бер юаныч, рәхәт җиңеллек китерә иде.

Ләкин көннәрдән беркөнне... Хәер, ашыкмыйк әле... Бу — апрель башы иде, апрельнең беренче атнасы. Көн кояшлы, җылы-йомшак. Язның беренче чәчкәсе умырзая да чыккан икән. Нина эшкә килешли чаттагы марҗадан салкын нәфис исле шул гади генә чәчәкләрнең бер бәйләмен сатып алды. Ресторанга кергәч тә ул аларны сулы вазага утыртып, профессоры ашый торган өстәлгә китереп куйды.

Көн бик җылы булгач, залның да тәрәзәләрен ачтылар. Үзәк урамнан берөзлексез агылган халыкның тонык кына гүләве ишетелеп тора. Шулай да бүген ресторанга керүчеләр әзрәк. Күрәсең, язгы кояш һәм саф һава алар өчен тансыграк. Бары төшке аш вакытында гына клиентлар күбәеп, гадәттәге ыгы-зыгы көчәеп, официантларга бераз йөгергәләргә туры килде. Ә бер-ике сәгатьтән зал тагын бушап калды. Хәер, бөтенләй үк түгел, ресторан бервакытта да кешесез калмый ул... Официантлар, бушаган өстәлләрне җыештырып, чиста сервизлар тезеп куйдылар. Бу эшләрен дә бетергәч, читтәге өстәлләрнең берсе тирәсенә утырышып, ишеткән-күргәннәрен, көндәлек гайбәтләрен сөйләшергә керештеләр. Тик Нина гына бер дә утырып тора алмый, һаман үзенә эш табып, әрле-бирле йөри дә йөри. Шушы иркә-матур көннең тәэсиремедер инде, аның бүген рухы күтәренке, кәефе аеруча яхшы иде. Аннары ул бит профессорын көтә, аның килер вакыты якынлаша, бәлки, шуңадыр әзрәк кенә тынычсызлана да иде. Моның өчен ул үзен хәтта, тиле син, килмәгән кеше түгел ич, дип әрләмәкче дә була, ләкин барыбер сабырсызланып көтүдән тыела да һәм тынычлана да алмый иде.

Әйе, аның профессоры бүген дә, гадәтенчә, сәгать дүртләр тирәсендә залга килеп керде һәм түр почмактагы иялəшкән урынына барып утырды. Нина аны шунда ук күреп алды, ләкин янына барырга ашыкмады. (Ашыгып баруның килешеп бетмәсен сизә иде ул.) Профессор өстәлдәге умырзаяга игътибар итте, якынрак китереп иснәп карады, аннары кире урынына куйды. Нина моны күреп торды, эченнән генә шуңа сөенде һәм тынычлана төшкәч, катыргы менюны алып, кунагы янына барды.

— Исәнмесез, Виктор Иванович! — диде ул ачык йөз белән.

— Ә, Ниночка, исәнмесез, исәнмесез! — диде профессор да аны күрүенә куангандай.— Йә, бүген безне ни белән сыйларсыз икән, Ниночка?

— Рәхим итеп карагыз!.. Сез яраткан ашлар булырга тиеш.

Профессор, менюны ачып, ашыкмыйча гына карый башлады. Ул, һәрвакыттагыча, чиста итеп кырынган, пөхтә итеп киенгән, ә өстеннән сандал агачының исен хәтерләткән ниндидер бер нәфис-таза ис тә сизелер-сизелмәс кенә килеп тора. Шушы исне тоеп калганда Нинаның башы әйләнеп киткәндәй була; чөнки моның кебек тәмле таза иснең башка ирләрдән килгәнен һич сизгәне юк — гүя бу бары тик «аныкы», «аңа» гына хас иде... Ә шулай да Нинага аның янында менә болай озак басып тору уңайсыз, ничектер килешми дә кебек... Бүтәннәр яныннан ул менюны тапшыргач та китеп бара бит, ә менә аның яныннан, исенә исергәндәй, китә алмыйча көтеп тора да тора.

Ниһаять, профессор башын күтәрде.

— Без булдыксызларның ашын үзегез дә беләсез инде, Ниночка! — диде ул, көттергән өчен гафу үтенгәндәй, һәм гадәттәге заказларын яздыра башлады: яңа кыярдан салат, сыр белән май, дөге шулпасы һәм пешерелгән тавык ите. Ә иң ахырдан, гадәтенә каршы килеп дигәндәй, йөз генә грамм биш йолдызлы коньяк та яздырды.

— Бусы умырзая хөрмәтенә! — диде ул, чәчәккә ымлап.— Беренче тапкыр күрәм әле үзләрен...

— Шулаймыни? — диде Нина, гаҗәпләнгән булып, ләкин куанычын яшерә алмыйча; профессорның умырзаяга ымлап әйткәнен ул ни өчендер үзенә әйтелгән бер комплимент итеп тә кабул итте. Хәер, бу аңлашыла да иде, чөнки ул китереп куйган чәчәкләр ич! — Сизгер җанлы профессор моны белмимени?!

Нина иңенә канатлар чыккандай тиз генә китеп барды. Бу аның гомерендә, бәлки, беренче тапкыр үз эшеннән (әйтергә кирәк, шактый авыр һәм кадерсез эшеннән) чын канәгатьләнү табып, шуңа сөенеп йөрүе иде. Ул, билгеле, профессорның кушканнарын — башта закускасы белән эчемлеген — озак көттермичә китереп тә җиткерде. Аның әле хөрмәтле кунагы белән тагын әзрәк кенә сүз алышасы, аңардан тагын нидер ишетәсе килә иде, ләкин профессор зур портфеленнән калын китабын чыгарып, шуңа, дорфа итеп әйтсәк, төртелгән иде инде.

Нина аңа: «Рәхим итегез!» — диде, кунак китабыннан аерылмыйча гына: «Рәхмәт!» — дип куйды. Шуның белән хәзергә Нинаның эше бетте, ул китәргә, ул яңадан чакырганны көтәргә тиеш. Аңа нәүмизләнергә ярамый, юк, ярамый, аның үз эше, үз урыны бар.

Ә профессор ашыкмый иде. Шул йөз грамм коньягын да ул өчкә бүлеп, аз-азлап кына эчте, закускаларын да туктый-туктый озаклап ашады. Күрәсең, бик кызыклы нәрсәгә тап булгандыр инде дип уйлады Нина... Ул боларның барысын да читтән генә күзәтеп торды, чамалап торды, һәм, кунак закускасын бетерүгә барып:

— Ашыгызны китеримме инде? — дип сорады.

— Әйе, ярый...— диде профессор, таркау гына.

Нина, бушаган савытларны җыештырып, өстәлне яңадан сөрткәләгән арада, кыюланып әйтте, ниһаять:

— Виктор Иванович, нигә ашаганда да китабыгыздан аерылмыйсыз?.. Болай укый-укый ашау зарарлы диләр ич!

— Нишлим соң, Ниночка! — диде профессор, җиңел генә көрсенеп.— Бер дә вакыт җиткерә алмыйм шул.

— Анысы шулайдыр инде, ләкин ял итәргә дә кирәктер бит... Сезне кызганып әйтүем...

— Рәхмәт, Ниночка! — Һәм профессор китабын ябып куйды.

Нәкъ шушы минутта алар янына графин белән аракысын, тәлинкә белән закускасын күтәргән кызыл чырайлы бер юан кеше килеп басты.

— Хөрмәтле Виктор Ивановичка сәлам!.. Рөхсәт итегез, Сезнең белән кампания төзеп җибәрергә! — диде ул, шаулап, һәм рөхсәтне көтеп тә тормыйча утыра да башлады.

— Ә, Семен Семенович, сез икәнсез! — диде профессор, елмаеп кына.— Рәхим итегез!.. Ләкин минем монда эшем бетте диярлек.

— Зарар юк. Минем дә эшем күп түгел, менә төбендә генә калды... Сезне күргәч, янығызга килмичә китүне килештермәдем, хөрмәтле профессор!.. Йә тагын үпкәли башларсыз, шулай бит, Ниночка күгәрченем?!

Нина нидер әйтмәкче иде, ләкин тиз генә сүзен таба алмады һәм, ашыккан булып, китеп тә барды. Әйе, ул бу кызыл чырайны яхшы белә иде, күптәнге таныш, кермичә калган көне юк диярлек. Тик бервакытта да ашарга керми, эчәргә генә керә, күбесенчә буфеттан гына үз өлешен салып чыгып китә. Закускасын өенә кайткач каба, имеш. Әмма ул ни җитте кеше генә түгел, аны да кайсыдыр институтның доцентымы, профессорымы диләр. Бик кирәкле кешедер, ахрысы, чөнки күпләр аның белән очрашканда хөрмәт һәм түбәнчелек күрсәтеп исәнләшәләр — Нина моны үзе дә күргәне бар. Әнә Виктор Иванович белән дә таныш булып чыкты бит әле ул... Ләкин шулай да Нина аны бер дә яратмый иде. Әллә нинди шапшак, дорфа, йөгәнсез бер адәм шунда. Кычкырып сөйли, шаркылдап көлә, теленә ни килсә, шуны әйтә дә ташлый, хәтта официанткаларга «тозлырак» сүз ычкындырудан да тартынып тормый. Үзе турында бик югары уйлый, күрәсең, урамавыз!.. Ә Нинага аның кем булуы нигә кирәк — әдәп белән культурасы җитмәгәч! Әнә ичмасам Виктор Иванович... Хәер, янәшә куеп буламы соң аларны?!

Нина Виктор Ивановичка ашын китергәндә алар үз дөньялары турында бик бирелеп кенә сөйләшеп утыралар иде. Нинага игътибар да итмәделәр шикелле... Тик бераздан ашның икенчесен алып килгәч кенә

профессор аңа тагын кофе да китерергә кушты. Билгеле, Нина монысын да бик тиз китереп җиткерде. Әмма, ни үкенеч, болай ук тырышырга кирәк булмаган икән. Ул инде кофейник белән чәшкәләрне кунаклары алдына куеп китә дә башлаган иде, ләкин нидер исенә төшеп, шунда, тегеләрдән аз гына читтәрәк торган кечкенә савыт-саба өстәле янында тукталды. Бер генә минутка тукталды, ә тегеләр аны китте дип белделәр, ахрысы, көтмәгәндә сүзләрен бүлеп, Нина турында сөйләшеп алдылар, һәм Нина, ихтыярсыздан шуны ишетеп, селкенергә дә кыймыйча тыңлап торырга мәҗбүр булды. Сүзне әлеге кызыл чырай Семен Семенович, гадәтенчә, туп-турыдан башлады:

— Карап торам да, Виктор Иванович, бу җиңел сөяк сезнең тирәдә бөтерелеп кенә йөри бит, хикмәте нидә икән?..

— Уңган официантка шулай булырга тиеш тә,— диде Виктор Иванович.

— Ай-һай, хикмәт шунда гына микән?! Башкалар тирәсендә болай бөтерелгәнен бер дә күргәнем юк. Миңа калса, ул Чибәркәй сезгә гашыйк, Виктор Иванович, валлаһи, гашыйк!

— Юкны сөйләмәгез! — диде Виктор Иванович, коры гына.

— Нигә аңа исегез китә? — диде тегесе, отыры шаулап.— Сезгә кемнең генә күзе төшмәс! Җитмәсә, ялгыз башыгыз, ә мондагы хатыннар барысын да белеп торалар. Валлаһи!.. Менә юри генә кылын тартып карагыз әле, күрерсез...

Ләкин профессор шунда ук аның сүзен бүлде:

— Гафу итегез, Семен Семенович, сез мине просто кимсетәсез,— диде ул, бик нык хәтере калгандай.— Бер ресторан чыпчыгы белән чуалырга... Сез мине кемгә саныйсыз?..

— Йә, йә, бетте, хөрмәтле Виктор Иванович, мин болай, дусларча шаяртып кына... Беләм инде Сезнең никадәр нәзакәтле кеше булуыгызны! — диде теге урамавыз, көлеп, һәм шунда ук берни булмагандай икенче сүзгә күчте: — Да, Сездән шуны сорамакчы идем, теге кем, Исаев диссертациясе белән сез танышмы-юкмы?..

Менә шул. Калганы Нинага кирәкми иде инде. Хәзер аңа тыңлап торганын ничек тә сиздермичә, күләгә төсле генә китеп барырга кирәк. Ул хәтта өстәленнән, шалтыравын ишетмәсеннәр дип, буш савытларны да алып тормады.

Баштарак Нина ике ирнең сүзләренә әллә ни гаҗәпләнмәде дә кебек... Бу җирдә эшләгәч, күп кенә ирләрнең официанткалар турында ни уйлаулары, нәрсә сөйләүләре аңа билгеле иде, ишеткәне дә бар иде һәм андый сүзләргә күпмедер дәрәҗәдә күнеккән дә иде. Әмма ләкин хөрмәтле профессоры авызыннан ычкынган бер сүз аны тәмам кисте, үтерде. Колагына килеп керү белән аның миенә генә түгел, йөрәгенә барып кадалгандай булды. Ресторан чыпчыгы!.. Ни дигән сүз бу, Ходаем, ни дигән сүз?! Һәрбер ирнең итәгенә кунарга әзер торган әрсез-азгын хатын дигән сүз түгелме соң бу?.. Ник әйтте ул аны, ник әйтте? Бик каты хәтере калганга күрәме, ачуыннан белештермичәме?.. Ләкин барыбер ул андый сүзне әйтмәскә, әйтмәскә, әйтмәскә тиеш иде ләбаса!!

Кайчагында официантканың кулыннан берәр нәрсәсе һич көтмәгәндә, тик кенә торганнан, төшә дә ватыла. Нәкъ менә шуның шикелле, Нинаның да хөрмәтле профессорына карата күңелендә йөрткән иң матур, иң керсез, ә үзе өчен бик кирәкле, бик кадерле уй-хыяллары бер сүз аркасында кинәт кенә челпәрәмә килеп, җимерелде дә төште. Берни генә эшләр хәл дә юк! Яңадан җыеп алу, тергезү мөмкин түгел, үпкәләү, ачулану, зарлану да мөмкин түгел... Әмма җан әрни, бик әрни, хәтта яшен тыя алмый, ашыгып йөргәндә ирексездән тәгәрәп төшә берәр тамчысы...

1970

# Курай

Күптән түгел Сәгыйть* дус миңа курай турында шушы легенданы сөйләде:

«...Бик борын заманда безнең җирләрдәге бер хан үсмер малайларны берәм-берәм чакыртып, шулардан чәчен кырдыра торган булган. Әмма чәч кырган малайларның берсен дә хан кире кайтарып җибәрмәгән — һәркайсын шунда ук үтертә икән. Шулай итеп, ханның чәчен кырган күп кенә малайлар һәлак булганнар. Ни өчен хан аларны үтерткән — моның сәбәбен берәү дә белмәгән... Менә көннәрдән беркөнне бер ялгыз хатынның бердәнбер малаена да чират җиткән: хан чәчен кырдырырга аны да чакырткан. Малай хан сараена китәр алдыннан әнисе аңа төче икмәк пешереп биргән: мә, улым, тамагың ачкач, утырып ашарсың, дигән.

Малай төче икмәкне кыстырып сарайга киткән, хан янына барып кергән һәм күп сөйләшеп тормастан ханның башын бик әйбәт юешләп, үткен пәке белән чәчен кыркып төшергән. Менә шул чакта ул гаҗәеп бернәрсә күргән: ханның башында имән бармак чаклы мөгезе бар, имеш!.. Хан да шүрәле сыман мөгезле, имеш!..

Малай эшен бетергәч, хан аңа әйткән: «Син инде минем мөгезне күрдең, ханның мөгезе бар икән дип сөйләп йөрерсең, шуңа күрә мин сине үтертәм»,— дигән. «Ярый,— дигән малай, бер дә каушап тормыйча,— тик син миңа шушы икмәгемне генә ашап алырга рөхсәт ит»,— дигән. Хан рөхсәт иткән.

Малай төче икмәген ипләп кенә ашарга тотынган. Ул, ашыкмыйча, авызын чәпелдәткәләп, бик тә тәмле итеп ашый икән. Хан да моның ашаганын карап тора торгач, кызыгып киткән: «Икмәгең бик тәмле күренә, кая, миңа да әзрәк сындырып бир әле»,— дигән. Малай чамалап кына сындырып биргән. Хан ашый башлаган һәм исе китеп, малайдан: «Нигә бу икмәк шул хәтле тәмле?» — дип сораган. Малай: «Әнием аны үзенең күкрәк сөтенә изеп пешерде шул!» — дип җавап биргән. Моны ишеткәч, хан шактый аптырап калган: «Алайса без синең белән бер ананың сөтен капкан булып чыктык, без хәзер бертуганнар булабыз бит!» — дигән. Малай дәшмәгән. Ә хан уйланып: «Бертуганны үтерергә ярамый бит әле, менә хикмәт нәрсәдә! — ди икән.— Ләкин үтертмичә дә булмый, чөнки син минем мөгезне күрдең, халыкка сөйләп йөрерсең... Инде нишләтергә сине?..»

Малай бу юлы да дәшмәгән, һаман тәмләп кенә төче икмәген ашый биргән. Шуннан соң хан, бераз икеләнеп торгач, малайга әйткән: «Ярар, мин сине үтертмим,—дигән.— Ләкин бер шартым бар. Кырда кура дигән бер көпшә үсә, син аның кипкәнен чокыр башыннан табарсың. Менә шул көпшәне кисеп ал да минем мөгез турында сөйлисең килгән саен шуңа гына өрә торган бул... Аңладыңмы?.. Мөгез турында — ләм-мим!.. Телең кычыта башлады исә, көпшәне генә сызгыртырга тотын!.. Килештекме?»

Малай: «Ярый, риза»,— дигән, шуннан хан аны өенә кайтарып җибәргән.

Малайның вакыт-вакыт мөгез турында бик сөйлисе килеп китсә дә, вәгъдәсен бозмаган. Сөйлисе килгән саен, әлеге шул кырдан кисеп алган көпшәсен «гү... гү» өрергә тотына икән. Тора-бара ул көпшәнең түбән очына тишекләр дә ясаган. Тишекләргә баскалап, көпшәдән нечкә-калын тавышлар да чыгара башлаган. Шулай итеп малай төрле көйләр уйнарга өйрәнеп киткән. Хәзер инде ул ханның мөгезен сөйлисе килгәндә генә түгел, ә телдән әйтә алмаган берәр уе, хәсрәте бар чакта да көпшәсен алып уйный икән. Искиткеч моңлы-матур уйнаган ул, кешеләр аны таң калып тыңлаганнар. Кеше теле әйтеп бирүдән гаҗиз хисләрне кузгатучы курай дигән гаҗәеп нәрсә әнә шулай туган, имеш!»

Бу легенданы яңарак ишетсәм дә, курайның үзен миңа бик яшьли күрергә һәм тыңларга туры килде. Безнең Дәүләкәнгә терәлеп кенә торган Яңа Көрмәнкәйдә курай уйнаучы бер карт бар иде — менә шул картны хәтерлим әле мин... Тик минем балалык хәтеремдә аның кураеннан бигрәк башка ягы ачык сакланган. Хикмәт шунда, Тимербай карт курайчы гына түгел, балыкчы да иде. Һәм без, Дәүләкән малайлары, Дим тугаена барган чакта Тимербай картның шундагы күлләрдә тар гына бүрәнә каекка утырып, сыңар ишкәге белән камышларны ера-ера нәрәтә куеп йөргәнен гел күрә торган идек. Ул кояштан, җилдән бакырга әйләнеп, какланып беткән, бик чандыр бер кеше иде. Балакларын тезенә чаклы сызганган, күлмәгенең алдын ыштан бөрмәсенә кыстырган, үзе һәрвакытта ачык, ә башында беләүләнеп каткан түбәтәй... Аннары тагын шул ук ыштан бөрмәсенә бәйләп, ул иске күн кыныда кечкенә үткен пычак та йөртә иде. Бигрәк тә менә шул пычакка безнең күзебез яна иде һәм, әйтергә кирәк, бу пычаклы бабайдан без әзрәк кенә курка да торган идек.

Соңыннан Тимербай карт нәрәтәгә кергән бик шәп табан һәм кара балыкларны иске кәрзингә тутырып, өстен яшел үлән белән каплап, Дәүләкән урамында, ыштан балакларын да төшермәгән килеш, сатып йөри иде.

Аннары инде, үсә төшкәч, мин аның курайда уйнавын да хәтерли башладым. Әйбәт, оста уйный идеме ул —мин әле белми идем, әмма өч-дүрт тишегеннән башка бернәрсәсе дә булмаган, эче куыш, җип-җиңел, кибеп беткән көпшәдән шундый гаҗәеп озын көйләр чыгара алуына хәйран кала торган идем. Бер могҗиза булып тоела иде ул миңа, һәм мин, кем өрсә дә курайдан шулай көй-моң чыгара аламы икән, дип, баш вата идем. Билгеле инде, минем курай дигән шул җип-җиңел көпшәне тотып өреп карыйсым килә иде... Ләкин Тимербай карт кураен юри генә, карар өчен генә дә һичкемгә тоттырмый иде. Уйнап беткәч, ул кураеның башын ни өчендер ялаштырып ала да аннары күлмәк изүеннән каядыр эчкә үк тыгып куя. Бу да мине бик гаҗәпләндерә иде.

Әмма минем курай белән чынлап торып сихерләнүем тагы да үсә төшкәч, унөч-ундүрт яшьлек чагымда булды. Беләсез, бу шундый вакыт инде — күңел кыллары үзеннән-үзе тибрәнеп, йөрәктә җыр-моң туарга гына тора! Хыялның да бик җилкенгән, эзләнгән, очынган чагы!.. Нәкъ менә шушы чакларда миңа курайны еш кына ишетергә дә туры килде.

Безнең күршедә генә Миңнегәрәй исемле башкорт тора иде. Аның ике аты бар. Шул атларын тәңкәле камыт-эшлияләр белән читән тарантаска җигеп, поезд килүгә Дәүләкән станциясенә чыга һәм поездан төшкән кымызчыларны утыртып, Дим буе авылларына илтеп куя торган иде. Бу аның төп кәсебе, атларын һәрвакыт таза, көр тота, ә көз җитеп, беренче кар төшкәч, шул атларның берәрсен иярләп, төлке, бүре сугарга да чыга иде. Шуның өчен генә ул ике бурзай да асрый иде. Кыскасы, бик егет кеше иде безнең күрше Миңнегәрәй агай.

Менә шул Миңнегәрәй агайга базар көннәрендә Дим буеның берничә мулласы, әйтик, Шәрип авылыннан Котлыяр мулла, Казанголдан — Исхак мулла, Япардан — Сафуан мулла гел килә торганнар иде. Бу өч мулла бик дуслар иде, ахрысы, чөнки кайчан карама, алар һәрвакыт бергә булалар иде.

Аларның базарда бернинди сату-алу эшләре юк, иртәнге якта чыгып, базарны бер әйләнәләр дә үзләре кебек тагын берничә мулланы яки бай башкортны ияртеп кайталар һәм Миңнегәрәй агайның түр сәкесендә көне буе диярлек ашап-эчеп, курай тартып, җырлашып утыралар... Ике ихата арасында тәбәнәк

читән генә, ә күрше өйнең тәрәзәләре киңенчә ачык, шунлыктан барысы да — сәкедәге чирек-чирек кымызлары да, табак тулы итләре дә һәм кунаклар үзләре дә ап-ачык күренеп тора. Гомумән, башкорт муллалары ашап-эчеп утыруларын берәүдән дә яшермиләр иде. Исерә калсалар да гаеп итүче юк — мулла да кеше!

Менә шул ачык тәрәзәләрдән инде бервакыт, абзыкаем, курай белән җыр агыла башлый!.. Һәм мин шуны ишетүгә, барган җиремнән капкынга эләккәндәй, шып тукталып кала идем. Һич ычкына алмый идем мин ул татлы әсирлектән... Бөтен дөньямны онытып, ләззәтеннән, сызландыруыннан җыларга җитешеп тыңлыйм да тыңлыйм... Күз алдымда үзенең якты киңлекләре, тын түбәләре, ак тирмәләре, утрауда йөргән җылкылары белән кылганлы дала әкрен генә җәелә дә җәелә... Бик биектә бөркет салмак кына йөзә. Еракта ялгыз җайдак шәүләсе күренеп кала, әллә кайда гына әрлән сызгыруы ишетелгән кебек була... Һәм иң гаҗәбе, шул далада ак тастарлы җиңгәнең муенына корык салган бияне савып утырганын бик ачык итеп күрә торган идем. Бу шулхәтле ачык-җанлы булып күз алдына килә, мин хәтта җиңгәнең ике тез арасына янтайтыбрак кыстырган агач чиләген дә, шул чиләккә биянең ике имчәгеннән алмаш-тилмәш бәреп төшкән нечкә генә сөтне дә күргәндәй була идем... Әнә шулай әллә кайларга алып китә, хыялый итә иде мине бу башкорт курае, башкорт җыры!

Курайчыны берничә мәртәбәләр күрсәм дә, мин аның кайсы авылдан, кем икәнен белә алмадым. Аны шул муллалар үзләре базардан ияртеп кайталар иде. Аз гына кылый, аз гына шадра, озын буйлы бу агай, минемчә, бик шәп курайчы булгандыр. Бик дәртләнеп, бик рәхәтләнеп, ничектер җиңел итеп, гүя уйнап кына тарта иде ул үзенең кураен! (Аның сирәк кенә төкле ирене кураен китереп терәмәс борын ул үзеннән-үзе селкенә башлый иде инде.) Әмма шул ук вакытта ул кураеннан гаҗәп саф, гаҗәп иркен тавышлар чыгара белә һәм шуны искиткеч озын итеп, бормаландырып суза да ала иде. Кыскасы, тәмам җелеккә үтәрлек итеп уйный иде агабыз!

Ә курайга кушылып һәрвакыт Котлыяр мулла җырлый торган иде, һичшиксез, курайчыга тиң җырчы иде ул... Авызын ачар-ачмас, иреннәре арасыннан гына бер суза башласа, тавышы киң далага да сыймас кебек... Шуның өстенә гаҗәеп моңлы-матур җырлый иде бу мулла!.. Мин аны яхшы беләм, бездә дә аның булганы бар иде. Озын кара кәзәки кигән мәһабәт таза гәүдәле, елтырап торган кызгылт-шома битле, сирәк кенә кара сакаллы бер кеше иде ул. Базардан базарга, кунактан кунакка гел бал, кымыз эчеп тә кызык сөйләп, җыр җырлап йөргән бу кешенең мулла булуына ышануы да читен иде. Елына ике килә торган гаеттан башка ул үзенең мәчетенә йөрде микән?.. Һәрхәлдә, мин аның чалма кигән чагын күрмәдем.

Озын сүзнең кыскасы, күрше Миңнегәрәй агай өенә җыелып, сәрхуш булып утыручы муллаларның җыр-курайларын миңа бер-ике җәй буена еш кына ишеткәләргә туры килде. Нәкъ менә шул чакта башкортның тиңсез бай, гүзәл, сихри җыр-моңнары минем кайрыланып өлгермәгән күңелемә гомерлеккә диярлек сеңеп калды да булса кирәк. Аннары озак та үтми мин, шактый яшь башымны алып, туган-үскән оядан, якты Дим буйларыннан ерак калага чыгып киттем. Ә бер өч-дүрт елдан соң теге муллалар да кайсы кая таралып, югалып беттеләр шикелле.

Шактый күп еллар узгач, мин үзебезнең радиокомитетта (фронттан кайтып шунда эшли башлаган чагым) тагын бер курайчы белән таныштым. Бу инде татар курайчысы иде. Шуның өстенә радиода уйнаштыра, димәк, аны күпмедер дәрәҗәдә профессиональ курайчы дияргә дә була. Ләкин якынрак танышкач, мин аның кайчандыр хуҗалык эшләрендә эшләп йөргәнен, тик соңгы вакытларда гына курайчы булып танылып киткәнен белдем. Әлбәттә, музыкага бик сәләтле кеше иде ул, кулына ни тотса, шуны уйный ала, курайга да яшьтән үк өйрәнгән, әмма болар берсе дә аның өчен төп кәсеп була алмаган. Инде аны радиога чакырып уйната башлаганнар икән, моның сәбәбе бик ачык: шәһәрдә ул бердәнбер курайчы.

Исеме аның Исмәгыйль иде. «Исмәгыйль абзый» дип эндәшә идек без аңа. Җыйнак-җиңел гәүдәле, җирән сакаллы, зур коңгырт күзле бу чибәр абзый телгә дә бик җор иде, гел уен-көлке сөйләргә ярата торган иде. Шуңадыр инде ул безнең радиокомитетка йөрүче күп кенә артистлар, җырчылар, композиторлар белән дә якыннан аралашып, ничектер җиңел генә дуслашып өлгергән иде.

Мин үзем дә Исмәгыйль абзыйны ярата идем, алюмин кураен да рәхәтләнеп тыңлый идем, ләкин ни өчендер шул чакта еш кына «Нигә бу абзый табигый курайда уйнамый икән?» дип, ихтыярсыздан уйлана да идем. Белмим, яшьтән үк тыңлап өйрәнгәнгә күрәме, миңа ясалма курайга караганда кырда үскән табигый курай якынрак та һәм тансыграк та иде. Дөресен генә әйткәндә, күптән инде мине бер нәрсә гаҗәпләндерә: ни өчен табигый курай бездә юк, ни өчен ул, әйтик, башкортларда сакланган да, бездә сакланмаган?.. Бик сирәк кенә очраган безнең курайчылар йә тимер, йә җиз курайда уйнаганнар. Бәлки, кеше кулы белән ясалган бу курайлар теге ялан кураена караганда әйбәтрәктер, курай сәнгатендә үзенә күрә бер алга китештер?.. Ихтимал, шуның өчен дә ясалма курай табигый курайны гамәлдән кысып чыгаргандыр?.. Бу хакта мин Исмәгыйль абзыйның үзеннән дә сораган идем. Аның әйтүенә караганда, табигый курай, билгеле, безнең татарларда да булган, хәзер дә әле кайбер җирләрдә, мәсәлән, Ык буенда ялан кураенда уйнаучылар очрый, ләкин татар халкы кырда үскән курай белән генә чикләнмичә, шуның төсле итеп тимердән, җиздән дә ясарга өйрәнгән. Моның сәбәбе безнең дымсурак, салкынчарак җирләрдә уйнарга яраклы курайны табуга караганда, аны кулдан ясау ансатрак булганга күрәдер, бәлки?! Аннары

тагын ясалма курайның тавышы да безнең татар колагына нәфисрәк ишетелсә кирәк.... Бу сүзләрдә, һичшиксез, дөреслек булырга тиеш.

Шуннан соң мин бер сөйләшүдә Исмәгыйль абзыйдан туп-туры сорадым:

— Ни өчен сез ялан кураенда уйнамыйсыз?

Моңа каршы ул көрсенә биреп:

— Их, Әмирхан туган, уйнамас идеммени мин, ләкин юк бит ул, ялан курае юк,— диде.

— Ә сез дөресен генә әйтегез әле: ялан кураен үзегез яратасызмы?

— Һе, яратмыйча, әлбәттә, яратам.

— Алайса табарга кирәк аны.

— Ә кайдан?.. Акчага сатылмый. Арчада үсми ул... Аның өчен генә Урал тауларына барыргамы?

— Бик кирәксә, барасың да аны...

— Мин әзер,— ди Исмәгыйль абзый, шунда ук сүзне уенга борып.— Әйдә, командировочный яздыр, иртәгә үк китәм.

— Курай сиңа кирәк бит.

— Нишләп миңа, халыкка кирәк ул... Ә халыкка кирәкне табу — сезнең эш... Чын, комитет алдында мәсьәләне күтәр, курай җыеп кайтыр өчен Уралга экспедиция җибәрик, диген.

Безнең сөйләшү әнә шулай ярым уен-көлкегә әйләнеп бетә торган иде. Әлбәттә, миңа тансык курай турында бүтән уйлаучы да юк, аннары Исмәгыйль абзыйның алюмин курайлары бар чагында башкасын кирәк дип белүче дә юк иде.

Ул шулай кысыр хыял булып калган да булыр иде, ләкин бер җәйне минем үземә Оренбург өлкәсенә, Куандык дигән җиргә кайтырга туры килде. Юлга чыгар алдыннан мин бу сәфәремне Исмәгыйль абзыйга да әйттем.

Абзый, кызыксынып:

— Куандык?.. Нинди җир, кайда ул? — дип сорады.

— Сакмар буенда,— дидем мин.

— Сакмар буенда!.. Бик тә ямьле якларга китәсең икән, туган! — диде ул сөенеп һәм әз генә көнләшкәндәй дә булып. Аннары, нидер исенә төшкәндәй, ачылып өстәде: — Карале, син шуннан миңа әлеге үзең мактаган ялан кураен табып кайтмассыңмы?.. Сакмар буенда үсәргә тиеш ул!

Аның бу үтенече миңа да ошап куйды.

— Ярар, абзый, эзләп карармын! — дидем мин ихлас кына.

— Зинһар, туган!.. Син үзең кырда үскән курайны таныйсыңдыр бит?

— Танымасам, мин аны шундагы агайлардан эзләтермен.

— Бигрәк тә яхшы!.. Тик син берничәне табарга куш инде... Түләргә туры килсә, алып кайткач, исәпләшербез...

— Анысы өчен борчылмагыз, Исмәгыйль абзый,— дидем мин, сүзне шуның белән өзеп.

Куандык!.. Кайдан бу шигъри матур исем?.. Минем сугышка чаклы да бу тирәләрдә булганым бар иде. Беренче күргәч, үзем дә куануга охшаш хис кичергән идем. Табигатьнең гаҗәеп бай, матур җирендә утыра ул Куандык!.. Кайсы ягына карама, ямь-яшел йомры түбәле биек-биек таулар... Шул таулар арасыннан бормаланып көмештәй ак, чиста Сакмар агып килә. Таулар чигенгән җирләрдә билдән дә югары куе үлән үскән тип-тигез тугай җәелеп китә. Ә таулар китереп кыскан урыннарда текә кыялар бөтерелеп аккан Сакмар өстендә таш стенадай басып торалар... Билгеле инде, бу гүзәллекне, бу байлыкны беренче килеп күргән кешеләрнең чынлап куанулары да һәм ак тирмәләрен корып утырган шушы урынга «Куандык» дип исем бирүләре дә бик табигый, бик аңлашылса кирәк. Шигъри исем үзе үк шуны әйтеп тора!

Куандыкка мин кыз туганнарыма кунак булып кайткан идем. Аларда хәзер ир заты юк, икесенең ире һәм бердәнбер энеләре сугышта һәлак булдылар. Шуңа күрә мин, фронттан исән-имин кайткан ага тиешле кешеләре, алар өчен бик кадерле кунак идем. Сый-хөрмәтне әйткән дә юк, ашап-эчеп кенә өлгер, шуның өстенә ике-өч көн саен эссе мунча, яткан урыным да ак өйнең түрендә, сиртмәле караватта гына...

...Бу сый-хөрмәттән бик тиз маемларга да мөмкин иде, ләкин мин Ходай бирмеш һәр көн йә Сакмар буена, йә тауларга чыгып китә идем. Таулар!.. Малай чактан ук калган бер комарлыгым бар — кайда гына берәр биеклек күрмим, шуңа үрмәләп булса да менәргә тырыша идем. Менә Куандык әйләнәсендәге тауларга да мин тырыша-тырмаша мендем, ниһаять!

Тау биекме?
Син менәмсең?
Мен, менә алсаң, тауга мен!
Тауга мен, күр дөньяны син,
Күр бу дөньяның ямен!

Әйе, дөньяның хәйран ямьнәре, хәйран киңлекләре ачыла икән бу таулардан!.. Әкрен генә җил уйнаган биек түбәдән мин, үземчә чамалап, әле Орск, әле Җилаир якларына озак кына карап тора идем. Аннары...

Төш түбән, йөр син түбәндә,

Күр чәчәкләр, чишмәләр,
Күр игеннәр, күр җимешләр.
Хәсрәтеңне бер китәр!

Әйе, Сакмар буена төшкәч, хәсрәт-уйлар чынлап та каядыр ага да китә. Назлы-шаян кызлар кебек бит ул җыр булып аккан Сакмар!.. Бер карасаң, чуерташлар өстеннән ак тәпиләрен елтыратып көлә-көлә йөгерә, икенче карасаң, озын толымнарын сүткән шикелле, зәңгәрләнеп-уйчанланып тын гына агып ята.

Ничөн суга сузыласың,
Тал чыбыккай, интегеп,
Ялварасың, борыласың,
Тилмерәсең, өзеләсең,
Аккан суга күз тегеп?
. . . . . . . . . . . .

Әнә шулай иске шигырь өзекләрен искә төшереп, мин Куандык әйләнәсендә күп йөрдем. Әлбәттә, Исмәгыйль абзыйның курай табып кайтырга кушкан үтенечен дә хәтеремнән чыгармый идем, киресенчә, күңелгә килгән җыр, шигырьләр курайны гел искә төшереп кенә тора иде. Әмма мин үзем Сакмар тугаенда да, тау битләрендә дә, күпме каранып йөрсәм дә, аны очрата алмадым. Әллә юк, әллә эзли белмим?.. Ахрысы, танып та җиткерми торганмындыр. Иллә мәгәр бөтен нәрсә күкрәп үскән бу җылыякты җирләрдә курай булырга тиеш бит, булмыйча мөмкин түгел!

Ахырда бу эшне, башта уйлаганча, бер агайдан үтенергә туры килде. Кешесе дә табылды. Базар көн саен Сакмар үрендәге бер авылдан килеп, минем кыз туганнарда атын тугарып торучы Хаҗиәхмәт исемле бер агай иде ул. Үзе урман каравылчысы икән... Менә бер килүендә мин шул агайдан, «базар чәен» изүен чишеп клиндер манып эчеп утырган чагында, иплэп кенә сорадым:

— Әйт әле, Хаҗиәхмәт агай, сездә курай бармы?

— Курай? Нинди курай? — диде ул, аңлап бетермичә.

— Соң, уйный торган курай.

— Бар бугай бер-ике кешедә. Уйнаштыралар.

— Менә миңа да кирәк иде шул курай.

— Тарта беләсеңмени? — диде ул, елмаеп кына.

— Үзем өчен түгел. Бездә бер курайчы бар, шул кушкан иде. Табып китермәссеңме?.. Буш итмәм.

— Курайны бит аны, туган, сатар өчен ясамыйлар.

— Миңа ясаганы кирәкми. Кырда үскәне булса ярый... Үсәме ул сездә?..

— Үсә, күп үсә, бер колач кыркып китерергә була,—диде ул, кәефле генә елмаеп.

Аның болай җиңел генә әйтеп ташлавы мине бераз пошындырып та куйды. Колачы белән кыркып китергән курай ни төслерәк булыр икән?.. Эшкә ярый торганмы, түгелме?..

— Син, Хаҗиәхмәт агай,— дидем мин, шигемне сиздермәскә тырышып,— курайның уйнарга ярый торганын гына табып китер инде. Колачлап кирәкми, берничәү булса, шул җитәр... Сине өйрәтәсе юк, үзең дә беләсеңдер?!

— Ярар, синең өчен чагылда үскәнен генә табып китерермен,— диде Хаҗиәхмәт агай, пинжәк чабуы белән шабыр тир битен сөртә-сөртә. Аннары сыңар кулы белән генә ияген сыпырып куйды: «Аллаһе әкбәр!»

Әлбәттә, белә ул, белмиме соң?.. «Чагылда үскәнен» ди бит. Ягъни кояшка каршы тау битендә үскән курай була инде ул... Мин чамалыйм, бу курайның иң әгъләсе, өрмәс борын «Баранбай»ны суза башлый торганы булырга тиеш. Ишеткәнем дә бар, җылы туфрактан һәм эссе кояштан ярала икән ул чын курай! Шуңа күрә төпченеп тормадым, хәтта кайчан китерәсен дә сорамадым — Хаҗиәхмәт агай, барыбер, клиндерләп чәй эчәр өчен генә булса да, алдагы базарга килеп җитәчәк.

Ләкин атна арасында беркөнне Сакмардан су кереп кайтсам, өйнең тышкы бусагасында әлсерәп бер карчык утыра. Ерактан килгәнгә охшый, җирдә таягы да ята, үзе янып-көеп, тәмам бакыр төсенә кергән. Көннәре дә бу арада бик эссе тора, пешеп үләрлек... Мин ихтыярсыздан: «Кем бу әби, ни өчен мондый чакта йөри, саилче микән әллә?» — дип тә уйлап куйдым. Шул чакта кар базыннан салкын катык күтәреп, минем кече сеңел Һәммәюн килеп чыкты. Мин, аңа таба атлап, әкрен генә:

— Бу әби кем була? — дип сорадым.

— Хаҗиәхмәт агайның әсәе, Миңзифа әби,— диде Һәммәюн.

— Шулаймыни? — дидем мин аптырап, аннары карчык янына барып исәнләштем: — Исәнме, әби!

— Саумы, улым! — диде әби, ачык кына.

— Кем белән килдегез?

— Үзем генә.

— Әллә җәяү?

— Җәяү шул,— диде әби, елмаерга тырышып. Мин гаҗәпләнеп торган арада Һәммәюн әйтеп куйды:

— Әнә ул сиңа курайлар китергән.

Курайлар китергән?! Шушындый эсседә, унбиш чакрым җирдән, җәяүләп?! Бер мизгел ни әйтергә дә белмичә торгач, мин, ниһаять:

— Их, әбекәем! — дидем, ачынып.— Нигә болай азапланып йөрисең, ашыгыч нәрсә түгел бит ул. Хаҗиәхмәт агай үзе дә базар көнне китергән булыр иде!

— Улым килә алмый, печәнгә төштеләр...

— Шулаймыни?.. Җайсызрак килеп чыккан икән. Сезгә, карчык кешегә, бу эсседә йөрүләре бик авырдыр бит? Әби бер дә исе китмичә генә:

— Һи, йөрүмени бу! — диде.— Көн өстенә килеп китәбез без Куандыкка... Әле индә йөк тә була, буш кул белән килүнең бер азабы да юк. Менә әзрәк кенә хәл алам да кире китәм.

— Кире?.. Юк инде, әбекәем, бүген мин сезне җибәрмим. Хәзер менә чәй эчәрбез, аннары аш та өлгерер.

— Юк, булмый, миңа эчәргә ярамый әле,— диде карчык, кипкән иреннәрен ялап.

— Нишләп?

— Мин — ураза.

— Ураза?

— Әйе, Алла кабул итсен!

Тагын шул гына җитмәгән иде! Их, әби, әби, болай да элеп киптергән кебек булгансың бит, дидем мин эчемнән генә, ләкин үзенә әйтеп тормадым, чөнки әйтүдән мәгънә юк, һәм, килешмәс тә иде ул. Кешенең гомере буе тоткан уразасын бозып буламы соң?!

Минем карчык китергән курайларны тизрәк күрәсем килде. Аның артындарак чүпрәккә төрелгән озын бер нәрсә стенага сөялеп тора иде, шуңа ымлап сорадым:

— Шулмы инде сез китергән курайлар?

— Ийе,— диде карчык һәм борылып озын төргәкне алды.— Мә, үзең сүтеп кара.

Мин, чүгәләп, баш-башыннан бәйләгән бауларны чиштем дә чүпрәкне сүттем. Менә сиңа курайлар!.. Дөресрәге, курай булачак куралар... Җидәү икән үзләре, кайсы озын, кайсы кыскарак. Бик үткен пәке белән киселгән булса кирәк, очларында бернинди яньчелгән яки ярылган җире юк... Һәм шушы эче куыш, җип-җиңел, үтә кипкән үсемлек сабагы, кемдер ирененә тидереп, өрә башлагач та, үзенә сихри җан кергәндәй, өздереп уйнап җибәрергә тиеш!.. Гаҗәп, гаҗәп!.. Бәлки, безнең иң ерак бабаларыбыз әле үләнтамыр җыеп туена башлаган чакларында ук бу үсемлекне өреп карарга, сызгыртырга өйрәнгәннәрдер. Бәлки, шул заманнардан ук инде сакланып килә торгандыр бу курай дигән иң табигый, иң кадерле уен коралы?! Ләкин менә хәзер аны ничек бәяләргә? Бәһасе бармы аның? Һәрхәлдә, бушка гына бирелми һәм алынмый торгандыр инде.

— Хаҗиәхмәт агай нәрсә әйтте соң? — дип сорадым мин карчыктан. Ул, билгеле, минем тел төбемне аңламады.

— Нәрсә әйтсен. Куралар әйбәт, диде, үзе дә ике көн эзләп йөрде.

— Рәхмәт инде аңа, бик рәхмәт!.. Тик, әби, мин боларның бәясен белмим бит әле... Күпме тора икән үзләре?

— Хода белсен! — дип кенә куйды карчык. Ул һаман да әле сүзнең нәрсә турында баруын аңлап бетерми иде, ахрысы... Шуннан соң мин, торып, кесәмнән утыз сумлык* чыгарып суздым.

— Аз булмасмы, әби?

Карчык сискәнгәндәй кинәт миңа ике кулын селтәде:

— Куй,кирәкми!

— Ничек инде кирәкми?.. Бушка гына булмый бит.

— Кирәкми, кирәкми! — диде карчык, кат-кат башын, кулын селкеп.— Кырда үскән кура өчен кеше акча аламыни, ошамаганны!..

— Кура өчен булмаса, хезмәтегез өчен алырга тиешсез. Хаҗиәхмәт агай вакытын әрәм итеп эзләп йөргән, сез менә җәяүләп китерә килгәнсез... Шуның өчен түлим мин, алыгыз!

— Юк, алмыйм! — диде карчык, кырт кисеп.

Мин шактый кыен хәлдә калдым. Кулымдагы акчаны карчыкка көчләп бирә дә алмыйм, кире кесәмә салсам да бик уңайсыз. Нишләргә соң?.. Карчыкны болай бернәрсәсез җибәрү һич тә ярый торган эш түгел, ничек кенә булса да аны бәхилләтергә кирәк. Ләкин ничек итеп?.. Ахырда, без, җыйнаулашып дигәндәй, карчыкны бүген китмәскә, авыз ачып, куна калырга кыстый башладык. Карчык моңа да бик авырлык белән генә күнде. Балалар көтә, килен ачуланыр дип, һаман карышып маташты.

Балалар дигәннән, мин Хаҗиәхмәт агайның вак кына балалары күп булуын ишетеп белә идем. Шуннан күңелгә бер әйбәт уй килде: әлеге карчык баш тарткан акчаны Һәммәюнгә биреп, шул балаларга тәмле-төмледән ни дә булса, ә карчыкның үзенә чәй-шикәр алып, шуларның һәммәсен киткән чагында гына кулына тоттырырга куштым. Күчтәнәчтән инде әбиебез баш тартмас, шаять!

Кояш баегач, әби тоз тәмләп кенә авыз ачты, безнең белән утырып аш ашады, аннары бик күп итеп чәй эчте. Икенче көнне таң беленгәч үк торып, яңадан уразага керер өчен сәхәрен ашап, Сакмар үрендәге авылына кайтып киткән иде инде ул...

Санаулы көннәр тиз үтте. Минем дә китәр вакыт җитте. Юлга әзерләнгән чакта гына көтелмәгән бер мәшәкать чыкты: куралар минем чемоданга сыймый икән. Бөкләп сала торган әйбер түгел, нишләтергә үзләрен?.. Болай төреп бәйләп кенә алсаң, юлда йә сынар, йә изелер дип тә курыктым. Шуннан соң кыз туганнарның киңәше белән, май заводында әрҗә ясаучылардан тиз генә озын футляр сыман бер нәрсә эшләтеп алдым. Куралар шуңа шып кына кереп утырдылар.

Өйгә кайткач, Исмәгыйль абзыйны чакырып алып, тантаналы рәвештә дигәндәй, кураларны футлярыние белән аңа тапшырдым. Абзый, үзе кушып җибәрсә дә, ышанып көтмәгән икән, күргәч бик куанды.

— Валлаһи газим, чын куралар бит болар, башкорт менә шулардан курай ясап тарта да инде! — диде ул, һәркайсын бик җентекләп карый-карый.

— Хәзер, Исмәгыйль абзый, син «тартканны» ишетәсе калды безгә,— дидем мин.

Ул әзрәк уйланып торды да ни өчендер башын кагып куйды:

— Белмим шул, белмим шул!..

Шактый гаҗәп тоелды миңа аның бу уйчан-сәер җавабы. Ничек юрарга моны дип торган арада, ул миннән кинәт кенә сорады:

— Ә күпме түләргә үзләренә?

Тагын каһәр суккан акча мәсьәләсе!.. Теге әби шикелле кырт кисеп кенә: «Юк, бер тиен дә кирәкми!» —дип әйтмәкче булган идем дә, кинәт Исмәгыйль абзыйны бераз шаяртасым килеп китте. Авыр гына сулаган булып:

— Кыйбатка төште бу куралар, Исмәгыйль абзый, һәркайсы утызар сум тора,— дидем.

Ләкин Исмәгыйль абзыйның моңа бер дә исе китмәде:

— Булыр, булыр!.. Сакмар кадәр җирдән кайткан ич алар! Нәрсә, хәзер үк түләргәме?

Мин ирексездән көлеп җибәрдем һәм теге әбинең бу кураларны иң эссе көндә, ураза килеш, унбиш чакрым җирдән җәяү китерә килеп тә бер тиен акча алмавын сөйләп бирдем.

Кечкенә бу вакыйга Исмәгыйль абзыйга шактый нык тәэсир итте булса кирәк, ул сүз таба алмагандай бераз дәшми торды, аннары, башын кагып: «Кара син, ә, изге бәндәләр дә бар икән!» — дип куйды. Шуннан соң кураларны, дөньяның иң кадерле бер нәрсәсе шикелле култык астына сак кына кыстырып, кат-кат рәхмәтен әйтеп китеп барды.

Әмма иң кызганыч, Исмәгыйль абзыйның ялан кураенда уйнаганын миңа ишетергә туры килмәде... «Белмим шул» дигән иде ул, курайларны миннән алып киткән чагында. Нидер сизенгән шикелле әйткән икән абзый кеше!.. Башта аның өен, урыны яңа төзелешкә кирәк булгач, шәһәрдән шактый еракка, каядыр Чыңгыз тирәсенә күчерделәр. Исмәгыйль абзый шуның мәшәкатенә кереп батты, ахрысы, бөтенләй күзгә күренми башлады. Аннары күпмедер вакыттан соң үзе дә каты авырып, көтмәгәндә генә үлеп киткән... Мин аның үлемен хәтта ишетми дә калдым. Кем әйтмешли, дөнья бу!..

Ләкин соңыннан инде, Исмәгыйль абзыйны искә төшергән чакта, теге курайларны ул нишләтте икән дип уйлап куйгалый идем. Бары күптән түгел генә ишетеп белдем:

Исмәгыйль абзыйдан калган барлык курайлар да Тел, әдәбият институтының музыка кабинетында саклана икән... Юри кызыксынып барып карадым. Моннан күп еллар элек Хаҗиәхмәт агай Сакмар буеның тау битләреннән кыркып алган, әнисе Миңзифа карчык җәяүләп Куандыкка китерә килгән, мин исә махсус футлярга салып алып кайткан курайлар кабинет шүрлегендә, иске газеталарга төрелгән килеш яталар. Сүтеп карагач, мин аларны таныдым. Исмәгыйль абзый һәркайсына өстән дүрт, астан бер тишек ясаган (нәкъ башкорт курае төсле итеп), кулыңа ал да сыздырып сузып җибәр!.. Әмма алар өнсезләр, сыздырып сузып җибәрердәй кешесе юк — әкияттәге теге малай кебек кешесен, кешесен кайдан табарга?!

1970

# Онытылмас минутлар

Кәрим абзый белән Рәмзия ханым — гашыйклар. Ихтимал, шунлыктандыр, алар бер-берсенә гаҗәп тиң, пар килгәннәр. Кәрим абзагыз иллеләр өстендәге буе-сыны бик төз, бик егәрле, чын ир кеше — ир солтаны! Ә Рәмзия ханым кырыклар тирәсендәге гаҗәеп сылу, нәфис, мөлаем бер хатын. Йөзе дә аның кызларныкы кебек чиста, алсу, күзләре якты, кашлары нечкә. Картая белми торган токымнан булса кирәк.

Имештер, кешеләр туган чакта ук үзләренә билгеләнгән ишләре белән туалар, тик күп очракта алар бер-берсен таба гына алмыйлар. Ә менә Кәрим абзый белән Рәмзия ханым бик соңга калып булса да, ниһаять, бер-берсен тапканнар һәм, табигый инде, ялкынлы дәрт белән яратышып-якынаеп та киткәннәр.

Ләкин без капчыкта ятмаган шикелле, яшерен мәхәббәт тә озак билгесез булып кала алмый, иртәмесоңмы барыбер төртеп чыга ул. Моның өчен берәр таныш-белешнең ишетеп яки күреп алуы гына кирәк — шомлы хәбәр шунда ук тиешле җиренә барып та җитә.

Шуннан соң инде... Шуннан соң менә алар, ягъни Кәрим абзый белән Рәмзия ханым, заманча бик шәп җиһазлы иркен квартираның бер бүлмәсендә икәү генә утыралар. Дөрес, бер-берсеннән читтәрәк утыралар һәм бер-берсенә карамаска тырышалар. Әмма тыныч үзләре... Бәйрәмчә киенгәннәр: Кәрим абзыйның

өстендә ак нейлон күлмәк белән бик килешле утырган кара костюм, ә Рәмзия ханымда ачык изүле, тар билле күк күлмәк, аягында французский туфлилар.

Алар көтәләр, әйе, каушамыйча сабыр гына үзләренә хөкем чыгарылуын көтәләр, чөнки күрше залда гына ике гаиләнең әгъзалары бу ике гашыйкның язмышын хәл итәр өчен үзара җитди киңәш корып утыралар. Ябылып бетмәгән ишектән аларның сөйләшүләре ишетелә. Гаҗәеп нәрсәләр ишетелә аннан... Мәсәлән, Кәрим абзыйның хатыны Бану апа ашыкмыйча, тыныч кына болай сөйли:

— Мәхәббәткә каршы нәрсә әйтеп була? Мәхәббәтне кешенең иң саф, иң изге хисе, диләр. Мин үзем дә моңа ышанам. Шулай булгач, кешене кемгәдер гашыйк булганы өчен генә гаепләргә, хөкем итәргә ярыймы, мөмкинме? Аны яратудан тыярга, тиргәргә, каргарга, җәнҗал куптарырга, кыскасы, төрле кыргый чаралар белән аны мәхәббәттән ваз кичтерергә безнең хакыбыз бармы? Аннары бит, әгәр дә аның мәхәббәте чын икән, ниләр генә эшләсәң дә, нинди генә җәһәннәм газапларына салсаң да, аны барыбер мәхәббәтеннән ваз кичтереп булмаячак. Минем янымда калган тәкъдирдә дә ул барыбер үзенең икенче берәүгә булган мәхәббәте белән яшиячәк. Шулай булгач, нигә аны да, үзеңне дә гомерлек газапка дучар итәргә, нигә тормышның астын-өскә китереп, ямьсезләнеп, дошманлашып бетәргә? Иң яхшысы — бу эшне зур фаҗигагә әйләндермичә, тату гына, тыныч кына аерылып куймаскамы? Менә мин шул хакта уйланам.

Бану апа, аз гына тынып торганнан соң тирән сулап, янә болай диде:

— Тагын шуны да әйтәсем килә, Кәрим абыегыз бик тә әйбәт, бик тә намуслы, инсафлы кеше. Әйе, әйе, инсафлы кеше!.. Менә утыз ел бергә торып, ул мине бер генә тапкыр да авыр, нахак сүз әйтеп рәнҗетмәде, ялгыш кына да, ичмасам, чәнчи бармагы белән дә ул миңа тимәде. Бик бәхетле яшәдем мин аның белән, рәхмәт аңа шуның өчен! Әмма, әмма... нишлисең, язмыштыр инде, ул хәзер бүтәнне ярата... Бүтәнгә күчте аның күңеле... Бу хәбәрне ишеткәч, мин аңардан: «Дөресме, Кәрим?» — дип сорадым, ә ул һич тә икеләнмичә: «Әйе, дөрес, Бану!» — диде. Намуслы кеше шул — алдашу юлына басмады. Менә шуңа күрә дә мин аның теләгенә каршы килә алмыйм, бик авыр булса да, юк, килә алмыйм... Мин аның Рәмзия ханымга булган мәхәббәтен хөрмәт итәм, мин... кыскасы, дусларым, миннән аларга фатиха!.. Бәхетле яшәсеннәр!..

Бер мәлгә киеренке тынлык урнашты. Бану апаның сүзләре көчле тәэсир иткән булырга тиеш, ләкин берәү дә моны ни өчендер сиздерергә теләми. Шулай ук Кәрим абзый белән Рәмзия ханым да әүвәлгечә бер-берсенә карамаска тырышып, тын да алмыйча утыралар, әмма икесе дә Бану апа турында ихтыярсыздан: «Кара, нинди олы җанлы хатын икән!» дип эчләреннән генә уйларга мәҗбүрләр.

Ниһаять, сөйләшүне алып баручы Булат — Кәрим абзыйның улы, математик, фәннәр кандидаты — урыныннан кузгала биреп:

— Мәсьәлә ачык! — дип куйды.— Инде Гыймран абзыйны тыңлап карыйк.

Гыймран абзый, Рәмзия ханымның ире, төп кебек таза, йомры бер кеше... Аны, кайсыдыр заводның әр-җәләр цехында мастер булып эшли, диләр. Җыелыштагы шикелле, ул урыныннан ук торып, сөйләргә тотынды:

— Монда Кәрим абзыйны бик мактап ташладылар әле... Алайга китсә, мин дә хатынны яманлый алмыйм. Минем хатын да шәп, хәтта ки бик шәп!.. Моңарчы алай-болай шаярганы да сизелмәде. Ә хәзер... әнә нишләгән, оятсыз!.. Ну, үзегез беләсез, моның өчен хатынны ишекле-түрле йөгертеп, дуңгыз урынына ярып булмый бит —заманасы ул түгел. Аннары, дөресен генә әйткәндә, хатын минем үземә кирәк, какже, бик кирәк!.. Кәрим агай шәп кеше икән дип, Рәмзия аны ярата икән дип, ансат кына кулдан ычкындырасы килми шул... Түлке менә ничек иттереп аны, оятсызны, тотарга?! Карават аягына чылбыр белән беркетеп куеп булмый бит — китим дисә, караватыңны сөйрәп тә китеп барыр, ышан син аңа! Сыер дуласа, аттан уздыра, диләр... аннары тагын шунысы да бар: мин үзем коллектив сүзенә буйсынып өйрәнгән кеше... Партия безне шулай өйрәтте, ийе, менәтерә!.. Әгәр дә ки сез монда, мәхәббәт зур нәрсә ул, тыярга ярамый, торсыннар, дип әйтәсез икән, миңа ни эшләргә кала? Әйдә, чукынып китсеннәр, дип кул селтәргә генә кала, заманасы шулай булгач ни...

Гыймран абзый йомры, каты башын уң кулы белән бераз сыпырып торды да, башка әйтер сүз таба алмагач, әкрен генә урынына утырды. Булат шунда ук аңардан сорады:

— Димәк, сез дә риза!

— Нәрсәгә? — диде Гыймран абзый, күзләрен түгәрәкләндереп.

— Ну, Рәмзия апаның минем әти белән кушылуына.

— Үзегез шулай кирәк дисез ләбаса!.. Мин ни... коллективка буйсынып өйрәнгән кеше инде...

— Мәсьәлә ачык,— диде Булат, Гыймран абзыйның мескен кыяфәтенә карап та тормыйча.— Ике як та гашыйкларның кушылуына каршы түгел, димәк... Сүзнең кыска булуы яхшы, бигрәк тә бу темага сөйләшкәндә...

— Туктагыз әле,— диде Рәмзия ханымның студентка кызы Эмма, сикереп торып. Ул чия кебек кызарган, ул яна, ул кабалана иде:

— Мин дә әйтмәкче булам... Минем этигә рәхмәт әйтәсем килә. Ул да, наконец, мәхәббәтнең нәрсә икәнен аңлаган... Бу бит, бу бит бик важно. Скандал юк, угроза юк, барысы да бик мирно... Мин даже бу

турыда курсовой эш язарга да уйлап утырдым. Например, «Яңа кешеләрнең яңа сыйфатлары» или «Иске кешеләрнең яңа сыйфатлары...» Ну, эш исемдә түгел, ә...

Булат кыргый рәвештә аның сүзен бүлде:

— Сез риза, шулаймы?

— Конечно, конечно, мин әнием өчен бик шатмын! —диде кыз, ашыгып.

— Алайса нокта куйдык. Мәсьәлә хәл ителде. Әни, давай, бокалларны китер, шампанскийны чыгар!.. Гашыйкларны чакырып, тәбрик итик!

...Нәкъ шушы урында Кәрим абзый, кара тиргә батып, уянып китте. Башта, ни булганын аңламыйча, бертын сыны катып ятты, аннары кинәт кенә исенә килде. Йә Хода, төш икән, төш кенә икән ләбаса! Мең шөкер!.. Йә, шуннан мондый хәл өнеңдә була калса, нишләрсең, әкәмәт?! Бр-р, куркыныч!.. Ярый, Кәрим абзагызның бәхете әле, Бану апагыз аңардан мәхәббәт турындагы хыялларны күптән инде бәреп чыгарып бетерде. Башыңны читкәрәк борсаң да: «Карама кеше хатынына, күзләреңне умырып алырмын!» дип кенә җибәрә. Хәзер менә абзагызның җаны тыныч... Исән генә була күрсен инде Бану апагыз!

1972

## Чикерткә

*(Әбдерәхим кода әкияте)*

Сез белмәгән, ә без күрмәгән борын заманда иске авыл мәдрәсәсендә ата-анасыз бер ятим малай укып яткан. Барыр-торыр җире булмагач, ятим шәкерт үзенең хәлфәсенә самовар куеп, аш пешереп, җәен-кышын шул мәдрәсәдә яши биргән. Хәлфә янында үз тамагы да ач булмаган моның. Аннары атнакичләрен авыл малайлары боларга садака итеп әз-мәз онын, ярмасын, йомыркасын, сөтен дә китергәлиләр икән. Шулай ук хәлфә үзе дә аш мәҗлесләренә барган җиреннән ятим шәкертенә бәлеш төпләре кыстырып кайткалый торган булган. Сирәк эләксә дә ярап куйган бәлеш төбе!.. Әмма шулай да үсеп барган малайга ашау асла җитмәгән, буйга һаман үскән, ә тәненә бер дә ит кунмаган, сыйраклары да бик нечкә булып калган. Шуңадыр инде, шәкертләр аңа «Чикерткә» дигән ләкаб тә биргәннәр. Ятимнең моңа әллә ни ачуы килмәгән — болай да ул аз сүзле, сабыр холыклы малай булган.

Тора-бара моның чын исеме онытылган, бары шул «Чикерткә» дигән ләкабе генә торып калган.

Менә берзаман озын кыш та үтеп китә, җылы язлар да килеп җитә, шәкертләр дә өйләренә таралышып бетәләр. Хәлфә дә, елдагы гадәте буенча, Коръән укып, садака җыеп йөрер өчен җәй башыннан ук авыллар арасына чыгып китә. Мәдрәсәдә ятим шәкерт ялгыз үзе генә торып кала.

Ләкин бу юлы моның хәлфәсе авыллар арасында ни сәбәптер озак йөргән. Ул калдырып киткән азык та бетә башлаган, атнакичләрен садака итеп онын, ярмасын китерүчеләр дә юк бит инде, шулай итеп ялгыз малай бик аптырауга төшкән. Нәрсә ашарга, кайдан алырга? Ачлык — убырлы карчык, җилегеңне суыра ул! Ахырда, уйлана торгач, Чикерткә тәки бер хәйләсен тапкан бит! Мәдрәсә мичендә кыштан калган шактый көл өелеп ята икән, менә шул көлне иләктән үткәреп, бер кечерәк капчыкка тутырган да күрше авыл базарына күтәреп киткән шәкерт. Базарга барып җиткән бу, сатучылар рәтеннән урын табып, капчыгының авызын ачып җиргә куйган — инде килеп сораучыларны гына көтәсе калган. Базар әкренләп зурая, халык артканнан-арта, менә әле берсе, әле икенчесе килеп, капчыгы янында утырган Чикерткәдән сорый икән:

— Улым, ни бу, нәрсә сатасың?

— Абзый кеше, бу күсе үтерә торган дару, шәп дару, алып җибәр әле булмаса! — ди Чикерткә, сәүдәгәрләрчә өлгер генә.

Ә күсе даруы авыл халкына бик кирәк нәрсә икән ул. Агайлар шунда ук моның көлен учлап-учлап ала да башлыйлар. Чикерткәнең капчыгы бик тиз бушап кала, шактый гына акча да төшерә, шул акчага үзенә җитәрлек азык-төлек ала да, базарда озак буталмыйча, тизрәк авылына таба сыптыра.

Ә агайлар, базарчылар өенә җыелышкач, бер-берсеннән сорыйлар икән: бу даруны күсегә каршы ничек кулланырга соң?.. Ләкин берсе дә белми, имеш, берсенең дә малайдан сорарга уена килмәгән. Эх, ачыгавызлар дип үзләрен тиргиләр икән агайлар. Шуннан бер өлкәне яшьрәкләрнең берсенә әйткән:

— Бар, ат менеп базарга чап, малайдан сорашып кайт! — дигән.

Егет ат менеп чапкан, ләкин базарда малай утырган җирдән җилләр генә исә икән. Шулай да, сораша торгач, бер адәм егеткә капчык аскан малайның кайсы якка таба чыгып киткәнен күрсәткән. Егет шул якка таба чаптырып киткән. Ахырда малайны куып җиткән. Җиткән дә туктатып сораган:

— Карале, энекәш, син безгә күсе даруы саттың да бит, ә менә ничек итеп кулланырга кирәклеген әйтмәдең... Яле, тиз генә шуны әйтеп бир, юньсез! — дигән.

Чикерткә бер дә каушамыйча гына егеткә болай дип аңлаткан:

— Бик ансат эшләнә ул, кем, абый кеше! Күсене тоткач, шул даруны аның күзенә сибәргә кирәк. Шуннан күсе тәгәри дә үлә,— дигән.— Аңладыңмы инде?

— Аңладым! — дигән егет, атын борган да тизрәк авылдашлары янына чапкан.

Ә Чикерткә исән-имин генә авылына кайтып җиткән. Азык кайгысы күпмедер вакытка онытылган, ятим шәкерт буш мәдрәсәдә артык ваем чикмичә генә тора биргән.

Менә берзаман югалган хәлфәсе дә кайтып төшә моның... Былтыргы шикелле җәяүләп, әлсерәп түгел, ә шәп ат җиккән таза тарантаста кайтып керә бу... Чикерткә хәлфәсен каршыларга йөгереп чыга. Сәлам алышып, кул бирешеп күрешәләр. Бик куана шәкерт хәлфәсенең, ниһаять, кайтып керүенә. Тиз генә эләктереп самоварын да куя, чәй урынын да әзерли, хәлфә астына йомшак юрган да җәя, таянырга мендәр дә ташлый.

Хәлфә, атын тугарып, юынып-сөртенеп кергәч, күчтәнәчләрен ашъяулык өстенә чәчеп сала да үзе йомшак юрганга аяк бөкләп утыра. Кул күтәреп, бер дога кылалар, шуннан соң ашыкмыйча тәмләп кенә ашый-эчә башлыйлар. Ә ашъяулык өстендә төче күмәч, бавырсак, кызыл эремчек, калай савытта бал белән май — Чикерткәнең тәмам күзләре яна. Мондый сыйны аның әле беренче күрүе икән.

Хәлфәнең дә кәефе бик әйбәт була. Бу юлы сәфәре уңышлы чыккан икән. Шактый күп садака төшергән, шуның өстенә бер байдан карызга* да алып торган, менә шул акчаларга җигүле ат та сатып алган. Боларны сөйләп бетергәч, хәлфә шәкертенә әйтә:

— Безгә бу хәерче авыл мәдрәсәсен ташларга кирәк,—ди,— монда ачка киселеп ятудан мәгънә чыкмас. Әнә моннан көн тарафтагы кыргыз далаларында кәрван үтә торган юллар бар — безгә дә менә шул тарафларга күчәргә кирәк. Ул юллардан мал төягән кәрваннар өзлексез үтеп йөриләр. Кәрван хуҗалары — бай сәүдәгәрләр, садаканы да алар мул тамыза. Әмма безгә хәер эстәүче генә булырга ярамый. Без изге затлардан булырга тиешбез. Менә мин сине, шәкерт, ишан итәм, ә үзем синең мөридең булырмын, ийе, Аллага тапшырып!.. Төшенәсеңме?.. Без кәрван юлыннан ерак түгел бер хозур гына урында чатыр корып җибәрербез. Мин инде ишан хәзрәтләре торырлык, җефәктән тегелгән чатыр да сатып алдым,— дип сүзен бетерә хәлфә.

Чикерткә хәлфәсенең бу сүзләреннән бик аптырап кала, ни диеп әйтергә дә белми. Әллә мине шаярта гына микән дип тә уйлый, ләкин үзе шиген әйтергә дә курка. Хәлфәсе шуны сизгәндәй моңардан сорый:

— Йә, ник дәшмисең? Ни уйлыйсың?

— Хәлфә абзый, сез мине ишан итмәкче буласыз да бит, әмма миннән, ай-һай, ишан чыгар микән соң? — ди Чикерткә, түбән карап кына.

— Чыгар, боерган булса! — ди хәлфә, бер дә исе китмичә.— Син зиһенле шәкерт, Коръән сүрәләрен дә яттан беләсең, буең-сының да килгән — менә дигән ишан ясап чыгарам мин син сасыктан, Алла бирсә!..

Хәлфәсенең сүзе — боерык, күңеле бик үк тартмаса да риза була шәкерт. Шул көннән хәлфә аны ишан кыланышларына өйрәтә дә башлый: ничек итеп йөрергә, ничек итеп утырырга, кешеләр белән ничегрәк сөйләшергә, доганы ничегрәк итеп кылырга — әлхасыйль, барысын да күрсәтеп бирә хәлфә. Чикерткә боларның һәммәсен дә шактый тиз отып ала.

Ә бер атнадан инде болар юлга да җыеналар. Туры атны әйбәтләп җигәләр, юрган-мендәрләрен, кечкенә сандыкларын, кургашын белән ямаган таз-комганнарын тарантаска чыгарып салалар, үзләре әгузе-бисмиллаларын әйтеп, ипләп кенә менеп утыралар да Аллага тапшырып, кыйбла тарафка карап чыгып та китәләр. Бер көн баралар, өч көн, биш көн баралар, җиденче көн дигәндә, ниһаять, кыргыз даласына барып җитәләр. Далада буталып йөри торгач, кәрван үтә торган юлны да эзләп табалар. Инде туктар өчен әйбәт кенә урын сайларга кирәк. Ахырда болар тип-тигез далада көзгедәй ялтырап яткан бер түгәрәк күл буена килеп чыгалар да шуның янында туктарга булалар. Бик ямьле, бик хозур җир икән... Шулай да хәлфә чатырны күлдән читтәрәк, юлдан еаграк калку бер урынга мендереп коруны мәслихәт таба, чөнки калкулык өстеннән карап, ике яктан да килеп яткан кәрваннарны әллә каян ук күреп булачак. Шулай ук чатыр үзе дә еракта ук күренеп торачак. Моның әһәмиятен Чикерткә аңлап бетермәсә дә, хәлфә үзе бик яхшы аңлаган.

Шулай итеп, чатырны калкулык өстенә коралар, чатыр башына ишанның яшел әләме дә кадап куела. Бу эш беткәч, чатыр эченә киез-паласларын кертеп җәяләр, йомшак юрганны буйга бөкләп, сузып салалар, шуның өстенә берничә колакчын мендәр дә ташлыйлар. Аннары нәкъ урта бер җиргә тәбәнәк кенә өстәл куеп, аның өстенә зур-зур, калын-калын китапларны өяләр. (Берсен урта бер җиреннән ачып та куялар.) Бу эшләр дә беткәч, хәлфә Чикерткәне киендерә башлый. Иң элек ул аңа тезенә хәтле үк төшеп торган ак күлмәк белән иләмсез киң ак ыштан кидерә, шулар өстеннән яшел-сары буйлы ефәк чапан кидерә, ә башына егерме аршин ак бәздән, Бохара түбәтәе тирәли, шавадан да зуррак чалма урап куя. Шуннан соң әйтә Чикерткәгә:

— Тәкъсир, синең эшең менә шушы өстәл янында башыңны бөгеп, изге китап моталәгә кылып утыру... арсаң, әнә мендәргә таянырсың... Ә калганы минем эшем,—ди.

Тәмам урнашып беткәч, болар башта тәмле күл суыннан чәй кайнатып эчәләр, аннары хәлфә, атка атланып, тирә-якны карап кайтмакчы булып, чыгып китә. Чикерткә тәбәнәк өстәл янында аяк бөкләп, изге китап «моталага» кылып кала. Хәлфә дала буйлап шактый озак йөри, ләкин бер җирдә дә бернинди адәм заты яки җан иясе очратмый. Кәрван юлы да буш, тын, бер атлы, бер җәяүленең килгәне яки китеп барганы күренми. Әллә ташландык юл микән бу, дип шиккә дә төшә хәлфә, әмма шулай да өметен өзми.

Дөрестән дә, бер калку урыннан тирә-якка әйләнгәләп карана торгач, бик ерακτα, офык чигендә үк нәрсәдер селкенгән шикелле күренә моңа... Көтә хәлфә сабыр гына, көтә, инде кояш баерга да күп калмаган була һәм, көтә торгач, теге селкенгән нәрсә әкрен генә килеп яткан озын бер кәрван булып чыга. Моны күрү белән хәлфә атын борып, җан-фәрман чатырына таба чаптыра. Кайтып керсә, ни күрсен — Чикерткә чалма-чапанын салып ташлап, мендәрләргә батып, сабыйдай изрәп йоклап ята, имеш!

— Әй, син, хәшәп, тор тизрәк! — дип кычкыра хәлфә.—Тапкансың вакыт, әнә кәрван килә ятыр! Чалма-чапаныңны ки дә өстәлең янына утыр. Кәрван кешеләре безгә сугылмыйча калмас, әзер булып тор!

Үзе шунда ук кире чыгып та китә. Кәрван, дөяләр адымы белән генә килсә дә, шактый ук инде якынлашкан була. Калкулык өстендәге чатырны да күрәләр, ахрысы, менә ике җайдак, кәрваннан аерылып, болай таба чаптырып килә дә башлый. Озак та үтми, килеп тә җитәләр. Атларыннан төшәләр, хәлфәгә сәлам бирәләр. Хәлфә дә, түбәнчелек белән башын иеп, сәламнәрен ала, аннары чүгәләп бер дога кылалар. Шуннан килүчеләр җайлап кына: әйтсәгезче, кардәш, бу кем чатыры була, кем тора анда? дип сорыйлар. Хәлфә үз нәүбәтендә зур бер серне ачкандай итеп, бу — бөтен әтрафта дан тоткан фәлән ишанның чатыры була дип җавап бирә. Нишли соң ул монда, дип сорыйлар тегеләр. Ишан хәзрәтләре, ди хәлфә җавабында, Аллаһы Тәгаләгә якын торыр өчен адәмнәр арасыннан китеп, ошбу тын сәхрәдә ялгызы көн вә төн изге гыйбадәттә утыра!.. Алай икән, диләр килүчеләр тыйнак кына, ә син үзең кем буласың? Мин изге ишанның мөбарәк кулын тоткан мөриде булам, ди хәлфә, һәм бер мәлгә аптырабрак— уйланыбрак калган җайдаклардан үзе сораша башлый: сез кемнәр буласыз, бу кәрван кайдан, кайсы якларга китеп бара? Без кәрван озатучылар булабыз, диләр тегеләр, фәлән җирләрдән фәлән илгә мал төяп барабыз... Юлыгыз уң булсын, Ходай бәла-казалардан сакласын, ди хәлфә, кара сакалын сыпырып. Җайдаклар кулларын күкрәкләренә куеп рәхмәтләрен белдерәләр, аннары монда изге ишан торганын хуҗаларына кайтып әйтер өчен тиз генә китеп тә баралар.

Хәлфә шунда ук борылып чатырга керә.

— Ә, утырасыңмы? — ди ул Чикерткәгә.— Шулай кирәк, тәкъсир. Тик чалмаңны батырыбрак ки, авып төшмәсен... Тиздән кәрван хуҗалары килергә тиеш. Алар синең догаңны алыр өчен яныңа керерләр. Китаптан башыңны күтәрмә, сүзеңне кыска тот, ә догаңны озак итеп укы, аңладыңмы?

Чикерткә башын гына кага. Ул инде тәбәнәк өстәл янында утыра-утыра алҗып беткән була, һавага чыгасы, далада рәхәтләнеп йөрисе килә, әмма булмый — түзәргә кирәк, түзмичә ярамый, хәлфәнең талканы коры, ишан дип тормас, бөкләп ишкән тастымалы әнә мендәр астында гына...

Хәлфә чатырдан чыкканда кәрван туктаган яктан ике кеше җәяүләп кенә бу якка таба килә иде инде. Өс-башларына караганда, болар, һичшиксез, кәрван хуҗалары булырга тиеш. Хәлфә бер таш өстенә утырып, аларны сабыр гына көтеп ала. Менә килеп җитәләр, сәлам бирәләр, утырып дога кылалар, аннары әйтәләр:

— Әфәндем, бу ефәк чатырда ишан хәзрәтләренең изге гыйбадәттә утыруын белеп, без бик хәйран вә шат булдык. Инде безгә дә олы зат үзенең хәер-фатихасын бирмәсме икән? Хозурына кереп, тезләнәсебез килгән иде.

— Мәрхаба, изге ният белән килгәнсез икән,— ди хәлфә торып.— Әмма башта үзем кереп, ишан хәзрәтнең рөхсәтен алышым кирәк. Аз гына көтегез.

Кергәч, Чикерткә шыпырт кына:

— Килделәр! — ди.— Каушама, һаман мөгрәнеп кенә укыган бул, ара-тирә кычкырып та куйгала, ишетеп торсыннар! Мин аларны азрак тота төшәрмен.

Чыккач, тегеләргә әйтә:

— Ишан хәзрәтләре изге китап моталәгә кылып утыра, бераз сабыр итәргә кирәк булыр, әфәнделәр! — ди.

Кәрван хуҗалары сабыр гына көтәләр, мөридтән ишанның исән-саулыгын, хәл-әхвәлен сорашалар. Ә бераздан хәлфә чатыр эченә башын тыгып карый да: «Инде, кардәшләр, керсәгез дә ярый, тик озак тормасагыз иде, ишан хәзрәт көне буе гыйбадәттә утырып, бик арды булса кирәк»,— ди... Тегеләр чүәкләрен салып чатыр эченә керү белән лып итеп тезләнәләр, тез өстендә генә мүкәйләп ишан хәзрәтнең алдына баралар һәм йөзләрен җиргә оралар. Шул рәвешчә, бик түбәнчелек белән изге ишаннан фатиха бирүен сорыйлар. Чикерткә, чалмалы башын игән килеш кенә, тәсбих аскан кулын күтәреп, әкрен генә селкенә-селкенә бик озак итеп дога кыла. Маңгаеннан алып ияк очына кадәр битен сыйпаганнан соң, мосафирлардан сәфәрләре турында сораша, сәүдә итеп йөрүнең саваплы эш булуы турында Коръәннән берничә аять тә китерә, пәйгамбәремез Мөхәммәт саллаллаһегаләйһивәссәламнең дә сәүдәгәр булуын исләренә төшерә. Мосафирлар алларына карап, оеп кына утыралар, ишан хәзрәт сүзен бетергәч, кесәләреннән чыгарып аның алдына садакаларын салалар һәм мөбарәк кулына иреннәрен тидереп алалар. Ишан хәзрәт сәүдәләренә уңыш, малларына бәрәкәт, үзләренә иминлек теләп тагын бер озын гына итеп дога кыла. Шуннан соң кәрван хуҗалары ишанга кат-кат баш иеп, тезләре өстендә генә чигенеп, чатырдан чыгып китәләр.

Мосафирларны озаткач та хәлфә ашыгып Чикерткә янына керә.

— Йә ничек? — ди ул, түземсезләнеп. Чикерткә учын ачып күрсәтә: ике зур алтын тәңкә!.. Хәлфә айгыр кешнәгәндәй көлеп җибәрә:

— И-ха-ха!.. Менә күрдеңме, сасык!.. Кәрван юлы —хәерче татар авылы түгел шул! Мәшә алла иншалла, эшләр ходка китә болай булгач... Ә син, шәкерт, ишанлыкны шәп очлап чыктың, афәрин!.. Шулай кирәк, Коръәннән дә, хәдистән дә, телеңә дә килгәнне сип тә утыр!.. Ул хәсисләр барысы да туң күчән, ни әйтсәң дә бата үзләренә... Тик син вәкарь сакла, изгеләрчә тот үзеңне, хикмәт менә шунда гына!..

Тышта кеше авазлары ишетелгәндәй була, хәлфә ашыгып чатырдан чыга. Чыкса, ни күрсен, биш-алты кеше, чатырга якынаерга курыккандай, бер читтәрәк таптанып торалар. Хәлфәне күрү белән аңа иелә-бөгелә сәлам бирәләр һәм без дә ишан хәзрәтнең догасын алырга килгән идек диләр. Хәлфә ялт итеп чатыр эченә керә дә Чикерткәгә: «Тагын бер төркем килгәннәр, төзек кенә утыр, хәзер кертә башлыйм. Ә тәңкәләреңне яшер, соңыннан санап алырмын», дип әйтә. Шуннан, кире чыгып, кәрван кешеләрен берәмләп кенә чатыр эченә уздыра башлый. Тегеләрнең һәркайсы керә дә лып итеп тезләнә, мүкәйләп кенә барып, ишанның мөбарәк кулына авызын тидереп ала, акчасын чыгарып сала һәм ишанга ияреп дога кыла да артын-артын гына ишеккә таба чигенә.

Шулай итеп, ул кичне кәрван озатучыларның барысы да килеп, ишанның догасын алып, кулын үбеп китәләр. Чикерткәнең киндердән махсус теккән чапан астындагы тирән кесәсенә алтын тәңкәләр шактый ук җыелып кала.

Бу «изге эшләрдән» котылгач та хәлфә, билгеле, ишан кесәсен бушатып, тәңкәләрне санап ала да үз сандыгына бикләп куя. Аннары таганда пешергән умачын кертә, икәүләп шуны тәмләп кенә ашыйлар, артыннан баллап чәй дә эчәләр. Шуннан соң «ишан хәзрәтләре» чалма-чапанын салып ташлый да, мендәрләре өстенә сузылып, утын ярып аргандай, гырылдап йоклап та китә.

Ләкин хәлфә тиз генә йокларга ятмый әле. Бер бәйләнчек уй аның башына кереп утыра. Кәрванчыларга ишанның берәр могҗизасын да күрсәтәсе иде бит — менә шул хакта һаман баш вата ул... Могҗиза кирәк, могҗиза күрсәтсә, ишанның даны әллә кайларга таралачак. Ләкин ничек итеп, нинди могҗиза табарга соң?

Ниһаять, бик еракка китеп кояш та бата, дала өстенә бик тиз караңгылык иңә, ә күктә, төнгелеккә бер җиргәрәк җыелган кыргыз малларыдай, бихисап йолдызлар калка. Ә ай юк, айның соңгы көннәре, тиз генә чыкмаячак, шуңа күрә төне дә дөм-караңгы.

Хәлфә, чатырдан чыгып, кәрван туктаган якка колак салып тора. Анда да тынлык, шылт иткән тавыш та юк —юлчылар ишанның хәер-фатихасын алганнан соң бик тынычлап йоклыйлар, күрәсең. Шулай да хәлфә ашыкмый, ярты төн җиткәнне көтә төшә, чөнки белә ул — бу вакытта кешеләрнең йокылары каты була.

Менә бервакыт далада шундый тирән тынлык урнаша ки, әйтерсең дөнья яратылганнан бирле килә бу гаҗәеп, серле тынлык!.. Инде Аллага тапшырып кузгалырга да ярый торгандыр... Хәлфә кәрван яткан күл буена сак кына төшеп китә. Аның күзләре, мәче күзе кебек, дөм-караңгыда да тирә-юньне аера ала. Бер дә адашмыйча кәрванчылар янына туры гына барып та җитә... Кәрван йоклый, тик җиргә чүккән дөяләрнең күшәве, атларның солы кетердәтүе генә ишетелеп куйгалый. Хәлфә башта туктап тирә-ягын бераз күзәтә, аннары мыштым гына шул дөяләр, атлар арасына керә. Әзрәк караштырып йөргәннән соң, ялгыз чатыр артына бәйләп куйган ике бик шәп, бик сылу атларны күреп ала, бик сакланып кына якынлаша, икесенә дә ипи кисәге каптыра, шуннан соң тиз генә чишеп ала да әкрен-әкрен генә кәрван яткан җирдән чыгып та китә. Төн, тынлык, сызылып кына йолдыз атылып китә, әмма кәрванчылардан селкенгән кеше дә булмый.

Хәлфә бары таң алдыннан гына үзләренең чатырына кайтып керә. Ул шунда ук «ишан хәзрәтләрен» төрткәләп уята.

— Әй, син, хәшәп, тор! Тор, диләр сиңа!.. Арт саныңны онытып йоклыйсың да йоклыйсың... Килешми ул ишанга! Бар, әнә тышка чыгып кер дә, чалма-чапаныңны киеп, өстәлең янына утыр. Бик мөһим сүзем бар сиңа.

Чикерткә торып, хәлфәсе кушканча, тиз генә чатыр артына чыгып керә дә, чапанына чорналып, чалмасын башына батырып, тәбәнәк өстәл янына аякларын бөкләп утыра.

— Инде яхшылап тыңла! — ди хәлфә.— Тиздән кәрван хуҗалары сиңа китап ачтырырга килерләр. Бүген төнлә аларның ике шәп атларын урлап киткәннәр. Менә син аларга шул атларны «табып» бирерсең.

— Ничек итеп?

— Китап ачып дим ич, миңгерәү!.. Башта тыңла! —Һәм хәлфә атларның ни төстә булуын, кай тарафка китүләрен, моннан ничә чакрымда, нинди урында торуларын әйбәтләп төшендерә дә аннары әйтә:

— Менә шуларны онытмыйча, китапка карап сөйләрсең... Ягъни мәсәлән, Хак Тәгаләнең әшкәртүе буенча изге китап сиңа боларның барысын да ачып бирә, аңладыңмы?..

— Аңладым аңлавын да, тик ул атлар сез әйткән җирдә булмаса? Сез дә бит, хәлфә абзый, күрәзә түгел.

— Мин өйрәткәнчә эшлә син, хәшәп! Төпченмә! Ату кара аны, ишан дип тормам! Алланың үзенә якын торучы, надан халык белмәгән серләрне белүче, могҗизалар кәшеф итүче — менә кем син, сасык!.. Башкасы сиңа кирәкми... Әнә алдыңдагы кара тышлы китапны моталәгә кылып утырган бул, ә кәрван хуҗалары килгәч, яшел тышлысын ачарсың.

Чикерткәне шулай боргычлап өйрәткәннән соң хәлфә чатырдан чыгып, кәрван ягын күзәтергә тотына. Кәрван халкы инде торган була, анда нindидер хәрәкәт башлана, шаулашкан тавышлар да ишетелә. Озак та үтми, кәрваннан аерылып, өч кешенең чатырга таба килгәне дә күренә.

Хәлфә, чатырның ишек япмасын аз гына ача төшеп, Чикерткәгә хәбәр итә:

— Киләләр!.. Казык шикелле утырма, бөгелеп утыр!.. Күзең китапта булсын!

Ниһаять, тегеләр килеп җитәләр, кычкырып сәлам бирәләр — хәлфә дә тәгазим белән сәламнәрен ала. Шуннан арадан бер таза мәһабәте, шәп киенгәне, дәрәҗәсен төшермичә, әдәп белән генә әйтә:

— Әфәндем, без ишан хәзрәтләре хозурына килгән идек, аңа гозеребез бар, кабул итүен үтенсәгез иде.

— Белмим шул,— ди хәлфә, уйланган булып.— Ишан хәзрәтнең бүген кәефе юграк иде, шулай да үтенечегезне кереп әйтим. Сез, әфәнделәр, аз гына сабыр итегез!

— Мәйле! Без көтәрбез.

Хәлфә кереп, Чикерткәнең өс-башын, алдын-артын дигәндәй күздән кичергәннән соң, тора төшеп, кире чыга да:

— Мөбарәк зат сезне кабул итәргә булды, рәхим итәсез! — ди.

Кәрван хуҗалары, чатыр эченә узып, шунда ук тезләнәләр һәм башларын келәмгә тидереп алалар. Ишан хәзрәт, уйлары белән бу гөнаһлы җирне ташлап, каядыр гарешкә ашкандай тәмам онытылып оеп утыра, керүчеләрне гүя сизми дә, тик бераздан гына иләмсез зур чалмасы астыннан боларга бер карап ала. Аннары һич сүз әйтмәстән, озын тәсбих элгән кулын күтәреп, озак кына дога кыла, бары шуннан соң гына телгә килә:

— Алла бәндәләре, йөзегездән күрәм, сезне нindидер кайгы минем хозурыма китергән булырга тиеш. Сөйләгез! — ди.

— Хак сүз, тәкъсир! — ди кәрван хуҗасы, бөгелеп.—Бүген төнлә ике иң шәп атыбыз юкка чыкты. Явыз адәмнәр угрылап киткәндер дигән шигебез бар, сездән, тәкъсир, шул хакта китап ачуыгызны түбәнчелек белән сорамакчы идек.

— Алай, бик зур казалы булгансыз икән, Ходай ахырын хәерле итсен! Үтенечегезне кире кага алмыйм, кардәшләр, ачып карыйк, Хак Тәгалә эшкәртсә, изге китап алдамас,— ди дә ишан, өелеп торган китаплар арасыннан бер яшел тышлысын тартып ала. Аннары, әгузе-бисмилласын әйтеп, урта бер җиреннән ача да авыз эченнән генә мөгрәнеп укырга тотына. Әзрәк укыгач, тегеләрдән сорый:

— Атыгызның берсе тимер күк, икенчесе кызыл туры идеме?

— Шулай, тәкъсир, бик дөрес, тимер күк белән кызыл туры,— диләр кәрванчылар өметләнеп.

Ишан хәзрәт тагын китапка бөгелә, озак кына селкенә-селкенә укый, тынып күзләрен йомып тора, аннары тагын укый, ахырдан әйтә боларга:

— Изге китап миңа шуны ачты: атларыгызны бер угры таң алдыннан урлап киткән. Әмма ләкин көн яктыра башлагач, далада тотылудан куркып, атларны бер сай чокырдагы ялгыз агачка бәйләп калдырган. Угрының нияте караңгы төшкәч, яңадан килеп алу булса кирәк... Әгәр дә хәзер генә эзләп барсагыз, атларыгызны мотлака шунда табарсыз.

— Кай тарафтарак соң ул сай чокыр, тәкъсир?

— Мәгъриб тарафында... Чыккан кояшка аркагыз белән торып туры гына барсагыз, чокырның нәкъ өстенә барып чыгарсыз.

— Еракмы соң ул чокыр, шуны да әйтсәгезче, тәкъсир!

Чикерткә, ишетмәгәнгә салышып, бераз уйга кала: нәрсә дип әйтте әле хәлфә абзый? Әллә сигез, әллә унсигез чакрым диде инде шунда, мөртәт?.. Хәер, кем үлчәгән аны? Җитәр, китсеннәр тизрәк!

Тамак кыргалаган була да әйтә тегеләргә:

— Хәерле сәфәр сезгә, мосафирлар! Хак Тәгалә башка бәла-казадан сакласын, амин!

— Рәхмәт, тәкъсир, бик зур рәхмәт!.. Шулай була гына күрсен!.. Тик без әлеге ни... чокыр турында...

— Кызу чапсагыз, тиз барып җитәрсез! — ди ишан шактый дорфа итеп һәм ашыгып тәсбихенең «хөрмәләрен» тарта башлый.

Тегеләр, бердән авып, маңгайларын келәмгә тидереп алалар, сузылышып ишан хәзрәтнең алдына алтын тәңкәләрен салалар, шуннан соң Чикерткәгә ияреп дога кылалар да бик мәмнүн кыяфәттә чатырдан чыгып, ашыга-ашыга, кәрваннарына китеп баралар. Ә бераздан инде өч-дүрт җайдакның «мәгъриб тарафына» чаптырып киткәнен хәлфә дә, Чикерткә дә күреп калалар.

Атларны табып кайтканнан соң, кәрван шул ук көнне күл буеннан кузгалып, үз юлы белән китеп тә бара. Бер-бер артлы тезелешкән дөяләрнең ике яклап салындырган йөкләре белән чайкала-чайкала салмак кына атлап барулары тигез далада әле шактый озак күренеп тора.

...Атларны табып биргән «могҗизадан» соң, калкулык өстендәге чатыр эчендә утырган яшь «ишан хәзрәтнең» даны бик тиз тирә-якка тарала: менә кайда икән ул изге зат!.. Менә кемдә икән ул хикмәт!.. Вай-вай-вай!.. Аның өчен яшерен бер нәрсә дә юк икән ләбаса!.. Аллаһе Тәгалә үзе аңа барысын да эшкәртеп кенә тора икән шул!

Хәзер инде күл буеннан узучы кәрваннар чатыр турысына җиткәч туктамыйча калмыйлар. Мал хуҗалары, ялчылар, кәрван озатучылар һәммәсе тезелешеп калкулыкка менәләр, берәмләп кенә чатыр

эченә кереп, лып итеп тезләнәләр, мүкәйләп барып, Чикерткәнең «мөбарәк» кулын үбәләр, учларындагы алтын яки көмеш тәңкәләрен тәбәнәк өстәлгә салалар. Ишанның, бөгелеп утыра торгач, авыр чалмадан нечкә муены арып бетә, дога кыла-кыла авызы кибә, куллары тала. Вакыт-вакыт аның хәтта сикереп торасы, тәбәнәк өстәлне тибеп очырасы, чалмасын сүтеп ыргытасы, ә бу «аңгыра сарыкларны» выжлатып куып чыгарасы да килеп китә. Әмма... хәлфә уяу, хәлфәнең күмердәй кара мут күзләре көйдереп алырга гына тора.

Ә көннәрдән беркөнне күл буена баштанаяк коралланган биш-алты җайдак килеп чыга. Калкулык өстендәге чатырны күрү белән атларын тизрәк шунда таба боралар. Бу вакытта хәлфә тышта була. Чаптырып килгән кораллы кешеләрне күреп, ул «талаучылар түгелме икән?» дип шактый шүрләп тә ала. Ләкин килеп җиткән җайдаклардан берсенең бик зиннәтле киемнәрдән булуын күргәч кенә азрак тынычлана.

Җайдакларның әнә шул шәп киенгәне ат өстеннән төшмичә генә сәлам бирә, хәлфә исә кул кушырып аның сәламен ала.

— Әйтегезче, изге ишанның чатыры шушы буламы? —дип сорый сәлам бирүче.

— Ийе, ишан хәзрәтләренең изге гыйбадәт урыны шушы була,— ди хәлфә.— Кем дип белик сезне, хөрмәтле юлчылар, кайсы илләрдән киләсез?

— Без фәлән патшалыктан илчеләр булып килдек,—ди юлчы.— Безгә ишан хәзрәтләренең үзен күрү кирәк, хозурына керергә рөхсәт итегез.

— Гозерегез ни соң? — дип сорый хәлфә сак кына.

— Без олуг падишамызның сәламен ишан хәзрәтләренә тапшырырга һәм мөбарәк затны үземез белән алып китәргә тиешмез.

— Алай икән,— ди хәлфә уйланып.— Ни өчен мөбарәк затны урыныннан кузгатырга телисез, әгәр белергә мөмкин булса?

— Падишамызның әмере шулай... Хафа булмагыз, ишан хәзрәтләренең иминлеген саклаячакмыз, ә барып җиткән сарайда аңа тиешле кадер-хөрмәт күрсәтеләчәк.

— Яхшы, алайса мин кереп ишан хәзрәтләренә бу мөһим хәбәрне җиткерим. Соңра сезне чакырырмын. Моңа кәефегез кырылмасын, чөнки ишан хәзрәтләре һәрдаим изге гыйбадәттә утыра һәм алдан хәбәр итмичә һичбер кемсәне кабул итми.

Шулай ди дә хәлфә, илчегә түбәнчелек белән баш иеп, чатыр эченә кереп китә. Кергәч, Чикерткә янына тезләнеп, аның колагына шыпырт кына әйтә:

— Бәхетең бар икән, шәкерт!.. Ерак патшалыктан сине алып китәр өчен илчеләр килде.

— Нинди, кайсы патшалыктан? — ди Чикерткә, сискәнеп.— Юк, мин беркая да бармыйм, минем үзебезнең Тәпәрешкә кайтасым килә.

Ул инде кайнар яшьләрен агызып елый да башлый. Хәлфәнең моңа бик тә ачуы килә:

— Бу ниткән эш тагын?! Син хәсискә патша кадәр патшадан махсус илчеләр чакыра килгәндә, бармыйм дип, авызыңны бияләйдәй җәеп шыңшып-елап торасың. Юк, барырсың!.. Хәерче татар авылына кайтырга кайчан да өлгерербез... Бел аны, бу чакыру тикмәгә генә түгел, димәк, син сасыкның даны чит мәмләкәткә дә барып җиткән дигән сүз. Ходай кушып, патшаның да ышанычын казана алсак, беләсеңме, муеныбыздан дәүләткә батачакбыз. Йә, җитәр! Яшьләреңне сөрт, борыныңны тартма!.. Хәзер илчене кертәм. Төзек кенә утыр. Ишанча... Күп сөйләмә, җавабыңны уйлап кына бир... Падишаһе әгъзам хәзрәтләренең чакыруын кире кага алмыйм диген... Менә шул... Кара аны!..

Хәлфә Чикерткәнең чалмасын төзәтеп, тәсбихен кулына тоттыра да ашыгып чыгып китә.

Ул да булмый, чатырга зиннәтле киемнәре өстеннән кәкре кылыч таккан илче кыю гына килеп керә. Сәлам бирә, туп-туры ишан алдына барып тезләнә, кул күтәреп бер дога кылалар. Шуннан соң илче, вәкарьлеген саклаган хәлдә, үзенең кайсы илдән, кем булуын әйтеп, патша хәзрәтләренең сәламен тапшырып, нинди максат белән килүен аңлатып бирә. Бик йончыган кыяфәттә бөрешеп кенә утырган «ишан» әкрен-сүлпән генә:

— Падишагыз хәзрәтләренә безгә күрсәткән игътибары өчен рәхмәт инде,— ди,— Аллаһе Тәгалә үзенә һәм дәүләтенә иминлек китерсен, амин!.. Әмма аның безләргә гозере нидән гыйбарәт соң?

— Падишамыз хәзрәтләре хозурына баргач, ул үзе сезгә гозерен бәян кылыр,— ди илче,— безләргә исә сезне алып килү вазифасы гына йөкләтелде.

Ишан хәзрәтләре башын иеп, тәсбихен тартып, озак кына уйланып утыра, тик шуннан соң гына болай дип җавап бирә:

— Мин фани дөнья ыгы-зыгысыннан, ахирәтен оныткан бәндәләрдән читкә китеп, бары изге гыйбадәттә утыручы, Алланың бер зәгыйфь колымын, бернинди сәбәп белән дә мин бу... ни... мәҗбүрән эшемне бүлмәс идем, әмма ерак җирдән махсус кешеләр җибәреп, безгә тәгазим күрсәткән, безне үзенең солтанатлы хозурына чакырган падишаһе әгъзам хәзрәтләренең үтенечен кире кагарга җөрьәт итә алмыйм. Әлхасыйль, кадерле илче, мин Аллага тапшырып сезнең белән озын сәфәргә чыгарга ризалыгымны белдерәм. Инде, бер фатиха кылып, мөридемә тиешле боерыкларны бирергә рөхсәт итегез!..

Сүзен шулай тәмам иткәннән соң, ишан хәзрәтләре кулын күтәреп, күзләрен йомган килеш, озын итеп бер дога кыла. Илче дә, ишан хәзрәтне күндерүеннән бик канәгать булып, аңа ияреп дога кыла да, алдына бер янчык алтын тәңкәләр куеп, чатырдан чыгып китә.

Шунда ук ялт итеп хәлфә керә:

— Йә, ничек булды?

— Булды инде, сез әйткәнчә булды, хәлфә абзый! —ди Чикерткә боек кына.

— Менә бик әйбәт, муладис!.. Җыендык алайса! Ай-һай, мин әйтәм, эшләр кая китте — патша хозурына барабыз гой!

Тиз генә чатырны сүтәләр, әләмне таягына урыйлар, калын китапларны өеп бәйлиләр, шуннан соң барлык әйберләрен, мендәр-юрганнарын тарантаска чыгарып төйиләр дә, атларын җигеп, әлеге җайдакларга ияреп, озын юлга чыгып та китәләр. Чикерткә өчен бу озын юлның газабы шунда иде ки, ул тарантас өстендә барганда да үзенең изге ишан икәнен бер генә минутка да онытмаска тиеш иде. Шуңа күрә еш кына атларны туктатып, су булган җирдә тәһарәт алып, су булмаган җирдә тәямим генә сугып, биш вакыт намазын калдырмыйча укып барырга мәҗбүр була. Шуның аркасында юл да озаккарак сузыла.

Чиксез даланы, даладан соң галәмәт эссе ком чүлен үтеп, болар унсигезенче көн дигәндә, ниһаять, ерак патшалыкның пайтәхетенә барып җитәләр. Биек капусыннан керәләр, кәкре-бөкре урамнарыннан узып, чылтырап арыклар аккан бакча эчендәге әллә ни зур да түгел, әмма бик чибәр салынган бер өйнең ишеге төбенә килеп туктыйлар. Бу патша боерыгы белән ишан хәзрәтләре өчен махсус әзерләп куелган өй була.

Чикерткәне тарантастан култыклап кына төшерәләр һәм кыйммәтле келәмнәр, алтын кәндилләр белән зиннәтләнгән шул өй эченә алып керәләр. Монда аны атлас-ефәкләрдән генә киенгән яшь кенә егет-хадимнәр каршы алалар.

Алып кайткан илче ишан хәзрәткә әйтә:

— Тәкъсир, сез инде бүген шушында тәгам җыеп, авыр, озын юлдан соң әйбәт кенә истирахәт итегез... Падишаһ хәзрәтләре үз вакыты белән сезне хозурына чакыртып алыр,— ди.

Ул чыгып киткәч тә чибәр егетләр идәндәге келәмгә табын җәеп, төрле кош итләреннән кыздырылган кәбаблар, алтын-көмеш тәлинкәләрдә әлвән вә әлвән җимешләр, озын муенлы көмеш савытларда затлы шәраблар һәм зур табак белән бик әгъла пешерелгән пылау кертеп куялар. Чикерткә белән хәлфә бу сый-нигъмәтләргә исләре китсә дә, тыштан артык сиздермичә, ефәк мендәрләр өстенә утырып, җиңнәрен сызганып, иң элек әгъла пылауны куллары белән ашыкмыйча гына ура башлыйлар. Алар бүре шикелле ачыкканнар иде. Шулай да Чикерткә тыелып кына ашарга мәҗбүр, чөнки ул изге зат, тамак колы булу аңа ярамый — тәнендә җан сакларлык кына ашарга тиеш ул. Ә хәлфәгә ярый, хәлфә ул гөнаһлы бәндә, шуңа күрә олы табак пылауны берүзе диярлек ялтыратып та куя.

Пылаудан соң Чикерткә ширбәт, хәлфә шәраб эчкәләп, җимешләрнең төрлесеннән капкалап бераз хушлангач, теге хадимнәр табынны җыеп ала да боларның икесен генә калдырып чыгып китәләр.

Икәү генә калгач, мендәрләренә таянып, корсакларын угалап бераз ятканнан соң хәлфә сүз башлый:

— Хуш, шәкерт, менә төшеңә дә кермәгән оҗмах нигъмәтләреннән авыз иттең... Менә ефәк мендәрләр өстендә шәһвәткә бирелеп ятасың... Бу бит синең башыңдагы егерме аршин бөздән ураган чалмаң өчен генә булмаска тиеш... Патша хәзрәтләре, мөгаен, сиңа берәр бик четерекле мәсьәлә йөкләр һәм шуны чишүне таләп итәр. Йә, шул чакта син ни эшләрсең, ни дип җавап бирерсең, хәлбуки янында акыл бирергә мин дә булмасам?..

— Белмим инде, хәлфә абзый!..

— «Белмим» — сүз түгел!.. Патшаның гозерен җавапсыз калдырырга һич тә ярамый, бел шуны!

— Ярамаса да нишлим соң? Җавап таба алмасам, патша хәзрәтләре, мин ишан түгел, диярмен.

— Әх, син, туң күчән, иштең ишәк чумарын! — дип кызып китә хәлфә.— Алай дисәң бит, сине шунда ук сарайдан чыгарып, беренче очраган тут агачына асып куячаклар... Юк, син ашыкмале сыйракларыңны сузарга, аның өчен генә килмәдек әле без чүлләр кичеп, мин барын да онытма әле син, хәшәп!.. Ике колагың белән дә яхшылап тыңла: патша өчен дә син изге ишан булып каласың! Синең эшең Коръән сүзләрен тезү, кул күтәреп дога кылу, фатихаңны бирү — бары шул гына... Инде патша хәзрәтләре сиңа берәр төрле чи төенне чишәргә кушса, түбәнчелек белән ипләп кенә әйт: олуг падишам, диген, сезнең әмерегезне үтәр өчен без кайтып, изге китапны ачып карарга тиешбез, диген. Аңладыңмы? Бөтен нәрсәне изге китапка сылта... Ә монда кайткач, без инде икәүләп, менә шулай кырын ятып кына мәслихәтләшербез һәм, иншалла, патша биргән төенне дә чишәрбез. Моңарчы эшли белгән баш бу юлы да берәр әмәлен табар әле, боерган булса!

Шул арада ишек шакып, рөхсәт сорап кына әлеге илче дә килеп керә. Баш иеп сәлам биргәннән соң, ул ишан хәзрәтләрен патша сараена алып китәр өчен килгәнлеген белдерә. Чикерткәнең йөрәге жу-у итеп китә. Әмма хәлфә тыныч. Мөридләрчә өлгерлек белән ул Чикерткәне утырган җиреннән ипләп кенә торгыза, өстенә озын чапанын кидерә, кулына тәсбихен тоттыра да култыклап кына урамга алып чыга. Чыгышлый колагына пышылдап кына: «Матри, нык бул, җебеп калма!» — дип әйтергә дә өлгерә.

Урамга чыккач, ишан хәзрәтләрен көмеш иярле, көмеш йөгәнле, муенына алтын шөлдерек таккан кечкенә ишәк өстенә күтәреп атландыралар. Шул рәвешчә, ике яклап атлы сакчылар озата барган хәлдә, аны сарайга алып та китәләр. Бу өйдә хәлфә үзе генә торып кала.

Барып җиткәч, ишанны, ишәк өстеннән төшереп, ике ягыннан култыклап, сарайның чит ил кунакларын гына кабул итә торган гаять тә бай, зиннәтле бер залына алып керәләр. Яшел бәрхет белән тышланган атлас мендәрле йомшак көрсигә китереп утырталар. Шунда ук залның ике ягындагы ишектән патшаның вәзирләре һәм иң олы түрәләре кереп, үзләренә тәгаенләнгән урыннарга дәрәҗәләре буенча урнашалар. Озак та үтми, каяндыр быргылар уйнаткан тавыш ишетелә — залдагы кешеләр барысы да берьюлы аягүрә катып, бер мәлгә тып-тын булып калалар. Тик Чикерткә генә йомшак көрсигә тәмам баткандай кузгалмыйча утырып кала. Менә берзаман түрдәге сырлап эшләнгән, алтын йөгерткән зур ишек гүя үзлегеннән тавышсыз гына ике якка ачыла, һәм залга, өстендәге чапаны, башындагы таҗы белән елык-елык уйнаклап, патша хәзрәтләре үзе дә ап-ак сакаллы баш вәзирен ияртеп килеп керә. Зал уртасындагы атлас чатырлы алтын тәхетенә ашыкмыйча гына барып утыра. Шунда ук тәхетнең ике ягына гөрзиле сакчылар килеп баса.

Патша хәзрәтләре утыру белән башкалар да янәдән үз урыннарына утырышалар. Шуннан соң ишан хәзрәтләре тәсбих элгән кулын күтәреп, селкенә биреп, бик озын итеп дога кыла. Аның артыннан патша үзе дә, патшаның вәзирләре дә битләрен сыпырып куялар. Дога тәмам булгач, патша хәзрәтләре ишан хәзрәтләреннән исәнлек-саулыгын, озын сәфәрне ничегрәк кичерүен йомшак кына сораша, чакыруны кабул итеп, хозурына килүе өчен рәхмәтен белдерә һәм ахырдан нинди максат белән чакыртуын болай дип әйтеп бирә:

— Бәлки ишеткәнсездер дә инде, тәкъсир, билгесез угрылар сараема кереп, хәзинәмнән күп кенә асыл ташларымны, алтыннарымны урлап чыктылар. Шулар белән бергә атамнан мирас булып калган, минем өчен аеруча кадерле булган бер алтын балдак та югалды. Тирә-әтрафтагы мәшһүр фалчыларны чакыртып, угрыларны фаш итүләрен сорасам да, алар миңа ярдәм итә алмадылар. Инде сезнең халык арасында даны таралган могҗизалар күрсәтүче бер изге зат булуыгызны ишеткәч, ниһаять, менә сезне ерак җирләрдән үз хозурыма чакыртып алдым. Әгәр дә ки, ишеткәнемчә, сезнең шундый зат булуыгыз хак икән, сез миңа угрыларны һичшиксез фаш итеп бирерсез дип ышанам. Ул чагында мин сезне мәмләкәтемнең баш вәзире итеп куячакмын. Менә шулай... Инде дә мәгәр сез халыкны алдап йөрүче бер надан, ялган ишан булсагыз, бүтән чара юк, миңа сезнең мут, хәйләкәр башыгызны халык җыелган мәйданда чаптырырга туры киләчәк. Сезгә бу шаять аңлашыла торгандыр, тәкъсир?

— Әйе, аңлашыла,— ди Чикерткә, әкрен генә.

Патша хәзрәтләренең сүзне бик мөлаем-йомшак башлап та, бу кадәр каты-куркыныч итеп бетерүе, әйтәсе дә түгел, Чикерткәне бик нык куркуга сала. «Бетте баш!» дип уйлый ул шунда ук эченнән, сикереп торып ишеккә дә ташланасы килә, әмма ләкин хәлфәнең биргән киңәшләрен исендә тотып, ничек кенә булса да сабырлыгын җуймаска тырыша. Патшаның сүзләренә артык исе китмәгәндәй тәсбихен тартып, фани дөнья уйларыннан киткәндәй күзләрен йомып, озак кына өнсез-сүзсез утыра. Бары шуннан соң гына ашыкмыйча тыныч кына әйтә:

— Олуг падишаһ, безгә күрсәткән игътибарыгыз вә мәрхәмәтегез өчен тәшәккердән гаҗизмен, әмма ләкин әйтергә тиешмен ки, мин күрәзәче дә, фал салучы да түгелмен. Мин гомеремне гыйбадәткә багышлаган Тәңренең бер зәгыйфь колымын, Хак Тәгалә күңелемә ни салса, мин бары шуны гына изһар итә алам. Моның өчен миңа шәһәр ыгы-зыгысыннан китеп, этәч тавышы да ишетелми торган берәр аулак урында изге китап ачып карашым кирәк. Шул сәбәпле мин сез галиҗәнаптан без фәкыйрегезне әнә шундый аулак урынга күчерүегезне һәм өч көн мөддәт бирүегезне баш иеп сорыймын. Иншалла, өч көн дәвамында Хак Тәгалә изге китап аша миңа ни дә булса эшкәртер дип ышанам.

Билгеле, Чикерткә мондый шартны аулак җирдән качып китеп булмасмы дигән бер өмет белән дә куя. Патша аның үтенечен кабул итә һәм вәзирләренә каладан читтә этәч тавышы да ишетелми торган җирдән берәр өй табып, хәзрәтне мөриде белән бергә шунда күчерергә куша.

Өй табыла, боларны шунда күчереп куялар. Бик мул итеп, өч көнгә җитәрлек азык-төлеген дә биреп калдыралар. Тик хадимнәр генә булмый, чөнки ишан хәзрәтләре Аллаһе Тәгалә белән аулакта ялгызы гына гәп алып барыр өчен хадимнәрдән баш тарта.

Икәү генә калгач, болар патшаның таләбен ничек итеп үтәү турында баш вата башлыйлар. Сарайдан алтыннарны чәлдергән ул мәлгунь каракларны кайдан табарга?.. Чикерткәгә бу эш бөтенләй өметсез булып күренә —мәшһүр фалчылар да фаш итә алмаган ич аларны! Хәер, ул башын артык ватмый да, чөнки өч көннән соң барыбер газиз башкайдан аерылырга туры киләчәк. Әнә хәлфә ватсын, баш аңа кирәгрәк, ник дисәң, аның мәдрәсә сандыгы Чикерткә җыеп биргән алтын тәңкәләр белән тула язды инде.

Ә хәлфә чынлап та уйлана, ашау-эчүен дә онытып уйлана. Башымны чабарлар дип тә курыкмый ул (аныкын түгел, ишанныкын тәгәрәтәчәкләр ич!), әмма ләкин шул «ишан» аркасында патшаның ышанычына кереп, сарай кешесе булып китү хыялы аңа бер генә дә тынгылык бирми... Моның өчен күп тә кирәкми ләса — каядыр посып яткан угрыларны фаш кына итәсе... Ахыр чиктә, түбәтәен бер салып, бер киеп уйлана торгач, хәлфә абзаң тәки хәйләсен таба. Ул тота да Чикерткәдән түбәндәге игъланны яздыра:

«Падишаһиәгъзам хәзрәтләренең чакыруы буенча пайтәхеткә үзенең изгелеге вә күрәзәлеге белән бөтен мәшрикъка даны таралган ишан хәзрәтләре килде. Килүеннән максат шул ки, ишан хәзрәтләре, изге китап ачып, падишаһ хәзинәсен баскан угрыларны фаш итәчәк. Әгәр дә мәгәр угры үзе үз ихтыяры илән урлаган алтыннарын вә һәм падишаһ хәзрәтләренең атасыннан мирас булып калган мөһерле балдагын китерсә, ишан хәзрәтләре аның җанын саклап калуны өстенә алачак. Инде дә ки китермәсә, угры барыбер тотылачак һәм иң каты җәзага хөкем ителәчәк. Килү мөддәте ошбу игълан хәбәр ителгән көннең икенче тәүлегеннән дә соңга калмаска тиештер. И угры, изге ишан хозурына килеп, тез чүгәргә ашыгың!.. Ул сине мәрхәмәтеннән ташламас».

Игъланны тагын берничә нөсхә күчерткәннән соң, хәлфә, Чикерткәне ялгызын гына калдырып, үзе каланың базар мәйданнарына йөгерә-чаба китеп тә бара. Мәгълүм ки, бу илнең тәртибе буенча, мәйданнарда быргылар уйнатып җыйган халыкка патша фәрманын яки төрле мөһим хәбәрләрне кычкырып әйтүче көр тавышлы махсус адәмнәр була — хәлфәнең исәбе менә шул хәбәр салучылардан әлеге игъланны укыту иде. Һәм ул шулай эшли дә — зур каланың барлык мәйданнарында булып, үзенең игъланын халыкка кычкыртып укыта.

Шул рәвешчә эшен бетереп, хәлфә, шактый арыган булуына да карамастан, кала читендәге аулак өйгә күтәренке кәеф белән кайтып керә. Ә Чикерткә нарасый баладай борынын әкрен генә сызгыртып йоклап ята. Хәлфә аны тибеп уята:

— Бу ниткән эш? Мин эт шикелле телемне салындырып чабам, ә син тук мачы кебек бөгәрләнәсең дә йоклыйсың! Тәмам аздың, малай!

— Хәсрәттән, хәлфә абзый, ачуланма,— ди Чикерткә, күзләрен уып.

— Нинди хәсрәттән?..

— Бетә бит, китә бит инде баш!.. Шуны онытып торсын дип яткан идем.

— Юк, син ашыкмале башыңнан аерылырга. Ахмаграк булса да торсын әле ул үз урынында... Ни өчен чабам соң мин бу каланың кәкре-бөкре урамнарыннан? Менә быргылар уйнатылды, халык җыелды, игъланны кычкырып укыдылар, мондагы такыр башларның колагына керде инде ул... Иншалла, моның берәр нәтиҗәсе булмыйча калмас... Минем исәбемчә, карак та берәү генә булмас, икәү яки өчәү булырга тиеш алар... Игъланны ишеткәч, өчәүнең берсе килер, килмичә калмас... Беләм мин адәм баласын, иптәшен сатып булса да башын сакларга тырыша ул!..

— Ай-һай, хәлфә абзый, башы өчен курыккан кеше патша хәзинәсен басармы икән? Булмас,— ди Чикерткә, сүлпән генә.

— Ни беләсең син, мәдрәсә чыпчыгы? Урлаганда бар да батыр, ә тотыла башлагач, һәркайсы шыр җибәрә. Батырлык белән куркаклык кешенең йөрәгендә гел алмашынып тора ул, тәкъсир! Менә көтеп карыйк, ут яктысына килгән күбәләк кебек берәрсе килмәсә, патша кызы миңа хәрам булсын!

Хәлфәнең бу гаҗәеп күрәзәлеге шул ук кичне раслана да. Иң элек караклар чынлап та өчәү булып чыга. Билгеле, ишан хәзрәтләренең игъланын алар да ишетәләр һәм, билгеле инде, бу хәбәр аларны шактый хәвефкә сала. Үзара киңәш коралар: нишләргә? Малмы, башмы? Бер куркаграгы әйтә, алтыннарын ишан хәзрәткә тизрәк илтеп бирик, ди. Икенчесе — хәйләкәррәге — ашыкмаска куша: иң элек белик, нинди ишан икән ул, ди. Китап ачып фаш итәм дигән. Ничегрәк итеп, кайсы битеннән ачып фаш итмәкче була ул безне, башта шуны күрәсе иде, ди. Ахырда өченче бер тәвәккәллесе төнлә ишан торган йортка барып, читтән генә хәзрәтне күзәтеп кайтмакчы була.

Базарлар таралып, кибетләр һәм кярханәләр ябылып беткәч, шәһәр дә әкренләп тынгач, ишан йортын эзләп китә угры. Бара, бара, ниһаять, кала читендәге ялгыз йортны барып таба. Дөнья тын, төн караңгы, тик ишан тәрәзәсендә генә ут яна. Угры бик саклык белән, диварга елышып кына шул бердәнбер якты тәрәзәгә килә.

Ә бу вакытта хәлфә белән Чикерткә дә йоклап ятмыйлар. Берсе ишек төбендә, икенчесе бүлмәдә төнге кунакны көтәләр.

Угры диварга сылашып, бүлмә эченә үрелеп кенә карый һәм күрә: бүлмә уртасындагы тәбәнәк өстәл янында чалма-чапан кигән берәү әкрен генә селкенә-селкенә калын китап укып утыра. Ишан хәзрәтләре шушы үзе микәнни инде? Нәкъ шул чакта ишек артыннан хәлфә бер генә тапкыр «эһ-һем» дип тамак кырып куя, ләкин угры моны ишетми. Ә ишан хәзрәт китабыннан башын күтәрмичә нидер мыгырдана башлый, аннары кинәт кенә сикереп тора да: «Берсе килде, берсе килде!» — дип кычкырырга тотына.

Угры, моны ишетеп, бөтенләй коелып төшә: «Килгәнемне белде, китабына карап белде! Чукынган да ишан икән!» Ул шунда ук тәрәзә яныннан сыза. Ашыга-ашыга иптәшләре янына кайта да ишеткән-күргәннәрен түкми-чәчми аларга сөйләп бирә. Өч угрының икесе күп уйлап тормыйча, болай булгач, алтыннарны тизрәк илтергә кирәк, барыбер ул безне фаш итәчәк, диләр. Ләкин әлеге хәйләкәре, юк, ашыкмыйк, тагын бер сынап карыйк әле, ди. Ничек итепме?.. Менә икәү барып карыйк, икәүләп килгәнебезне белерме-юкмы?..

Шулай килешеп, угрыларның икесе яңадан ишан йортына китәләр. Барып җитәләр. Ишан тәрәзәсендә ут яна, ә үзе тәбәнәк өстәл янында һаман китабына төртелеп утыра. Бу юлы инде хәлфә ишек артыннан ике тапкыр әкрен генә тамак кырып куя. Угрылар исә тәрәзәнең ике ягына ышыкланып, ни булыр икән

дип, тын да чыгармыйча карап торалар. Ишан хәзрәт, селкенә-селкенә бераз укыгач, шашынган шикелле кинәт кенә сикереп тора да, кул-аякларын болгап: «Икесе килде! Ике-сее!» —дип, бик яман акыра башлый... Угрылар тәрәзә яныннан җил өргәндәй юк булалар. Шактый чапканнан соң болар туктап, үзара сөйләшеп алалар:

— Алай, эш харап икән, ул тилергән ишаннан котылып булмас, хәзер үк патшаның алтыннарын китереп бирергә кирәк, баш кадерлерәк! — диләр.

Әмма кайтып җиткәч, теге хәйләкәр комсызы тагын әйтә: «Нигә алтыннарны илтергә, алтыннар калып торсын, балдакны гына илтик, патшага атасының балдагы кадерлерәк дигән ич ишан үзенең безгә язган хитабында»,— ди.

Үзара озак кына тарткалашканнан соң, ахырда балдакны гына илтергә булалар. Бу юлы да ишанны сынап карыйсылары килә — алтыннарны таптырырмы, юкмы ул?

Шул ук төнне өчәүләшеп тагын ишан йортына китәләр. Ә тәрәзәдә һаман ут яна... Килеп җитүләре була, ишан хәзрәт бүлмәсендә котырына да башлый: «Өчесе дә килде. Өчесе дә, өчесе дә!..» Ул хәтта кызып китеп, киң ыштан балакларын җилфердәтә-җилфердәтә, чатлы-ботлы биергә дә тотына... Угрылар тәрәзәдән генә балдакны бүлмә уртасына ташлыйлар да үзләре, тасыр-тосыр чабып, төн эчендә эреп тә югалалар.

Шунда ук тыштан күзләрен елтыратып хәлфә килеп керә:

— Йә ничек?

Чикерткә учына йомган балдакны ачып күрсәтә:

— Менә... ташлап киттеләр.

— Шәп, бик шәп! — ди хәлфә, кулларын угалап.

— Ә алтыннарны китермәгәннәр,— ди Чикерткә нәүмизләнеп.

— Алтыннарына төкер! Безгә бусы да җиткән.

— Ә патша таптырса?

— Таптырмас, патшаның болай да алтыны күп... Кая, бир әле монда балдакны. Ай-һай, авыр да икән соң, ләгънәт, ничә мыскал булыр бу?!

Ә Чикерткәнең һаман үз кайгысы:

— Угрыларны фаш итеп булмады бит, хәлфә абзый, патша хозурына баргач, мин нәрсә дип әйтермен?

— Йә җыларга тормале, чебеш!.. Мин барын онытма! Патша хәзрәтләрен шаккатырачаксың әле син бу балдак белән!

— Ничек итеп?

— Анысын иртәгә белерсең... Ә хәзер сөтләп, йөземләп бер чәйләп җибәрик булмаса!

Төн уза, таң ата, Чикерткә ефәк юрган астында йоклап кала, ә хәлфә, балдакны элэктереп, иртән иртүк патша сараена китеп бара. Сарайның бик зур бакчасы була. Бакчада гаҗәеп агачлар, гаҗәеп гөлләр үсә, түгәрәк күлләр елтырап ята, чылтыр-чылтыр чишмәләр агып тора. Һәм шулай ук анда нинди генә кошлар да булмый!.. Баш бармак хәтлесеннән алып, бозау чаклысына кадәр!.. Аларның сайравыннан, кычкыруыннан бөтен бакча гөж килеп тора. Әмма ничек керергә соң бу җәннәттәй бакчага? Хәлфә биек диварлар буйлап йөри, ләкин бер дә керерлек тишек таба алмый. Ахырда, йөри торгач, дивар астыннан агып чыккан бер арыкка туры килә. Күп уйлап тормыйча сикереп төшә дә, каты агымны ера-ера, дивар астыннан бакчага кереп тә китә. Кергәч, арыктан чыгып, чабуларын сыгып, бер юан агач артына ышыклана да бакчадагы кошларны күзәтә башлый. Күлдә йөзгән кошлар аңа кирәкми, җирдә йөргәннәре кирәк — аларның да тик иң зурлары гына...

Ахырда аның алдына салмак кына атлап берничә тәвә кошы килеп чыга. Арада берсе, шәрә башлысы, аеруча зур-таза була. Хәлфә теге балдакны кесәсеннән тиз генә чыгарып ипи йомшагына әйбәтләп төрә дә, тәвә кошының алдына ипләп кенә ыргыта. Тәвә кошы аны шунда ук йотып та җибәрә. Хәлфәгә шул гына кирәк тә иде. Яңадан арыкка төшеп, бата-чума дивар астыннан чыга да уңга-сулга карамыйча өенә сыптыра.

Ә бу вакытта Чикерткә: «Тагын кая китеп олакты бу хәлфә абзый?» — дип, бүлмәсендә боегып утыра. Әллә ташлап качтымы дип бик борчылып куркып та куя. Алай дисәң, тәңкә тулы сандыгы менә монда, мендәр астында гына... Алтыннарын ташлап качмас ул кеше!

Чынлап та, бераздан хәлфә үзе дә тирләп-пешеп кайтып керә. Керүе белән үк сорый:

— Сарайдан килмәделәрме әле?

— Юк, күренмиләр...

— Шөкер алайса, кайтып җиттем... Тиздән килерләр, әзер булып тор!

— Мин әзер, тик син генә әллә кайда йөрисең! — ди Чикерткә, үпкәсен белдереп.

— Синең башыңны саклап калыр өчен йөрим, сасык! Бүген патша хозурында җавап тотасың бар, белеп тор!

— Беләм. Тик син миңа балдакны биреп куй.

— Балдак юк.

— Ничек юк? — ди Чикерткә, коты алынып.

— Мин ул балдакны,— ди хәлфә, кара сакалын учлап,— Аллага тапшырып, тәвә кошына йоттырдым.

— Алдыйсың, алдыйсың,— ди Чикерткә, үрсәләнеп.—Яшергәнсең, үзеңә алып калмакчы буласың...

— Үкермә, хәсис!.. Могҗиза бу, аңлыйсыңмы? Изге ишан могҗизасы!.. Балдакны патшага чыгарып тоттырмыйсың, ә изге китап сүзе белән әйтеп бирәсең, атагыздан калган мөһерле балдак тәвә кошының карынында, дисең... Төшендеңме инде?

— Ниткән тәвә кошы, кайда соң ул?

— Патшаның сарай бакчасында. Син, Чикерткә, шуны гына бел: балдак кош карынында, вәссәлам!..

— Ә ышанмасалар?

— Ышанмасалар — суеп карарлар. Тик шуны онытма, тәвә кошлары анда берничәү... Шәрә башлысында диген, ягъни мәсәлән, таз башлысында, аңладыңмы?

— Аңладым,— ди Чикерткә, мөгрәнеп кенә.

Ә бераздан ишан хәзрәтләрен алып китәр өчен сарай атлары җигелгән зиннәтле фаэтон килеп тә җитә. Чалма-чапаннарын киеп, әзерләнеп торган ишан хәзрәтләре яшел таягын алып, ашыкмыйча гына фаэтонга чыгып утыра. «Хуш, хәлфә абзый, күрешмәсәк, бәхил бул!» —ди Чикерткә, чак еламыйча. «Һи, шәкерт,— ди хәлфә, кәефле генә елмаеп,— бу фаэтон мине дә алырга киләчәк әле, кайгырма!»

Атлар кузгалалар һәм Чикерткәне тибрәндереп кенә алып та китәләр.

Ә бу вакытта патша хәзрәтләре үз тирәсенә бөтен вәзирләрен җыеп, тәхетендә ишанны көтеп утыра. Менә берзаман ишек ачыла һәм ике сарай хадиме ишан хәзрәтләрен ике ягыннан култыклап, патша хозурына алып керәләр. Тәхет каршына китереп, кыйммәтле келәм каплаган бер калкурак урынга үзен иплэп кенә утырталар. Ишан хәзрәтләре башта озак кына итеп дога кыла. Башкалар да аңа ияреләр. Шуннан соң патша хәзрәтләре ишан хәзрәтләренә әйтә:

— Тәкъсир, сезгә бирелгән өч көн мөддәт үтеп китте. Шушы вакыт эчендә сез изге китап ачып, минем хәзинәмне талаучыларны фаш итәргә тиеш идегез. Шартын беләсез: йә үлем җәзасы, йә вәзирлек вазифасы!.. Йә, ни әйтәсез?

Чикерткә җавап бирергә ашыкмый, күпмедер вакыт патшаның үзен дә, сүзен дә оныткандай күзләрен йомып, тәсбихен тартып утыра. Аннары кинәт кенә уянгандай, башын күтәреп, патшага туп-туры карый да һич каушау сиздермичә, тыныч кына сөйләп китә:

— Олуг падишаһ, Хак Тәгаләнең эшкәртүе буенча изге китаптан без фәкыйрегезгә шул мәгълүм булды: хәзинәгезне талаган угрылар өчәү булган, ләкин алар урлаган алтыннарын алып чит мәмләкәткә чыгып киткәннәр. Аларны шуннан гына эзләп табарга була... Әмма... (Чикерткә әз генә тынып тора.) Әмма атагыздан мирас булып калган кадерле балдакны табарга мөмкин, ул шушыннан, сарай ихатасыннан чыкмаган.

— Чыкмаган?! — ди патша, алга омтылыбрак.— Кайдан табарга соң аны?

— Табуы читен булмас... Изге китап күрсәтүенчә, балдак бакчагыздагы тәвә кошының карынында!

Моны ишеткәч, патша ышанмыйча башын гына селкеп куя.

— Ай-һай, тәкъсир, изге китап сезне алдамый микән?! Аннары тәвә кошлары минем бакчамда берәү генә түгел бит, кайсы юньсезнең карынында икән соң ул балдак?

— Таз башлысында! — ди Чикерткә.

— Таз башлы тәвә кошы юк минем бакчамда! — ди патша, ачулана биреп.

— Ягъни мәсәлән, йоны коелган шәрә башлысында,—ди Чикерткә һаман шулай тыныч кына.

— Андые бар шикелле,— ди патша ахыр килешеп.—Ләкин әйтегезче, тәкъсир, балдак аның карынына ничек итеп эләккән соң?.. Үзе сарайга кереп, сандыкны ачып йотмагандыр ич?!

Менә бу сорауга хәлфәдән бернинди дә сүз-киңәш булмаган иде. Ни диеп җавап бирергә? Чикерткә, тәсбихен тарткан булып, аз гына уйланып тора да бик гади генә итеп аңлатып бирә:

— Угрылар ашыгып бакча аша качканда балдакны төшереп калдырганнар. Ә тәвә кошы, мәхлук, шуны табып, таш урынына йоткан да җибәргән.

Патша рәхәтләнеп бер көлә, вәзирләр дә тыелып кына көлешеп алалар.

— Ярый, тәкъсир,— ди патша, көлеп туктагач,—сүзләреңнең хаклыгын хәзер белербез!

Шунда ук ул сарай хадимнәренә шәрә башлы тәвә кошын тотып китерергә һәм үзе алдында суярга да куша.

...Атланып чабарлык таза, мәһабәт кошны патша алдына тотып китерәләр, озын аякларын ныгытып бәйләп, кырын яткыралар да, әгузе-бисмилла әйтеп, чалып та җибәрәләр. Аннары эчен ярып карыйлар һәм менә патшаның күз алдында кош карыныннан әлеге балдак ялтырап килеп чыкмасынмы?! Бу тамашага бөтен сарай әһеле ис-акыллары китеп, тәмам хәйран вә вәйран булып калалар. Күпмедер вакыт бөтенләй телләренә килә алмыйча торалар. Патша хәзрәтләре балдакны кулына алып, авырлыгын белергә теләгәндәй, чөеп тә карый, бары шуннан соң гына аягүрә басып, Чикерткәгә әйтә:

— Афәрин, тәкъсир!.. Инде мин сезнең хак ишан булуыгызга тәмам ышандым,— ди.

Ә Чикерткә, һич исе китмәгән бер кыяфәт белән, тәсбихен тарткалап тик кенә утыра бирә.

— Ләкин, тәкъсир,— ди патша, сүзен дәвам итеп,—минем сезнең белән икәүдән-икәү генә сөйләшәсем килә. Әйдәгез әле, булмаса, бакчага чыгыйк!

Патша тәхетеннән төшә, ишан урыныннан тора, башкалар барысы да аларга баш иеп калалар.

Бакчага чыккач, патша ишанны үзе дусларча култыклап, бераз аны-моны сөйләнеп барган була да аннары кинәт исенә нидер төшкәндәй тукталып кала.

— Тәкъсир, сез атлый торыгыз, мин хәзер артыгыздан җитәрмен,— ди ул ишанга.

Ишан моңа шактый гаҗәпләнә калса да, билгеле, атлый тора, ләкин артына борылып карарга курка. Ә арттарак калган патша хәзрәтләре шул арада җиргә чүгәләп нәрсәдер тотарга азаплана. Бер чүгәли, ике чүгәли, учы белән җиргә сугып та алгалый, аннары торып ишанны куып җитә дә, йомарлаган кулын сузып, аңардан сорый:

— Йә, тәкъсир, әйтеп бирегез әле, минем шушы кулымда нәрсә?

Ишан ни әйтергә дә белмичә аптырап тора, ә патша аны отыры кыстый да кыстый:

— Йә, әйтегез, әйт! Сез изге зат икәнсез, белергә тиешсез. Йә, нәрсә минем учымда?..

Ниһаять, ишан хәзрәтләре аңлап ала: бу — сынау, патша хәзрәтләре тагын бер мәртәбә аны сынап карамакчы икән!.. Ләкин нәрсә әйтә алсын ул, патшаның учына нәрсә йомганын каян белсен ул? Хәлфә абзые да юк бит янында! Менә кайчан килеп җитте «изге ишанның» соңгы сәгате! Килә икән шул, күпме генә хитрит итсәң дә, барыбер килә икән!.. Беткән баш — беткән дигәндәй, малай-ишан ахырда бик ачынып үз-үзенә әйтә: «Әй, Чикерткә, Чикерткә! Бер сикердең — котылдың! Ике сикердең — котылдың! Өч сикердең — анысыннан да котылдың! Инде менә дүртенчесендә котыла алмадың —тотылдың!»

Моны ишетүгә патша хәзрәтләре шатлыгыннан хәтта кычкырып җибәрә:

— Ах, тәкъсир, белдең бит, белдең!.. Менә Ходаның хикмәте! — Һәм йомарлаган кулын ачып күрсәтә — учында яшел бер... чикерткә!

«Йә Хода, мең шөкер сиңа! — дип куя ишан да эченнән генә.— Дөньяда чикерткәләрең бер мин генә түгел шул синең!..»

— Синдә икән күрәзәлек, синдә икән зирәклек! — ди патша.— Дөрестән дә бит, мин бу бөҗәкне тотар өчен дүрт тапкыр чүгәләп, дүрт тапкыр учым белән җиргә сугарга мәҗбүр булдым. Инде минем бер шигем дә калмады, тәкъсир, син чын мәгънәсендә изге зат, олы акыл иясе икәнсең!.. Вәгъдә — иман, бүгеннән мин сине үземнең баш вәзирем итәм һәм, өстәвенә, сиңа бердәнбер кызымны да бирәм. Ризамы?

— Рәхмәт, патша абзый! — ди Чикерткә бичара аптыравыннан.— Мин инде сезнең теләккә каршы килә алмыйм. Тик шартым бар.

— Әйтегез, тәкъсир!

— Миңа һәрвакыт итагать белән хезмәт иткән мөридемне миннән аермасагыз иде.

— Теге сезгә ияреп йөргән чандыр, кара хәлфәне әйтәсезме? Бик мут кешегә охшаган ул, әмма акыллы адәм булса кирәк. Ярый, мин риза, үз янытызда бер хадимегез итеп тотарсыз, ә киләчәктә бәлки аңа берәр төрле дәүләт эше дә бирербез, әгәр бик мутлашып китмәсә...

— Рәхмәт, падишам, рәхмәт! Тыныч булыгыз, мин аны үз кулымда нык тотармын.

Шул ук көнне патшаның боерыгы белән фаэтон җибәреп хәлфәне сарайга алып та китәләр. Озын кара казаки киеп, кырпу бүреген кырын салган хәлфә, кияү егетедәй, тәңкә тулы сандыгын култык астына кыстырып кына килеп төшә.

Икенче көнне инде патшаның бердәнбер кызын ишан хәзрәтләренә никахлап бирү турында бөтен илгә рәсми хәбәр дә таратыла. Патша сараенда туйга хәзерлек башлана. Шәһәрдәге бөтен йортларга бәйрәм флаглары эленә. Күрше дәүләтләрдән ханнар, шаһлар, шаһзадәләр кунак итеп чакырыла. Илдәге бөтен мәшһүр җырчылар һәм уенчылар сарайга җыела.

Никах укыласы көнне халык урамнарга, мәйданнарга агылып чыга. Бөтен җирдә — бәйрәм, шатлык, җыр-музыка... Алар өчен мәйданнарда зур-зур казаннар асыла. Әллә ничә йөз баш куй, тана, тәвәләр суела... Ә сарайдагы туй мәҗлесен инде әйткән дә юк — анда нинди генә кош итләреннән кәбаблар кыздырылмый да, нинди генә зат ашлар, җимешләр, шәраблар табынга куелмый!

Никахтан соң безнең Чикерткә, чалма-чапаннарын салып ташлап, шаһзадәләрчә тоташ ефәктән җиңелчә генә киенеп, дөньяда тиңе булмаган сылулардан-сылу, гүзәлләрдән-гүзәл кыз янына кияү булып керә... Шул керүдән инде ул могтәбәр кунаклар янына бүтән чыкмый да — аның изге ишан да, шайтан да, беркем дә буласы килми, бары тик бәхеткә чумган яшь кияү генә булып каласы килә. Ә шаккатыргыч туй җиде көн, җиде төн дәвам итә. Хәлфә исә, «ишан хәзрәтләренең» бердәнбер якын кешесе буларак, мәҗлеснең иң түрендә утыра һәм үзенең зирәклеге, тапкыр сүзләре белән бик күпләрне авызына каратып та өлгерә. Чит ил кунаклары, исләре китеп: «Һай, бу нугай, кандай адәм бу?..» — диләр. Ә хәлфә, бөеренә таяна биреп: «Безме, без шундый адәм инде. Бөтен җирдә баш вәзир! Эшли дә, ярый да беләбез!» — дип кенә җибәрә.

Туйлар узгач, Чикерткә, баш вәзир сыйфатында, әкренләп дәүләт эшләрен үтәргә дә керешә. Хәлфә һәрвакыт аның янында була. Әйтергә кирәк, дәүләт эшләрен дә алар акыл белән бик оста йөртәләр. Патшага бик ошыйлар, патша алардан бик канәгать була.

Шул рәвешчә тату-тыныч кына шактый еллар бергә гомер кичерәләр. Ләкин патшаның ир баласы булмый, шул сәбәпле үзеннән соң илдә патшалык итүне рәсми фәрман белән киявенә тапшыра.

Менә көннәрдән беркөнне карт патша, ниһаять, үлеп китә. Гәүдәсен ак мәрмәрдән махсус эшләнгән төрбәгә бик олылап җирлиләр. Илдә бер атналык матәм көннәре игълан ителә. Шуннан соң, әлеге фәрман нигезендә, патшалык итү Чикерткәгә күчә. Тора-бара халык та аны ярата, чөнки кече яшьтән үк нужаны бик нык татыган безнең ятим Чикерткә үзен акыллы, гадел һәм миһербанлы патша итеп таныта. Үз урынына исә ул хәлфә абзыен баш вәзир итеп куя. Хәлфә дә инде олаеп бара, шуның өстенә өйләнмичә дә кала (сарайдагы җарияләр белән генә юана), әмма Чикерткәгә шул кадәр иянәшә — аңардан башка инде ул яши дә алмый...

Чикерткәнең биш баласы була — өчесе малай, икесе кыз. Хатыны бер дә картаймый. Бик тату, матур, бәхетле яши алар... Озак яшиләр... Инде Чикерткә вафат булганнан соң... Хәер, Чикерткәдән соң ниләр булганын без белмибез. Әкият шуның белән тәмам. Нокта куйдык! Бигайбә! Әкият ары, мин бире, аркасына чи тире!

Кода сөйләп беткәч, мин аңардан сорадым:

— Кемнән ишеткән идегез бу әкиятне?

— Беркемнән дә түгел, үзем...— диде кода, тыйнак кына елмаеп.

— Ничек «үзем»?

— Ну... үзем чыгарган әкият.

— Шулаймыни? — дидем мин, гаҗәпләнүемне бер дә яшермичә.

— Мин дә бит кайчандыр ятим шәкерт идем,— диде кода, акланырга теләгәндәй.— Хәллерәк шәкертләрдән әзрәк өлеш тимәсме дип, кичләрен мәдрәсә идәнендә тезелешеп яткан чакларда мин аларга озын-озын әкиятләр сөйли торган идем... Тамак кайгысы хыялны эшләткән, күрәсең...

— Алай икән... Интересно...

Мин, коданың чал башына карап, бераз уйланып тордым, аннары өйрәнелгән гадәт буенча әкият турында нидер әйтергә кирәк таптым. Билгеле, хәзерге заман күзлегеннән карап...

— Макташудан булмасын, кода, әкиятегез кызыклы, хәтта бик кызыклы. Тик менә ахыры әллә ничегрәк. Дөрес түгел кебек, минемчә.

— Нәрсәсе дөрес түгел?

— Сез үзегезнең Чикерткәгезне иң ахырда гына яхшы, гадел патша иткәнсез бит!..

— Нигә, ярамыймыни?

— Ярап бетмәс шул. Беләсезме, бик шәп фәкыйрь дә, баегач, бигрәк тә патша булып алгач, еш кына иң алама кешегә әйләнә дә куя... Ә сездә әйләнмәгән. Ни өчен?

— Юк,— диде кода, башын селкеп.— Элек бөтен әкиятләр дә шулай бетә торган иде, ник дисәң, халыкның һәрвакытта да яхшы патша күрәсе килгән.

Һәм ул моның бик күп мисалларын китерде. Кыскасы, ышандырды кода! Әкиятнең бер гаебе дә юк икән монда. Хикмәт исә халыкның өмет-хыялында икән. Бәс, шулай булгач, коданың әкиятен дә нәкъ үзе сөйләгәнчә калдырырга туры килә, иптәшләр! Әлеге ни... рациональ орлыгы өчен генә булса да...

1976

## Мандарин сатучы

Менә икенче тәүлек инде мин «С» шәһәренең аэропортында каңгырап утырам. Мәскәү тарафыннан самолетлар очмый гына бит! Алма-Атага оча, Алтайга оча, тагын әллә кайларга оча, ә Мәскәүгә юк, Мәскәү кабул итми — анда тоташ болыт, куе томан диләр. Көзге һава җылы өеңдә телевизор карап яткан чагыңда гына әйбәт икән, әмма берәр ят шәһәрнең тап-такыр, шәрә аэропортына килеп эләксәң, аңардан да әшәкерәк урын юктыр, валлаһи!

Шушы бер тәүлек эчендә ялан хәтле аэровокзал бинасы халык белән шыгрым тулды, тыгылды, утырып торыр урын да калмады. Бу — Урал үзәге, бирегә кайсы яклардан гына очып килмиләр, һәм шуларның бик күбесе — Мәскәүгә узып баручылар. Нефтьче дә, кибетче дә, урман кисүче дә, алтын эзләүче дә, балалы хатын да, пенсионер карчык та — барысы да пайтәхеткә ашыга! Чынлап та Мәскәү җирнең кендегенә әйләнгән икән. Хәтта менә мин дә, Казан кешесе, үземнең шәһәргә төшеп тә тормыйча, туп-туры башкалага очарга тиешмен. Институттан шундый боерык алдым — тиз генә Мәскәүгә барып җитәргә кушканнар. Тиз генә!.. Тиз генә туалетка барып килергә була, шуннан башкасы хәзергә әле Алла кулында.

Мин инде көтү залыннан беркая да чыкмыйча, мендәр сыярлык портфелемне кочаклап, ипле креслода гына утырып торам. Бөтен игътибарым түшәмдәге радиотапшыргычта — шуннан диспетчерның «Мәскәү!» дип кычкырганы ишетелмәсме дип көтәм. Хәер, көтә-көтә дә туеп беттем инде, еш кына ишетмичә дә калам, аннары күршеләрдән сорашырга тотынам. Борчылмагыз, Мәскәүне әйткәне юк, диләр.

Шул рәвешчә, буфетка барып килергә дә куркып утырган чакта күршемдәге кресло бушады. Бушаган урынга шунда ук бер тере генә карт килеп утырды. Картның битен әйләндереп алган кыска ак төкләренә, очлы мыегына, куе кашларына һәм башындагы күн түбәле түгәрәк каракүл бүркенә бер карау белән аның кавказлы адәм булуын һич икеләнмичә танырга мөмкин иде. Ул креслоны биләп алгач та, бер рәхәт җиңеллек татыгандай, йомшак хром итекле аякларын сузып җибәрде, бераз ботларын ышкып торды, аннары һич тартынып-нитеп тормыйча миңа да сүз катты:

— Бу ни тамаша? Кайдан бу кадәр халык?

— Мәскәү ягына самолетлар очмый бит,— дидем мин, картның соравына бераз гаҗәпләнеп.

— Күптәнме?

— Икенче тәүлек инде.

— Алай икән, кара син!

— Нигә, белми идегезмени?

— Юк,— диде карт, бернинди борчылу сиздермичә.—Без әле күптән түгел генә Норильскидан килеп төштек... Сез дә Мәскәүгәме?

— Әйе, китеп булса...

Карт әз генә дәшми торды, аннары тыныч кына әйтеп куйды:

— Иншалла, китәрбез!

Кавказлы картның салкын якларда ни эш бетереп йөрүен әзрәк чамаласам да сораган булдым:

— Норильскига нинди җилләр ташлады сезне? Әллә шунда торасыз дамы?

— Алла сакласын! — диде карт.— Болай, эш белән генә...

Тагын сорыйсым килде, ләкин карт яратыр микән?.. Хәер, яратмаса җавабы үзендә калыр.

— Ниндирәк эш белән инде,— дидем мин, сакланып кына,— әгәр дә сер булмаса?..

— Коммерция эше белән,— диде карт, ике дә уйламыйча.— Без мандарин илтеп саттык.

— Шундый ераккамы?

— Нигә исегез китә?.. Авиация заманы ич, көне белән илтеп җиткерә.

— Анысы шулай, ләкин бик кыйммәткә төшмиме соң?

— Зарар юк, анда халык акчалы, күпмегә сатсаң да ала, рәхәтләнеп ала!

Картның болай ачык сөйләшүе миңа ошап куйды. Әйтерсең аның өчен мандарин сатып йөрүдән дә кызыграк һәм гаделрәк эш юк бу дөньяда! Ләкин безнең сүз бүленеп калды — карт янына яшь кенә бер егет килеп басты. Башында поднос шикелле түп-түгәрәк иләмсез зур кепка, шуның астында тар гына озынча бит, карчыганыкыдай кәкрәеп килгән зур борын, ә борын төбендә бер чеметем генә кара мыек.

Карт белән егет арасында кыска, әмма бик мәгънәле генә сөйләшү булып алды.

— Йә, күрдеңме? — дип сорады карт егеттән.

— Күрдем,— диде егет.

— Тапшырдыңмы?

— Тапшырдым.

— Нәрсә диде?

— Була диде.

— Молодец, Арсен! — диде карт, сабагын белгән малайны мактагандай.— Ә хәзер утырып ял ит инде, урын тапсаң...

— Юк, утырмыйм, барам әле,— диде егет, ни өчендер җәһәт кенә миңа күз ташлап.

— Кая тагын?

— Ну... шул тирәгәрәк.

— Ә-ә! Бар алайса, бар!

Егет тар чалбарлы нечкә сыйраклары белән идәндәге чемоданнар, төеннәр арасыннан акробат шикелле кыеклап кына үтеп киткәч, карт сокланган әйтеп куйды:

— Ух, шайтан!

— Улыгызмы?

— Агамның улы. Пләмәнник. Бик тә уңган, чая егет! Менә коммерциягә өйрәтәм әле үзен.

— Коммерциягә?! Ни өчен?.. Аның укыр чагында...

Ләкин карт миңа әйтеп бетерергә дә ирек бирмәде:

— Ә укыганнар алар семьясында болай да күп. Бер абыйсы — галим, профессор, ике апасы — врачлар, тагын бер абыйсы инженер, ә сеңлесе консерваториядә укый. Җитмәгәнмени?.. Туганнар арасында бер коммерсант та булырга тиеш.

— Нигә, бик кирәкмени ул шулай? — дидем мин, отыры гаҗәпләнеп.

— Кирәк! — диде карт, кырт кына өзеп.— Коммерция һәр заманда, һәр җирдә кирәк булачак. Мәсәлән, безнең бакчаларда мандарин үсә, ә Норильскида яки әнә Магаданда пока үсми әле. Аны кемдер илтеп сатарга тиеш бит!

— Ә нигә дәүләткә генә тапшырмыйсыз?

— Хи-хи! — дип кеткелдәде карт.— Дәүләт җыйганчы да төяп илткәнче мандариннар тирескә әйләнә ич!.. Ә мин үзем бүген җыйганны — бүген илтеп җиткерәм. Сәүдә эшенең бөтен сере — өлгерлектә!.. Шулай иптәш, кем... дип белик сезне?..

Мин бик теләмичә генә кем булуымны әйттем. Карт елмаеп кына:

— Алайса сез дә галим икәнсез! — дип куйды. Ул арада көтеп утыручылар арасында сизелерлек хәрәкәт-җанлану башланды. Мәскәүгә юл ачык, имеш, тиздән ул тарафка самолетлар оча башларга тиеш икән... Карт минем тез башыма сугып алды:

— Әйттем ич, китәбез дип!

— Нигә, сез дә Мәскәүгәмени? — дидем мин, аптырабрак.

— Мәскәүгә инде, Мәскәүгә... Кайсы яктан гына кайтсак та безнең юлыбыз һәрвакыт Мәскәү аша... Анда дуслар бар. «Арагва» бар, табасы-аласы нәрсәләр бар. Шулай иптәш кем... дидегез әле? Ә-ә, профессор!..

Мин дәшмәдем. Ул да булмый моның пләмәше, яшь коммерсант Арсен да чабып килеп җитте.

— Әйдә, кузгалдык! — диде ул, агасының дөнья гизгән таза чемоданына үрелеп.

— Хәзер үкмени?

— Әйдә, тиздән утырта башлыйлар.

Карт ашыкмыйча гына урыныннан торды, аеруча бер канәгатьләнү белән очлы мыекларын сыпыргалап куйды. Мин тагын, аңгыра сарык шикелле, аптырап сорамыйча булдыра алмадым:

— Сезнең ничәнче рейс соң?

— Ә безгә кайсысы да ярый,— диде карт, ваемсыз гына,— тик илтеп кенә җиткерсен! Йә, хуш иттек, иптәш кем... Танышуыбызга бик шатмын. Сезгә дә монда озак утырырга туры килмәсен.

Шулай диде дә, чемоданын күтәргән пләмәше артыннан генерал сыман ашыкмыйча эре генә китеп барды. Ә миңа алардан соң тагын дүрт сәгать көтеп утырырга туры килде әле. Кайчагында аңлавы бик читен бу дөньяны!

Ниһаять, мин дә Мәскәүдә! Иң зур, иң шәп гостиницаның холласында әлеге шул бичара күндәм портфелемне кочаклап, бик күпләр белән бер рәттән номер көтеп утырам. Вакыт — кичке тугыз. Барьер артында тезелешеп утырган мәгърур купшы ханымнарга кат-кат мөрәҗәгать итеп карауның хәзергә әле һич нәтиҗәсе булмады. Барып сораган саен аларның кирпечтәй кызыл авызларыннан ук шикелле бары бер генә сүз атылып чыга: «Урын юк! Юк!..» Әмма бу сүзне бик тыныч кабул итәргә кирәк. Монда дәгъвалашып, нидер исбат итеп маташырга һич тә ярамый. Монда, әфәндем, сабырлык кирәк, бары сабырлык аркасында гына «биек» максатка ирешү мөмкин.

Әнә шундый акыллы фикерләргә батып, оеп утырганда каршыдагы киң баскычтан ашыкмыйча гына төшеп килгән берәү күземә чалынды. Өстендә өф иткән чем-кара костюм, аякларында кара лаклы туфлилар. Ак чәч, ак сакал, кара кашлар. Бу нинди академик төшеп килә дисәм, ул теге, миннән алда китеп барган мандарин сатучы икән ләбаса!.. Исем-акылым китте. Ул да мине танып алды.

— Ә, сез дә килеп җиттегезмени? — диде ул, туктала биреп.

— Әйе,— дидем мин, кыюсыз гына. Гаҗәп, шушы минутта мин үземне чынлап та аңардан шактый түбән торган бер кеше итеп сизгәндәй булдым.

— Номер көтәсезме?

— Әйе, көтәм... Ә сез... Сез урнаштыгыз дамыни?

— Килеп төшү белән.

— Ничек соң ул алай?

Карт авызын ачарга өлгермәде, кабыргасыннан яралгандай, кинәт каяндыр теге нечкә сыйрак пләмәше килеп чыкты. Анысы да бай ресторанның официанты сыман шәп костюм, ак яка, кара «бабочкадан» иде.

— Ага, өстәл әзер! — диде ул, картның колагына үрелеп.

— Шулаймы?.. Кунаклар җыелдылармы соң?

— Барысы да... Сине генә көтәләр.

— Дора Владимировна да килдеме?

— Килде, ага, килде!

— Үзе генәме?

— Әйе, үзе генә.

— Ә шампанскийны бозга куярга куштыңмы?

— Барысын да нәкъ сез кушканча эшләттем!

— Яхшы, барам,— диде карт, ләкин китә башлагач кына кире туктап:

— Да, сез миннән нидер сорадыгыз шикелле, иптәш... ученый?

Әлбәттә, сорап торуның хаҗәте дә юк иде, әмма үзе махсус тукталгач, кабатларга туры килде:

— Мин сездән, ничек болай бик тиз номерга керә алдыгыз, дип кенә сорамакчы идем.

— Ә-ә! — диде карт, мәгънәле генә елмаеп.— Аңа һич тә исегез китмәсен! Беләсез ич, хәзер безнең кебек (ул моңа аеруча басым ясап әйтте) гади кешеләргә бөтен җирдә дә юл ачык, хөрмәтлем!

Шулай диде дә карт, пләмәшен ияртеп, ресторанның киң ишегенә таба атлады. Билгеле, ул моны миннән көлеп, мине үртәп әйтте, әмма бәхәскә урын калдырмаслык итеп әйтте, мөртәт!..

1976

# Бүрек... түгәрәк була

*(натурадан диярлек)*

Мөхтәрәм пенсионер язучы Камали агай күп кенә еллардан бирле башында йөрткән, әмма һич тә туза белмәгән авыр һәм каты цегейка бүрегеннән тәмам туеп беткән иде. Агарган карт башына аның җиңелрәк, йомшаграк бүрек табып киясе килә иде. Әйтик, тиеннән яки ондатрадан тегелгәнне... (Ондатра — күсенең бер төре, шәбе һәм кыйммәтлесе. Сазлыклы суда яши.) Кызганычка каршы, Камали агай бу йомшак, затлы бүрекләрне кеше башында еш кына күрсә дә магазин шүрлекләрендә, ни хикмәттер, бер дә очрата алмый иде. Ләкин алар, кеше башында булгач, сатуда да булырга тиештер бит инде.

Ахырда бер дөнья күргән кеше Камали агайга киңәш биреп әйтте: син, абзый, магазинның артына кереп кара, бәлки эзләгәнеңне шунда табарсың, диде. Менә шуннан соң карт язучы, гәрчә бу киңәшне бик үк өнәп бетермәсә дә, көннәрдән беркөнне бүрекләр магазинының директорына керергә, ниһаять, батырчылык итте. Бүлмә ишеген башта кыюсыз гына шакыды, җавап булмагач әкрен генә ачты һәм рөхсәт сорап, эчкәре узды. Ул кергәндә такыр башлы, шома битле директор дигән кеше, бармаклары арасына кыстырган карандашын юри генә әйләндергәләп, өстәле артында тик кенә утыра иде. Өстәлдән читтәрәк, кайсы ягы беләндер директорның үзенә бик охшаган, тагын бер кеше утырып тора иде. Камали агай да кергәч, тар бүлмә тулып, тыгызланып киткәндәй булды. Мөхтәрәм язучы түбәнчелек белән баш иеп исәнләште, ни өчендер гаепле кеше сыман кыюсыз гына елмайды, ләкин боларның берсенә дә директор тарафыннан бернинди дә реакция булмагач, бик кыенсынып кына үзенең кем икәнлеген әйтте. Шуннан соң гына директор аңа күтәрелеп карады: язучы халык сирәк керә аның янына, карарга стоит!.. Ул хәтта елмаерга да итте, ләкин кире уйлады булса кирәк — елмаймады. Нишләптер бу үзен язучы дип таныткан агайны аның телевизордан да күргәне юк, шулай ук трибуна-мазардан да фамилиясен ишеткәне юк. Күрәсең, тиражга чыккан бер Алла бәндәседер инде. Мәсәлән, картаеп онытылган артист кебегрәк... Әйтергә кирәк, директор, нигездә, дөрес чамалый иде, хәерсез!.. Чынлап та шулайрак шул: Камали агай инде язасын язган, заманында күпме-азмы шаулап алган, хәзер исә онытылганда бер күренгәләп, иске дан белән генә йөрүче хөрмәткә лаек союз члены иде. Хәтта аның өс-башы да шактый модадан чыккан иде инде: кигәне шул әлеге илленче еллардагы озын кытай макинтошы да киң читле, биек түбәле яшел эшләпә... Әмма Камали агай, язучы буларак, бөтен нәрсәне дә ал да гөл итеп кенә күрергә өйрәнгән кеше иде. Шуңа күрә ул менә бүрексез дә...

Йә, моның кебек... төшеп калган кешенең гозерен тыңлаудан директорга ни файда? Ни аласың, ни көтәсең аңардан? Ә зарары булуы мөмкин. Гомумән, язучы халык магазин артында ниләр барын белергә тиеш тә түгел. Шул сәбәпле директор Камали агай белән сүзен бик кыска тотты:

— Юк шул, дәү абый, сез сораган бүрек юк!

— Гафу итегез, мин ишеткән идем, миңа әйткәннәр иде,— дип нидер аңлатырга маташты Камали агай.

Моңа каршы директор әче генә елмаеп куйды:

— Элек безгә дә, Агыйделнең аръягында бер энәгә бер сыер, дип әйтә торганнар иде. Ә барсаң... менә шулай ул, агай-эне, кеше ни әйтмәс!..

Камали агайга бу гыйбрәтле сүзләрнең мәгънәсе шундый нык барып җитте ки, сүз озайтып торуның инде бөтенләй кирәге дә калмады. Ләкин болай капыл гына чыгып китеп тә булмый бит әле. (Килеп керүдән дә авыр икән ул чыгып китүләре!) Агаебыз кызарды, бүртенде, аптырагач, җилкәсен дә кашып алды, ахырда сүзен очлар өчен генә әйткән булды:

— Бәлки сезгә тагын да килер әле?

— Бәлки, бәлки,— диде директор да.— Кергәли йөрегез... магазинга!

— Рәхмәт! — диде Камали агай, үзенең табигый йомшаклыгын җиңә алмыйча. Һәм кыенсынып кына ишеккә таба борылды.

Ул чыгып киткәч, директор һәм аның янында утырган кеше мәгънәле генә карашып алдылар. Алар сүзсез дә бер-берсен аңлыйлар иде.

Камали агай артыннан бүлмәгә бик шәп киенгән, калын гына җилкәле бер егет килеп керде. Ул баш кагып кына исәнләште һәм кыска гына итеп үзенең фамилиясен әйтте. Директор башта өстәл тартмасын ача төшеп, шунда яткан ниндидер исемлеккә күз салды да, аннары җитез генә торып, ишектән бер күк халатлы кызны дәшеп алды.

— Нәсимә, акыллым,— диде ул, халатын кысып буган сылу гына кызга,— менә бу иптәшкә түбәндәге бүрекләрне күрсәт, үзенә яраганын сайлап алсын.

— Яхшы,— диде кыз һәм таза егеткә «әйдәгез» дигәндәй күз карашы белән генә ишарә ясады. Егет, директорга рәхмәт тә әйтеп тормыйча, кыз артыннан иярде.

Инде икәү генә калгач, директор белән аның үзенә охшаган әлеге кеше арасында кыска гына сөйләшү булып алды.

— Бу кем, кайдан?

— Олы йорттан.

— Ну-ну!

— Ну-ну шул менә! Күрдеңме, сәлам дә биреп тормады,— диде директор, такыр башын сыпыргалап.— Йә, сиңа ничәү кирәк соң?

— Күп түгел, өч кенә! — диде тегесе, өлгер генә.

— Һе, өч кенә!.. Үзеңә дә малаеңа, тагын кемгә?

— Алма-Атадагы баҗайга җибәрәсе иде.

— Алма-Атада да бүреккә шулай кытлыкмыни?

— Казан бүреген киясем килә дигән. Хаты артыннан посылкасы да килде әле. Ат казылыгы җибәргән, казакъныкы, капсаң телеңне йотарсың, валлаһи!

— Авыз да иттергәнең юк, чукынган!

— Ә үзең соң, үзең... Әстерхан икрасын иснәтеп тә карамадың.

— Ярый, алары качмас... Ә шифер ничек?

— Була!

— Күпме?

— Шул, үзең сораган чамада.

— Тәк-тәк... Ну шулай да мин сиңа хәзер үк өчне биреп чыгаралмыйм. Ярамый. Икесен ала тор, ә баҗаңа дигәнен, соңыннан.

— Алай да ярый.

Кеше зур сумкасын кулына алып, урыныннан торды.

— Нәсимә янына төшимме инде?

— Теге китте микән?

— Киткәндер инде... Ә, әнә чыгып бара!

— Алайса бар, тизрәк сыпырт!

Директорның үзенә охшаган кеше шунда ук гаип тә булды. Инде, дуслар, бүрекнең түгәрәк булуына ышангансыздыр, шәт! Теләгән кешесенә тәгәрәп кенә килә, ә теләмәгәненнән тәгәри-тәгәри кача икән ул! Нәкъ җәнлекнең үзе кебек...

1976

# Интервью

Ресторан директорының кабинетына хәбәрче иптәш килеп керә. Директор аны сынаулы караш белән сүзсез генә каршы ала. Хәбәрче урын тәкъдим иткәнне көтеп, ишек төбендә басып тора. Ниһаять, директор сорый:

— Сез кайдан? Редакциядән?.. Бик хуп! (Директорның йөзе яктырып китә.) Рәхим итегез, иптәш корреспондент, рәхим итегез!.. Менә монда, йомшакка утырыгыз... Сәламәтлек, кәеф-хәтерләрегез? Бик әйбәт, бик әйбәт... Хуш, ни йомыш иде? Бәлки сезгә теге ни... юк, сез тартынмагыз, хәзинәдә барын дигәндәй... Ну, ихтыярыгыз... Ә-ә, интервью дисез, сөйләшергә? Пажалысты, без тайяр!.. Нинди сорауларыгыз бар — рәхим итегез!.. Эчкечелеккә каршы көрәш мәсьәләсе... Әлбәттә, әлбәттә, гаять тә мөһим мәсьәлә, бик дөрес әйтәсез. Бездә ничек дисезме?.. Ну бит без — ресторан, безгә рөхсәт ителгән... Ә нормага килгәндә... юк, без законны бозмыйбыз. Борын башына 100 грамм, шуның белән вәссәлам! Официантларга катгый рәвештә әйтелгән... Алайса нигә исерекләр күп дисезме?.. Бездә генә түгел, бөтен рестораннарда да шулайрак инде ул. Кеше бит аракыдан гына исерми, коньяктан да, төрле винолардан да, хәтта пиводан да исерә. Ә боларга норма юк, юк-юк, пажалысты, күпме телисең... Сез, иптәш корреспондент, бер нәрсәне аңларга тиешсез: без —ресторан, безгә сату итәргә кирәк, штобы әзерләнгән ашлар, закускалар көн дә сатылып бетеп торсын. Финансовый план — бу да бит безнең өчен закон. Әйе, дөрес, планны үтәгән өчен премия дә алабыз. А как же, бөтен җирдә шулай инде ул, хәтта парикмахерскийларда да... Ничек итеп үтибезме?.. Ну, яхшы сервиз, тәмле ашлар, төрле закускалар... Ләкин бит клиент аларны заказать итәргә дә тиеш әле. Клиентның музыка тыңлап, кәефләнеп утырасы килә. Ә йөз грамм белән генә озак утырып буламыни, үзегез уйлап карагыз!.. Заграницада утыралар дисезме? Анда бит халык ярлы, инфляция, иптәшкәем, кая ул безнең клиентка җитәргә?! Йөз грамм аның кортын гына уята. Ә безгә законны бозарга ярамый, не в коем случае! Йә, нишләргә? Менә шуннан соң инде без аңа коньяклар, марочный винолар тәкъдим итәбез. Әйткәнемчә, аларга норма юк, күпме сыя —

пажалысты! Билгеле, безнең юмарт клиентыбыз, утырасы килгәч, тегесен дә, бусын да китерә, ә винолар артыннан ашлар, закускалар, шоколад-конфетлар да китеп кенә тора. Менә сиңа план!.. Ералаш була дисезме, ну, ул кадәресен эчкән кеше үзе белергә тиештер инде... Әгәр дә ки исереп, урындыгыннан шуып төшә башласа, түбәннән безнең Абдулла менә дә, кунакны әйбәт кенә алып чыгып, милициягә тапшыра. Ә милициянең машинасы да, илтеп яткыза торган җире дә бар. Анда инде хөрмәтле кунакны аякка бастырып, адәм кыяфәтенә кертәчәкләр, бер дә борчылмагыз!

Кыскасы, менә шул. Эчкечелеккә каршы законны да бозмыйбыз, финпланны да үтибез. Барысы да в ажуре!.. Ә ни дисез, кешеләрне әдәпле эчәргә, матур гына утырырга өйрәтү кирәк дисезме?.. Ну, беләсезме, алкашлар өчен без инде курслар ача алмыйбыз. Ничек эчү, күпме эчү — бу пичәт эше, сез өйрәтергә тиешсез анысына. Менә шулай, иптәш корреспондент! Сорауларыгыз беттеме?.. Хушыгыз алайса! Йомышыгыз төшкәндә керә йөрегез!

1977

# Тынычлану

## I

...Көне... Иртәнге сәгатьтән үк бөркү эсселек үзен шулчаклы сиздерә дә башлар икән? Гаҗәп! Хәтта төне дә җиңеллек китермәде — суынырга өлгермәгән таш йортлардан, таш урамнардан, тузан исен аңкытып, һаман бөркелеп торды бу китмәскә килгән эсселек... Менә өч атна инде яңгыр тамганы юк. Температура көндезен утыздан артып китә, төннәрен егермедән дә төшми диярлек. Бер кат җәймә генә ябынып ятсаң да йоклап китә алмыйча азапланып бетәсең, мендәреңнең салкынчарак җирен эзләп, аны кат-кат әйләндерергә мәҗбүр буласың. Кышкы суыктан да әшәкерәк икән ул бөркү эсселек!..

Гасыйм Сәләхович та шәрә килеш диярлек киң кроватенең читенә таянып, күзләрен дә ачарга иренеп, тик кенә утыра. Әллә ялкаулыктан, әллә хәлсезлектән? Икесе дә бардыр, ахрысы. Шулай да ялкаулыгы хәлсезлектән иде. Хәлсез булганга күрә аның кыл да кыймылдатасы килми иде. Чөнки ул бик начар йоклады, тирләде-пеште, әйләнде-тулганды — һаман да шул әшәке эсселек аркасында. Әмма сәбәп бер аңарда гына түгел иде шикелле... Төп сәбәп йөрәгендә булса кирәк — йөрәге таза түгел иде Гасыйм Сәләховичның...

Менә хәзер дә ул, кроватеннан кузгалырга кыймыйча, гүя йөрәгенә колак салып утыра. Нишли, ничегрәк «тота» ул үзен — тәндәге тере җан? Көйсезләнмиме, ялгышмыймы, хәрәкәт итүе ничегрәк? Шуны әйтергә кирәк, соңгы вакытларда йөрәге аның нәкъ менә йоклаганда яки уянгач үзен ныграк сиздерә башлады. Нидән, ни өчен?.. Бүгенгесен бөркү һава, начар йокыдан да күрергә мөмкин, ә башка көннәрдә? Бу хәл, билгеле, Гасыйм Сәләховичны борчый, кәефен боза, куркытып та куя иде. Ярамый бит болай ди ул, үз-үзенә җитди бер хәтәрне сизгәндәй, һәм, бөтен эшен ташлап, бүген үк врачка күренергә кирәк дигән карарга да килә. Ләкин шулай дисә дә ул бармый-күренми, чөнки эшеннән аерыла алмый, ә врачка бару үзе бер мәшәкать, аннары — иң гаҗәбе — йөрәк үзе дә тәмам тынычлана, «хуҗасын» бер дә диярлек борчымый башлый. Гүя «хуҗасының» эше, хәрәкәте, кайгысы аңа да күчә, ул да шуларга көйләнә, җайлаша, гүя үзен юри онытгырып тора. Кыскасы, яраклаша белә йөрәк кешегә!

Тик менә кеше үзе еш кына йөрәге белән хисаплашмый. Борчый, җәберли, оныта бичараны еш кына! Сәбәпләре моның кырык төрле — санап кына чыгарлык та түгел. Гадәттә, кешенең үзен гаеплиләр, «саклый белмәде йөрәген» диләр.

Әмма кеше үзе генә саклый ала микән соң аны? Иң элек кешенең үзен сакларга кирәк түгелме икән?

...Икенче атна инде, Гасыйм Сәләхович өч бүлмәле квартирасында япа-ялгыз яши. Хатыны больницада, улы Кырымга китте. Ирексездән төрлесен уйларга туры килә аңа ялгызлыкта. Бигрәк тә бүгенге шикелле иртәдән үк йөрәгенең хәлсезлеген сизеп торган чакта; ул бит бала түгел, үз хәленең җитдилеген аңлый торган кеше. Ярый, әллә ни булмасын да ди, ләкин шулай да... Һәм мондый минутларда Гасыйм Сәләховичның күңелендә хатыны белән улына карата ирексездән рәнҗү хисе уяна. Дөрес, сирәк уяна, әмма ялгызлыгын тирәнрәк сизгән һәм күңеленә төрле шомнар килгән чакта уянмыйча калмый иде. Белергә теләмиләр, тиешенчә игътибар итмиләр аның хәленә хатыны да, улы да... Эше шундый күп, киеренке, тыгыз бер вакытта аны тоттылар да ялгыз калдырдылар; хатыны Рәмзия ханым юк авыруын бар итеп дигәндәй (белештермичә ашаса, кайчагында бавыры авырткалый иде), тикшертүләр ясар өчен спецклиникага кереп ятты, ә малае Радик, икенче курс студенты, имтиханнарын ашык-пошык биреп бетерде дә, нинди дер хөр егетләр һәм кызларга ияреп, Кырымга китеп барды. Гасыйм Сәләхович фикеренчә, клиникага кереп яту да, Кырымга китеп бару да һич тә зарури, кичектермәс эш түгел иде. Ә менә аның өчен хәзер чынлап та бик тыгыз вакыт. Уку елы тәгәлләнеп килә, студентлардан имтиханнар кабул итү башланды, һәртөрле отчетлар язасы бар — бу вакытны кафедра мөдиренең урагөсте дияргә ярый. Иртәдән кичкә кадәр ул хәзер бушамаячак, ашау-эчү, яту-торуның да рәте-юне булмаячак, кыскасы, авырга киләчәк аңа. Шуны уйлап, ул хатынына әйтеп тә карады:

— Җаный, әллә бераз сабыр итеп торасыңмы?.. Нинди вакыт икәнен беләсең...

— Урын барында кереп ятарга кирәк,— диде Рәмзия ханым, өзеп кенә.

— Урын булыр иде әле...

— Ә минем көтәсем килми.

— Миңа авыр булачак бит, аңлыйсыңмы?.. Эшемнең иң тыгыз чагы.

— Син гел үзеңне генә кайгыртасың, минем сәламәтлегем турында уйлап та карамыйсың, эгоист син! — диде Рәмзия ханым, кинәт кыза ук башлап.

— Һич тә алай түгел, әнкәсе! — диде Гасыйм Сәләхович, хатынын тынычландырырга ашыгып.— Синең сәламәтлегең минем өчен дә бик кадерле. Сүз бит клиникага керүне беразга кичектерү турында гына бара. Тикшерүләр үтәр өчен генә булганда ашыкмаска да ярыйдыр инде.

— Ярыйдыр!.. Аны син беләсеңме, әллә минме?.. Аннары синең эштән бушаган чагыңны көтсәң, кабергә кергәнеңне дә сизми калырсың!.. Юк инде, җан кисәгем, клиникада урын бар чагында керәм дә ятам. Бала түгелсең, үз-үзеңне генә карый алырсың әле.

Билгеле, мондый катгый сүзләрдән соң бәхәсләшеп торуның мәгънәсе юк иде. Бигрәк тә авыру мәсьәләсендә, бигрәк тә хатының белән. Гомумән, хатынны сүз белән җиңеп булмый, юк, мөмкин түгел. Бөтен дәлилләрең аның «корыч» логикасына бәрелә дә чәлпәрәмә килә... Иң яхшысы чигенү, нервны бозмас өчен, йөрәкне саклар өчен бары тик чигенү, чигенү — калганы ник шунда чәнчелеп китми!..

Беренче мәртәбә генә түгел инде. Зуррак, җитдирәк мәсьәләләрдә дә аңа еш кына чигенергә туры килде. Гадәтенә керде дияргә ярый. Чигенсә, семьяда азмы-күпме татулык һәм тынычлык урнаша. Ә бу Гасыйм Сәләхович өчен иң зур ганимәт... Аннары ул мондый татулык урнашкан чакларда үзеннән шактый яшь, чибәр, әмма еш кына кәҗәләнергә ярата торган Рәмзиясен иркәли дә, сөя дә ала. Сирәк кенә булса да... Йә, аңа тагын ни кирәк?!

Тик шулай да әлеге рәнҗү тойгысы аның күңелендә бервакытта да бетми диярлек. Яки бетеп торган төсле генә була да, берәр сәбәп чыгу белән яңадан көчәеп китә. Чөнки күп вакытта ул тынычлык хакына дөреслекне, гаделлекне корбан итеп чигенергә мәҗбүр була. Чөнки эгоизм җиңә, ә эгоизм белән килешүе бик-бик читен... Нәкъ менә бу очрактагы шикелле: Рәмзия керәм диде һәм керде дә ятты. Һичнигә карамастан... Урынсыз, мәгънәсез эгоизм түгелмени бу?! Инде хәзер Гасыйм абзаңа ике көннең берендә клиникага барып йөрү мәшәкате дә өстәлде. Рәнҗемәс җиреңнән рәнҗерсең! Ичмасам, куркуга салырлык берәр җитди авыруы булса иде! Юк, анысы да юк, үзе уйлап чыгарган шик кенә бар. Остарды кеше врачларның башын әйләндерергә!

Хатыны клиникага кереп ятканда улы Радик өйдә иде әле. Бик кызу имтиханнарын биреп йөри иде. Гасыйм Сәләхович та тынычлана төшкән иде, бөтенләй үк ялгыз түгел, өйдә сүз кушарга кеше бар, имтиханнарыннан бушагач, әнисе янына да баргалар дип ышанып тора иде. Ләкин Радик имтихан биреп бетерү белән, әтисенә бер сүз әйтмәстән, каядыр китәргә җыена да башлады. Билгеле, ата кеше аптырый калды: «Кая син болай?» — дип сорады ул улыннан. «Кырымга!» — диде малае гади генә итеп. Моны ишеткәч, Гасыйм Сәләхович бик гаҗәпләнде, хәтта ышанып бетмәгәндәй күпмедер ара сүз әйтә алмыйча торды, аннары сабырлыгын җуймаска тырышып, тагын иплән кенә сорады:

— Син, улым, әзрәк уйлап эшлисеңме моны?

— А в чем дело? — диде Радик, тыныч кына.

— Әниең больницада, минем эшем баштан ашкан. Ниткән Кырым ди ул шушындый чакта?

— Ә миңа отдыхать итәргә кирәкме-юкмы?

— Җәй озын, өлгерерсең... Ә хәзергә менә өйдә ял итәрсең.

— Ха! — диде егет, башын чөя биреп.— Көлке!.. Өйдә пенсионерлар да ял итми хәзер.

— Әниең чыккач, син дә китәрсең.

— Кая?

— Кая да булса. Әнә үзебезнең Идел буендагы студентлар лагерена.

— Юк, булмый! Мин Кырымны күрмәгән, только —Кырымга!

— Кырымны менә мин кырыктан узгач кына күрдем,— диде Гасыйм Сәләхович, тыелып кына.

Егет әтисенең бу минуттагы хәлен әллә сизми, әллә сизәргә теләми иде, шактый дорфа гына:

— Таптың чем гордиться! — диде дә бөтенләй аркасы белән үк борылды.

Гасыйм Сәләховичның эчендә кинәт дөрләп ачу кабынды. Малаеның җилкәсенә төшеп торган озын чәчләреннән урап алып, яңадан үзенә таба борасы килде. Ләкин ул тыелып калырга мәҗбүр булды — һәртөрле кискен хәрәкәт аның йөрәге өчен хәтәр иде. Шулай да ачуын сиздерерлек итеп, әкрен генә әйтте:

— Әгәр дә мин рөхсәт итмәсәм?

— Поздно,— диде егет, игътибарсыз гына.— Безнең билетлар уже кесәдә!

Радик күптән инде әтисеннән курыкмый иде. Нишләп курыксын, нишләтә ала ул аны? Берни дә эшләтә алмый, билгеле! Һәм берни дә эшләтә алмавын Гасыйм Сәләхович үзе дә бик яхшы белә иде. Кул күтәреп суга алмый ул студент егеткә, хәленнән дә килми, табигате дә сыйдырмый андый кыргыйлыкны. Үз гомерендә бер тапкыр, Радикка унберме-уникеме яшь чагында, бик ачуы килгәч, аның яңагына шап кенә бер чәлтерәткән иде, анда да әнисе малаен кочаклап ярты көн үкерде, ә ул үзе шул эше өчен үкенеп бетә алмыйча күпме газапланып йөрде. Юк, ата-бабайлардан калган тәрбия «ысулы» бетте, онытылды, күптән юкка чыкты. Әлбәттә, Гасыйм Сәләхович хәзерге заман педагогы буларак, андый «ысулларның» бетүе

белән һичшиксез килешә... Тик шулай да, үз малаең өчен генә булса да, берәр төрлесен саклау зарар да итмәс иде, бәлки. Менә Гасыймның үз атасы, мәрхүм, кыска саплы каеш чыбыркысын ишек яңагында гына элеп тота иде; әйткәнен тыңламасаң яки берәр әшәкелек эшләсәң, хәзер үк шул чыбыркысын чөйдән ала торган иде. «Әлә-лә-лә»не әйттерә иде ул зәһәр чыбыркы!.. Ләкин сыртка бик сирәк төшә иде бит, күп вакытта әтисе аны худка җибәрмичә кире элеп тә куя иде. Әмма чыбыркы бар, чыбыркыны онытырга ярамый! Нишләргә генә уйласаң да кылт итеп ул искә төшә торган иде.

Әлбәттә, хәзер чыбыркыны сагыну, Радик әйтмешли, үзе бер «көлке». Сатып алыйм дисәң дә юк ул хәзер. Тик менә аның урыны буш калды, шунысы кызганыч! Яхшы сүз, үгет-нәсихәт белән генә максатка ирешүе бик читен икән шул. «Тегенең» кебек үтемле түгел берсе дә.

Әмма... сүздән башка чара юк. Искерсә дә, үтмәсләнсә дә бердәнбер «ысул» шул гына... Гасыйм Сәләхович үзалдына озак кына уйланып торганнан соң, авыр гына сулап, малаеннан янә сорады:

— «Без» дигәнең кемнәр инде алар?

— Ну, Вовка Бобров, Гена Соловьев, Рита Козлова, Эмма Булатова, Марсель Ганеев... Вообщем, компания менә дигән!

— Студентлармы?

— В основном.

— Кем балалары соң алар болай ансат кына Кырымга очып китәргә?

— Это не имеет значения.

— Шулай да?.. Кем акчасына йөрмәкче буласыз?

— Мин синнән акча сорамыйм.

— Рәхмәт монысы өчен... Ә башкаларыгыз?

Радик аз гына икеләнеп торды, шулай да кыюланып әйтте:

— Башкаларның родительләре сорамасаң да бирәләр. Без унижения.

— Алай икән,— диде Гасыйм Сәләхович, кызара төшеп.— Күрәсең, бик байлардыр инде.

— Причем байлык! Просто понимают.

— Нәрсәне?

— Понимают наши потребности.

— Ах, шулаймыни?! Алар аңлый, мин аңламыйм икән!.. Хуш, шулай да булсын ди, ләкин бит сезнең потребностьне үтәр өчен бер аңлау гына җитми, аның өчен, хочешь не хочешь, 300 — 400 тәңкәңне кесәдән чыгарып та бирергә кирәк. Ә аны кайдан алырга? Ярый, минем хәлемнән килә, аңламасам да мин бирә алам. Ә башка кеше, мәсәлән, уборщица булып эшләүче берәр апа кадерле малаеның потребностен бик аңлый да, тик менә сезнең белән Кырымга җибәрергә хәленнән килми. Ул чагында нишли?

— Ялгышасың, па! Рита Козлова, биофак студенткасы, тоже уборщица кызы, ә безнең белән барачак. Вот так!

Гасыйм Сәләхович бер мәлгә аптырый калды, күңеленә шунда ук ямьсез уй да килде: «Берәр акчалы кешенең яшерен сөяркәседер әле ул юньсез кызый!» — ләкин бу уен тизрәк үзеннән куарга тырышты. Дөрес, булмый торган хәл түгел, ишеткәне дә бар андыйларны, тик бу очракта бик сак булырга кирәк иде. Онытырга ярамый, малае белән сөйләшә ул. Шулай да әйтмичә түзә алмады:

— Әгәр дә сезнең ул Ритагыз әнисе җилкәсендә шулай кылана икән, бу бик кызганыч! Бичара хатын аның өчен муеныннан бурычка баткандыр, үзе ипи белән суда гына утыра торгандыр... Юк, жестокий ул сезнең мактаулы кызыгыз! Миһербансыз!

Радик әтисенә нәфрәт белән диярлек карады.

— Син, па, абсолютно бернәрсә белмисең, син страшно артта калган кеше... Син просто невежа!

— Җитәр, малай актыгы! — диде Гасыйм Сәләхович, буыла язып.— Күземә күренмә, эзең булмасын монда!

— Яхшы, мин күренмәм,— диде егет һич исе дә китмичә һәм юри ашыкмыйча гына ишеккә таба юнәлде.

— Ләкин бел,— дип кычкырды әтисе аның артыннан.— Әниең белән сөйләшмичә торып, мин сине Кырымга түгел, Арчага да җибәрмим.

Егет ишетмәгән дә шикелле артына да борылып карамыйча чыкты да китте. Гасыйм Сәләхович, хәлсезләнеп, креслосына барып утырды. Сул кулын йөрәге өстенә куеп торды — йөрәк шактый каты тибә, ләкин авырту-чәнчү кебек нәрсә сиздерми иде. Шуңа күрә дару-мазар да кабып тормады.

Бераздан, тынычлана төшкәч, Гасыйм Сәләхович уйлана башлады. Кызганычка каршы, улының «бернәрсә белмисең» дигән сүзләрендә дөреслек юк түгел иде. Бигрәк тә тормыш мәсьәләсендә һәм хәзерге яшьләрне аңлауда... Нигә ул алай, тормыштан бөтенләй үк аерылган кеше дә түгел ләбаса!.. Бөтен үзгәрешләрне, яңалыкларны күреп тә тора шикелле... Ләкин үзе дә сизә, нәрсәнедер белеп җиткерми, аңлап җиткерми... Әйтик, кешеләрнең көнкүрешләрен... Сүз дә юк, кешеләр хәзер җиңелрәк тә, яхшырак та торалар, әмма шуның белән бергә аларның килерләре тигезләнеп беткәне юк бит әле. Аерма шактый зур, мәсәлән, профессор алган 450 — 500 сум айлыкны бик күпләр алмыйлар ич әле. Ә шулай да 70 сум ала торган вахтерның яки уборщицаның кызы сиксән сумлык импортный сапожкиларны киеп йөри...

Ничек итеп моны эшләргә мөмкин? Дөньяның чыгымы күп — ничек кенә арттыра алалар?.. Баш җитәрлек түгел. Әйтәләр инде, кеше хәзер яшәргә остарды дип... Ни дигән сүз бу? Ничек аңларга ул «остаруны»? Берничә җирдә эшләүме? Хаклы һәм хаксыз премияләр алумы? Спекуляция белән шөгыльләнүме? Ниһаять, дәүләт милкен әкрен генә ташумы? Кайберәүләрнең әйтүенә караганда, «остару» дигән төшенчәгә бу «ысулларның» барысы да керә, имеш. Тик кеше кайда, кем булып эшләвенә карап, шул «ысулларның» берәрсен оста гына куллана икән. Ышансаң — ышан, ышанмасаң — юк, анысы синең эш. Гасыйм Сәләхович ул ысулларның берсен дә белми иде, әлбәттә. Бервакытта да бер тиен хәрам акча кермәде аңа. Хезмәт хакы аның һәрвакытта зур булды, иркен-мул гына яшәр өчен җитеп торды. Кайчандыр фән әһелләре халык арасында иң яхшы тәэмин ителгән катлаудан санала иде. Ә хәзер дөнья тигезләнеп бара шикелле... Һәрхәлдә, Гасыйм абзаң ашаган-эчкәнне, Гасыйм абзаң кигәнне һәркем диярлек ашый-эчә дә, кия дә. Хәтта уздырып та җибәрәләр; белеме юк, квалификациясе юк, ә машинасы бар. Әнә кая китте эшләр!

Хәерле булсын. Халыкның тормышы елдан-ел яхшыра икән, бу бик әйбәт, ул шулай булырга тиеш тә, тик әлеге хәрам «ысуллар» гына тамыр җәя күрмәсен иде. Гаять зарарлы нәрсә, кешене тәмам боза, җәмгыятьне имгәтә торган хәтәр нәрсә. Бигрәк тә яшьләргә күчә башласа, бик начарга әйләнеп китүе мөмкин. Ә аның симптомнары юк түгел. Акча яратучы, акча артыннан куучы яшьләр студентлар арасында да бар, кызганычка каршы. Менә шушы нәрсә Гасыйм Сәләховичны аеруча борчый да инде. Чөнки аның белүенчә, яшьләрдәге акчага, малга комсызлык һич тә нужадан түгел (иске мәгънәсендәге нужа юк та ул), ә бик иртә, бик яшьли, әле кеше булып җитәргә дә өлгермәс борын, рәхәт, иркен яшәргә омтылудан гына килә. Менә үз улы белән бәхәс-талашуның бик ачык бер мисалы түгелмени?!

Әйе, улы аңа «син бернәрсә дә белмисең, па!» дигән гаеп ташлады. Ә ул бит менә утыз ел инде шул яшьләр арасында яши, шуларны укыта, тәрбияли. Нәрсәне белми соң ул? Яшьләрнең уйларын, хыялларын, теләкләрен, кыскасы, эчке рухи дөньяларынмы — шуны күздә тотып әйтәме Радик?.. Әйе, кырык ата баласының эчке дөньясын белеп бетерү гаять читен, мөмкин дә түгел диярлек. Бигрәк тә дүрт-биш ел саен алар алмашынып тора, берәүләре китә, икенчеләре килә (һәм гел генә үзгәреп килә), ә син һаман искечә каласың, һаман олая барасың, һәм табигый хәл — яшьләр гүя синнән ераклаша, син инде аларны томанлырак, ятрак итеп күрә башлыйсың. Әйе, белүләре бик читен. Әмма белмим дип әйтергә дә аның хакы юк. (Бу үз-үзеңә каты һәм гаделсез хөкем чыгару булыр иде.) Иң элек аның өчен көн кебек ачык бер хакыйкать шуннан гыйбарәт ки, сугыш артыннан ук укырга килгән яшьләр белән хәзерге абитуриентлар арасында искиткеч зур аерма бар. Бөтен җәһәттән. Сугыштан соң килгәннәрнең күпчелеге буйга кечкенә, арык, өс-башлары өтек, үзләре бик күндәм, тыйнак булса, хәзер килүчеләр барысы да диярлек озын буйлы, тук чырайлы, зәвык белән киенгән, үз-үзләренә нык ышанган, таза, чибәр егетләр һәм кызлар. Тегеләрдә белем чамалы, ә дәрт-теләк бик көчле булса, боларда инде белем бик күп, шунлыктан, ахры, кыюлык та, әрсезлек тә җитәрлек. Тегеләр университет бинасына, изге бер җиргә аяк баскандай, эчләреннән дулкынланып һәм чын күңелдән шатланып керсәләр, хәзергеләр исә хис-хыялларга артык бирелмичә, бары үтеп китү турында гына борчылып, бик эшлекле кыяфәттә килеп керәләр. Дөрес, университетка керү, сугыштан соңгы елларга караганда, шактый авырлашты, каты конкурс аша үтәргә кирәк, әмма үтә алганнар инде үзләрен судагы балык кебек хис итә башлыйлар. Алар арасында бик сәләтле яшьләр дә бар — киләчәктә алардан чын фән эшлеклеләре дә, зур белгечләр дә, һичшиксез, чыгачак. Ихтимал, үзләрендә шундый көч-куәт барын сизгәнгә күрәдер дә алар бик хөр кылыналар, фикердә, сүздә хөр — менә хикмәт нәрсәдә! Гүя аларның үз башлары эшли, үз хакыйкатьләре бар. Гүя алар бөтен кыланышлары белән сиңа: «Әнә үз предметыңны бел, башкасында эшең булмасын»,— дип әйтергә телиләр. Әлбәттә, мондый чакларда Гасыйм Сәләховичка бик ямансу булып китә торган иде. Ераклашу, ераклашу... шулай ук бу котылгысыз бер күренеш микәнни?! Хәтта үз балаңнан да!

Билгеле инде, ул Радикны Кырымга китүдән дә туктата алмады. Шул ук көнне клиникага барып, бу хакта сүз башлагач, Рәмзия ханым, гадәтенчә, уйлап-нитеп тормыйча гына:

— Ник тыясың, китсен! — диде.— Аңа да ял кирәк ич.

— Ләкин вакыты ул түгел бит! Син монда, мин анда ялгыз башым...

Рәмзия ханым шунда ук аның сүзен бүлде:

— Радикның ни гаебе бар соң, ул бит инде синең эшеңне эшләп йөрмәс.

— Эш андамыни,— диде Гасыйм Сәләхович, үртәлеп.— Үзем өчен әйтмим мин... Менә синең яныңа да кемдер килеп йөрергә тиеш бит әле.

— Ә мин эгоистка түгел, миңа кирәк булыр дип кенә Радикны иптәшләреннән аерырга һич тә теләмим.

— Ләкин моның авырлыгы миңа төшәчәк.

— Авыр булса син дә килмәссең... Ятармын әле шунда тол хатын кебек.

— Йа Хода! — дип куйды Гасыйм Сәләхович, ирексездән.— Ник син минем һәр сүземне кирегә тырныйсың да торасың? Менә киләм ич, тик миңа барысына да өлгерүе читен, аңлыйсыңмы шуны?

— Бик яхшы аңлыйм. Ләкин Радикны барыбер җибәрергә кирәк. Иптәшләреннән яхшы түгел, аның кай җире ким? Юк, барсын... Инде расходыннан курыксаң, акчасын да үзем рәтләп бирермен.

— Бусы тагын ни дигән сүз?

— Нигә, әллә мин белмимме?

— Нәрсәне?

— Синең саранлыгыңны... Шуңа күрә җибәрәсең килмидер әле.

— Их, Рәмзия, Рәмзия, ничек телең әйләнә! — диде Гасыйм Сәләхович тирән әрнү белән.— Аңлый алмыйм мин сине, җаный, әллә ни булды сиңа!

— Миңа берни дә булганы юк,— диде Рәмзия, гаепсез баладай елмаеп кына.— Ә менә син, дускай, чынлап та үзгәрдең... Картаясың, ахры...

— Ярый, шифаханә — сүз көрәштерү урыны түгел, китим булмаса,— диде Гасыйм Сәләхович, авыр гына урыныннан кузгалып.— Нәрсә китерим?

— Апельсин согы тапмассыңмы? Монда берәү хатынына китерде. Импортный икән... Аннары минем челтәрле бюстгалтерымны онытма әле, бик эссе була башлады. Шифоньерның уң тартмасында, өстә генә, күрерсең...

Гасыйм Сәләхович ярый-фәлән дип тормады, бары чарасыздан башын гына каккандай итте. Урамга чыккач, тел астына валидолын салды һәм иләсрәк бер хәлдә университетка таба атлады. Әйтергә кирәк, соңгы вакытларда аңа гасабилану, нервы бозу бер дә ярамый иде. Шунда ук йөрәккә суга, башына каба, җитмәсә, хәтере дә кинәт кенә югалып торгалый. Кеше сүзен тиз генә аңламый, алдында яткан әйберне дә күрми башлый. Иртәрәк килә түгелме соң әле бу зәхмәтләр?! Аңа бит әле илле тугыз яшь кенә — хәзерге безнең заман өчен әллә ни күп тә түгел шикелле... Дөрес, өч елга якын ул фронтта йөрде, шуның михнәт-газапларын кичерде, берничә тапкыр бик хәтәр хәлләргә дә юлыккалады, ләкин шулай да, бер авыр контузияне исәпләмәгәндә, кул-аягы бөтен килеш әйләнеп кайтты. Баш та ярыйсы, йөрәк тә тап-таза иде әле ул чакларда. Тик соңгы дүрт-биш ел эчендә генә бирешә башлады. Күрәсең, еллар үзенекен итә, какшата әкрен генә кешене... Аннары безнең бу тынгысыз, киеренке заман кеше өчен шактый куркыныч бер нәрсә китереп чыгарды — стресс дип атыйлар аны. Кинәт башка төшкән зур хәсрәттән яки һич көтелмәгән берәр күңелсез эштән була диләр ул явызны. Хәтта көтелмәгән зур шатлыктан да була, имеш, хәер, анысын инде, шәт, татырга туры да килмәс. Ә менә һәртөрле ямьсез эштән туганың Гасыйм абзаңа татырга туры килгәне бар. Дөрес, алар вак стресслар иде, көчек кебекләре генә, ләкин барыбер каты «тешлиләр», каһәрләр!

Рәмзия белән бүгенге сөйләшү дә әнә шундый көчектәй кечкенә стресс иде, ә шулай да Гасыйм Сәләховичның кәефен чынлап торып бозар өчен җитә калды һәм бик авыр уйлар да кузгатты. Күпме бергә гомер иткән ир белән хатын бер-берсен аңламасыннар әле — гаҗәп бит бу... Гүя икесе ике телдә сөйләшәләр! Бигрәк тә соңгы ике-өч елда алар арасындагы каршылык, аңлаша алмау ни сәбәптәндер аеруча ешаеп китте. Гасыйм Сәләхович торып-торып аптырый: әллә бу хатыннар кырык биштән узгач, психически үзгәрә башлыйлар микән? Менә аның Рәмзиясе кебек... Ни әйтсәң, шуңа каршы төшә, һәр сүзеңне гел кирегә бора, бернинди дәлилең аңа үтми дә, керми дә, юньләп тыңламый да әле ул сине! Шуның өстенә, Рәмзия аңардан унбер яшькә кечерәк, табигый инде, ул көйсезләнергә ярата, ул моны үзенең Ходай биргән хокукы дип саный, ә ир дигән кемсә, үзен яшь хатыннан яраттырасы килсә, һәрвакытта аның көенә торырга, аңа юл куярга тиеш. Гаделлекне, дөреслекне аяк астына салып булса да!

Иң аянычы тагын шул, Рәмзия ханым бөтен мәсьәләдә диярлек гел генә малае ягын каера, гел аны гына яклый. Дөресме, кирәкме, урынлымы — анда аның эше юк. Ул ана кеше, ул гына малаен аңлый, кызгана, ә син — деспот, син бары кысу, тыюны гына беләсең. Өстәвенә, җитмәсә, малае алдында еш кына көлеп тә, чынлап та, синең этиең инде шундыйрак та мондыйрак дип әйткәләп тә тора. (Әнә саранлыкны аңа таккан шикелле.) Ә малай яшь, кемнең хаклы-хаксыз булуын уйларлык акыл юк әле аңарда. Кем аның яклы, кем аңа файдалы — ул бары шуны гына белә. Табигый инде, ул күбрәк әнисенә елыша, үзенә кирәкне аның аша алырга тырыша. Ә этине тыңламаска да була, этидән курку юк. Әнә шулай бер-берсеннән читләшә, ераклаша ата белән бала.

Аптырый иде Гасыйм Сәләхович бу хәлгә, төрлечә уйлап карый иде; әллә Рәмзиядә җиткән улын этисеннән әзрәк көнләшү дә бар микән? Үзенеке генә итәргә тырышу, үзенә генә карату?.. Буламы шундый нәрсә хатыннарда?.. Ә, бәлки, аның үзендә дә берәр гаеп бардыр, берәр төрле хаталык эшләгәндер дә, тик ул аны эш, мәшәкать аркасында сизмичә калгандыр. Хәзер инде әйтүе читен, ләкин шулай да бер эпизодны яхшы хәтерли, чөнки аңа әле күп вакыт та узмады. Радик унынчыны бетергән елны, әнисе белән шундый сүз булып алды. Дөресрәге, Рәмзия үзе башлап аңардан сорады:

— Син Радикның кем булуын теләр идең?

Гасыйм Сәләхович үзенең язу өстәлендә нидер эшләп утырган җиреннән генә бары:

— Кеше булуын,— диде.

Менә шушы сүзгә Рәмзия ханым бөтенләй күтәрелеп бәрелә язды. Яман кызып, иренә:

— Ахмак, идиот! — диде.— Мин синнән аны сорыйммыни?! Ул болай да кеше, дүрт аяклы хайван түгел!

«Хайванның ике аяклысы да була»,— димәкче иде дә Гасыйм Сәләхович, ярый, тыелып кала белде. Рәмзия бит, асылда, улыбызны кайсы вузга кертәбез, кем итәбез, дип сорамакчы иде, ә ул акыллы

башланып, әнә нәрсә әйтеп ташлады. Ә соңыннан Рәмзия ханым улы алдында ничә тапкыр «әтиең кешегә дә санамый» дип кабатлады. Яхшы сүз дә кайчан баш казыгына әйләнә икән!

Әйе, сәер халык бу хатыннар җенесе, ике төпле, юк, өч төпле чемодан кебек, ниләр генә ятмыйдыр аның төпләрендә. Кайчагында шундый көтелмәгән берәр әкәмәт китереп чыгара, шаккатудан тәмам телсез каласың. Әнә бит Радикка акчаны да үзем табып бирермен ди! Күзен дә йоммый. Менә бу, ичмаса, «көлке!» Әйтерсең акчаны ул үзе таба!

Ярый, хәерле булсын! Барыбер хатын бик кирәк кеше, аңардан башка күңелсез, кызыксыз, әйләнәңдә шыксыз бушлык. Гаилә тормышына бер өйрәнгәч, башкача яшәү мөмкин дә түгел. Тик җайлаша, яраклаша белергә кирәк. Яраклаша белсәң, яшәп була, диләр күпне күргән агайлар!

Шул ук кичне Гасыйм Сәләхович малае алдына 250 сумны чыгарып салды да әйтте: «Менә сиңа акча, шуны җиткерергә тырыш, әйбәт кенә йөр, бәла-казага тарыма, кайда икәнеңне хәбәр итәрсең»,— диде. Егет бер сүз дә дәшмәде, тик аның йөзеннән: «То-то, старик!» дигән сыман елмаю гына чагылып узды. Икенче көнне үк ул рюкзагын аркасына киеп, фотоаппаратын муенына асып, үзе кебек хөр, горур егетләр һәм аларны иңнәренә таяндырып йөртүче чалбарлы кызлар белән бергә Кырымга — диңгез буендагы ташлар арасында кызынып ятарга китеп тә барды. Исән-сау гына йөри күрсеннәр инде, балакайлар! Исән йөрсәләр, башта акча сорап телеграммалары килер, аннары үзләре дә кояшта кара янган бәхетле кыяфәтләре белән кайтып төшәрләр.

## II

...Көне... Булыр икән бу хәтле дә теңкәгә тигән эсселек! Өченче атнага китте бит инде, зур бер афәткә әйләнмәсә ярар иде. Игеннәр ни хәлдә икән, ялан-кырлар, болыннар? Терлекләр дә интегә торгандыр... Чакырып кына китерәсеңмени шифалы яңгырларны... Юк шул әле, юк кешедә андый кодрәт!

Ә шулай да кузгалырга вакыт, күптән вакыт. Хатыны белән малае өйдә булса, уянгач болай карават читендә изрәп, иренеп утырыр идемени?! Ә ялгыз булгач менә утыра, берәүдән дә тартынмый, уңайсызланмый —үзенә күрә бәләкәй генә бер хөрлек! Дөресен генә әйткәндә, ялгызлык ул кадәр начар нәрсә дә түгел. Күпмегәдер семья ыгы-зыгысыннан котылып торасың, әзрәк җан тынычлана, үзалдыңа уйланып була, тып-тын бүлмәдә дөньясын онытып эшләп яки укып утырып та була. Йә, начармыни ул?! Тик менә хәлсезлек кенә борчымасын иде.

Гасыйм Сәләхович ике карават арасындагы тумбочка өстендә яткан сәгатенә үрелеп карады. Сәгать тугыз иде инде. Мәлҗеп озаграк та утырган икән, хәерсез. Унда инде аңа кафедрада булырга кирәк.

Карават башыннан зәңгәр буйлы киң пижама чалбарын алып киде, аякларына артсыз чүәкләрен эләктереп кенә кухняга чыкты да, газ плитасына ут кабызып, чәй кайнатырга куйды. Ванна бүлмәсенә кергәч, башта кулы белән ияген, яңагын ышкып карады, ләкин бүгенгә ярар әле дип, кырынып тормады. Аннары краннан суны шактый гына агызып торып, битен-күзен юарга кереште. Су барыбер көткәнчә салкын ук булып килмәде, шулай да әйбәтләп юынгач, бераз хәл кереп, җиңеләеп калды. Шуннан соң яңадан кухняга кереп, тиз генә ашый-эчә башлады. Билгеле, ашау ягы аның хәзер мактанырлык түгел иде. Кичтән калган бер күкәй, искерәк булки белән ак май, бер чәшке куе гына сөтле чәй — завтрак дигәне әлегә менә шул. Аннары сәгать 12 ләрдә, ачыга төшкәч, университет буфетында ул тагын җиңелчә генә бер тамак ялгап алачак әле. Инде эш беткәч, кайтышлый, сәгать 3 — 4 ләрдә «Татар ашлары»на кереп, татарча токмач белән татарча пешерелгән ит кисәге ашап чыгачак. Тик кай көннәрдә токмач та, ит тә беткән була — ашап бетерә халык. Шуңа бераз кәефсезләнә, мыгырдана Гасыйм абзаң, ләкин башка җиргә кереп тормый, чөнки «Татар ашлары»ннан башка җирдә аңа ярарлык ризыгы юк та диярлек (хек белән дуңгызны, гафу итсеннәр, аның нәфесе кабул итми)... Кайтышлый юл өстендәге магазиннан сөт, эремчек, каймак кебек азыклар сатып ала да өендә үзе бик әйбәтләп кенә сөтле токмач белән берәр төрле ботка пешереп ашый. Дөрес, карын канәгатьләнеп бетми бетүен, ләкин аның каравы йөрәгенә җиңел була. Аз ашасаң, күп яшәрсең, дигәннәр, имеш, безнең ерак бабайлар.

Гасыйм Сәләхович кыска җиңле саргылт күлмәген, яньчелә төшкән капрон эшләпәсен киеп һәм биге бозык иске зур портфелен күтәреп өеннән чыкканда сәгать ун тулып килә иде инде. Урамга чыгып, кояшка эләккәч тә ул аның агарган тимердәй кыздыруын тойды. Тизрәк күләгә якка күчте һәм ашыкмыйча гына урам буйлап атлады.

Бу урамнар буйлап Гасыйм Сәләхович менә утыз ел атлый инде. Шуның егерме елын кафедра мөдире буларак. Шулай уза гомер. Әмма ул үз эшеннән бик канәгать. Бөтен илгә исеме билгеле мәшһүр университет аның туган йортына әверелде дияргә дә ярый. Шунда үсте ул, шунда шактый зур дәрәҗәгә ирешде һәм тормышын тәэмин итәрлек матди җирлекне дә, үзенә кирәк мәгънәви азыкны шунда тапты. Билгеле, төрле чаклар да булды, төрле авырлыкны кичерергә, төрле кыенлыкларны җиңәргә дә туры килде аңа. Шунсыз бер генә хезмәт тә булмый торгандыр инде безнең заманда. Шулай ук кайбер максатына да ирешә алмады: мәсәлән, күпме генә уйланса-борчылса да докторлык диссертациясен, ахры, яза алмыйча калды. Ул бит тарихчы, тарихчының эше гадәттә зур күләмле, тарих өлкәсендә чын фәнни хезмәт тудырыр һәм нindидер яңа сүз әйтер өчен бик күп эзләнергә, тикшеренергә, уйланырга кирәк.

Тарихчыдан да күп нәрсә таләп итеlә хәзер. Ә ул яшьрәк, җегәрлерәк чакта, әйтик, илленче елларның башларында, тарих фәне өлкәсендә ниндидер бер торгынлык хөкем сөрә иде. Нидер көтү, тыелып тору, саклык күрсәтү хас иде тарихчыларга ул елларда. Менә ни өчен алар әзер программа нигезендә, тәкъдим ителгән дәреслекләр буенча студентларга лекцияләр укуны артыграк күрәләр иде. Җиңелрәк тә һәм хәвефсезрәк тә... Инде гыйльми дәрәҗә алыр өчен берәр хезмәт язарга кирәк булса, бу очракта да теманың отышлырагын, үтемлерәген сайларга тырышалар. Ә андый өстә генә яткан темалар һәрвакытта табыла, бар алар. (Фән әһелләре арасында «дежур тема» дигән төшенчә дә бар хәтта.)

Кыскасы, безнең Гасыйм Сәләхович та асылда әнә шул юл белән китте. Аспирантураны бетереп, университетта калгач, ул бик җигелеп һәм бик бирелеп студентлар белән шөгыльләнә башлады. Ә торабара кандидатлыгын яклап, ниһаять, кафедра мөдире булып алгач, инде укыту-тәрбия эшләре аның өчен төп хезмәт, төп йөк булып калды. Вакытын, көчен, акылын, хәтта сәламәтлеген дә беткәнче шуңа бирде. Үзе әйтмешли, университет белемле кадрлар әзерләп чыгаруга багышлады ул бар гомерен!

Әмма ләкин университет эчендә, шуның бер кешесе була торып, фәнни эшләрдән бөтенләй ваз кичү һич тә мөмкин түгел иде. Фәнни эшләр буенча кафедрада махсус план бар, шунда кемнең нәрсә эшләргә тиешлеге ачык язылган һәм бу планны үтәүне тәэмин итү Гасыйм абзаң җилкәсендә, беренче нәүбәттә аңардан сорыйлар. Шул сәбәпле аңа бу очракта да, үзе утырып язуга караганда, башкаларны эшләтергә, башкалардан таләп итәргә туры килә иде. Иң мөһиме кафедра үтәсен, кафедра үтәсә аның да йөзе ак — мөдир җитәкчелек итә белгән, диячәкләр.

Хәер, ул үзе дә каләм тибрәтмичә тормады торуын. Редакцияләрнең заказлары буенча төрле даталарга карата мәкаләләр, теге яки бу темага багышланган брошюралар, чыккан китапларга рецензияләр, кыскасы, шуның кебек вак нәрсәләр шактый күп язылды. Билгеле, болар да хезмәт, әмма алар гына җитми, канәгатьләндерә алмый иде Гасыйм Сәләховичны. «Галим» дигән исемне акларлык, горурланып кулга тотарлык җитди зур хезмәте (калын китабы) юк иде аның... Һәм бу «юклык» аның җанын гел иги дә тора иде. Бигрәк тә соңгы елларда, чөнки соңгы 10 — 15 ел эчендә тарих фәне бездә дә шактый җанланып китте, бер-бер артлы яңа хезмәтләр чыга башлады; һәм аеруча күзгә ташланганы — яңа яшь галимнәр үсеп, калкып чыкты. Өлгер һәм кыю галимнәр! Менә шуларның барысын да уйласаң, чынлап торып борчылмыйча хәлең юк. Артта калу дигән нәрсә бик хәтәр, иртәме-соңмы исемеңә дә, дәрәҗәңә дә китереп суга ул!

Ә бит аның күптән уйлап йөргән теләк-хыялы да бар иде. «Татарларда эшче сыйныфының тууы һәм формалашуы» дигән темага зур бер хезмәт язмакчы иде. Шуңа дип ничәмә еллар буенча, Петр патша заманыннан алып дигәндәй, күпме материал җыйнады ул!.. Әнә калын папкаларга тутырып бәйләгән килеш ярты шкафны биләп яталар... Әмма, ни кызганыч, шуны утырып тәртипкә салырга, эшкә кертергә, бөтен бер язма хәленә китерергә вакыт та, мөмкинлек тә таба алмады. Мөдирлек йотты аны. Хәер... бу үзеңне юатыр өчен генә әйтелгән сылтау түгелме? Кешеләр икесен дә сыйдыра лабаса! Ихтимал, аңа җитди хезмәт өчен кайбер сыйфатлар, әйтик, көчле теләк, тәвәккәллек, ниһаять, үзеңне мәҗбүр итә белү җитмәгәндер. Шуның өстенә тагын фикерне эшләтү, хыялны җигү, сәләтеңне сынау — иҗатны шулар кабындыра бит инде. Ничек кенә булмасын, ул һаман сузды да сузды һәм суза торгач, иң ганимәт вакытын уздырып та җибәрде. Дәртле һәм җегәрле чагын!

...Үтте инде, булмады, дип, бәлки, тынычланырга да ярагандыр, болай да эше начар түгел иде, ләкин ул һич тә тынычлана алмады. Үкенү, кимсенү, хәтта оялу аның җанын борчыды да торды. Ә борчылу бик кирәк нәрсә икән, борчылу ахыр чиктә кешене кузгата да ала икән. Башкаларга да гыйбрәт бу!.. Кыскасы, моннан өч ел элек Гасыйм Сәләхович үзенең ял айларында беркая да китмичә, тотты да шул папкаларын сүтеп актара-карый башлады. Материал бик күп, бик кызыклы иде; борынгы лашманчылардан алып, Уралдагы чуен коючылар, Каспийда балык тотучылар, Апшеронда нефть чыгаручылар, Донбасста күмер чабучыларга кадәр барысы да монда тупланган иде. Әмма бу хәтле материалны ничек кенә эшкәртеп чыгасы да, ничек итеп бер кулъязма хәленә китерәсе? Каян көч аласы да каян гына вакытын җиткерәсе? Мөмкин эшме бу?! Бер мәлгә яңадан күңеле сүрелеп, әллә ташларга микән дип тә уйлады Гасыйм Сәләхович, ләкин шулай да бер тотынгач аерыласы килмәде, кызганыч иде аерылуы, һичьюгы өлешчә файдаланып булмасмы дип, баш күтәрмичә утыра бирде һәм утыруның бер нәтиҗәсе булмыйча калмый ул. Менә Гасыйм абзаң да казына, уйлана торгач, шул тау чаклы материалдан йолкып алып, «Донбасста татар шахтерлары» дигән йөз кырык битлек монография сыман нәрсә дә язып ташлады. Өч ай эчендә! Соңыннан үзе дә гаҗәпләнә калды, шундый авыр башланган нәрсәне ничектер җиңел генә язды да чыкты. Донбасс бит татар кешесенә якын җир,—йөргән-таптаган, җырларына кергән җир,— бәлки, шул да ярдәм иткәндер. Нәтиҗәдә менә өч нөсхә итеп машинкада бастырылган, яңа таза папкага пөхтәләп салынган кулъязма аның өстәлендә ята! Бер дә икеләнмичә нәшриятка илт тә бир!

Әмма ләкин Гасыйм Сәләхович кулъязмасын йөгертеп илтергә ашыкмады. Нигә ашыгырга, бераз ятсын әле, күз алдында торсын, караштырыр, уйлаштырыр — кадерле, тансык бит әле ул аның үзенә дә! Ләкин анысыннан да битәр, кулъязманы кемнәндер укытып та алырга кирәк иде. Гәзитәдәге шикелле «свежий голова»дан һәм бик ышанычлы кешедән. Ягъни киңәш-күрсәтүләрен әйтерлек тә, шуның белән бергә автор теләгән аңларлык та булсын иде ул кеше!

Кем бар, кемгә ышанып бирергә мөмкин? Үз кафедрасындагы кешеләрнең берсе дә, билгеле, аның үтенечен кире какмаячак. Ләкин чынлап аны хөрмәт иткәне һәм чын сүзен әйтердәе кем булыр икән? Шактый уйланганнан соң, ул ахырда Идеал Ибәтович Шәйхиевне сайларга булды. Бу — кафедра профессоры, тарих фәннәре докторы, арада иң яшь галим һәм иң мөһиме — кайчандыр Гасыйм Сәләхович кул астында аспирантураны бетергән егет... Хәер, бу кадәресе бер яктан уңайсызрак та кебек, ләкин чынлабрак уйлаганда, моның һичбер гаебе дә юк шикелле... Шәйхиев аңа шәкерт булудан күптән узган инде, үзен бик баш иеп, бил бөгеп тә тормый ул. Әмма күңелендә аның элеккеге хәлфәсенә карата билгеле бер хөрмәт сакланган булырга тиеш. Димәк, хәерхаһлык күрсәтүенә дә ышанырга мөмкин.

Идеал Шәйхиев, гомумән, бик оригиналь шәхес. Искиткеч тырыш, басылып утыручы, бер генә минутын да бушка әрәм итмәс. (Университет китапханәсеннән хезмәткәрләр утларны сүндереп кумыйча, ул чыкмый да торган иде.) Коточкыч хәтер үзендә, тарихчы белергә тиешле йөзләрчә исемнәрне һәм даталарны ул күңелдән генә әйтә дә бирә. Башка ягы ничектер, әмма башы аның чынлап та идеальный корылган диярсгә була. Уйлап карагыз, бүтәннәр утыз елда да үтә алмаган юлны Идеал Шәйхиев ун-унике ел эчендә үтте дә китте: аспирантураны кандидатлык диссертациясен яклап бетерде, ә алты-җиде ел узуга докторлыгын яклап, әнә профессор да булды һәм үзенең моңа һич тә исе китмәде, киресенчә, шулай булырга тиеш ул дигән шикелле генә карады. Күпләр аны артык һавалы булуда гаеплиләр, хәлбуки бу аның үз-үзенә бик нык ышанудан килгән гадәти тотышы иде. Гомумән, ул аз сүзле кеше, тигез, тыныч холыклы, сүз көрәштерергә, шаулап бәхәсләшергә яратмый, әмма инде сөйләргә туры килсә, бик төпләп, дәлилләп, сеңдерерлек итеп үзенекен әйтә дә белә. Логика гаҗәп! Аның өчен фән бар, ул фәндә яши, өзлексез казына, эзләнә, өйрәнә һәм яза, күп яза. Үзәк журналларда аның мәкаләләре әледән-әле чыгып тора. (Тарихтагы тикшерenә торган төп өлкәсе — XVIII һәм XIX гасырларда Рус самодержавиесенең колониаль сәясәте, шул нигездә капитализмның үсү-җәелүе һәм бу процесска Россия эчендәге төрле халыкларның тартылуы.) Хәзер инде тугандаш республикаларда да профессор Идеал Шәйхиев дигән исемне яхшы ук беләләр. Әйе, һаваланырга хакы да бар егетнең!

Яшь галимнең бу уңышлары Гасыйм Сәләховичта ирексездән беркадәр көнчелек уятса да, ул шуңа карамастан аның өчен куана иде. Ярый, ул үзе кандидат кына булсын, фәндә зур казанышларга да ирешмәсен ди, ләкин дә бит Идеал аның шәкерте, аның кул астында шәп галим булып өлгерде бит әле Яңа бистә малае! (Шәйхиев үзе бу хакта ничегрәк уйлый торгандыр, ул кадәресен Гасыйм Сәләхович белми иде, әлбәттә.) Алай гына да түгел, Гасыйм абзаң нәкъ менә хәлфәләрчә Шәйхиевне үз урынына кафедра мөдире булып калачак бердәнбер лаек кеше итеп тә саный иде. Тик Шәйхиев үзе генә ни өчендер моңарчы мөдирлеккә бер дә омтылыш сиздермәде. Ихтимал, аңа мәшәкатьле эшкә башын тыкканчы, фән белән шөгыльләнү һәм лекцияләр укып кына йөрү файдалырактыр, шуны артыграк күрәдер, әмма Гасыйм абзый тагын үзенең беркатлылыгы белән моны шәкертнең хәлфәсенә конкурент булырга теләмәве дип кенә карый иде. Һәм, дөресен генә әйткәндә, яшь галимнең мөдирлеккә ашкынып тормавы Гасыйм Сәләхович өчен бик тә әйбәт иде. Һичьюгы тагын бер дүрт ел мөдирлектән төшмичә утырырга кирәк иде әле аңа!

Озын сүзнең кыскасы, Гасыйм Сәләхович үзенең кульязмасын Идеал Шәйхиевтән укытырга булды. Иң кулай кеше шул, әгәр баш тартмаса. Хәер, ни өчен баш тартырга тиеш?.. Юк, тартмас, күрсәтмәс ул андый сансызлыкны кафедра мөдире Гасыйм абзасына! Тик җаен-форсатын туры китереп, дәрәҗәне төшермичә генә сөйләшергә кирәк үзе белән, һәм Шәйхиев аның янына кереп, бер сөйләшеп утырганда, Гасыйм Сәләхович сүз ахырында гына сорады аңардан:

— Идеал Ибәтович, әгәр мин сезгә бер эшемне карап чыгарга бирсәм, ничек, вакытыгыз булырмы?

Һәрвакыттагыча яхшы кара костюм, чиста ак күлмәк кигән, арык кына урта буйлы, какча битле, әмма калку маңгайлы Шәйхиев үз нәүбәтендә тыныч кына сорады:

— Нәрсә ул?

— Донбасс турында... Дөресрәге, татарларның Донбасс шахталарына кай заманда бара башлаулары турында, ничек дим, тарихи бер күзәтү... Исеме дә «Донбасста татар шахтерлары» дип атала. Күләме зур түгел, вакытыгызны күп алмас дип уйлыйм.

Шәйхиев дәшми торыбрак тагын сорады:

— Минем бурыч нидән гыйбарәт?

— Сездән мин, Идеал туган, бер генә нәрсә ишетәсем килә: кульязма шушы хәлендә нәшриятка тәкъдим итәрлекме-түгелме?

Шәйхиев көлемсерәп куйды:

— Нәшрият үзенчә хөкем итәчәк.

— Әлбәттә... Сүз бары тәкъдим итеп карау турында гына бара. Мин моны үзем дә эшли алам, билгеле, ләкин сез бит нәшрият белән күбрәк эш иткән кеше, аларның таләпләрен яхшырак беләсез!

Шәйхиев бераз гына уйланып торды. Аннары:

— Яхшы,— диде һәм папканы кулына алды.— Карап чыгармын.

— Рәхмәт, туган! — диде Гасыйм Сәләхович һәм шуның белән сүз дә бетте. Шактый ук коры килеп чыкты бу сөйләшү, шул сәбәпле киңәшегез-фәлән булса дип тә сүз озынайтып тормады. Тик Шәйхиев чыгып киткәч кенә артыннан көрсенеп: «Үзенә күрә түгел егет!» — дип калды.

Ә өч көннән соң яшь профессор кульязманы китереп тә бирде. (Эшне тиз тотарга ярата иде ул.) Папканы «Дипломат» дип йөртелгән өр-яңа сай гына тартмадан чыгарып:

— Укыдым,— диде.— Минемчә, бу хезмәтегезне нәшриятка тәкъдим итәргә ярый, Гасыйм Сәләхович!

— Рәхмәт, туган!.. Биреп карыйм алайса...

— Бирегез.

Гасыйм Сәләхович әз генә сүз табалмыйчарак торды.

— Бәлки, замечаниеләрегез бардыр, Идеал Ибәтович? Мин, рәхәтләнеп дигәндәй, әзер...

Шәйхиев бик мәгънәле генә итеп елмайды.

— Сез бит миннән бер генә нәрсәне ишетергә теләдегез, Гасыйм Сәләхович? Шулай түгелме?

— Анысы шулай инде... Мин канәгать, тагын бер мәртәбә рәхмәт сезгә!

Аннары әзрәк вакытны сузар өчен генә аны-моны сөйләшкәләп утырдылар. Ә бер биш-алты минуттан Шәйхиев каядыр ашыккандай сәгатенә карап алды да, торып, баш кагып кына чыгып китте. Күрәсең, бу сөйләшү дә Гасыйм Сәләхович көткәнчә булып чыкмады. Янәсе ул бер генә нәрсә ишетергә теләгән?! Бу кадәр коры, рәсми булыр икән кеше! Бигрәк тә аның мәгънәле генә елмаюы Гасыйм Сәләховичка бер дә ошамады. Хәтта билгесез бер борчылу да тудырды.

Әмма соңыннан Шәйхиевнең «тәкъдим итәргә ярый» дию бушка булып чыкмады. Кульязманы нәшриятта кабул иттеләр, бик озакка сузмыйча укыдылар, ошаттылар, кемнәндер рецензия дә яздырып алдылар. Гүя кульязма тышындагы исеме белән үк үзенә юл ачты һәм менә бер ел үтүгә, күптән түгел, дөньяга басылып та чыкты. Йөз егерме битлек, катыргы тышлы, кулга тотарлык бер китап — һәм бу китап Гасыйм Сәләховичка чын канәгатьләнү белән бергә рухи бер җиңеллек тә китерде. Ниһаять, җаны тынычланып, үзенә ышанычы артып, өметләре яңадан кабынгандай булды. Ә бит аның яшенә җиткән һәм кафедра мөдире булып торган кеше өчен моның әһәмияте кечкенә түгел — баскан урынында әле селкенмичә нык торырга була дигән сүз!

Билгеле, Идеал Шәйхиевкә дә аның ышанычы яңадан артты, яңадан ныгыды. Теге вакытта егетнең сәер елмаюына әһәмият биргән булып, юкка гына борчылган икән. Просто балалык! Асылда, дөрес бәяли белгән яшь галим, аның хезмәтен тәкъдим итәргә ярый, дип, бик дөрес, бик урынлы әйткән. Кыскасы, Гасыйм Сәләховичның рәхмәте зур аңа!

Ул эчке кичерешләрен тышка чыгармаска өйрәнгән кеше. Шулай да бу юлы аңа куанычын яшерү җиңел булмады. Сүзләреннән сизелмәсә дә, моны аның йөзеннән күрергә мөмкин иде; гадәттә сытыграк чырайлы шешенке бите ничектер языла һәм яктыра төшкәндәй булды. Аннары китап магазинга чыккач та, берьюлы утыз данә сатып алып, шуларны кыска гына автограф белән кафедра кешеләренә һәм якын танышларына өләште. Бу да үзенә күрә шатлыгы белән уртаклашу иде. Барысы да рәхмәтләрен әйттеләр, кулын кыстылар. Ә соңрак аларның кайберләреннән ул «Бик кызыксынып укыдым», яки «Китабыгыз миңа бик ошады», яки «Бик кирәкле нәрсә язгансыз, Гасыйм Сәләхович» дигән кебек сүзләр дә ишеткәләде. Автор кеше бу мактау сүзләрен шактый ук ышанып кабул итте, чөнки аның фикеренчә, бер дә ошамаган китап турында берәү дә алай ялганлап әйтмәс, хәтта комплимент итеп тә.

...Тик иң теләгән кешесе Идеал Шәйхиевкә китабын тапшыра алганы юк әле. Китап сатуга чыккан көннәрдә генә яшь галим персональ чакыру буенча Болгариягә китеп барды. Шуннан соң өч атна чамасы вакыт үтеп китте, күптән кайткан да булырга тиеш, ә менә Гасыйм абзасына ни сәбәптер килеп күренгәне юк. Бу хәл Гасыйм Сәләховичны беркадәр гаҗәпләндерә дә, уйландыра да, ләкин үзе башлап аның өенә шалтыратырга уңайсызлана да иде. Шәйхиев берәр ерак җирдән кайтса, кафедрага кереп, исәнләшеп, күргәннәрен кыскача гына сөйләп чыга торган иде. Бу юлы ни үзе, ни хәбәре — гаҗәп! Теләсәң ни уйла!.. Шулай итеп, Гасыйм Сәләхович үзенең зур рәхмәтен һәм хөрмәтен титул битенә язып, махсус әзерләп куйган китабын аңа тапшыра алмыйча менә күпме вакыт портфелендә саклап йөртергә мәҗбүр... Кызыксызрак килеп чыкты әле бу, хәерсез!.. Хәзер инде аның шатлыгы да, дәрте дә шактый сүрелде. Кәефе дә шәп түгел... Ләкин ул китабын барыбер тапшырыр, бүген булмаса — иртәгә!

## III

Университетның таш идәнле караңгырак вестибюленә килеп кергәч тә, Гасыйм Сәләхович җиңеләеп бер сулап куйды. Тыштагы эсселек монда юк, һава монда салкынчарак иде. Тәненнән бигрәк йөрәге белән сизде ул моны.

Имтиханнар бетеп, студентларның таралыр вакыты җитсә дә, университет коридорларында шаулашып, ашыгып йөрүче яшьләр күп иде әле. Билгеле, аларның барысында да хәзер йә эшкә, йә ялга китү кайгысы — шуның белән мәш килеп йөриләр. Ә гомумән исә, бу коридорларның бушап торган чаклары булмый да диярлек. Менә озакламый читтән торып укучылар киләчәк, аннары университетка керергә теләүче яшь кенә егетләр һәм кызлар монда әйләнә-тулгана башлаячак, ә күпмедер вакыттан соң йөзләренә өмет, шик, каушау чыккан шул яшь абитуриентлар аудитория ишек төпләренә җыелачак.

Елдан-ел кабатлана бу хәрәкәт, университет күпме яшәсә, шулчаклы дәвам итә ул! Кайберәүләр яшь кенә студент булып керәләр дә ап-ак сакаллы галим булып чыгып китәләр моннан — вакыт һәм язмышлар әнә шулай өзлексез агып һәм алмашынып тормакта бу таш бина эчендә!

...Кояшлы көн яктысыннан килеп кергәч, аеруча караңгырак булып күренгән озын коридор буйлап Гасыйм Сәләхович үзенең кафедрасына таба атлады. Очраган танышлары белән баш кагып кына исәнләшеп узды. Инде үз бүлмәсенә кереп, капрон эшләпәсен чөйгә элеп, өстәле янына килгәч, ул башта таза, иркен креслосында җәелә биреп, бераз хәл алып, тик кенә утырды. Бер-ике генә минут шулай тугарылып утыруга ул соңгы вакытларда гына ничектер гадәтләнеп киткән иде. Күрәсең, бу аның йөрәге белән бәйләнгәндер инде. Аннары гына ул эшкә күчә, уйлый һәм хәрәкәт итә башлый һәм тиз арада йөрәк тә, хәлсезлек тә — барысы да онытыла. Бары тик эш кенә кала, ә эш сыналган дәва, яшәтә ул кешене!

Алгы бүлмәдә утыручы лаборант кыз көндәге тәртип буенча бүген дә яңа гәзитәләрне аның өстәленә кертеп куйган иде. Гасыйм Сәләхович, эше бик тыгыз булмаса, аларны шунда ук караштырып чыга, инде вакыты юк икән, барысын бөкләп портфеленә тыга да, өенә кайткач, ашыкмыйча иркенләп карый.

Бүген исә ул гәзитәләрне хәзер үк ачып, күздән бер кичерергә булды. Башта, билгеле, Мәскәү гәзитәләрен карап чыкты. Алардагы кыскарак хәбәрләрне тиз генә укыштырды да үзе өчен әһәмиятле булган җитдирәк мәкаләләрне кайткач укырга дип калдырды. Шуннан соң үзебезнең гәзитәләргә күчте. Гадәтенчә, ул аларны ахыргы битеннән карый башлый — төрле яңалыклар, кызыклы хәбәрләр күбрәк шушы биттә табыла. Шулай ук бу биттә ара-тирә булгалап торган кара сызыклар эчендәге кайгылы белдерү дә аның игътибарын җәлеп итмичә калмый —кайчагында күз күргән яки колак ишеткән кешеләр дә очрап куя бу кара сызыклар эчендә. Әмма Гасыйм Сәләхович үзе үлем турында уйларга да, сөйләргә дә бер дә яратмый.

...Инде менә «Татарстан»ның икенче, өченче битләре. Чит ил хәбәрләре, хуҗалыкка караган мәкаләләр, алдынгыларга багышланган язмалар... Тукта, ә бусы нәрсә?.. «Донбасста татарлар». Гаҗәп таныш исем ич бу!.. Ә исемнән өстәрәк, ваграк хәрефләр белән бер читтә «Тәнкыйть-библиография» диеп тә куелган. Димәк, рецензия, аның китабы турында рецензия бу! Ә кем язган?.. Гасыйм Сәләхович тиз генә мәкаләнең ахырына күз төшерде: профессор Идеал Шәйхиев! Алай-й икән, хөрмәтле Идеал Шәйхиев аның китабы турында рецензия язып чыккан икән ләбаса! Рәхмәт төшкере!

Гасыйм Сәләхович гәзитәне урталай бөкләп, алдына салып, кечерәк подвал итеп басылган мәкаләне бик игътибар белән ашыкмыйча гына укырга кереште. Баш күтәрмичә һәр җөмләсен, һәр сүзен, хәтта юллар арасында әйтелмичә калганын да аңларга тырышып укыды. Кайбер төшләрен кайтадан укып карады. Ниһаять, укып бетерде һәм бик нык уйга калды Гасыйм абзаң!.. Хуш, ничегрәк аңларга бу мәкаләне? Китапка ниндирәк бәя бирә хөрмәтле рецензент? Мактыймы, яманлыймы?.. Хәер, монда артык юрап маташыр нәрсә юк та шикелле... Әгәр аның катлаулы җөмләләре белән бик фәнчә итәргә тырышып язганнарын гадиләштереп, кеше аңларлык телгә күчерсәң, түбәндәге төп нәтиҗә үзеннән-үзе диярлек килә дә чыга: ягъни «Донбасста татар шахтерлары» дигән бу әсәр чын мәгънәсендә фәнни хезмәт түгел, имеш! Менә шул. Дөрес, Шәйхиев китапны яманламый. Киресенчә, укыр өчен кызыклы, гыйбрәтле китап, ди. Тик хикмәт шунда, имеш, бу китап, башлыча, җирсезлектән интеккән ярлы татар агайларының Донбасска отхожый эшкә китәргә мәҗбүр булуларын бик тәфсилләп язган бер беллетристика сыман нәрсә булып чыккан, янәсе... Чын фәнни хезмәт булыр өчен аңа теге җитми, бу җитми, имеш, анысы онытылган, монысы ачылмаган, анализ йомшак, гомумиләштерү зәгыйфь, кыскасы, китапка карата рецензиядән әнә шуның кебек тәнкыйть сүзләрен күп чүпләргә була. Дөрес, фәннәр докторы үзенең каты хөкемен мөмкин кадәр такт саклап, аябрак әйтергә тырыша, моның өчен еш кына «хәлбуки», «безгә калса», «кызганычка каршы» кебек буфер ролен үтәрдәй сүзләр дә куллана, әмма ләкин күпме генә йомшартып маташмасын, төп нәтиҗә һаман шул бернәрсәгә кайтып кала: Гасыйм абзаңның бу хезмәте хәзерге фән таләпләренә җавап бирүдән ерак тора икән әле... Менә шулай ул, кем, автор иптәш!

...Озак утырды Гасыйм Сәләхович алдында яткан гәзитәгә текәлеп, һәм ул бу минуттагы хәлен ничек кенә дип атарга да белми иде. Әллә авыр аңа, әллә түгел, әллә инде барыбер?! Хәер, барыбер булуы һич мөмкин түгел, чөнки рецензияне иң ышанган кешесе язган, һәм шик тә юк ки, аның зарарына язган. Әмма шул ук вакытта ул Идеал Шәйхиевкә бертөрле дә гаеп ташлый алмый иде. Менә нәрсә аны тирән бер аптырауга төшерде. Йә, ничек итеп, нәрсәдә гаепли ала ул аны?.. Икейөзлелектәме?.. Әйе, Шәйхиев кулъязманы укыганнан соң менә монда язып чыккан фикерләренең берсен дә аңа әйтмәгән иде. Ләкин бит ул үзенең шулчакта биргән киңәшенә каршы да килми ич! Кулъязманы нәшриятка тапшырырга да, бастырып чыгарырга яраган, хәтта әнә китапның укыр өчен кызыклы, гыйбрәтле булуын да әйткән! Кайда монда икейөзлелек?.. Юк, тагып булмый аңа бу гаепне!.. Тик шул гына, теге вакытта үзенең чын, асыл фикерләрен әйтеп торуны кирәк дип тапмаган. Ни өчен? Әйе, ни өчен, нигә яшергән? Бәлки, ул кулъязманы сүтеп ташларга теләмәгәндер (кызганган Гасыйм абзасын!), ә, бәлки, әйтеп торудан файда юк, бу карттан шуннан да артыгын көтеп булмый дип уйлагандыр. Бик мөмкин моның шулай булуы... Теге вакытта аның йөзендә чагылган мәгънәле елмаю да нәкъ менә шуны раслый түгелме?!

Кинәт күңеленә килгән бу уйдан Гасыйм Сәләхович үзен ничектер бик кечерәеп калган шикелле хис итте. Ниндидер мескенлек, нәүмизлек аның җанын биләп алды. Күңелендә ирексездән яшь галимгә рәнҗү

хисе уянды. Ни әйтсәң дә, Гасыйм абзасы аны кайчандыр укыткан кеше бит әле, остазы, хәлфә хакы бар бит әле, аңардан башка бүтән тәнкыйть итүче табылмас идемени? Ә ул, профессор, яшь галим, бик югарыдан торып: «Җитте сиңа, абзый, иярдән төшәргә вакыт!» — дип әйтә кебек.

Хәер, ник әйтмәсен?.. Хәлфә-шәкерт төшенчәсе хәзер инде бер анахронизмга әйләнеп бара. Алар, Шәйхиевләр килә, хәтәр килә, юл бирмәсәң, күрәләтә таптап та узарлар. Нәрсә ул аерым кеше язмышы! Алар өчен иң югары максат — фән, ә фән ул һәртөрле исәп-хисаплардан өстен торырга тиеш. Йә, алар хаклы түгелме?! Юк, картайдың син, картайдың, хөрмәтле мөдир!

Гасыйм Сәләховичның хәзерге минуттагы рухи хәлен бер генә сүз белән билгеләргә була, бу — апатия. Дөньясына, эшенә, үзенә, ниндидер Шәйхиевләргә — барысына да салкын битарафлык. Кызыксыз, мәгънәсез, кирәксез... Шушы минутта, шушы сәгатьтә... Аннары үтәр, иншалла, үтәр! Тик болай бөкрәеп утырмаска, торырга, хәрәкәтләнергә кирәк. Йөрәгенә дә хәрәкәт кирәк... Иң яхшысы, чыгып китеп, бераз йөреп кайту — монда хәзергә әле ашыгыч эше дә юк. Кешеләр килеп кергәләгәнче — югыйсә тегесе яки бусы килеп керер дә хәл-әхвәл сорашкан булыр, гәзитәне укыганнары гаҗәпләнүләрен, хөрмәтле Шәйхиев белән килешеп бетмәүләрен белдергән булырлар... Юк, юк, кирәкми, Алла хакы өчен икейөзлеләнмәсеннәр! Берсенеке дә бик җиткән!

Гасыйм Сәләхович сәгатенә карап алды — унике тулган икән инде. Халыкның нәкъ мыжгыган чагы... Ул алдында яткан гәзитәне бөкләп, башкалары өстенә куйды, ләкин кеше күрмәсен дип, ахры, кире алып, өстәл тартмасына салды. Аннары барып, чөйдән калай шикелле яньчелеп каткан эшләпәсен алып киде. Ах, белсәгез иде аның бу капроннан туйганын! Юк бит электәге башка сихәтле салам эшләпә!..

Портфелен алып, кабинетыннан чыккач, алгы бүлмәдә утыручы лаборант кызга узышлый гына: «Мин клиникага киттем, бер-ике сәгатьтән кайтырмын»,— диде. Кыз аның хәлен аңлагандай башын кагып: «Ярый, Гасыйм абый, ярый!» — дип калды. Ә Гасыйм абзасы инде шунда ук үкенеп тә куйды: «Нигә әле мин кая баруымны әйтеп торам?.. Сораган бер кешегә клиникага китте дияр, ә сораучы эченнән генә: «Әһә, Шәйхиев тәнкыйтен күтәрә алмаган икән»,— дип уйлар... Минем кебек тә хәйлә белмәс кеше бар микән?!» Ләкин шуның артыннан ук ул үзен тиргәргә дә тотынды: «Нишләп әле мин җыен чепухага игътибар итә башладым? Хатынның клиникада ятканын белмиләрме соң... Юк белән баш ватасың, карт тиле!»

Дөрес, хатын янына барырга бик иртә иде әле. Анда сәгать дүрттән соң гына кертә башлыйлар. Хәер, Рәмзия ханым аяк өстендәге авыру, чакырткач, үзе дә чыгар. Бүген барыбер аның янына барасы көн. Аннары, кеше күп булмаса, бәлки, ул үзе дә врачка күренер. Йөрәгенең әледән-әле борчып торуыннан бер кереп зарланырга кирәктер бит инде, кешеләр әнә эчләре катса да тизрәк врачка йөгерәләр.

Гасыйм Сәләхович як-ягына каранмыйча гына озын коридор буйлап узды, кемнәрдер аңа баш иде, ул да таныса-танымаса да баш иде, ахырда менә яп-якты урамга да килеп чыкты... Ну көне... Пешерә генә. Тынны куыра... Яктысыннан күзләр камаша... Һава эретеп агызган кургашындай тик тора. Ник бер генә яфрак селкенсен! Яңгырга гына булса ярар иде! Алай дисәң, төпсез күк йөзе чалт аяз... Килеп чыкмый бит шул Ослан таулары артыннан кәҗә тиресе хәтле генә бер кара болыт!.. Ә барырга, әлсерәп булса да, барырга кирәк... кирәк... Ул трамвайга утырыр өчен университет урамы буйлап түбән төшеп китте. Тротуарның кояшка караган җирләре йомшарган, аяк батып киткәли хәтта.

Шәһәр урамында бик сакланып йөрергә кирәклеген Гасыйм Сәләхович һәрвакытта исендә тота торган иде. Бу юлы исә ул һәртөрле куркынычны онытып, бары өйрәнелгән гадәт буенча гына башын уңга-сулга борды да, ашыкмыйча гына киң, хәтәр урам аша чыга башлады. Алдыннан һәм артыннан выжлап машиналар узды, әмма ул аларга юньләп игътибар да итмәде. Тукталышка килде, трамвайга утырды, ә трамвай аны үргә таба алып менеп китте. Бер кыз бала торып аңа урын бирде (рәхмәт төшкере!), Гасыйм Сәләхович, утырып, вагон тәрәзәсеннән урамга карады. Ул тыныч иде, ул һични уйламый иде, ул урамда ниләр барын да күрми иде шикелле. Көзгедә чагылгандай күзләреннән йортлар, агачлар, кешеләр үтә, әгәр шуларның берәрсе таныш кеше булса, ул аны да, ихтимал, күрми-танымый узар иде. Ләкин шулай да бу әле аның чын хәле түгел, чын хәле аның үз эчендә, каядыр тирәндә. Иң элек ул бер генә минутка да Идеал Шәйхиевне оныта алмый. Идеал Шәйхиев гүя бер адым калмыйча аңа ияреп бара, һәм Гасыйм Сәләхович теләсә-теләмәсә дә аның турында уйланырга мәҗбүр иде. Уйланып гаҗәпләнергә һәм ирексезләп рәнҗергә мәҗбүр иде. Ничек кенә булмасын, башта чын фикереңне әйтмичә яшерү, соңыннан шуны язып чыгу бу егетлек түгел. Бу куркаклык һәм түбәнлек! Аннары ни өчен ул, Шәйхиев, менә өч атна инде кафедрага килмичә, күренмичә йөри? Намусы кушмыймы әллә?.. Юк, ул андый кеше түгел, салкын, рационалист кеше ул, намус аның өчен абстракт төшенчә генә... Хәер, килеп күренмәве яхшы да булган икән. Югыйсә Гасыйм абзасы аңа дип саклап йөрткән китабын түбәнчелек белән тапшырган да булыр иде. Ярый ходай саклаган! Әмма барыбер аларга очрашырга туры киләчәк. Ник шул чакта бәхәскә кермәскә (керүдән ни мәгънә?), сер сынатмаска, бәйсезлек, тынычлык сакларга иде. Тик шуңа көче җитсен иде аның!

...Трамвай урам чатына җитеп туктады, халык төшә башлады, ул да агымга ияреп төште. Чехов базары аша үткән чакта хатынына дип бакчачылардан бер кило виктория җиләге сатып алды. Шуны үзе белән йөртә торган салафан капка салдырды да урам ашасындагы клиникага таба атлады. Башта ул үзен кабул итә торган врачка кермәкче булды, ләкин аның врачы бүген сәгать икедән генә кабул итә башлаячак икән.

Шуннан соң ул ишегалды аша гына авырулар ята торган стационарга узды һәм түбәндә утыручы сестрадан хатынын дәшеп чыгаруны үтенде. Сестра аны таный иде, шуңа күрә, вакытсызрак килгән булса да, сүзен тыңлады.

Гасыйм Сәләхович бер читтәрәк торган дерматин тышлы киң генә йомшак эскәмиягә барып утырды, эшләпәсен салып янына куйды, шактый керләнгән кулъяулыгын чыгарып, маңгаен, муенын сөрткәләде. Монда, таш бина эчендә, аз гына салкынчарак иде, тын алуы да җиңелрәк иде... Озак та үтми, соры халаттан гына Рәмзия ханым да килеп чыкты. Больница киеме кешене гадәттә авыру итеп кенә түгел, килбәтсез итеп тә күрсәтә. Авыру ирләр бу хәл белән ничектер килешсәләр дә, хатын-кызлар, бигрәк тә яшьрәкләре, бер дә килешергә теләмиләр, күрәсең. Менә Рәмзия ханым да өстендәге котсыз халатын гәүдәсенә сыланганчы урап, билен фланель билбавы белән шундый кысып бәйләгән — озын аяклары да, җәелә төшкән янбашлары да, тулы күкрәкләре дә йомры-калку булып, бик ачык беленеп тора. Кыскасы, эссе дип тормаган, сакларга тырышкан фигурасын... Шулай ук бакыр төсенә кертеп буяган чәчләренең прическасы да һаман шул килеш, матур килеш тора икән әле... Озынчарак куллары да әнә нинди ак, йомшак — төче генә бер ис тә аңкый үзләреннән. Әлбәттә, хатынының шушылай пөхтә, чиста, чибәр булуына һәрбер җаны бар ир сокланмыйча, хәтта дәртләнмичә калмас иде, әмма Гасыйм Сәләхович Рәмзия ханымның бу котыртып торырлык килеш-килбәтенә гүя бөтенләй игътибар да итмәде. Хәер, игътибар итте итүен, ләкин гаҗәеп бер салкынлык һәм битарафлык белән генә... Гүя хатынының бу байлыклары бер дә аның өчен түгел иде. Хәтта көнләшү дә кузгалмады аңарда — кузгалырга иренде, ахрысы.

Янәшә утырышкач, Гасыйм Сәләхович, күрешергә килгән ир буларак, башлап үзе сүлпән генә сорады:

— Йә, ничек соң... хәлең?

Рәмзия ханым да, гадәтенчә, туры гына «яхшы» яки «начар» дип әйтмичә, башта әзрәк зарланып алды; үткән төнне начар йоклаган икән, шуңардан бүген менә башы авырткан. Ә хәзер?.. Ә хәзер үтте кебек... Әлбәттә, үткән булырга тиеш... Кайчан чыгасың, дип сорады ире, тезләренә таянган килеш кенә.

— Ахрысы, озак тотмаслар,— дип зарланды Рәмзия ханым.— Урын кирәк, диләр. Үзләренең берәр дус-ишләренәдер инде. Бөтен җирдә блат, җаным!

— Нигә, үзеңнең чыгасың килмимени?

— Килсә дә бит, бер кергәч барысын да белеп чыгасы иде. Кат-кат кереп булмый монда.

— Врачлар белеп чыгара торганнардыр инде.

— Сиңа шул врач сүзе генә сүз,— диде Рәмзия ханым, турсая биреп,— ә минем хәлемдә кайгың юк синең...

Гасыйм Сәләхович дәшмәде. Сүз көрәштерергә аның һич кенә дә теләге юк иде. Врачлар турында әйтү дә кирәк булмаган. Ни пычагыма?!

Менә ул көнаралаш диярлек килә, китә, ә Рәмзиянең бер генә тапкыр да аның үз хәле турында сорашканы юк. Ничек яши ул ялгызы, үзен ничек хис итә, эшендәниләр бар? Ник бер юри генә сорап карасын! Бәлки, зарланганны көтә торгандыр. Ә Гасыйм Сәләхович зарлана алмый, һәм иң гаҗәбе — нәкъ менә хатынына зарлана алмый ул. Сәбәп?.. Моны аңлатуы да читен. Кыскасы, үзеннән күп яшь һәм шактый ваемсыз хатынын борчымаска теләп, ә, бәлки, аның алдында дәрәҗәсен төшерүдән куркып та, ул Рәмзиягә эше-хезмәте, бигрәк тә сәламәтлеге турында зарланудан һәрвакытта тыелып килде һәм шушы нәрсә ничектер ирексездән аның гадәтенә дә кереп калды. Куанычын уртаклаша ала, әмма кайгысын — юк, сөйли алмый. Ләкин бит сөйләмәсә дә сизәргә, күрергә мөмкиндер инде, кешенең йөзенә карап та! Сукыр булмаса... Хәер, күрсә дә, бәлки, әһәмият бирми торгандыр. Кем ул ир дигән кемсә? Эш аты. Аттан да бит кәефең ничек, берәр җирең авыртмыймы, дип сорамыйлар. Селкенәме — селкенә, тартамы — тарта, тагын ни кирәк?!

Рәмзия ханым малае турында сорады:

— Радиктан хат юкмы?

— Юк.

— Бу ни эш, киткәннән бирле бер хаты юк. Син шул бала өчен борчыласыңмы әзрәк?

— Бала түгел, җиткән егет,— диде Гасыйм Сәләхович.

— Ата диген инде... Бу хәтле дә таш йөрәк булырсың икән!

— Мин аның исән-сау кайтуына ышанам,— диде Гасыйм Сәләхович, ничектер бик кистереп.

Рәмзия ханым иреннәрен кысарга мәҗбүр булды, тик бераздан гына үзалдына хафалангандай:

— Акчасы да җитмәс инде балакаемның,— дип куйды.

— Җитмәсә, телеграммасы килер, борчылма!.. Акчадамыни эш? Менә көннәр бик кызуга китте әле...— Гасыйм Сәләхович эшләпәсен алып җилпенә башлады. Бите аның тимгел-тимгел кызарып һәм бүртенеп тә киткән төсле иде. Аннары кинәт кенә сүнгән хәлсез тавыш белән: — Мин кайтыйм инде булмаса! — диде.

— Нигә, миңа бернәрсә дә алып килмәдеңмени? — диде Рәмзия ханым, аз гына көлемсерәп.

— Да... бөтенләй онытып җибәргәнмен.— Гасыйм Сәләхович артындарак торган салафан капны алып, хатынына сузды.— Виктория. Әле генә базардан алдым.

— Рәхмәт инде... Ә мин кушканны китердеңме соң?

— Нәрсә иде ул?

— Минем челтәр бюстгальтерымны?

— Нәрсә-ә?

— Бюстгальтерны, дим... Челтәрен...

Гасыйм Сәләхович һичнәрсә аңламыйча, кашларын җыерып, хатынына карап тора башлады. Бюстгальтер!.. Бик мәгънәсез бер әйбер турында сүз бара түгелме?.. Каян белсен, хәтерләсен ул аны?! Шундый бер чүпне!

Рәмзия ханымның кинәт аңа ачуы килеп китте:

— Нәрсә син, аңгыра сарык шикелле, миңа карап торасың? Бюстгальтерның нәрсә икәнен белмисеңме әллә?

— Белмим! — диде Гасыйм Сәләхович, хатыныннан күзләрен ала алмыйча.

— Нигә, студенткалар түшендә бер дә күргәнең юкмыни? — диде Рәмзия ханым, юри шаркылдап.

Гасыйм Сәләховичның йөзе, каны качкандай, кинәт агарынып китте. Әллә һава җитмәгәннән, әллә нидер әйтмәкче булып авызын ачты, нигәдер бик кызганыч итеп бер елмаеп та алды, әмма ни дә булса әйтә алудан узган бер хәлдә, авыр гына торып, бөкрәеп, ишеккә таба атлады. Аяк атлаулары бик сәер, бик кыюсыз иде аның —хәтта Рәмзия ханым да моңа игътибар итте. Ләкин ирексездән борчылып куйса да, ирен шулай да туктатып тормады.

Урамга чыккач, Гасыйм Сәләхович бик аз гына вакытка туктарга мәҗбүр булды. Ашыгырга ярамый иде аңа. Йөрәк менә тире астында гына тибә кебек, бер авырттырып кыса, бер җибәрә, бер кыса, бер җибәрә... Хәтәр иде бу... Тизрәк валидол кабарга теләп кесәсенә тыгылды, ләкин анысы да онытылып калган булып чыкты. «Өйгә, тизрәк өйгә!» — диде ул үз-үзенә һәм әкрен-сак кына атлап китте. Башы да бераз әйләнә кебек, шунлыктан ара-тирә чайкалып та киткәли иде.

Үз хәленең бөтен җитдилеген яхшы аңласа да, ул ни өчендер шушында ук врачка күренергә кирәк дип уйлый белмәде. Күңеле аны нигәдер өенә тартты. Ә бит аның кәефе иртәдән үк начар иде, эшенә баргач, Шәйхиев мәкаләсе кәефен тагы да ныграк бозды — бозу гына түгел, бәгърен тирән яралады. Шулар өстенә тагын Рәмзия белән менә бу мәгънәсез сөйләшү! Җиткән иде аңа, бик җиткән иде, кирәкми иде аңа, агудай кечкенә, әмма бик хәтәр бу соңгы тамчы!

...Көн әүвәлгечә аяусыз эссе иде. Эссе генә түгел, гаять бөркү-тынчу да иде. Һава һич селкенмичә, шылт та итмичә бөтен нәрсәне басып, изеп тик тора. Моның кебек авыр, тын, хәрәкәтсез һава бары яшенле яңгыр яки көчле давыл алдыннан гына булырга мөмкин, һәм, ныграк игътибар итсәң, көн чынлап та үзгәрмәкче иде шикелле... Әнә еракта Иделдән дә ары, тауларга охшап тик кенә торган ак читле кара-зәңгәр болытлар күренә. Юк, алар, чынлабрак баксаң, тик кенә тормыйлар икән, алар һаман кабара баргандай үсәләр, куералар һәм бик әкрен генә болай таба авышалар да иде... Әмма Гасыйм Сәләхович боларның берсен дә күрми иде, эсселеккә дә, сәер тынлыкка да бөтенләй игътибар итми иде, аның бөтен кайгысы — тизрәк өенә кайтып җитү иде.

Үз йортларына җитеп, өченче катка туктый-туктый менгәнче, ул тәмам тиргә батты, калтыранган кулы белән ишекнең ике биген азаплана-азаплана ачты, эчкә узды, шулай да кире борылып, чылбыр бикне генә булса да эләктереп куярга онытмады. Аннары үз бүлмәсенә узып, эшләпәсен һәм портфелен диванга ыргытты да, сөйрәлеп кенә өстәле янындагы күн төпле креслосына барып утырды. Аңа хәзер үк берәр дару кабу кирәк иде, ул үзе дә моны бик яхшы белә иде, ләкин ни өчендер ашыкмады — чак кына хәл аласы, бер-ике генә тапкыр булса да тирән итеп һава сулыйсы килде. Нәкъ шул чакта каядыр бик еракта кинәт тау ишелгәндәй дәһшәтле гөрселдәп, көчәя барып, озак итеп күк күкрәде һәм нәкъ шул ук мизгелдә Гасыйм Сәләховичның йөрәгенә әйтерсең уттай кызган пычак китереп тыктылар. Кискен, көйдергеч авыртудан яман коты алынып, авызын зур ачып, креслосына чатыр ябышты, көзән тарткандай киерелеп артка каерылды, бугазыннан гыжлап әллә тавыш, әллә һава чыккандай булды, ләкин шул секундта ук гәүдәсе капчыктай бушап, күзләре сүнеп туктап та калды. Тик бераздан гына аның башы үзеннән-үзе күкрәгенә кире салынып төште. Тагын еракта отыры дәһшәтлерәк, катырак итеп күк күкрәде, якынлашып килгән давыллы яңгырның беренче кискен җиле урам агачларын сыгып, шаулатып узды, ләкин Гасыйм Сәләхович өчен дөнья тып-тын, дөнья юкка чыккан иде инде.

Ә давыл артыннан килгән бәрәкәтле яңгыр тәүлек буена бер әкренәеп, бер шәбәеп туры гына яуды да яуды. Көчле җилдән бүлмәнең урам тәрәзәсе ачылып калган иде, өйгә яңгыр шавы белән бергә дымлы салкынча һава тулды. Гасыйм Сәләхович шул рәхәт җиләстә тынычланып ял иткәндәй, үзенең креслосында, башын игән килеш, берьялгызы тып-тын гына утыра бирде.

Әле беркем дә бернәрсә дә белми иде.

1978

# Кыз һәм сәгать

Бер купеда икәүдән-икәү генә чәй эчә-эчә сөйләшеп бара торгач, безнең сүз шактый тирәнгә кереп китте. Без кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр турында, ачыграк әйткәндә, кешегә карата сак, сизгер, гадел булуның әһәмияте турында сөйләшә башладык. Билгеле инде, бу мавыктыргыч тема. Тормышта бит бик гыйбрәтле хәлләр тулып ята. Яхшысыннан, яманыннан гаҗәп мисаллар табарга мөмкин. Минә шуларның төрлесеннән ишеткән-күргәннәрне искә төшергәли торгач, Сәлим Галимович сөйләячәк хикәянең очы килеп чыкты.

Инженер Сәлим Галимович минем юлдашым, менә Бөгелмәдән кайтышлый бер купеда туры килеп, танышып киттек. Куе чәчләре юл-юл булып агарса да, бу әле кыяфәткә бик егәрле, чиста-шома битле, мәһабәт-таза кеше иде.

Мин инде аның үз башыннан кичергән вакыйганы ни өчен, нәрсәгә мисал итеп сөйләвен әйтеп тормыйм, ул кадәресе хикәя барышыннан болай да аңлашылыр. Ләкин шуны ачык әйтергә кирәк, Сәлим Галимович үзенең хикәясенә ни өчендер бик кыенсынып, ничектер теләр-теләмәс кенә кереште. Күрәсең, сөйләячәк вакыйгасы бик үк күңелледән түгел иде. Шулай да, бер очы чыккач, сөйләмичә булдыра алмады. Мин дә, билгеле, зур кызыксыну белән көтүемне яшереп тормадым.

Сәлим Галимович, эчкән стаканын арырак этәреп куйды да, кырын ята төшеп, миңа беравык, нидер уйланып, карап торды. Аннары яңадан турайды һәм, ныклы карарга килгәндәй, тәвәккәл генә:

— Ярый, мин сезгә вакыйганың үзен сөйлим алайса,— диде.— Бер дә арттырмыйча, киметмичә — нәкъ булганча гына. Ә вакыйга менә ничек булды: былтыр көз, Сочида ял иткәннән соң, мин өйгә икенче бер яңа маршрут белән кайтырга уйладым.

Гел поездда йөрү туйдырган иде... Мин мондый маршрут билгеләдем: Сочидан Анапага чаклы пароходта, Анападан Краснодарга чаклы автобуста барырга, ә Краснодардан Казанга инде самолетта кайтырга... Максат диңгездә дә йөрү, бай Кубань кырларын да карап узу һәм бигрәк тә Краснодар белән танышу иде. Күрәсез, ниятем бик яхшыдан иде. Кызганычка каршы, Азов диңгезендә йөри торган пароходлар,— ә Анапага бары шулар гына керәләр,— шактый кечкенәләр икән. Мин үземә аерым каюта ала алмадым. Яхшы урыннар беткән иде. Икенче классның ике кешелек каютасына билет алырга туры килде.

Пароход иртән сәгать унбердә китәргә тиеш. Мин, унбиш минут калганда килеп, үз каютама урнаштым. Каюта болай ярыйсы гына, үзенә күрә җиһазы да бар, ятар урыны да ипле, йомшак кына... Сез беләсезме икән, диңгез пароходларының каюталары безнең Идел пароходларыныкына бер дә охшамаган. Анда бөтен нәрсә таза, нык һәм — шунысы әһәмиятле — барлык әйберләр һич селкенмәслек итеп стенага яки идәнгә беркетелгән булалар. Хәтта өстәлдәге графин-стаканнар да махсус кыршаулар эченә тутырылган...

Аннары каюталар гадәттә түбәндә, пароходны диңгездән юка тимер стена гына аерып тора. Кыскасы, диңгезнең никадәр усал, хәтәр нәрсә икәнен кечкенә пароходка кереп урнашкач та сизә башлыйсың.

Мин ишектән сул яктагы койканы үземә алдым. Икенче койка буш әле, хуҗасы юк... Язмыш кемне миңа юлдаш итәр,— хәзергә билгесез... Мин, чемоданымны койка астына куеп, плащымны баш очындагы чөйгә элдем дә каютадан чыктым. Палубага күтәрелдем. Пароход кузгалырга бик аз вакыт калган, соңгы пассажирлар ашыгып басмадан менәләр. Менә иң соңгыларның берсе булып нәзек кенә, көяз генә бер кыз, җиңел чемоданын һәм чәчәкләр бәйләмен селкә-селкә, басмадан йөгереп менде. Түбәннән аны тап-тар яшел чалбар, вак шакмаклы соры пиджак кигән егет озатып калды... Пароход соңгы тапкыр көр тавыш белән һаваны калтыратып үкерде һәм кузгала башлады... Егет түбәннән нидер кычкырды, кулы белән авызыннан кызга үбү юллады... Кыз да югарыдан очынып, нәфис бармакларын иреннәнә кат-кат тидереп, егеткә бер-бер артлы тәмле үбүләрен җибәрде. Шактый кайнар саубуллаштылар болар. Нишлисең, яшьлек, абзыкаем!

Шулай да бу җилбәзәк кызый миңа әллә ничек кенә бик шикле күренде. Була бит әле кәеф-сафа артыннан куарга яратучы берише «хөр» яшьләр,— соңгы елларда менә шундыйлар курорт шәһәрләрендә шактый күбәеп киттеләр. Көндезләрен алар пляжларда аунап яталар. Кичләрен рестораннарны басып алалар, ләкин кем исәбенә, нинди акчага болай рәхәттә гизә торганнардыр,—Хода белсен! Мин үзем, мәсәлән, егерме ел инженер булып йөреп, бары кырыктан узгач кына курортка бара алу бәхетенә ирештем. Шуңадыр, ахры, мин ул маймыллар төшерелгән күлмәкләр киеп, кыска тар балактан йөрүче егетләргә һәм шуларның беләкләренә асылынып, ярым шәрә йөрүче кызларга шикләнеп, ят күреп, өнәмичә карый торган идем.

Менә бу кызый да миңа шундыйларның берсе булып тоелды. Кулга ияләшкән бер тутый коштыр инде, дип уйлап куйдым мин, ихтыярсыздан. Хәер, болай уйларга һичбер нигезем юклыгын үзем шунда ук сиздем һәм бу читен каршылыктан котылыр өчен кызга юри игътибар итмәскә тырыштым.

Пароход причалдан бераз ераклашкач та, мин түбән төштем: юлдашым кем икән,— тизрәк шуны беләсем килде. Ләкин каютаны ачсам, берәү дә юк, берәү дә кермәгән... Һе, мин әйтәм, ялгыз гына баруны теләгән идең, менә теләгеңә ирештең шикелле!.. Ләкин шулай дип уйларга да өлгермәдем, каютага әлеге кыз килеп керде.

— Шушы бит 8 нче каюта?

— Әйе, шушы! — дидем мин, кызга сарык төсле текәлеп. Кыз каюта эченнән җитез генә бер күз йөртеп чыкты.

— Димәк, сез дә монда барасыз?

— Әйе, мин дә...

— Ну что же...— дип куйды кыз, бер дә исе китмичә генә. Аннары шундый ук бер хөрлек һәм ваемсызлык белән бу үзенчә урнаша башлады. Чәчәкләр бәйләмен өстәлдәге стаканга утыртып куйды. Җип-җиңел чемоданын аягы белән генә койка астына этәреп җибәрде. Өстендәге пальто дисәң, пальто түгел, жакет дисәң, жакет түгел, исемен дә белмим, галәмәт киң, кыска, иңбашсыз нәрсәсен салып, койкасына ташлады. Аннары стенадагы көзгегә карап, битен-күзен тикшерде, малайларныкы төсле итеп кенә кыркылган җирән чәчләрен рәтләштерде һәм шул чакта сорап куйды:

— Сез еракка мы?

— Анапага чаклы... Ә сез?

— Мин Ростовка.

Көзге каршында эшен бетергәч, бу миңа борылып: «Менә барысы да тәртиптә!» — дигән төсле карап алды. Шуннан: «Ачкыч кайда булыр?» — дип сорады да каютадан чыгып та китте. Мин баскан җиремнән кузгалмыйча торып калдым.

...Сез елмаерга ашыкмагыз әле! Бәлкем, менә нинди шәп юлдашка тап булдыгыз, дип әйтергә телисездер? Юк, һич юк, чын күңелдән әйтәм, мин куана алмадым. Киресенчә, бу уйнак сылу кыз мине борчуга гына салды. Мин бит нигәдер юлдашым ир кеше булыр дип бик ышанып тора идем. Бер үк каютага ир белән ят хатын-кызга билет сатарлар дигән уй башыма да килмәде. Инде менә, юри үчекләгән шикелле, яныма яшь боландай кызны китерделәр дә керттеләр. Әйтәсе дә юк, шәп сюрприз! Хәзер, рәхим итеп, шуның көенә генә җайлашып, үзеңне гел киеренке бер хәлдә хис итеп бар инде. Юк, ошамады бу нәрсә миңа, һич ошамады. Вәсвәсәгә бирелүдән мин курыкмыйм, әлбәттә, ул җәһәттән нервларым таза, чыдарлык, әмма шулай да курорт тирәсендә йөргән мондый кызлардан ераграк булуың хәерлерәк... Кыскасы, юлдашым миңа кулай кеше булып чыкмады...

...Кыз чыгып киткәч, башны кашып бераз тордым да, үзем дә чыгып йөрергә булдым. Ачкычны коридорда дежур торучы хатынга тапшырып, югары күтәрелдем. Җил чыккан, пароход акрын гына чайкалып, ак сыртлы дулкыннарны ерып бара. Диңгез, диңгез! Очы да юк, кырые да юк, тик уң яклап аксыл яр сызыгы һәм шул сызыктан ук күтәрелеп киткән берсеннән-берсе биегрәк кучкыл яшел яки ялангач соры мәһабәт таулар күренә...

Минем иң элек пароход белән яхшылап танышасым килде. Кулымны артка куеп, бер очыннан икенче очына каранып йөрергә тотындым. Бер җирен калдырмадым, керергә мөмкин булган бөтен почмакларына кереп чыктым. Бер башында буфет, икенче башында салон кебек нәрсәсе бар икән, аларына да кереп күз салып чыктым.

Шулай каранып йөргән чакта кызымны да очраттым. Ул пароход койрыгында ике егет белән бик кәефле генә сөйләшеп тора иде. Егетләр әлеге шул мин әйткән «хөр» яшьләрдән булса кирәк. Өсләрендә әтәч тиресеннән теккәндәй үтә күренмәле заграничный плащ, аякларында калын табанлы зур ботинкалар, үзләре яланбаш, кыска гына итеп кыркылган чәчләре, керпе энәләредәй, үрә басып тора. Кызым үз ишләрен тапкан икән, яхшы булган, дидем мин эчемнән.

...Вакыт бик акрын уза. Йөри-йөри дә арыдым. Нигәдер эч тә поша башлады. Ялгыз сәфәр, бигрәк тә пароходта, шактый күңелсез нәрсә икән ул... Ахырда вакытны «үтерер» өчен салонга керергә булдым. Шунда юанып утырырмын, ашаган-эчкән арада, бәлкем, үзем кебек берәр кеше белән танышып, сөйләшеп тә китәрмен дип уйладым.

Салонда халык аз иде. Тәрәзәгә якын аулак бер өстәлгә утырдым да, менюны алып, ашыкмыйча гына блюдо һәм шешәләрне «өйрәнергә» керештем. Шунысы яхшы бу Кавказ ягында, ашлар күптөрле, эчемлекләр күптөрле, җаның теләгәнен сайлап алырга була.

Мин үзем эчүдән саклана торган кеше. Олыгая башлагач бигрәк тә... Әмма шулай да ара-тирә үземне сыйларга яраткалыйм. Менә курорттан кайтып барам, тазалык Аллага шөкер, бернинди эш, вазифа, мәҗбүрият белән бәйләнмәгәнмен,— үземә үзем хуҗа! Җитмәсә, диңгез пароходының шәп салонында утырам. Монда инде, дус кеше, шикәр сипкән эремчек ашап утырып булмый!

Кыскасы, алдымда басып торган ак алъяпкычлы официанткага закускалардан анысын-монысын һәм кавказларның «пити» дип йөртелгән ашларын яздырдым. Бу соңгысы, ничек кенә аңлатыйм, ни... һәркемгә аерым чүлмәктә, симез ит янына һәртөрле әче-төчеләр салып әзерләнә торган, аз гына шулпалы гаҗәп тәмле бер аш шунда... Инде болар өстенә тагын 150 грамм гына биш йолдызны да китерергә куштым,— беләсезме, шунсыз әлеге «пити» үз урынына иплән ятмас кебек, шайтан алгыры!..

...Ярый, бусы болай гына, хикмәт анда түгел, тизрәк төп вагыйгага якынлашыйк. Хәер, бу сөйләгәннәрнең билгеле бер әһәмияте бар, соңыннан үзегез дә күрерсез.

Бераздан официантка минем алдыма маен, икрасын, балыгын һәм башкаларын китереп тезде. Мин ашыкмыйча гына эшкә керештем... Әйткәнемчә, теләгем — матур гына итеп, озак кына юанып утыру...

...Пароходны уйнап кына тирбәткән кыргый диңгез, аулак, чиста урын, тансык ашлар һәм бик таман гына төшкән «биш йолдыз» — һәммәсе дә тора-бара минем кәефемне тәмам яхшыртты. Эч пошуның эзе дә калмады, тәрәзәдән Кавказга карап, бик хуш-мәмнүн булып барам. Хәтта юлдаш кызым турында да матур уйлый башладым. В конце концов, мин әйтәм, аңардан миңа ни зарар, туры килгән икән инде, хәерле булсын! Үзе болай ипле, ачык кына күренә, сөйләндереп карарга кирәк булыр, дим. Сочидан кайтып баручы туташның ни уйлаганын, ни теләгәнен белү кызык ич!

Ниһаять, мин ашау-эчүне тәмамладым. Бу вакытта палубада ниндидер җанлану башланды, халык күбәеп китте. Сәгатемә карадым: өченче ярты икән. Нәкъ ике сәгать утырганмын... Официантка белән исәп-хисапны өзеп, мин дә палубага чыктым. Туапсега якынлашып киләбез икән, халык шуңа урыныннан купкан.

Пароход портка кереп туктагач, мин дә, халыкка ияреп, ярга чыктым. Көн кояшлы булса да, җылы түгел иде. Таулар арасыннан безнең якның чиркандыргыч җиле исә. Шәһәр кечкенә, якын-тирәдә кызыгып карар бернәрсә дә юк... Яр буйлап әрле-бирле йөргәләдем, шул чакта нигәдер кинәт үлеп йокым килә башлады. Тукта, мин әйтәм, җилдә болай куырылып йөргәнче, керим дә рәхәтләнеп бер йоклыйм әле, дим. Сәгатемә карадым,—вакыт өч тулган икән инде.

Пароходка күтәрелгәч, мин, яңадан салонга кереп, бер шешә сыра эчтем. Шуннан соң минем күзләрем тәмам йомыла башлады. Пароходның кузгалганын да көтмичә, мин үземнең каютага төшеп киттем. Безнең каюта коридорның иң очында, бик тыныч җирдә, шунда ук ачкычлар алып-биреп торучы хатын да утыра.

Мин аңа керешли әйттем әле:

— Йоклап алмакчы булам,— дидем.

— Рәхим итегез!

— Ләкин,— мин әйтәм,— минем бер юлдаш кызым бар. Ишекне эчтән бикләсәм, ул керә алмас, нишлим икән?

— Ә сез бикләмәгез, монда берәү дә йөрми, мин гел шушында утырам, тыныч булыгыз! — диде дежур хатын.

Шуннан мин кердем дә, чишенеп торып, урыныма яттым. Ничә минут узганын да хәтерләмим,— бишек шикелле сиртмәле урынга яту белән сеңеп тә киткәнмен... Һәм үлек кебек йоклаганмын, хәтта бер генә тапкыр борылмаганмын да.

Бер заман уянып китсәм, каюта эче дөм караңгы. Ай-һай, мин әйтәм, йокының кирәген биргәнмен икән, дим. Кимендә бер дүрт сәгать йоклаганмын, ахрысы. Торып утырдым. Баш тонган, шактый изрәгәнмен, һаман әле йокыдан айнып җитә алмыйм. Бераз оеп утырганнан соң, үрелеп утны кабыздым һәм сәгатемне карамакчы булдым. Ләкин сәгатем кулымда юк. Хәер, мин беркайчан да сәгатьне салмыйча йокларга ятмыйм, һәрвакыт өстәлгә яки янымдагы урындыкка салып куям. Бу минем бик күптән килгән гадәтем...

Баш очымдагы креслода салган киемнәрем ята, иң элек сәгатьне шуннан карадым... Юк... Торып, өстәл өстен карадым,— сәгать анда да юк. Бу ни эш? Яңадан киемнәремне берәм-берәм күтәреп, селкеп карадым, чүгәләп креслоның гына түгел, койканың да астын җентекләп карадым, тагын бер кат өстәл өстен тикшереп чыктым, әмма сәгать юк кына бит. Гаҗәп, гаҗәп! Ни уйларга да белмим...

Шуннан киендем, креслога утырдым һәм кереп ятканчыга кадәр булган хәлләрне бик җентекләп исемә төшерә башладым. Сез беләсез инде, сәгатем минем бар иде. Кулымда иде. Пароходка утыргач, мин күпме тапкыр аңа карадым. Соңгы мәртәбә Туапсе портында, пароходка керер алдыннан гына карап, вакытның өч икәнен белдем. Шуннан соң салонда бер шешә сыра эчтем дә каютага төштем. Берәү белән дә очрашмадым, сөйләшмәдем, йөрмәдем. Димәк, каютага кергәндә дә сәгатем кулымда булган! Бу — бәхәссез!..

Ләкин менә каютага кергәч, мин аны салдыммы, салсам — кая куйдым,— бу кадәргесен һич хәтерли алмыйм. Акылымны ничаклы гына җиксәм дә, хәтерли алмыйм... Күрәсең, сәгатьне салып кую минем өчен шундый бер күнегелгән, механик рәвештә генә үтәлә торган эшкә әйләнгән инде, мин ничек салуыма да, кая куюыма да игътибар итеп тормаганмын... Әмма ләкин ул сәгать, шайтан алгыры, барыбер шушында булырга тиеш ләбаса! Аякланып чыгып китмәс бит инде! Кайда соң ул?

Яңадан бер кат бөтен каюта эчен бетереп, эзләп чыктым. Ләкин юк, сәгать юк! Димәк, кемдер алган, кемдер шушыннан, каютадан урлап чыккан. Дөрес түгелме, әйтегезче?.. Мин моны үзем башкача аңлый алмыйм. Чынлап та бит, сәгатем бар иде, кулда иде — бу кадәресе минем өчен көн кебек ачык!.. Шулай булгач, бер генә нәтиҗә ясарга кала: сәгатемне мин йоклаганда урлаганнар!.. Кем, ничек итеп — Хода белсен!..

...Урлаган бер тапкыр гөнаһлы, урлаткан ун тапкыр гөнаһлы диләрме әле? Дөрес сүз икән! Каютадан чыкмыйча, креслога утырып, мин бу хәлнең ничек булуын уйларга керештем. Һәм, нәкъ шул мәкаль әйткәнчә, минем шигем берьюлы берничә кешегә төште. Иң элек, коридордагы дежур хатын алмадымы икән, дип уйладым. Аннары юлдаш кызым исемә төште, мөгаен, шул кереп, эләктереп чыккандыр, дип уйладым. Ләкин, ныграк уйлаганнан соң, боларның икесеннән дә шикләнү миңа нигезсез булып тоелды. Бигрәк тә дежур хатыннан шикләнү читен иде, чөнки алардан гаять гадел булу таләп итеlә, кечкенә

җинаять өчен дә аларны бер минут тотмыйча эшләреннән куалар. Инде юлдаш кызга килгәндә, шигем бөтенләй үк бетмәсе дә, тәгаен шулдыр дип уйларга батырчылык итә алмыйм. Яхшы гына киенгән, чибәр, интеллигент кыяфәтле бер кызның шундый әшәкелеккә бара алуына ничектер ышанасы килми... Хәер, кем белсен аны! Яхшы киенгән чибәрләр арасында аларның ниндиләре очрамый! Менә Сочидан кайтып бара, акчасы беткәндер, ә гадәтләнгәнчә тәмледән генә ашыйсы-эчәсе киләдер... Алай дисәң, хәзер генә ул минем сәгатем белән нишли алсын?

Ихтимал, мин йоклаган чакта бүтән берәү, берәр жулик каютага кереп, сәгатьне эләктереп чыккандыр. Моның өчен күп вакыт кирәкмени? Ә дежур хатынның берәр яры китеп торган чагы булгандыр. Шул чакта керде алды — вәссәлам! Кыскасы, теләсәң кем өстенә уйларга мөмкин, әмма тотылмаган — карак түгел...

...Инде нишләргә? Сәгать урлату әллә ни зур каза түгел, билгеле,— артык уфтанмаска да була... Әмма шулай да факт үзе, урлау факты, минем ачуымны гаять кузгатты. Гомумән талау, урлау, хулиганлык кебек җинаятьләрне мин һич кичерә алмыйм, андый җинаять эшләүчеләргә һич рәхим-шәфкать юк миндә... Кызган тимер белән көйдереп бетерер идем мин аларны!.. Хәзер исә бу ачу-нәфрәт, бик табигый буларак, минем эчемдә бөтенләй кайный башлады. Чөнки сәгать кайчандыр якын дустым биргән минем өчен бик кадерле бер бүләк тә иде... Мин аны табарга да тиеш идем!

...Мин киенеп, рәтләнеп каютадан чыктым. Коридорда дежур хатынны очраттым, ләкин аңа бер сүз әйтмичә, югары менеп киттем. Башта буфетка кереп, бер стакан кара кофе эчтем, аннары, чыгып, арлы-бирле пароход буйлап йөрергә тотындым...

Уем билгеле инде, һаман бер тирәдә: кемнең эше булыр бу? Ничектер, теләсәм-теләмәсәм дә, һәрбер начаррак киенгән яки шиклерәк күренгән кешегә: «Урлаучы шушы түгелме икән?» — дип карап уза башладым... Әшәкелек инде бу, әлбәттә, ләкин баягы сүз: урлатучы ун тапкыр гөнаһлырак!.. Хәер, минем урынымда һәр кеше шулай шикләнеп карар иде. Пароходта баручылардан кем дә булса «берәү» урлаган бит инде сәгатьне!

Табуыма һич ышанмасам да, булган казага ничек тә җиңел карарга тырышсам да, мин бу хәлне шулай да пароходның командасына җиткерергә уйладым. Эзләгез, табыгыз дип түгел, ә аларның пароходында каютага кереп әйбер урлау кебек җинаятьнең булуын белсеннәр дип әйтәсем килде. Кечкенә факт түгел бит! Бүген берәүнең сәгатен урларлар, иртәгә икенче берәүнең чемоданын алып чыгарлар яки берәрсен киемсез шыр ялангач калдырырлар... Юк, моның кебек кабахәтлекне белми калмасыннар әле!

Радиорубканың ишеге ачык иде. Шунда ике кешенең сөйләшеп утыруын күреп, мин тукталдым. Болар миңа игътибар иткәч, әдәп белән генә сорадым:

— Гафу итегез, миңа капитан үзе яки аның ярдәмчесе кирәк иде, берәрсен күрергә мөмкин булмасмы?

Кара китель, ак фуражка кигән озын гына егет торып:

— Менә мин капитанның ярдәмчесе булам, ни йомыш? — диде.

Мин эчкә керергә рөхсәт итүләрен сорадым. Кергәч, аяк өсте генә вакыйганы сөйләп бирдем. Капитан ярдәмчесе бик игътибар белән тыңлады. Аннары кем булуымны, кайдан кая баруымны сорашты. Ул мин хәбәр иткән вакыйгага зур әһәмият бирде булса кирәк, чөнки яңадан кабатлап барысын да сорашып чыкты. Ахырдан:

— Сез бу хакта беркемгә дә сөйләмәдегезме әле? — диде.

— Юк, сөйләгәнем юк,— дидем мин.

— Яхшы иткәнсез... Ә хәзер каютагызга барыйк!

Без түбән төшеп киттек, каютага кердек. Мин аңа эшнең ничек булганын әйтеп бирдем: менә шушы креслода киемнәрем иде, сәгатемне йә шулар өстенә, йә өстәлгә куйган булырга тиешмен.

— Тәгаен кая куюыгызны хәтерләмисезмени? — диде капитан ярдәмчесе.

— Кызганычка каршы, тәгаен генә хәтерләмим, әмма сәгатемне салып, йә креслога, йә өстәлгә куюымда һич шигем юк, чөнки бу минем күптән килгән гадәтем,—дидем мин.

Шуннан капитан ярдәмчесе каютаны дикъкать белән күздән бер кичерде дә дежур хатынны чакырып алды. Үзе креслога утырып, аңардан сораша башлады:

— Сез бу каютада кемнәр барганын беләсезме?

— Беләм: менә бу иптәш, тагын бер кыз бара.

— Нинди кыз ул, кайда утырды, билетын карадыгызмы?

— Карадым. Сочида утырды.

— Бергә утырдылармы?

— Юк, бергә түгел...

— Ә шулай да ниндрәк кыз соң ул?

Хатын иңбашын җыерып куйды.

— Ничек дим? Яшь бер кыз инде, чибәр генә болай... өс-башы да простойдан түгел, модный...

— Кайда ул хәзер?..

— Белмим...

Капитан ярдәмчесе аз гына тынып торды да яңадан сораша башлады:

— Сез менә бу иптәшнең, Туапседан кузгалгач, йокларга ятканын белдегезме?
— Белдем. Ул үзе әйтте.
— Каюта ишеген бикләп яттымы?
— Юк, бикләмәде. Икенче пассажир бар бит.
— Яхшы. Ул йоклаганда каютага кем дә булса кермәдеме?
— Юк шикелле,— диде хатын, уйланып, аннан кинәт исенә төшергәндәй өстәп куйды: — Да, теге кыз гына кереп чыкты.
— Кайсы кыз?
— Бу каютада баручы пассажир кыз инде.
— Алай икән,— диде капитан ярдәмчесе һәм миңа күтәрелеп карады: — Сез аның кергәнен сиздегезме?
— Юк, һич сизмәдем,— дидем мин.
Капитан ярдәмчесе тагын хатынга борылды.
— Кыз үзе генә идеме?
— Юк, ни... бер егет белән керделәр.
— Так, так... Ә нигә аны башта ук әйтмәдегез?
— Дежур хатын кызарды, ни әйтергә белмичә ык-мык итеп калды.
— Кем ул, ниндирәк егет, өс-башы, кыяфәте? — диде капитан ярдәмчесе, шактый кырыс кына.
Бу допросның ни өчен икәнен аңламаган хатын тәмам каушап төште. Сүзләрен рәтләп әйтә алмас булды.
— Ә-ә, ни, кем дим? Ну менә таза бер егет. Сезнең төслерәк...
— Нишләделәр алар монда, озак тордыларлармы?
— Нишләделәрме?.. Белмим шул, карап тормадым, иптәш капитан!
— Ни сөйләшкәннәрен дә ишетмәдегезме?
Хатын башын гына селекте.
— Чыккач кая киттеләр?
— Югары менеп...
— Ә ул егет үзе кайсы класста бара?
— Белмим... Ләкин миндә... монда түгел.
— Капитан ярдәмчесе хатынга җитди, сынаулы карашын төбәп торды да соңгы соравын бирде:
— Так, бүтән керүче кеше булмады дисез?
— Юк, булмады.
— Бәлки, сез күрми калгансыздыр?
— Ничек күрмичә калыйм икән? Мин бит һаман шушында, беркая да киткәнем юк. Белмим, белмим,— диде хатын, башын чайкап,— керүче булса, күрми калмас идем.
Капитан ярдәмчесе, башын иеп, тагын нәрсә сорыйсы калды дигәндәй уйланып торды, аннары яңадан хатынга күтәрелеп карады.
— Ни өчен мин сездән боларны сорыйм?.. Менә иптәш пассажирның йоклаганда кемдер сәгатен урлаган.
— Йа Аллам,— дип уйлап куйды хатын, сизелерлек агарынып.— Чынлапмы?
— Чынлап ди шул! Гомердә безнең пароходта булмаган хәл... Позор!.. Ярый, барыгыз, ләкин бу турыда беркемгә бер сүз әйтмәгез! Аңладыгызмы?
Хатын раслап башын какты һәм чыгып китте. Без икәү генә калдык.
— Йә! — диде капитан ярдәмчесе, миңа борылып.—Менә ишетеп тордыгыз. Нинди нәтиҗә ясарга мөмкин?
Дөресен генә әйткәндә, минем нәтиҗәм әзер иде инде: кыз белән егетнең каютага кереп чыгуын ишеткәч тә, мин эчемнән: «Ну, хәзер аңлашылды, мотлака шулар эше генә бу!», дип бик өздереп уйлап куйган идем. Һәм капитан ярдәмчесенә дә шуны әйттем:
— Мәсьәлә, минемчә, ачык. Шул кыз белән егет турында гына уйларга кала.
— Сәгатьне алар алган димәкче буласызмы?
— Әлбәттә!
Капитан ярдәмчесе, кашларын җыерып, бераз дәшми торды.
— Әмма шулай да тәгаен алар дип әйтергә безнең нигезебез җитәрлек түгел бит. Кем күргән, кем исбат итә ала аны?
— Әйе, күрүче юк, анысы дөрес,— дидем мин.—Ләкин фактларның үз логикасы бар бит. Әгәр минем сәгать шушы каютадан мин йоклаган чакта югалган булса, ә шул вакыт эчендә бирегә әлеге кыз белән егет кенә кереп чыккан булсалар, әйтегезче, сәгатьне бары шулар гына алгандыр дип нәтиҗә ясарга мөмкин түгелмени?
— Мөмкин. Мин үзем дә шулай уйларга мәҗбүрмен, ләкин дөрес булып чыгармы ул безнең нәтиҗәбез? — диде капитан ярдәмчесе, нигәдер миңа туры карап.

Аның бу икеләнүе минем дә ышануымны бераз какшата төште.

— Өзеп әйтүе читен, әлбәттә. Тотылмаган — карак түгел... Шуңа күрә тикшерергә кирәк. Сез, бәлкем, хәзер кызны чакырып сорашырсыз?

— Юк, кирәкмәс,— диде капитан ярдәмчесе, урыныннан торып.— Аннары безнең пассажирлардан допрос алырга хакыбыз да юк.

— Нишләргә кирәк соң? — дидем мин, ризасызлыгымны яшермичә.— Шушының белән эшне беткәнгә санаргамыни инде?

— Нигә алай дисез? Мондый хәлләрдә без чара күрмичә калмыйбыз. Ләкин һәр эшнең үз җае бар. Борчылмагыз, без тиешле урынга хәбәр итәрбез.

Мин дәшмәдем, дөресен генә әйткәндә, аның «тиешле урынга хәбәр итәрбез» дигән сүзен аңлап та бетермәдем.

— Ә сез шулай да,— диде капитан ярдәмчесе, чыга башлаган җиреннән тукталып,— ул кызны очратсагыз, миңа читтән генә күрсәтерсез әле. Аның үзенә берни дә сиздерергә ярамый, әлбәттә.

— Кайдан соң сезне табарга булыр?

— Радиорубкага килерсез,— диде ул, каютадан чыга-чыга.

Ялгыз калгач, мин, баскан урынымнан кузгалмыйча, башымны иеп тордым: нишләргә соң? Буш каютада утыруның яки ятуның минем өчен хәзер бер кызыгы да калмады. Чыгып йөрергә булдым. Тукта, мин әйтәм, юлдаш кызым очрамасмы. Аның бит әле пароходка утыргач та чемоданын кертеп чыгудан башка минем күземә юньләп күренгәне юк. Кайда ул, нишләп йөри? Тизрәк үзен очратып, шигем расланырмы, юкмы дип, аңа бер сынап карыйсым килде. Гүя бер карау белән дөреслекне белеп алырмын кебек идем.

Палубага күтәрелдем. Төн, диңгез өсте дөм караңгы. Ләкин пароход үзе яп-якты. Барлык утлары белән балкып, шул иксез-чиксез караңгылык эчендә кечкенә, әрсез, батыр җан ияседәй һичнәрсәгә исе китмичә баруын белә. Җил тагын да көчәйгән, ахрысы, диңгез уссалланып үкерә, пароходны җиңел-җиңел генә күтәреп-күтәреп җибәрә... Йөргәндә исерек кешедәй чайкалып-чайкалып китәргә туры килә.

Пароходны бер әйләндем, ике әйләндем, төрле почмакларына да күз салдым, ләкин кызымны бер җирдә дә очрата алмадым. Кайда соң ул, шайтан алгыры? Парлап басып торучыларны кат-кат карап уздым, ләкин берсе дә мин эзләгән кыз белән егет булып чыкмады. Гаҗәп инде бу, әйтерсең юри яшеренгәннәр.

Йөреп арыгач, мин салонга кереп утырдым. Инде сәгать унберенче яртылар булгандыр, ниһаять, болар күренделәр. Минем юлдаш кызым, әлеге шул ике егетне ияртеп, салонга килеп керде. Кайдадыр бик озак ябылып утырганнар, ахрысы, барысы да кызышканнар, үзләре бик шатлар, бертуктаусыз көләләр... Буфет алдында бераз таптанып тордылар да, ерак түгел бер өстәл әйләнәсенә утырып, официантканы чакырып алдылар. Заказлары нигәдер бик кыска булды, озакламый официантка болар алдына бер шешә шампанский китереп куйды. Шуннан мин, күзләренә чагылмаска тырышып, салоннан чыктым да капитан ярдәмчесенә хәбәр итәргә киттем.

Ул әйткән җирендә юк иде, ләкин аны шунда ук телефон белән чакыртып алдылар...

Салон янына килгәч, мин аңа «кунакларымны» тәрәзәдән генә күрсәтеп әйттем:

— Әнә буфеттан сулда бер кыз, ике егет шампанский эчеп утыралармы... Шулар инде.

— Яхшы,— диде капитан ярдәмчесе һәм үзе генә салонга кереп китте.

Ул, буфет янына барып, андагы юан хатын белән нидер сөйләшкән булып, тегеләргә кырын гына күз төшергәләп, бераз вакыт басып торды. Яшьләрнең исә берәүдә дә эшләре юк, бары үзләренең бер шешә шампанскийларын көлешә-көлешә эчүләрен беләләр. Ни өчен болай вакытлы-вакытсыз, ашау-эчүсез, тиктомалга мәзәк кыланып утыра торганнардыр, һич аңламассың. Шампанский күтәрер өчен бит инде ниндидер бер зур сылтау кирәк.

Бераздан капитан ярдәмчесе салоннан чыкты да минем яныма килде.

— Күрдем... Ничего, күңелле компания! — диде ул, елмаеп.

Миңа ошамады аның бу ваемсызлыгы.

— Шулаймы? — дидем мин, коры гына.— Ә сез белмәдегезме, аларның болай кәефләнеп, шампанский эчеп утырулары нидән икән?

Капитан ярдәмчесе минем бу ризасызлыгыма игътибар итмәгән төсле итеп кенә әйтте:

— Кайсыдыр бәхәсен оттырган шикелле, сүзләреннән шулайрак аңлашылып калды.— Аннан рәсми тонга күчеп, өстәде: — Сез хәзер тыныч кына йоклый аласыз. Өч сәгатьтән Новороссийскийга җитәбез, шунда мәсьәлә ачыкланыр.

Һәм китәргә теләп борыла башлады. Мин аны туктаттым:

— Карагыз әле, иптәш помкапитан, шулай да сез үзегез ничегрәк уйлыйсыз соң? Бу типлар бит чыннан да...

Ул минем сүземне бүлде:

— Беләсезме, мондый эштә бервакытта да алдан юрап куярга ярамый. Без портка радиограмма бирдек. Аннан тиешле органнарның кешеләре килерләр, шул чакта сезнең дә, безнең дә шикләребез хәл ителер... Ә хәзер рөхсәт итегез!..

Һәм миңа честь биргәндәй итте дә, борылып китеп тә барды.

Минем аңа шактый ачуым килеп калды. Нинди формаль мөнәсәбәт! Безнең дә шикләребез хәл ителер, имеш! Юк инде, иптәш помкапитан, сәгатемне минем чәлделәр. Бик оста, шома гына йомдылар да куйдылар... Һәм тәгаен шул тар балаклар! Барысы бер шайка булып... Бу инде миңа хәзер көн кебек ап-ачык. Тик сез генә күрергә теләмисез... Кайсыдыр бәхәсен оттырган, имеш! Бәхәс оттырган өчен шартлатып шампанский ачтырырга кемнәр алар ул хәтле? Кайдан килгән, нинди акчаларын чыгарып сибәләр?

Шулай ачынып уйлана-уйлана, мин түбән төшеп, каютама кереп яттым. Утны сүндердем. Ләкин күземә барыбер йокы керми, тышта диңгез шаулый, пароход кырынаеп-кырынаеп китә, иллюминаторны әледән-әле дулкын килеп баса, шул чакта бөтенләй диңгез төбенә китә башлаган кебек тоясың үзеңне. Шактый куркыныч. Укшыта башламаса ярар иде дип борчылам.

Гомумән, җан тынычлыгым китте, уфтанып, пошынып, әйләнеп-тулганып ятам шунда...

Менә бер заман кызым кайтып керде. Ишекне әкрен генә ачты, әкрен генә япты, тынын да чыгармаска тырыша. Сәгать хуҗасы уяна күрмәсен дип бик курка, ахрысы... Мин исә күзләремне йомган килеш, йоклаган булып, аның һәр хәрәкәтенә колак салып ятам. Менә кыз караңгыда кыштыр-кыштыр чишенә башлады, менә нәрсәсендер салып урындыкка куйганда тимер тавышы чыңлап китте... Аннары койкасы шыгырдады,— кызым одеял астына чумды булса кирәк.

Эчемнән көрсенеп уйланам: дәшмәс идемме мин аңа, хәерле йокы теләмәс идемме? Без бер каютада баручы юлдашлар ич!.. Һәм шушы табигый кешелекле мөнәсәбәт урынына безнең арада хәзер шик-шөбһә, ачу-нәфрәт, курку-калтырау! Их кызый, кызый, боздың син эшне, боздың!

Кайчан, ничек йокыга киткәнмендер,— белмим, ләкин күпмедер вакыттан соң акрын гына ишек шакуга уянып киттем... Пароход туктап тора, Новороссийскийга килеп җиткәнбез, ахрысы. Мин торып ишекне аз гына ача төшеп карадым. Ачуга, капитан ярдәмчесенең тавышы ишетелде.

— Гражданин, киенеп чыгыгыз әле.

Тиз-тиз генә киенеп чыктым. Коридорда капитан ярдәмчесе белән бергә тагын ике милиционер басып тора. Берсе — старшина, бик пөхтә итеп өр-яңадан киенгән, икенчесе — рядовой. Мин алар белән исәнләштем.

Киң җилкәле, кызыл чырайлы старшина шунда, коридорда ук власть кешесенә хас җитдилек белән миннән сораша башлады. Мин вакыйганы кыскача гына сөйләп бирдем. Ахырдан ул бер-ике генә сорау бирде — күрәсең, капитан ярдәмчесе аңа барысын да сөйләгән инде.

— Димәк, тәгаен әйтә аласыз: каютага кергәндә сәгатегез яныгызда иде!

— Әйе, менә шушы кулымда иде, моны бик ачык хәтерлим.

— Сез үзегез белән баручы кызны электән белә идегезме, юкмы?

— Юк, белми идем. Беренче тапкыр очратуым...

— Сез сәгатегезне шул кыз алган дип ышанып әйтәсезме?

Мин бер мәлгә икеләнебрәк калдым.

— Ничек дим сезгә? Сәгать каютадан югалды, ә аңардан башка керүче булмаган... Менә шуннан үзегез нәтиҗә ясагыз инде.

— Ярый,— диде старшина, каешларын төзәткәләп.—Кыз каютадамы?

— Әйе, йоклый.

Шуннан старшина капитан ярдәмчесенә алдан кереп ут кабызырга кушты. Аннары үзе батыр гына кереп, кызны уятырга тотынды:

— Гражданка, ә гражданка, торыгыз әле, торыгыз!

Кыз күзен ачты һәм сискәнеп китте. Өстенә иелеп торган милиционерны күргәч, ул әйтерсең телдән калды, бер сүз әйтмәстән, одеялын иягенә чаклы тартып һәм аптырау, курку тулы күзләрен старшинага тегеп, карап тора башлады. Шул арада аның йөзе агарып та өлгерде.

— Сез курыкмагыз,— диде старшина аңа, тыныч кына.— Безгә сөйләшергә кирәк. Торыгыз. Киенәсегез дә булса, без чыгып та тора алабыз.

Ләкин чыгып тору кирәк булмады. Кыз креслодан күлмәген алып одеял астыннан чыкмыйча гына башына каплады, ашыга-ашыга өстенә тартты, аннан ялангач аякларын идәнгә салындырды. Старшина аның каршысына, минем койкага утырды.

— Ә хәзер документларыгызны рөхсәт итегез!

— Ни бар, ни булды? — диде кыз, көчкә-көчкә генә.

— Хәзер белерсез. Документыгызны, пажалысты!

Кыз, мендәр астыннан кечкенә сумкасын алып, шуннан бер кызыл билет чыгарып суздь.

— Алай... Сез студентка? — диде старшина, билетны карый-карый.— Медицинскийда укыйсыз?

— Әйе.

— Ничәнче курста?
— Өченчедә.
— Кайдан кайтып барасыз?
— Сочидан.
— Сочидан? Ни өчен Сочига бардыгыз?
— Анда минем апам тора. Шуңа кунакка бардым.
— Так, так,— диде старшина, билетны кире биреп, һәм кызга туп-туры карап тора башлады. Бу һич тартынусыз, ачыктан-ачык сынап карау иде. Кыз ахырда бу карашка түзмәде, тәмам сабырлыгын җуеп, елардай булып, ялварып сорады:
— Бу ни эш? Аңлатыгыз, зинһар!
Ләкин старшина аңа җавап бирергә ашыкмады. Юри кадалыбрак һәм озаграк карап торганнан соң гына яңадан сораша башлады:
— Ә сез пароходта нинди егетләр белән таныштыгыз, кемнәр алар?
Кыз, ярамаган бер эш сизенеп шомлангандай, бераз җавап бирә алмый торды.
— Алармы?.. Алар да студентлар,— диде ул, кыюсыз гына.
— Нинди студентлар?
— Мәскәү университеты студентлары...
— Кая баралар?
— Керчька.
— Ни өчен Керчька, ни өчен Мәскәүгә түгел?
— Алар практикага баралар...
— Сочиданмы?..— диде старшина, көлемсерәп.
Кыз кызарып куйды.
— Сочидан түгел. Кавказдан баралар. Алар — геологлар. Башта Кавказ тауларында йөргәннәр, ә хәзер Кырымга китеп баралар.
— Кара, сез аларны бик яхшы беләсез икән!
Кыз башын иде, бераз дәшми торды.
— Миңа... Үзләре әйттеләр...
— Кайчан?
— Менә пароходта танышкач.
— Ә элек сез аларны белә идегезме?
— Юк.
Старшина, күзләрен кысып, тагын кызга төбәлеп торды. Власть кешесенең бу үтә сынаулы салкын карашыннан кыз өшеп киткәндәй, куырылып, бөрешеп куйды. Башын тагын да ия төште, ничектер кечерәеп калды.
— Сез ул егетләрнең берсе белән бу каютага кереп тә чыккансыз икән,— диде старшина, гүя болай гына сүз кыстырган төсле итеп.
— Әйе,— диде кыз, акрын гына.— Кофтамны алып чыктым.
— Бары шул гынамы? Ә нигә ул чакта егетне ияртеп кердегез? Юк, чыннан да, ни өчен ул егетне ияртеп керү кирәк булды?
Кыз иреннәрен генә кысты, һаман түбән карап, хәрәкәтсез утыра бирде. Шуннан соң старшина, яңа каешлары белән шыгырдап, урыныннан торды.
— Инде алайса рөхсәт итегез чемоданыгызны карарга?
Кыз кинәт курку-аптырау тулы күзләрен старшинага күтәрде.
— Ни өчен? Бу ни эш тагын? Әйтегез, зинһар! — диде ул, гаять дулкынланып.
Старшина рәхимсез бер салкынлык белән аңа туп-туры әйтеп бирде:
— Шушы каютада баручы менә бу гражданинның йоклаганда сәгате югалган... Аның әйтүенә караганда, сәгатьне сез яки кергән егет алган булырга тиеш... Әйтегез дөресен генә, кайсыгызның эше бу?
— Боже мой! Нинди хурлык, нинди хурлык! — диде кыз, йөрәгеннән чыккан тавыш белән, һәм ике куллап йөзен каплады. Безнең барыбызга да бик читен, уңайсыз булып китте. Капитан ярдәмчесе тәмам караңгыланып, ачулы мөгрәнеп куйды:
— Шулай да ... артыкка китте бу!
Миңа да старшинаның чемоданны тентергә җыенуы бер дә ошамады. Чыннан да, кыз, алган тәкъдирдә дә, нишләп инде сәгатьне чемоданына салып куйсын ди! Тотылыр өченме? Акылга сыймый! Әмма старшина, безгә һич игътибар итмәстән, үзенең нәрсә эшләгәнен бик яхшы белгән тыныч бер кыяфәт белән, кызның чемоданын актарырга тотынды. Андагы кыз кешенең ят күздән яшерен эчке күлмәкләрен һәм башка әйберләрен берәм-берәм күтәреп селки башлады. Хәтта сабын савытын да ачып карарга онытмады. Ә кыз бу вакытта, сыны каткандай һич кыймылдамыйча, йөзен каплап утыра бирде... Старшина карап бетерде, әйберләрне ни җитте алай кире салып, чемоданны ябып куйды. Аннары торып, китель чабуларын тарткалап, кызга дәште:

— Бәлкем, үзегез генә әйтеп бирерсез, сәгать кайда? Кыз җавап бирү түгел, селкенмәде дә. Әйтерсең мәрткә киткән. Хәзер инде артык бәйләнеп, җәберләп торуның кирәксезлеге көн кебек ачык иде. Моны старшина үзе дә сизде булса кирәк, тамак кыргалап, таптанып торды да каютадан чыкты. Аның йөзе тирләгән һәм бүртенгән иде. Ахрысы, ул да, ямьсез бер эш үтәп, шуның нәтиҗәсез чыгуына шактый нык кәефсезләнгән иде.

— Ә хәзер теге егетләр янына илтегез! — диде ул, кашларын җимереп, капитан ярдәмчесенә.

Бар да югары менеп киттеләр. Алар артыннан теләр-теләмәс кенә мин дә иярдем. Дөресен генә әйткәндә, бу шактый күңелсез тамашадан минем гайрәтем чигеп өлгергән иде инде, эшнең ахыры белән кызыксыну бетте диярлек, тик әле кыз янында ялгыз каласы килмәгәнгә күрә генә ияргән булдым.

Егетләрнең бара торган каюталары пароходның икенче башында булып чыкты. Яңадан түбән төштек. Коридор очындагы бер каюта каршысына җитеп туктагач, капитан ярдәмчесе ишекне шакырга тотынды. Егетләр каты йоклыйлар иде. Кат-кат шакыгач кына ишекне ачтылар. Капитан ярдәмчесе белән старшина эчкә уздылар, мин ачык ишек төбендә калдым.

Ишекне ачкан егет бөтенләй ялангач диярлек, бер кат трусиктан гына, һәм аның гәүдәсе сокланып карарлык таза, сылу иде. Ут яктысында тәне шомартылган имән төсле елкылдап, ә каты мускуллары ап-ачык беленеп тора. Типсә тимер өзәрлек егет!

Ул, үзенең ялангач булуыннан бер дә уңайсызланмыйча власть кешеләрен бик тыныч каршылады.

Кергәч тә старшина аңардан документын сорады.

— Ни өчен ул сезгә? — диде егет.

— Ни өчен икәнен соңрак белерсез, ә хәзер рөхсәт итегез! — диде старшина, коры гына.

Егет, тыңларгамы моны, юкмы дигәндәй, беравык көттереп торды, аннары чөйдәге пиджагыннан паспортын алып бирде. Старшина паспортның һәр битен ачып карарга кереште.

— Иптәшегезне уятыгыз!

Егет иптәшен уятты. Анысы татлы йокыдан айнып җитмәгәнгә, ахрысы, каютадагы кешеләргә бөтенләй игътибар итмәде.

— Сезнең документыгыз? — диде старшина аңа.— Сезнең документыгыз дим?

Ниһаять, егет, башын күтәреп, старшинага карады.

— Документ?

— Сез, нәрсә, исерекме әллә?

Егет җавап биреп тормыйча, һаман йокысын кызгангандай, иренеп кенә каяндыр документын чыгарып сузды. Старшина алып карады, кире бирде һәм тамак кыргалап куйды.

— Студентлар, значит?

— Әйе, дипломантлар,— диде егетләрнең басып торганы.

— Кая барасыз?

— Керчька.

— Максат?

— Без практикага китеп барабыз.

— Аңлашыла... Ә әйтегез әле, сезнең кайсыгыз икенче класста баручы кызның каютасына кергән иде?

Ялангач егетнең йөзеннән бер мизгелдә гаҗәпләнү һәм борчылу чагылып узгандай булды.

— Мин...— диде.— Эш нәрсәдә соң?

— Эшме? — старшина беравык егетнең эченә үтәрдәй булып аңа текәлеп карап торды.— Эш менә нәрсәдә: сез кереп чыккан каютада баручы менә бу гражданинның сәгате югалган...

— Хуш, шуннан соң?..

— ...Сездән башка бүтән керүче булмаган. Так вот...

Егет кинәт кычкырып көлеп җибәрде:

— Ха-ха-ха! Игорь, ишеттеңме, мин — сәгать урлаучы! Ну и ну!

Старшинаның йөзенә кызыл таплар бәреп чыкты, ләкин ул таштай тынычлыгын һәм рәсми корылыгын саклап, бүленгән сүзен әйтеп бетерде:

— Так вот, эшнең нәрсәдә икәнен аңлагансыздыр?.. Ә хәзер рөхсәт итегез әйберләрегезне карарга!

— Юк, рөхсәт итмим! — диде егет, кинәт усалланып.—Сезнең ни хакыгыз бар?

— Бу башбаштаклык! — дип кычкырды егет.— Мин протестую! Мин моны болай гына калдырмаячакмын!

Ләкин старшинаның моңа һич исе китмәде, күрәсең, инде ул, кешеләрнең төрлесен һәм төрле хәлләрне күреп, өйрәнеп беткән... Үтә бер битараф салкынлык белән:

— Яхшы алайса,— диде.— Ул чагында киенегез, без сезне пароходтан алып калабыз. Анда тикшерербез.

Бу сүзләр егетләрне берьюлы аптырауга төшерде булса кирәк, алар, бер-берсенә карашып, ни әйтергә белмичә тынып калдылар. Ниһаять, койкада йокымсырап утырган егет, кулын селтәп, иптәшенә:

— Мансур, төкер үзләренә! — диде.— Әйдә, карасыннар. Пустяк өчен пароходтан калып булмас!

Шуннан соң Мансур дигәне, каршы килмәвен аңлатып, мускуллы кулларын ялангач күкрәге өстенә кушырып куйды да нәфрәт һәм бәйсезлек күрсәткән бер кыяфәт белән стенага сөялде. Старшина эшкә кереште. Иң элек егетнең чөйдәге киемнәрен капшап, суккалап карады. Аннан чемоданын ачып күрсәтергә кушты. Егет кузгалмыйча гына:

— Ачык ул! — диде.

Старшина кечкенә чемоданны идәннән алып урындыкка куйды да ачып актарырга тотынды. Дәфтәр, китаплар, ниндидер таш кисәкләре, майка, трусик, күлмәк, галстуклар — шуларның барысын да берәмберәм күтәреп, карап чыкты.

— Йә? — диде егет, каш астыннан гына аңа карап. Старшина тураеп, фуражкасын арткарак этәреп куйды.

— Тагын нәрсәләрегез бар?

— Без күп багаж йөртмибез. Әйбер җыярлык баеганыбыз юк әле.

— Шулаймы? Ә шампанский эчәргә акчаны каяндыр табасыз?

Егет авыз кырые белән генә елмайгандай итте.

— Кара, сез барысын да белеп өлгергәнсез икән инде! Бәлкем, сәгать акчасын эчкәндер болар дип уйлый торгансыздыр?

Старшина дәшмәде. Үзен ничаклы гына тыныч, салкын тотарга тырышмасын, шулай да хәле аның бик шәптән түгел иде. Йөзе караңгыланды, яңак сөякләре уйнаклап куя башлады. Ихтимал, ул егетләрне юкка борчуын, бу тентүләрнең бернинди нәтиҗә бирмәячәген эченнән аңлагандыр да инде, ләкин шулай да үз ролен ахырынача үтәүдән туктамады. Һаман рәсми җитдилеген саклап, ул койкада утырган егеткә дәште:

— Ә хәзер сезнең әйберләрне карарга рөхсәт итегез!

Егет, бу эшне бик хуп күргәндәй, кәефле генә:

— Ә, пожалуйста, рәхим итегез! — диде.

Старшина аның да киемнәрен, чемоданын карап чыкты. Әлбәттә, эзләгәнен тапмады ул. Бу вакытта инде мин каютадан читкәрәк киткән идем. Егетләрнең күз алдында торасым килмәде. Читтән генә аларның көлүен, ә старшинаның: «Сез көлмәгез... Сез аңларга тиеш, безнең бурыч...» — дип, нидер сөйләп маташуын гына ишетеп калдым.

Бераздан старшина тирләгән битен-муенын яулык белән сөртә-сөртә каютадан чыкты. Минем янга килгәч, бу миңа ачулы карап, кырыс кына сорап куйды.

— Ә сез, гражданин, үзегез исерек түгел идегезме?

Мин комачтай кызарып киттем. Һич көтмәгәндә бик капыл сукты бу милиция! Аптыраудан бары:

— Нигә алай дисез? — дип кенә әйтә алдым.

— Нигәме? Исерек кеше сәгатен генә түгел, башын да югалта. Беләбез без, күргәнебез бар... Сәгатегезне пароходка утырганчы ук югалткансыздыр может, ә?..

— Гафу итегез! — дидем мин, аның бу әрсез дорфалыгына гаять ачуым килеп.— Кем дип беләсез сез мине? Мин эчсәм дә акылымны җуя торган кеше түгел. Сезнең миңа ышанмаска һичбер хакыгыз юк, һәм мин сезгә кабатлап әйтәм: сәгатем каютада югалды...

— Ну алайса каютагыздан эзләгез дә! — диде старшина, гаҗәп салкын-сансыз гына итеп, һәм, шуның белән сүзне беткәнгә санап, капитан ярдәмчесенә борылды: —Безнең өстән йөк төште, иптәш помкапитан! Рөхсәт итегез китәргә?

Капитан ярдәмчесе иңбашларын җыерып куйды.

— Әйе, сездән дә, бездән дә эш калмады. Гаепсез кешеләрне борчыдык, гафу үтенә белмәдек... Инде гражданин пассажирның безгә артык претензиясе булмас дип уйлыйм. Сез дә, иптәш старшина, безгә ачуланып китмәгез!

— Ничего! — диде старшина, кулын селтәп.— Без күнеккән инде... Ну, пока!

Һәм честь биргәндәй итте дә, иптәшен ияртеп, югары атлады. Капитан ярдәмчесе дә алар артыннан китте. Берсе дә миңа соңгы мәртәбә сүз әйтү түгел, башын да какмады. Гаҗәп уңайсыз, мәгънәсез, ачу китергеч бер хәлдә торып калдым мин... Нәрсә булып чыкты соң бу? Гүяки менә мин, сәгатемне югалтучы, бөтен күңелсезлекләрнең бердәнбер гаепчесе булдым да калдым. Әмма гаепләме соң мин?

Аптырап, көенеп, һичнәрсә аңлый алмый өстерәлеп, каютама кайттым. Ә анда юлдаш кызым, бала сыман бөгәрләнеп, мендәренә капланган да һаман әле лышык-лышык елап ята. Чәчләре тузган, иңбашлары әкрен генә калтырыйлар,— шундый мескен, кызганыч бер кыяфәт үзендә!.. Мин ишек төбендә тукталып калдым. Нишләргә? Юатыргамы, гафу үтенергәме, йә нишләргә?.. Баягынак аның өзгәләнеп: «Нинди хурлык, нинди хурлык!» — дип әйткәне исемә төште. Һәм мин хәзер, сүз кату түгел, биредә басып торырга да ярамаганын аңладым. Бу минутта аның өчен миннән дә явыз, әшәке кеше юк бит инде!

Болай булгач, әйдә инде бөтен гарьлеген, газабын аулакта елап бетерсен дип, мин акрын гына чигендем дә кире югары ук менеп киттем.

Бер җан иясе калмаган буш палубада бүре шикелле арлы-бирле йөрим, тынычланырга, үземне юатырга тырышам. Чёрт возьми, дим, нишләп мин ул кызый каршында әшәке, гаепле кеше булып калдым соң әле? Анык түгел, минем сәгать югалды бит! Бу — факт лабаса! Инде кызга шик төшкән икән, бу бит бөтенләй

үк нигезсез түгел инде,— күрдегез!.. Хәтта капитан ярдәмчесе дә башта аңардан шикләнде. Ул инде мондый хәлләрне күреп үткәргән булырга тиеш.

Ләкин күпме генә үземне акларга тырышсам да, барыбер тынычлана алмадым. Юк, алмадым. Шул чандыр кызның, кайчан гына әле каютага җилтерәп килеп кергән ваемсыз шат кызның, хәзер койкасында бала шикелле бөгәрләнеп елап ятуы һич күз алдымнан китмәде. Күпме генә акланып маташма, әмма шулай да кешене нахакка рәнҗетү, кешенең шатлыгын үтерү килеп чыкты бит, хәерсез! Уен эшмени ул — кеше шатлыгын үтерү!

Салкын таңны мин пароход өстендә йөреп каршы алдым. Өшеп, туңып беттем, ләкин түбән төшмәдем. Көн бик акрын ачылды, кояш юк һәм булмас та, ахрысы —бөтен күк йөзен авыр, кара болытлар каплаган. Диңгез чытык ачулы, хәтта акчарлакларны да качырып бетергән. Берни юк, берни күренми... Тизрәк җитәсе дә, тизрәк җиргә төшәсе иде инде булмаса...

Ниһаять, иртәнге сәгать җиделәрдә Анапага якынлаштык. Пристане аның бик кечкенә икән. Диңгезнең чайкалуы көчле булганлыктан, пароход портка кереп тә тормады; пассажирларны алырга ярдан моторлы көймә килде.

Мин, әйберләремне алырга дип, каютага төштем. Юлдаш кызым шулай бөгәрләнеп яткан килеш йокыга киткән: одеялын да өстенә тартмаган, мескен!.. Уяна күрмәсен дип, мин сак кына плащымны, идәннән чемоданымны алдым да, эчемнән генә: «Хуш, кызый! Гаепләштән булмасын!» — дип, ишекне акрын гына ябып чыгып киттем.

Моторлы көймә көч-хәл белән генә пароход янтыгына туктый алды. Без, берничә пассажир, матрослар ярдәме белән басмадан чайкала-чайкала ярга төштек.

Көймә пристаньга килеп җиткәндә, безнең кечкенә пароход, ачулы дулкыннарны яра-яра, диңгез түренә таба китеп бара иде инде.

Ниһаять, ярга чыктык. Аяк каты җиргә баскач, юри бераз туктап тордым: тукта, мин әйтәм, рәхәтен ныграк татыйм әле!.. Аннары җәяүләп кенә шәһәргә таба киттем... Сез, хикәя әле бетмәдемени дип, гаҗәпләнә торгансыздыр... Аз гына сабыр итегез, хәзер бетә.

Инженер, әллә кайчан суынып беткән чәен алып, бер-ике генә йотым кабып куйды. Аннан ни өчендер беравык түшәмгә карап торды.

— Әйе, искиткеч булды бу маҗараның финалы! — диде ул, үзалдына башын чайкап.— Тыңлагыз, дус кеше! Анапа тигез яр өстендә утырган кечкенә бер шәһәр икән. Монда инде төньяктан искән җилләрдән ышыклап торучы таулар юк. Нәкъ бездәгечә көзге табигать, салкын, шыксыз. Урамнарда тузан бөтерелеп йөри... Мин, туктап, өстемә плащымны кидем. Шул чакта ни өчендер кулымны плащ кесәсенә тыктым... Һәм кинәт сискәнеп киттем. Тиз генә кулымны тартып чыгардым: учымда... минем сәгатем!.. Баскан урынымда каттым да калдым. Бу ни хәл? Ничек бу болай?

Иң тәүге реакциям шул булды,— сәгатемне күтәреп җиргә бәрәсем килде. Бәдбәхет, мөртәт сәгать!.. Ләкин мин бәрмәдем, ә өстенә карап шаккатып тордым да тордым. Нишләп, ничек итеп син, кабахәт, плащ кесәсенә барып кердең?.. Ниһаять, бөтен хәтеремне аякка бастырып төпченә һәм уйлана торгач, мин аңладым: йокларга ятар алдыннан үзем... үзем плащ кесәсенә салганмын икән. Әйе, бу һичшиксез шулай, башкача мөмкин түгел. Әмма ләкин бит, шайтан алгыры, мин сәгатемне һәрвакыт өстәлгә, йә урындыкка куя торган идем, нишләп соң бу юлы кием кесәсенә тыкканмын?.. Хәер, моны хәзер аңлавы читен түгел иде: пароход чайкалудан төшеп ватылмасын дип, мин аны кесәгә салган булганмын. Игътибар итегез, шуны уйларга акылым җиткән, ә менә уянгач, күпме эзләп, күпме баш ватып та исемә төшерә алмаганмын, менә бит ул, кем әйтмешли, склерозлы баш! Ахмак, юньсез, мәгънәсез баш!.. Ташка гына орыр идем үзен, ләкин соң шул инде хәзер!

Ышанасызмы, сәгатьнең табылуына аз гына да, ичмасам, куана алмадым,— шундый сыкратты, көйдерде ул мине!..

Әгәр табылмаган булса, мин барыбер, каза күргән кеше, кемнән генә шикләнсәм дә, акланырга хакым булыр иде... Ә хәзер? Хәзер инде мин, карт күсәк, тегеләр алдында гына түгел, үз вөҗданым алдында да аклана алмыйм... Иң авыры минем өчен шушы хакыйкатьне аңлау булды...

Билгеле инде, бу хәлдән соң минем үземчә матур уйлап башланган сәяхәтемнең бөтен кызыгы, яме бетте. Шул ук көнне автобуска утырып, Краснодарга киттем, анда бер кич кунып, икенче көнне Казанга очтым... Кайткач, булып үткән вакыйганы хәтта хатыныма сөйләргә дә җөрьәт итә алмадым. Шундый үкенечле, ямьсез бер төер булып утырып калды ул минем йөрәктә!

Өемә кайтып җиткәнче, мин ямьсез уйлардан котыла алмадым... Әлеге туздырылган чемоданы янында елап утыручы кыз бала да күз алдымнан бер дә китмәде. Үкенечле газабым да озакка сузылды... Чөнки бу минем төзәтеп булмас хатам иде.

1960

# Мәчет җылый

Хәтер сандыгында бик күптән бер әйбер саклана,—язмыйча котылып булмас, ахрысы, үзеннән... Әйе, кемнәр генә булмадык,ниләр генә күрмәдек без. Аянычын да, көлкесен дә. Сүз биредә шундый көлкерәк бер әкәмәт вакыйга турында барачак.

1929 — 1930 елның кышында мин өлкә газетасында штаттан тыш репортер булып эшләп йөрдем. Бик яшь идем әле ул чакта һәм, «репортер» дигән исемне бик зурдан санап, шуның белән үземчә горурланып йөри идем. Асылда исә редакциядә минем урыным да, эшем дә бик кечкенә иде, даими хезмәт хакым да юк иде, редакция кушуы буенча, төрле җирдән вак-төяк хәбәр ташып, шулардан килгән бәләкәй генә гонорарга яшәп маташа идем. Ләкин яшьлек дигән нәрсәне беләсез инде, барысына да түзә, барысын да күтәрә ул, ә җитмәгәнен хыялы белән тутырырга ярата.

Заманның да бик кызыклы, бик киеренке чагы иде. Бөек борылыш елы!.. Илне индустрияләштерү, авылны колхозлаштыру, кулакларны бетерү — менә нинди зур вакыйгалар башланып китте ул елны... Сыйнфый көрәш гаять кискенләште, бу көрәш тормышның бөтен тармакларына үтеп керде, ни генә эшләнмәсен, барысы да шул көрәш хакына эшләнә торган булды. Мәчетләр мәсьәләсендә дә эш шундыйрак иде. Мәчет — сыйнфый дошман терәге, шуннан ул үзенең зарарлы коткысын таратып ята, бетәргә тиеш аның бу соңгы оясы!.. Әгәр мәчет агачтан икән, аның манарасын шунда ук кисеп төшерделәр. Янәсе, тормасын нечкә ае белән әллә кайларга күренеп!

Без, газета кешеләре, бу эшне бик хуплап яза торган идек. Хезмәт иясенә мәчет кирәкми, мәчет — дин оясы, ә дин халык өчен әфьюн ул... Мәчетләрне япкач, дин дә бик тиз үзлегеннән бетәргә тиеш, янәсе... Гомумән, без ул чакларда күп нәрсәләр турында ансат уйлый идек. Теләк көчле, дәрт көчле, менә шунлыктан бөтен искене тиз генә аударып, өр-яңаны бастырып куярга без бик атлыгып тора идек.

Ләкин шул кышны Яңа бистә татарлары арасында гаҗәп сәер бер хәбәр тарала башлый: күптән түгел ябылган шундагы мәчет елап утыра, имеш. Дөресрәге, Ямашев урамы чатындагы таш мәчеттән һәр көнне, караңгы төшкәч, бала җылавына охшаган тавыш ишетелә, имеш... Шуны үз колаклары белән ишетүчеләр дә бар икән... Билгеле инде, башта бу уйдырмага берәү дә чынлап ышанмады. Ләкин юньсез хәбәр бит ул яман ис кебек, бер чыкса, тарала да тарала; хәзер инде Яңа бистәдә генә түгел, бөтен шәһәрдә шул хакта гына сөйлиләр: мәчет җылый!.. Бәгырьләргә төшәрлек бала тавышы белән мәчет җылап утыра!.. Һәм тагын иң сәере шунда, бу «җылауны» үз колаклары белән ишетүчеләр көннән-көн күбәя бара. Менә хикмәт!

Ниһаять, бу хәбәр безнең редакциягә дә килеп керә. Күпләр моны, билгеле, көлеп кенә каршы алалар, һәрнәрсәдән мәзәк табарга яратучылар исә үзләреннән җыен кызык өстәп тә сөйлиләр: янәсе, мәчетнең күз яшьләре яңгыр торбалары буйлап агып төшә, имеш; мәчет җылаганда аның ишек-тәрәзәләре шап та шоп ачыла да ябыла, имеш. Аннары хыялы йөгерек берәү, мәчет үзе җыламый, ә мәчетне япкан чакта чыга алмый калган карт мәзин җылап утыра, дип тә безне көлдерә. Кыскасы, көлеп сөйләүләр күп була, әмма һәркем бу хәбәргә пүстәк нәрсә дип кенә карый.

Ләкин редакциянең җаваплы секретаре Мөрти агай икенче төрлерәк уйлаган булса кирәк. Ничектер бу мине чакырып ала да әйтә:

— Менә нәрсә, егет,— ди, баскан килеш кенә.— Сиңа әйбәт кенә фельетон язарлык бер эш чыгып тора, шуны булдыра алырсыңмы?

— Нинди эш соң ул? — дим мин, гадәтемчә, каушабрак.

Биредә шуны әйтергә кирәк, Мөрти агай, күптәнге газетачы буларак, ара-тирә «Татарстан» битләренә сенсация кузгатырлык маҗаралы, шаккатыргыч материаллар да җибәргәләргә ярата иде. Миңа да күбрәк шундый материаллар табып китерергә куша иде.

— Ишеткәнсеңдер,— ди бу миңа,— әнә Яңа бистә обывательләре, мәчет җылый, дип шау итәләр.

— Әйе, ишеткән идем.

— Менә шул провокацияне фаш итәргә кирәк.

— Ничек итеп?

— Ничек итеп, имеш!.. Их, син!.. Репортер сорап торамыни, репортер үзе белергә тиеш.

Мин дәшмәдем, минем әле бөтенесеннән курка торган чагым иде. Ә Мөрти агай шактый коры кеше ул, һич юктан кыздырып, тиргәп алырга да күп сорамый иде. Ләкин шулай да ул мине, үземә сиздермичә, эченнән генә кызгана да шикелле... Еш кына тиргәп ташласа да, китергән хәбәрләремне үз кулы белән төзәтеп, озак яткызмыйча чыгаргалый тора иде. Редакторга да өстемнән зарланган чагы булмады. Үзе дә күреп, белеп тора иде минем хәлемне... Бу юлы да әнә шулай дорфа гына шелтәләп алды да кистереп кенә әйтте:

— Бүген кич шул мәчет янына бар да үз колагың белән тыңлап тор... Кайткач, бернинди мәчетнең җыламаганын, бары контр мулла-мунтагайлар чыгарган бер провокацион уйдырма булуын әче генә итеп язып бирерсең. Аңладыңмы?

— Аңладым,— дидем мин, баскан урынымда таптанып.

— Бар алайса.

Ләкин мин чыгып китәргә ашыкмадым. Куркып кына булса да, сорыйсым килде.

— Әгәр ишетелсә, нишләргә?

— Нәрсә ишетелсә? — диде Мөрти агай, кашларын җыерып.

— Мәчетнең ... җылаганы.

Мөрти агай: «Бу нинди миңгерәү?» — дигән төсле гаҗәпләнеп, азрак кызганып, күбрәк ачу белән миңа бераз карап торды.

— Син әллә шуңа ышанасыңмы, советский репортер?

— Ышанмыйм да бит, тик шулай да...

— Нәрсә шулай да?

Мин җавап бирә алмадым. Бу минутта Мөрти агай: «Булмас бу җебегәннән»,— дип уйлагандыр, бәлки, ләкин артык сүз озайтырга теләмичә, боерык биргән сыман, коры гына әйтте:

— Бар, кушканны эшлә. Бурычыңны яхшы бел: мәчет җыламый, безгә бу провокацияне фаш итәргә кирәк.

Мин сүзсез генә борылып чыгып киттем. Шулай да эчемнән генә, нигә бу мине җибәрә инде дип, аңа рәнҗемичә булдыра алмадым. Син ышанмаган кебек, мин дә мәчетнең җылавына ышанмыйм, шулай булгач, нигә әллә кайдагы Яңа бистәләргә барып торырга? Бик кирәк икән, тотарга да шушында гына, Мөрти агай әйткәнчә, контр муллаларны, фанатик карчыкларны, дин-исламны — барысын да берьюлы тетеп, фаш итеп ташларга була бит. Андый нәрсәләр, редакциядән чыкмыйча гына, бездә аз языламыни?! Юк, менә аның өчен җәһәннәм астына барырга, ниндидер ташландык, караңгы мәчетне күрергә, җитмәсә, шуның янында катып-туңып, тыңлап торырга кирәк. Әлбәттә, моның кебек мәгънәсез эшкә өлкән сотрудниклардан берәү дә бармаячак, ә минем шикелле малай репортерны җибәрергә ярый инде...

Мин редакциядән чыкканда, кояшсыз декабрь көне сүнеп тә бара иде инде. Искереп беткән пальтомның өтек якасын күтәреп, ашыга-ашыга Чернышевский буйлап (редакцияләр элек шушы урамда иде) Кольцога төшеп киттем. Күз бәйләнгәнче Яңа бистәгә барып җитәргә кирәк, чөнки, кешеләр әйтүенә караганда, мәчет нәкъ менә караңгы төшкән чакта гына (ягъни икенде-ахшам арасында) җылап ала, имеш. Аннары төн буе карулап торсаң да тавышын чыгармый, имеш.

Ул елларда Яңа бистәгә трамвайлар йөрми иде әле. Ләкин бер шәп нәрсә — «барабызлар» Свердлов урамының башында өелешеп торалар. Мин шул чаналарның берсенә килдем дә, салам тутырган чыпта кап өстенә кырын ятып, барабызчы агайга: «Әйдә киттек»,— дидем. Билен кызыл билбау белән әйбәтләп буып, тун өстеннән җилбәгәй генә чикмән кигән Әлдермеш татары, чанасына аягүрә басып, атын куа-куа, мине алып та китте. «Кая барабыз?» — дип сорады ул миннән... «Яңа бистәгә, җылак мәчет янына»,— дидем мин, ваемсыз гына. Агай даны чыккан мәчетне белә иде күрәсең: «Була»,— дип кенә куйды.

Бер егерме минуттан без барып та җиттек. Миңа кирәк ак мәчет Ямашев урамы белән бер кыска тыкрыкның чатында тора икән. Агайга унбиш тиенне бирдем дә төшеп калдым... Бу тирәләр миңа шактый таныш — үткән ел гына мин мондагы мех фабрикасында бераз эшләп киткән идем. Ул фабрика мәчеттән ерак түгел, шул ук Ямашев урамында, татар зиратына табарак урнашкан. Ә кыска тыкрыкта икенче мех фабрикасы — ул элек кайсыдыр бер татар баеның сабын заводы булган, диләр... Мәчет күршесендә генә, шул фабрика өчен булса кирәк, яңа бер бина салынып ята.

Караңгы тәмам төште диярлек. Инде нишлим, бу серле мәчетнең кайсы ягына чыгыйм дип торганда гына, күреп алдым: тар тыкрык чатында, нәкъ мәчеткә каршы, бер төркем халык басып тора. Болар анда белмичә тормыйлардыр дип, мин дә шуларга таба атладым, һәм, берсенә бер сүз катмыйча аз гына читкәрәк тукталдым. Алар минем килеп басканны сизмәделәр дә шикелле... Төркем дигәнем берничә карт белән карчык һәм ике-өч малай иде. Үзара һични сөйләшмичә генә тик кенә торалар. Нидер көтәләр. Тәрәзәләре караңгы ак мәчет тә тын гына, боек кына тора... Урам буш, үтеп-сүтеп йөрүчеләр бөтенләй юк диярлек. Тик әле бер яктан, әле икенче яктан берничә агай һәм берничә хатын-кыз төркемгә килеп кушылдылар. Исәнләшмәделәр, дәшмәделәр, килделәр дә бастылар. Сабырлыклары җитмәгән малайлар әкрен генә шаулаша башлаганнар иде, аларны шунда ук төрле яктан ысылдап кына тыйдылар...

Шактый гына вакыт узды, минем юка оек белән генә кигән ботинкаларыма бик нык сиздереп суык үтә башлады. Инде тәмам күз дә бәйләнде, ә халык серле, караңгы, тып-тын мәчеткә карап, тавыш-өнсез тора да тора... Мин дә карап торам, бу салкын, таш мәчеттә нәрсә булырга мөмкин дип уйланам, һәм ихтыярсыздан малай чакта (моннан нибары биш-алты ел элек кенә) ишеткән төрле куркыныч әкиятләрне искә төшерәм. Сөйлиләр иде, һәр мәчетнең үз өрәге була, имеш. Өрәк кешегә бер дә күренми яки бик сирәк кенә күренеп китә икән. Аның тавышы юк, йөргәне һич сизелми, үзе ул кәфенгә урангандай ап-ак, нечкә-озын була, имеш. Аннары тагын ул өрәк дигән нәрсәнең бик шаяны, йә бик явызы да булырга мөмкин, имеш. Шаян өрәк куркыныч түгел, кешегә тими, күбрәк ул кызык өчен, мәчеткә килгән картларның галош-каталарын буташтырып бетерә, мәзиннең манарага менгәндә чабуыннан тарта, хәзрәтнең мөнбәр таягын яшереп куя, имеш. Ә менә явыз өрәк бик хәтәр нәрсә, ди, кешенең каршысына ул кинәт кенә килеп чыгып, аның котын алырга ярата, ди. Кеше куркуыннан йә телдән яза, йә дивана булып кала, ди. Хәтта үче булган кешене буып та үтергәли, ди...

Мин хәзер бу әкиятләрнең берсенә дә ышанмыйм, билгеле, юк нәрсә дип көләм генә, батырайган булып, моның ише шик-куркуларны үземнән куам гына... Дөресрәге, куарга тырышам... Ә шулай да... ни

пычагыма басып торам әле мин монда? Бу мәгънәсез көтүдән эчем дә поша башлады, катып-туңып йөрүемә ачуым да килеп китте.

Ләкин нәкъ шул чакта төркемнән бер агай кинәт кенә: «Чү!» — дип куйды, аннары бик шомланып, коты алынган тавыш белән: «Әнә, әнә ишетәсезме... башлады!» —дип пышылдады. Төркемдәге халык барысы да үлектәй катып, өнсез калдылар. Ә бераздан әле берсе, әле икенчесе: «Ие шул, ие шул, ишетелә, Ходавәндә!» — диделәр. Аларга кушылып, бүтәннәр дә: «Мин дә ишеттем, мин дә ишеттем!» — дия башладылар. Бер карчык: «Мәчетебез җылый-й!» — дип сузып кына шыңшып та җибәрде. Ә башкалар кызу-кызу гына пышылдап, белгән догаларын укырга тотындылар... Ә мин берни дә ишетмим, күпме генә колагымны торгызсам да, юк, һичнәрсә ишетә алмыйм... Аптырагач, янымда басып торган бер агайга: «Чынлап әйтәсезме, мин нигәдер берни дә ишетмим»,—дидем. Агай миңа борылып карады да кырыс кына: «Ә син бүрегеңнең колагын күтәр»,— диде. Мин тиз генә малахаемның колагын күтәрдем. Шул чакта тагын берәвесе ачулы гына: «Чүгез»,— диде, без барыбыз да шым булып тынып калдык, һәм менә шушы тынлыкта — кеше әйтеп кеше ышанмас,— минем колагыма да, ниһаять, нидер килеп ишетелде. Башта ышанмыйчарак тордым, ләкин... ишетәм бит, чәнчелеп китим, ишетәм! Чынлап та «и-и» дип, бик нечкә генә сузып, әкрен генә җылаган тавыш!.. Бала җылавына охшаган, әмма сабый баланыкына караганда да нечкәрәк тавыш!.. Кайдан килә бу? Һичшиксез, мәчеттән, ләкин бинасы эченнән түгел, ә каяндыр югарыдан, түбә-кыек тирәсеннән килә — шулай ишетелде миңа...

Мин берьюлы аптырап та, куркып та калдым, әмма һич шик юк ки, җылаган тавыш бар, мин моны бер түгел, берничә тапкыр үземнең тырпайган колакларым белән ишеттем. Әллә галлюцинация микән бу? Алай дисәң, ишетүем бик ачык, кат-кат, галлюцинация шулай буламы икән соң? Аннары мондагы бөтен кешеләр дә ишетеп торалар ич, барыбызның да берьюлы алдануы мөмкин түгелдер бит инде!.. Димәк, тавыш бар, тавыш ишетелә, һәм нәкъ менә җылаган тавыш!.. Ләкин ничек инде мәчетнең җылавына ышанырга мөмкин ди? Акылга сыймый ич бу. Алайса мәчетнең эчендә нәрсәдер бар, нәрсәдер куйганнар анда...

Мәчетнең «җылавы», бүленгәләп, бер ун минут чамасы дәвам иткәндер, аннары ул тынды; ахрысы, бөтенләйгә тынды... Чөнки тавыш ишетелми башлагач та халык, сеанс тәмам дигәндәй, куркынып һәм укынып, тизрәк таралып та бетте. Ә мин баскан урынымда торып калдым. Кузгалырга көчем җитмичә, ихтыярсыздан торып калдым... Мин бик аптырауда идем, ни уйларга да, ни эшләргә дә белми идем. Әгәр кайтып, Мөрти агайга, үз колагым белән ишеттем, дип әйтсәм, ул мине шул ук көнне редакциядән куачак, валлаһи, куачак. Контрлар провокациясенә бирелгәнсең, чыпчык! диячәк. Газетада эшләргә ярамыйсың, булмый, мәгънә чыкмый синнән, диячәк. Инде ышана калса, нигә колагың белән ишеткәнеңне күзең белән күреп кайтмадың, дип, җаныма тиячәк. Бу очракта бигрәк тә — чөнки ул да, мәчет эчендә нидер бар, нәрсәдер куелган, дип уйлаячак. Аныңча бит, репортер дигән кемсә бөтен нәрсәнең төбенә үзе төшәргә, үзе күрергә, үзе белергә тиеш...

Нишләргә соң, ә?.. Вәт сиңа мәсьәлә, шайтан алгыры! Инде катып-туңып та беттем, дер-дер калтырый да башладым, ә торам, казыкка бәйләнгән тай шикелле селкенеп-таптанып торам да торам. Үзем мәчеткә карыйм, куркыныч ул миңа, үзенең серле тынлыгы, караңгы зурлыгы белән шомландыра, куркыта ул мине... Ә китеп булмый, китсәм, миңа тагы да начаррак булыр төсле. Ахырда, чарасыздан, бөтен шик-шөбһәләргә кул селтәп, мин катгый бер карарга килдем: кирәргә һәм бу серле-шомлы мәчетнең эчен бер әйләнеп, карап чыгарга кирәк. Ни булса, ул! Әйе, ни булса, ул!... Ашамас әле таш мәчет, йотмас, әйләнеп чыгармын әле ничек тә, тик каушамаска гына кирәк. Егет кеше ләбаса мин!

Ләкин шулай батыраеп урынымнан кузгалуым булды, минем алга шунда ук беренче кыенлык килеп тә басты: хәзер төн бит инде, мәчет эче дөм караңгыдыр, утсыз-нисез нәрсә генә күрә алырмын мин?! Димәк, кермичә кайтып китәргә дә була, ут юк, вәссәлам!

Мөрти агай үзе дә дөм караңгы мәчет эченә кереп тормас иде, билгеле... Әмма ни өчендер минем бу сылтаудан тизрәк файдаланасым килмәде, тәвәккәлләгән эштән ансат кына баш тарту ничектер уңайсыз булып тоелды.

Менә күзем мәчет күршесендә салынып яткан бинаның каравыл будкасына төште. Туктале, мин әйтәм, каравылчы янына кереп карыйм, аның фонаре булырга тиеш, биреп тормасмы... Булмаса инде, икенче мәсьәлә... Шулай уйлап, урам аша чыктым да такта будкага барып кердем. Каравылчы абзый бик шәп урнашкан икән —будканың нәкъ уртасында, җир идәндә кечкенә чуен мич гүләп янып тора, ә абзый шуның каршында тун чабуларын кайтарып, аякларын аерып, ботларын ышкый-ышкый җылынып утыра.

— Исәнме, абзый — мин әйтәм.

Абзый миңа кырын гына күз ташлап алды, көттереп һәм мыгырданып кына:

— Исән әле, чынлап сорасаң,— дип куйды.

— Җылы икән сезнең монда,— дидем мин, чакыруны да көтмичә, тизрәк чуен мич янына узып: — Әх, үткән икән шул суык үзәккә...

Абзый дәшмәде, тик шактый гаҗәпләнеп һәм шикле сынап, миңа баштанаяк бер сөзеп кенә карап алды. Күрәм, минем вакытсыз килеп керүем абзыйга бер дә ошамады. Аның мине, бөтенләй ят кешене,

хәзер үк будкасыннан җилтерәтеп кууы яки тревога күтәреп бирәр этлек эшләве дә мөмкин иде. Ләкин минем бик туңган булуым һәм балаларча әрсезлегем аны бераз аптыраашта калдырды шикелле.

Шулай да мин, абзый үзе телгә килгәнче, йомышымны әйтергә ашыктым.

— Абзый кеше, минем сезгә бер йомышым бар иде.

— Нинди йомыш?

— Сезнең әнә стенада «ярканат» фонаре эленеп тора. Шул фонарьны миңа биреп торсагыз иде... Әлбәттә, вакытлыча гына...

— Нигә ул сиңа?

Минем алдан ук хәзерләп куйган бер хәйләм дә юк иде, шул сәбәпле дөресен генә әйтергә туры килде:

— Мин ни... менә мәчеткә кереп чыкмакчы идем.

— Мәчеткә? Нинди мәчеткә!

— Шушы сезнең күршедәге мәчеткә?

Абзый, тиз генә сүз таба алмагандай, күзләрен шарландырып, миңа беравык тик кенә карап торды. Гаҗәпләнүе аның гүя чиктән ашкан иде.

— Син нәрсә, энекәш,— диде ул, ниһаять, әкрен-усал гына,— әллә бераз салып килдеңме?

— Юк, нишләп салыйм, ап-айнык мин.

— Соң!.. Әллә башың икеме?

— Юк, башым да берәү генә,— дидем мин, елмаерга тырышып.

— Берәү генә булса, йөрмә монда... үкчәңне күтәр. Син, ахрысы, ул мәчеттә нинди хикмәт барын ишетмәгәнсең әле.

— Ишеттем шул... Ә менә хәзер нәрсә барын кереп беләсем килә.

Абзый, кызып, кискен генә кулын селтәде:

— Әйдә, әйдә, йөрмә, кит моннан... Бетмәс монда сезнең ише суга... «с...ннәр»...

Абзыйның бу хәтле сыртын кабартып кире торуы мине чынлап борчый башлады. Ахрысы, мәсьәләне аңа ачыграк, җитдирәк итеп төшендермичә булмас.

— Син, абзый, мине куарга ашыкма әле, башта әйбәт кенә тыңла,— дидем мин, ничек тә юмалап, ипләп кенә.—Мин редакциядән килгән кеше, миңа газета редакциясе сезнең мәчеттә нәрсә барын белеп кайтырга кушты. Ышанмасагыз, менә минем документым. Так што, сезгә куркып торырга урын юк, барысы өчен дә үзем җавап бирәм. Фонарегыз өчен дә курыкмагыз, кирәксә, мин акча калдырып торам... Ә газета заданиесен үтәргә кирәк, үтәмичә ярамый, белдегезме?

«Газета» дигән сүзнең тәэсире ул заманда мәчет җылавыннан бер дә ким түгел иде — абзый шактый йомшарып киткәндәй булды. Шулай да ул тиз генә бирешергә теләмәде:

— Килгәнсең икән, бар, кер, нигә мине борчып йөрисең,— диде бу, мыгырданып кына.

— Миңа фонарь кирәк, фонарьсыз мин анда нәрсә күрим? Син инде, агай-эне, мине задание үтәмичә кайтып китәргә мәҗбүр итмә... Каравылчы фонарен бирмәде, дисәм, сиңа да рәхмәт әйтмәсләр.

— Их, парин! — диде абзый, чын-чыннан ачынып.—Үз башыгызга гына бәла алу түгел, кешегә дә зыян-зәхмәт ясап йөрисез.

— Син, абзый, борчылма, бернинди зыян да, зәхмәт тә булмас сиңа... ун минуттан фонареңны исән-сау китереп бирермен.

— Бирерсең, башыңны алып чыксаң.

— Һи, чыгабыз аны,— дигән булдым мин, көлеп.— Нык утыра баш, тәгәрәп төшәрлек түгел... Әле без синең белән шушы мич алдында, тәмләп кенә тәмәке көйрәтә-көйрәтә, мәчеттә күргәннәрне сөйләшеп утырырбыз.

Абзый авыр гына сулап, урыныннан кузгалды, ашыкмыйча гына фонарен чөйдән алып бирде. Бөтен хәрәкәте аның, бу эшкә минем катнашым юк, бары мәҗбүр булганга күрә генә, дип әйтеп тора иде кебек. Мин фонарьны урындыкка куеп яндырып карадым да борылып чыга да башладым. Шул чакта абзый түзмәде, кыюсыз гына минем арттан:

— Денсез булсаң да, белгән догаларыңны укырга онытма! — дип калды.

— Рәхмәт, абзый, онытмам,— дидем мин, ишекне ябып.

Урамда адәм заты түгел, адашып йөргән эт тә юк иде. Аяк астында чайкалган фонарь яктысына карап, мин ашыга-ашыга мәчеткә таба киттем. Мәчеткә керә торган ишек ихатада икән. Ярый, капка ачык булып чыкты, ишегалдына уздым. Ләкин мәчетнең яшел ишеге зур йозак белән бикле иде. Мин йозакны тотып та, яктыртып та караган булдым: димәк, мәчетнең үзенә керү мөмкин түгел... Гап-гади, әмма репортер башы уйлый белмәгән киртәләр чыга да тора. Нишләргә?.. Аптырап сулга борылган идем, тагын бер кечкенә яшел ишекне күреп алдым. Анысының йозагы юк иде. Бу — манарага менә торган ишек булырга тиеш... Туктале, мин әйтәм, теге җылау тавышы мәчетнең эченнән түгел, ә каяндыр югарыдан, чорма тирәсеннән ишетелгән иде бит. Мөгаен, бу манарага менә торган баскыч белән чормага да үтеп була торгандыр, һич югы шунда менеп карыйм әле.

Артык уйланып тормыйча кечкенә ишекне ачып җибәрүем булды — нәкъ каршымда бер озын ак нәрсә күренде: бу ни бу, өрәкме әллә?! Фу, нәләт, стенага сөяп куйган, мәет юа торган ак кабык икән лә!.. Йөрәк

жу итеп китте. Яшен тизлеге белән хыялымнан бу кабыкта юылган мәетләр үтеп киткәндәй булды. Хәтта ул менә хәзер минем өстемә авар шикелле булып тоелды. Мин ихтыярсыздан бер адым артка чигендем, ләкин ишекне япмадым. Беренче курку шулай бөтен тәнем буйлап йөгереп узганнан соң, мин бераз исемә килдем. Тынычлана төштем. Аннары, нигә мин бу кабыктан шулхәтле шыр җибәрдем әле, җансыз нәрсә ич ул, әкәмәт! дип, үземне юатырга тырыштым һәм, батыраеп, яңадан эчкә атладым. Кабыкны читләтебрәк уздым да борылмалы тимер баскычтан песи төсле тиз-тиз генә югары менеп киттем. Азрак менгәч тә, уң кулда тагын бер тәбәнәк кенә такта ишек күренде. Бу, билгеле, чормага үтә торган ишек булырга тиеш иде... Мин шул ишекне әкрен генә ачып, алдан фонаремны сузып, кыек астына атладым, һәм, кирәк бит, мәчетнең туфраклы түшәменә аяк басуым булды — минем фонарем кыек астында урап йөргән кискен җилдән бер-ике тапкыр гына пылт-пылт итте дә сүнде. Мин дөм караңгыда басып калдым. Ашыгып, әле бер кесәмә, әле икенче кесәмә тыгылдым, ләкин, гөнаһ шомлыгына каршы, шырпымны каравылчы будкасында, фонарьны кабызган чакта калдырганмын икән ләбаса!

Инде нишләргә? Зиһенемне җыя алмыйча багана төсле катып торам, тизрәк, яхшы чакта кире борыласым килә, әмма аягымны кузгату түгел, аз гына селкенергә дә куркам, көчем җитми. Бу караңгыда ничек төшәрмен дә ничек итеп теге кабык яныннан узармын? Ай-яй! Һәм, ышанасызмы, нәкъ шул чакта чорманың түр почмагыннан бик ачык булып әлеге бала җылаган сыман нечкә тавыш ишетелмәсенме: и-и-и-и!.. Әтекәем, әнекәем, әбекәем!.. Чәч үрә тора дип ишеткәнем бар иде, белмим, үрә торгандырмы юктырмы, әмма баш тиресе тартышып, чәч төпләрем сап-салкын булып китте... Әгәр шуннан тагын ишетелә калса?! Чәчең генә түгел... Алла сакласын!..

Ташка әйләнгәндәй торам, көтәм, ләкин юк, ишетелми, тып-тын, бары тик җил генә әйләнеп, выжлап йөри. Кайдан соң бу җиле тагын? Игътибар беләнрәк карасам, чорманың урам башында тонык кына бер яктылык күренә. Анда тәнлек тәрәзәсе булса кирәк, ул, билгеле, ватыктыр инде... Әшәке җил әнә шуннан исә икән.

Теге җылау тавышы яңадан ишетелмәгәч, минем, котларым алынып, куркуым әзрәк узгандай булды. Мин тынычлабрак уйлый башладым: димәк, монда нидер бар. Шикләнергә урын калмады — бар, һичшиксез бар! Әмма нәрсә икән соң ул? Үзлегеннән тавыш чыгара торган берәр механизм куйганнармы, әллә берәр җәнлек-мазар чыелдыймы? Җәнлек дисәң, аның йөрүе-хәрәкәте ничектер сизелергә тиеш иде. Ә бу бары «җылап» кына ала да тына, бүтән бер шылт иткән тавыш та чыгармый... Йә, нәрсә булырга мөмкин? Ничек кенә белергә моны?.. Әллә шул тавыш килгән җиргә әкрен генә барып карыйсы микән? Чынлап та, ни булыр икән, әгәр... шунда таба атласам? Әйе, ни булыр? Ә бәлки, берни дә булмас, шайтан алгыры!.. Гаҗәп, адәм баласында кызыксыну дигән нәрсә куркудан да көчлерәк икән — шул чакта мин моны бик ачык сиздем, һәм шушы кызыксыну мине гүя аркан белән тарта башлады: үз-үземә хисап та биреп тормыйча, тәвәккәлләп мин әлеге шомлы почмакка таба атладым. Аягымны шудырып кына бер атладым, ике, аннары кыюлана төшеп, аякны күтәребрәк тагын атлаган идем, кинәт нииндидер юан бернәрсәгә абынып та киттем. Каһәр генә суксын, түшәмгә аркылы салынган өрлек икән бу... Кулымнан, шалтырап, фонарем очты, үзем «гөрс» итеп йомшак туфракка капландым. Җан саклаган чакта гына була торган тизлек белән үз-үземне белештермичә сикереп торуым булды — каяндыр шунда кыек буеннан гына нәрсәдер фырылдап күтәрелде. Кош! Ходавәндә, кош ич бу, кош! Менә ул, канатларын шап-шоп селкетеп, пырылдап, кыек астында бер-ике әйләнде дә, әлеге урамга караган ватык тәрәзәдән тышка очып чыгып та китте. Бу тамашада күпме вакыт өнсез калып торуымны һич әйтә алмыйм, ләкин шуны ачык беләм, мин курку тоймадым, куркуны тоюдан узган идем. Барысы да шулхәтле кинәт булды ки, мин хәтта һичнәрсә уйларга да өлгерми калдым. Тик бераздан, исемә килгәч кенә, мине курку-шомлану калтыратып җибәргәндәй итте, ләкин бу соңга калган курку иде инде — ул мине артык тетрәтмәде.

Тагын берәр нәрсә ишетелмәсме дип, мин күпмедер вакыт селкенмичә басып тордым. Тын, караңгы, җил өргәли, әмма бернинди тавыш та, өн дә юк. Алайса бөтен хикмәт шул кошта булса кирәк. Бик сәер, бик гаҗәп иде бу, ләкин башкача тагын нәрсә уйларга, нәрсә көтәргә мөмкин?!

Ахырда мин кузгалырга булдым. Башта аягым белән капшанып, фонарьны табып алдым, аннары борылып, бик саклык белән чорма ишегенә таба киттем. Шушы минутта мине — артымда кемдер, нидер бар шикелле — тагын курку-шомлану биләп алды. Ирексездән ашыгып ишеккә килдем, тизрәк баскычка чыктым һәм даң-доң басып түбән төштем. Әлеге кабык яныннан тын да алмыйча тиз генә уздым да кечкенә яшел ишекне шап иттереп яптым. Кар яктысына чыккач, башта өстемне каккаладым, шуннан соң каравылчы будкасына кереп, абзыйга фонарен бирдем:

— Менә, абзый, фонарең исән-сау,— дидем мин, үземә дә әллә ничек ят тоелган сәер тавыш белән.

Абзый миңа, өрәккә караган шикелле, телдән калып, күзләрен чекрәйтеп карап тора башлады. Аннары минем тирләп туңган ат шикелле калтырануымны күреп, кашларын җыерыбрак, җитди генә:

— Кил, утыр, җылын,— диде.

— Юк, мин өшемәдем, абзый,— дидем мин, бөрешкән авызымны ерырга тырышып. Чыннан да мин бу минутта өшү-туңуны һич сизми идем. Шуңа күрә абзыйга рәхмәтемне әйтеп, тизрәк чыгып китәргә ашыктым.

Яңа бистәнең тын, буш урамнары буйлап атлаган чакта мин үземнең нык ачыккан һәм эттәй ватылган булуымны тойдым. Әзрәк кенә исерә төшкәндәй чалыш-чолыш атлабрак, Пеләтән урамына чыктым, аннары Тукай урамына җитеп, тәрәзәләре агарып туңган трамвайга утырдым... Утыргач та ничектер йокы баса башлаган кебек булды...

Мәскәүский (хәзерге Киров урамы) чатына җиткәч, мин трамвайдан төшеп калдым да «Сарай» номерларының ашханәсенә кердем. Монда торган татар агай-энесе... Җылы пар, төтен, шау-шу эчендә утырып, шул агай-энегә: «Сез белмисез әле минем кайда булып, ниләр күргәнемне, кәпәчләр!» — дигән төсле горур гына карап, бик әйбәтләп, сыралап, туйганчы пилмән ашадым. Аннары көчкә генә кузгалып, үземнең Суконныйдагы тар, ялгыз бүлмәмә кайтып киттем.

Икенче көнне мин редакциягә бернәрсә язмыйча буш кул белән генә бардым. Язарга вакытым да, хәлем дә булмады. Күрәсең, бик нык салкын үткәндер инде, төн буена калтырап, туңып, янып чыктым. Редакциягә килгәч тә, туп-туры Мөрти агай янына кердем.

— Йә, нәрсә китердең? — дип каршы алды ул мине.

Мин аңа түкми-чәчми бөтен күргәнемне сөйләп бирдем... Ул миңа, ышаныргамы, юкмы дигәндәй, бераз дәшми генә карап торды да җилкәсен кашып алды, авыз эченнән генә нидер мыгырданып куйды, бары шуннан соң гына телефон трубкасына тотынды. Университетның зоология кабинетына шалтыратып, шундагы кем беләндер сөйләшә башлады. Мин шәкерт сыман тик кенә тыңлап утырдым.

Мөрти агай теге кешегә мәсьәләне кыскача гына аңлатып бирде: «Әйтегезче, шундый бала җылавына охшатыбрак кычкыра торган кош бармы, булса — нинди кош ул, безнең бу тирәдә очрыймы?» — дип сорады. Зоология кабинетыннан болай җавап бирделәр: «Әйе, бала җылавына охшаганрак нечкә тавыш белән кычкыручы кош бар. Ул — филин, безнеңчә — төнге ябалак. Урманда яши торган кош, ләкин бик сирәк кенә авыл-шәһәр эчендәге кайбер ташландык биналарга да кереп оялый. Сезнең мәчеттәге кош әнә шул төнге ябалак булырга тиеш».

Мөрти агай рәхмәт әйтеп трубкасын куйды да миңа: «Кара син бу малайны»,— дигәндәй, бераз сәерсенеп карап торды, аннары саран гына елмайды:

— Молодец, энекәш, заданиене әйбәт үтәгәнсең,—диде.— Ә хәзер бар, ике-өч битлек кенә фельетон язып китер... Тозлап-борычлап яз, мәчет җылый дип провокация таратучы обывательләрнең авызын томаларлык булсын.

Ләкин ни сәбәптәндер мин ул чакта фельетонны яза алмадым. Бик тырышып утырсам да, чыкмады миннән ул фельетон. Иң кирәге үтәлмичә өстемдә калды, тик менә күпме еллар узгач кына минем аны, ниһаять, язып котыласым килде.

1967

# Шиһап абзыйның таныш кызы

*(Сугышның бер көне)*

### *Кереш сүз*

*«Шиһап абзыйның таныш кызы» моннан 50 ел чамасы элек язылды. Шул чагында ул «Совет әдәбияты»нда басылып та чыкты. Әмма минем ризалыгымнан башка хикәяне бик яман бозып бастыралар. (Хикәягә Сталинны керттеләр.) Шуңа күрә мин ул хикәяне моңарчы чыккан бер генә җыентыгыма да кертмәдем.*

*Ләкин хикәядәге төп үзәк вакыйга саклanган иде. Сүз анда бер ананың үлеме, ә биш-алты айлык баласы тере калуы турында бара. Нәкъ шуның кебек бер вакыйганы «Известия» гәзитәсе дә басып чыгара... Бу инде Чечнядагы сугыш вакыты. Гәзитәдә дә сүз бер яшь ананың үлеме, ун көнлек сабыйның исән калуы турында. Вакыйга бер үк — аналар үлә, сабыйлар исән кала... Бу хәтле үк туры килү мине башта бик гаҗәпләндергән иде. Ләкин тагын бер кат укыгач, бу ике вакыйга арасында зур аерма булуын да күрдем. Беренче хатынны фашистлар үтерә, икенчесе, яшь-яшь чәчән хатыны, руслар ташлаган бомбадан һәлак була. «Известия» кебек гәзитәнең язганына ышанмыйча мөмкин түгел, әлбәттә!*

*Мәгәр минем моннан 50 ел чамасы элек үзем язганны һәртөрле бозулардан чистартып, башка эпизодларның һәммәсен бетереп, бары тик төп вакыйганы гына калдырып, шул ук исем белән хикәяләр томына кертәсем килде. Сугышта ниләр генә булмый — без аны күреп уздык. Шуңа күрә җәяләр эчендә генә «Сугышның бер көне» дип куюны кирәк дип таптым... Укучы минем белән, шәт, килешер!*

Ниһаять, күптән көткән, күптән әзерләнгән һөҗүм сугышлары башланды. Боларның дивизиясе һөҗүмнең беренче көненнән үк якындагы кечерәк бер шәһәрне, фронтча әйтсәк, сходу бәреп алырга тиеш иде. Ләкин зур юллар чатындагы бу шәһәрне немецлар бик нык ныгытканга күрә, алай бер ыргылуда гына аңа бәреп кереп булмый. Шәһәр кырыена килеп җитә язган пехота ирексездән җиргә каплана — немец пулемет-минометларыннан башны да күтәреп булырлык түгел... Менә шул чакта аерым артдивизион командиры үзенең команда пунктын тагы да алгарак күчермәкче була. Моның өчен ул шәһәрдән читтәрәк,

калкулык өстендә ялгыз гына торган, мөгаен, бушап калган ике катлы таш йортны сайлый һәм элемтә ротасына шул йортка телефон сузарга боерык бирә.

Әйтергә кирәк, һөҗүм сугышларында элемтәчеләр җилкәсенә йөкнең бик авыры төшә. Дошман уты астында аларга элемтә чыбыкларын һаман алга таба сузарга туры килә. Шул чакта еш кына яраланалар һәм үлүләр дә булып тора...

...Зур һөҗүмнең беренче көне — күпләр өчен соңгы көн... Шиһап абзый белән сержант Карабашева өчен дә ул шулайрак булды. Әмма һич онытылмаслык көн булып калды ул карт солдат хәтерендә...

Команда пункты шәһәр читендәге калкулыкка күчәсен ишеткәч, Шиһап абзый эченнән генә: «Нигә дошман күзендәге ачык урынга менәргә кирәк булды икән»,— дип пошынып уйлап та куйган иде... Хәер, командир бу урынны белмичә сайламагандыр: моннан каршыдагы шәһәр аңа да уч төбендәге шикелле күренеп торачак... Шул кирәк тә инде аңа туплардан төзәп атар өчен...

...Йорт тирәсе хәзергә тыныч, элемтәче кызлар чыбыкны тиз суздылар, ә телефон аппаратын сержант үзе илтеп куярга булды. Командир, Шиһап абзыйның җигүле арбасына утырып, шул ялгыз йортка тиз генә барып җитәргә кушты. Мондый чакта һәр минут исәптә, шәһәр өчен каты сугышның тынып торганы юк, артдивизион командиры ашыктыра, аңа хәзер үк яңа урынга күчәргә кирәк... Барып җитүгә сержант сикереп төшеп, күн тышлы кыр аппаратын иңенә аскан килеш, йөгерә-атлый таш йортның икенче катына менеп тә китте... Шиһап абзый атын йорт ышыгына борып, шундагы бер киртәгә бәйләп куйды. Аннары ашыкмыйча гына тирә-ягына каранды. Тып-тын гына торган бу таза йорт аңарда, билгеле, зур кызыксыну уятты... Утар йорты икәнлеге күренеп тора, ихатасы — иркен, яшел чирәм, ләкин капка-коймасы юк... Каралтылары да таштан, коесы да бар... Әмма иң сәере — бернинди җан иясе, тереклек заты монда юк иде. Хәтта эт заты да, ә утар ул этсез яшәми... Күрәсең, утар хуҗасы, безнекеләрнең киләсен алдан сизеп, һәммәсен дә алып китәргә өлгергән...

...Инде таш йортның эченә кергәч, Шиһап абзый каты сугышның аны да читләтеп узмаганын ачык күрде. Тыштан бөтен генә күренгән йорт эченнән әйтерсең көчле җил исеп узган — күп нәрсә урыныннан кузгалган, урындыклар аунап ята, идән тулы савыт-саба ватыгы... Шиһап абзый уйлап куйды: йә тышта авыр бомба шартлаган, йә түбән катка мина эләккән... Аның күзе сул кулдагы бер тупсасы каерылган ишеккә төште. Сак кына шуны ачып карады: бүлмәнең шәһәр ягына караган тәрәзәләре бөтенесе дә чәлпәрәмә ватык иде. Алай, каядыр якында гына бомба бәргән — шуның эше бу, дип уйлап алды Шиһап абзый һәм бүлмә эченә атлады. Керү белән аның күзе тәрәзәләрдән читтәрәк идәндә чалкан яткан кара күлмәкле хатын гәүдәсенә төште. Шиһап абзый сискәнеп куйды, шунда ук кире чигенде...

Үлеп ятучыларны адым саен күрсә дә, солдат кеше бер генә мәеткә дә тыныч кына карый алмый — бигрәк тә хатын-кызныкына...

...Шул арада югарыдан Вера Карабашева төште. Шиһап абзыйсын бүлмә ишегенә аркасы белән сәер генә терәлеп торганын күргәч, ирексездән көлемсерәп сорады:

— Ни таптың, ни саклыйсың, дядя Шигап?..

— Анда бер хатын ята! — диде Шиһап абзый, шыпырт кына.

— Нинди хатын, кая әле! — диде Вера берьюлы җитдиләнеп һәм ишекне дә үзе ачып.

Эчкә керделәр, ватык тәрәзәдән читкәрәк яткан кара күлмәкле хатын янына бардылар... Вера шунда ук ничектер үзгәреп киткән тавыш белән:

— Үзе генә түгел ич, менә баласы да,— диде, тиз генә яннарына тезләнеп.

Чынлап та, хатынның идәнгә сузылган сул беләге өстендә искегә төргән бер сабый да ята иде... Шиһап абзый ашыгу аркасында баланы, күрәсең, шәйләп өлгермәгән.

— Ходавәндә! — диде бик гаҗәпләнеп.— Икесе бергә һәлак булдылар микәнни, бичаралар?!

Вера башта хатынның кан качкан кәфендәй ак йөзенә карады, ул — җансыз, бәлки, кичә үк инде гомере өзелгәндер... Нишләп соң бу таза чибәр генә яшь хатын монда ялгызы калган — каты атышлар башланганчы чыгып китәргә өлгермәгәнме?! Ике ут арасында калып, һәлак булучылар азмыни бу мәхшәрдә... Ә баласы?.. Вера аның искедән чыгыбрак торган тәпиенә сак кына кулын тидерде — бала тәпиен кинәт кенә үзенә тартты...

— Тере бит ул! — дип кычкырып җибәрде Вера, һәм баланы тиз генә кулына күтәреп тә алды.— Тере ләбаса бу сабый, дядя Шигап!

— Сөбханалла! Сөбханалла! — дия генә алды Шиһап абзый да, артык гаҗәпләнүдән...

...Үлек ана куенында биш-алты айлык кына тере бала!.. Бу инде фәүкылгадә вакыйга иде. Сугыш узган җирләрдә һәлак булган аналарның һәм балаларның исәбенә чыгарлык түгел... Әмма менә мондый хәлне сирәк күрергә туры килгәндер безнең Берлинга барып җиткән солдатларга да.

Ә бала әнисенең салкын беләге өстендә озак яткан булса кирәк, Вера күтәреп алу белән ул, уянып киткәндәй, күзләрен дә ачмыйча, бик әче җылап җибәрә... Вера ничектер каушабрак «нишлим соң» дигәндәй, Шиһап абзыйга карый... Шиһап абзый, ашыгып:

— Сез аны ныграк селкетеп йөрегез, селкетеп! — ди.

...Вера өзелеп җылаган баланы селкетә-селкетә алгы бүлмәгә чыга... Чыгуына тыштан дивизион командиры атылып килеп керә... Ул тирләгән, пешкән, ул ярсыган —шуңадыр, ахры, бала күтәргән Верага ачуланып кычкыра:

— Бу ни эш, нинди бала, кайдан ул?

...Шундый тыгыз вакыт, элемтә әзерме, тизрәк яңа позициядән ут ачарга кирәк, ә монда сержант бала тирбәтә?! Вера гаепле кеше сыман үзе дә җылардай булып:

— Әнисе янында ята иде,— ди һәм башы белән хатын яткан бүлмәгә ымлый.

Командир эшне әзрәк аңлады шикелле:

— Үлгән што ли?

— Әйе...

— Элемтә әзерме?

— Әзер.

— Баланы моннан хәзер үк алып китегез! — диде ул, югары катка атлый-атлый.— Санбатка!

Ә бала җылый да җылый, авызын япмыйча, эчен суыра-суыра җылый, тик нәрсәдер эзләгәндәй кулларын гына хәлсез йөртә.

— Ач бит ул мескенкәй, ач! — диде Шиһап абзый, баланың хәлен аңлап,— Шуңа өзгәләнә бит ул!..

— Нишлим соң, нишлим,— ди Вера, үрсәләнеп.

— Их, ипи сыныгын чиста чүпрәккә төреп, юешләп каптырсак, бәлки, тынычланыр да иде, бичара!

— Шулаймы?.. Бинтыбыз бар бит, икмәк сыныгы табылмас микән монда?!

— Анысы минем үземдә дә бар, түлке арбада...

— Китер соң, китер!

Ләкин шул арада, каядыр якында урнашкан безнең туплар бөтен тирә-юньне дер селкетеп, тоташтан яман гөрселдәтеп шәһәр өстенә ата да башладылар... Бу гарасаттан туган кинәт чиркандыргыч тетрәнү, гүя барлык җанлы вә җансыз нәрсәләр аша өшетеп уза. Хәтта моны көн саен ишетеп торган солдат апа да — ул да, ирексездән куырылып төшә... Инде тиздән бу тирәгә дә дошман снарядлары ява башлаячак...

Шиһап абзый борчылуын яшермичә:

— Әйдә, китик әле без моннан, яхшы чакта! — диде.

— Әйе, әйе, китик! — диде Вера да, баланы күкрәгенә кыскан килеш... Ул инде гимнастерка изүен чишеп, лифчик аша гына булса да баланы йомшак түшенә терәгән иде. Сабый, кызның җылы түшен тоеп, бер мәлгә тынып та калган иде.

...Алар йорттан ашыгып чыктылар да арбаларына йөгерделәр. Йорт артында бәйләп калдырган кола ат кинәт купкан атыштан коты алынып, баскан урынында тора алмыйча бер алга тартыла, бер артка чигенә иде... Вера тиз генә арба кырына сикереп утырды. Шиһап абзый бизгәк тоткандай калтыранган атын чиште дә, йөгереп барып, үзе дә арбасына сикерде. Юлсыз-нисез чабып киткән атны ул көчкә-хәлгә арба юлына төшерде.

Моннан 3—4 километрда, урман буендагы кечерәк кенә бер авылга санбат урнашкан иде — аларның юлы шунда табан... Анда врачлар һәм сестралар — баланы шуларга тапшырырга кирәк. Ләкин барып җитәргә өлгермәделәр, боларга каршы тирә-ягына карана-карана килүче, иңенә кызыл хач брезент сумка аскан бер сестраны очраттылар. Аны туктатып, Вера аңардан сорады:

— Сез кая барасыз?

— Менә сезгә каршы бара торырга куштылар,— диде үзе дә үсмер кыздай кечерәк кенә буйлы сестра.

— Кем кушты?

— Командный пункттан шалтыратканнар... Анда бер бала табылган икән, шуны килеп алыгыз, дигәннәр...

— Шулаймыни,— диде Вера, арбадан төшеп,— күрәсең, командир безне бу эштән тизрәк бушатырга теләгәндер...— Шулай уйлап алганнан соң, ул баланы сестрага сузды:

— Мә, иплән кенә тот алайса... Ләкин беләсеңме, иркәм, бала бик ач бит!

— Беләм,— диде сестра, сумкасын ача башлап.

— Кайдан беләсең?

— Әнисе үтерелгән ич, шулай диделәр миңа... Менә мин үзем белән аңа әзрәк кенә җылы сөт тә алып килдем.

— Һай, рәхмәт төшкере! — диде Вера, чын-чыннан куанып.

— Соң бит инде әнисе аны ике сәгать саен имезгәндер,— диде җитди генә үсмер кыздай сестра, күпне белгән ана сыман. Сумкасыннан кечкенә шешәдәге сөтен һәм балкашыгын чыгарды. Бала инде җылый-җылый арган булса кирәк — ул бары сулкылдап ыңгыраша гына иде... Ике кыз җиргә чүгәләделәр, Вера баланы иплән кенә тезләре өстенә салды, ә сестра балкашыгы белән баланың авызына әз-әзләп кенә сөт сала башлады. Беренче салганы сабыйның иреннәре буйлап агып китте, икенче салганы гына бераз авызына эләкте. Ләкин бала шунда ук чәчи дә башлады... Шиһап абзый тиз генә арбасыннан төшеп, кызлар янына чүгәләде.

— Башын күтәрергә кирәк ләбаса! — диде ул, пошынып, һәм зур кытыршы кулы белән баланың аксыл башын сак кына күтәрә төште.

...Сестра сөтен сала, бала чәчмичә генә йота — бер йота, ике йота, өч йота... Ә өч солдат шуңа сөенә-сөенә, дөньяларын онытып, тузанлы юл буенда бала ашаталар... Кечкенә шешәнең яртысына җиткәч, Шиһап абзый, ниһаять, әйтә: «Җитеп торыр, кызлар, берьюлы күп ярамас»... Кызлар да тәҗрибәле абзыйның әйткәне белән килешәләр, өчесе дә җирдән торалар, өчесе дә бик канәгатьләр — кечкенә сабыйны, ана сөте урынына сыер сөте биреп булса да, тынычландырдылар... Инде алар үз юллары белән китәргә тиешләр... Вера кулындагы йокыга киткән баланы соңгы тапкыр кысып, сүзсез генә бер үпте дә, сестрага сузды: «Саклагыз!» —диде ул аңа. Сестра, башын кага-кага, баланы кулына алды.

— Ә син, дядя Шигап,— диде сержант кыз, аңа борылып,— аларны санбатка илтеп җиткер!

— Ә син үзең?

— ...Мин туп-туры гына командный пунктка сыпыртам.

— Миңа да кирәктер бит...

— Башта боларны илтеп куй! — диде сержант, коры гына кабатлап.

— Була ул, була! — диде Шиһап абзый, кызның кәефе үзгәргәнен сизеп.— Ягез, чибәрләрем, утырыгыз алайса!..

Сестра, «борчылмагыз» — дигәндәй, елмаеп кына сержантка баш какты да баласы белән тизрәк арбага менеп урнашты.

— Кузгалдык, бахбай! — диде Шиһап абзый, якын дустына дәшкәндәй, һәм юырттырып кына китеп тә барды.

Сержант, алар артыннан бераз гына карап торганнан соң, үзе дә тузанлы юл буйлап алда өзлексез атыш тавышлары ишетелеп торган шәһәргә таба ашыга-ашыга атлады. Солдат киемендәге егерме яшьлек туташ нигә ул хәтле ашыга, ни көтә аны ул котырынган үлем туенда?! Әйе, Шиһап абзый белән алар бүтән очрашмадылар... Шул ук көнне, кичкә табан безнекеләр бәреп кергән шәһәр урамында сержант Вера Карабашева яраланып госпитальгә озатыла.

Шиһап абзый бу аяныч хәбәрне икенче көнне генә ишетеп белде... (Үзе ул урам сугышлары барган шәһәргә аты белән керә алмады — хәер, аның анда керәге дә булмады.) Әйтсәң дә юк, Вера өчен бик борчылды. Кайда, ничек яраланганын бик беләсе килде. Аның белән бергә булган элемтәче кызлардан сорашып та карады... Шуларның берсе аңа гүя юатыр өчен генә:

— Борчылма, абзый, ярасы авыр түгел, туена хәтле төзәлер,— дигән булды.

...«Туена хәтле төзәлер?!» Бирсен Алла! Әмма бу сүзне иң каты яраланучыга карап та әйтәләр. Солдатлар арасында еш әйтелә торган өметләндергеч бер сүз генә ул хәзер... Шуңа күрә җилбәзәк кызның узышлый гына әйтеп киткәне Шиһап абзыйны тынычландыра алмады. Борчылма, имеш!.. Борчылмыйча буламы соң?! Яшь җан бит ул, кызыкай, яшисе бар бит әле аның, яшисе... Менә минем кебек тормышны күпмедер татыган солдат яраланып исән калса, госпитальдән алган аягын аркасына асып өенә кайта ала — гомер иткән хатыны аны, әлбәттә, ташламаячак, карыячак... Ә кыз бала аяксыз яки кулсыз кайтса, кемгә ярый, кемгә кирәк ул?! Юк, борчылмыйча булмый кыз бала өчен... Аннары, абзый кеше аңа бик ияләшкән дә иде, серләре дә килешкән иде —шуның белән кадерле дә ул фронт дуслыгы!

1947—1996

## Фәридун белән Фирая

Эстрада артисты Фәридун Идиятов дүртенче тапкыр өйләнергә ниятләгәч, күңел күзен гастрономда эшләүче Фирая исемле яшь хатынга төшерде. Үз тирәсендәге языльшып яки языльшмыйча гына торып караган хатын-кызлардан ул ахыр чиктә туйган иде инде. Хиссият кешесе буларак, кайнар мәхәббәт аркасында кушылса да, нишләптер берсе белән дә озак тора алмады. Гел бертөрле аштан маемлагандай, ул аларга бик тиз хыянәт итә башлады. Хәер, тегеләре дә аңа бурычлы булып калмадылар шикелле... Кыскасы, егетнең «кайнар мәхәббәте», кызган тимерне сулы чиләккә тыгып алгандай, чыжылдап бер парын чыгара да шунда ук сүнеп, сүрелеп тә бетә торган иде.

Инде Фирая мәсьәләсенә килгәндә, монда Фәридунның кайнар йөрәгеннән бигрәк, салкын акылы алдарак йөрмәде микән? Ике нәрсәне ул бик нык исендә тотты: беренчедән, гастрономның «штучный» бүлегендә эшләүче яшь хатын иң элек үзе Фәридун кебек шәп куплетчы һәм көяз егетне чынлап торып яратырга тиеш иде. Икенчедән, ул хатын мәшһүр егетнең үзенә өйләнүен гаять зур бәхеттән санап, аны, ягъни Фәридун Идиятовны, җанын һәм малын кызганмыйча назларга, кararга, һәр теләгәнен үтәп торырга тиеш иде. Гастрономда эшләүчеләрнең чамасын белә ул. Затлы винолар, яхшы закускалар аның суыткычында һәрвакытта тулып торачак. Кыскасы, мәхәббәт һәм сый-хөрмәт Фираядан, ә фәлән-фәләновның хатыны дигән зур дәрәҗә аңардан — артист Идиятовтан булачак. Тик кадерен генә белсен.

Аннары, дөресен генә әйткәндә, Фирая үзе дә алай яратмаслык түгел бит әле. Ак чырайлы, кара кашлы, таза-тыгыз хатын. Ирдә дә бары бер генә тапкыр булган икән. Яше дә бик кулай, егерме бишләр тирәсендә

генә, ир белән торуның ямен-тәмен дигәндәй бик белә торган чагы. Дөрес, культура ягы түбән инде, киенү-ясануга килгәндә дә вкус юк инде, юк, бер генә сүз белән әйткәндә, ни... гыйбадия!.. Хәер, буе-сыны бар, акчасы да булса, Фәридун аны картинка төсле итеп киендерәчәк, әлбәттә.

Бу заман хатын-кызлары эстрада җырчыларын гомумән бик яраталар. Моны яхшы белгән Фәридун, билгеле, үзенең исәпләрендә ялгышмады. Яшь хатынны бер-ике мәртәбә аулак бүлмәсенә чакырып, тумбочка өстендәге төнге утны гына яндырып, кыйммәтле коньяк, эпилсин, кәнфитләр белән сыйлагач һәм хатынның йомры тезләренә озын яллы башын салып, үзенең ялгызлыгыннан ачынып зарлангач, «син кирәк миңа, бары син генә мине бәхетле итә аласың!» дип зар елагач, Фирая, ниһаять, түзмәде, йомшарды, биреште. Аның кул-аягын бәйләгән кешесе дә, югалтыр нәрсәсе дә юк иде. Шуңа күрә ул, артист-җырчы халкына бик үк ышанып бетмәсә дә, бу көяз, чибәр егет белән торып карарга булды. Алдагысын ишәк кайгыртсын, дип юатты ул үзен, ичмасам, ахирәт-дусларның эчләре бер янсын әле!

Башта матур гына торып киттеләр. Фәридунның теле татлы, мөгамәләсе йомшак, сөюләре ялкынлы булды. Буш кичләрендә Фираяны каршы алырга да баргалады, авыр сумкасын да күтәрешеп кайткалады. Тик шулай да ул кешеләр арасында үзен читтәрәк тота, гүя Фираяның ире булуын артык сиздермәскә тырыша иде... Ә бер-ике айдан инде егетебез, сөттән бизгән ата песи кебек, яшь хатынга суына башлады. Арган булып кыланды, кәефем юк дип зарланды, юкка-барга да көйсезләнә торган булып китте.

Кеше — гадәт колы, дигән бер бөек язучы. Фәридун да кол, хиссият колы. Аңа төрлелек кирәк, хисләрнең яңарып торуы кирәк. Аның әйләнәсендә мавыктыргыч акшарлы чибәркәйләр күп, шайтан алгыры! Үзләре үк сыланырга торалар... Билгеле инде, хөрлекне сагынып өлгергән Фәридун аякларын тышаудан бик тиз ычкындырды. Көн дә йөрү, көн дә кайдадыр, кемнәр беләндер утыру, төнге сәгать берләр, икеләрдә генә утын кисkәндәй әлсерәп, сөйрәлеп кайту — тик сүз генә әйтмәгез егеткә! Ул аны күтәрәчәк түгел. Әмма торуына чалбар үтүкләнгән, туфлиләр чистартылган булырга тиеш.

Фирая чыдам хатын иде. Ул тавышланмады, җыламады, ялвармады — ул түзеп карарга булды. Тик эченнән генә: «Бу чуар әтәч мине күпмегә кадәр сынамакчы була икән, карап карыйк»,— дип уйлап кына куйды... Әйтергә кирәк, егетнең әйбәт кенә чаклары да булгалый иде. Каты эчү һәм өшәнүдән соң ул бер-ике көн өйдә ята. Тына, юашлана, Фираясына да әзрәк сырпалана. Аңа ул тар билле, озын итәкле сарык туны, кара төлкедән теккән шәп бүрек вәгъдә итә. Гастрольләргә дә үзе белән алып чыкмакчы була. Хәтта чалкан яткан килеш кенә корсагы өстендә гитарасын чиртеп, Фираясына үзенең куплетларын да җырлап күрсәтә. Әмма ләкин бу озакка бармый иде. Хәл кергәч тә егет тагын киенеп-ясанып тибенгә чыгып китә. Бу чагында инде ул батырая, кикриге дә турая, үзенә күрә түгел — бик хәтәргә әйләнә.

Әнә шундый көннәрнең берсендә булды да инде бу соңгы финал! Билгеле, җырчыбыз бик соң кайта, исереп кайта. Чишенгән чагында сатучы хатынны бәхетле итүе белән гадәтенчә мактанып ала, рәхмәт сүзе ишетмәгәч, әшәке итеп сүгенә, мәсхәрәләргә тотына, бу да тәэсир итмәгәч, Фираяны киң тахтага көчләп екмакчы була.

Фирая урыныннан да кузгалмыйча аны этеп кенә җибәрә.

— Кит яныймнан, сасы көзән!

Ярым шәрә килеш чайкалып торган Фәридун тәмам котырып:

— Ә-ә, кем, минме сасы көзән? — ди дә озын бармаклары белән Фираяның битенә селтәнә.

Шуннан соң Фирая диван өстендә яткан гавай гитарасын эләктереп ала да, ярсып:

— Юк, алай сукмыйлар аны, менә болай сугалар! —дип куплетчының нәкъ баш түбәсенә китереп тондыра ки, хатын кулында гитараның бары озын сабы гына торып кала.

Фәридун әзрәк исенә килгәч, чәчләрен төзәткәләп, эре генә:

— Син кем? Вак сатучы... Түбән кеше! — ди.

Аныңча бу сүзләр Фираяны бик нык кимсетергә тиеш иде. Ләкин Фираяның җавабы әзер иде инде:

— Ә син, «югары» кеше, көн саен «түбән» кешенең аракысын эчеп, итен-маен ашап ятасың... Бар әнә берәр «югары» хатынга... Ә миңа азган әрәмтамак кирәкми... Җитәр! Бүгеннән миндә эзең булмасын!

...Фәридун өчен иң кирәге — килеш-килбәтен саклау иде.

Шуңа күрә ул бу ярсыган хатыннан яхшы чакта тизрәк чыгып китүне хәерлерәк күрде... Ә бичара гитараның үксегәндәй әкрен генә зыңлавы атна буена аның сизгер колагыннан китмәде...

1977

## Эчтәлек

*Т.Миңнуллин*. Татар әдәбиятының морзасы ............
Бала ..................................
Ана һәм кыз .............................
Бер генә сәгатькә ............................
Ялгыз каз ...............................
Мәк чәчәге ...............................
Кунакчыл дошман ............................
Икенче көнне..............................

Тауларга карап............................
Бөке .................................
Кем җырлады? ............................
Ялгызлык................................
Майбәдәр карчыкның туган көне..................
Туган туфрак..............................
Шаяру .................................
Яшьлек хатасы.............................
Сыбызгы................................
Гадәт колы ...............................
Әзер хикәя ...............................
Әҗәл дигәнең..............................
Матурлык ...............................
Төнге тамчылар ............................
Коръәнхафиз..............................
Җиз кыңгырау.............................
Картлар ................................
Бер сүз .................................
Курай .................................
Онытылмас минутлар.........................
Чикерткә ................................
Мандарин сатучы...........................
Бүрек... түгәрәк була.........................
Интервью ................................
Тынычлану...............................
Кыз һәм сәгать ............................
Мәчет җылый .............................
Шиһап абзыйның таныш кызы....................
Фәридун белән Фирая .........................

*Амирхан Еники*
*(Еникеев Амирхан Нигметзянович)*

**СОЧИНЕНИЯ**
**В ПЯТИ ТОМАХ**

**том 1**

*(на татарском языке)*

Мөхәррире *Х.Г.Әюпов*
Рәссамы *В.Е.Булатов*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире *Н.Н. Мусина*
Корректорлары *Р.В.Сабирҗанов, Г.Х.Сундукова, З.А.Даутова.*

Нәшриятка 0201 нче номерлы лицензия 1997 елның
22 августында бирелгән.

Оригинал-макеттан басарга кул куеды 18.09.2000. Форматы 84ә108 1/32.
Офсет кәгазе №1. «Школьная» гарнитурасы. Офсет басма. Шартлы басма табагы 23,52+форз.0,21. Шартлы буяу-оттиск 23,94. Нәшер-хисап табагы 25,19+0,36.
Тиражы 5000 экз. Заказ

Татарстан китап нәшрияты. 420503. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420503. Казань, ул.Баумана, 19.
**http://www.tatarstan.ru/books/**
**e-mail: tki@books.kazan.ru**

Отпечатано в РГУП «Чебоксарская типография # 1».
428019, г. Чебоксары, пр-кт Яковлева, д.15.